

# ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ

*Сайланма әсәрләр*

***Драмалар***

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(Р-Тат)-6
Г92

Төзүчесе *Казбек Гыйззәтов*

**Гыйззәтов Таҗи**

Г92 Сайланма әсәрләр, драмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 384 бит, рәс. белән.

Таҗи Гыйззәтнең күп кенә әсәрләренең сюжеты халык кичергән зур социаль вакыйгаларга нигезләнгән. Бу яктан караганда аның иҗаты татар халкының сәхнәдәге тарихы дип карарлыга мөмкин. Язучы әсәрләренең бертомлыгы нәкъ шушы үзенчәлекне нигезгә алып төзелде дә. Җыентыкта сайланма әсәрләр язылу хронологиясе буенча түгел, бәлки, тарихи чорлар тәртибендә тезелгән. Алар, 1861 елдан алып («Наемщик»), 1917 елга кадәр («Ташкыннар»), ягъни халыкның алты дистә еллык авыр кичерешле, драматик тарихын колачлый.

ISBN5-298-00629-9 © Татарстан китап нәшрияты, 2002

# НАЕМЩИК

*Музыкаль тарихи драма, биш пәрдәдә, җиде күренештә*

Катнашучылар:

Батырҗан — крепостной крестьян.
Бикчәнтәй — уенчы карт.
Гөлйөзем — аның кызы.
Булат — крепостной крестьян.
Зөбәрҗәт — аның кызы.
Гәрәй — Зөбәрҗәтнең сөйгән егете, крепостной крестьян.
Шәрифә бикә — морза хатыны, тол.
Аскәр — аның улы, яшь офицер.
Бикташ — аларның управляющие.
Йөзкәй — түрә.
Колтай — аның ярдәмчесе.
Иманкол — мулла.
Айсылу — аның олы хатыны.
Тимерхан — аларның улы.
Гөлбикә — Иманколның уртанчы хатыны.
Байбурин, Бикбаев, Абалинский — күрше алпавытлар.
Сандр — качкыннар башлыгы.
Армай — морзаларда приказчик.
Нәгыйм — вәкил.
Крестьяннар, хезмәтчеләр, солдатлар.

Вакыйга 1861 елда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Морза утары ишегалды. Бер якта — балконнар белән салынган матур өй, икенче якта — яңа салынып килә торган сарай. Такта яра торган станоклар, китерелгән кирпечләр, бүрәнәләр. Пәрдә ачылганда крепостной крестьяннар туктаусыз эшлиләр. Булат пычкы кайрап утыра.

Музыка. Хор.

Хор. Күтәр, күтәр, әйдә, дуслар,
Авыр хезмәт җиңел булсын.
Кызлар. Эш белән
Ирләр. Күңелне юатыйк.

К ы з л а р. Көч белән.
И р л ә р. Дөньясын яңгыратыйк.
Х о р. Боярлар торганчы,
Шәфәкъләр батканчы,
И р л ә р. Тир түгеп,
Х о р. Авырлыкта,
К ы з л а р. Яшь белән
И р л ә р. Без эшлибез.
Х о р. Балчыгың бас, ташыңны ват,
Балтаңны чап, пычкыңны тарт;
К ы з л а р. Шауласын
И р л ә р. Көр беләкләр тартканда,
К ы з л а р. Чыңласын
И р л ә р. Үткен балтаң чапканда...
Х о р. Шулай безнең бояр бикә
Иркенлектә гомер итә.
К ы з л а р. Мал белән
И р л ә р. Ул рәхәттә,
К ы з л а р. Дан белән
И р л ә р. Ул шатлыкта.

Җыр, музыка туктый.

Б у л а т. Бу Батырҗан нишләп тора икән? Бикташ ага йокысыннан торганчы килеп җитсә ярар иде.

Трубка тартып Б и к т а ш керә.

Б и к т а ш. Нәрсә син пычкы белән кайнашасың? Аның белән никадәр маташсаң да маен чыгара алмассың... Батырҗан кайда?

Б у л а т. Килеп җитмәгән әле.

Б и к т а ш. Нишләп бик озак? Кара, кояш кая җиткән.

Б у л а т. Белмим шул. Авырып-нитеп ятмыймы икән?

Б и к т а ш. Узган атнада да бер көн эшкә чыкмады, өченчекөн кичегеп килде, диделәр. Азына башлаган. Суктырырга вакыт җиткәндер.

Бикташ чыгып китә. Җыр башлана.

Х о р. Иж сулары ташып аккан чакта
Колач җәеп булмый йөзәргә,
Алпавытка шулай мәңге эшләп
Язганмыни безгә үләргә?
Иж сулары тирән, бик агым су,
Урман ярып килә ерактан.
Кара урмандай кайгы-хәсрәтләре
Китәр икән кайчан йөрәктән?

Б а т ы р җ а н к ү р е н ә.

Б у л а т. Әйдә, энем Батырҗан, әйдә.

Б а т ы р җ а н *(җырлый).*

Без торабыз иртән
Таңнар аткан чакта...

Х о р. Күңел әзләнә.

Б а т ы р җ а н. Сандугачлар сайрап
Канат каккан чакта...

Х о р. Йөрәк сызлана.

Б а т ы р җ а н. Нурлы таңда аваз биреп,
Ник мин болай моңланам?
Сыңар канат, моң тургайдай
Нигә икән сызланам?

Х о р. Күктә кичке шәфәкъ кебек
Кабындырма йөрәк утларын.

Б а т ы р җ а н. Килер бер көн, киләчәктә
Ярлы халык торып

Х о р. Үч алыр.
Баш тартырга, эш ташларга без әзер,
Әлегә көчсез — җиңелсәк нишләрбез?
Кулда корал юк, алда киртәләр,
Төрле яктан күңелне биртәләр.
Күтәр, күтәр, әйдә, дуслар,
Авыр хезмәт җиңел булсын.

К ы з л а р. Эш белән

И р л ә р. Күңелне юатыйк.

К ы з л а р. Көч белән

И р л ә р. Дөньясын яңгыратыйк.

Х о р. Боярлар торганчы,

И р л ә р. Шәфәкъләр батканчы
Без эшлибез.

Х о р. Балчыгың бас, ташыңны ват,
Балтаңны чап, пычкыңны тарт;

К ы з л а р. Шауласын

И р л ә р. Көр беләкләр тартканда,

К ы з л а р. Чыңласын

И р л ә р. Үткен балтаң чапканда...

Х о р. Шулай безнең бояр бикә
Иркенлектә гомер итә.

К ы з л а р. Мал белән

И р л ә р. Ул рәхәттә,

К ы з л а р. Дан белән

И р л ә р. Ул шатлыкта.

Б а т ы р җ а н. Әйдә, дуслар, ут уйнатып,
Киң болыннар

Х о р. Шаулатыйк.

Б а т ы р җ а н. Кулга алыш сәнәк, балта,
Ил өстендә
Х о р. Уйнатыйк.
Б а т ы р җ а н. Нурлы таңда аваз биреп,
Ник мин болай моңланам?
Сыңар канат, моң тургайдай
Нигә икән сызланам?
Х о р. Күктә кичке шәфәкъ кебек
Кабындырма йөрәк утларын.
Б а т ы р җ а н. Килер бер көн, киләчәктә
Ярлы халык торып
Х о р. Үч алыр.
Баш тартырга, эш ташларга без әзер,
Әлегә көчсез — җиңелсәк нишләрбез?
Кулда корал юк, алда киртәләр,
Төрле яктан күңелне биртәләр.
Күтәр, күтәр, әйдә, дуслар,
Авыр хезмәт җиңел булсын.
К ы з л а р. Эш белән
И р л ә р. Күңелне юатыйк.
К ы з л а р. Көч белән
И р л ә р. Дөньясын яңгыратыйк.
Х о р. Боярлар торганчы,
Шәфәкъләр батканчы,
И р л ә р. Тир түгеп,
Х о р. Авырлыкта,
К ы з л а р. Яшь белән
И р л ә р. Без эшлибез.
Х о р. Балчыгың бас, ташыңны ват,
Балтаңны чап, пычкыңны тарт;
К ы з л а р. Шауласын
И р л ә р. Көр беләкләр тартканда,
К ы з л а р. Чыңласын
И р л ә р. Үткен балтаң чапканда...
Х о р. Шулай безнең бояр бикә
Иркенлектә гомер итә.
К ы з л а р. Мал белән
И р л ә р. Ул рәхәттә,
К ы з л а р. Дан белән
И р л ә р. Ул шатлыкта.

Б и к т а ш керә.

Б и к т а ш. Туктагыз! Эш вакытында бу нинди җыр? Батырҗан, нигә син эшкә тагы кичегеп килдең?

Б а т ы р җ а н. Мулла абзыйның ишан кулын үбәргә барасы бар иде. Мине озатмыйча бармассың дип җибәрмәде.

Б и к т а ш. Син килгән саен нинди дә булса хәйлә табасың. Мулла абзыең әйтә: бояр эшенә барасы көнне мин аңар кичтән үк әйтеп куям, ул үзе кире нәрсә, ничек теләсә шулай йөрергә ярата, ди. Кара аны, моннан соң шундый эшең булса, суктырырмын үзеңне. *(Китә.)*

Б а т ы р җ а н. Их син, алпавыт эте! Бер тотып кадалдырырмын инде мин сине. Кайчан гына өлгерсең икән?

Б у л а т. Чү, энем, тыңлап тормасын.

Б а т ы р җ а н. Тыңласын! Тагын килеп бер генә сүз әйтеп карасын, авызында бер тешен калдырмам!.. Нишләргә инде? Көне-төне эшлисең, битең белән җир себерәсең, шулай да сиңа нәрсә диләр бит: «суктырырмын», имеш!

Б у л а т. Сөйләмә инде, Батырҗан... Бу алла бер дә күрми, ахры... Тәүбә, әстәгыфирулла...

Б а т ы р җ а н. Их, Булат абзый, ул турыда мин төннәр буенча йокламый уйлап ятам. Ләкин очына чыгып булмый.

Б у л а т. Батырҗан, бу соң Нәфикъ солдатның, Әлександр патша крестьяннарны азат итәргә тели икән дигән сүзләре дөрес булмадымыни?

Б а т ы р җ а н. Итәрләр азат! Алар безне юри генә юатып йөртәләр. Син аны көтмә, Булат абзый.

Б у л а т. Соң бит, энем, крестьян шулай гомер буе газап чигеп, крепостной булып йөрсенмени?

Б а т ы р җ а н. Без, Булат абзый, барыбыз бер булып баш күтәргәндә генә болардан котылырбыз.

Б у л а т. Юк, энем, алай булмый ул. Мин яшьрәк чакта күтәрелеп караганнар иде дә, башлап йөрүчеләрне семьялары белән бергә тереләй җиргә күмделәр. Шул хәлне күреп-ишетеп торганда кем генә башлар икән соң?

Б а т ы р җ а н. Сезнең арагыздан мин башларга уйлыйм.

Б у л а т. Син?!

Б а т ы р җ а н. Кичә Иманкол мулла кортлыгында безнең берничә кешенең җыены булды. Шунда, Шәрифә бикәдән кайбер җиңеллекләр сорарга дип, мине вәкил итеп сайладылар.

Б у л а т. Ай-һай, энем, харап булмасаң гына ярар иде. Үзең беләсең, бикәнең холкы бик начар. Авызыңнан бер сүз чыгу белән, котырган бүре кебек, өзгәләп ташларга тора.

Б а т ы р җ а н. Соң бит, Булат абзый, намусы булган кеше ятим балаларның, бөкрәйгән карт-карчыкларның бер телем икмәккә тилмереп йөрүләрен күреп ничек чыдый алсын? Әйдә, Булат абзый, тәвәккәлләп шул эшне башлыйк.

Б у л а т. Юк, анысы миннән булмас. Шулай ук сиңа да киңәш бирмим, кешене кызганам дип, арка тиреңне этләрдән тунатудан башка нәрсә чыкмас. Илгә ни булса — безгә шул булыр. Патша кайчан булса бер азат итәр әле. Әйдә, энем, юк-бар сүз белән сөйләнеп торганчы, бераз эшләп алыйк.

Эшли башлыйлар.
Музыка.

К ы з л а р. Яшел урман буйларында,
Болынлыкта әлсерәп,
И р л ә р. Чалгы тотып печән чаба
Батыр егет киң сулап.
Х о р. Әй, ямьледер җәйләрнең айлары,
Матур була болыннары, кырлары.
К ы з л а р. Кич салкында һава ярып
Чыңлый чалгы тавышы.
И р л ә р. Дошман явы ауган кебек,
Ава печән покосы.
Х о р. Әй, ямьледер җәйләрнең айлары,
Матур була болыннары, кырлары.
К ы з л а р. Чапкан печән асларында
Җир җиләкләр коела,
И р л ә р. Арып егет өйгә кайткач,
Иркәсеннән сөелә.
Х о р. Әй, ямьледер җәйләрнең айлары,
Матур була болыннары, кырлары.

Җыр бетә.
Ш ә р и ф ә бикә белән А с к ә р керә.

А с к ә р. Инәй, бүген һава нинди матур, нинди яхшы икән.

Ш ә р и ф ә. Әйе, Аскәрик, чынлап та матур икән...

А с к ә р. Инәй, мин бүген Бикбаевларга эт узыштырырга барам.

Ш ә р и ф ә. Аскәрик, син бит офицер кеше, үзеңне тота белергә кирәк, аларның кызлары да бар.

А с к ә р. Юк, инәй, үткән елны да аларның этләре узып, мине адәм көлкесе ясаган иде. Шуңа күрә мин бу юлы Оренбур кадәр җирдән менә дигән эт алып кайттым. Их, инәй, син Норикны күрсәң иде, ул чапкан чагында колакларын артка, койрыгын аска сала да... *(Сызгыра.)*

Ш ә р и ф ә. Аскәрик, бу нинди эш! Мин сине үзебезнең хуҗалыгыбыз белән таныштырыйм дисәм, син һаман шул этең турында...

А с к ә р. Виноват, инәй, прости. Таныштыр.

Ш ә р и ф ә. Менә кара, моңа кадәр тузылып-чәчелеп яткан хуҗалыгыбызны Бикташ агаң рәткә салып, имениегә ямь кертте.

А с к ә р. Әйе, инәй, бик яхшы булган.

Ш ә р и ф ә. Әнә тегендә яңа стиль белән җәйге сарай салабыз. Менә монда верандалар белән...

А с к ә р. Бикташ агага әйтергә кирәк, минем Норигыма да аерым бүлмә ясатсын.

Ш ә р и ф ә. Аскәрик! Шул этең турында ташлыйсыңмы инде, юкмы?

А с к ә р. Бетте, бетте. Әнә Бикташ ага да килә.

Б и к т а ш керә.

Б и к т а ш. Олугҗан бикәм һәм яшь түрә, сәламәтлек теләп каршыгызда баш иям. Йокыларыгызны туйдырдыгызмы, кәефләрегез ничек?

Ш ә р и ф ә. Чамадан тыш яхшы. Аскәрик, Бикташ агаңа күрсәткән яхшылыклары өчен рәхмәт әйт.

А с к ә р. Нәрсә өчен?

Ш ә р и ф ә. Бая хуҗалыгыбыз турында сөйләдем бит.

А с к ә р. Ә... әйе... Бикташ ага, аның өчен сезне благодарю.

Б и к т а ш. Тәңре гомеремне бирел, сез хуҗалар тарафыннан ышаныч булганда, хуҗалык эшләрегезне иң югары дәрәҗәгә күтәреп, тел озайтучы крестьяннарны баш идерергә сүз бирәм.

Ш ә р и ф ә. Менә Аскәрик, Бикташ агаңны күрдеңме? Ул нинди яхшы күңелле кеше. Аның авызыннан чыккан һәрбер сүз җанга ятышлы.

Б и к т а ш. Җан бикәм һәм яшь түрәм, имениенең доходын күтәрү өчен, крепостнойларга яңа бер эш тапкан идем. Сез ни диярсез икән?

Ш ә р и ф ә. Безнең өчен файдалы эш булганда, шатлык белән каршы алырбыз.

А с к ә р. Сөйләгез, мин тыңлыйм. Нинди эш ул?

Б и к т а ш. Сабан бетү белән барлык ирләрне, хатын-кызларны урманга куып, берничә мең пот сагыз, сумала кайнаттырырга телим. Хатын-кызларга тагын да берничә баш киндер арттырырга уйлыйм. Әгәр дә без шушы товарларны быел хәзерли алсак, бер француз фирмасы безнең салыначак комач фабрикабыз өчен кирәк булган машиналарны табарга сүз бирде.

Ш ә р и ф ә. Бу планыңа Аскәрик тә, шулай ук мин дә каршы килмим. Әгәр дә ул планнарың тормышка ашса, монда крестьян тирен иснәп ятудан котылып, газиз пайтәхетебез булган Петербургта торыр идек. Ярый, Бикташ, эшләгез.

Китәләр. Б у л а т , Г ә р ә й , З ө б ә р җ ә т керәләр.

Б у л а т. Менә, балалар, шунда көтеп торыгыз. Бикәләр йөреп кайтсыннар да, рөхсәт сорарбыз.

З ө б ә р җ ә т. Ярый, әти, ярый.

Б у л а т. Их, сезне! Хи-хи-хи... *(Китә.)*

З ө б ә р җ ә т. Гәрәй, бикә рөхсәт итәрме икән?

Г ә р ә й. Итәр, чибәрем, итәр. Бикәнең шатлыклы көннәре бит.

З ө б ә р җ ә т. Нинди шатлык?

Г ә р ә й. Кичә Аскәр түрә кунакка кайтты.

З ө б ә р җ ә т. Шулаймыни? Әйе, алай булганда рөхсәт итәр. Аннан соң...

Г ә р ә й. Мулладан никах укытырбыз.

З ө б ә р җ ә т. Аннан инде... пар күгәрченнәрдәй гомер буе бергә яшәрбез.

Г ә р ә й. Менә мондый гына, бәләкәй генә, кара күзле малаебыз булыр.

З ө б ә р җ ә т. Ә мин аны җырлый-җырлый тирбәтермен.

Музыка.

З ө б ә р җ ә т *(җырлый).*

Йокла, балам, йокла син,
Бәлли бәү, бәү, бәү.
Йокла, бәгърем, йом күзең,
Бәлли бәү, бәү, бәү.
Минем өмет йолдызым
Бәлли бәү, бәү, бәү.

Г ә р ә й. Күгәрчендәй без гөрләшеп
Көн итәрбез бергәләп.
Мин сөярменназлый-назлый
Син гүзәлне иркәләп.

З ө б ә р җ ә т. Бергә-бергә каршыларбыз
Сызылып таңнар атканын.
Син, сөйгәнем, янда булсаң,
Сизмәм нужа басканын.

И к ә ү б е р г ә. Нинди рәхәт булыр безгә,
Тар дөньялар киңәер,
Кара урманда безне мактап
Таң күкесе моңаер.

Г ә р ә й. Ах син, җаным, бир кулыңны,
Яр булырга гомергә.

Б е р г ә. Вәгъдә бирәм кабергәчә
Сине назлап сөяргә.

А р м а й керә.

А р м а й. Эш вакытында нишләп монда торасыз?

Г ә р ә й. Армай агай, безнең бүген үзебезгә эшли торган көнебез иде.

А р м а й. Алай булгач, нишләп монда бояр йортында кыршылып йөрисез?

Г ә р ә й. Бикәдән рөхсәт сорарга килгән идек.

А р м а й. Ә? Шулаймыни?.. Әле сез сөешеп йөрисез икән. Барыгыз, бар, сөешәсегез килсә, аулакка барыгыз. Бикә кайткач килерсез. *(Куып чыгара.)*

Б и к ә, Б и к т а ш, А с к ә р, алар артыннан Б а т ы р җ а н белән Н ә г ы й м керәләр.

Ш ә р и ф ә. Сезгә ни кирәк?

Н ә г ы й м. Данлыклы бикәбез, халык тарафыннан вәкил булып килгән идек.

Ш ә р и ф ә. Сөйләгез, мин тыңлыйм.

Н ә г ы й м. Без, бикә... без... без...

Ш ә р и ф ә. Нәрсә безелдисең, сөйлә тизрәк!

Н ә г ы й м. Юк, бикә, миннән булмас, ахры. Менә бу егет сөйләп бирер.

Б а т ы р җ а н. Бикә, крестьяннарның хәле көннән-көн авырлана, ачтан үлүчеләрнең саны күбәя бара.

Ш ә р и ф ә. Шуннан соң?

Б а т ы р җ а н. Менә шул ачтан интеккән халык үзенең теләкләрен тапшырырга дип безне җибәрде.

Ш ә р и ф ә. Теләкләрегез ни соң? Әйтегез.

Б а т ы р җ а н. Беренче: патша семьясына дип Идел җирләрендә ашлык игүне безнең өстән алыгыз. Икенче: эшли алмый торган карт-корыларга көненә бераз гына булса да икмәк бирегез. Өченчесе: безнең басуда куян кудырып ашлык таптатуны туктатыгыз. Дүртенче: ата-аналары үлеп ятим калган балаларны кантонистлыкка озатмыйча, монда, үз арабызда тәрбияләгез. Менә шуларны сорарга дип безне ил картлары җибәрде.

Ш ә р и ф ә. Хи-хи-хи!.. Тагын нинди теләкләрегез бар? Әйтегез, әйт...

Б а т ы р җ а н. Сез, бикә, көлмәгез, без моны мең ике йөз крестьян исеменнән сорыйбыз.

Ш ә р и ф ә. Тукта, башкисәр! Мондый сүзләр сөйләргә кемнән өйрәндең?

Н ә г ы й м. Соң бит, бикә, халык ач, бераз гына ярдәм итәргә кирәк иде.

Ш ә р и ф ә. Җитәр!.. Моның өчен беләсезме мин сезне нишләтермен...

Б а т ы р җ а н. Юкка кызасыз, бикә. Без бит боларны сорыйбыз гына.

Ш ә р и ф ә. Сорыйсызмы? Бикташ! Хәзер үк икесенә дә йөзәр камчы сугыш, салкын базга ябыгыз.

Батырҗан белән Нәгыймне тотарга телиләр.

Б а т ы р җ а н. Якын килмәгез!.. *(Бәреп җибәрә.)*

Крестьяннар җыела.

Ш ә р и ф ә. Каршылык итәсең?.. Тотып бәйләгез үзләрен!

Х а л ы к. Тимәгез аларга!

Ш ә р и ф ә. Нәрсә, минем имениемдә бунт?..

Б и к т а ш *(яшерен)*. Бикә, тынычланыгыз, бөтен эшне хәрап итәсез. *(Халыкка.)* Егетләр, тынычланыгыз. Ә сез урынnarыгызга барыгыз. Без монда киңәшеп карарбыз.

Б а т ы р җ а н. Карагыз аны, кара уй белән хәйлә кора күрмәгез. Көлегезне күккә очырырбыз.

Крестьяннар китәләр.

Ш ә р и ф ә. Бикташ, бу ни бу?

Б и к т а ш. Сабыр итегез. Армай!

А р м а й керә.

А р м а й. Тыңлыйм.

Б и к т а ш. Хәзер үк ат менеп Йөзкәй түрәгә чапсыннар. Гаскәр белән килеп теге башкисәрләрне тотып япсыннар.

А р м а й. Тыңлыйм, ага. *(Китә.)*

А с к ә р. Бикташ ага, минемчә, сез очень рискованный адым ясыйсыз. От этого, шайтан белсен, что может случиться.

Ш ә р и ф ә. Аскәрик, без сине кадетский корпуска биреп, куян йөрәк булыр өчен укыттыкмыни? Тукта, мин синең хакта корпус начальнигына язып әле.

А с к ә р. Виноват, инәй, прости. Моннан соң йөрәкле булырга постараюсь.

Ш ә р и ф ә. Бикташ, Йөзкәй килгәч мине чакырырсың. Аскәрик, әйдә минем белән өйгә. *(Китәләр.)*

А р м а й керә.

А р м а й. Әбәт вакыты җитте. *(Китә.)*

Эшләүчеләр әбәткә утыралар. Б и к ч ә н т ә й белән Г ө л й ө з е м керә.

Б е р ә ү. Уенчы бабай килә.

Х а л ы к. У-у... Бикчәнтәй бабай!..

Б и к ч ә н т ә й. Исәнме, балалар! Боярлар өйдәләрме? Нишләп яталар?

Б а т ы р җ а н. Өйдәләр, бабай, өйдәләр, мич башында боз киптерәләр.

Б и к ч ә н т ә й. Бикәне әйтәм, бик баеган икән. Әллә нинди сарайлар салдыра башлаган.

Г ө л й ө з е м. Әти, минем карыным ачты.

Б и к ч ә н т ә й. Балалар, берегездә артык икмәк кисәге юкмы? Кызымның бүген ашаганы юк иде.

Б а т ы р җ а н. Бар, бабай, минем талканым бар. Менә, туганкай, йөрәк ялгап алырсың.

Г ө л й ө з е м. Рәхмәт, абый.

Б и к ч ә н т ә й. Син, кызым, капкалый тор. Мин танышларым янына барып сөйләшеп килим әле. *(Китә.)*

Г ө л й ө з е м. Абый, син такта яручымы?

Б а т ы р җ а н. Әйе, туганкай.

Г ө л й ө з е м. Бояр крестьянымы?

Б а т ы р җ а н. Әйе, гөлкәй.

Г ө л й ө з е м. Мескен... Ата-аналарың120 бармы?

Б а т ы р җ а н. Беркемем дә юк.

Г ө л ө з е м. Юк? Кая киттеләр?

Б а т ы р җ а н. Әтием шушы боярның крепостной крестьяны булган, миңа дүрт яшь тулганда үлгән. Җиде яшемә җиткәндә, әнием боз астына төшеп үлде.

Г ө л й ө з е м. Боз астына? Нишләп?

Б а т ы р җ а н. Әти үлгәч, әни мине хәер сорашып туйдыра башлады. Шулай бервакыт, яз көне иде, әни мине, тәмле йокыдан уятып, күкрәгенә кысты да, балам, актык тапкыр юл беткәнче чыгып кайтыйм инде, дип. Идел аръягына, башкорт арасына хәер сорашырга чыгып китте. Шуннан көтәм, әни юк... Көтәм, юк. Өч көн булды, һаман юк. Атна булганда авыл башлыгы килеп, бәхетсез бала икәнсең, әниең Идел аша чыкканда боз астына төшеп үлгән, диде.

Г ө л й ө з е м. Ярабби, нинди куркыныч! Шуннан?

Б а т ы р җ а н. Шуннан, боярлар мине кантонистлыкка биреп җибәрә башлагач, авыл картлары алып калды. Менә шулай итеп, өйдән-өйгә йөреп, унбиш яшькә җиттем. Шуннан бирле муллага да, боярга да хезмәт итәм.

Г ө л й ө з е м. Әйе, абый, дөньяның ачысын-төчесен татыгансың икән.

Б а т ы р җ а н. Ә сез кемнәр буласыз?

Г ө л й ө з е м. Әти уенчы карт, мин җырлыйм. Җыйган хәеребезгә тамак туйдырабыз.

Б а т ы р җ а н. Сез башкортлармы?

Г ө л й ө з е м. Юк, типтәрләр. Минем әтием дә элек крепостной крестьян булган. Үзенең уеннары белән боярның күңелен тапкан да, Сәлимгәрәй дигән бояр үзен азат иткән.

Булат. Бикчәнтәй агай, я әле, булмаса, тутыккан күңелләрне нечкәртеп, уйнап, җырлап җибәрегез.

Бикчәнтәй. Юк, балалар, кызым бик арыгандыр, бераз ял итсен.

Гөлйөзем. Юк, әти, хәзер миңа хәл керде инде.

Бикчәнтәй. Алай булса әйдә, кызым, миннән эш тормас.

Музыка.

Гөлйөзем *(җырлый)*.

Сызылып кына таңнар аткан чакта
Йоклый алмый егет, аһ ора,
Ялкынланган йөрәк дуласа да,
Морза әмеренә түзә, баш ия.
Таң кошлары сайрап моңланганда
Бояр быргылары уята,
Мәңге газап, хурлык, кол булуга
Әрни йөрәк, ыргып җан ата.
Акбүз матур юрга өсләрендә
Армай килә, дуслар, каңгырып,
Аның ямьсез, усал тавышыннан
Игенчеләр кала калтырап.

Булат. Их, туганнар, йөрәккә яткан моң-зарларны ачып салдыгыз! Ягез инде, булмаса, күңел ача торганын да әйтеп алыгыз.

Егет. Чынлап та, бабай, уйнагыз, без дә кушылырбыз.

Музыка.

Гөлйөзем.

Егет күңеле җилкенә,
Яхшы ат күргәч,
Бар нужасы онытыла,
Янда сөйгәне булгач.

Хор. Их, шаян син, кызыкай, кызыкай!
Кемгә насыйп булырсың, кызыкай?
Кемнәр кочар, кемнәр сөяр
Син гүзәлне, сылукай?

Гөлйөзем. Кошлар күңеле көр була,
Ямьле җәй килгәч,
Кыз йөрәге җилкенә,
Сылу яр күргәч!

Хор. Их, шаян син, кызыкай, кызыкай!
Кемгә насыйп булырсың, кызыкай?
Кемнәр кочар, кемнәр сөяр
Син гүзәлне, сылукай?

Г ө л й ө з е м *(Батырҗанга).*

Ни уйлыйсың, егеткәй?
Уйлап күзең уйнатма,
Сөйгән ярың киттеме әллә
Ташлап сине еракка?

Х о р. Их, шаян син, кызыкай, кызыкай!
Кемгә насыйп булырсың, кызыкай?
Кемнәр кочар, кемнәр сөяр
Син гүзәлне, сылукай?

Бию башлана. А р м а й керә.

А р м а й. Бу нинди бәйрәм! Таралыгыз!

Халык тарала.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәрифә бикәнең матур бакчасы. Түрдә агачлар арасыннан сарай ишеге күренә. Бер якта шәрекъ стилендә салынган чардуган эчендә Ш ә р и ф ә бикә белән Б и к т а ш сөйләшеп утыралар. А р м а й керә.

А р м а й. Морза бикә, килделәр!
Ш ә р и ф ә. Әйт, монда керсеннәр.
А р м а й. Тыңлыйм. *(Китә.)*

Й ө з к ә й, К о л т а й һәм с о л д а т л а р керәләр.

Й ө з к ә й. Морза бикә, тәңребездән озын гомерләр сорыйм сезгә.

Ш ә р и ф ә. Сезгә дә шуны телим, Йөзкәй түрә. Исән килеп җиттегезме?

Й ө з к ә й. Хәзергә аллага шөкер. Ләкин сездә коточкыч хәлләр булса кирәк.

Ш ә р и ф ә. Әйе, түрә, крепостнойларыңнан шундый сүзләр ишетүнең авырлыгын белсәгез иде!

Й ө з к ә й. Йә, бикә, ул башкисәрләр белән нишләргә кушарсыз?

Ш ә р и ф ә. Хәзер үк берничәсен халык алдында сугарга. Ә теге башкисәрен тотып алып губернага җибәрегез.

Б и к т а ш. Әйе, Йөзкәй түрә, ул малайны безгә ничек кенә булса да моннан алдырырга кирәк. Юкса, бөтен крестьяннарны котыртып аякка бастыру куркынычы бар. Хәзер үк алып китегез.

Й ө з к ә й. Моннан элек әйтүләрегезгә карап та мин ул малайны бик яхшы беләм. Ләкин хәзер кеше күзе алдында кулга алалмыйм.

Ш ә р и ф ә. Кулга алалмыйсыз? Нишләп? Куркасызмы әллә?
Й ө з к ә й. Куркуын курыкмыйбыз, ләкин кайбер сәбәпләргә таянып, кулга алалмыйбыз.

Ш ә р и ф ә. Нинди сәбәпләр?

Й ө з к ә й. Сез аның халык алдында нинди дан тотканын яхшы беләсез. Әгәр дә мин көпә-көндез аны тотып алып китә башласам, халыкның чуалу куркынычы бар.

Б и к т а ш. Анысы дөрес. Безнең имениедә бик күп кенә кешеләрнең аның белән бер фикердә булганлыгы миңа билгеле. Ләкин бит аны монда бер минут та тотарга ярамый.

Й ө з к ә й. Без аны кеше аяк эзе басылгач, төнлә, таң вакытларында тотып алырбыз да туп-туры шәһәргә озатырбыз.

И м а н к о л керә.

И м а н к о л. Түбәнчелек белән алдыгызда баш иям, җан бикә.

Ш ә р и ф ә. Әйдә, мулла, рәхим ит.

Дога кылалар.

И м а н к о л. Исән торасызмы, җан бикәм, кәеф-хәтерләрегез яхшымы?

Ш ә р и ф ә. Аллага шөкер, изге ата.

И м а н к о л. Йөзкәй түрә, күңелегезгә тынычлык, эшегезгә уңышлык телим. Ни эшләр бетереп йөрисез?

Й ө з к ә й. Безнең билгеле инде, мулла, сезнең кебек җәмәгатьнең тормышын, илнең тынычлыгын саклыйбыз.

И м а н к о л. Яхшы, яхшы, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре ярдәм бирсен. Җан бикәм, мин сезгә бик зур бер үтенеч белән килгән идем.

Ш ә р и ф ә. Сөйлә, изге атам, нинди үтенеч ул?

И м а н к о л. Теге мәлгуньнең җәбер-золымына чыдарлыгым калмады.

Ш ә р и ф ә. Кем ул мәлгунь дигәнең? Батырҗанмы?

И м а н к о л. Әйе, шул, мәлгунь. Кичә, әлгаязе биллаһи, өч батман арышымны парникта эшләүчеләргә әҗәткә дип өләшкән.

Й ө з к ә й. Сезнең рөхсәтегездән башкамы?

И м а н к о л. Әйе, Йөзкәй түрә, минем рөхсәтемнән башка... «Минем хәләл хәзинәмне нигә аларга бирәсең», — дигәч, әлгаязе биллаһи, нәрсә ди бит...

Б и к т а ш. Тынычлан, мулла. Без үзебез дә аның турында сөйләшеп утыра идек. Иншалла, котылырсың. Без ул башкисәрне моннан бөтенләйгә озатмакчы булабыз.

И м а н к о л. Амин! Хак Тәгалә вә Тәбарәкә хәзрәтләре ярдәм бирсен... Юкса ул явызга каршы минем тәкатем калмады. Аннан соң, җан бикәм, мин сезгә булган шатлыгымны уртаклашырга килгән идем.

Ш ә р и ф ә. Нинди шатлык ул, изге атам?

И м а н к о л. Улымнан хәбәр алдым, кайтам, дип хат язган.

Ш ә р и ф ә. Шулаймыни? Бик яхшы булган, изге ата.

Й ө з к ә й. Улыгыз кайда иде соң, мулла?

И м а н к о л. Каргалы мәдрәсәләрендә гыйльми тәхсил алу белән мәшгуль иде. Падиша әгъзам хәзрәтләренә хезмәт итүне үзенә фарыз санап, солдатка каралырга кайтам, дигән.

Артта Аскәрнең хатын-кызларны кычкыртып, куып йөргәне ишетелә.

Й ө з к ә й. Ни бар анда?

Ш ә р и ф ә. Юк, болай гынадыр. Сез сөйләшә торыгыз, мин монда өстәл хәзерләтергә әйтеп чыгам. *(Китә.)*

Б у л а т, Г ә р ә й, З ө б ә р җ ә т керәләр.

Б и к т а ш. Сезгә ни кирәк монда?

Б у л а т. Бикташ ага, кызым белән булачак киявем морза бикәдән рөхсәт сорарга килгәннәр иде.

А с к ә р керә, чәчләре тузгыган, исерек.

А с к ә р. Болар нишләп йөриләр монда?

Б и к т а ш. Кыз белән егет рөхсәт сорарга килгәннәр.

А с к ә р. Ә... кияү белән кәләш! Карап карыйк... *(Барып карый.)* Малы зарарсыз икән.

И м а н к о л. Яшь түрә, хайваны ярарлык диюең алайса.

А с к ә р. Әйе, чыннан да... ярарлык...

Й ө з к ә й. Әйбәт, чибәр кыз. Моның каршына җиде ел кабердә яткан әрвахны чыгарып бастырсаң, ул да терелер иде.

И м а н к о л. Минем ул кызга күптәннән күңелем төшеп йөри иде. Шундый гүзәл кыз бала моның шикелле нәҗескә әрәм булмасын, бирегез миңа, сездән бүләк булыр.

А с к ә р. Юк, мин бу кызны Бикташ агага бирмәкче булам. *(Бикташка күз кысып.)* Аның күңеленә ошый микән?

Б и к т а ш. Сезнең кулыгыздан алынган бүләк, нинди генә булса да, мине шатландырачак.

Ш ә р и ф ә б и к ә чыгып тыңлап тора.

А с к ә р. Алыгыз кызны, мин сезгә бүләк итәм.

Ш ә р и ф ә. Аскәрик, бу ни эшең?

И м а н к о л. Җан бикәм, бу кызны хәләл җефетлеккә сораган идем, ләкин Аскәр түрә Бикташ агага бүләк итәм, ди.

Ш ә р и ф ә. Бикташ агаң кебек морза нәселеннән булган бер кешегә шундый сасы крестьян кызын тәкъдим итәргә ничек оялмыйсың? Кыз Иманкол муллага булыр. Дога кылыш алыгыз.

Б у л а т. Бикә, син алай дисең дә бит...

Ш ә р и ф ә. Ул нинди каршы сөйләү?

Б у л а т. Бикә, табаныңны үбәргә риза. Безне мыскыл итмәгез, зинһар. Гәрәй кияү дә кеше арасында көлкегә калмасын.

Б и к ә. Ул нинди мыскыл?! Ул нинди көлке? Мин сезнең туйдыручыгыз. Шулай булгач, Гәрәй киявең дә морза бикәсенең теләгенә каршы килмәс.

Г ә р ә й. Юк, бикә, мин каршы.

Ш ә р и ф ә. Каршы?

Г ә р ә й. Берничә елдан бирле сөйгән ярымны ничек итеп башкаларга бирим?

Ш ә р и ф ә. Сөйгән ярың? Хи-хи-хи! Сез бетлеләр дә сөешкән буласызмы?

Г ә р ә й. Нигә, без кеше түгелмени?

Ш ә р и ф ә. Ә син, ана көчек, шул бетлене сөйгән буласыңмы?

З ө б ә р җ ә т. Морза бикәм, бәгърем, тәңре хакына, безне аермагыз, гомерем буена битем белән җир ертырга, чәчем белән ишегалдыгызны себерергә риза. Тик безне аерып мыскыл итмәгез.

Ш ә р и ф ә. Бикташ, куып чыгар үзләрен.

Й ө з к ә й. Сез, ишәкләр, бу кыланышларыгыз белән ата-бабаларыгыздан калган йолаларны бозмакчы буласызмы?

Г ә р ә й. Без бит аның кушканнарын эшлибез. Аның теләкләренә каршы килмибез, ләкин ул минем сөйгән кызымны тартып алырга тели икән, мин аңар каршы.

Ш ә р и ф ә. Барыгыз! Кыз монда калыр!

Г ә р ә й. Башымны чабып төшерегез, аннан кызны алырсыз.

Й ө з к ә й. Хуҗаңа, ризык бирүчегә каршы торырга ярамый. Муллага да кыз бөтенләйгә түгелдер. Алай-болай... уйнаштыргалар да, кызыңның күңелен табып, бер-ике көн кунак иткәч, үзеңә кайтарып җибәрер. Аннан сиңа ни зыян?

Г ә р ә й. Ә соң намус?..

Агач арасыннан Б а т ы р җ а н һәм б е р н и ч ә к е ш е күренә.

Ш ә р и ф ә. Намус? Ха-ха-ха!.. Йөзкәй түрә, алар белән төче телләнеп торуда мәгънә юк. Кыз безнең крепостноебыз, кемгә телим шуңа бирәм. Китер кызны! Сезгә әйтәләр бит.

Г ә р ә й. Мин сезгә кызны бирмим!

Ш ә р и ф ә. Карарбыз, ничек бирмәссең икән! Бикташ, китер миңа кызны.

Бикташ аларга таба бара.

З ө б ә р җ ә т *(Бикташка)*. Кит минем янымнан. *(Этеп җибәрә.)*

Й ө з к ә й. Менә ул ничек! Сез хәзер телләрегезгә генә түгел, кулларыгызга да ирек бирә башладыгызмыни!

Ш ә р и ф ә. Йөзкәй, минем әмерләремне тыңламаулары өчен, икесенә дә йөзәр камчы сугыгыз.

Б у л а т. Морза бикәм, бераз гына оят кирәк иде. (*Алдына килеп тезләнә.)*

Ш ә р и ф ә. Сарылма миңа, пычрак. *(Тибеп ега.)*

З ө б ә р җ ә т. Бикәм, хуҗам, шәфкать итегез, кичерегез!

Ш ә р и ф ә *(яңагына сугып)*. Менә сиңа шәфкать! Мулла, ал кызны. Йөзкәй, тизрәк әмеремне җиренә җиткерегез!

И м а н к о л. Әйдә, кызым, киттек.

З ө б ә р җ ә т. Әти, Гәрәй!..

Мулла Зөбәрҗәтне алып китә.

Й ө з к ә й. Колтай! Икесенә дә йөзәр камчы сугыгыз!

К о л т а й. Яткырыгыз үзләрен!

Гәрәйне көчләп яткыралар.

Б а т ы р җ а н. Боярлар, түрәләр, бу эшегезне калдырыгыз!

Ш ә р и ф ә. Синең дә аркаң кычытамыни? Сугыгыз!

Б а т ы р җ а н. Мин сезгә әйтәм, яхшылыкта ташлагыз, юкса сөякләрегезне дә җыя алмассыз!..

Й ө з к ә й. Ни карап торасыз? Сугыгыз!

Суга башлыйлар.

Б а т ы р җ а н. Их сез, кан эчүчеләр! Менә сиңа!.. Менә монсы, ана эт, сиңа! Менә монсы сиңа!.. *(Барысын да кыйнап кача.)* Сау булыгыз, туганнар... *(Йөгереп чыга.)*

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Иманкол мулланың ишегалды. Бер якта — умарталык, икенче якта — өй. Иртә намаз вакыты. М у л л а белән Т и м е р х а н намазга чыгалар.

И м а н к о л. Улым, Тимерхан, соңга калмадыкмы икән?

Т и м е р х а н. Юк әле, әле соң түгел.

Иманкол. Гөлбикә!

Гөлбикә чыга.

Иманкол. Әйтергә оныткanмын, без намаздан чыгышлый Әсфәндияр байгурага барабыз, иртә чәйгә безне көтмәгез.

Гөлбикә. Ярый.

Китәләр.

Гөлбикә. Тукта инде, сыерларны савып, кырга куарга кирәк. *(Китә.)*

Умарталар арасыннан Батырҗан күренә. Музыка.

Батырҗан *(җырлый).*

Авылкаем, моң-зарларың синең
Яшьтән бирле уйлап сызланам,
Төннәр буе күзләр йоммый, сине
Коткарырга юллар эзләнәм.

Гөлбикә. Бу кем? Батырҗан түгелме?

Батырҗан. Җәйге төннең матур иртәседәй,
Кайчан икән синдә таң атар?
Караңгылык куган Чулпан кебек,
Йөрәгеңдә кайчан үч янар?

Гөлбикә. Батырҗан!

Батырҗан. Чү, Гөлбикә, шаулама!

Гөлбикә. Нигә кайттың? Тоталар бит. Сине монда эзлиләр.

Батырҗан. Анысын беләм, ләкин миңа кайбер кешеләрне күрергә кирәк иде.

Гөлбикә. Кемне?

Батырҗан. Булат абзыйларны, Гәрәйләрне.

Гөлбикә. Тагын кемнәрне?

Батырҗан. Тагын дус-ишләрне.

Гөлбикә. Мине сагынмадыңмыни?

Батырҗан. Сине дә сагындым.

Гөлбикә. Их, Батырҗан, синең өчен эчтән януларымны нечкә карашларым белән аңлатырга никадәр йөрсәм дә, аңламадың, ахры...

Батырҗан. Аңлыйм, Гөлбикә. Ләкин син бит мулла хатыны.

Гөлбикә. Булсын. Синең өчен булганда үземне корбан итәргә риза. *(Барып сарыла.)*

Батырҗан. Җибәр, Гөлбикә.

Гөлбикә. Син миннән җирәнәсең?..

Батырҗан. Тукта, хәзергә бу хакта сөйләнүләрне калдырыйк. Син миңа шуны әйт, сездә нинди хәбәрләр бар?

Г ө л б и к ә. Кичә Тимерхан кайтты.

Б а т ы р җ а н. Тимерхан? Нигә?

Г ө л б и к ә. Наборга каралырга.

Өй эчендә талаш, кычкырыш, елаган тавыш ишетелә.

Б а т ы р җ а н. Кемне елаталар анда?

Г ө л б и к ә. Теге убырлы карчык тагы Зөбәрҗәтне кыйный торгандыр. Син кач, күрмәсеннәр.

Батырҗан китә. А й с ы л у З ө б ә р җ ә т н е кыйнап чыгара.

А й с ы л у. Себерке, уйнашчы! Нигә китмисең, теләнче марҗа! Өйгә кирәсе булма! *(Кереп китә.)*

Г ө л б и к ә. Акыллым, тагын сине кыйнадымыни?!

З ө б ә р җ ә т. Үтерәләр бит, түтәй, нишлим инде?

Г ө л б и к ә. Елама, акыллым, елама, сабыр ит.

З ө б ә р җ ә т. Гөлбикә түтәй, өйрәт, нишләргә миңа?

Г ө л б и к ә. Кайгырма, мин сиңа берәр җаен табармын.

А й с ы л у керә.

А й с ы л у. Әле монда иркәләнергә кеше таптыңмыни? Әнә тагын күмер чүлмәгеңнең капкачын ачык калдыргансың. Эш рәте белмәсәгез дә, ирләр белән себерелергә беләсез. Илле яшьлек картның муенына асылынмасагыз, үз хәерчеләрегез беткәндер шул. Байга барып, рәхәт тормышта торасыгыз килгәндер. Күрсәтермен мин сиңа рәхәт! Кипкән балык кебек каклап кип-терермен!

Г ө л б и к ә. Көндәш, бераз гына алладан курку кирәк иде.

А й с ы л у. Сиңа ни калган, нигә кысыласың?

Г ө л б и к ә. Ул кадәр кыйнарга эт баласы түгел бит ул.

А й с ы л у. Ә мин эт баласы идеммени? Ике себерке өстемә килдегез.

Г ө л б и к ә. Безне көчләп бирделәр.

А й с ы л у. Тамагың туя башлагандыр, чандыр марҗа.

Г ө л б и к ә. Җитәр сиңа, кылый җылан! Моңа кадәр чыдап килгәнем дә җитәр. Күзеңне төртеп тишәрмен.

А й с ы л у. Чандыр марҗа, әле син шулаймыни!

Г ө л б и к ә. Шулай шул.

А й с ы л у. Акырма миңа!

Г ө л б и к ә. Акырсам, әллә куркаммы! Башыңда бер бөртек чәчеңне калдырмам.

А й с ы л у. Сузма кулың, ник сузасың!

Г ө л б и к ә. Төртмә, убыр, ник төртәсең!

А й с ы л у. Типмә, чандыр марҗа, ник тибәсең!

Г ө л б и к ә. Тартма чәчтән, ник тартасың! Кит моннан, убырлы карчык! *(Төртеп ега.)*

А й с ы л у. Алла, билем, алла, билем... Каравыл!.. Каравыл!.. *(Кереп китә.)*

Г ө л б и к ә. Елама, акыллым, тынычлан. Мин сыерларны гына савыш килим әле. *(Китә.)*

Музыка.

З ө б ә р җ ә т *(җырлый).*

Инде нишлим, яшьлек матурлыгым
Кырау төшеп иртә тапталгач?
Инде нишлим, шәфкать итеп
Ярдәм кулын кем дә сузмагач?
Көн дә сыктап түгәм күз яшьләрем
Таң җилләре койган тамчыдай.
Җан әрнетеп, мыскыл, хурлауларга
Яшь башкаем түзеп, ник чыдый?

Батырҗан кереп тыңлап тора.

З ө б ә р җ ә т. Инде нишлим, тормыш киләчәгем
Кормавыклар белән үрелгәч?
Инде нишлим, ямьле дөньясында
Яшәр өчен өметем киселгәч?

Б а т ы р җ а н. Зөбәрҗәт!

З ө б ә р җ ә т. Тукта, бу кем? Батырҗан абый, синме бу?

Б а т ы р җ а н. Чү, Зөбәрҗәт! Нигә елыйсың?

З ө б ә р җ ә т. Абыем, коткар мине, коткар...

Б а т ы р җ а н. Елама, сине коткару турында Гәрәй белән сөйләштек. Мин Урал ягына барып урнашкач, минем янга килерсез. Елама, сабыр ит.

З ө б ә р җ ә т. Батырҗан абый, чынлап әйтәсеңме?

Б а т ы р җ а н. Әйе, гөлкәй, чынлап әйтәм.

З ө б ә р җ ә т. Батырҗан абый, сине эзлиләр дә, ди. Тотмасыннар!

Б а т ы р җ а н. Беләм. Менә нәрсә, Зөбәрҗәт, Гөлйөземнәр безнең авылда икән. Озакламый алар монда килергә тиешләр. Ничек кенә булса да аны күреп, минем монда качып ятканымны әйтә алмассыңмы?

З ө б ә р җ ә т. Ярар, Батырҗан абый, әйтермен.

Урамда тавышлар.

Б а т ы р җ а н. Ул нинди тавыш?

З ө б ә р җ ә т *(барып карый).* Батырҗан абый, Гөлйөземнәр!

Б а т ы р җ а н. Гөлйөземнәр? Ярый, мин киттем, үзең җайлап әйтерсең. *(Китә.)*

Б и к ч ә н т ә й белән Г ө л й ө з е м күренә.

Б и к ч ә н т ә й. Остабикәләр өйдәме? Иманкол мулла кереп чыгарга кушкан иде.

З ө б ә р җ ә т. Гөлйөзем, Батырҗан абый бездә качып ята. Мине күрергә тырышсын, диде.

Г ө л й ө з е м. Зөбәрҗәт, тизрәк әйт, кайда ул?

З ө б ә р җ ә т. Батырҗан абый!.. *(Китә.)*

Б а т ы р җ а н керә.

Г ө л й ө з е м. Батырҗан, бу синме?

Б а т ы р җ а н. Әйе, Гөлйөзем, мин!..

Г ө л й ө з е м. Сөйлә, Батырҗан, хәлең ничек?

Б а т ы р җ а н. Урманда, биктау качкыннары янында ята идем, синең безнең авылга килгәнеңне ишетеп, саубуллашырга кайттым.

Г ө л й ө з е м. Саубуллашырга? Аннан кая барасың?

Б а т ы р җ а н. Мин бу илдән китәм.

Г ө л й ө з е м. Китәсең? Кая?

Б а т ы р җ а н. Урал ягына.

Г ө л й ө з е м. Урал ягына! Нигә?

Б а т ы р җ а н. Монда кайтсам — тоталар. Урманда беглыйлар янында яту да туйдырды.

Г ө л й ө з е м. Нишләп туйдырды?

Б а т ы р җ а н. Аларда киләчәккә өмет белән карау юк. Аларның эшләре боярларның кәҗәләрен, сарыкларын урлап сую, олы юлда почта талап, гаепсез кешеләрне үтерү белән генә чикләнә. Минемчә, гаеп почта йөртүчеләрдә түгел. Шулай ук бүген алпавытка бер тиенлек зыян китерсәң, иртәгесен ул шул ук крестьяннардан мең өлеше белән кайтара. Менә шуның өчен дә мин беглыйлар яныннан китәргә булдым.

Г ө л й ө з е м. Шулай, туган илеңне, дус-ишләреңне ташлап китәргә бер дә кызганмыйсыңмы?

Б а т ы р җ а н. Миңа нәрсәне кызганырга? Мин бит бу илдә балам, дип башымнан сыйпаучы, иркәм, дип җылы аш бирүчене күрмәдем.

Г ө л й ө з е м. Нигә алай өметсезләнәсең? Моңар кадәр булмаган икән, моннан соң барысы өчен дә берьюлы күрерсең.

Б а т ы р җ а н. Юк, Гөлйөзем, мин аңар ышанмыйм.

Г ө л й ө з е м. Ни өчен ышанмыйсың?

Б а т ы р җ а н. Минем кебек бунтарь егеткә кем генә карар икән?

Г ө л й ө з е м. Батырҗан... Менә мин...

Б а т ы р җ а н. Син?

Г ө л й ө з е м. Әйе, Батырҗан, мин сине көчле ир, батыр йөрәкле булуың өчен яратам.

Б а т ы р җ а н. Гөлйөзем, син мине яратасың?
Г ө л й ө з е м. Әйе, яратам.

Музыка.

Б а т ы р җ а н *(җырлый)*.

Тал чыбыктай буй-сыннарың
Тартты бит күңелкәем,
Гомерем буе син гүзәлне
Мин сөярмен, гөлкәем.

Т и м е р х а н керep Батырҗанны күрә.

Т и м е р к ә й. Батырҗан кайткан? Тукта, Бикташ агага әйтеп, тоттырыйм әле. *(Китә.)*

Г ө л й ө з е м *(җырлый)*.

Яшь баланы карагандай
Назлап, сөеп тотармын.
Син, батырым, янда булсаң
Бар хәсрәтем йотармын.

Б е р г ә.

Пар күгәрчен кебек гөрләп
Ямьле тормыш төзербез.
Икәүләшеп, бергә-бергә
Озак гомер сөрербез.

Б и к ч ә н т ә й керә, аларны күреп читкә борыла.

Г ө л й ө з е м. Әйе, нинди рәхәт... Гомер буе шулай тибрәнсәм иде.

Б а т ы р җ а н. Тибрән, чибәрем, тибрән... Гомер буе шулай тибрәтсәм иде.

Б и к ч ә н т ә й. Әйе... мин дә шулай тибрәнсәм иде...

Г ө л й ө з е м. Ай!

Б и к ч ә н т ә й. Нәрсә, кызым, аягың тайдымы әллә?

Б а т ы р җ а н. Бабай, оятлы булдык бит.

Б и к ч ә н т ә й. Нишлисең, миңа да оят булды да бит... хәерле булсын инде... Шулай да, балалар, мулла йортында бу эшегез килешми.

Г ө л й ө з е м. Әти, нишлим соң, ташкан йөрәгем түзмәде.

Б и к ч ә н т ә й. Түгелеп киттемени? Бу егетне кем дим соң?

Г ө л й ө з е м. Әллә танымыйсыңмы? Шәрифә бикәләрдә бөтен түрәләрне кыйнап качырган Батырҗан бит.

Б и к ч ә н т ә й. Шулаймыни? Улым, сине качкан дигәннәр иде бит?

Б а т ы р җ а н. Әйе, бабай, качкын булып йөрим.

Б и к ч ә н т ә й. Рәхмәт, балам, синең кебек ир йөрәкле егетне гомеремдә беренче тапкыр күрәм. Моннан соң нишләргә уйлыйсың?

Б а т ы р җ а н. Мин, бабай, Урал ягына заводларга качарга уйлыйм. Син миңа каянрак китәргә юл күрсәтә алмассыңмы?

Б и к ч ә н т ә й. Була ул, була. Без үзебез дә моннан шул якка, башкорт арасына китәргә уйлый идек. Ул тирәдә минем танышбелешләрем дә күп. Телисең икән —безнең белән йөрерсең. Теләмәсәң — үз юлыңны үзең карарсың.

А й с ы л у *(арттан).* Хәерче тамаклар, тагын кая китеп югалдылар?

Г ө л й ө з е м. Батырҗан, чыгалар, кач!

Б а т ы р җ а н кача. А й с ы л у керә.

А й с ы л у. Әй, уенчы карт килгән икән.

Б и к ч ә н т ә й. Әйе, остабикә, килдек. Бая хәзрәт Әсфәндияр байгуралларда очратып кереп чыгарга кушкан иде.

А й с ы л у. Кызың да бик зур булган икән.

Б и к ч ә н т ә й. Әйе, остабикә, бәхете-тәүфигы булсын инде.

А й с ы л у. Кая, булмаса, уйнап-җырлап җибәрегез.

Б и к ч ә н т ә й. Әйдә, кызым, остабикәләргә әйтеп алыйк.

Г ө л б и к ә белән З ө б ә р җ ә т керә, Зөбәрҗәт боегып кына бер җиргә барып баса.
Койма буена халык җыела, җыр башлана.

Г ө л й ө з е м. Кара болыт чыккан күк йөзенә,
Әллә тагын бозлар ява рмы?
*(Зөбәрҗәткә карап җырлый.)*
Явып аккан ташкын бозлар кебек
Кызлар яше шулай агармы?
Юл өстендә кара суер җылан
Узганнарга чыгып сызгыра,
Безнең илнең мескен яшь кызлары
Хәсрәт йотып кына көн күрә.
Өермәләр өеп ил өстеннән
Туфан дулый безнең җирләрдә.
Түкмәгез яшь, юкка еламагыз,
Якты көннәр туар безгә дә.

И м а н к о л керә.

И м а н к о л. Бу нинди җыен? Таралыгыз, фасикълар!

Халык тарала.

Б и к ч ә н т ә й. Сәламәләйкем! Исәнме, мулла!

И м а н к о л. Бик яхшы, Бикчәнтәй ага. Килгәнсең икән. *(Хатыннарына.)* Әй сез, күзле бүкәннәр! Ни көтеп торасыз, барыгыз, өйгә керегез.

А й с ы л у. Сезгә әйтәләр ич.

Гөлбикә белән Зөбәрҗәтне куып кертә.

И м а н к о л. Ә сиңа монда ни калган? Бар, бар, эшеңне кара!

Айсылу кереп китә.

И м а н к о л *(Гөлйөзем янына килеп).* Нихәл, кызым, үсеп буламы?

Г ө л й ө з е м. Була, мулла абзый.

И м а н к о л. Бәрәкалла, бәрәкалла. Бикчәнтәй агай, кызың бик көрәйгән икән. Үзе кечкенә генә булса да, тутырган тавык кебек булган. Хи-хи-хи!.. *(Гөлйөземнең аркасыннан кага.)*

Б и к ч ә н т ә й. Аллага шөкер, мулла, кул арама керә башлады.

И м а н к о л. Бикчәнтәй агай, минем синдә бер гозерем бар иде.

Б и к ч ә н т ә й. Нинди гозер ул, хәзрәт?

И м а н к о л. Мин аны үзеңә генә сөйләмәкче идем.

Б и к ч ә н т ә й. Була, мулла, була. Кызым, бар әле син беразга урамга чыгып тор.

Г ө л й ө з е м. Мин, әти, Батырҗан янына барам.

Б и к ч ә н т ә й. Чү, юньсез!

Гөлйөзем китә.

И м а н к о л. Шулай, Бикчәнтәй агай... бик аптырамыйсыңмы?

Б и к ч ә н т ә й. Дөнья булгач төрле вакыт була инде ул, мулла.

И м а н к о л. Хәлең начар булса, яшермә. Ярдәм итәрмен. Карт көнеңдә намазлык өстендә генә утырырга кирәк иде бит... нишләмәк кирәк...

Б и к ч ә н т ә й. Анысы, мулла, безгә насыйп түгелдер инде.

И м а н к о л. Шулай итеп, сиңа ярдәм кирәк булмасмыни?

Б и к ч ә н т ә й. Мин, мулла, төшенә алмыйм. Миңа нинди ярдәм итмәкче буласың? Аңлатыбрак сөйлә.

И м а н к о л. Менә нәрсә, Бикчәнтәй агай, мин синең кызыңны ошаттым. Әгәр дә син риза булсаң, хәләл җефетлеккә алмакчы булам.

Б и к ч ә н т ә й. Соң бит, мулла, синең аннан башка да өч хатының бар түгелме?

И м а н к о л. Булса ни? Алар уңайсызламый. Пәйгамбәр саллаллаһи галәйһе сәлам уналты хатын белән дә торган. Аллага шөкер, байлыгым бар. Син дә карт көнеңдә көснә уйнап йөргәнче, минем түремдә намаз карты булып, зекер-тәсбих өстендә генә утырырсың.

Б и к ч ә н т ә й. Юк, мулла, мин риза түгел.

И м а н к о л. Риза түгел? Нишләп?

Б и к ч ә н т ә й. Бу сүзең белән мине кимсетәсең.

И м а н к о л. Әй, фасикъ, җаһил мөрәккәп, авыз күтәреп, кәҗә сакалыңны сәлперәйтеп җырлап йөргәнче, тамагың туеп, арканнан хәерче капчыгың төшәр дип куркасыңмыни?

Б и к ч ә н т ә й. Тамак өчен намус саталмыйм. Мулла башың белән, күлмәк алыштыргандай, көн дә матур кызлар белән сату итеп уйнарга оят һәм зур гөнаһ! *(Бик тиз генә чыгып китә.)*

И м а н к о л. Ах син, фасикъ угылы фасикъ!

А й с ы л у юри җылап керә.

А й с ы л у. Алланың каһәре генә төшсен! Бөтен йортыбызны туздырып бетерә бит...

И м а н к о л. Нәрсә булды тагын?

А й с ы л у. Теге хәерче марҗасы самоварымны эретте.

И м а н к о л. Ә? Самоварны? Кем? Зөбәрҗәтме?

А й с ы л у. Зөбәрҗәтме дип торган була тагын. Хәерче марҗасы дисәң ни була?

И м а н к о л. Бар әле, үзен монда алып чык.

Айсылу китә.

И м а н к о л. Бу хәерче баласы нигезеңә аяк басмасын икән.

А й с ы л у, З ө б ә р җ ә т керә.

А й с ы л у. Әнә бар, сезнең өчен тиргәш алыр хәлем юк.

И м а н к о л. Син нигә күзеңне ачып йөрмисең? Нигә самоварны эреттең?

З ө б ә р җ ә т. Якын да барганым юк. Юри миңа сылтый ул.

Батырҗан тыңлап тора.

А й с ы л у. Әй, имансыз, күзгә карап ялганлый бит!

И м а н к о л. Нигә син байлыкның кадерен белмисең! Нигә ватасың, нигә җимерәсең! Менә сиңа... менә сиңа!..

А й с ы л у. Кызганып сукма, кулың өзелеп төшмәс. Ныграк бир.

Зөбәрҗәт ычкынып кача, камчы Айсылуга эләгә.

А й с ы л у. Ай!.. Ай аркам!..

И м а н к о л. Фу, хәлем бетте. Күптәннән бирле кызыгып йөри идем. Уф!.. Ныграк кыйнап ташладым, ахры. Карыным ачыгып китте. Кереп талкан болгатыгыз. Бу малае да нишләп тора соң?

А й с ы л у. Әсфәндияр байгура белән киңәштеңме соң?

И м а н к о л. Киңәштек. Солдат алучы түрәләр белән сөйләшергә булдылар.

А й с ы л у. Кайчанрак барырга ди?

И м а н к о л. Берсекөнгә юлга чыгабыз. Бар, ашарга әзерлә!

Айсылу кереп китә.

И м а н к о л. Хуш... Бу малайны ничек котылдырырга соң?

Б у л а т керә.

Б у л а т. Мулла кияү, сиңа килгән идем.

И м а н к о л. Сөйлә, ни йомыш?

Б у л а т. Мулла кияү, бик зур казага очрадык. Минем сыер синең сыерны сөзеп үтергән.

И м а н к о л. Нәрсә?.. Синең сыер минем сыерны сөзеп үтергәнме? Нигә соң, ахмак, карамадың?

Б у л а т. Малны, мулла кияү, каравыллап булмый бит, безнең абзар-кураны да беләсең. Бичараның эчәгеләрен актарып чыгарган. Мулла кияү, моның китапчасы ничек була инде?

И м а н к о л. Моны китаптан-нидән карап торасы юк. Җан башына җан түләргә кирәк. Шулай да карыйк әле. *(Яшел китап алып.)* Бу беренче фасыл икән. Менә китап әйтә: җан башына җан түләргә дигән. Мал асрагач, карарга кирәк иде.

Б у л а т. Шулай кирәк иде дә бит, карамагансыз. Син инде, мулла кияү, үз кеше, синнән китап кушканча бөтенләй сорап булмас, шулай да бераз ярдәм итсәң яхшы булыр иде.

И м а н к о л. Ярдәм итсәм? Нәрсәгә ярдәм итсәм?

Б у л а т. Шулай, мулла, синең коба сыерың минем ала сыерымны сөзеп үтергән.

И м а н к о л. Алай икән... Димәк, синең сыерыңны минем сыерым үтергән?

Б у л а т. Әйе, синеке минекен үтергән.

И м а н к о л. Ай, бичара хайван әрәм булган икән, хәерле каза булсын! Сүзне рәтләп сөйләргә кирәк. Сыерым үлгән дип котны алдың.

Б у л а т. Минеке шул, синеке булса, килеп тә йөрмәс идем. Бичараның бозавы да сөтсез калды. Читтә такта ярып тапкан

акчага сатып алып, бозаудан үстергән идем. Йә, мулла кияү, эшне бетерик тә, мин китим, бояр эшенә барасым бар.

Иманкол. Эшең беткән, китәргә рөхсәт.

Булат. Хакымны биреп җибәрсәгез иде дим.

Иманкол. Нинди хакны?

Булат. Ә соң сыер?

Иманкол. Аны сиңа кем әйтте?

Булат. Хәзер генә үзең китабыңнан карап әйттең бит.

Иманкол. Ах алла!.. Бу кадәр аңламаган кеше булырсың икән? Зобани карчыгы, сандык өстеннән сары тышлы китапны алып бир әле.

Айсылу китап чыгара.

Иманкол. Менә сары тышлы китапта бигрәк тә ачык итеп әйткән. Дүртенче фасыл икән. «Әгәр дә ике мөэмин-мөселман хайваннары бер-берсенә зыян салсалар, дөнья малы өчен, кил зинһар, гауга күтәреп йөрмәсеннәр», дигән. Шулай, каенатай кисәге, кеше көлдереп, авыз тәмебезне бетереп йөрмик.

Булат. Шәригать шулай ике яклы буламыни?

Иманкол. Бу кадәр томана кеше булырсың икән! Анысы аның яшел тышлы китап иде, ә монысы сары тышлы.

Булат. Әй, мулла кияү, ачуың килмәгәе, әйтер идем инде мин синең китапларыңа... Шулай итеп, түләмим дисеңмени инде?

Айсылу. Ул нинди түләү? Кызыңның ваткан, җимергән нәрсәләре өчен булыр.

Иманкол. Бик яхшы искә төшердең әле. Әнә бүген кызың ун сумлык самоварны эреткән.

Айсылу. Әйе!..

Иманкол. Синең сыерың сигез сум торса, минем самоварым ун сум тора. Димәк, синең үзеңнән ике сум тия икән әле.

Гәрәй керә.

Гәрәй. Мулла абзый, Зөбәрҗәт тегермән алдындагы суга батып үлгән.

Булат. Үлгән? Кем батырган? *(Шашып кала.)*

Гәрәй. Үзе сикереп төшкән. Көчкә эзләп таптык.

Булат. Балам, балам!..

Гәрәй. Кайсы өегезгә кертик?

Айсылу. Юк, юк!.. Мордар киткән кешене өебезгә кертер хәлебез юк.

Иманкол. Атасының өенә илтегез.

Айсылу. Әнә алып киләләр. Миңа үлек карарга ярамый, башым әйләнә. *(Кереп китә.)*

З ө б ә р җ ә т н е күтәреп кертәләр.

И м а н к о л. Нигә сорамый кертәсез? Мордар китүчеләрне йортыма кабул итәр хәлем юк. Барыгыз, каравыл өенә илтегез!

Б у л а т. Каравыл өенә?.. Чәчәк кебек баланың җиде ай буена канын эчеп үтергәннән соң, инде үле гәүдәсен дә каргаларга ташларга уйлыйсыңмы! Их син, оятсыз, тирес бит!.. *(Төкерә.)*

А й с ы л у *(чыгып).* Хәзрәт, сары майга талкан болгаткан идем, әйдә, өйгә кер, суынмасын.

И м а н к о л. Үлекне алып китегез. *(Кереп китә.)*

Г ә р ә й. Булат абзый, елама, җылы кочагы насыйп булмаса да, салкын гәүдәсен, хәрәкәтсез йөрәген минем өемә алып кайтыйк.

Б а т ы р җ а н атылып чыга.

Б а т ы р җ а н. Абзыйлар!

Х а л ы к. Батырҗан!..

Музыка.

Б а т ы р җ а н *(җырлый).*

Соң бу кадәр изү, хурлауларга
Ничек итеп безгә түзәргә?
Күтәрелик, вакыт җиткән инде
Балталарга хөкем сөрергә!

Х о р. Явызлар көчләп сине аердылар
Ярыңнан, намусыңнан көлделәр.
Әйдәгез, барыбыз бердән кузгалыйк.
Балта, сәнәкләр алып, үч алыйк.

К ы з л а р. Саф суларда тынган йөрәккәең,
Куйдылар бит яшьтән киртәләп.
Күрмәдең син назлап сөюләрне,
Башларыңнан сыйпап, иркәләп.

Х о р. Бәхил бул, мескенкәй Зөбәрҗәт,
Тын кабердә инде тыныч ят.
Синең өчен якын дус-ишләрең
Киләчәктә үчне алырлар.

А р м а й, Т и м е р х а н һәм с о л д а т л а р керә.

Т и м е р х а н. Әнә ул качкын!..

А р м а й. Ә, башкисәр, эләктеңме!

Батырҗанны төрле яктан чолгап алып мылтыкларын териләр.

А р м а й. Бәйләгез! *(Тотып бәйлиләр.)*

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шәрифә бикәнең сарай эче. Сәхнә икегә бүленгән: бер якта — зал, икенче якта — ятак бүлмәсе. Пәрдә ачылганда п о в а р л а р, д в о р н и к л а р, г о р н и ч н ы й л а р җыелганнар. Бер ноктага карап көтәләр.
Бераздан х е з м ә т ч е керә.

Х е з м ә т ч е. Бикә хәзрәтләре!.. Тез чүгеп каршы алыгыз!..

Җиргә яталар. Ш ә р и ф ә бикә керә.

Ш ә р и ф ә. Бераздан могтәбәр кунаклар килеп җитәчәк, һәркайсыгыз үз хезмәтендә булсын, Исак Пантелеевич! Кара аны, безнең кухня сынатырга тиеш түгел. Җаннарыгызны алырмын. Барыгыз!.. *(Поварлар китәләр. Дворникларга.)* Сакал батырлар! Урамнарыгыз, ишегалларыгыз көзге кебек чиста булсын. Бераздан чыгып карармын, әгәр дә чүп яисә салам кисәге күрсәм, телләрегез белән җыйдырырмын, барыгыз!.. *(Дворниклар китә. Горничныйларга.)* Ә сез, шумала башлар, ишек тоткаларыгызны начар чистартасыз, келәмнәрегезне, паласларыгызны начар кагасыз. Барыгыз, эшегезне бетерегез дә кунакларны каршы алырсыз. *(Китәләр.)*

А с к ә р чыга.

А с к ә р. Инәй бәгърем, хәерле иртәләр...
Ш ә р и ф ә. Сиңа да шуны телим, Аскәрик.

Х е з м ә т ч е керә.

Х е з м ә т ч е. Господин Байбурин!
А с к ә р. Байбурин?.. Инәй, минем балалык иптәшем.
Ш ә р и ф ә. Әйе, Аскәрик, минем белән бертуган тутаңның улы. Син аны каршы чыгып ал.
А с к ә р. Ярый, инәй.

Китә, бераздан З ә к ә р и я белән керәләр.

А с к ә р. Имею честь представить: Зәкәрия Адамович Байбурин!..
Ш ә р и ф ә. Боже мой, Зәкәрия, кечкенә Зәкәрчик, нинди бравый, нинди матур егет булгансыз!
З ә к ә р и я. Рәхмәт, тутакай. Сәламәтлегегез ничек?
Ш ә р и ф ә. Күргәнегезчә. Рәхим итегез! Утырыгыз!
З ә к ә р и я. Яхшы.
Ш ә р и ф ә. Әниемнең хәле ничек? Бу арада бара алмадым.
З ә к ә р и я. Куркынычлы түгел. Кичә каладан докторлар чакырткан идем, «Астма» дигән диагноз куйдылар. Дәваланырга киңәш бирәләр.

А с к ә р. Зәкәрия Адамович, сез бу елларны безне оныттыгыз, семьягыз янына да кайтмый башладыгыз.

Зәкәрия. Петербург кадәр җирдән кайтып йөрү мәшәкатьләргә, юл газапларына бәйләнгән, Аскәр Сәлимович. Әле бу елда исәбем юк иде, бары тик әнкәйнең җитди авыруы гына кайтырга мәҗбүр итте.

Ш ә р и ф ә. Гафу итегез, хәтеремдә калмаган, нинди мәктәптә укыйсыз әле?

З ә к ә р и я. Горно-инженерный факультетны бетерәм.

А с к ә р. Минемчә, неудачный путь.

Б и к т а ш керә.

Б и к т а ш. Господа, сез ишеттегезме?

А с к ә р. Нәрсә бар?

Б и к т а ш. Кичә Тирсә боярларын талап, имениеләренә ут төрткәннәр.

Ш ә р и ф ә. Ут төрткәннәр?

А с к ә р. Кемнәр?

Б и к т а ш. Сандр атаман кул астындагы качкын крестьяннар.

Ш ә р и ф ә. Шул разбойникларны нигә тотып асмыйлар икән?

Б и к т а ш. Өяз каласыннан йөз кешелек гаскәр белән Йөзкәй түрә киткән, иншалла, тотсалар кирәк.

Ш ә р и ф ә. Зәкәрия Адамович, кайчанга кадәр шушындый пычрак җаннар дәһшәтеннән кан калтырап торырбыз икән? Бу бит кичәге яки бүген булган очраклы вакыйга түгел! Без бит еллар буена, кайчан өстебезгә килеп басарлар икән, дигән куркыныч астында яшибез. Его величество государь император Александр Николаевич хәзрәтләре безнең турыда нәрсә уйлый да, шушындый юлбасарларга карата нинди чаралар күрергә тели икән? Һәм менә сезнең кебек изге пайтәхетебездә торучы укымышлы кешеләребез нәрсә уйлыйлар?

З ә к ә р и я. Бердәнбер һәм котылгысыз чара: крестьяннарны азат итәргә кирәк.

А с к ә р. Азат итәргә?

Ш ә р и ф ә. Сез ни сөйлисез?

З ә к ә р и я. Әйе, Шәрифә Асановна, Россиядә югарыгы сыйныф дворянство интересларын һәм чикләнмәгән монархияне саклап калу өчен крестьяннарны азат итүдән башка бернинди дә чара юк.

А с к ә р. Зәкәрия Адамович, сез в уме?.. Такие слова! Тыңлап торырга да нинди куркыныч.

З ә к ә р и я. Моны мин түгел, тормыш логикасы куша. Бу Александр Николаевич хәзрәтләренең үз фикере. Әгәр дә без

аларны азат итмәсәк, аларның үз-үзләрен азат итү куркынычы бар.

Бикташ. Рөхсәт итегез миңа да берничә сүз әйтергә. Зәкәрия Адамович авызыннан мондый сүзләр ишетүне көтмәгән идем. Юкка хафаланып куркасыз. Кешелек дөньясының тарихында, алла тарафыннан иңдерелгән изге дворянлык строен җимереп, тупас кара халыкның өстенлек, хакимлек итүен минем ишеткәнем дә, укыганым да юк иде.

Зәкәрия. Положениене аңламавыгыз бик кызганыч, Бикташ Алимбекович. Хәзер безгә элеккеге алымнар белән яшәп булмый инде. Крестьяннарның ачуы арта бара. Стенька Разин, Пугачев фетнәләрен онытмагыз.

Бикташ. Исемдә, Зәкәрия Адамович. Ләкин бит аларның үзләрен дә бүреләр өерен аулаган кебек аулап, берәм-берәм дар агачларына асканнар.

Аскәр. Браво, браво, Бикташ ага!..

Зәкәрия. Анысы шулай, әмма, Шәрифә Асановна, безгә Россиядә туып килә торган завод-фабрикаларыбызга эшче көчләре кирәк. Без, әлбәттә, аларны кол крестьяннар белән тутыра алмыйбыз.

Шәрифә. Юк, юк, Зәкәрия Адамович, мин дә сезнең белән килешә алмыйм. Крестьяннарны азат итү безнең кебек дворяннарны бөтенләйгә юк итү дигән сүз бит ул.

Зәкәрия. Киресенчә, тутакай, алар бу азатлыклары өчен безгә тагын да күбрәк файда китерәчәкләр. Без ул чагында натураль хуҗалыктан Европадагыча сәүдә, акча хуҗалыгына күчәрбез. Сез үзегез уйлап карагыз. Алар хәзер безгә каршы үчегүнең чигенә килеп җиттеләр. Крепостной крестьян ул шундый: эшкә кушсаң, күңел куеп эшләми, сылтау таба, ялкаулана. Очраган саен тормышының начарлыгы турында сыкрый, зарлана, елап ашарга сорый, бирмәсәң, хуҗалыкка зыян итә, вата, җимерә, ут сала.

Шәрифә. Анысы дөрес, Зәкәрия Адамович, шулай да мин аңлый алмыйм, ничек итеп крепостной крестьяннарсыз торырга да, ничек итеп дворяннар үз хуҗалыкларын алып барырлар?

Зәкәрия. Әлбәттә, аларга экономика, сәүдә өлкәләрендә җитезрәк, инициативалырак булырга туры килер. Конкуренция сүлпәнлекне, ялкаулыкны яратмый.

Аскәр. Инәй, мин Зәкәрия Адамовичның чепухаларын тыңлый алмыйм. Безнең өебездә кара фикерләрне таратучыларга каршы Оренбург кадетлары исеменнән протестовать итәм.

Зәкәрия. Тутакай, Аскәр Сәлимовичның мондый дорфа чыгышларына түзеп тора алмыйм.

Ш ә р и ф ә. Зәкәрия Адамович, сез ни сөйлисез?..

З ә к ә р и я. Гафу итегез, сезне ташлап китәргә мәҗбүрмен.

Ш ә р и ф ә. Бу һич мөмкин түгел, мин сезгә рөхсәт итмим.

З ә к ә р и я. Булдыра алмыйм, хушыгыз!.. *(Китә.)*

Ш ә р и ф ә. Аскәрик, гафу үтен, калуын сора.

А с к ә р. Яхшы тәкъдимегез өчен рәхмәт, инәй. Бәхете әле, синең туганыңның улы булу мине тыелырга мәҗбүр итте. Әгәр дә ул башка бер кеше булса иде, мин аны шунда ук пистолетымнан чокнул бы...

Ш ә р и ф ә. Зөләйха тутаңнан яхшы түгел.

А с к ә р. Подумаешь, инженер, имеш!..

А р м а й керә.

А р м а й. Кадерле бикәм, Батырҗан башкисәрне тотып китердек.

А с к ә р. Браво!

Ш ә р и ф ә. Молодцы!

А р м а й. Нишләтергә кушасыз?

Ш ә р и ф ә. Хәзергә салкын базга төшереп ябыгыз.

А р м а й. Тыңлыйм, бикә! *(Китә.)*

Ш ә р и ф ә. Бикташ, мәҗлес үтү белән ул башкисәрне читлек эченә бикләргә дә калага Йөзкәй түрәгә озатырга.

Б и к т а ш. Тыңлыйм, бикә.

Х е з м ә т ч е керә.

Х е з м ә т ч е. Отставной полковник Бикбаевлар...

Ш ә р и ф ә. Сорагыз, рәхим итсеннәр!

Хезмәтче китә. Ишекләр ачыла. Б и к б а е в л а р керә.

Б и к б а е в. Исәнмесез, Шәрифә Асановна!..

Ш ә р и ф ә. Сезне өебездә күрүебезгә бик шатбыз, Сөләйман Моисеевич.

Б и к б а е в. Аскәр Сәлимович, офицер булуыгыз белән котларга рөхсәт итегез.

А с к ә р. Рәхмәт, Сөләйман Моисеевич.

Ш ә р и ф ә. Рәхим итегез, кунаклар, утырыгыз.

Б и к б а е в. Аскәр Сәлимович, назначение кая алдыгыз?

А с к ә р. Кавказга, драгун полыгына.

Х е з м ә т ч е керә.

Х е з м ә т ч е. Князь Абалинскийлар...

Ш ә р и ф ә. Боерсыннар, түземсезлек белән көтәбез!

Хезмәтче китә, ишекләр ачыла. А б а л и н с к и й л а р семьясы керә.

А б а л и н с к и й. Сәламәтлек телибез сезгә.
Ш ә р и ф ә. Рәхим итегез, князь.
А б а л и н с к и й. А?..
Ш ә р и ф ә. Утыруыгызны сорыйм!
А б а л и н с к и й. Рәхмәт.

Х е з м ә т ч е керә.

Х е з м ә т ч е. Йөзкәй түрә!
А с к ә р. А!.. Пожалуйста, рәхим итсеннәр.

Хезмәтче китә, Й ө з к ә й белән К о л т а й керә.

Й ө з к ә й. Аскәр Сәлимович!
А с к ә р. Йөзкәй түрә... *(Күрешәләр.)*
Й ө з к ә й. Шәрифә Асановна, сезне күрүемә бик шатмын.
Ш ә р и ф ә. Рәхим итегез, түрә. Сөйләгез, нинди хәбәрләр алып килдегез?
Й ө з к ә й. Господа, беләсезме нәрсә? Кичә Сандр атаман кул астындагы качкыннар Тирсә боярларын талап, имениеләренә ут төрткәннәр.
Б и к б а е в. Ут төрткәннәр?..
А б а л и н с к и й. А?..
Б и к б а е в. Ут төрткәннәр!
А б а л и н с к и й. Кемгә?
Ш ә р и ф ә. Тирсә боярларына, князь...
Б и к б а е в. Шуннан, Йөзкәй түрә, шуннан?
Й ө з к ә й. Шуннан, мин, приказ алу белән, йөз кешелек отряд ияртеп Тирсәгә киттем. Барсам, исем китте. Шундый зур бай имение урынында утлы кисәүләрдән башка бернәрсә дә калмаган.
Б и к б а е в. Ай, ай, боже мой!
А б а л и н с к и й. А?..
Б и к б а е в. Сезгә соңыннан сөйләрбез, князь, соңыннан.
А б а л и н с к и й. А?
Б и к б а е в. Дальше, дальше, Йөзкәй түрә.
Й ө з к ә й. Дальше мин, отрядны алып, качкыннарга облава ясарга урман эчендәге авылларга юл тоттым. Ләкин, йөрибез-йөрибез, һич эзләренә төшеп булмый. Көн узды, кич булды, караңгы төште, качкыннар һаман да юк. Нишләргә?.. Кешеләр дә ардылар, атлар да йончыды. Кире борылып кайтырга дип торганда безне эзләп килүче чирмеш сәүдәгәре: «Алар безнең авылда ит пешертеп, эчеп утыралар», — дип безгә белдерә. Мин

бу хәбәрне ишетүгә күзәтчеләрне алдан җибәреп, отрядка аяк очында гына барырга приказ бирдем. Таң атканда авылга җиттек. Саклык, яшеренлек белән, корсак өстендә генә шуыш, болар утырган алачыкны атаковать итеп алдык. Чыннан да, икеөч казанда ит пешертеп, көмешкә эчеп утыралар. Көтмәгәндә бер тапкыр залпом һавага атабыз, алар безгә каршы...

А с к ә р. Димәк, кораллары да бар?

Й ө з к ә й. Һәммәсендә дә иярле ат һәм чакма мылтыклар.

А с к ә р. Вон что... Шуннан соң?..

Й ө з к ә й. Шуннан алачыкка каратып берничә залп биргән идек, түзмәделәр, «Атмагыз, бирeләбез», дип кул күтәреп чыктылар.

А с к ә р. Ура, ура, господа!..

Й ө з к ә й. Ләкин атаманнарын тота алмадык. Берничә иптәше белән башка бер өйдә булган, качып котылды, сукин сын.

Б и к т а ш. Иң кирәклесен тота алмавыгыз кызганыч.

Й ө з к ә й. Ничего, господа, алар хәзер икенче тапкыр кузгала алмаслык булып кыйналдылар. Әнә карагыз! *(Тәрәзәдән күрсәтә.)* Унҗиде юлбасар бер бауга бәйләнгән.

Карыйлар.

Ш ә р и ф ә. Ах, нинди куркынычлар алар... Йөзкәй түрә, безнең бүген гадәттән тыш шатлыклы көнебез, без бүген башкисәр Батырҗанны тотып бәйләдек.

Й ө з к ә й. Бәйләдегез?

Ш ә р и ф ә. Әйе, бәйләдек, ул хәзер салкын базда утыра. Сез аны үзегез белән бергә алып китәрсез.

А с к ә р. Инәй, Йөзкәй түрәнең уңышлы операциясенә багышлап, бүгенге мәҗлесне тагын да зуррак, тагын да күңеллерәк ясарга кирәк.

Ш ә р и ф ә. Дөрес, Аскәрик! Шуның белән бергә, безнең өяздәге дворяннар, князьләр исеменнән, безнең тормышыбызны, тынычлыгыбызны, гомеребезне калкан булып саклаучы Йөзкәй түрәгә губернатордан зур награда, медальләр бирелүен сорарбыз. Бикташ! Качкын юлбасарлар тотылу шәрәфенә бүгенге мәҗлесебезгә уенчылар, җырчылар һәм авылдагы барлык матур кызлар чакырылсын.

Б и к т а ш. Тыңлыйм, җан бикәм.

Ш ә р и ф ә. Господа, рәхим итегез, аш урыны бакчадагы терраска, саф һавага хәзерләнгән. *(Китәләр.)*

А с к ә р. Йөзкәй түрә, Сөләйман Моисеевич, сез минем белән.

А б а л и н с к и й. А?..

Б и к б а е в. Юк, сезгә түгел, чыга торыгыз.

А б а л и н с к и й. А?..

Б и к б а е в. Барыгыз, барыгыз дим!

А с к ә р. Мин сезне, господа, Оренбургтан алып кайткан заграничный шәраблар белән сыйлыйм әле. *(Китәләр.)*

Б и к т а ш. Әй! Кем бар анда?

Х е з м ә т ч е керә.

Б и к т а ш. Әйтегез, эчемлекләр белән монда өстәл хәзерләсеннәр!

Х е з м ә т ч е. Тыңлыйм, ага. *(Китә.)*

Ш ә р и ф ә керә.

Ш ә р и ф ә. Бикташ, әйдә минем белән. *(Ятак бүлмәсенә керәләр.)* Ишекне биклә. Кил минем яныма.

Б и к т а ш. Көпә-көндез яхшы түгел.

Ш ә р и ф ә. Син ни өчендер бу арада миңа салкын карый башладың.

Б и к т а ш. Җибәр, бикә, кеше сизәр.

Ш ә р и ф ә. Сизсен, бөтен кеше сизсен. Мин бит синсез тора алмыйм.

Б и к т а ш. Хәзер вакыты түгел. Аскәрик китсен, икәү генә калгач, беркем дә уңайсызламас.

Ш ә р и ф ә. Әллә син миннән риза түгелме, яисә хәтереңне калдырдыммы?

Б и к т а ш. Кунаклар янына чыгыйк, җибәр мине.

Ш ә р и ф ә. Юк, җибәрмим. Кил, минем яныма утыр.

Б и к т а ш. Әби патша теләкләреңне беразга ташлап торырга иде. Бу кыланышларың белән мине кимсетәсең, хурлыйсың. *(Китә.)*

Ш ә р и ф ә залга чыга, өстәлдәге эчемлекләрдән берничәне салып эчә. А с к ә р, Б и к б а е в, Й ө з к ә й сөйләшә-сөйләшә керәләр.

А с к ә р. Инәй, син ничек монда?

Шәрифә эндәшми ачуланып китә.

А с к ә р. Аңламыйм, бу инәй нишләгән?

Й ө з к ә й. Шуннан соң, Аскәр Сәлимович?

А с к ә р. Шуннан соң теге почта чиновнигының кызы —гимназистканы һич тә уговорить итә алмыйм. Мин, как храбрый кадет, аптырап калмадым, Яңа елны каршылау маскарадына корпуска чакырдым. Кыз киенеп килгән, прелесть... Буй-сыны, ул күкрәкләр, ә аяклар дисәң... Бөтен кадетларның күзе моңарда. Бераз биегәннән соң алдап бүлмәгә алып керәм. Мин, как

храбрый кадет, күп уйлап тормыйча ишекне бикләп тә алдым... Кыз разбой сала башлады, мин, как храбрый кадет, растеряться итмәдем, пистолетымны чыгардым да маңгаена төзәдем.

Б и к б а е в. Интересно, очень интересно. Дальше, Аскәр Сәлимович, дальше.

А с к ә р. Дальше да больше... как старики говорят, вы сами должны догодаться.

Й ө з к ә й. Молодец, Аскәр Сәлимович, ха-ха-ха!..

А с к ә р. Соңыннан гимназисткам үзе минем арттан йөри башлады. Үткән көз отпускыдан кайткач, мине эзләп корпуска килгән. «Нишлибез, мин положениедә», —ди. Мин, как храбрый кадет, күп сөйләшеп тормадым, кудым да чыгардым... Шуннан соң бу нишли диң?.. Кайта да ак серкә эчә. Больниска салалар... Атасы минем өстән корпус начальнигына жалоба белән килә. Безнең начальник бик строгий генерал. «Мин Ватанга офицерлар хәзерләүче корпус начальнигы, мещан кызлары белән командовать итмим, кызыгыз булгач үзегез карарга иде», — дип, чиновникны куып чыгара.

Б и к б а е в. Молодец, акыллы генерал икән.

А с к ә р. Бикташ ага, уенчыларың, җырчы кызларың кая?

Б и к т а ш. Хәзер була, яшь түрә. *(Китә.)*

А с к ә р. Господа, Йөзкәй түрәнең бунтовщиклар тоту шәрәфенә эчик! *(Эчәләр.)* Минем монда бер кызга күңелем төшеп йөри. Но мин, как храбрый кадет, аны да теге гимназистка кебек... понимаете?..

Й ө з к ә й. Кем ул, Аскәр Сәлимович?

А с к ә р. Гөлйөзем.

Й ө з к ә й. Кайсы Гөлйөзем, теге уенчы карт кызы Гөлйөземме?..

А с к ә р. Нәкъ үзе. Замечательный кыз.

Й ө з к ә й. Да, ул кыз ярарлык.

А с к ә р. Господа, матур кыз Гөлйөзем саулыгына эчик! *(Эчәләр.)*

Б и к ч ә н т ә й, Г ө л й ө з е м һәм б а ш к а к ы з л а р керәләр.

Б и к т а ш. Йә әле, карт, уйнап җибәр, ә син, кызый, җырларсың.

Музыка, җыр.

Г ө л й ө з е м. Иж буйлары кара урман,
Анда тугай, чабынлык;
Яз тургаен көткән кебек,
Син түрәмне сагындык.
Түрәләй!..
Түрәмләй!..

Янса ла йөрәгең
Кайгы-хәсрәттән,
Шифасын табыгыз
Балдан, ширбәттән!..

Х о р. Күтәрик чәшкеләр баллар белән,
Үтсен гомер байлык, мал белән.
Салыгыз тутырып, ай, балларны,
Шатлыклы үткәрик көннәрне.

Г ө л й ө з е м. Иж буеның, ай, кызлары
Бар да килеп тезелгән;
Иж буеның түрәләре
Бу мәҗлескә җыелган.
Түрәләй!..
Түрәмләй!..
Янса ла йөрәгең
Кайгы-хәсрәттән,
Шифасын табыгыз
Балдан, ширбәттән.

Х о р. Күтәрик чәшкеләр баллар белән,
Үтсен гомер байлык, мал белән.
Салыгыз тутырып, ай, балларны,
Шатлыклы үткәрик көннәрне.

Г ө л й ө з е м. Иж буйлары туйра таллык,
Аланнары җир җиләк;
Арсландай түрәләре
Бу дөньяда бик сирәк.
Түрәләй!..
Түрәмләй!..
Янса ла йөрәгең
Кайгы-хәсрәттән,
Шифасын табыгыз
Балдан, ширбәттән...

Х о р. Күтәрик чәшкеләр баллар белән,
Үтсен гомер байлык, мал белән.
Салыгыз тутырып, ай, балларны,
Шатлыклы үткәрик көннәрне.

А с к ә р. Бикташ ага! Бераздан Гөлйөземне минем бүлмәгә җибәрерсез.

Б и к т а ш. Ничек, сезнең бүлмәгә?

А с к ә р. Шулай, минем бүлмәгә, больше никаких...

Б и к т а ш. Ул кызда күңелем барлыгын мин сезгә сөйләгән идем бит.

А с к ә р. Мин, как храбрый кадет, ике сөйләргә яратмыйм.

Б и к т а ш. Гафу итегез, минем теләгемне дә...

А с к ә р. Отставить!.. Барыгыз.

Б и к т а ш. Тыңлыйм. *(Ятак бүлмәсенә керә.)* Шулай ук бу сантый минем теләкләремне аяк астына салып таптар микәнни?.. Күрербез. Армай!..

А р м а й керә.

А р м а й. Ни боерасыз, ага?

Б и к т а ш. Батырҗанны базга ябылган җиреннән чыгарыгыз да, кара яктан монда, минем яныма җибәрегез.

А р м а й. Батырҗанны, монда?

Б и к т а ш. Әйе, бу шулай... Гөлйөземне Аскәр түрә көчли диң, аңлыйсыңмы?..

А р м а й. Әйе, бераз гына аңлыйм.

Б и к т а ш. Аңласаң, бар. Бөтен ишекләргә, тәрәзә асларына сакчылар куегыз, качып китәрлек булмасын.

А р м а й. Тыныч булыгыз, Бикташ ага. *(Китә.)*

Б и к т а ш залга чыга, Й ө з к ә й кызлар арасына керә.

Й ө з к ә й. Кызкай, егетләр кочагында ятканың бармы? Нигә эндәшмисең? Бар. Күзең зәңгәр икән. Ә син, кара күз, сиңа ничә яшь? Тәнең ярыйсы гына тыгыз, күкрәкләрең дә калку икән, аякларың да яхшы күренәләр.

Б и к б а е в. Йөзкәй түрә, әллә сез базарда ат карыйсызмы?

Й ө з к ә й. Юк, Сөләйман Моисеевич, сугымлык сайлыйм. Ха-ха-ха!..

Б и к т а ш. Кызлар, җырлагыз, кунакларның күңелен ачыгыз!

Батырҗан ятак бүлмәсенә керә. Гөлйөзем белән дуэт җырлыйлар.

Б а т ы р җ а н. Әрни йөрәккәем шомлы хәбәрләрдән,
Үч алырга кызды, дуслар, кан гынам.
Ачуларым ташты язгы ташкыннардай,
Ни хәлдә соң сөйгән яр гынам.

Г ө л й ө з е м. Күңелкәем боек, нидер сизгән төсле,
Ач бүреләр мине күзлиләр.
Ах, Батырҗан дустым, батыр йөрәккәем,
Хәлләремне ул бит белмидер.

Х о р. Күтәрик чәшкеләр баллар белән,
Үтсен гомер безнең дан белән.
Салыгыз тутырып, ай, балларны,
Шатлыклы үткәрик көннәрне.

Б а т ы р җ а н. Монда мәҗлес бүген,
бар да шатланганнар,
Шаулый дөнья җырлар, биюдән.

Сөйгән яр гынамны ятлар килеп кочса,
Мин тартынмам каннар коюдан.

Г ө л й ө з е м. Күк батыры, үткен бөркет кебек
Сакланырсың, иркәм, күңелемдә.
Көндезләрен истә, төнен төштә күреп,
Син булырсың бәгърем түрендә.

Х о р. Күтәрик чәшкеләр баллар белән,
Үтсен гомер безнең дан белән.
Салыгыз тутырып, ай, балларны,
Шатлыклы үткәрик көннәрне.

Б и к т а ш Батырҗан янына чыга.

Б и к т а ш. Батырҗан, моңарчы җәберләвем өчен гафу ит. Мин дә хәзер синең яклы.

Б а т ы р җ а н. Ышандыра алмассың, хәйләкәр.

А с к ә р. Бикташ ага!..

Б и к т а ш. Әнә, ишеттеңме? Ул хәзер Гөлйөземне монда чакырырга кушачак. Ышанмасаң, качып яшеренеп тор. Менә бу хәнҗәр сиңа шаһит булачак. *(Аскәр янына килә.)* Ни боерасыз?

А с к ә р. Мин анда чыгам, кызны җибәрерсең. *(Ятак бүлмәсенә чыга.)*

Батырҗан ламбрекеннар арасына яшеренә.

Б и к т а ш. Бикчәнтәй карт, яшь түрәнең кәефе юк, аның янына чыгып, уйнап-җырлап алыгыз.

Б и к ч ә н т ә й. Ярый, Бикташ ага. Әйдә, кызым.

Аскәр бүлмәсенә чыгалар.

Б и к т а ш. Ә сез, кызлар, бу якта җырлагыз.

Гөлйөзем белән кол кыз дуэты.

Г ө л й ө з е м. Сандугачкай дигән, ай, асыл кош
Читлекләрдә, мескен, көн кичә,
Читлектәге тоткын сандугачтай
Яшь башкаем нигә интегә.
Түрәләй!..
Түрәмләй!..
Кемнәр соң калдырды
Хәтереңне, әйтсәнә,
Төнбоектай йөзең
Бер көлеп ачсана.

К о л к ы з. Сандугачкай кунса тал чыбыкка,
Чык тамчысы биткә сибелә.
Чык тамчысы кебек күз яшьләре,
Күз яшьләре монда түгелә.

Түрәләй!..
Түрәмләй!..
Янса ла йөрәгең
Кайгы-хәсрәттән,
Шифасын табыгыз
Балдан-ширбәттән.

Хор. Күтәрик чәшкеләр баллар белән,
Үтсен гомер безнең дан белән.
Салыгыз тутырып, ай, балларны,
Шатлыклы үткәрик көннәрне.

Аскәр. Карт, әйт, мин сезгә нәрсә бүләк итим?

Бикчәнтәй. Белмим, түрә, үзегез ни теләсәгез, шуны.

Аскәр. Мин сезгә Полканымның көчеген бирмәкче булам, ни диярсең?

Бикчәнтәй. Нәрсә дим? Мин үзем этне бик яратмасам да, сез түрә кулыннан булгач шатланып алырмын.

Аскәр. Армай!..

Армай керә.

Аскәр. Менә бу картка Полканымның көчеген бүләк ит.

Армай. Яхшы, түрә.

Бикчәнтәй. Әйдә, кызым.

Аскәр. Юк, карт, кызыңны борчыма, безнең этләр усаллар, тешләп куймасыннар. Ул аргандыр, син килгәнче бераз ял итәр, кайтышлый кереп алырсың.

Бикчәнтәй. Ярый шул. Кызым, син монда калып тор, мин хәзер килермен. *(Китәләр.)*

Бикташ. Кызлар, егетләр, биеп алыгыз.

Музыка, биюләр.

Аскәр. Кызкай, нигә басып торасың, кил, утыр.

Гөлйөзем. Юк, кирәкми, миңа монда да ярар.

Аскәр. Алай басып торырга ярамый, зурлар сүзен тыңларга кирәк. Менә шулай. Синең тәнең бик эссе икән... Әллә авырыйсыңмы?..

Гөлйөзем. Юк, авырмыйм.

Аскәр. Авырыйсың, кая әле йөрәгеңне тыңлап карыйм.

Гөлйөзем. Туктагыз, сез нишлисез?.. Җибәрегез, юкса хәзер кычкырам.

Аскәр. Тавышыңны чыгарма!..

Гөлйөзем. Әти, ярдәм итегез!

Аскәр. Яхшылыкта бирел!.. *(Диванга сузып сала.)*

Эт баласы күтәреп Бикчәнтәй керә.

Бикчәнтәй. Бу нинди эш?

Аскәр. Югал моннан, старый чорт.

Бикчәнтәй. Син безнең намусыбызны эт баласы белән сатып алмакчы буласыңмы?.. Мә этеңне, кабахәт!.. *(Өстенә ташлый.)*

Аскәр. Ах, син, сволочь!.. *(Атып үтерә.)*

Батыржан качкан җиреннән чыга.

Батыржан. Әле син шулаймы? Менә сиңа, эт! *(Чәнчеп үтерә.)*

Бикташ. Йөзкәй түрә, Аскәрикне Батыржан чәнчеп үтерде.

Йөзкәй. Батыржан?

Шәрифә белән кунаклар керә.

Шәрифә. Бу нинди мылтык тавышы?

Бикташ. Аскәр түрәне менә бу башкисәр үтерде.

Шәрифә. Беглый, син минем баламны?..

Гөлйөзем. Юк, бикә, ата канын дауламыйча чыдамадым, мин үтердем аны.

Батыржан. Юк, гөнаһсыз картның канын агызучыны җәһәннәмгә мин җибәрдем.

Йөзкәй. Колтай! Боларның икесен дә бәйләгез.

Бикташ. Юк, бу кыз бала гөнаһсыз... Ул монда калыр...

*Пәрдә.*

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Иманкол мулланың икенче пәрдәдәге өй алды.

Айсылу. Кайчан чыгарга диләр?

Иманкол. Бер-ике атнадан артык торылмас диләр.

Айсылу. Ярабби, шулай ук бик тизмени! Башка елдагы солдатлар бик озак йөриләр иде.

Иманкол. Башка елларда болай тынычсыз булмый торган иде.

Тимерхан җырлап керә, исерек.

Тимерхан. Ак кош очар, мамыгын кояр,
Аның мамыгын кем җыяр?
Солдатларга китеп вафат булсам,
Җеназалар укып кем куяр?

Иманкол. Улым, синең башыңа ис тигән, ахры. Ятып ял итсәң, яхшырак булыр иде.

Тимерхан. Нигә мине чакырып кайтардыгыз? Солдатка җибәрер өченме?

И м а н к о л. Тимерхан, улым, зинһар өчен әкренрәк. Халыктан яхшы түгел.

А й с ы л у. Әйдә, булмаса, өйгә кереп ят.

Т и м е р х а н. Аягымны бозыйм, дидем — боздырмадыгыз; имән бармагымны чабыйм, дидем — чаптырмадыгыз; бер күземне чыгарыйм, дидем — рөхсәт бирмәдегез. Сезнең мине солдатка җибәрәсегез килде. Ярый, мин китәм, морадыгыз хасил булды.

И м а н к о л. Әлгаязе билләһи, ифтира сөйлисең, улым, ифтира! Солдатка китүең безнең өчен зур кайгы-хәсрәт икәнен әллә син сизмисеңме? Атаңның сине коткару турында җанын-тәнен кызганмыйча, түрәдән түрәгә чабып йөрүләрен әллә күрмисеңме? Әле менә шул турыда киңәшер өчен Бикташ морза килергә булган. Иншаллаһ рахман, ул сине коткарырга юллар тапса кирәк.

А й с ы л у. Әнә Бикташ морза үзе дә килде. Әйдә, балам, әйдә, керик.

И м а н к о л. Зинһар, балам, исерек көенчә аңар күренә күрмә. Бар, өйгә кереп ятып тор.

Айсылу белән Тимерхан кереп китәләр. Урам яктан морзалар киемендә Б и к т а ш керә.

Б и к т а ш. Әссәламегаләйкем!

И м а н к о л. Вәгаләйкем әссәлам! Әйдә, морза, рәхим ит.

Б и к т а ш. Рәхмәт, мулла.

И м а н к о л. Әйдә, өйгә рәхим итегез.

Б и к т а ш. Зарар юк, монда гына, саф һавада утырыйк.

И м а н к о л. Ярый алайса, ихтыярыгыз.

Б и к т а ш. Йә, мулла, калада ниләр ишеттегез?

И м а н к о л. Артык хәбәрләр юк. Сезнең Шәрифә бикәгә өйләнеп морза булуыгыз бөтен могтәбәр кешеләрне шатландырган. Үзегезнең губернага бару сәфәрегез ничек булды соң?

Б и к т а ш. Чамадан тыш уңышлы. Яңа салына торган комач фабрикабызга машиналар китертү турында бер француз фирмасы белән договор ясап кайттым. Озакламый машиналар килә башлар.

И м а н к о л. Бик яхшы, бик гүзәл булган. Ансы да монсы, морза, улым Тимерханны солдатка алдылар бит.

Б и к т а ш. Әйе, шулай дип ишеткән идем.

И м а н к о л. Нишләрбез икән, бер дә җибәрәсе килми иде.

Б и к т а ш. Бернәрсә дә эшләп булмый, алынган, эш беткән, мулла.

И м а н к о л. Әгәр дә сез иҗтиһат итеп чара күрсәгез, бәлки, калдырыш булмасмы диюем иде?

Б и к т а ш. Булыр иде дә, ләкин, мулла, өстегезгә төшкән бурычыгызны начар үти башладыгыз.

И м а н к о л. Ничек начар? Әллә сез миннән риза түгелме?

Б и к т а ш. Шулайрак, мулла, шулайрак. Үзем өйдә юклыктан файдаланып, салына торган комач фабрикабызның берничә җирен җимергәннәр. Урманга ут салганнар. Тегермән буасын ердыра язганнар. Болар барысы да сезнең карамавыгыздан, сезнең үгет-нәсихәтләрегез юклыктан килә бит. Әгәр дә сез аларны җыеп, яхшылап үгетләсәгез, бу хәлләрнең берсе дә булмас иде.

И м а н к о л. Дөрес, Бикташ, гөнаһлы колыгызны гафу итегез. Соңгы көннәрдә улым артыннан йөреп, үз вазифамны тиешенчә үти алмадым шул... Сез тыныч булыгыз, мин ул фасикъларның, сезнең милекләрегезгә зыян салучыларның җилекләренә төшәрмен. Тик, зинһар өчен, улымны коткарып калу турында берәр чара күрсәгез иде.

Б и к т а ш. Минем бер чарам бар, мулла.

И м а н к о л. Нинди чара ул?

Б и к т а ш. Улың өчен наемщик ялларга кирәк.

И м а н к о л. Наемщик?

Б и к т а ш. Әйе, наемщик.

И м а н к о л. Бик гүзәл эш. Ләкин аңар кемне табарбыз?

Б и к т а ш. Без, Шәрифә бикә белән киңәшеп, Батырҗанны дигән идек.

И м а н к о л. Батырҗанны?

Б и к т а ш. Әйе, Батырҗанны. Йөзкәй түрә аны бүген безнең авыл аша, калада булачак судка озатачак.

И м а н к о л. Ай-һай, морза, ул фасикъны андый эшкә күндереп булыр микән?

Б и к т а ш. Күнәр, мулла, тик менә Йөзкәй түрәне генә күндерәсе иде. Батырҗан өчен, унике ел төрмәләрдә, салкын Себерләрдә йөрүгә караганда, солдат булып китү артыграк.

И м а н к о л. Ансы дөрес. Ә ул риза булмаса?

Б и к т а ш. Ул чагында башка чарасын эзләрбез. Әнә Йөзкәй түрәләр.

Урам яктан б е р н и ч ә с о л д а т белән Й ө з к ә й һәм К о л т а й күренә, алар артыннан Б у л а т ияреп керә.

Б у л а т. Йөзкәй түрә...

Й ө з к ә й. Ү-ү...

Б у л а т. Йөзкәй түрә...

Й ө з к ә й. Ү-ү...

Б у л а т. Йөзкәй түрә дим!

Й ө з к ә й. Ни булган?

Б у л а т. Синдә йомышым бар иде, түрә.

Й ө з к ә й. Йомышың бар иде? Сөйлә.

Б у л а т. Минем сыерымны Иманкол мулланың сыеры сөзеп үтергән иде, шул турыда берничә кат сорап карасам да, ул миңа түләми. Сез ил түрәсе, безнең хакыбызны алып бирсәгез иде.

Й ө з к ә й. Ярый, ярый, алып бирермен.

Б у л а т. Безне яклавыгыз өчен рәхмәт, түрә.

Й ө з к ә й. Колтай, мулла өстеннән дәгъва кылып йөргән өчен сыер хакын биреп җибәр... камчы белән... үлгәнче онытмаслык булсын.

Б у л а т. Түрәм, әйттем исә кайттым, бернәрсә дә сорамыйм. Зинһар, җибәрегез!..

К о л т а й. Әйдә, әйдә. Муллаң өстеннән шикаять итеп йөрүнең ничек икәнен танытыйм әле. *(Җилтерәтеп алып китә.)*

И м а н к о л. Хи-хи-хи!.. Бәрәкалла, мөбарәк эшләдегез, Йөзкәй түрә.

Й ө з к ә й. Исәнмесез, мулла?

И м а н к о л. Шөкер әле, Йөзкәй түрә. Әйдә, рәхим итегез.

Й ө з к ә й. Бикташ морза, сезгә сәламәтлек телим.

И м а н к о л. Сезгә дә шулай булсын, исән-сау гына йөрисезме?

Б и к т а ш. Йөзкәй түрә, без монда бик мөһим бер мәсьәлә хакында сүз ачкан идек, шул турыда сез ни диярсез икән?

Й ө з к ә й. Нинди мөһим мәсьәлә ул?

Б и к т а ш. Мулланың малае өчен наемщик яллау турында киңәшә идек.

Й ө з к ә й. Наемщик? Бик әйбәт эш, бик гүзәл, ләкин кемне яллларга уйлыйсыз?

Б и к т а ш. Без үз тарафыбыздан Батырҗанны дигән идек.

Й ө з к ә й. Батырҗанны?.. Ул бит унике ел каторгага хөкем ителеп, Себергә озатылачак кеше, без аны калага судка алып барабыз.

Б и к т а ш. Әйе, шулай... Аны наемщик итү турында без карар бирдек инде.

Й ө з к ә й. Ничек инде миннән башка карар бирдегез? Мин һич риза түгел.

Б и к т а ш. Тыңлагыз инде, түрә.

Й ө з к ә й. Юк, юк, аның шикелле башкисәрне тотуыбыз өчен безгә хөкүмәт тарафыннан награда биреләчәк.

Б и к т а ш. Ул турыда кайгырмагыз, награданың иң яхшысын, иң асылын Иманкол мулладан алырбыз.

Г ө л б и к ә керә.

Г ө л б и к ә. Хәзрәт, табынга тәгам куелды.

И м а н к о л. Кадерле кунакларым, әйдәгез, рәхим итегез. Тәгамнән тәнәвел итәрсез.

Кереп китәләр.

Г ө л б и к ә. Батырҗанны бүген Себергә озаталар икән... Шулай ук соң көткән өметләрем бушка очтылармыни?

Музыка.

Г ө л б и к ә *(җырлый)*.

Ни көтәм мин өметләрем өзелгәч,
Теләкләрем тар-мар килеп сүтелгәч,
Кемнәр мине каргадылар,
Ник бәхетсез булдым мин?
Сусыз корган чияләрдәй,
Чәчәк атмый шиңдем мин.
Сөю утларында янып көлләндем,
Төн йокламый син ярымны уйладым.
Бар да очты мәңгелеккә,
Калды ла ялгыз башым.
Үксеп җылап, сине сагынып,
Түгәрмен канлы яшем.
Кайда син, күз нурым,
Бәгырькәем, Батырҗан?
Алсалар да тартып миннән,
Йөрәгемдә син һаман.
Җәй көннәрдә киң кырларда
Эшләп бергә йөргәнем,
Онытылмас еллар буе
Синең өчен көйгәнем.

Арттан исәнләшкән, саубуллашкан тавышлар ишетелә. Бәйләүле хәлдә Б а т ы р җ а н н ы кертәләр, аңар ияреп к а р т л а р, к а р ч ы к л а р, е г е т л ә р, к ы з л а р керә.
Музыка.

Б а т ы р җ а н *(җырлый)*.

Сау бул инде, минем туып үскән илем,
Сау булыгыз урман, басу, кырларым,
Сау булыгыз печән чапкан болыннарым,
Сау бул, даннар тоткан сабан туйларым.

Г ә р ә й. Әхмәт, Тимер, Батырҗаннар
Нигә шулай

Х о р. Себер сөрелә?

Г ә р ә й. Алпавыттан, түрәсеннән
Мең йөрәкләр

Х о р. Нигә тилмерә?
Язганмыни шомлы җилләр
Безнең өстән һаман исәргә?
Коллык богауларын кулдан
Кирәк, дуслар, безгә кисәргә.

Б а т ы р җ а н.
Рәхмәт сезгә, илнең батыр егетләре,
Сау булыгыз, дуслар, инде мин китәм.
Онытмагыз безнең изге эшебезне,
Иртән искән җилдән хәбәрләр көтәм.

К о л т а й *(халыкка)*. Кая киләсез, мөгезсез сыерлар! Таралыгыз!..

Х а л ы к. Хуш, Батырҗан! Хуш!

Халык чигенә.

Г ө л б и к ә. Батырҗан!

К о л т а й. Юк, абыстай, аны кеше белән сөйләштерергә ярамый.

Г ө л б и к ә. Ник ярамасын? Ул бит безнең үз кешебез.

К о л т а й. Нишләп сезнең үз кешегез булсын? Ул боярларга каршы крестьяннарны котыртучы, безнең кебек түрәләргә кул күтәрүче.

Г ө л б и к ә. Колтай ага, зинһар өчен минем белән сөйләшергә рөхсәт итегез.

К о л т а й. Юк, юк! Һичкем белән дә...

Г ө л б и к ә. Менә сиңа муенсамны бүләк итәм, рөхсәт итегез. *(Муенсасын бирә.)*

К о л т а й. Болай булгач, эш башка. Ләкин тиз булыгыз. *(Читкә китә.)*

Г ө л б и к ә. Мескенем, сине кыйнаганнар, ахры?

Б а т ы р җ а н. Әйе... Гөлбикә, минем эчәсем килә...

Г ө л б и к ә. Хәзер, Батырҗан. *(Кереп китә дә җамыяк тотып чыга.)* Менә салкын әйрән эч... Батырҗан, сине кая озаталар?..

Б а т ы р җ а н. Калага судка, аннан Себергә, диләр.

Г ө л б и к ә. Их, Батырҗан! Шундый зур эшләргә катнашмаска кирәк иде. Дөньяның тигезсезлекләрен син генә бетерә алмассың.

Б а т ы р җ а н. Алар бит безне хайван урынына исәпләп хурлыйлар, хатын-кызларыбызны күз алларыбызда мыскыл итәләр. Изелгән халыкны яклап чыгуым өчен Себергә түгел, әллә кайларга җибәрсәләр дә, миңа зур мәртәбә генә.

Г ө л б и к ә. Ә теге хәерче кызың кая?

Б а т ы р җ а н. Белмим. Дөрес булса, моннан качкан диләр...

Г ө л б и к ә. Хуш, Батырҗан. Тормышыңда авыр сәгатьләр кичергәндә, мине искә төшер. Мин сиңа һәрвакытта яхшы теләктә булырмын. Синең юлыңа акчаң бармы?

Б а т ы р җ а н. Юк. Нигә?

Г ө л б и к ә. Менә сиңа дәвәтемне бүләк итәм. Сатып кирәк-ярагыңа тотарсың.

Б а т ы р җ а н. Кирәкми, Гөлбикә.

Г ө л б и к ә. Курыкма, Батырҗан. Сине сөйгән хатыннан түгел, туган тутаңнан, анаңнан алган кебек итеп ал. *(Чыгалар.)* Хуш, сау бул!.. *(Батырҗанны үбеп кереп китә.)*

И м а н к о л, Й ө з к ә й, Б и к т а ш чыга.

Й ө з к ә й *(тешен казып)*. Мулла, балың бик татлы икән. Үз кортларыңныкымы?

И м а н к о л. Бу, түрә, бала кортлар балы иде. Аллага шөкер, быел өч батманлап бал алдым.

Б и к т а ш. Ягез, эшегезне бетерегез дә, аннан китәрбез.

Й ө з к ә й. Әгәр дә мулла, миңа биш баш умарта, бер төлке тамак, начальствога йөз сум күчтәнәч бирергә булса, аллага тапшырып, үз өстемә алырга риза.

Б и к т а ш. Ә сез, мулла, ни дисез?

И м а н к о л. Гәрчә бу шартлар минем өчен авыр булсалар да, күнми хәлем юк. Ярый, мин дә риза.

Б и к т а ш. Ярый, бар, мулла, үзе белән сөйләш.

И м а н к о л. Яхшы, хәерле булсын. *(Батырҗан янына чыга.)* Саумы, улым Батырҗан?

Б а т ы р җ а н. Әйбәт әле, мулла абзый.

И м а н к о л. Әй, улым, улым, кискенрәк егет булдың шул... Түрә кадәр түрәгә кул күтәргәнсең...

Б а т ы р җ а н. Әйе, мулла абзый, күтәрдем.

И м а н к о л. Шулай итеп, бала, гомерең буена таш капчыкларда ятып, салкын Себерләрдә сөргәрдәр булып йөрерсең микәнни?

Б а т ы р җ а н. Шулай инде, мулла абзый. Тәкъдирем шулай булгач, берни дә эшләр хәлем юк.

И м а н к о л. Әле бүген өйлә намазы укыганда башыма бер фикер килде.

Б а т ы р җ а н. Нинди фикер ул?

И м а н к о л. Чит-ят илләрдә, кул-аякларың богаулы хәлдә, катор хезмәтләре итеп йөргәнче, Тимерхан өчен наемщик булып солдатка китәм дисәң, бәлки, түрәләр калдырырлар иде дим.

Б а т ы р җ а н. Наемщик булырга?

И м а н к о л. Әйе, наемщик булырга.

Б а т ы р җ а н. Мулла абзый, чынлап та мин наемщик булырга риза булыр идем.

И м а н к о л. Шулаймы, ризамы?.. Әйдә алайса, түрәләр янына кереп сөйләшик әле. *(Китә.)*

Б а т ы р җ а н. Әйе, бу минем өчен яхшы булыр... Бердән, богаудан түгел, икенчедән, бәлки шул арада бер искиткеч нәрсә дә эшләп алырмын. *(Тегеләр янына керә.)*

И м а н к о л. Түрәләр, Батырҗанның сездә бик зур үтенече бар икән.

Б и к т а ш. Нинди үтенеч?

И м а н к о л. Әгәр дә сез рөхсәт итсәгез, ул, Тимерхан өчен наемщик булып китәр идем, ди.

Й ө з к ә й. Наемщик булып? Юк, юк, мулла.

И м а н к о л. Йөзкәй түрә, мәрхәмәт итегез, мөселман бәндәне салкын Себерләрдә әрәм итмәгез.

Й ө з к ә й. Юк, мулла, мөмкин түгел.

Б и к т а ш. Минемчә, Батырҗан кебек батыр йөрәкле бер кешене, каторгага җибәреп харап итүгә караганда, ватанга хезмәт иттерү артыграк булыр.

Й ө з к ә й. Анысы шулаен шулай да, ләкин бит...

И м а н к о л. Түрәм, ялварып сорыйм, мөэмин-мөселман кеше юкка газап чикмәсен. *(Юри елаган була.)*

Б и к т а ш. Тыңлагыз инде, түрә, хәзрәтнең күз яшен түктермәгез.

Й ө з к ә й. Ярый, үземә авырлык булса да, сүзегезне тыңлыйм. Ләкин хәзер үк, минем алдымда кәгазь язышып, эшегезне бетерегез.

Б и к т а ш. Була ул, аны хәзер язып ташлыйбыз.

Б а т ы р җ а н. Туктагыз әле, ашыкмагыз, минем дә берничә шартым бар.

И м а н к о л. Шартың бар?..

Б и к т а ш. Нинди шарт ул? Әйтеп кара.

Б а т ы р җ а н. Беренче: наемщик булуым өчен бер йөз тәңкә акча бирәсез.

И м а н к о л. Йөз тәңкә?!

Б а т ы р җ а н. Икенче: бүгеннән башлап, солдатка чыгып киткәнче, теләгән нәрсәмне эшләү ирекен миңа калдырасыз.

Б и к т а ш. Алай...

Б а т ы р җ а н. Өченче: үткәндәге гаепләрем бетерелде дип, кулыма язу бирәсез.

Й ө з к ә й. Язуын бирербез, ләкин акчасы мулладан булыр.

Б и к т а ш. Йә, мулла, нигә телеңне тешләдең?

И м а н к о л. Тешләрсең, морза... Мин ул йөз сум акчаны каян алыйм?

Б а т ы р җ а н. Мин шушы шартларым үтәлгәндә генә наемщик булырга риза. *(Китә башлый.)*

Б и к т а ш. Батырҗан, тукта әле...

Батырҗан туктап кала.

Б и к т а ш *(Иманколны читкә алып китә).* Мулла, эссе чакта сук инде. Шулай ук соң бер йөз тәңкә акча табарлык байлыгың юкмыни?

И м а н к о л. Сез алай дисез дә бит, морза, аңар бер йөз сум, Йөзкәй түрәгә төлке тамак, биш баш умарта, начальникларына тагын бер йөз сум акча бирә башласам, ә үземә йомран башы каламыни?..

Б и к т а ш. Әгәр дә күпсенәсең икән, ихтыярың, малаеңны җибәрерсең.

И м а н к о л. Күним микәнни?

Б и к т а ш. Билгеле, күн.

И м а н к о л. Ярый, улым Батырҗан, мин риза.

Й ө з к ә й. Мин кәгазьләрне язып бетердем. Кулларыгызны куегыз.

Б а т ы р җ а н. Минем кулларым бәйләүле, чишегез.

Й ө з к ә й. Колтай, кулларын чиш.

Чишәләр, Батырҗан укып кул куя.

Б а т ы р җ а н. Йөзкәй түрә, пичәтеңне басарга оныткансың.

Й ө з к ә й. Шулаймыни?.. *(Печать басып бирә.)*

А р м а й каушап йөгереп керә.

А р м а й. Бикташ морза, Шәрифә бикәнең ашына агу салып агуладылар.

И м а н к о л. Шәрифә бикәгә агу?..

Й ө з к ә й. Тизрәк, каладан доктор чакыртырга кирәк.

А р м а й. Соң инде, ул үлде.

Й ө з к ә й. Үлде?.. Алай булса, әйдәгез, янына барыйк.

Б и к т а ш. Мәшәкатьләнмәгез, үзем карармын. Ярый, хушыгыз! *(Ишегалдына чыгып туктый.)* Тәфкилевләрнең тамыры корып, Атабаевлар чәчәк ата башлады. Хәзер минем планнарым тормышка ашып, мәшһүр миллионер буласым гына калды. *(Китә.)*

Б а т ы р җ а н. Ярый, хәзергә хушыгыз.

И м а н к о л. Улым, Батырҗан, бераз гына ачы балдан тәнәвел итеп алыр идең.

Б а т ы р җ а н. Юк, мулла абзый, мин эчмим. *(Китә. Ише-*

*галдында басып торган Колтай алдына туктап.)* Булды! Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, ди. *(Кулындагы договор кәгазе белән Колтайның борынына сугып, чыгып китә.)*

*Пәрдә.*

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Иманкол мулланың икенче пәрдәдәге ишегалды. Пәрдә ачылганда Иманкол урам як капкадан карап тора. Өйдән А й с ы л у чыга.

А й с ы л у. Хәзрәт, кайда кычкырышалар?

И м а н к о л. Каравыл өе янында.

А й с ы л у. Нәрсә өчен ди, белмәдеңме?

И м а н к о л. Ни дә булса, Бикташ морза белән ике арада чыккан тавыш булса кирәк.

А й с ы л у. Әй, ходаем, бу нинди замана булды соң? Морзасына буйсынмый, мулласына ышанмый. Түрәләр ни карый, нигә шуларны яткырып сукмыйлар?..

Т и м е р х а н керә.

И м а н к о л. Йә, улым, белдеңме?

Т и м е р х а н. Бөтен авыл Бикташ морзаның эшенә чыгудан баш тарткан.

И м а н к о л. Баш тарткан?

Т и м е р х а н. Бикташ морза Армай белән эшкә куа башлаган иде, ташлар атып, үзләрен куып җибәрделәр.

И м а н к о л. Мондый явызлыкка кем өйрәтте икән үзләрен?

Т и м е р х а н. Мәзин абзый әйтә — безнең Батырҗан, ди.

И м а н к о л. Бу нинди башкисәр, әбуҗәһил булды соң!

Т и м е р х а н. Әткәй, Бикташ ага сине мәчеткә килсен, диде.

И м а н к о л. Мәчеткә? Анда нигә?

Т и м е р х а н. Бикташ морза мәзин абзыйга өйдән өйгә йөреп бөтен кешене мәчеткә куарга, шул җыйналган халыкка синә вәгазь сөйләргә кушты.

И м а н к о л. Яхшы, бик мәгъкуль, бик мәслихәт эш. Бар, улым, мәзин абзаң белән син дә мәчеткә өндәрсең. Мин озакламый барып җитәрмен.

Т и м е р х а н. Ярый, әткәй. *(Китә.)*

А й с ы л у. Ай-һай, хәзрәт, мондый чакта сүзләрең үтәрме икән!

И м а н к о л. Мин ул бәдбәхетләргә, мин ул әбуҗәһил кот-

кысына ияручеләргә шундый сөйләрмен, җилекләренә үткәрермен. Мин киенә торам, син, бар, китабымны хәзерлә.

А й с ы л у. Кайсын, яшел тышлысынмы?

И м а н к о л. Икесен дә хәзерлә.

Кереп китәләр. Урам яктан Б а т ы р җ а н кайтып керә. Музыка.

Б а т ы р җ а н *(җырлый).*

Язгы ташкын ярсыгандай
Ярсый йөрәк, уйларым,
Ярсып күңлем көтә минем,
Көтә җиңү туйларын.
Юллар буйлап, кылыч болгап,
Шәһәрләргә җитәргә,
Таш өстендә таш калдырмый
Барсын таптап китәргә.

Г ә р ә й керә.

Г ә р ә й. Батырҗан абый!

Б а т ы р җ а н. Ни бар?

Г ә р ә й. Эшләр начар.

Б а т ы р җ а н. Ни булды?

Г ә р ә й. Бөтен авылны мәчеткә куалар. Иманкол мулла вәгазь сөйләячәк.

Б а т ы р җ а н. Вәгазь сөйләячәк?

Г ә р ә й. Йә, Батырҗан абый, нишлибез?

Б а т ы р җ а н. Бу Гөлйөзем нишләп тора икән?

Г ә р ә й. Безгә аны көтәргә ярамый. Үзебезгә чарасын күрергә кирәк.

Б а т ы р җ а н. Юк, Гәрәй, Гөлйөзем килмичә бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Безнең бөтен ышаныч аңарда.

Г ә р ә й. Әгәр мулла халыкны үгетләп, бояр ягына аударып куйса, нишләрбез?

Б а т ы р җ а н. Курыкма, җаен табарбыз. Мин мулланы мәчеткә җибәрмичә, ат җиктереп, үзем белән Гөлйөземне каршыларга алып китәм. Ә син хәзер Булат, Ходаяр, Нәгыйм бабайларга барып әйт, өйдән өйгә, колактан колакка ымлауларын ташламасыннар.

Г ә р ә й. Ярый, Батырҗан абый. *(Китә.)*

И м а н к о л, таякка таянып, намаз киемнәреннән чыга.

И м а н к о л. Нихәл, улым Батырҗан?!

Б а т ы р җ а н. Бик яхшы әле, мулла абзый. Син кая болай җыендың?

И м а н к о л. Бүген бит гашүрә бәйрәм көне, шул турыда бераз халыкка вәгазь сөйләмәкче булам.

Б а т ы р җ а н. Алай икән...

Иманкол. Әйе, улым, шулай. Сиңа да мәчеткә барып тыңлаганда яхшы булыр иде.

Батырҗан. Вакытым юк, барасы җирем бар.

Иманкол. Шулаймыни? Ярый алайса. *(Китә башлый.)*

Батырҗан. Тукта әле, мулла абзый.

Иманкол. Нигә, улым?

Батырҗан. Бар, миңа ат җигеп бир әле.

Иманкол. Ат җигеп?

Батырҗан. Әйе.

Иманкол. Миңа, ат җигәргә?

Батырҗан. Әйе, сиңа дим бит.

Иманкол. Улым Батырҗан, сиңа җен-пәриләр кагылганга охшый. Кая, өшкерергә кирәк.

Батырҗан. Күп сөйләнеп торсаң, менә моның белән өшкерермен... Бар, атыңны җик!

Иманкол. Әлгаязе билләһи, мин нишләп ат җигеп йөрим? Күрәсең бит, гашүрә намазына барышым.

Батырҗан. Намазларыңны мин киткәч укырсың. Ә хәзер мин кушканнарны җиренә җиткер.

Иманкол. Соң бит, улым, үзең бик яхшы беләсең, минем гомеремдә ат җиккәнем юк.

Батырҗан. Җиккәнең булмаса, өйрәнерсең.

Иманкол. Бераз гына инсаф, ригая кирәк иде, улым.

Батырҗан. Яхшылыкта мин әйткәнне тыңлыйсыңмы, юкмы?

Иманкол. Тыңламыйча чарам юк. Чөнки син минем наемщигым. *(Китә.)*

Батырҗан. Бу Гөлйөзем нишләп тора? Әллә Сандр атаман урынын алыштырып, таба алмый йөриме икән?

Гөлбикә керә.

Гөлбикә. Батырҗан, кесәл пешергән идек, әйдә, ашарга кер.

Батырҗан. Рәхмәт, Гөлбикә, мин кешедә ашадым.

Гөлбикә. Син, ни өчендер, соңгы көннәрдә өйгә кайтмый башладың?

Батырҗан. Ахыргы көннәрем бит, дус-ишләрем белән күрешеп йөрим.

Гөлбикә. Кайчан юлга чыгасың?

Батырҗан. Иртәгә.

Гөлбикә. Шулай итеп, туып үскән җиреңне ташлап китәргә бер дә кызганмыйсыңмы?

Батырҗан. Кызганып нишлим, язмышым шулай булгач.

Гөлбикә. Батырҗан, нигә син котылырга юллар эзләмисең?

Б а т ы р җ а н. Мөмкин түгел бит ул. Ак өстенә кара белән язылган — эш беткән инде...

Г ө л б и к ә. Юк, бетмәгән, мин сине коткара алам.

Б а т ы р җ а н. Син әйт, ничек?

Г ө л б и к ә. Тимерханны...

И м а н к о л керә.

И м а н к о л. Солдат әфәнде, ат җигелде, рәхим итеп чыгып утырыгыз.

Б а т ы р җ а н. Яхшы. Ләкин син дә минем белән барырсың.

И м а н к о л. Синең белән?

Б а т ы р җ а н. Әйе, минем белән. Ат тотарсың, кучер булырсың.

И м а н к о л. Әлгаязе билләһи, мин кучер, дисеңме?

Т и м е р х а н керә.

Т и м е р х а н. Әткәй, халык мәчеткә җыйналып бетте, сине көтәләр.

И м а н к о л. Улым Батырҗан, ишетәсеңме, мәчеттә — алла йортында мине көтәләр.

Б а т ы р җ а н. Без озак йөрмәбез, хәзер кайтырбыз.

И м а н к о л. Булмаса, минем өчен улым Тимерхан гына барсын.

Б а т ы р җ а н. Юк, мулла абзый, син барырсың.

И м а н к о л. Йә, Ходай, пәрвәрдикар! Нишләргә инде? Улым, бар тизрәк, Бикташ морзага барып әйт, әткәйне Батырҗан җибәрми, диең.

Т и м е р х а н. Ярый, әткәй. *(Китә.)*

Б а т ы р җ а н. Әйдә, мулла абзый, киттек.

И м а н к о л. Тукта әле, улым, бераз сабыр ит, урам буйлап намаз киеменнән ат тотып бару килешмәс. Өс-башларымны алыштырып чыгыйм. *(Кереп китә.)*

Г ө л й ө з е м керә, ирләр киеме киенгән.

Г ө л й ө з е м. Батырҗан!

Б а т ы р җ а н. Гөлйөзем, ник бик озак? Йә сөйлә, нинди хәбәрләр алып кайттың?

Г ө л й ө з е м. Сандр агай белән Тирсә, Нажар крестьяннарына аңлаттык. Алар, «башлагыз, без сездән калышмабыз», диделәр.

Б а т ы р җ а н. Йә, йә, шуннан?

Г ө л й ө з е м. Шуннан Биктау качкыннарын үзебез белән монда алып килдек. Алар хәзер Сандр агай белән Тирән чокыр урманында. Сездән хәбәр көтәләр.

Б а т ы р җ а н. Яхшы. Безнең монда да эшләр әзерләнгән. Син хәзер ат менәрсең дә Сандр агайны монда алып килерсең.

Өс-башларын алыштырып, кулына чыбыркы тотып, И м а н к о л чыга.

И м а н к о л. Әйдә, наемщигым, киттек.

Б а т ы р җ а н. Менә нәрсә, мулла абзый, син хәзер җиккән атыңны туарырсың да менә бу егеткә иярләп бирерсең.

И м а н к о л. Иярләп бирермен?

Б а т ы р җ а н. Әйе, иярләргә. Бар, тизрәк бул!

И м а н к о л. Ә син?

Б а т ы р җ а н. Мин бармаска булдым.

И м а н к о л. Йә, Ходай, бар икән күрәселәрем!

Иманкол белән Гөлйөзем китә. Г ә р ә й белән Б у л а т керәләр.

Б у л а т. Энем, Батырҗан, Гөлйөзем нинди хәбәрләр китергән?

Б а т ы р җ а н. Шәп, Булат абзый. Сандр атаман үзенең беглыйлары белән Тирән чокыр урманында безнең эш башлаганны көтә. Гөлйөзем аларны озакламый монда алып киләчәк.

Б у л а т. Ярый алайса, Аллага тапшырып, башларга кирәк. Бөтен халык мәчеткә җыелган. Бер сүз әйтүгә дары кебек кабынырга торалар. Башлап үзем сүз катам.

Г ә р ә й. Булат абзый, сиңа читтәрәк йөрсәң дә ярар иде. Без шул юлда үлсәк тә, артыбыздан җылап калучыларыбыз юк. Ә синең хатының, биш балаң бар.

Б у л а т. Юк инде, энекәем Гәрәй, җитәрлек түздем... Кызымны көчләп алдылар — түздем. Сыерымны үтерделәр — түләмәделәр, хакны сорап бардым — аркамны камчыладылар. Инде бу эшләренә чыдап торыр хәлем юк. Их, мин аларны!..

Б а т ы р җ а н. Рәхмәт, Булат абзый.

Б у л а т. Әйдәгез, киттек мәчеткә!

Б а т ы р җ а н. Туктагыз, Сандр агай килә.

С а н д р керә.

С а н д р. Ну, братлар, эшләр ничек?

Б а т ы р җ а н. Эшләр яхшы, Сандр агай. Безнең кешеләр әзер, сәбәпләр җитәрлек. Эш сездә тора.

С а н д р. Минем егетләр карчыгадай көтеп торалар. Бер сүз әйтү белән утка керергә әзерләр. Сез курыкмагыз, без күп, безгә янәшә тирәдәге вольный крестьяннар да, завод эшчеләре дә кушыла. Сез беләсезме, мин хәбәр алдым, көнбатыш губерналарда Александр патшаның чыгарган манифестына каршы восстаниеләр белән җавап бирәләр.

Б а р ы  д а. Димәк, манифест чыгарылган?

С а н д р. Да, чыгарылган. Ну, крестьяннар ул хәйләне тиз төшенгәннәр. Ирекне бирелә, ә җире юк. Икенче кат кол итәр өчен чыгарылган манифест икәнлеген аңлап, мужиклар балта, сәнәкләр белән каршы торалар.

Г ә р ә й. Бикташ килә.

С а н д р. Батырҗан, син аны миңа бир...

Б а т ы р җ а н. Үзем башлыйм, сез яшеренегез.

Яшеренәләр. Б и к т а ш, Т и м е р х а н, А р м а й керә.

Б и к т а ш. Син, динсез мөртәт, ни өчен мулланы намазга җибәрмисең?

Б а т ы р җ а н. Җибәрмәсәм, анда синең ни эшең бар?

Б и к т а ш. Син шулай дингә, аллага каршылык итә башладыңмы?

Б а т ы р җ а н. Алла белән сукыр бер тиенлек эшең булмаса да, баш тартучы крестьяннарны буйсындырырга алла кирәк була башладымыни?

Б и к т а ш. Җитәр сиңа!

Б а т ы р җ а н. Яхшы чакта тай моннан.

Б и к т а ш. Нәрсә? Миңа?..

Б а т ы р җ а н. Әйе, сиңа. Эт кебек өреп торсаң, муеныңны борып ташлармын.

Б и к т а ш. Синең китәр вакытың җитте, мин сине хәзер бәйләп җибәрермен. Бәйләгез үзен!

Б а т ы р җ а н. Якын килмәгез. *(Пистолет чыгара.)*

Б и к т а ш. Синең коралың бар?

Б а т ы р җ а н. Булат абзый, Гәрәй, Сандр агай, бәрегез үзләрен.

Бикташка ташланалар. Армай белән Тимерхан чыгып кача. Н ә г ы й м к а р т керә.

Н ә г ы й м. Батырҗан, Йөзкәй түрә патшадан крестьяннарны азат иткән манифест китергән.

Б у л а т. Манифест? Безне азат иткәннәрме?

Б а т ы р җ а н. Әйдәгез, киттек! Манифест тыңларга!..

С а н д р. Сез анда башлагыз. Мин карчыгаларымны алып килергә барам.

Чыгып китәләр.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Каравыл өе алды. Халык җыелган.

Б а т ы р җ а н. Абзыйлар!.. Әллә сез безнең файдага манифест чыгарырлар дип көтәсезме?

Б у л а т. Син, энем Батырҗан, халыкны алай котыртма. Иң элек тыңлыйк әле. Аннан әйтерсең. Әмма болай вәсвәсә салып маташма.

Б е р ә ү. Чыгалар, чыгалар.

С о л д а т л а р белән Й ө з к ә й чыга.

Й ө з к ә й. Шауламагыз, мин сезгә Александр Николаевич хәзрәтләренең крестьяннарны азат иткән манифестын укыйм. *(Укый.)* «Боярлар кул астындагы крестьяннарны ике ел эчендә азат итәргә бөтен боярларга боерам. Азат ителгән крестьяннарга җирне...»

Х а л ы к. Җә, җә... җирне?..

Й ө з к ә й. Шауламагыз! «Җирне боярлар үзләреннән арткан кадәресен крестьяннарга биреп торалар. Крестьяннарга бирелә торган җирләр өчен хөкүмәт боярларга акча түләп, крестьяннардан недоимка дип, ел саен ясак алыныр. Волостной управлениеләр төзелгәнгә кадәр крестьяннар үз боярларының әмерләренә буйсыналар. Тәртипсезлек чыгаручылар, наразыйлык күрсәтүчеләр өстеннән тикшереп торырга боярларга тапшырам. Бу манифест чыгарылды Санкт-Петербургта. Бер мең сигез йөз алтмыш беренче елда...»

Б у л а т. Уһу!.. *(Үрти.)*

Й ө з к ә й. «У... унтугызынчы февральдә. Патшалык буыныбыз җиденче. Мөбәрәк кулым куйдым: Александр икенче».

Б у л а т. Уһу!..

Тынлык.

Й ө з к ә й. Ник эндәшмисез? Әллә шатлыктан телләрегезне йоттыгызмы?

Б у л а т. Ирек бирүен биргән дә бит... Җир хакында әллә ничек, буталчык... Минем аңлавымча, җиргә һаман да боярлар хуҗа булып калалар, ахры...

Х а л ы к. Әйе, шулай шул...

Й ө з к ә й. Шауламагыз! Әйе, җиргә боярлар хуҗа булып, бояр межалары искечә кала.

Б у л а т. Ул ничек була инде? Аның җирсез иреге белән без нишлик? Менә алыйк безнең авылны, алты йөз илле җан исәпләнә. Шулкадәр кешегә урман-сулар, чокыр-чакырларыбыз белән биш йөз мең бау җиребез бар. Ә боярларның бирүзләренә биш йөз мең бау. Шулай булгач, җирсез манифестның тәрәтемә кирәге бармыни, ә?

Й ө з к ә й. Ансы минем эш түгел. Патша хәзрәтләренең әмере шулай.

Г ә р ә й. Абзыйлар! Нигә эндәшмисез, әллә сез шуңа ризамы?

Х а л ы к. Нигә риза булыйк!

Й ө з к ә й. Тавышланмагыз!

Б а т ы р җ а н. Туганнар, мин дә бер-ике сүз әйтим әле.

Й ө з к ә й. Беркемгә дә сөйләргә рөхсәт юк.

Х а л ы к. Сөйләсен, тимәгез, сөйләсен!..

Б а т ы р җ а н. Абзыйлар! Безне азат иткән булып, шул ук боярларны җир-сулар, урман-кырлар белән калдырып, безне тагын да катырак кол итәргә телиләр. Безгә андый ирекнең кирәге юк. Безгә җир-сулар, урман-басулар кирәк!

Х а л ы к. Дөрес! Дөрес!..

Й ө з к ә й. Әй, солдатлар!.. Тотып бәйләгез үзен! Авызын томалагыз!..

Солдатлар Батырҗанны алырга баралар.

Г ә р ә й. Абзыйлар, ни карап торасыз, бәрегез үзләрен!

Бердән һөҗүм ясыйлар, Йөзкәй белән солдатларның коралларын алып таптыйлар.

Б а т ы р җ а н. Туганнар!.. Ачы тормышыбыз кушкан үч алу көне җитте!.. Сәнәк, чалгыларыгызны, бүре чабагачларыгызны алыгыз! Хөкем йөртергә вакыт җитте!

Качкыннар ияртеп С а н д р керә.

С а н д р. Ну, братлар, әйдәгез! Боярларны, чиновникларны кырырга!

Батырҗан җыр башлый. Музыка.

Б а т ы р җ а н. Рәхмәт сезгә, илнең батыр егетләре,
Сау булыгыз, картлар, инде без китик.
Онытмагыз безнең изге эшебезне,
Чын ирекләр даулап йөрәк җилкетик.

Хор. Сау булыгыз, авылдашлар,
Сау бул, урман-кырларым,
Сау булыгыз, туганнарым,
Сау бул, сөйгән ярларым.

*Пәрдә.*

# ЧАТКЫЛАР

*Драма биш пәрдәдә*

Катнашучылар:

Гаяз — тимерче егет.
Хәсби — аның анасы.
Рамай — ярлы, бунтарь егет.
Дәүли — староста.
Гарифә — аның хатыны.
Маһисәрвәр — аларның кызы.
Сәетгәрәй — уку яшендәге бала.
Сабир — авылның зур сәүдәгәре.
Фәрхәнә — аның анасы.
Тимай — каравылчы карт, инвалид.
Хәмдия — аның кызы.
Орлов — сөргенгә җибәрелгән Мәскәү эшчесе.
Дерюгин — урядник.
Макар — стражник.
Гобәй — авыл бае.
Тимергали — ярлы егет.
Шәриф — гармунчы егет.
Гыйльмениса — ярлы карчык.
Фәйзулла — батрак.
Сәләхи — Сәетгәрәйнең иптәш малае.
Хөснижамал
Миңҗамал } яшь кызлар.
Мочтак — хаҗи малае.
Тикшерүче.

Вакыйга 1907-1910 елларда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сабир байның өе. Яхшы мебельләр, матур җиһазлар белән бизәлгән. Бер якта кибеткә чыга торган ишек, ишек башында кечкенә кыңгырау, икенче якта кереп-чыгып йөри торган ишек. Пәрдә ачылганда сәхнәдә Сабир белән Фәрхәнә.

Сабир *(өстәл өстенә куелган зур саквояждан төлке тамагы чыгарып)*. Менә, монысы, әни, сиңа тунга, төлке тамагы.

Фәрхәнә *(күрүгә исе китеп)*. Ах!.. Нинди йомшак, нинди матур... Кара инде, күз нурларын алырлык. Рәхмәт, улым,

рәхмәт. Мине куандырган өчен алла сине зурласын.

С а б и р. Ә менә монысы үземә, чалбар белән пиджакка. Англиядән килгән трико.

Ф ә р х ә н ә. Әйбәт, улым, бик әйбәт. Җылы тәнеңдә тузарга язсын. Тик кара аны, былтыргы кебек авыл тегүчесеннән боздырма, волостьтагы рус мачтырына бирерсең.

С а б и р. Ә менә инде боларын булачак киленең өчен дип алдым. Йон күлмәклек һәм Пенза шәле. Ошыймы?

Ф ә р х ә н ә. Ошамыймы соң, шундый затлы әйберләр. Тик шәле Оренбурныкы булса да ярыйсы иде дә...

С а б и р *(кашемир яулык белән бохар түбәтәен чыгарып)*. Боларын инде мулла абзый белән абыстайга бирерсең. Дога кылып алсыннар.

Ф ә р х ә н ә. Аларны онытмавың бик әйбәт булган, улым. Нигә дисәң, синең өчен үлеп торалар. *(Кычкырып.)* Хәмдия, Хәмдия, дим! Кичә мине чәйгә чакырганнар иде. Әй мактыйлар, әй мактыйлар сине...

Х ә м д и я керә.

Х ә м д и я. Нигә чакырдың, абыстай?

Ф ә р х ә н ә. Менә бу бүләкләрне карт хәзрәтләргә илтеп кайтырсың.

Х ә м д и я. Ярый, абыстай. *(Китә башлый.)*

Ф ә р х ә н ә. Тукта әле, бераз инжир белән хөрмә җимеше дә бирим. Кара аны, юлда урлап ашый күрмә, санап салам. Бар, бер аягың анда булса, икенчесе монда булсын!

Хәмдия китә.

С а б и р. Шулай итеп, әни, мин өйләнергә булдым.

Ф ә р х ә н ә. Ярый, улым, ярый. Шушы кадәр зур дәүләтне алып бару миңа да бик авыр иде. Эш рәте белгән бала туры килсә, бөтен ачкычларымны аңа тапшырып, үзем кибеттә генә калыр идем. Бу ниятеңне хәзрәтләр дә ишеткән икән, кичә шул турыда сөйләшеп утырдык, кыз да сайладык.

С а б и р. Я әле, әйтеп кара, кемне сайладыгыз икән?

Ф ә р х ә н ә. Остабикә, чулак мәзин кызын алыйк, ди.

С а б и р. Китегез, әллә юләрләндегезме?

Ф ә р х ә н ә. Нигә, балам, кызы бик чибәр, диләр.

С а б и р. Чибәр, чибәр... күрсәң, гайрәтең чигәр. Табак кадәр биткә орчык башы кадәр курнус борын.

Ф ә р х ә н ә. Курнус булса да, борыны бик матур, ди абыстаң, зур битенең уртасында песи борыны кебек килешеп кенә тора, ди.

С а б и р. Юк, әнкәй, кирәкми. Тагын кемнәрне сайладыгыз?

Ф ә р х ә н ә. Хәзрәт әйтә, яргыччы Шәйдүк кызын үзем кодалыйм, ди.

С а б и р. Аллам сакласын, аның ише тел бистәсен аламмы соң? Бөтен нәселләре белән телгә беткәннәр!

Ф ә р х ә н ә. Дөрес шул. Мин үзем дә аны ошатып җиткермәдем. Минемчә, Хәкимҗан кызы ничек булыр икән?

С а б и р. Яратмыйм, бите сипкелле.

Ф ә р х ә н ә. Мортаза Хәдичәсе?

С а б и р. Ярар иде дә, ләкин бераз гына шадрасы бар.

Ф ә р х ә н ә. Булат Нәгыймәсе?

С а б и р. Кирәкми, кипкән балык төсле, үзе озын, үзе чандыр. Тәнендә карга чукырлык та ите юк.

Ф ә р х ә н ә. Шәйхи Фәхернисасы?

С а б и р. Анысы инде кирәгеннән артык юан.

Ф ә р х ә н ә. Ай Алла, берсен дә яратмыйсың, өч хатын аерган кешегә әллә кемне бирмәсләр инде.

С а б и р. Бирерләр, әнкәй, тал чыбыктай зифа буйлы, гөлҗимеш чәчәгедәй алсу йөзле кызны алырмын.

Ф ә р х ә н ә. Ул кадәрле искитәрлек кем соң ул?

С а б и р. Ул, әнкәй, Маһи.

Ф ә р х ә н ә. Кайсы Маһи?

С а б и р. Әтүтән Дәүли кызы, Маһисәрвәр.

Ф ә р х ә н ә. Ай-һай, улым, үткән елны да сүз салдырып карадык бит, тел төпләре бирмәскә булды.

С а б и р. Быел тагы сорап карарбыз. Яхшылыкта бирмәсәләр, башка юлларын да табарбыз.

Ф ә р х ә н ә. Белмим шул, ул кызның башын тимерче Гаяз чуалткан, диләр.

С а б и р. Зарар юк, ата-аналарын күндерсәк, беркая да китә алмас. Шулай, әнкәй, Маһисәрвәргә өйләнеп, хуторга күчеп алсак, дөньяда бер теләгем дә калмас иде.

Ф ә р х ә н ә. Хутор-хутор дип исең китте инде, улым. Безгә аның нинди генә файдасы булыр икән?

С а б и р. Безнең ишеләргә зыянлы булырлык булса, патша хәзрәтләренең иң сөекле министры Столыпин җәнаплары уйлап чыгармаган булыр иде.

Ф ә р х ә н ә *(тәрәзәдән күреп)*. Теге Әхмәтша малае килә. Акча сораргадыр. Ай-ваена карамыйча, бая мин әйткәннәрне басып кал.

Фәрхәнә кибеткә кереп китә. Р а м а й керә.

Р а м а й. Исәнме, Сабир абзый?

С а б и р. Яхшы.

Р а м а й. Фәрхәнә абыстай кирәк иде.

С а б и р. Ул өйдә юк, ни йомыш?

Р а м а й. Бер атнадан бирле кибәннәрегезне суккан артель акчасын бирми йөртә. Иртә килсәк, тормаган була, кичен килсәк, йоклый, диләр. Йөри-йөри аптырап беттек инде.

С а б и р. Акча сорарга беләсез, ә эшегезне эт ашы — арыш боламыгы итеп эшләгәнсез.

Р а м а й. Ничек арыш боламыгы?

С а б и р. Суккан арышларыгызны амбарга чыгып караган идем, чүбе-балчыгы белән тутыргансыз.

Р а м а й. Машинагызның иләге начар булуга без гаеплемени? Фәрхәнә абыстайга әллә ничә тапкыр әйттек, берәрсеннән машина алып чыгыйк, дидек. Кешегә лапатка бирәсе килмәде.

С а б и р. Шуның өстенә өч капчыкны ярып, ике көрәкне сындыргансыз, бер тырманы ватkансыз.

Р а м а й. Кем әйтә?

С а б и р. Кем булсын, әнкәй!

Р а м а й. Их, Сабир абзый, сезне күзгә карап җан сатучылар дип сөйлиләр иде, дөрес икән. Суккан саламнарыгызны ындыр буена өяргә сөйләшкән булсак та, утар түбәсенә күтәртеп чөебезне чыгардыгыз. Капчык ташырга ат бирергә вәгъдә итте, аны бирмәде. Эш беткәч, сыйларга булды, аны эшләмәде. Шулай була торып та безнең өскә бәла ягарга ничек оялмый ул? Карт башы белән ялганлап йөргәне өчен битенә төкерер идем, бәхете, өйдә юк икән.

С а б и р. Ярый, ярый, теленә салынма, акчаңны ал да үкчәңне күтәр. Мә!

Р а м а й *(акчаны алып)*. Тагы?..

С а б и р. Нәрсә тагы?

Р а м а й. Акча!

С а б и р. Нинди акча? Кулыңда ич.

Р а м а й. Ике сум җитми, дим.

С а б и р. Ни барлыгы шунда, артыгын бирә алмыйм.

Р а м а й. Ничек инде бирә алмыйсың?.. Ике йөз илле потка дүртәр тиеннән ун сум тиешле иде, монда сигез генә сум.

С а б и р. Әйе, шулай, ике сумыгызны тотып калабыз.

Р а м а й. Тотып каласыз?.. Ни өчен?

С а б и р. Өч капчыгың егерме бишәр тиеннән — җитмеш биш тиен. Ике көрәк, бер тырма — илле биш тиен. Кибеттән җитмеш тиенлек бурыч бирелгән. Барысы була төгәл ике сум.

Р а м а й. Ул нинди бурыч тагы?

С а б и р. Ун кадак клиндер ашагансыз.

Р а м а й. Имансыз икән... Кибән башлаган көнне, гадәт буенча өегезгә чакырып, чәй белән сыйлап маташкан иде, инде шуны да безнең өскә саласызмы?

С а б и р. Ник салмаска, бушка клиндер ашатырга сез безнең кемебез? Бар, бар, энем, хакыңны алдың. Алдыңнан артың яхшырак.

Р а м а й. Ә калганы?

Сабир. Әйттем бит инде, бирмим.

Р а м а й. Юкка маташасың, Сабир абзый. Барыбер бирерсең.

С а б и р. Бирмәм.

Р а м а й. Бирерсез.

С а б и р. Бирмәбез. Бездә казенный акчалар юк.

Р а м а й. Алырбыз!

С а б и р. Булмас!

Р а м а й. Яхшылыкта бирмәсәгез, бише белән кайтарырбыз.

С а б и р. Нәрсә?.. Куркытып алмакчы буласыңмы, әтрәк әләм? Ишбулды Сабирын куркыта алмассың!

Р а м а й. Куркытырбыз, башкаларның хакын ашап симерсәң дә, Әхмәтша малае Рамай хакын ашый алмассың.

С а б и р. Нишләрсең?

Р а м а й. Бугазыңнан каерып алырбыз! *(Чыгып китә.)*

С а б и р. Янама, янап мине куркыта алмассың!..

Ф ә р х ә н ә керә.

Ф ә р х ә н ә. Менә рәхмәт, улым, яхшы иттең.

С а б и р. Ничек гайрәтләнгән була, әтрәк әләм...

Ф ә р х ә н ә. Бик усал нәрсә, диләр иде, дөрес икән. Үрәдниккә хәбәр итәргә кирәк, син югында йортка зыян салмасын.

С а б и р. Минем белән эш иткәне юк әле, күрсәтермен мин аңар.

Ф ә р х ә н ә. Анысы да монысы, улым, бу Гобәй байлар белән нишләргә инде?

С а б и р. Ни булган тагы?.. *(Акча санарга утыра.)*

Ф ә р х ә н ә. Узган атнаны такта чәйгә киметкәннәр иде, бүген тагы керәчинне, тозны бездән арзан сата башлаган.

С а б и р. Безнең белән ярышкан буламы? Кайгырма, әнкәй, тиздән, алла боерса, аңарга да мин эт җиктерермен.

Ф ә р х ә н ә. Шулай итә күр. Юкса бездән алучыларны үзенә тарта... Тукта инде, буш чагымда ахшам намазымны гына укып алыйм.

Намазлык җәеп укырга керешә. Сәҗдәгә китәм, дигәндә кыңгырау шалтырый. Башын күтәреп тукталып кала, намазын ташлап кибеткә китә.

Х ә м д и я керә.

Х ә м д и я. Абый, Гыйльми карчык килгән, кертимме?

С а б и р. Керсен.

Г ы й л ь м и керә.

Г ы й л ь м и. Исәнме, улым Сабирҗан.

С а б и р. Әйдүк, Гыйльменисаттәй, түрдән уз.

Г ы й л ь м и. Нигә чакырткан идең?

С а б и р. Менә нәрсә, Гыйльменисаттәй, синең тормышыңны начар дип ишеттем.

Г ы й л ь м и. Сөйләмә инде, Сабирҗан. Юньләп ипигә дә туйган юк. Үткән ел аннан-моннан сукалатып бер бау чәчкән идем, уңмады, алган әҗәтләремә дә, ясак түләргә дә җитмәде.

С а б и р. Бүген шулай әнкәй белән киңәштек тә сиңа ярдәм итәргә булдык.

Г ы й л ь м и. Ярдәм итәргә?.. Мин төшенә алмыйм, нинди ярдәм ул?..

С а б и р. Без быел дәүләтебездән зәкят чыгарабыз. Чит кешеләргә биреп әрәм иткәнче, үз кардәшебезгә булсын, дидек. Ерактан булса да, син бит безгә туган тиешле.

Г ы й л ь м и. Ерак дип, алай бик ерак түгел инде, синең бабаңның әбисе белән минем әбинең бабасы туганнан туган балалары гына бит.

С а б и р. Әйе, әйе, шулай шул. Әнкәй, бушаган булсаң, монда чык әле. Шулай, Гыйльменисаттәй, мин синең ашарыңа-эчәреңә дә бирермен.

Г ы й л ь м и. Рәхмәт, балам Сабирҗан, рәхмәт. Ходай сиңа озын гомер биреп, бетмәс-төкәнмәс маллар белән баетсын.

Ф ә р х ә н ә керә.

С а б и р. Менә нәрсә, әнкәй, бая сөйләшкән буенча, Гыйльменисаттәйгә ун кадак ярма, бер кадак шикәр, чирек чәй биреп җибәр әле.

Ф ә р х ә н ә. Әллә иманасын...

С а б и р. Тсс... зәкяттән, хәердән булыр.

Ф ә р х ә н ә. Зәкяттән?

С а б и р. Бар инде, бар.

Ф ә р х ә н ә. Әйдә... *(Китә башлыйлар.)*

С а б и р. Гыйльменисаттәй, оныта язганмын икән, Гобәй байга иманаңны сатарга йөрисең дип ишеткән идем, шул сүз дөресме?

Г ы й л ь м и. Әйе, улым, дөрес.

С а б и р. Күпмегә килештең?

Г ы й л ь м и. Биш сум акча, өч пот арыш оны, бер күлмәк һәм вак-төяк нәрсәләр.

С а б и р. Сөйләшкән нәрсәләреңне алып бетердеңме әле?

Г ы й л ь м и. Бер пот оны белән өч сум акчасын алган идем, калганнарын кәгазь язышкач бирәм, ди.

С а б и р. Фәкыйрь карчык хакын ашарга кешедән оялмаса да, алладан куркырга кирәк иде, комсыз...

Г ы й л ь м и. Нигә, улым Сабирҗан?

С а б и р. Ул бит сине алдаган.

Г ы й л ь м и. Алдаган?..

С а б и р. Әйе, алдаган. Хәзерге заманда ул хакка имана саталармы?

Г ы й л ь м и. Карчык кеше мин каян белим соң?

С а б и р. Бүген үк үзенә бар да, иманамны сатмаска булдым, диген.

Г ы й л ь м и. Бәхетсезлеккә каршы, акчасын алып тоткан идем шул.

С а б и р. Кайгырма, Гыйльменисаттәй, үз кардәшебезне таларга ирек бирмәбез. Мә, илтеп бир үзенә. *(Акча бирә.)*

Г ы й л ь м и. Ә ул риза булмаса?

С а б и р. Риза булмый хәле юк, сез бит әле кәгазь язышмаган. Бар, әнкәй, Гыйльменисаттәйне көттермә.

Ф ә р х ә н ә. Әйдә!..

Г ы й л ь м и. Ярый, улым Сабирҗан, яхшы киңәшеңә рәхмәт.

Ф ә р х ә н ә Гыйльмине кибеткә кертеп җибәрә дә үзе Сабир янына килә.

Ф ә р х ә н ә. Син нишлисең, улым?..

С а б и р. Шаулама, әнкәй, аның сере бар.

Ф ә р х ә н ә. Нинди сер?

С а б и р. Ансын соңыннан белерсең. Чыраеңны сытмый гына мин әйткәннәрне үлчәп бир.

Ф ә р х ә н ә. Ай-һай, улым.

С а б и р. Бар, бар, әйберләреңне кыстырмасын. *(Фәрхәнә китә.)* Хәмдия, Хәмдия!..

Х ә м д и я керә.

Х ә м д и я. Нәрсә, абый?

С а б и р. Мәүләви абзыйга чыгып әйт, җылымса суга бераз солы оны болгатып, кара айгырга эчерсен.

Х ә м д и я. Ярый, абый.

С а б и р. Хәмдия, мин сиңа ярминкәдән бер бүләк алып кайткан идем, яратырсың микән?

Х ә м д и я. Миңа бүләк?..

С а б и р. Әйе, бүләк... *(Чалбар кесәсеннән яулык чыгарып бирә.)* Әйбәтме?

Х ә м д и я. Рәхмәт, абый.

С а б и р. Кичкә урыныңны киңрәк җәярсең, төнлә белән чыгып ятармын.

Х ә м д и я. Абый, бу арада минем, әллә нишләп, күңелем болгана.

С а б и р. Күңелең болгана?..

Х ә м д и я. Гөлҗамаләттәй көмәнең юк микән, ди.

С а б и р. Көмәнең юк микән, ди? Кит, кит, минем сине белгәнем дә, күргәнем дә юк, бар, эшеңдә бул!..

Хәмдия нәүмиз булып китә, ишек янында Т и м а й белән очраша.

Т и м а й. Нихәл, кызым?

Х ә м д и я. Әйбәт әле, әти... *(Китә башлый.)*

Т и м а й. Тукта, кызым, сиңа ни булды?

С а б и р. Хәмдия, мин сиңа нәрсә кушкан идем!..

Хәмдия китә.

Т и м а й. Ни булган ул балага?

С а б и р. Бозыла башлаган, Тимай абзый, бозыла башлаган. Төнлә белән мунча алдына егетләр чакыра икән, әле менә шул турыда үгетләп тора идем.

Т и м а й. Ах, ходай орган бала! Мин ул каһәрнең... *(Китә башлый.)*

С а б и р. Тукта, Тимай абзый, алай ярсыма, башта яхшылап белергә кирәк. Бәлкем, кеше сүзе генәдер. Мин аны сыныйм, тикшерим, дөрес булса, сиңа әйтермен. Ә хәзергә бер сүз дә эндәшмә.

Т и м а й. Ярый, Сабирҗан, ярый, зинһар, карый күр инде.

С а б и р. Я, Тимай абзый, ни эшләр бетереп йөрисең?

Т и м а й. Безнең эшләр билгеле инде, Сабирҗан, санга тулсын өчен яратылган баш булгач, җан көеге булып йөрисең шунда; авызың ишигә, өстең киемгә туймый... Менә озакламый салкын кыш җитә. Карчык белән икебезгә алмаш-тилмәш кия торган бишмәт кисәгебез бар иде, хәерчегә җил каршы дигәндәй, юып элгән җирдән аны да күрше Гайфулла бозавы чәйнәп эштән чыгарган. Озын сүзнең кыскасы, бишмәт тышлыгы бирмәссеңме дип килгән идем, яз көне пожар каравыллау акчасын җыйгач та китереп түләрмен, алай булмый икән, иманама тигән болынымны алырсың.

С а б и р. Кирәкми, Тимай абзый, акчаң да кирәкми, болының да үзеңдә калсын. Ни әйтсәң дә, син бит безнең үз кеше.

Андый гына ярдәмне болай да итәрбез. *(Чыгып китә дә иске бишмәт тотып керә.)* Менә сиңа иске бишмәтем, хәзер үк өстеңә киеп җибәр.

Т и м а й. Тукта әле, Сабирҗан, элек хакын сөйләшик.

С а б и р. Сөйләшәсе-нитәсе юк, мин аны сиңа бушлай бирәм. Дога кылып киярсең.

Т и м а й. Рәхмәт, улым Сабирҗан. Бик зур рәхмәт. Сафура карчыкның күзен дүрт итим әле.

С а б и р. Тукта, Тимай абзый, бераз ярминкә күчтәнәче алып китәрсең.

Т и м а й. Кирәкмәс, Сабирҗан, болай да бик зурладың инде.

С а б и р. Мә, кара җимеш белән әлвән кагы, Сафура әби белән чәйгә салып эчәрсез. *(Кесәсенә ирексезләп сала.)*

Т и м а й. Рәхмәт, Сабирҗан, ярый, сау бул. Кара әле, Сабирҗан, син теге баланы, зинһар, караштыра күр инде.

С а б и р. Ул турыда кайгырма, Тимай абзый, мин барында берсенең дә кулы салынмас.

Тимай китә. Ф ә р х ә н ә кибеттән керә.

Ф ә р х ә н ә. Улым, Сабирҗан, Солтан хаҗи малае Мочтак килгән.

С а б и р. Минем янга, монда җибәр.

Фәрхәнә китә. Зур төен күтәреп М о ч т а к керә.

С а б и р. Әйдә, Мочтак дус, рәхим ит. Ни эшләр бетереп йөрисең?

М о ч т а к. Хәлләр шәптән түгел, малай, казалы булдым, атым үлде.

С а б и р. Атың үлде? Нишләп?

М о ч т а к. Мин дә «Пәнҗәр» ярминкәсенә барган идем бит. Кайтканда эчкән баштан атны куганнан-куып яндырып үтердем.

С а б и р. Кызганыч... Атың бик яхшы иде, әрәм булган икән.

М о ч т а к. Әйе, ат шәп иде, харап иттем бичараны. Менә шул ат алу теләге белән әткәйдән калган кием-салымнарны, өй җиһазларымны сиңа сатарга китергән идем. *(Төенен чишеп күрсәтә.)*

С а б и р. Күпме сорыйсың?

М о ч т а к. Бөтенесенә, уптым илаһи, йөз илле сум акча, дим.

С а б и р. Уһу!.. Кыйбат икән.

М о ч т а к. Әйберләре затлы бит. Кара, алтышар аршинлы ике иран паласы, дүрт данә плюш ашъяулык, ике чапан, чалмасы белән хаҗилар җөббәсе, әткәй, мәрхүм, хаҗга барганда,

Мәккәи шәрифтән алып кайткан иде. Шуның өстенә тагы хатынның артыннан килгән өшәнчекләре...

Сабир. Шулай да, Мочтак дус, кыйбат, кыйбат.

Мочтак. Синеңчә күпме тора соң?

Сабир. Минемчә, менә нәрсә, Мочтак дус: син боларны сатып, Хаҗи абзый төсен әрәм итмә. Хәзергә син аларны бездә калдыр.

Мочтак. Ничек, ягъни закладка?

Сабир. Әйе, закладка. Ат алырга сиңа вакытлыча бер утыз сум акча биреп торырмын. Көз көне рәтләнгәч, түләп алырсың.

Мочтак. Түли алмасам?

Сабир. Анда күз күрер тагы, без бит чит кешеләр түгел. Бергә уйнап үстек, бергә мәдрәсәдә укыдык. Әткәй мәрхүм белән Хаҗи абзый бер кашыктан ашап торганнар бит. Курыкма, бер-беребезне җәберләмәбез.

Мочтак. Чынлап та, бу киңәшең өчен рәхмәт, Сабир дус. Хатынның да саттырасы килми, елап калган иде. Ләкин, малай, бик аз бирәсең, утыз сумга нинди генә ат алып булыр икән?

Сабир. Кайгырма, менә дигәнен алырбыз. Сиңа бит эшкә түгел, анда-монда, җиңелчәгә йөрергә өч-дүрт яшьлек хайван табарбыз.

Мочтак. Шулай да син кырык сум ит инде.

Сабир. Артык бирә алмыйм, Мочтак дус. Әле монысын да хәлеңә кереп, яшьлек дусым, Хаҗи абзый хакы өчен генә ярдәм итүем.

Мочтак. Ярый, хәерле булсын. Кая, акчаңны бир.

Сабир. Менә мә, рәхим ит.

Мочтак. Ярый, малай, рәхмәт. Сау бул.

Сабир. Исән бул, киләсе базарда мине күрергә тырыш, атны үзем алып бирермен.

Мочтак. Ярый, ярый, әбәзәтилнә күрермен.

Мочтак китә. Фәрханә керә.

Фәрханә. Алдыңмы, улым?

Сабир. Әйе, әни, алдым.

Фәрханә. Күпмегә?

Сабир. Утыз сум.

Фәрханә. Утыз сум, нигә бик арзан?

Сабир. Закладка салды.

Фәрханә. Закладка? Ялгышкансың, улым, ул кадәр зур суманы бәйләп куюың бер дә яраган эш түгел.

Сабир. Әллә син аны түләп алыр дип уйлыйсыңмы? Ул бит аны бер атнага да җиткермәс, барысын эчеп бетерер. Хатыны да пар килгән, бертуктамый кәнфит суыра.

Ф ә р х ә н ә. Сөйләмә инде. Ярканат теләге белән төн йөрми, ата малы белән бала көн күрми, диләр бит. Бик дөрес шул. Атасыннан күпме байлык, өелгән дәүләт калды, һәммәсен дә очлап киләләр.

Артта кыңгырау тавышы.

Ф ә р х ә н ә. Тагын кемдер килеп туктады. Шулай инде, син өйдә торсаң, ишек-капка ябылмый.

С а б и р. А!.. Бу, әнкәй, көткән кешем, Николай Федорыч, господин урядник. *(Чыгып китә.)*

Ф ә р х ә н ә. Хәмдия, Хәмдия!

Х ә м д и я керә.

Ф ә р х ә н ә. Самовар куй, казан асып җибәр, кунак бар.

Д е р ю г и н, С а б и р, М а к а р керәләр.

С а б и р. Әйдә, Николай Федорыч, әйдә, рәхим ит.

Д е р ю г и н. Исәнмесез, Фәрхәнә Давыдовна.

Ф ә р х ә н ә. Шөкер әле, Николай Федорыч...

Д е р ю г и н. Макар, атларны туар, кунарбыз.

М а к а р. Тыңлыйм, господин урядник. *(Китә.)*

Кибеттә кыңгырау шалтырый.

С а б и р. Әнкәй, кибеткә килделәр.

Фәрхәнә китә.

Д е р ю г и н. Ну, Сабир Хасанович, барышлар булдымы?..

С а б и р. Аллага шөкер, Николай Федорыч, көткәненнән артыгы белән. Ун олау тире белән барган идем, һәммәсен дә яхшы хакка җибәрдем.

Д е р ю г и н. Яхшы, яхшы, молодец.

С а б и р. Эшләр яхшы иде, Николай Федорыч, тик менә мин югында авылда булган хәлләр генә...

Д е р ю г и н. То есть, нинди хәлләр?

С а б и р. Тимерче Орлов алачыкта җыелган кешеләргә руханилар турындагы әкиятләрдән башлап социал-демократларның җир программалары турында сөйләгән.

Д е р ю г и н. Аграрный программалар турында?

С а б и р. Әйе, әйе, аграр программалары турында, шулай ук Думага сайлап җибәргән депутатларыбызны да халыкка яманлаган.

Д е р ю г и н. Так, так, дальше?

С а б и р. Ул хәзер үзенә иярченнәр дә табып алган. Шәймәрдәнев дигән егет Столыпин җәнапларының җир төзү законына каршы өндәп, алпавытларның җир-суларын үзебезгә алырга кирәк, дип халыкка сөйләгән.

Д е р ю г и н. Кайсы Шагимарданов ул?

С а б и р. Орловның помощнигы булып алачыкта эшләүче Гаяз Шәймәрдәнев. Шуның өстенә тимерче Орлов үз квартирасына яшьләрне җыеп урысча укыта башлаган.

Д е р ю г и н. Ах, подлец, ах, мерзавец!.. Ә староста ни карый?

С а б и р. Аңар нәрсә? Староста булып баеп алды да, минем белән ярышып сату итә. Атналар буе кунакта йөри. Кичә бер җирдән кайткан иде, бүген тагы күрше авылдагы кызына киткән.

Д е р ю г и н. Ах, сволочь!.. Сабир Хасанович, хәзер үк бер кеше җибәреп, тимерче Орлов белән Шагимардановны чакыртыгыз.

С а б и р. Хәзер була ул, Николай Федорыч. Хәмдия, Хәмдия!..

Х ә м д и я керә.

Х ә м д и я. Нәрсә?..

С а б и р. Мәүләви абзыйга чыгып әйт, алачыкка барып тимерче Орлов белән Шәймәрдән малаен чакырып китерсен. Господин үрәдник көтә, диген.

Х ә м д и я. Ярый... *(Китә.)*

С а б и р. Николай Федорыч, мин сезгә элек-электән үк безнең авылны карамыйсыз, дип әйтеп килә идем.

Д е р ю г и н. Җитешә алмыйбыз, Сабир Хасанович, җитешә алмыйбыз. Бер җирдәгесен басарга өлгермисең, икенчесе дөрләп кабына. Узган атнаны Асан чиркәвен талаганнар иде, кичә Муратовларның магазиннарын басканнар.

С а б и р. Муратовларның?..

Д е р ю г и н. Да, Муратовларның, нинди бай магазинның шырпысын да калдырмаганнар.

С а б и р. Дөньялар болай булса, юл йөрергә дә куркыныч... Әле күптән түгел генә бер башкисәре килеп миңа да янап китте.

Д е р ю г и н. Сиңа янап китте?! Ни өчен?..

С а б и р. Ике сум акча сорый, бирмәгән идем, бише белән алырбыз, ди.

Д е р ю г и н. Кем икәнен танымадыңмы?

С а б и р. Үзебезнең авылныкы, Рамай Ахметшин дигән егет. Менә шуның кебекләрне бераз гына авызлыкларга иде, Николай Федорыч.

Д е р ю г и н. Тыныч бул, Сабир Хасанович, мин ул сукин сынны иртәгә үк правлениегә чакыртып җанын алырмын.

С а б и р. Николай Федорыч, безгә Гобәй старостаны алыштырырга кирәк. Авылда шушындый куркыныч хәлләрнең булуы барысы да аның карамавыннан килә бит.

Д е р ю г и н. Да, да, алыштырырга иде, ләкин кемне куярбыз?..

С а б и р. Әгәр сезгә ошаса, минем билгеләгән бер кешем бар.

Д е р ю г и н. Кем ул?

С а б и р. Дәүли солдат.

Д е р ю г и н. Кайсы Давли, яргыччы Шайдуллинмы?

С а б и р. Юк, ул түгел. Моны Әтүтән Дәүли дип йөртәләр. Үзе простой мужик булса да, дәрәҗәне ярата торган кеше. Солдатта да булган, тотарга да шуны куярга кирәк.

Д е р ю г и н. Үзен күреп сөйләшмичә бер сүз дә әйтә алмыйм.

Х ә м д и я керә.

Х ә м д и я. Сабирҗан абый, тимерчеләр икесе дә килделәр.

Д е р ю г и н. Әһә, килделәрме?.. Орловка әйтегез, керсен.

Хәмдия китә.

Д е р ю г и н. Сабир Хасанович, безне икебезне генә калдырыгыз...

С а б и р. Яхшы, Дәүли солдатны чакыртыйммы?

Д е р ю г и н. Ярый, чакыртыгыз.

Сабир китә. О р л о в керә.

Д е р ю г и н. Господин Орлов, рәхим итегез, утырыгыз...

О р л о в. Ярый, басып та торырбыз.

Д е р ю г и н. Ну, господин Орлов, сәламәтлегегез ничек?

О р л о в. Зарарсыз.

Д е р ю г и н. Туган илегезне, дус-ишләрегезне сагынмыйсызмы?

О р л о в. Юк.

Д е р ю г и н. Да... Караңгы татар авылында гомер үткәрүе күңелсез түгелме?

О р л о в. Киресенчә.

Д е р ю г и н. Материальный яктан аптырамыйсызмы?

О р л о в. Юк...

Д е р ю г и н. Сез ни өчендер, кыйналган кеше төсле, салкын гына сөйләшәсез, авырыйсыз, ахры.

О р л о в. Ике көннән бирле тегермән буасына шпильләр ясыйбыз. Көне буе авыр чүкеч белән эшләгәнгә арылгандыр.

Д е р ю г и н. Семьягыздан хәбәр аласызмы?

О р л о в. Господин урядник, төп мәсьәләгә күчик әле.

Д е р ю г и н. То есть, ничек төп мәсьәләгә?..

О р л о в. Сез мине күрәсегез килгәнлектән, шулай ук хәлемне белер өчен чакыртмавыгызга ышанам. Шулай булгач, нәрсә кирәклеген боргаланмый-сыргаланмый гына әйтегез.

Д е р ю г и н. Ялгышасыз, господин Орлов. Миңа хөкүмәт тарафыннан сезнең өстегездән политик надзорлык итү вазифасы белән бергә, сезнең личный тормышыгызны, көнкүрешегезне тикшереп торырга да тапшырылган. Хәзерге минутта сездән миңа берни дә кирәкми.

О р л о в. Алай булгач, миңа китәргә мөмкин?

Д е р ю г и н. Сөйләшеп утырырга теләмисез икән, әлбәттә, мөмкин. *(Орлов ишеккә таба китә башлый.)* Бер генә минутка!.. Әйтәсе сүзем калган икән.

О р л о в. Ну вот, күптән шулай диләр аны.

Д е р ю г и н. Хәтерегездәме, моннан ике ел элек Москвада кораллы восстаниегә катнашуыгыз өчен безнең волостька сөргенгә җибәрелгән идегез.

О р л о в. Әйе, шулай иде, аны нигә кабатларга?

Д е р ю г и н. Зарар юк, искә төшереп үтүнең зыяны булмас. Сез шул чакта крестьяннар белән аралашмаска, общественный урыннарда политик темаларга бер сүз дә сөйләшмәскә дип кулыгыздан подписка биргән идегез.

О р л о в. Әйе, биргән идем.

Д е р ю г и н. Шулай булуга карамастан, халык арасында агитация таратып ятасыз икән.

О р л о в. Нинди агитация?

Д е р ю г и н. Алачыкта социал-демократ большевикларның аграрный программалары, Дәүләт думасы турында сөйләгәнсез.

О р л о в. Юк, господин урядник, бу турыда минем берни дә сөйләгәнем юк.

Д е р ю г и н. Конечно, юктыр. Мин үзем дә аңа ышанмадым, господин Орлов андый глупостьны сөйләмәс, дидем. Ләкин булган жалобаларны тикшермичә мөмкин түгел. Үзегез беләсез, каһәр төшкән служба...

О р л о в. Әйе, анысы дөрес, каһәрле служба...

Д е р ю г и н. Гафу итегез, тагы бер кечкенә соравым бар икән, мөмкинме?

О р л о в. Рәхим итегез.

Д е р ю г и н. Берничә егетне үз квартирагызга җыйнап русча укытасыз дип ишеттем, анысы да ялганмы?

О р л о в. Юк, монысы дөрес, укытам.

Д е р ю г и н. Напрасно, господин Орлов, напрасно. Башта сезгә укыту ведомстволарына обращаться итеп үзегезгә укыту правосы сорарга иде.

О р л о в. Мин бит укытучы түгел, яшьләрне сораулары буенча аз-маз хәреф танытырга, язарга гына өйрәтәм.

Д е р ю г и н. Анысы бик әйбәт, ләкин укыту ведомстволарын санга санамау булып чыга бит. Минем урынымда башка бер кеше булса, әллә нинди политик выводлар чыгарып, жандарм управлениесенә язар иде. Үзегез бик яхшы беләсез, мин андый кеше түгел.

О р л о в. Әгәр дә берәүнең белгән нәрсәсен белмәгәннәргә өйрәтүе гаеп санала икән, ул вакытта сез дә языгыз. Языгыз, яз...

Д е р ю г и н. Юк, мин андый начарлыкны эшли алмыйм, чөнки, бердән, мин рус, икенчедән, христиан. Әллә нинди гололобый Мамай нәселе өчен үз русымны, үз христианымны бервакытта да батырмам... Нигә көләсез?

О р л о в. Бер әкият исемә төште.

Д е р ю г и н. Нинди әкият?

О р л о в. Бүре белән сарык әкияте. Сөйлимме?

Д е р ю г и н. Рәхмәт. Мин аларны үзем дә бик яхшы беләм...

О р л о в. Белсәгез мондый приемнар белән маташмагыз, мин аларны бик күп ишеткән, ни булса да башка берәр нәрсә уйлап табыгыз.

Д е р ю г и н. Ярый!.. Яхшылыкның кадерен белмәсәң, мин сиңа башка приемнар да табармын... Мин синең ише негодяйларны бик күп акылга утырткан.

О р л о в. Менә монысы миңа ошый: үз кыяфәтегезгә кайттыгыз. Юкса сарык тиресе ябынган бүре төсле кыланасыз.

Д е р ю г и н. Молчать!.. Килегез, утырыгыз, кулыгыздан подписка бирегез...

О р л о в. Нинди подписка? Бер кат алдыгыз бит.

Д е р ю г и н. Тагын бирерсең... Крестьяннар белән аралашмаска, политический темаларга сөйләмәскә, үз квартирагызда яшьләр укытуны бу көннән туктатырга сүз бирәм, дип языгыз.

Орлов язарга утыра.

Орлов. Яздым, башка сүзегез юкмы?..
Дерюгин. Барыгыз!..

Орлов китә. Дерюгин арлы-бирле йөри. Гаяз керә.

Дерюгин. Син нәрсә сөйләнеп йөрисең, чучка колак?
Гаяз. Мин, господин урядник...
Дерюгин *(бүлдереп)*. Молчать!.. Гололобый башың белән алпавыт җирләренә нәфесең суза башладың?!
Гаяз. Кем әйтә?
Дерюгин. Каршы сөйләмә! Тула өмәләрендә, базарларда баш министр Столыпин җәнапларының җир реформасына каршы өндисең...
Гаяз. Тукта әле, господин...
Дерюгин. Тик тор, Мамай калдыгы!.. Его величество государь императорның законнарына риза булмыйча, Тимерлан дәүләте төзергә уйлыйсың?
Гаяз. Нинди Тимерлан, мин аны ишеткәнем дә юк.
Дерюгин. Җитәр дим, сволочь!..
Гаяз. Господин...
Дерюгин. Тукта, дим!.. *(Йодрыгы белән Гаязның борын астына тери.)*
Гаяз. Сузма кулыңны... *(Кулын читкә этеп җибәрә.)*
Дерюгин. Вот что... син, мерзавец, миңа кул тидерәсең?!.
Гаяз. Әллә син мине уң яңагына сукканда сул ягын куеп торучылардан дип уйладыңмы? Юк!.. Мин андыйлардан түгел. Юк-барга кулың белән уйнасаң, тешләреңне учлап китәрсең.
Дерюгин. Ах, гадина... *(Камчы белән кизәнә.)*
Гаяз. Килеп кенә кара... *(Урындык күтәрә.)*

Сабир керә.

Сабир. Чү, Гаяз. *(Тота.)* Алай кызу канлы булырга ярамый.
Дерюгин. Кил, кулыңны куй, берсекөнгә допроска килерсең.

Гаяз килеп кул куя.

Дерюгин. Кара аны, малайка!.. Гомерең буе төрмәдә черисең килмәсә, Орлов коткыларына ияреп йөрисе булма. Бар кит!..

Гаяз китә.

Сабир. Мин уңайсызладым бугай.
Дерюгин. Ничего, допроска килсен әле, мин аның җиде бабасын танытырмын.

С а б и р. Я, Николай Федорыч, рәхим итегез. *(Өстәл янына урын күрсәтә.)*

Д е р ю г и н. Рәхмәт.

С а б и р *(аракы тәкъдим итеп)*. Тотыгыз әле.

Д е р ю г и н. Яхшы. *(Эчәләр.)*

С а б и р. Әйе, халык бозылды, Николай Федорыч, ничек усалландылар.

Д е р ю г и н. Да, Сабир Хасанович... болар бар да социал-демократ чумасы, Орлов агитациясе... Ул гад белән нишләргә инде...

С а б и р. Тотарга да башка авылга сөрергә...

Д е р ю г и н. Ул язвадан алай гына котыла алмыйбыз. Безгә аңардан бөтенләйгә котылу юлын табарга иде.

С а б и р. Ничек бөтенләйгә?

Д е р ю г и н. Моннан позорный рәвештә куарлык нинди дә булса берәр җинаятькә бәйләргә иде дим, аңлыйсыңмы?..

С а б и р. Аңлыйм, Николай Федорыч, бик яхшы аңлыйм... Әйдә тотыгыз. *(Эчәләр.)* Анысы да монысы, Николай Федорыч, безнең тирәдә акча ясаучылар күбәеп китте бит.

Д е р ю г и н. Да, ничек тә эзләренә төшә алмыйбыз. Узган атнада унбиш бөтен белән берсен тоткан идек, ләкин өч көн буе кыйнап, ач тотып карасак та, әйттерә алмадык.

С а б и р. Ул акча ясаучылар шушы безнең авыл шайкасы түгел микән?

Д е р ю г и н. Ничек сезнең авыл шайкасы?

С а б и р. Тимерче Орлов белән Шәймәрдәневләр, дим.

Д е р ю г и н. Так, так, так... Бик возможно... Искә төшерүең өчен рәхмәт. От души рәхмәт.

С а б и р. Әйдәгез, эчик әле. *(Эчәләр.)*

Д ә ү л и керә.

Д ә ү л и. Нихәл, Сабирҗан?

С а б и р. Әйдә, Дәүли абзый, түрдән уз.

Д ә ү л и. Безгә монда да ярар.

С а б и р. Әйдә, әйдә, чәйгә утыр.

Д ә ү л и. Рәхмәт, энем, яңа гына торып килдем.

С а б и р. Әйдә, әйдә, эчәрбез әле.

Д е р ю г и н. Вот что, Тимиршин.

Д ә ү л и. Уф алла...

С а б и р. Нигә уфылдыйсың?

Д ә ү л и. Өегез бик эссе икән.

Д е р ю г и н. Син беләсеңме, без сине ни өчен чакырдык?

Д ә ү л и. Белә алмыйм, господин урядник.

Д е р ю г и н. Без сине староста итеп куймакчы булабыз.

Д ә ү л и. Мине староста итеп?..

Д е р ю г и н. Да, староста...

Д ә ү л и. Мин староста?

С а б и р. Әйе, Дәүли абзый, син староста...

Д ә ү л и. Шаяртасыз, Сабирҗан, шаяртасыз.

С а б и р. Шаяртмыйбыз, Дәүли абзый.

Д ә ү л и. Куегыз әле, мин нинди староста булыйм ди. Минем бит грамотам юк. Кул да куя белмим.

Д е р ю г и н. Староста булырга грамота кирәкми. Каракларны, мошенникларны, патша законына тел тидерүчеләрне вакытында хәбәр итеп торсаң, безгә шул җитә.

Д ә ү л и. Аларны гына эшләп булыр иде булуын, солдатта дүрт ел офицерлар клубында да хезмәт иттем. Бөтен начальство ярата иде.

С а б и р. Шулай булгач...

Д е р ю г и н. Ризамы?

Д ә ү л и. Мин риза булыр идем дә, авыл халкы ни әйтер бит?

Д е р ю г и н. Ул ягын син безгә калдыр. Иртәгә үк җыен җыйдырабыз да сайлатабыз.

Д ә ү л и. Ярый алайса, риза...

Д е р ю г и н. Вот молодец, күптән шулай кирәк иде.

С а б и р. Мә, Дәүли абзый, берне салып җибәр әле.

Д ә ү л и. Ярый, сау булыгыз... *(Эчә.)*

Д е р ю г и н. Бар, Тимиршин, хәзергә башка сүз юк.

Д ә ү л и. Прущай, господин үрәдник...

С а б и р. Дәүли абзый, менә монысы юл аягы булыр.

Д ә ү л и. Син бигрәк инде, Сабирҗан...

С а б и р. Әйдә, әйдә, күп сөйләнмә, тот.

Дәүли эчә.

Д ә ү л и. Рәхмәт, хушыгыз!.. *(Китә.)*

Д е р ю г и н. Безнең өчен яхшы староста булырга охшый.

С а б и р. Әйдә, Николай Федорыч, яңа староста саулыгына күтәрик...

Стаканнарын чәкештереп эчәргә дигәндә түр тәрәзәгә күсәк белән сугалар. Пыялалар чәчелеп, рамалары эчкә коела. Дерюгин белән Сабир сикереп торалар.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Дәүли староста өе. Пәрдә ачылганда каз өмәсенә килгән кызлар «Һаваларда йолдыз» көенә җырлап, кием алыштыралар. Бизәнәләр.

К ы з. Бадиян чәчтем, дуслар, ай, уңмады,
Буразнасы аның тулмады.

Х о р. Һаваларда йолдыз,
Суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама!
Калдырмам ялгыз.
К ы з. Һичбер кемгә, дуслар, үпкәләмим,
Үз бәхетем минем булмады.
Х о р. Һаваларда йолдыз,
Суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама!
Калдырмам ялгыз.

Д ә ү л и керә.

Д ә ү л и. Әниең кайда?
М а һ и. Мунчада терсәк пешекли.
Д ә ү л и. Барыгыз, бар. Эшегездә булыгыз.
М а һ и. Әйдәгез, кызлар.

Кызлар китә. Дәүли өсләрен сала. Т и м а й керә.

Т и м а й. Ник чакырдың, Дәүләтша?

Д ә ү л и. Десятникләргә йөреп чыгарсың, кичкә халыкны җыенга кусыннар.

Т и м а й. Җыенга? Нәрсә бар тагы?

Д ә ү л и. Җир турында яңа закон чыккан. Авылга старшина белән сельскийлар килә.

Т и м а й. Шулаймыни? Дәүләтша, минем сиңа бер сүзем бар иде. Үзең беләсең, кызым Хәмдия Ишбулдиннарда хезмәтче булып тора иде. Кичә балакайны куып чыгарганнар.

Д ә ү л и. Куып чыгарганнар, ни өчен?

Т и м а й. Аларга кеше ярыймыни. Кайтканнан бирле елый да елый, башын да күтәрми. Үгетләп тә, сораштырып та карадык. Ни өчен елаганын әйтми. Анасы карчык, берәрсеннән алданмадымы икән, ди. Бер араны, безгә кереп, сораштыра алмассыңмы, ни өчен елый икән ул бала?

Д ә ү л и. Башка эшем бетте, кызлар артыннан гына йөрисем калды ди.

Т и м а й. Вакытың булмаса, көчләмим, тик закон белүчебез, зур кешебез дип соравым иде. Авылга бәла була күрмәсен дим; асылам, бәкегә ташланам, дип күршеләргә сөйләгән.

Д ә ү л и. Бәкегә ташланам дигән?.. Ярый, кичкә барып чыгармын.

Т и м а й. Рәхмәт, энем Дәүләтша. *(Китә.)*

Г а р и ф ә. Кайттыңмыни, әтисе?

Д ә ү л и. Иләк авыз, өйалларыңны себерергә кулың черемәгәндер бит. Басып менәргә җирәнерсең.

Г а р и ф ә. Күрәсең бит, бушамыйм.

Д ә ү л и. Бушамыйм, бушамыйм, земский нәчәлник булдыңмы әллә?.. Йөрисең шунда эч пошырып, өйнең ямен җибәреп. Авылга нәчәльство килә, өеңә керми төкереп китәрләр.

Г а р и ф ә. Ярый инде, баш-күз алгач себербез әле.

Д ә ү л и. Идән себерергә баш кирәкми аңар, кул кирәк, кул!

Г а р и ф ә. Ай алла, нигә бу кадәр холыксызланасың?

Д ә ү л и. Печать кая?!. *(Әтәчләнеп кычкыра.)*

Г а р и ф ә. Тәрәзә кашагасында.

Д ә ү л и. Уҗым бозавы, шунда куйма дип ничә тапкыр әйтелгән сиңа. Волостька онытып киткәнмен, эзли-эзли мием череде. *(Сәкегә менә башлый. Кызлар калдырган ата каз куыгына басып шартлата.)* Бу ни бу?..

Г а р и ф ә. Кызлар шаярып ата каз куыгы калдырганнар.

Д ә ү л и. Ата каз куыгы?..

Г а р и ф ә. Әйе, менә ул...

Д ә ү л и. Уф, котым алынды. Быелдан болай шул икмәк убырларыңны асрыйсы булма, муеннарыннан тотып бәрермен. Яндыр лампаны!.. Җәй булса, аякка уралып теңкәне корыталар, көз булса, аларны симерт, өмә яса, кызлар җыеп тыгындыр.

Г а р и ф ә. Аның урынына рәхәтен дә үзебез күрәбез, урак өстендә каклаган ит ашыйбыз.

Д ә ү л и. Заманалар болай булса, ашаганнарыңны кире чыгарырлар.

Г а р и ф ә. Әллә тагы берәр шомлы хәбәр бармы?

Д ә ү л и. Бар шул.

Г а р и ф ә. Нәрсә, сугыш-фәлән юктыр бит?

Д ә ү л и. Күрше волостьта крестьяннар көчләп алпавыт урманын кисә башлаганнар. Гергери Гергрич дигән управляющие каршы торып маташкан икән, үзен тотып үтергәннәр.

Г а р и ф ә. Ярый әле, аллага шөкер, андый бозыклыклар безнең мөселманнар арасында юк.

Д ә ү л и. Син нәрсә беләсең, башмак борын. Әнә Чаллыбаш Сәгыйть хәзрәткә исемсез хат язып, казна урманы авызына йөз сум акча китерергә кушканнар. Китермәсәң, үтерәбез, дигәннәр.

Г а р и ф ә. Имансызлар икән. Хәзрәт чаклы хәзрәтне үтерергә диләрме?

Д ә ү л и. Хәзер бит халыкта рәт бетте. Алладан җәяүләп качтылар. *(Кәгазьгә печать басып.)* Менә шул ат распискасын ишек төбендә көтеп торучы Күркә Нәфигының хатынына чыгарып бир. Староста печать басты, хәзер эшкә ярый инде, дип әйтте, диген.

Г а р и ф ә. Әтисе, кызлар алдына ару әйберләр аласы иде. Берьюлы шунда алынган солдатларны да дәшер идек.

Д ә ү л и. Юк, юк, андый нәрсәләргә миннән акча сорыйсы булмагыз.

Г а р и ф ә. Кеше алдына куярлык бернәрсәбез дә юк бит.

Д ә ү л и. Шишара пешерерсең.

Г а р и ф ә. Оялмыйчамы?

Д ә ү л и. Төртелмәс әле.

Г а р и ф ә. Ярый, ир кеше, үзең беләсең, тик шул кадәресе бар, кешене чакыргач, сыйламыйча ярамый. Бәйрәм ашы каракаршы дигәндәй, үзебезнең дә кызыбыз йөри бит. Аннан нәчәльстволар да килә дисең.

Д ә ү л и. Нәчәльство дисеңме?

Г а р и ф ә. Алар алдында староста башың белән оятка кала күрмә диюем иде.

Д ә ү л и. Алай дисәң, мә, бер кадак клиндер, чирек кадак лампачи алырсың. Кара аны, кызлардан тыгындырып бетермә.

Гарифә китә. Р а м а й керә.

Р а м а й. Исәнме, Дәүли абзый!

Д ә ү л и. Әйбәт әле, энем.

Р а м а й. Дәүли абзый, паспорт алырга Ибәтулла писердән язу алган идем, тамгаңны куеп, печәтеңне басып бир әле.

Д ә ү л и. Кая, читкә китәсеңме әллә?

Р а м а й. Камашау заводына эшкә бармакчы идем.

Д ә ү л и. Юкка йөрисең, энем, барыбер акча төшерә алмассың.

Р а м а й. Монда да бит бер эш юк. Урамда трай тибеп йөргәнче, ичмасам, тамак узмасмы, дим. Кая, басып кына бир инде.

Д ә ү л и. Басуын басар идем дә, энем, тик сиңа волостьта паспорт бирерләр микән?

Р а м а й. Нигә бирмәсеннәр?..

Д ә ү л и. Синең, энем, чатакларың бар икән...

Р а м а й. Нинди чатакларым?

Д ә ү л и. Ишбулды Сабирының тәрәзәсен сиңа сылтадылар бит.

Р а м а й. Ул әллә нәрсәләр сылтар иде дә, булдыра гына алмый. Мин ватканга шаһитлар бармы соң?

Д ә ү л и. Барын-югын белмим, әмма сине гамәл дәфтәренә теркәп куйдылар. Шуңа күрә сине авылдан да чыгармаска куштылар.

Р а м а й. Кемнәр?

Д ә ү л и. Үрәдник белән старшина.

Р а м а й. Мин бит, Дәүли абзый, еракка түгел, Камашауга гына барам. Кирәк булсам, чакыртып та алырсыз.

Д ә ү л и. Юк инде, энем, синең өчен җавапка калыр хәлем юк. Аннан соң, башка гөнаһларың да бар икән.

Р а м а й. Нинди гөнаһ тагы?

Д ә ү л и. Тимерче алачыгына Орлов әкиятләрен тыңларга йөрисең диләр.

Р а м а й. Әллә инде әкият тыңларга да ярамыймы?

Д ә ү л и. Ярамый торгандыр шул, яраса, закон белән тыймаслар иде.

Р а м а й. Бирмисеңмени?

Д ә ү л и. Булдыра алмыйм.

Р а м а й. Ну бу чукынган Сабирны нишләтергә инде?.. Берәр аулак җирдә туры килсә, муенын борып ташлар идем ташлавын...

Д ә ү л и. Рамазан энем, миңа ачулана күрмә, үзең беләсең, нәчәльство сүзен тыңламыйча булмый бит.

Р а м а й. Син дә инде, байлар җырын җырлап, үрәдник кубызына бии башладың.

Д ә ү л и. Минем урынымда булсаң, син дә шулай эшләр идең, үзең беләсең, мин бит казна кешесе.

Р а м а й. Әй, чукынып китсәң иде шул казнаң белән!.. *(Китә.)*

Д ә ү л и. Чая егет, чая... Берни булды исә, күкерт кебек кабынып китә.

Г ы й л ь м и керә.

Г ы й л ь м и. Дәүләтша өйдәме?

Д ә ү л и. Әйдә, әйдә, Гыйльменисаттәй. Әйдә, утыр.

Г ы й л ь м и. Утырып тормыйм, мине Сабирҗан җибәргән иде.

Д ә ү л и. Нинди йомышлар белән?

Г ы й л ь м и. Менә шушы кәгазьгә тамгасын куеп, печәтен басып җибәрсен, дигән иде.

Д ә ү л и. Бу нинди кәгазь соң?.. *(Баш-аяклы әйләндергәләп карый.)*

Г ы й л ь м и. Иманамны аңар бирдем бит, язышу кәгазебез.

Д ә ү л и. Шулаймыни?.. Нишләп алай бирәсе булдың?

Г ы й л ь м и. Аның белән нишлим, үзем чәчә алмыйм, кысыр калдырып әрәм иткәнче, әйдә, алар файдалансыннар. Алла Сабирҗанның гомерен генә бирсен инде, көн дә чакырып сыйлыйлар, кадер-хөрмәт итәләр. Кышка җитәрлек утыныма кадәр китертеп куйдырды.

Д ә ү л и. Иманаңны бирергә булсаң, язышмый да була бит, нигә соң кәгазь язышасыз?

Г ы й л ь м и. Әллә тагын. Сабирҗан язышыйк дигәч, каршы килмәдем. Законча булсын ди торгандыр.

Д ә ү л и. Әйе, законча шул, законча... *(Печать басып бирә.)* Булды бу, Әүвәле-ахыры хәерле булсын.

Г ы й л ь м и. Иншалла, шулай булыр инде. Ярый, сау булып тор. Безнең очка барсаң, чәйгә кер, миләш кагы белән сыйлармын.

Д ә ү л и. Ярый, ярый, Гыйльменисаттәй, Сабирҗанга сәлам әйт.

Гыйльми китә.

Д ә ү л и. Ай, бу Сабирны... Вак балыкларны йотып йөргән чуртан кебек, төрле яктан каптыра. Кибете дә бар, тире белән дә сату итә. Иманалар алуын да читкә калдырмый. Тимерче Орлов хутор булырга йөрүчеләрне яңа алпавытлар дип әйтә диләр иде. Дөрес булыр, ахры.

Мәктәптә укыган сабакларын кабатлап, С ә е т кайтып керә.

С ә е т. Ә-и-ө-бә-би-бө.

Д ә ү л и. Әй, син, малай актыгы, нишләп сабактан иртә кайттың?

С ә е т. Атнакич бит, иртә җибәрделәр.

Д ә ү л и. Хәереңнән калган акчаңны алып кайттыңмы?

С ә е т. Юк, әти.

Д ә ү л и. Нишләп юк?

С ә е т. Мулла абзый кайтарып бирмәде.

Д ә ү л и. Соң бит, телең чергере, мин сиңа әйтеп җибәрдем, бер тиене хәер, калганын алып кайт, дидем. Нигә сорамадың?..

С ә е т. Сораган идем дә, мулла абзый әйтә: хәер акчасын кайтарып сорамыйлар, зур гөнаһ була, ди.

Д ә ү л и. Әй, җебегән авыз, җебегән авыз... Кемгә генә охшадыгыз соң?.. Бар, калган хәер акчасын әти сорады, диген. *(Сәет китә башлый.)* Әй, тукта әле, тукта!.. Сабагыңны беләсең микән. Әгәр дә белмәсәң, сәдакага биргән бер тиенне дә сорарсың. Я, шартлатып укып җибәр әле. (*Чыбыркы алып утыра.)*

С ә е т. Бисмиллаһи... ә-и-ө...

Д ә ү л и. Ташла әле шул шайтан такмагыңны, сабагыңны укы.

С ә е т. Укыйм ич, әти!

Д ә ү л и. Укы дим шул, укы!

С ә е т. Ә-и-ө.

Д ә ү л и. Сыртыңа чыбыркы төшкәнне көтәсеңме әллә? Укы диләр бит сиңа.

С ә е т. Ә-и-ө-бә-би-бө...

Д ә ү л и. Нәрсә?.. Ә-ә-ә, бә-бә-бә, дисеңме?

С ә е т. Алай түгел, ә-и-ө-бә-би-бө, дим.

Д ә ү л и. Бу нинди кәҗә сабагы?

С ә е т. Бу, әти, яңа сабак.

Д ә ү л и. Яңа сабак?.. Сабакның искесе, яңасы буламыни, сыбызгы борын!..

С ә е т. Була икән шул, әти. Яшь мулла абзыйның хатыны Зәйтүнә апа...

Д ә ү л и. Нәрсә, папа дисеңме?..

С ә е т. Юк, әти, а-па дим.

Д ә ү л и. Анысы нинди әкәмәт тагы?

С ә е т. Түтәй дигән сүз икән. Шул, яшь мулла абзыйның Казанда укый торган хатыны Зәйтүнә апа кайткан. Бүген безгә сабак бирергә кергән иде, мин сезгә бер айда хәреф танытып, язарга өйрәтәм, ди. Барыбызга бирәр китап та өләште.

Д ә ү л и. Шул, биленә каеш буып йөрүче сары марҗамы?

С ә е т. Аның каешы юк бит, әти. Әмма биле нечкә дә инде. Аягына сары чәпчүрләр кигән дә, кәҗә кебек, шыгыр-шыгыр басып йөри.

Д ә ү л и. Ах сез, машинниклар, сабакны шулай укыйсыз икән, кая, китабыңны бир әле. Ул фетнә безгә дә килеп җитте, ахрысы. Болай булса, үзләре генә бозылып калмыйлар, безнең балаларны да бозарга керешәләр. Каферләр, кара аны, моннан соң анда аяк атлыйсы булма.

С ә е т. Алай булса бир, китапларны илтеп ташлыйым.

Д ә ү л и. Юк, китап миндә калсын. Андый-мондый патшаны сүккән җире юкмы икән. Үрәдниккә күрсәтим әле.

Ф ә р х ә н ә керә.

Ф ә р х ә н ә. Исән генә торасызмы, Дәүләтша?

Д ә ү л и. Бик яхшы әле, Фәрхәнә абыстай. Әйдүк, түрдән уз. Сәетгәрәй, бар, әниеңне чакырып кер.

Сәет китә.

Ф ә р х ә н ә. Вакытсызрак килдем бугай, каз өмәсе икән.

Д ә ү л и. Шулай иде дә, зарар юк. Я, Фәрхәнә абыстай, ни эшләр бетереп ятасыз, Сабирҗан өйдәме?

Ф ә р х ә н ә. Старшиналар киләсе булгач, беркая да китмәде. Кояшта тиреләр киптерә.

Д ә ү л и. Шулай итеп, хутор булырга риза булдыгызмыни инде?

Ф ә р х ә н ә. Яхшы әрәмәлек су буеннан яңа җир кисеп бирәләр дигәч, каршы килмәдем. Аллага тапшырып, күчәргә булдык.

Г а р и ф ә керә.

Г а р и ф ә. Кунак бар икән.

Ф ә р х ә н ә. Исәнме, Гарифә?

Г а р и ф ә. Шөкер әле, Фәрхәнә абыстай.

Ф ә р х ә н ә. Дәүләтша, мин сезгә мендәрле кунак булып килгән идем.

Г а р и ф ә. Мендәрле кунак?..

Д ә ү л и. Яучы булып, кемгә?..

Ф ә р х ә н ә. Билгеле инде, Сабирҗаныма.

Д ә ү л и. Шулаймыни?.. Әйдә, Фәрхәнә абыстай, теге якка, ак өйгә чыгыйк.

Г а р и ф ә *(салкын гына)*. Әйдә, анда сөйләшербез. *(Китәләр.)*

С ә е т керә.

С ә е т. Бу ит бүкәне нишләп йөри икән бездә? *(Ишектән тыңлый.)* Ә, түтәйне кодаларга...

М а һ и керә.

М а һ и. Сәетгәрәй, әни кайда?

С ә е т. Теге якта, Ишбулды Фәрхәнәсе белән сөйләшеп утыралар.

М а һ и. Ишбулды Фәрхәнәсе белән? Ул нишләп безгә килгән?..

С ә е т. Синең башыңны өтәргә, ахры.

М а һ и. Минем башымны, кемгә?

С ә е т. Кемгә икәне билгеле инде — Сабирына.

М а һ и. Сабирына? Юк, юк, мин үлсәм дә аңар барасым юк.

С ә е т. Әтиләр бирсә, бармый нишләрсең.

М а һ и. Сәетгәрәй, җаным, бар Гаязны чакырып кил.

С ә е т. Кайсы Гаязны?

М а һ и. Беләсең бит инде, тимерче Гаязны.

С ә е т. Барам, аяк ялы итеп нәрсә бирәсең?

М а һ и. Үз тутаңнан әйбер алыр идеңме?

С ә е т. Ник алмаска, минем аяк кәҗүнни түгел бит.

М а һ и. Ярый инде, бар, ни дә булса бирәр әйбер бирермен.
С ә е т. Юк, ни дә булса түгел, нәрсә икәнен атап әйт.
М а һ и. Урман чикләвеге, кипкән шомырт, кура җиләге, ни теләсәң шуны алырсың, тик, зинһар өчен, тизрәк кенә барып кайт.
С ә е т. Башта бир.
М а һ и. Ышанмыйсыңмы?
С ә е т. Бервакыттагы кебек алдар идең бугай.
М а һ и. Юк, җаным, бу юлы, билләһи, алдамам.
С ә е т. Икмәктер диген.
М а һ и. Икмәктер.
С ә е т. Чәчрәп китим, диген.
М а һ и. Чәчрәп китим.
С ә е т. Ярый, киттем... *(Китә дә борылып килә.)*
М а һ и. Нигә тагы борылдың?
С ә е т. Борынга томау төшкән, бер яулык та чигеп бирмисең.
М а һ и. Бар инде, бар. Бик матурлап чиккәнне бирермен.
С ә е т. Вәгъдәме?..
М а һ и. Вәгъдә.
С ә е т. Кара аны, бу юлы да алдасаң, бер йомышыңа да йөрмәм. *(Китә.)*
М а һ и. И, ходаем,ниләр генә бар икән анда... *(Ишектән тыңлый.)* Чыгалар... Шулай ук башымны ашадылар микәнни? *(Мич арасына кереп яшеренә.)*

Д ә ү л и, Ф ә р х ә н ә, Г а р и ф ә шаулашып чыгалар.

Д ә ү л и. Шулай, Фәрхәнә абыстай, нәсел-ыру белән уйлашып, иртәгә җавабын бирербез.
Г а р и ф ә. Уйлашасы-нитәсе юк. Кешене ышандырма.
Д ә ү л и. Гарифә!..
Г а р и ф ә. Шулай, Фәрхәнә абыстай, бирә алмабыз.
Д ә ү л и. Тукта дим, хатын!.. Кызга син хуҗамы, минме?..
Г а р и ф ә. Яшерен-батырын түгел, Фәрхәнә абыстай, бердәнбер кызымны өч хатын аерган кешегә бирер хәлем юк!..
Д ә ү л и. Җитәр, дим!.. Салма савытыңа биргәнне көтәсеңме әллә!
Ф ә р х ә н ә. Ярый, Дәүләтша, сау булып тор хәзергә.
Д ә ү л и. Хуш иттек, Фәрхәнә абыстай, хуш. Зинһар, гаепләп китә күрмә. Аның бүген башы өянәкле көне. Җавабын иртәгә үзем бирермен.
Г а р и ф ә. Өметләндермә!..
Д ә ү л и. Тик тор, дим мин сиңа!..

Ф ә р х ә н ә. Ярый, хуш...

Д ә ү л и. Хуш, хуш, Фәрхәнә абыстай, хуш... *(Фәрхәнә китә. Дәүли аны озатып керә.)* Син нишләдең, әйтче миңа, син нишләдең?

Г а р и ф ә. Турысын әйтәм, алма кебек баламны аңар биреп зар елатыр хәлем юк.

Д ә ү л и. Бетердең, бетердең... Урамга чыгарлыгымны калдырмадың *(Башын тотып ишекле-түрле йөгереп йөри.)* Болай булгач, старосталыгымны да алдырыр бит ул.

Г а р и ф ә. Алдырсын!.. Ике бозауга кибәк аера алмаган башың белән староста итеп куя башлагач та шикләнгән идем. Яшь балага тәти күрсәтеп кызыктырган кебек, староста калай медаленә кызыңны алмакчы булганнар бит.

Д ә ү л и. Теләсә ни булсын, Сабир кебек бай кияүне читкә җибәрмәм.

Г а р и ф ә. Төкерәм мин аның байлыгына, кешелеге булмагач!..

С ә е т керә.

С ә е т. Әти, сельский белән старшина килде, сине чакыралар.

Д ә ү л и. Мине чакыралар?

С ә е т. Ибәтулла писер, хәзер үк килеп җитсен, ди.

Д ә ү л и. Ах, ходай орган нәрсәләр, нишләп бик тизләгәннәр. *(Ашык-пошык киенеп.)* Өйне җыештыр. Самовар куй, нәчәльствоны чәйгә алып керермен. *(Китә.)*

М а һ и, мич арасыннан чыгып, Г а р и ф ә кочагына ташлана.

М а һ и. Әни...

Г а р и ф ә. Елама, балам, елама...

М а һ и. Әти Сабирга бирсә, мин нишләрмен...

Г а р и ф ә. Елама, кызым, бирдермәм. Җаным теләмәгән кеше белән үз гомерем үткәне дә җитәрлек. Башым исән чакта ул кансызга биреп елатмам.

М а һ и. Рәхмәт, әни...

Г а р и ф ә. Әйдә, балам, кызлар янына, эшләрен бетереп, безне көтеп ятмасыннар.

Китә башлыйлар. С ә е т Маһиның итәгеннән тартып туктата.

С ә е т. Түтәй...

М а һ и. Я, күрдеңме?..

С ә е т. Күрдем, хәзер киләм, диде.

М а һ и. Рәхмәт, җаным. *(Китә башлый.)*

С ә е т. Кая, бир инде.

М а һ и. Нәрсәне?..

С ә е т. Чикләвек белән яулыкны.

М а һ и. Хәзер вакытым юк, баш-күз алгач килеп сорарсың.

С ә е т. Тагын кәкре каенга терәтмәкче буласыңмы?

М а һ и. Күрәсең бит, вакытым юк.

С ә е т. Түтәй!..

М а һ и. Әй, калдыр әле.

С ә е т. Яхшылыкта бирәсеңме, юкмы?

М а һ и. Әгәр болай йөдәтсәң, миннән сиңа бернәрсә дә юк.

С ә е т. Бирмисеңмени?

М а һ и. Бирмим.

С ә е т. Ярый... Тимерче Гаязны өйгә чакырды дип әтигә барып әйтим әле.

М а һ и. Сәетгәрәй, акыллым, җан кисәгем, барма, хәзер бирермен.

С ә е т. Ә, бирерсеңме?

М а һ и. Син усал малайдан котылып буламы соң... *(Кереп китәләр.)*

Бераздан чикләвек ватып С ә е т керә, чиккән яулык белән борынын сөрткән булып, зур-зур атлап чыгып китә. М а һ и керә, тышкы ишеккә барганда, тәрәзәдән Г а я з күренә.

Г а я з. Маһи!..

М а һ и. Әйдә, өйгә кер.

Г а я з. Әтиеңнәр?

М а һ и. Әти өйдә юк. Әни мунчада.

Г а я з өйгә керә.

Г а я з. Тукта, Маһи, сиңа ни булды?

М а һ и. Син бит бернәрсә дә белмисең.

Г а я з. Ни булды соң? Сөйлә тизрәк!

М а һ и. Хәзер генә Ишбулды Фәрхәнәсе Сабирына сорап, яучы булып килгән иде.

Г а я з. Ишбулды Фәрхәнәсе?

М а һ и. Әти җавапны иртәгә бирермен дип вәгъдә куеп җибәрде.

Г а я з. Вәгъдә куеп җибәрде?.. Әниең?..

М а һ и. Ул баш-аягы белән каршы. Ләкин безнең әтине беләсең бит, тискәре кеше. Гаяз, акыллым, иртәгә үк яучы җибәреп кодала.

Г а я з. Юк шул, Маһи, алай бирмәсләр.

М а һ и. Ник бирмәсеннәр?

Г а я з. Байлык, дәрәҗә белән исергән Дәүли абзый таш пулатлы Сабир белән Тимерче Гаязны алыштырырга риза булмас.

М а һ и. Алай өметсезләнмә, риза булыр. Әни каты торса, нәсел-ыруглар да димләшсә, беркая да китә алмас.

Г а я з. Ярый, мин җибәрермен. Риза булмасалар?..

М а һ и. Тукта әле, Гаяз, нигә һаман кире якка уйлыйсың?

Г а я з. Алган эшеңне уңышлы башкарып чыгар өчен, яхшы ягына караганда, кире ягы турында күбрәк уйларга кирәк, ди безнең Захарыч.

М а һ и. Нинди кире як?

Г а я з. Ярый, мин иртәгә яучы җибәрдем, ди, әтиеңнәр, мине тыңләмичә, бирмәделәр, ди. Сине Сабирга ярәшә башлыйлар, ди, менә шунда нишләрбез, дим?

М а һ и. Белмим, чыннан да, нишләрбез соң?

Г а я з. Менә эшнең бөтен хикмәте дә шунда шул. Әгәр дә син булдыра алсаң, минем бер юлым бар.

М а һ и. Әйт тизрәк, нинди юл ул?

Г а я з. Яучы җибәреп бирмәсәләр, ябышып чыгарга ризамы?

М а һ и. Ябышып чыгарга?.. Кешеләр алдында адәм мәсхәрәсе булырга, әтиләрнең йөзенә кызыллык китерергә? Юк, мин аны эшли алмыйм.

Г а я з. Эшли алмасаң, миңа үпкәләмә, Ишбулды Сабиры үз теләгенә ирешер өчен әлләниләр дә эшли торган кеше.

М а һ и. Юк, булмас!.. Елармын, ялынырмын... Көчләп бирә башласа, йә аны, йә үземне харап итәрмен...

Г а я з. Их, Маһи... Үзләре теләмәгән кешеләр белән гомер итүчеләрне бер дә күргәнең юкмыни?.. Күз алдында бит, күршегез Гөлҗамалны кан-яшь елатып алтмыш яшьлек картка көчләп бирделәр. Шулай ук үткән елны гына унҗиде яшьлек Гыйльметдинне ата-аналары, байлыкка кызыгып, кырык биш яшьлек тол хатынга йортка керттеләр. Алар да башта синең төсле әрнеп еладылар, суга ташлану, шомырт мае эчү белән куркытып карадылар... Көннәр үтү белән гореф-гадәт колы булып байлыкка буйсындылар. Башта син дә еларсың, әкренләп тора башларсың. Балагыз булыр, аннан икенчесе туар...

М а һ и. Юк, мин алай булмам!.. Гаяз, иртәгә үк яучы җибәр.

С ә е т кереп карап тора.

Г а я з. Һаман бер балык башы.

М а һ и. Сиңа бирергә риза булмасалар, ул чагында мин синең белән әллә кайларга барырга да риза!..

Г а я з. Маһи, бу син... *(Кочагына ала.)*

С ә е т *(зурлар тавышы белән).* Ах, сез, явызлар!..

Г а я з *(Маһины кочагыннан җибәрә дә тавыш килгән якка борылып карый).* Бу синмени, шайтан баласы, котны алдың.

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Гаяз өе, бай булмаса да чиста итеп җыештырылган. Пәрдә ачылганда кайгылы хәлдә Г а я з кайтып керә.

Х ә с б и. Улым, кайда йөрдең болай бик озак?

Г а я з. Захарыч янында идем. Ул китәргә җыена.

Х ә с б и. Китәргә җыена? Кая?

Г а я з. Мәскәүгә, бүген кич юлга чыга. Әни, үзен бүген ашка чакырып алсак ничек булыр икән?

Х ә с б и. Бик әйбәт булыр иде дә, өлгерербез микән?

Г а я з. Өлгерерсең, вакыт бар әле. Аш дигәч тә, әллә нәрсәләр хәзерләп булмас, казан асарсың да чәй янына коры-сары куярсың.

Х ә с б и. Ярый, улым, чит кеше түгел, гаеп итмәс әле. Шәрифә тутәң килгән иде, Ишбулды Сабирына Маһисәрвәрне биргәннәр, ди.

Г а я з. Ишеттем...

Х ә с б и. Ул ничек булган соң? Анасы Гарифә каршы дигәннәр иде бит.

Г а я з. Ярый, әни, аш-суыңны кара инде.

Хәсби китә. Р а м а й керә.

Р а м а й. Нихәл, Гаяз?

Г а я з. Хәлләр шәптән түгел, Рамай дус. Маһисәрвәрне Сабирга ярәштеләр...

Р а м а й. Алай... Әтүтән Дәүли дисәң Әтүтән шул, байлыкка кызыгып, тәки кызын саткан икән... Йә, нишләргә уйлыйсың?

Г а я з. Кеше җибәргән идем, күреп сөйләшкән. Гаяз беркая да китми торсын, җайлы вакыт туры килү белән барып җитәрмен, дигән.

Р а м а й. Ай-һай, булыр микән? Минемчә, тотарга да урларга иде.

Г а я з. Куй, юләр, ул бит адәм баласы. Үзе риза булмаса, ничек урлыйсың аны?

Р а м а й. Һи, исең киткән икән, тора-бара риза булмый нишләсен, кеше түгел, аю да кулга ияләшә. Хәзер үк минем кара

алашамны җигеп чыгабыз да, суга барганын саклап торып, салабыз да китәбез.

Г а я з. Әгәр дә аны беркая да чыгармый каравыллап өйдә тотсалар?..

Р а м а й. Ул чагында Әтүтән Дәүлинең өенә кереп урлыйбыз.

Г а я з. Юк, Рамай, алай ярамый, бәлагә калырбыз.

Р а м а й. Курыкма, кыз урлап бирәүнең дә Себер киткәне юк әле. Бер-ике ай утырталар икән, әйдә, чорт с ним, казна икмәге ашарбыз.

Г а я з. Мин алай эшли алмыйм. Безнең Маһи белән куйган вәгъдәбез бар. Ул үзе килергә тиеш.

Йөгереп С ә е т керә.

С ә е т. Гаяз абый, түтәйне тоттылар!

Г а я з. Тоттылар?!

С ә е т. Әйберләрен зур төенгә төйнәп чыгып бара иде, каршысына әти — шалт! Кая барасың, ди, түтәй эндәшми, тагын сорый, тагын эндәшми, катып тик тора. Шуннан, төенен чишеп карады да: «Әһә... тимерче Гаязгамы?!» — дип типкәләп өйгә алып керде, ак өйгә ябып, чабата кадәр йозак белән өстеннән бикләп куйды.

Г а я з. Бикләп куйды?

С ә е т. Түтәй әйтә, ничек кенә булса да, Гаяз мине коткарсын, ди.

Р а м а й. Алай, менә сиңа малай...

Уйга калалар.

Г а я з. Нишләргә?.. Нишләргә соң, Рамай, киңәш бир.

Р а м а й. Минем киңәш бер генә — урларга кирәк. Әйдә, киттек!

Г а я з. Ишетәсең ич, бикләп куйганнар.

Р а м а й. Сәетгәрәй, тәрәзәгез алынамы?

С ә е т. Тышкысы алына да бит, эчкесе бөтенләй ачылмый.

Тынга калалар.

Г а я з. Ничек кенә коткарырга?..

С ә е т. Булды, Гаяз абый!

Г а я з. Ничек булды?

С ә е т. Безнең ак өйнең астында зур гына бәрәңге төнлеге бар, шуны төртеп төшерәм дә базга, баздан өйгә кереп түтәйне коткарам.

Г а я з. Ә түтәң ул төнлектән сыярмы соң?

С ә е т. Безнең түтәй нечкә билле бит ул, мин сыйган җирдән сыяр әле. *(Чыгып китә.)*

Т и м е р г а л и керә.

Т и м е р г а л и. Егетләр, эшләр начар бит.

Г а я з. Ничек начар?

Т и м е р г а л и. Хуторчыларга җир сорап авылга земский начальник килә.

Р а м а й. Земский начальник килә?

Т и м е р г а л и. Захарыч әйтә, хәзер үк аякка басып, халыкны кулга алырга кирәк, ди.

Г а я з. Әйдәгез, егетләр, эшкә... Үз байгураларын хуторга күчерәселәре килсә, тотсыннар да бояр, казна урманнарыннан кисеп бирсеннәр, үз басуыбыздан бер карыш җирне дә бирмибез. Тимергали, син югары очта булырсың. Сүз сыярдай кешеләрне үз тирәңә җыярсың.

Т и м е р г а л и. Ярый, мин киттем. *(Китә.)*

Г а я з. Ә син, Рамай, түбән якны йөреп чыгарсың. Мин алачыкта булырмын.

Т и м а й керә.

Т и м а й. Нихәл, улым Миргаяз?

Г а я з. Бик яхшы, бабай. Әйдә, уз.

Рамай китә. Х ә с б и керә.

Т и м а й. Саумы, Хәсбиҗамал?

Х ә с б и. Шөкер әле, Тимай абзый. Үзең нишләп йөрисең?

Т и м а й. Сөйләмә инде, Хәсбиҗамал, карт башыма төшкән кайгы-хәсрәтемне уртаклашырга кердем.

Г а я з. Нинди хәсрәт ул, бабай?

Т и м а й. Телгә алырга да чиркәнеч: Хәмдиянең көмәне бар.

Г а я з. Көмәне бар?

Х ә с б и. Кемнән?..

Т и м а й. Ишбулды ләгънәтеннән.

Х ә с б и. Имансыз икән, ярлы баласын елатмаса, үз ишләре беткәндер шул... Сорашмадыңмы, нишләп алай алданган?

Т и м а й. Иләс-миләс чагы бит. Хатынлыкка алам дигән, тасма теленә ышанган... Шул сүзне авызыннан ишетүгә тәнем калтырап, күз алларым караңгыланып китте. Ачу белән ярсыган йөрәгемә чыдаша алмыйча, ишек тоткасына бәйләп кыйнадым...

Г а я з. Елама, бабай...

Т и м а й. Бик авыр бит. Оланнар, киңәш бирегез, ул явызны нишләтим? Судка биримме, әллә земскийга әйтимме?

Г а я з. Кирәкми, бабай, карга күзен карга чукымас. Хәзер

җыен була, халык алдында Сабирның кабахәтлеге турында сөйләсәң яхшырак булыр. Әйдә, бабай. *(Китә башлыйлар.)*

Х ә с б и. Улым, тукта әле!

Г а я з. Нәрсә, әни?

Тимай китә.

Х ә с б и. Алай кеше котыртуың кирәкмәс иде. Сизеп-нитеп алсалар, алла сакласын, волостька чакыртып, тагын теңкәңә тиярләр.

Маһи керә.

М а һ и. Менә, Гаяз, мин килдем...

Г а я з. Рәхмәт, Маһи, сүзеңдә торгансың.

Х ә с б и. Әйдә, кызым, әйдә, төкле аягың белән. *(Аркасыннан сөя.)*

М а һ и. Гаяз, ат әзерләдеңме? Тизрәк башка авылга качып китәргә дә никах укытырга кирәк.

Г а я з. Беркая да качмыйбыз, Маһи. Яшь мулла белән сөйләштем, никах укырга булды. Хәзер ындыр артыннан гына керәбез дә укытып чыгабыз.

С ә е т йөгереп керә.

С ә е т. Түтәй, әти!

М а һ и. Әти?!

С ә е т. Әйе, пүнәтәйләр белән! *(Чыгып китә.)*

М а һ и. Гаяз! Харап булдым бит!..

Г а я з. Курыкма, Маһи, тынычлан.

Х ә с б и. Ходаем, әнә капкадан керделәр.

Г а я з. Бар, Маһи, чаршау эченә кереп тор, курыкма, мин сине аларга бирмәм.

Маһи бүлмәгә кереп китә. П о н я т о й л а р ияртеп, Д ә ү л и керә.

Х ә с б и *(каршы барып)*. Исәнме, Дәүләтша!

Д ә ү л и. Исән булмасам әллә син духтормы? *(Гаязга.)* Машинник, кая минем себеркем?

Г а я з. Дәүли абзый, мин Маһины күргәнем юк.

Д ә ү л и. Ялганлама, жулик!.. Кая яшердең?

Г а я з. Ышанмасаң, эзләп кара.

Х ә с б и. Ышан, Дәүләтша, валлаһи, бездә булганы юк.

Д ә ү л и *(понятойларга)*. Ни карап торасыз? Бер җирен калдырмыйча эзләгез!

Понятойлар кузгалалар. Урамда кыңгырау тавышы ишетелә. Туктап калалар. С ә е т йөгереп керә.

С ә е т. Әти, земский начальник килде, сине сорыйлар!

Д ә ү л и. Мине сорыйлар? Дөмеккере, тапкан килер чак. Әйдәгез!

Чыгып китәләр. Бүлмәдән М а һ и чыга.

Г а я з. Әйдә, Маһи, муллага.

Х ә с б и. Бар, кызым, форсат барында укытып калыгыз.

М а һ и. Әйдә, Гаяз, аллага тапшырдык. *(Китәләр.)*

Х ә с б и. Кичер, тәңрем, синең исемең белән ант итеп, беренче кат кеше алдадым. Тукта инде, токмач кабартырга утыным юк икән. *(Китә.)*

Бераздан әкрен генә ишек ачыла, як-ягына карана-карана Г ы й л ь м и керә. Өйнең бөтен җирен җентекләп тикшерә.

Г ы й л ь м и. Берсе дә өйдә юк икән, яхшы чакта урнаштырыйм әле. Баз капкачлары кая соң... Менә ул кайда икән... *(Базны ачып төен ташлый.)* Минем өчен нәрсә? Әтүтән Дәүли кызын Сабир алса ни дә, Тимерче Гаяз алса ни. *(Ишек янына барып утыра.)*

Чыбык-чабык күтәреп Х ә с б и керә.

Х ә с б и. Бәлеш, күрми дә торам, кунак бар икән.

Г ы й л ь м и. Нихәл, Хәсбиҗамал, арумы?

Х ә с б и. Әйбәт әле, үзең исәнме?

Г ы й л ь м и. Бер көе кыймылдап йөрим шунда. Картайдым инде, Хәсбиҗамал, картайдым. Колакларым да ишетми башлады. Улың өйдә юкмыни?

Х ә с б и. Урамга чыгып китте. Җыен була диме...

Г ы й л ь м и. Шулай бугай шул, бөтен халык урамда, ахыр заман төсле ыгы-зыгы килеп йөриләр.

Х ә с б и. Йомышың бар идеме?

Г ы й л ь м и. Менә шушы чиләгем су тотмый, төп салып бирмәсме дип килүем иде.

Х ә с б и. Өйдә эшләми бит, алачыкка илтерсең.

Г ы й л ь м и. Ике тапкыр бардым, туры китерә алмадым, теге урысыгыз булса, мондый нәрсәләрне төзәтмим дигән була.

Х ә с б и. Чыннан да, моның нәрсәсен төзәтәсең инде, колаклары юк, кысалары челтәрләнеп беткән. Юк, Гыйльмени-саттәй, эшкә ашарлык түгел бу. Кайтышлый чүплек базына гына ташлап калдырасың бар.

Г ы й л ь м и. Нәрсә?.. Базга ташлап калдырасың дисеңме?..

Х ә с б и. Юк, чүплек базына дим.

Г ы й л ь м и. Ә, ярый алайса, сау булып тор.

Х ә с б и. Утыр әле, чәй эчеп китәрсең.

Г ы й л ь м и. Рәхмәт, башка вакытта иркенләп килермен әле.

Х ә с б и. Гомер буе бер килгән кешегә буш чыгуы килешмәсә дә, гаеп итмәссең инде.

Г ы й л ь м и. Ул нинди гаеп була ди, якты чыраең өчен дә бик зур рәхмәт. *(Китә.)*

Х ә с б и. Эш күп чакта кул-аяк бәйләп йөрисең шунда. Тукта инде, токмачымны басып җибәрим.

М а һ и белән Г а я з керә.

Х ә с б и. Булдымы, улым?

Г а я з. Булды, әни, гөрләтеп никах укыттык...

Х ә с б и. Ярый, бәбкәйләрем, ярый. Озын гомер, тигез мәхәббәт бирсен.

Г а я з. Өсләреңне сал, Маһи, үз өеңдәге шикелле чишенеп утыр. Безне хәзер беркем дә аера алмас.

Еракта халык кычкырышкан тавыш ишетелә.

М а һ и. Бу ни бу?

Г а я з. Җыен башланган, мин анда киттем.

М а һ и. Гаяз, барма инде, минем эчем поша.

Г а я з. Юк, Маһи, миңа бармый калырга ярамый. Сабирларның икенче кат муеннарын сындырыр өчен мин анда булырга тиеш.

М а һ и. Миңа монда синсез күңелсез булыр.

Г а я з. Мин озакка түгел, хәзер кайтырмын, яныңда әни бар бит. Ярый, мин киттем. *(Китә.)*

М а һ и. Әни, мин сиңа әнкәй диярмен инде, яме?

Х ә с б и. Ярый, кызым, ни дисәң дә риза. Тик минем баламны болай зурлавыңны нинди генә яхшылыкларым белән кайтара алырмын икән?

М а һ и. Миңа синең бернинди хезмәтең кирәкми, әнкәй. Мин сине Гаязны яраткан кебек яратырмын. Аны кадер-хөрмәт иткән кебек карармын.

Х ә с б и. Юк, юк, кызым, тәнемдә җаным, кулымда көчем бар чагында өй эшләрен синнән эшләтмәм. Мин сине үз баламдай өрмәгән җиргә дә утыртмам. Ай-ай, башым әйләнә башлады...

М а һ и. Кил, әнкәй, түргә ятып тор. *(Сәкегә ястык салып бирә, Хәсби менеп ята.)*

Х ә с б и. Килен, токмачымны гына басып бирерсең инде.

М а һ и. Ярый, әнкәй, ярый, басармын. *(Җиңнәрен сызганып эшкә керешә.)*

Х ә с б и. Син инде, килен, токмачыңны ваграк кисәргә ты-

рыш. Минем Миргаязым эре кискән токмачны бер дә яратмый. Куна тактасы ян тәрәзә янында чөйгә эленгән. Уклавы казан өстендә булыр.

Маһи. Ярый, әнкәй, ярый, табармын.

Маһи токмач баса башлый. Озак тынлык.

Хәсби. Килен, бераздан, мин әйтәм, идәнне юып чыгарсаң да ярар иде. Минем Миргаязым чисталыкны ярата.

Маһи. Ярый, әнкәй, юармын.

Тынлык.

Хәсби. Аннан соң, килен, әллә ни гомердән бирле саклап килгән бераз бодай оным бар, иртә беләнгә коймак изеп җибәрербез. Бераз баш-күз алгач, түкми-чәчми генә кыл иләктән иләп куярсың.

Гарифә керә.

Маһи. Әни, бу син?..

Гарифә. Әйе, мин...

Хәсби. Әйдә, кодагый, түрдән уз.

Маһи. Әйдә, әни, утыр.

Гарифә. И бала, бала... *(Елый.)*

Маһи. Ярый инде, әни, елама...

Гарифә. Дус-дошман арасында адәм рисвае ясагач, еламый нишлим.

Маһи. Сабирга бирергә үзең дә каршы идең бит.

Гарифә. Каршы булсам да, болай мәсхәрә итәрсең дип көтмәгән идем.

Маһи. Нишлим соң, башка чарам булмады. Ялындым, ялварып сорап карадым, тыңламадыгыз.

Гарифә. Әйдә, балам, кайтыйк, иртәгә туй ясаган булып, никах укытып бирербез.

Маһи. Безнең эш беткән инде, әни.

Гарифә. Ничек беткән?

Маһи. Яшь мулладан никах укыттык.

Гарифә. Никах укыттыгыз?..

Хәсби. Әйе, кодагый, аллага шөкер, берьюлы эшләрен бетерделәр. Минем Миргаязым эшне җиренә җиткереп эшләргә ярата.

Гарифә. Соңгы өметемне дә кискәнсең икән.

Артта көлешә-көлешә сөйләшеп узган кешеләр тавышы ишетелә.

Хәсби. Нәрсә бар икән тагы?

Маһи. Җыеннан кайталар.

Г а р и ф ә. Ярый, сау булыгыз.

Х ә с б и. Утыр әле, кодагый, аш-су өлгерә бит.

М а һ и. Әни, син миңа ачуланма. Үзең беләсең, башка чарам булмагач, актык чиктә генә эшләдем.

Г а р и ф ә. Ярый, кызым, хәерле булсын. Тигез гомер белән байлык, муллыкта көнегез узсын.

Г а я з керә.

Г а я з. Нихәл, әби, исән килдеңме?

Г а р и ф ә. Исән!.. *(Пыр тузып чыгып китә.)*

Г а я з. Бәлеш... нишләп әби чәпчеде?..

М а һ и. Аның белән килешеп була. Ризалык бирде инде.

Х ә с б и. Улым, Миргаяз, нигә бик тиз борылдың?

Г а я з. Сабирлар җиңелде. Җыен таралды. Земский начальникны кудык.

М а һ и. Кудыгыз?..

Г а я з. Сабирларга җир бүлеп бирү турында сөйли генә башлаган иде, халык арасыннан Тимай бабай чыкты да: «Инде җанымны алырга телисезме, мә!.. Кирәк булса, аны да алыгыз, әмма мин үз өлешемә тигән су буендагы җиремне аңар бирмим!» — дип, земскийга ташланды. Аннан башкалар, аннан бөтен җыен белән: «Бездә хуторчыларга җир юк», — дип кычкырдылар. Башта үгетләп, соңыннан куркытып караса да, булдыра алмады. Атына утырып авылдан ук табан ялтыратты.

Р а м а й, Ш ә р и ф, Т и м е р г а л и һәм С ә е т керә.

Т и м е р г а л и. Әссәламәгаләйкем!..

Г а я з. Вәгаләйкемсәлам. Әйдәгез, егетләр, түрдән узыгыз...

Р а м а й. Ягез, бер дога, илаһи амин, күпер башы Әмин, күршегез Тимерша, кардәшегез Батырша кебек алты улыгыз, җиде кызыгыз булсын, имәндәй картаеп, юкәдәй муртаеп, билләр бөкрәйтеп, күзләр чекрәйтеп, исәнлектә, саулыкта, байлык белән муллыкта, керән кебек әчкелтем, чөгендердәй төчкелтем гомер итегез. Аллаһы әкбәр!..

Т и м е р г а л и. Яшь килен кая соң, әллә бездән качамы?

Г а я з. Маһи, әйдә, монда чык.

М а һ и. Чыкмыйм, оялам.

Т и м е р г а л и. Өй алам... Мунча булса ярамыймы?

О р л о в керә.

Р а м а й. Һу!.. Захарыч!..

О р л о в. Исәнмесез, егетләр!

Г а я з. Әйдә, Захарыч, өсләреңне сал.

Г а я з. Әйдә, Захарыч, тот.

О р л о в. Тукта әле, Гаяз, бераз хәл алыйм...

Р а м а й. Эчкәч алырсың, әйдә, крой.

О р л о в. Ярый алайса, яшь кияү белән уңган килен саулыгына.

Х ә с б и аш кертеп куя.

Х ә с б и. Саумы, Захарыч?

О р л о в . Бик яхшы, абыстай, киленле булгансың икән.

Х ә с б и. Аллага шөкер, бәхетле генә була күрсеннәр инде. *(Китә.)*

О р л о в. Молодец, Гаяз, үз сөйгәнеңне ятка бирмәдең.

Р а м а й. Монда, Захарыч, Гаязны түгел, кызны мактарга кирәк. Әгәр дә улябышып чыкмаса, Гаяз бернәрсә дә эшли алмый иде.

О р л о в. Дөрес, кыз да молодец. Но бит кыз ул смелостьны кем өчен эшләде?

Р а м а й. Гаяз өчен.

О р л о в. Шулай булгач, Гаязны мактарга кирәк.

Г а я з. Ягез әле, тагы берне тотыгыз.

Т и м е р г а л и. Кума, кума, янында бит, җитешерсең.

Г а я з. Май кап, әйдә тотыгыз. *(Эчәләр.)*

Р а м а й. Әйдә, Шәриф, тарт колагын, моңлансын, дошман ишетеп, ач бүредәй уласын!..

Шәриф гармун уйный. Тимергали җырлый.

Т и м е р г а л и. Абзый, атың юрга булса,
Мин дә утырыйм әле;
Дус-ишләрнең күңле булсын,
Җырлап утырыйк әле.

Р а м а й. Җиккән атым гнедой,
Без үзебез молодой...
Салып бирәм, якын дустым,
Эчеп җибәрче давай. *(Гаязга аракы бирә.)*

Г а я з. Әйдәгез, суынмасын...

Ш ә р и ф. Ай-һай, малай, Гаяз, бик зур савытка саласың, бу бит үзе бер ярты дигән сүз.

Р а м а й. Ничего, бер булганда берәгәйле булсын, әйдә, крой...

Т и м е р г а л и *(җырлый)*.
Байлар-байлар бал эчә,
Урта байлар сыра эчә,
Ярлы мескен, ни хәл итсен,
Ярдан ятып су эчә.

Әнкәй мине тапкачтан,
Ак биләүгә биләгән.
Ак биләүләргә биләгән,
Бәхете булсын димәгән.

Орлов. Гаяз, яратам мин сине.

Рамай. Захарыч, мине яратмыйсыңмы?

Орлов. Сине дә яратам, Рамай, ләкин син бунтарь, тәрәзә ватып үч аласың... Ә Гаяз ул — молодец, киләчәк өчен аңардан менә дигән көрәшче чыгар.

Тимергали. Ә мин ничек, Захарыч?

Орлов. Син дә молодец, Тимергали.

Шәриф. Захарыч, менә миннән нинди кеше чыгар икән?

Орлов. Синнәнме?.. Әйдә берәр бию көе уйнап җибәр әле. Күрербез, нәрсә чыгар.

Бию көе уйнала. Тимергали биеп Сәетне чакыра. Сәет бии, Гаязны чакыра. Гаяз бии, Захарычны чакыра.

Орлов. Уйна барыняны!..

Барыня уйнала, Орлов бии.

Гаяз. Анысы да монысы, егетләр, Захарыч китсә, нишләрбез.

Тимергали. Захарыч, чынлап та инде китәсеңме?

Орлов. Әйе, егетләр, китәм. Өяз жандарм управлениесеннән хәбәр алдым. Бүген кич юлга чыгам.

Рамай. Тагын тимерчесез калабыз икән.

Гаяз. Тимерчесез түгел, егетләр, укытучысыз, акыл бирүчесез калабыз.

Бер сүз эндәшми тынып калалар.

Орлов. Шулай да, җибәрәсегез килми, ахры.

Гаяз. Әйе, Захарыч, синең белән бергә эшләү рәхәт иде... Син бит безгә, моңа кадәр караңгы булган бик күп нәрсәләрне ачып, аңыбыздагы наданлык-томаналык пәрдәләрен кистең... Син бит кешеләр арасында булган тигезсезлекләрне бетерергә юллар күрсәтеп, бозланып туңган йөрәкләребезгә көрәш чаткылары кабындырдың. Китмә син, Захарыч. Хатыныңны, балаларыңны монда китерик тә, бергә-бергә эшләрбез.

Тимергали. Чынлап та, Захарыч, китмә, бездә кал.

Шәриф. Курыкма, җәйгә бездә эш күп булыр.

Орлов. Юк, егетләр, миңа монда артык калырга ярамый.

Гаяз. Минем синнән аерыласым килми.

Орлов. Ярый, алайса мин Мәскәүгә кайткач, иптәшләр

белән сөйләшеп, сине безнең заводка алдыру турында чара күрермен. Безнең анда татар эшчеләре дә күп.

Т и м е р г а л и. Захарыч, миңа да берәр урын таба алмассыңмы, мин дә китәр идем?

Артта свисток кычкырткан тавышлар ишетелә.

О р л о в. Бу ни бу?

М а һ и. Гаяз, безнең капка төбендә кешеләр бар.

Ш ә р и ф. Кайберләре ат менгәннәр. Әллә үрядникләр инде?

О р л о в. Урядниклар?

Г а я з. Алар нишләп монда йөриләр икән?

Р а м а й. Ар авылына күмүшкә тентергә баруларыдыр.

О р л о в. Шулай да, әйдә әле, Гаяз, яннарына чыгып керик. *(Китәләр.)*

Х ә с б и. И Ходаем, ямьле көннең ямен җибәрү өчен генә йөрмәсәләр ярар иде.

М а һ и. Әнкәй, минем өчен килгән булсалар, нишләрбез?

Р а м а й. Кайгырма, Маһи, үрәдник түгел, чорты булса да курыкма. Үзең каты торсаң, бернәрсә дә эшли алмаслар. Эшем беткән, печате басылган диген...

Т а в ы ш. Макар!..

Х ә с б и. Керәләр, әйдә, кызым, теге якка. *(Китәләр.)*

С ә е т. Шәриф абый, әйдә базга чумабыз.

Ш ә р и ф. Әйдә. *(Базга төшеп китәләр.)*

Р а м а й. Их, сез, куян йөрәкләр...

Д е р ю г и н керә.

Д е р ю г и н. Закон исеменнән игълан итәм: берегез дә урыныгыздан кузгалмагыз!

Өстәл янына килә. Аның артыннан М а к а р, и к е к а з а к, Д ә ү л и һәм п о н я т о й л а р эчкә узалар.

Д е р ю г и н. Әһә, кутеж, пьянство?!.

Х ә с б и. Дәүләтша кода, бу нинди эш?..

Д е р ю г и н. Не разговоривать!.. Староста, яныңа бер казакны алып, чишендереп тентегез...

Д ә ү л и. Господин үрәтник, безнең шәригать хатын-кызларны тентергә не вилит бит.

Д е р ю г и н. Ну, ну, ну!.. Мин үзем шәригать.

Д ә ү л и. Ладно, ладно, мин болай гына, әйдәгез. *(Ике казак белән китә.)*

Д е р ю г и н. Макар!.. Менә бу разбойникны тентергә!

М а к а р. Слушаюсь!.. *(Рамай янына килеп.)* Руки вверх!

Рамай теләр-теләмәс кенә кулын күтәрә. Макар аның итек куnычыннан кендек ала.

М а к а р. Господин урядник... Лом!..

Р а м а й. Нинди лом булсын, кендек ич.

Д е р ю г и н. Молчать!.. Макар, по всем правилам тентүне башларга, идән астын... башка җирләрне җентекләп карарга!

М а к а р. Слушаюсь. *(Базга төшеп китәләр.)*

Д ә ү л и керә. Казак кулында бөти.

Д ә ү л и. Господин үрәдник, карчыктан менә бу нәрсәдән башка әйбер чыкмады.

Д е р ю г и н. Это што?

Д ә ү л и. Бөти.

Д е р ю г и н. Как то есть бути?

Д ә ү л и. Каранский баранчук, малинки Каран.

Д е р ю г и н. Алай булса, кирәкми.

М а к а р *(баздан башын чыгарып кычкыра)*. Господин урядник, базда кешеләр бар.

Д е р ю г и н. Кешеләр бар?.. Үлеләрме, тереләрме?

М а к а р. Үлесен-тересен белмим, чучка төсле борыннарын җиргә тыгып ятканнар.

Д е р ю г и н. Ну-ка, тотып чыгар үзләрен.

М а к а р. Слушаюсь!.. *(Югала. Шәриф белән Сәетне колакларыннан тотып чыгара.)* Менә алар, гололобыйлар... *(Кире төшеп китә.)*

Д е р ю г и н. Ах сез, татарчоноклар...

Д ә ү л и. Господин үрәдник, бу бит минем малчуган.

Д е р ю г и н. Ах, гололобыйлар, ах, чучка колаклар...

Р а м а й. Господин үрәдник, нигә аларны кыйныйсың?

Д е р ю г и н. Молчать!..

Д ә ү л и. Ристан, нишләп монда йөрисең, бар өйгә... *(Сәетне кыйнап озата.)*

М а к а р баздан чыга.

М а к а р. Господин урядник, баздан бер төен таптык. *(Төргәк бирә.)*

Д е р ю г и н. Төен таптыгыз?.. *(Чишеп карый.)* Батюшки... Ялган акчалар...

Д ә ү л и. Ялган акчалар?

Т и м е р г а л и. Акчалар?..

Д е р ю г и н. Так-так-так. А ну-ка, атаманнарын монда кертегез.

Макар китә. О р л о в белән Г а я з н ы алып керә.

Д е р ю г и н. Шаймарданов, бу акчалар синекеләрме?

Г а я з. Нинди акчалар?..

Д е р ю г и н. Көмеш акчалар! Менә аларниндиләр, чылтырамыйлар да, фальшивыйлар.

Г а я з. Андый акчаларны минем күргәнем дә юк.

Д е р ю г и н. Господин Орлов, бу фальшивкаларны бергә ясадыгызмы?

О р л о в. Ничек бергә?

Д е р ю г и н. Тентү вакытында шушы өйнең базыннан табылдылар, чорт возьми! Бу гололобыйлар үзләре генә болай оста итеп ясый алмаслар иде, әлбәттә инде сезнең мастеровойлык ярдәм иткәндер. Я, ни дисең?

О р л о в *(өстәл янына килеп, акчаларны тоткалап караганнан соң)*. Паразит, негодяй!

Д е р ю г и н. Да, против факта не попрешь. Староста, подводы давай!..

Д ә ү л и. Господин урядник, барысын да алып китәсезме?

Д е р ю г и н. Что за вопрос?.. Әллә син боларның эшен шутка думаешь?

Д ә ү л и. Юк, мин болай гына, ничә олау кирәк булыр диюем иде.

Д е р ю г и н. Һәрберсенә аерым подвода бирерсең.

Д ә ү л и. Ладно, ладно, табарбыз.

Ш ә р и ф. Дәүли абзый, безнең нинди гаебебез бар, урядниктән сорап...

Д ә ү л и. Буталмагыз, күрәсең бит, эшем бар.

Д е р ю г и н. Әйдәгез, киттек.

Х ә с б и. Балам!.. *(Барып Гаязның муеныннан коча.)*

Аргы яктан чәчрәп М а һ и чыга.

М а һ и. Гаяз, бәгърем!..

Д е р ю г и н. Алып ташлагыз...

Хәсбине казаклар аера.

Д е р ю г и н. Әйдәгез, марш!..

Г а я з. Хуш, әни! Сау бул, Маһи!..

Х ә с б и. Алмагыз минем баламны, тимәгез аңар!

Барып ябыша, алып ташлыйлар. Чыгып китәләр. Маһи белән Хәсби идәндә аунап калалар.

*Пәрдә.*

# ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Каравыл өе. Төрле кәгазьләр эленгән. Бер якта яртылаш җимерелгән мич. Стеналарының кайбер җирләре, ишек яңаклары, тәрәзә бруслары үтмәс балта белән юнып алынган. Тәрәзәнең кайбер өлгеләренә чүпрәк, кәгазь ябыштырылган. Түшәм сайгаклары каралып, пычранып беткән. Пәрдә ачылганда, бер төркем халык Т и м а й б а б а й н ы чорнап алганнар да бәет тыңлыйлар.

Т и м а й. Бисмиллаһи, вә биллаһи,
Җитте корбан гаете.
Без әйтиек, сез тыңлагыз,
Тимерче Гаяз бәетен.
Үрәдникнең җиккән аты
Җирән белән тимер күк.
Ялган белән Себер киткән
Бер мин түгел, алар күп.
Үрәдникнең дугасында
Пар кыңгырау шалтырый,
Ул авылга килеп керсә,
Ярлылар дер калтырый.
Талир тәңкә — көмеш тәңкә,
Саф көмеш дип мактыйлар,
Ялган акча ясаучы дип
Башка бәла тактылар.
Талир тәңкә тавышлары
Яшь кызларны җилкетә;
Сабир кебек явыз җаннар
Бик күпләрне тилмертә.
Сабир белән үрәдниктән
Безнең башлар ни күрә?—
Унике ел катр, диеп
Чыгып әйтте карт түрә.
Әнкәй мескен елап калды
Бусагада ауналып,
Киттем илдән сөргеннәргә
Ятап белән кауланып.
Миннән калгач, хәер сорап
Көне узган урамда,
Күрше авылдан кайткан чакта
Туңып үлгән буранда.
Талир тәңкә — матур тәңкә —
Әби патша акчасы,
Мине белгән, мине күргән
Бәхил булсын барчасы.

Ш ә р и ф. Их, бабай... Ничек итеп болай оста чыгардың?

Т и м а й. Исегездәдер, кыш көне Гаязның әнисе Хәсби килен туңып үлгәч, становой килгәнче дип бозланып каткан гәүдәсен күрек белән лапаска аскан идек. Айдан арткан үлек саклау бәласенә мине дә чиратка куйдылар. Менә шул чакта, Хәсбиҗамал киленнең яшьләй тол калуы, нужа белән карап үстергән бердәнбер баласының нахакка Себер китүе, шул бала өчен судлашып, йортсыз-җирсез калганнан соң урамга ташлануы, ахыр чиктә хәер сорашып кайтканда туңып үлүләре бербер артлы күз алдымнан үтеп киттеләр. Күңелем тулып еларга теләдем, яшь чыкмады. Алласына, дөньясына ләгънәт әйтәсем килде, телем бармады... Шуннан менә шушы бәетне уйлап чыгардым.

Ш ә р и ф. Рәхмәт, бабай, рәхмәт, без аны урамда гармун белән җырлап йөрербез.

Р а м а й белән Т и м е р г а л и керә.

Р а м а й. Тимай бабай, әйдә әле, Тимергали белән бер җиргә барырсың.

Т и м а й. Кая?

Р а м а й. Гаяз өенә ялган акчаларны Гыйльми карчык ташлаган дигән хәбәр бар.

Т и м а й. Кем әйтә?

Т и м е р г а л и. Сәрби әбигә Гыйльми карчык үзе сөйләгән, өенә барып кайтыйк. Ничек булганны үз авызыннан сөйләтә алмабызмы?

Т и м а й. Әйдә, улым, әйдә. *(Китәләр.)*

Ф ә й з у л л а. Рамай, Гыйльми карчыкның сөйләве дөрес булса, Гаяз кайта бит, мин әйтәм.

Р а м а й. Шаулама, Фәйзулла абзый, эшләр уңайга бара.

Ф ә й з у л л а. Молодец, Рамай, алай иттең, болай иттең, атсыз калып булса да үзеңнекен эшләдең.

Ш ә р и ф. Атсыз калдың дигәннән, Рамай, бер ат акчасы бар да кереп беттеме?..

Р а м а й. Кучереннән алып, прокурорына кадәр бирә башлагач, бетә икән ул, егетләр. Мескен кара алашаның колагы да күренмәде. Ахырында, губерна кадәр җирдән тәрәзә саен сорашып кайтырга туры килде.

Ф ә й з у л л а. Кайгырма, Рамай, башың сау булса, атын табарсың, ичмасам, урядник кадәр урядникне чукындырасың бит.

Р а м а й. Үземнең дә шулай дип йөрүем иде.

Ш ә р и ф. Ул тикшерүче дигәннәре кая соң әле?

Р а м а й. Дәүли абзыйларда чәй эчә калды.

Шәриф. Рамай, теге бездән аерылгач, ниләр булганны сөйлә әле.

Рамай. Аның нәрсәсен сөйлисең инде, мине дә сезнең белән волостьтан кайтарып җибәрәләр иде, ничә әйтсәң дә, Ишбулды мөртәте белән урядник кенә башны ашады. Шулай, егетләр, ятабыз, бер ел булды, безнең өчен кайгыртучы юк. Безнең камерада Соколовский дигән бер социалист бар иде. Беркөнне шулай Гаяз белән икебезгә әйтә: «Әгәр дә сез үзегез кайгыртмасагыз, яңадан бер-ике ел ятарсыз. Минем шәһәрдә бер бик шәп атбакатым бар, тотыгыз да шуны яллагыз», — ди.

Шәриф. Йә, йә, шуннан?

Рамай. Без Гаяз белән Захарычка киңәш итәргә булдык. Ләкин йөрибез-йөрибез, Захарычны туры китерә алмыйбыз.

Фәйзулла. Ул соң сезнең белән түгел идемени?

Рамай. Түгел шул, аны социал-демократ большевиклар бүлмәсендә тоталар иде.

Фәйзулла. Алары нинди кешеләр тагы?

Рамай. Алары, малай, патшаны төшереп, завод-фабрикаларны эшчеләргә, җир-суларны крестьяннарга бирергә, эш башына эшче-крестьяннарны куярга дип баралар икән. Шуның өчен дә аларны, беркем белән аралаштырмый, аерым камерада тоталар...

Шәриф. Пәри башка, җен башка дигәндәй, аларның да аермасы бар икән. Кара әле, Рамай, ул рвалутса дигән халыкның тубык итләре юк диләр, шул сүз дөресме?

Рамай. Кит, юләр, тубык итсез кеше буламы?

Шәриф. Була икән шул. Иж заводында күргәннәр, бер стужин-рвалутсаны өч казак ат белән куа, ә ул, ичмасам, ияртми дә ди. Алар шәп йөгерер өчен тубык итләрен кистереп ташлыйлар икән.

Рамай. Дөрес түгел, бар да әкият. Шулай, егетләр, йөри торгач, прогулкада Захарычны күреп, сөйләп бирдек. Ул әйтә: «Адбакат яллау, судны тизләтү өчен файдасы булса да, сезне котылдыра алмас», — ди. Шулай да, ятып калганчы атып кал дип, адбакат ялларга булдык. Гаязның әнисе Хәсби җиңгинең барлык каралтыларын, җир-суларын сатып җибәргән илле сумына адбакатны яlладык. Бу, мин сиңа әйтим, унике көн дигәндә, безнең эшне әйләндереп чыгармасынмы? Суд башлана... Сорыйлар, сорыйлар, инәсеннән җебенә кадәр җентеклиләр, тикшерәләр. Миннән ул кадәр түгел, әмма инде Захарыч белән Гаяздан без белмәгән эшләр турында сорашып теңкәләренә тиделәр.

Фәйзулла. Анда соң тылмач буламы?

Рамай. Була икән. Бер татар морзасы минем туйга-ашка дигән сүзне ялгыш әйтә башлады, сикереп тордым да: «Это

человек не правильно говорит. Моя пришел только гусь ашать, а когда деньги под пол кидал наших не видал», — дип кычкырып җибәргән идем, бөтенесе шаркылдап көлделәр. Захарычның сүзе дөрес булып чыкты, адбакат мине җолып калса да, Гаяз белән Захарычны котылдыра алмады. Икесен дә уникешәр елга хөкем иттеләр.

Артта Мочтакның җырлаганы ишетелә.

Мочтак. Әйттер, типтер, сиптер әйдә, дөнья үзебезнеке.

Рамай. Бу кем ул көпә-көндез исергән?

Фәйзулла. Билгеле инде, безнең авылда бер генә бит ул, Солтан хаҗи малае Мочтак.

Рамай. Тагын башлаганмыни?

Фәйзулла. Атасы үлгәннән бирле ташлаганы да юк. Бөтен байлыгын эчеп бетергән иде, инде хәзер калдык каралтылары белән милеген дә Гобәй байга саткан. Шул акчага типтерә.

Мочтак керә.

Мочтак. Нихәл, егетләр, исәнмесез!

Фәйзулла. Үзең нихәл, Мостафа!

Мочтак. Күрәсез бит, минем эшләр шәп. Рамазан, рәхмәт сиңа, Ишбулды Сабирын акылга утыртасың икән. Утырт, энекәем, минем өчен дә утырт. Ул минем затлы әйберләремне алдап алган иде, мошенник! Шуның өчен үзеңне аракы белән сыйлыйм әле.

Дәүли керә.

Дәүли. Таралыгыз, җәмәгать. Тикшерүче килде.

Фәйзулла. Дәүли абзый, бездән дә сорар микән?

Дәүли. Белмим әле, белмим, баш катырып чуалма.

Фәйзулла. Чуалма дип кәпрәймә, Ишбулды Сабирының бөтен хикмәтләрен белә диген.

Мочтак. Дөрес! Мин дә аның махинацияләрен беләм, мине дә языгыз, мин дә шаһит булам.

Тикшерүче белән Гобәй керә.

Тикшерүче. Чакыртылган кешеләр бар да килдеме?

Дәүли. Килделәр, господин следователь, бар да килделәр.

Тикшерүче. Хәзергә чыгып торсыннар, кирәк булгач чакыртырмын.

Дәүли. Храша. Әйдәгез, әйдә.

Тикшерүче белән Гобәйдән башкалар чыгалар.

Т и к ш е р ү ч е. Ну, дәвам итегез.

Г о б ә й. Дөрес, егет бик күп еллар бурлакта, зимагурлыкта йөргән мут егет. Бигрәк тә тимерче Орлов килгәннән соң, байлар белән авыл халкы арасында дошманлык тудырган начар егет, шулай да акча ясауда аның гаебе булмаска тиеш.

Т и к ш е р ү ч е. Нигә соң алай булгач, тентү вакытында аңардан фальшивый монеталар табылган?

Г о б ә й. Ул ялган акчаларны Сабир Ишбулдин ташлаткан.

Т и к ш е р ү ч е. Ну, бит алар факт түгел, бары разговорлар гына.

Г о б ә й. Халык теленә кергән буш булмый, Сабирның ялган акчалар белән кайнашканы элек-электән ишетелә иде.

Т и к ш е р ү ч е. Господин Гобәй, мин сезне не понимаю... Разный слухлар, бабьи разговорлар белән сез нәрсә әйтергә телисез?

Г о б ә й. Господин следователь...

Т и к ш е р ү ч е *(бүлдереп)*. Позволь... Ниндидер бунтарь, уголовный преступник Ахметшиннарга ияреп, гаепсез кешене опозорить итмәкче буласыз. Ул бит сезгә барыбер не удастся.

Г о б ә й. Господин следователь, сез үзегез аның кем икәнен белмисез, ул бит үзе башкаларны позорить итәргә ярата. Бөтен нәрсә аңар гына булсын, ул гына сату итсен, ул гына баесын, имеш... Например, менә мине алыйк, унике ел староста булып берничә медаль алган кешене разжаловать иттерде дә, ике бозауга кибәк аера белмәгән кешене староста итеп куйдырды. Аннан соң минем сатып алган иманаларымны тартып алды. Хуторга күчкән булып, яхшы җирләребездән мәхрүм итте. Хәзер инде хутор аша ата-бабаларыбыздан калган юлдан да йөртми башлады.

Т и к ш е р ү ч е. Ярый, барыгыз.

Г о б ә й. Мин сөйләп бетермәдем әле.

Т и к ш е р ү ч е. Барыгыз, все понятно.

Г о б ә й. Аңлатмыйча ничек понятно булсын инде?..

Т и к ш е р ү ч е. Барыгыз... Староста!..

Д ә ү л и йөгереп керә.

Д ә ү л и. Ждич.

Т и к ш е р ү ч е. Тимергали Шәрифуллинны җибәрегез.

Д ә ү л и. Ладно... (*Ишек ачып, дорфа рәвештә кычкыра.)* Тимергали!.. Кая дөмектең, господин следователь чакыра.

Т и м е р г а л и керә. Дәүли китә.

Тикшерүче. Тимергали Шәрифуллинмы?..

Тимергали. Әйе, Шәрифуллин.

Тикшерүче. Син солдатмы?

Тимергали. Юк, зимагур.

Тикшерүче. Ничек зимагур?

Тимергали. Өч ел Урал заводларында, Себер шахталарында эшләгән идем, шуңа күрә зимагур дип йөртәләр.

Тикшерүче. Ну, Шәрифуллин, сез нәрсә әйтергә телисез?

Тимергали. Әйтәсе сүзләр күп, господин следователь. Беренче сүзне җыйган тамгалардан башлыйк.

Тикшерүче. Ничек тамгалардан?

Тимергали. Шушы кәгазьдә тамга салган йөзиксән капка кешеләре, Гаяз белән Орловның нахакка Себер китүен әйтеп, Ишбулды Сабиры белән урядникнең хөкемгә тартылуын сорыйлар.

Тикшерүче. Хөкемгә тартылуын?..

Тимергали. Әйе, хөкемгә тартуны авыл белән сорыйбыз.

Тикшерүче. Так... Дальше... Аларның гаепле икәнлекләрен күрсәтер өчен нинди фактларыгыз бар?

Тимергали. Моннан ике ел элек, Сабир Ишбулдин күрше авыл ары Тимкә Ниязовтан тиреләр алганда ялган акчалар биргән.

Тикшерүче. Сабир Ишбулдинмы?

Тимергали. Әйе, Сабир Ишбулдин. Ул акчалар хәзерге көнгә кадәр аның кулында саклана, бу — бер; икенчедән, тентү вакытында Гаяз Шәймәрдәнев өеннән табылган акчаларны да Сабир Ишбулдин ташлаткан.

Тикшерүче. Что вы, что вы, мин моңа ышанмыйм...

Тимергали. Ышанмасагыз, төен ташлаучы карчыктан сорагыз. Ул монда.

Тикшерүче. Монда?.. Ну-ка, давай сюда.

Тимергали китә, Р а м а й белән Г ы й л ь м и керә.

Р а м а й. Әйдә, Гыйльменисаттәй.

Т и к ш е р ү ч е. Ә сез нәрсәгә?

Р а м а й. Карчыкның тылмачы булам.

Т и к ш е р ү ч е. Кирәкми, тылмач староста булыр. Староста!..

Д ә ү л и. Ждич.

Т и к ш е р ү ч е. Переводчик булырсың, барыгыз...

Р а м а й. Кара аны, Дәүли абзый, бутый күрмә, тыңлап торабыз. *(Китә.)*

Т и к ш е р ү ч е. Бабушка, как тебя зовут?..

Г ы й л ь м и. И ходаем, казамат диме?

Д ә ү л и. Юк, ни атлы ди.

Рамайлар тикшерүчегә күренмичә тәрәзәдән карап торалар.

Г ы й л ь м и. Ә... үзең беләсең инде. Чикерткә Гыйльменисасы, иремнеке Әфләтүн иде.

Т и к ш е р ү ч е. Што бормочет, переведи.

Д ә ү л и. Кабилка дуч бает.

Т и к ш е р ү ч е. Как то есть кабилка?

Д ә ү л и. Вот бит, летом на травах гуляет, чикерт-чикерт, тырт-тырт... *(Сикереп күрсәтә.)* А мужика Әфләтүн...

Т и к ш е р ү ч е. Бернәрсә дә аңламыйм, обалдел что ли? Бабушка, в избу Шагимарданову узел ташлаган?

Г ы й л ь м и. Ә?..

Д ә ү л и. Гаяз өенә төен ташладыңмы, ди.

Г ы й л ь м и. Гөнаһ шомлыгына каршы ташлаган идем шул.

Дәүли тәрәзәгә карый. Рамай йодрык күрсәтә.

Д ә ү л и. Против греха бросал, говорит, господин следователь, бросал.

Т и к ш е р ү ч е. Спросите, кто велел бросать?..

Д ә ү л и. Анда илтеп ташларга кем кушты, ди.

Г ы й л ь м и. Кем булсын, Ишбулды мөртәте, Сабир имансыз.

Д ә ү л и. Сабирка мөртәт. Сабирка без... иман, говорит.

Т и к ш е р ү ч е. Как то есть мөртәт, без иман?

Д ә ү л и. Вот бит мусульман сначала молитва укыган, потом грешелся богу, чукынган. Потом...

Т и к ш е р ү ч е. Ладно, понятно... она хорошо знала, что имеется в этом узле?

Д ә ү л и. Ул төендә ни барлыгын белдеңме, ди.

Г ы й л ь м и. Юк, белмәдем, сүтеп карамадым. Үзе миңа, сихер кәгазьләре, сөйдергеч бөтиләре, диде.

Д ә ү л и. Не знала. Сам сказал — против чорта, шайтан бумагы, калдонски бугамалится баранчуклары, бает.

Т и к ш е р ү ч е *(бик каты өстәлгә сугып)*. Врешь, дохлая ведьма!..

Г ы й л ь м и. Ләхәүле вәлә куәте...

Т и к ш е р ү ч е. Почему она через такой промежуток времени әйтергә булган?

Д ә ү л и. Ни өчен хәзер генә әйтергә уйладың, ди.

Г ы й л ь м и. Иманамны алдап алганнан соң, ашарга-эчәргә

бирми башлагач, аның өчен гөнаһлы булып, мәхшәр көнендә дуңгызлар белән кубарылып, тәмуг утында янасым килмәде.

Дәүли аптырап кала.

Т и к ш е р ү ч е. Что, староста?

Д ә ү л и. Гыйльменисаттәй, бутамыйча юньләп кенә әйт әле.

Г ы й л ь м и. Аның өчен гөнаһлы булып, мәхшәр көнендә дуңгызлар белән кубарылып, тәмуг утында янасым килмәде, дим.

Д ә ү л и. Если грехами умирает булса, там-та-ра-ра далүки дөньяда, нашеныкы Мөхәммәтанский бух, как ваш свинья, тәмугта жарит буджет, говорит.

Т и к ш е р ү ч е. Как, как?..

Д ә ү л и. Нашеныкы Мөхәммәтанский бух, как ваш свинья, тәмугта жарит буджет.

Т и к ш е р ү ч е. Уф, ничего не понимаю. Идите к чорту!..

Г ы й л ь м и. Нәрсә ди?

Д ә ү л и. Шайтаннар янына китегез, ди.

Г ы й л ь м и. Дәүләтша, иманамны алып бирәме?

Д ә ү л и. Бирә, бирә, зинһар өчен күземнән югал...

Китәләр. С а б и р керә.

С а б и р. Һу!.. Таныш кеше икән, исәнмесез, Иван Василич.

Т и к ш е р ү ч е. Здорово, Сабир Хасанович, бик озакладыгыз.

С а б и р. Эш күп, Иван Василич, хуторга тегермән салдырам, каралтыларны күчертеп йөрим.

Т и к ш е р ү ч е. Да... вот что, Сабир Хасанович, эшләр сезнең өчен серьезный төс алып бара.

С а б и р. Ничек серьезный?

Т и к ш е р ү ч е. Шагимарданов белән Орлов эше буенча прошение язып губерна прокурорына барганнар.

С а б и р. Беләм, чепуха... Рамай Ахметшиннар кләвезе генә.

Т и к ш е р ү ч е. Юк, чепуха түгел, Гаяз Шагимарданов белән Орловның гаепсез икәнлеген күрсәтер өчен материаллар җитәрлек. Аннан соң, монда бер Ахметшин гына да түгел, алар хәзер бөтен авыллары белән өстеңнән приговор җыйганнар.

С а б и р. Приговор җыйганнар?..

Т и к ш е р ү ч е. Да, Сабир Хасанович, приговор җыйганнар. Шуның өстенә Шагимардановның өенә ялган акчалар ташлаучы карчык килеп үз теленнән миңа сознаться итте.

С а б и р. Сознаться итте?

Т и к ш е р ү ч е. Әйе, сознаться итте...

С а б и р *(куркып).* Иван Василич, Иван Василич, алай булгач нишлибез инде?

Т и к ш е р ү ч е. Мин сезне белмим, нишләргә телисездер, ләкин мин үзем төенләнгән төенне кире чишәргә уйлыйм.

С а б и р. Ничек кире чишәргә? Димәк, сез дә мине гаепләү ягында?

Т и к ш е р ү ч е. Лично мин түгел, конечно, конкрет материаллар шулай кушалар.

С а б и р. Иван Василич, ходай өчен харап итмәгез, коткарыгыз.

Т и к ш е р ү ч е. Мөмкин түгел, Сабир Хасанович, бөтен фактлар ялтырап яталар.

С а б и р. Но бит ул материаллар дөрес түгел. Столыпин җәнапларының җир реформасына үч итеп, булмаган гаепләрне минем өскә ыргыталар дип күрсәтергә була.

Т и к ш е р ү ч е. Анысы шулай... Но бит фактлар, аңлыйсызмы, фактлар...

С а б и р. Иван Василич, күпме алсагыз да алыгыз, ләкин мине бу бәладән коткарыгыз. *(Акча бирә.)*

Т и к ш е р ү ч е. Что сез, боже упаси... *(Тәрәзәгә карана.)*

С а б и р. Курыкмагыз, берәү дә юк, алыгыз...

Т и к ш е р ү ч е. Кирәкми, кирәкми. *(Акчаларны алып кесәсенә тыга.)* Сабир Хасанович, бу бит бик зур эш. Бөтен өяз, губерна чиновникларына беленсә, нишләрбез?

С а б и р. Мәгез, аларга да бирегез, бөтен байлыгымны, барлык дәүләтемне өләшегез, тик, зинһар өчен, мине аклый гына күрегез. *(Күп иттереп тагын акча бирә.)*

Т и к ш е р ү ч е. Ярый, мин алар белән сөйләшеп карармын, ну шулай да мин сезне хәзер арестовать итеп өязгә алып китәргә тиеш.

С а б и р. Өязгә, ни өчен?

Т и к ш е р ү ч е. Болай, формаль яктан дөрес булсын өчен дим.

С а б и р. Иван Василич...

Т и к ш е р ү ч е. Мөмкин түгел, бунт чыгарасың киләмени?.. Күрәсең, бөтен авыл белән саклап торалар. Кайгырма, өязгә баргач җайларбыз. Староста!

Д ә ү л и чабып керә.

Д ә ү л и. Ждич.

Т и к ш е р ү ч е *(хәзерләнеп).* Мин китәм, ике кешелек подвода бирегез.

Д ә ү л и. Ладно!.. *(Чыгып китә.)*

Т и м а й, Р а м а й, Т и м е р г а л и, Ш ә р и ф, Ф ә й з у л л а һәм б а ш к а л а р керәләр.

С а б и р. Их сез, хәерчеләр, минем өстемнән прошениеләр язып, приговорлар җыеп йөрисез!.. Моның башлыгы син, әтерәгәләм!

Р а м а й. Әйе, мин!

С а б и р. Мин сине моның өчен...

Т и м е р г а л и. Нишләрсең?!

Ф ә й з у л л а. Нишләрсең?!

Т и м а й. Нишләрсең?!!

С а б и р. Гомерегез булса, күрерсез!..

Р а м а й. Юк шул, моңа кадәр авылны үз кубызыңа биетеп килсәң дә, хәзер инде булдыра алмассың...

С а б и р. Булдырырмын, җиде кат җир астында калсам да, үземнекен итәрмен.

Р а м а й. Күрербез, анда синең үрәднигең булмас шул.

Т и к ш е р ү ч е. Ишбулдин, мин сезне кулга алам, әйдә атлагыз.

Р а м а й. Тарттыр, әйдә, тарттыр, алдыңнан артың!..

Б а ш к а л а р. Ха-ха-ха!..

Сабирлар чыгып китәләр. Рамайлар сызгырып озаталар.

*Пәрдә.*

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авансценада урам. Бер якта, икенче планда, Рамайның тәрәзәләре белән тамашачыларга карап торган иске өе күренә; икенче якта салам түбәле келәт, уртада киртә койма һәм җилкапка. Вакыт кич. Пәрдә ачылганда ачык тәрәзә аша М а һ и н ы ң шыңшып киндер сугып утырганы күренә. Сәхнәдә беркем дә юк. Еракта көтү кайткан тавышлар ишетелә. Бераздан ашыгып Г а р и ф ә керә, тәрәзә алдына туктый.

Г а р и ф ә. Исәнме, кызым!

М а һ и. Әйбәт әле, әни, әйдә, өйгә кер.

Г а р и ф ә. Кереп тормыйм, кызым, сыер савасым бар. Рамай кияү өйдәме?

М а һ и. Гобәй байларга ышна әрчергә киткән иде, никтер соңлады. Әти өйдәме?

Г а р и ф ә. Үрәдник белән авыл арасында йөриләр. Ясак түләмәүчеләрнең әйберләрен җыялар. Сезнең дә самоварыгызны язганнар иде бугай. Түләдегезме?

М а һ и. Каян аласың аны...

Гарифә. Ялгыштың шул, балам, ялгыштың... Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас дигән бабайлар... Бер бәхетең җимерелгәч, күрәләтә монысына килеп эләктең. Саварга сыерың, җигәргә атың да булмагач, тормышмыни ул?.. Самоварыгызны да алып чыксалар, нишләрсез инде?

М а һ и. Чәе булса, казаннан да эчәрбез.

Г а р и ф ә. Кемнеке — аныкы дигәндә, ояты ни тора.

М а һ и. Нишлисең бит, булмаганны каян аласың.

Г а р и ф ә. Куй инде, кызым, куй. Әхмәтша Рамае дип даны чыкканга килеп абындың. Юньле кеше булса, патша законнарына тел тидереп, бояр урманнарын талап йөрмәс иде.

М а һ и. Ярый инде, әни, өлешемә тигән көмешем, үзе егылган еламас диләр бит.

Г а р и ф ә. Менә нәрсә, кызым, хәзергә бала-чагаң да юк, әллә, мин әйтәм, аерылып кайтасыңмы, дим.

М а һ и. Әгәр дә моннан соң шундый сүзләр сөйлисе булсаң, әти шикелле син дә безнең өйгә аяк басасы булма.

Г а р и ф ә. Юк, юк, кызым, мин болай гына. Үзең теләсәң генә дигәнем иде. Мә әле, кызым, атаңнан яшереп җыйган акчам бар иде, Рамай кияүгә бирерсең, самоварыгызны йолып калыгыз.

М а һ и. Кирәкми, әни. Рамазанны ярлы дисәгез дә, кеше ярдәменә мохтаҗ түгел ул.

Бәйрәм киеменнән С а б и р күренә. М а һ и тәрәзәсен яба.

С а б и р. Нихәл син, күтәрмә борын, күк тәтәй!..

Г а р и ф ә *(салкын гына).* Әйбәт әле, әрем авыз, сыткы сагыз.

С а б и р. Кызыңның гүрничәсен карарга килдеңме? Кара, кара, күз нурыңны алмасын.

Г а р и ф ә. Мыскыл итүеңме үзеңчә?

С а б и р. Ул бит мыскылларга гына сыя торганнардан түгел, тутый кош кебек эре кыланган иде.

Г а р и ф ә. Эре булып нишләгәне бар?

С а б и р. Санатка барырдай булып масайган иде дә, булмады, ахырында җилкапкага яр булды!

Г а р и ф ә. Булса соң, нигә аңа эчең поша?

С а б и р. Кысыр аш беләнгенә торалар дип ишеттем. Тавык күзе булмасын дип кызганам.

Г а р и ф ә. Кызганма, синнән ярдәм сорарга бармаслар.

С а б и р. Син дә, мин әйтәм, чуклы кияү көткән идең, тәтемәде.

Г а р и ф ә. Аллага шөкер, ярлы булса да, менә дигән уңган егеткә юлыктык.

С а б и р. Егет уңган, сүз дә юк, тик шул кадәресе бар, ыштыр алырлык та хәле юк. Бичараның чабатасы үкчәсен кыра.

Г а р и ф ә. Ни әйтсәң дә, син түгел инде, кеше хакы ашап, нахактан яшь түктерми.

С а б и р. Ул да йөреп караган иде дә бит, булдыра алмады. Ахырында атыннан язып таякка калды.

Г а р и ф ә. Ул булдырмаса, башкалар булдырыр, кеше хакы бер тота ул.

С а б и р. Тотмас!.. Кая гына барсалар да, нинди генә җирдә булсалар да, Сабир сүзе сүз булыр.

Г а р и ф ә. Әй, синең ише котырган этне ырлатып торганчы...

С а б и р. Ачуың киләмени?..

Г а р и ф ә. Мучка, муһ-муһ-муһ!..

С а б и р. Ха-ха-ха!..

Гарифә чыгып китә. Сүгенә-сүгенә М о ч т а к керә.

М о ч т а к. Мошенник, чалмалы карак!.. Аның бит бөтен байлыгы минеке, дүрт иманамны, барлык каралтыларымны, хәтта милкемә кадәр алдап алды. Юллык акча сорап барган идем, капкасыннан да кертмәгән була, кашкорсак.

С а б и р. Берәр яры китәргә уйлыйсыңмы әллә?

М о ч т а к. Әти белән бертуган түтәйнең малайлары Оренбурда сату итәләр бит, шулар янына китәргә җыена идем, юлга акчам юк.

С а б и р. Шунлык та рәтем калмады диген, ә?

М о ч т а к. Әйе, Сабир дус, аю мае сөрткәндәй булды. Менә бүген әткәйдән калган иске дин китапларын муллага сатып эчеп бетердем. Шулай, Сабир дус, байлык та, дәүләт тә, элекке абруй да калмады, ахыргы чиктә ун ел бергә гомер иткән хатыным да ташлады. Безнең әткәйне өяздә генә түгел, бөтен губернада беренче бай санап йөрткәннәр, шунысы гаҗәп, аларның җиде бабадан бирле җыйган байлыклары миңа ун елга да җитмәде.

С а б и р. Мостафа, минем сиңа бер йомышым бар иде.

М о ч т а к. Нинди йомыш ул, Сабир дус?

С а б и р. Караңгы төшкәч, ындыр артлап кына миңа кер әле, шунда сөйләшербез.

М о ч т а к. Ярый, Сабир дус, ярый, рәтең дә булырмы?

С а б и р. Иске дус хөрмәтенә табарбыз.

Икесе ике якка китәләр. Р а м а й кайтып керә, өйдән М а һ и чыга.

М а һ и. Рамазан, нишләп болай бик боек?

Р а м а й. Арыдым, карыным ачты...

М а һ и. Хәзер бәрәңге пешә, ашарсың. Әйдә, кое суы белән

юынып җибәр, хәл керер. *(Юындыра.)* Гобәй абзыйларга онга кергән идем, булмады.

Р а м а й. Нишләп булмады?

М а һ и. Әти кушмады дип, өлкән улы бирмәде. Иртәгә ипи салырмын дигән идем, оным юк...

Р а м а й. Ярый, үзем кереп алырмын.

М а һ и. Әнә Гобәй абзый ахшамнан кайтып килә. *(Кереп китә.)*

Урамнан мәчет картлары киеменнән Г о б ә й узып бара, Рамай кычкырып туктата.

Р а м а й. Гобәйдулла абзый!..

Г о б ә й. Ни бар, энем Рамазан?

Р а м а й. Ыштанны әрчеп бетердем, төпләрен кагып, ызанга өеп куйдым.

Г о б ә й. Ярый, энем, молодец.

Р а м а й. Маһисәрвәр онга кергән икән дә, малаең бирми чыгарган.

Г о б ә й. Әйе, шулайдыр, бирмәскә үзем кушкан идем.

Р а м а й. Ни өчен?

Г о б ә й. Син кечкенә чакта әтиең, мәрхүм, әҗәткә дип бер пот он алган иде, бичара карт, тәки шуны түли алмый үлде бит.

Р а м а й. Соң?

Г о б ә й. Шул, ышна әрчегән акчаңнан шуны тотып калырга булдым.

Р а м а й. Хан заманындагы әти бирәчәген миннән аласыңмы?

Г о б ә й. Синнән алмый, кемнән алыйм? Дөньянықы дөньяда бетсен. Үлгән кешеләр гүрләрендә рәнҗеп ятмасыннар, ди хәзрәт.

Р а м а й. Ай-һай, Гобәй абзый, безнең әти бурыч түләми торган кеше түгел иде бит.

Г о б ә й. Әллә ышанмыйсыңмы?.. Бер пот он өчен иманлы авызым белән җан сатмам инде.

Р а м а й. Гобәйдулла абзый, бераз сабыр ит, күрәсең бит, быел минем начар чак. Сабир белән судлашып бернәрсәсез калдым, баш-күз алгач түләр идем.

Г о б ә й. Юк инде, энем, бик күп көттем бит, алай әрвахларны рәнҗетергә ярамый, бурыч белән дөньядан киткән кешеләр мәхшәр көнендә муеннарына бурыч такталарын тагып, оҗмах ишегеннән керә алмыйча җитмеш җиде мең ел, әлгаязы билләһи, җәһәннәм белән ике арада йөриячәкләр, ди хәзрәт.

Р а м а й. Ялганлыйсың, карт тәре!..

Г о б ә й. Нәрсә, мин ялганлыйммы?.. Тәүбә әстәгъфирулла диген!

Р а м а й. Тәүбәләрең белән нигә чәнчелеп китмисең шунда. Яхшылыкта, атна буе тамыр чапкан хакымны бирәсеңме, юкмы?!

Г о б ә й. Әй!.. Сафиулла, бире кил әле.

Б е р к е ш е керә.

Г о б ә й. Менә бу, бушбугаз, миңа ут салам дип янады. Әйдә урәдниккә, шаһит булырсың.

Р а м а й. Ах син, елан, мине урәдник белән куркытмакчы буласыңмы?!.

Г о б ә й. Караул, үтерәләр!.. *(Йөгереп китә.)*

Рамай балта белән куа башлый. М а һ и чыгып тота.

М а һ и. Рамазан, син нишлисең?

Р а м а й. Җибәр әле, җибәр, Маһи...

М а һ и. Юләрләнмә, ташла балтаңны.

Р а м а й. Маһисәрвәр, җибәр әле, үчемне алыйм, ичмасам.

М а һ и. Ярый, Рамазан, тынычлан, син акыллы бит, әйдә ашарга кер. *(Кереп китә.)*

Р а м а й *(үз-үзен өзгәләп).* Ух!.. Чәчәргә җирең, ашарга икмәгең булмасын, эшләсәң хакыңны бирмиләр. Бояр урманына керсәң, төрмәгә ябалар... Юк, юк, мин моны болай калдырмам. Мин Рамай, мин аны!.. *(Капкага барып яный.)*

Д е р ю г ин белән Д ә ү л и керә. Урамда бер читтә Гобәй карап тора.

Д е р ю г и н. Ахметшин, атаңнан калган недоимкаларыңны түләмәгән өчен сельскийлар әйберләреңне язганнар икән.

Р а м а й. Әйе, язганнар иде.

Д е р ю г и н. Почему түләмисең?

Р а м а й. Хәлем юк.

Д е р ю г и н. Бирелгән срогың тулган. Әйберләреңне алып чыгабыз, это раз. Во-вторых, казна урманыннан бүрәнә урлап тотылгач, өч тапкыр мировой судка чакырып повестка җибәргәннәр, почему бармадың?

Р а м а й. Барасым килмәде.

Д е р ю г и н. Соңгы тапкыр мировой суд заочно приговор чыгарып, бер ай ятарга, унбиш сум штраф түләргә ясаган. Менә шул решениене кул куеп ал.

Р а м а й. Беттеме?..

Д е р ю г и н. Юк әле. Нигә син Гобәй байга балта күтәреп һөҗүм ясадың?

Г о б ә й. Ут салырга янады, господин урәдник, менә шаһитым бар.

Д е р ю г и н. Өстеңнән протокол язам.

Артта тавыш, әйберләр күтәргән десятниклар белән Макар, Тимай бабай һәм башка ясакчылар керәләр.

Дерюгин. Нәрсә бар?

Макар. Бунтовать итәләр, господин урядник.

Дерюгин. Что?

Тимай. Господин үрәдник, үзем өйдә юк идем, авыру карчыгымның баш астыннан мендәрен тартып алганнар...

Дерюгин. Ну что же?.. Ни өчен недоимкаларыңны түләмисең?

Тимай. Юк бит, юк. Капка каравыллап кына тамак туйдырам. Алла биреп, игеннәр уңса, көз көне түләр идем.

Дерюгин. Быел көзгә икенче төрле ясаклар булачак. Моңа кадәр волость һәм өяз расходларын казна түләп килгән булса, бу елдан андый расходлар имана башыннан крестьяннардан алыначак.

Тимай. Патша хәзрәтләре дә инде, ата-бабаларыбыздан калган недоимкаларны түләтеп талатмаса, ярамый торгандыр шул.

Дерюгин. Что?.. Его величество государь императорга тел тидерәсең?!

Тимай. Мин аңар тел тидермим. Без аның өчен тырышабыз, аның кушканнарын үтибез. Ул да бераз гына безне җәлләсен иде. Мин Александр патшаның гвардейский полкында хезмәт итеп, сигез ел аның дворецларын сакладым. Дүрт ел төрек сугышында йөреп, бер аягымны имгәттем. Шул вакытта җыелган недоимкаларны нигә миннән ала ул?

Башкалар. Әйе, әйе, нигә бездән ала ул?..

Дерюгин. Довольно!.. Бар, кайтып кит, капкаңны каравылла.

Тимай. Кайтмыйм, мендәремне бирегез.

Дерюгин. Яхшылыкта китмәсәң, мин сине арестовать итәрмен.

Тимай. Не смиешь право, мин гвардейский солдат!..

Дерюгин. Әһә!.. Әле син шулаймы? Макар!.. Ал үзен...

Макар барып тотына.

Фәйзулла. Ни карап торасыз, җитмеш яшьлек гарип картны алалар бит.

Башкалар. Тимәгез аңа. Яхшы чакта җибәрегез...

Дерюгин. Макар, отставить!.. Староста, десятниклар, куып чыгарыгыз үзләрен.

Дәүли. Җәмәгать, аю күрдегезме әллә? Барыгыз, өйләрегезгә таралыгыз, барыгыз, бар...

Куып чыгаралар.

Д е р ю г и н. Макар!.. Староста белән өенә керегез дә самовары белән мендәрләрен алып чыгыгыз.

М а к а р. Тыңлыйм, господин урядник!

Дәүли белән кереп китәләр.

М а һ и. Рамазан, алып чыгалар бит. Нигә эндәшмисең?

Рамай һаман бер ноктага карап катып тора.

М а һ и. Менә, мә, кыз чагымдагы чулпымны бирәм, түлә үзләренә, бугазлары тыгылсын.

Р а м а й. Кирәкми, Маһи, хатын-кыз өшәнчекләре белән ясак түләү Рамай кебек егетләргә хурлык ул. *(Самовар, мендәр күтәреп чыгучы Макар белән Дәүли каршына барып баса.)* Калдырыгыз минем әйберләремне!

Д е р ю г и н. Нәрсә?..

Р а м а й. Алмагыз минем әйберләремне.

Д е р ю г и н. Нәрсә, нәрсә дисең?..

Р а м а й. Яхшы чакта алган урынына кертеп куегыз.

Д е р ю г и н. Ах син, гололобый! *(Камчы белән суга.)*

Р а м а й. Әле син шулаймы?.. *(Урядникны сугып ега.)*

Дерюгин, Макар, Дәүли, десятниклар әйберләрен ташлап йөгерәләр. Р а м а й балта белән артларыннан куа бара. М а һ и чыгып каршы төшә.

М а һ и. Рамазан, юләрләнмә, ташла балтаңны...

Р а м а й. Абзыйлар!..

Т и м а й белән ясактан т а л а н г а н к е ш е л ә р керәләр.

Р а м а й. Тимай абзый, әйберләрегезне алыгыз.

Т и м а й. Молодец, улым Рамазан, молодец. Урядник итеп сине генә куясы бар икән.

Әйберләрен алып таралалар.

М а һ и. Рамазан, син нишләдең?.. Тагын тотып ябарлар бит.

Р а м а й. Маһи, бар, әйберләрне җыйна, китәбез.

М а һ и. Кая?

Р а м а й. Тимергалиләр шахтага китәләр, алар белән без дә качабыз.

М а һ и. Качабыз? Барыбер эзләп табарлар.

Р а м а й. Тапсалар табарлар. Ләкин безгә монда торырлык калмады. Бар, җыен.

М а һ и. Ә йорт-җирләр?

Р а м а й. Әй, чәнчелеп китсеннәр... Бар, әзерлән. Мин Тимергалиләргә белешергә барам. *(Чыгып йөгерә.)*

Ерактан әкрен генә гармун уйнап килгән тавыш ишетелә.
М а һ и ялгызы.

М а һ и. Шахтага, чит-ят илләргә, тагын әллә кайларга... Туган илемнән — гомер иткән җиремнән?.. Ярабби, мин ни өчен бәхетсез булдым соң!..

Т и м е р г а л и йөгереп керә.

Т и м е р г а л и. Маһи, Рамай кайда?

М а һ и. Хәзер генә сине күрергә дип киткән иде. Нигә сорыйсың?

Т и м е р г а л и. Урядник белән Гобәй байның сөйләшкәннәрен тыңлап тордым. Рамай белән берничә кешене кулга алырга телиләр.

М а һ и. Кулга алырга?

Т и м е р г а л и. Әйе, кулга алырга. Ярдәм сорап волостька дисәтникне чаптырдылар. Хәзер үк аңа авылдан чыгып китәргә кирәк.

М а һ и. Ул үзе дә моннан китәбез дип миңа җыенырга кушкан иде.

Т и м е р г а л и. Шулаймыни?.. Ярый алайса, бар, җыен. Мин аны эзләп табармын.

Маһи өйгә кереп китә. Гармунда үзе уйнап, үзе җырлап Ш ә р и ф керә.

Ш ә р и ф.

Әнкәем мине тапкачтан
Ак биләүгә биләгән,
Ак биләүгә биләгәндә
Бәхете булсын димәгән.

Т и м е р г а л и. Нишләп болай ялгызың?

Ш ә р и ф. Иярүче юк бит, бөтен урамнар үлек чыккан йорт шикелле тын-тын. Үзең нишләп йөрисең?

Т и м е р г а л и. Рамайга килгән идем, өйдә юк икән.

Ш ә р и ф. Рамай дигәннән, урядникләрне кыйнап чыгарган ди. Шул сүз дөресме?

Т и м е р г а л и. Әйе, чыгарган. Ләкин Захарыч әйтмешли, юкка-барга кул белән уйнау дураклык кына. Бер кешенең әтәчләнүеннән илгә ни файда?

Ш ә р и ф. Файдасы юк та, кызык ич. Урядник кадәр урядникне кыйнап чыгаруның даны ни тора.

Т и м е р г а л и. Яхшы дан... Иртәгә үк килерләр дә, йорт-җирләрен сатып, ясакларын түләтерләр, үзен төрмәгә ябарлар.

Ш ә р и ф. Төрмә дигәннән, бүген Сабирның муллалардан

чыгып барганын күрдем. Исәнме, Сабир абзый, дип эндәшкән идем дә, күзенең агы белән генә карап китте.

Т и м е р г а л и. Соң ничек, бераз гына ябыкмаганмы?

Ш ә р и ф. Ябыгыр, тагын да симерә төшкән. Битенә кирпеч сылаганнармыни. Ул анда аристантларга дисәтник булып торган ди.

Т и м е р г а л и. Менә күрдеңме?.. Мескен Захарычның сүзләре алтын булганнар икән. Авыл белән тамга җыйган булдык. Приговор бирдек. Берсе дә эшкә ашмады, тишекле бер тиен кебек кайтып та килгән.

Ш ә р и ф. Гаяз әйткәндәй, карга күзен карга чукыганын каян күргәнең бар? Яманатлы гына булып калдык. Бигрәк тә безгә каныгыр инде.

Т и м е р г а л и. Ярый, Шәриф, сау бул.

Ш ә р и ф. Тукта, кая ашыгасың, сөйләшик әле.

Т и м е р г а л и. Кайтырга кирәк, таңнан юлга чыгасы бар.

Ш ә р и ф. Кая барасың?

Т и м е р г а л и. Тагын бәхет эзләргә, читкә китәргә йөрим.

Ш ә р и ф. Ни ултара, ни пултара дигәндәй, эш җиткәндә, нишләп китәсе булдың?

Т и м е р г а л и. Монда нишлим? Күрәсең, ярты авылны ясак белән таладылар... Киләсе юлга безнең әйберләрне дә яздылар. Монда җан көеге булып йөргәнче, ичмасам, бәхет табып булмасмы.

Ш ә р и ф. Әйе, мин дә китәр идем дә, өйдә кеше юк. Солдатка да караласы бар.

Т и м е р г а л и. Ярый, Шәриф, сау бул.

Ш ә р и ф. Исән бул, баеп кайтырга тырыш.

Тимергали китә. Шәриф озатып кала. Әкрен генә уйнап җырлый.

Уйныйм гармонь, җырлыйм үзем,  
Җырлыйм дусым-ишләргә,  
Эчем поша, йөрәгем яна,  
Белмим инде нишләргә.

*(Утырып, шыңшып тәмәке төрә, шырпы тартмасын алып кабызырга тели, шырпысы булмауга ачуланып тартмасын җиргә ыргыта.)* Шырпысы да юк бит, ичмасам!.. *(Гармунын алып ачу белән тартып җибәрә. Җырлап чыгып китә.)*

Үрәдникнең дугасында  
Пар кыңгырау шалтырый,  
Ул авылга килеп керсә,  
Ярлылар дер калтырый.

Ишегалды ягтан сакал-мыеклары җиткән Г а я з керә. Саклык белән килеп ишек шакылдата. М а һ и чыга.

М а һ и. Ах!.. Бу кем?..
Г а я з. Курыкма, Маһи, бу мин.
М а һ и. Гаяз?
Г а я з. Әйе, Гаяз... Шулай да таныдың.

Сүзсез аптырап торалар.

М а һ и. Ник танымаска, бер дә үзгәрмәгәнсең, тик сакал-мыеклар гына...

Г а я з. Ә син картайгансың...

М а һ и. Син киткәннән соң, авылда бик күп вакыйгалар булды... Шәйморат абзыйны алпавыт машинасы кысып имгәтте.

Г а я з. Шулай диген, Маһи...

М а һ и. Галиулла абзыйны, билән куганда, бүрәнә басып үтерде.

Г а я з. Авылда ниләр бар?

М а һ и. Син ничек монда, котылып кайттыңмы?

Г а я з. Захарыч белән Себердән качтык.

М а һ и. Алай булгач, нишләп монда йөрисең? Тотып ябарлар бит.

Г а я з. Мәскәү ягына узып барышыбыз. Сине алырга дип кергән идем, ләкин...

М а һ и. Гаяз, син миңа үпкәләмә. Рамайга да ачуланма. Ул да, мин дә гаепле түгел. Мин бөтен көчем белән тырыштым. Тик кара бәхетемне аклый алмадым. Сине алып киткәннән соң, әниең янында торырга теләдем, ирек бирми кыйнап алып кайттылар. Артыңнан Себергә китәргә булдым, сизеп алдылар да ике балалы тол иргә көчләп бирә башладылар... Менә шуннан соң Рамайга ябышып чыкмый чарам калмады.

Г а я з. Ярый, Маһи, елама... Мин барысын да ишеттем... Барысын да сораштым... *(Пауза.)* Рамай кая соң, йоклыймы?

М а һ и. Тимергалиләргә киткән иде, чакырып кайтыйммы?

Г а я з. Авырсынмасаң, чакыр. Минем аңар йомышым бар.

М а һ и. Мин хәзер кайтырмын. Син аңарчы келәткә кереп тор. Анда җәйгән урын да бар.

Г а я з. Ярый алайса. *(Келәткә кереп китә.)*

Маһи урамга чыгып югала. Икенче яктан С а б и р белән М о ч т а к керә.

М о ч т а к. Тукта әле, Сабир, ни өчен без бакча ягыннан гына дөрләтмибез.

С а б и р. Әйттем бит инде, анда салам күп, тиз күтәрелеп китәр дә, кача алмый калырсың. Әйдә, аллага тапшыр, менә бу келәт артына керәсең дә амбар астына саласың. Әйдә, тәвәккәллә, мин шушы тирәдә булырмын, курыкма.

М о ч т а к. Ярый, ләкин без исәп-хисапны бетерик әле.
С а б и р. Анысы качмас, соңыннан да алырсың.
М о ч т а к. Юк, мин алай көтәргә эшләмим хәзер.
С а б и р. Нәрсә, миңа ышанмыйсыңмы, шикләнәсең?
М о ч т а к. Ышанам, синнән шикләнергә ярыймы соң!..
С а б и р. Шулай булгач?
М о ч т а к. Һәрхәлдә, хәзер биргәнең яхшы булыр. Аннан син мине, мин сине белмим. Туп-туры Оренбурга таям.
С а б и р. Кара аны, алдарга уйлама, әҗәлең миннән булыр. *(Акча бирә.)*
М о ч т а к. Курыкма, алдамам. *(Китә.)*
С а б и р. Булды бу. Беренчедән Гобәй байдан үчемне алсам, икенчедән, ут салуны бу хәерчегә сылтарлар да, ун ел Себергә. *(Келәттә дөбердәгән тавыш ишетелә, барып тыңлый.)* Әһә... Монда йоклыйлар икән. Бигрәк тә яхшы. Ишекне бикләп алырга кирәк. *(Келәсен элә.)* Тычкан балалары шикелле чыелдашып янсыннар әле. *(Келәт артына поса.)*

Бакча ягыннан С ә е т белән С ә л ә х и керә.

С ә е т. Сәләхи, Гобәйнең кыярлары да кыярлары! Утыйк әле туйганчы.
С ә л ә х и. Безгә, малай, теге яктан кирәк иде, моннан бер дә җайлы урын юк.
С ә е т. Аннан ярамый, Гобәй байның эте сизсә, бөтен авылны җыяр. Менә моннан гына керәбез дә, кыярлар безнеке. Әйдә, чумдык.
С ә л ә х и. Әйдә, сыздык.

Китәләр. Бераздан йөгереп кире чыгалар. Рамайга очрыйлар.

С ә е т. Җизни, җизни, сезнең келәт артында бер кеше ут салып маташа!
Р а м а й. Ут салып? *(Мочтак киткән якка кереп югала.)*

Малайлар кычкырып урамга йөгерәләр.

М а л а й л а р. Ут бар!..

Р а м а й белән М о ч т а к куышып чыга. Г а я з келәт ишеген дөбердәтә.

Р а м а й. Качма, барыбер котыла алмассың. *(Сугып ега.)* Ут салучы бар!

Г а я з келәт ишеген ватып чыга.

С а б и р. Кычкырма, эт!.. *(Балта белән суга.)*

Р а м а й егыла.

Г а я з. Сабир! Кеше үтердең?
С а б и р. Каторжан?.. Әйдә, Мочтак, тот, качмасын.

Һөҗүм итәләр.

Г а я з. Ташла балтаңны, кабахәт! *(Тотып ала.)*

М о ч т а к арткы яктан килеп ябыша. Т и м е р г а л и , Ш ә р и ф һәм б а ш к а л а р керә.

Ш ә р и ф. Бу нинди эш? Нигә сугышасыз?

Аралыйлар.

Т и м е р г а л и. Тукта, бу кем?
Г а я з. Тимергали, бу мин, Гаяз.
Б а ш к а л а р. Гаяз?
Ш ә р и ф. Бусы кем? Рамай?..

М а һ и керә.

Т и м е р г а л и. Маһи, Рамайны үтергәннәр.
М а һ и. Рамайны?.. Рамазан, бәгърем...

Д ә ү л и , Д е р ю г и н керә.

Д ә ү л и. Нишләп монда җыйналдыгыз?
Д е р ю г и н. Нигә утны сүндермисез?
Ш ә р и ф. Господин урәдник, Рамайны үтергәннәр.
Д е р ю г и н. Рамайны? Кем үтерде?
С а б и р. Господин урәдник, без — Мочтак, Рамай белән өчәүләп менә бу каторжанны ут салганда тоткан идек, Рамайны балта белән сугып үтерде.
М о ч т а к. Дөрес, җәмәгать, әнә балтасы да кулында.
Д е р ю г и н. Ах син, гад!.. Каторгадан качуың гына җитмәгән, монда кайтып ут салдың, кеше үтердең?!
М а һ и. Гаяз, синме шуны эшләдең?
Г а я з. Юк, Маһи, мин түгел, алдыйлар! Мин, «ут бар», дигән тавышка келәт ишеген ватып чыкканда, алар үзләре Рамазанны үтерделәр.
М о ч т а к. Ялган! Ут салучы син...
С а б и р. Рамайны үтерүче дә син!
С ә е т. Әти, без ут салучыны күрдек.
Д ә ү л и. Күрдегез? Кем иде?
С ә е т. Ул кеше Мочтак абзыйга охшаган иде, шулай бит, Сәләхи?
С ә л ә х и. Шулай шул, әнә башында салам эшләпәсе дә бар.

Мочтак качмакчы була.

Ф ә й з у л л а. Тукта, сабыр итеп тор!

Т и м е р г а л и *(Мочтакның якасыннан алып)*. Җаның исән чакта дөресен әйт, синме салдың ул утны?

М о ч т а к. Әйе, җәмәгать, мин салдым. Ләкин мине Сабир яллады. Рамазанны балта белән сугып үтерүче дә ул үзе.

Х а л ы к. Әһә, менә ул ничек!

Д е р ю г и н. Староста! Өчесен дә тотып бәйләгез дә каравыл өенә илтеп ябыгыз.

М а һ и. Абзыйлар... Без бу кешене урядниккә генә биреп котыла алмыйбыз. Бүген алып китсәләр, иртәгесен кайтыр да башкаларыбызны үтерер, без аны үзебез хөкем итик!

Д е р ю г и н. Самосуд ясарга?..

М а һ и. Юк, бу юлы яклый алмассың!.. *(Сабирның якасына барыпябыша.)*

Д ә ү л и. Кызым, син ни эшлисең?..

М а һ и. Кит минем янымнан!.. Абзыйлар!.. Без аны үзе төрткән утка салыйк.

Ф ә й з у л л а. Дөрес, утка...

С а б и р. Николай Федорович, ходай өчен коткар!

Д е р ю г и н. Староста, нигә халыкны тыймыйсың?

Д ә ү л и. Җәмәгать, бу нишләвегез, әллә котырдыгызмы?

Т и м е р г а л и. Агайлар, ни көтеп торасыз? Маһи әйткәнчә, утка ташларга кирәк!

Д е р ю г и н. Якын килмәгез!.. *(Револьвердан ата.)*

Т и м е р г а л и. Әһә, әле син мылтык белән куркытасыңмы?

М а һ и. Абзыйлар, үзен дә утка ташларга!..

Т и м а й. Әйдә, җәһәннәм поход пошел!..

Урядникны тоталар.

Д ә ү л и. Җәмәгать алла хакына калдырыгыз, бөтен авылны харап итәсез бит!

Д е р ю г и н. Господа, Сабирны алыгыз, ради бога, мине җибәрегез.

Урядникны җибәрәләр, чукына-чукына чыгып йөгерә.

Т и м е р г а л и. Әйдә, тотыгыз!

С а б и р. Тимергали, җанкисәгем, Фәйзулла абзый...

Ф ә й з у л л а. Әйдә, җәһәннәмгә кисәү бул!..

Шашкан халык толпасы Сабирны күтәреп утка таба китәләр.

*Пәрдә.*

# ТАШКЫННАР

## Трилогия

## ШОМЛЫ КӨННӘР

### БЕРЕНЧЕ КИСӘК

*Дүрт пәрдәле драма*

Бу кисәктә катнашучылар:
Биктимер — урта хәлле крестьян.
Гөлниса — аның хатыны.
Мирвәли — аларның олы уллары, эшче.
Айсылу — аның хатыны.
Мирхәйдәр — уртанчы уллары.
Зәмзәмбану — аның хатыны.
Нургали — кече уллары.
Нурия — аның хатыны, соңыннан укытучы.
Мөршидә — кияүдәге кызлары.
Хөрмәтулла — аларның кияве, хәлле крестьян улы.
Гөлчирә — Биктимернең кече кызы.
Артамонов — күрше рус авылының аңлы кешесе, Мирвәлинең якын дусты.
Шәүлихан — нәсел-нәселдән килгән бай, старшина.
Ханзафа — аның хатыны.
Касыймхан — аларның зур уллары, сәүдәгәр.
Мирзахан — кече уллары, шәһәр мәктәбендә укучы.
Гайнавал — ярлы хатын, солдатка.
Әхтәри — авылның кара бае, староста.
Басарый — хәлле крестьян малае, авыл писаре.
Ясәви — Басарыйның туганы, Шәүлиханнарның доверенныйлары.
Самсонов — урядник.
Хәйбул — ярлы крестьян егете.
Наһар — күрше хатыны, солдатка.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Биктимер карт бакчасы. Бер якта агачлар арасында ишеге һәм берничә тәрәзәсе белән тамашачыларга таба карап торган зур гына иске өй. Икенче якта сиртмәле кое һәм арткы урамга чыга торган бәләкәй капка. Агачларда шомырт, алма, миләшләр өлгереп килә. Ачык тәрәзә аша Биктимер картның скрипка уйнап утырганы күренә. Урам яктан Мирвәли кайтып керә, моңлы скрипка тавышын ишетеп, туктап кала, тыңлый.

М и р в ә л и. Рәхмәт, әти, өздерәсең генә икән.

Б и к т и м е р *(тәрәзә төбенә таянып).* Байтактан бирле тоткан юк иде, бармаклар каткан, улым, тыңламыйлар.

М и р в ә л и. Юк, әти, бик моңлы уйныйсың. Әйдә монда, саф һавага чык. Авылга кайтканга икенче көн, рәтләп сөйләшкән дә юк.

Б и к т и м е р бакчага чыга.

Б и к т и м е р. Сөйләмә инде, улым, әле берсе, әле икенчеләре кереп бүлдерәләр, я сезне кунакка алып китәләр.

М и р в ә л и. Үзебез дә аптырадык инде. Өй борынча ашка йөртәләр. Әйтерсең хаҗдан кайтканбыз!

Зур шомырт агачы күләгәсенә палас җәеп утыралар.

Син кичә тормышыгыз турында сөйли башлаган идең.

Б и к т и м е р. Әйе, улым, җиде җанга бер имана булгач, безнең тормыш шул инде — уртакка чәчеп, кеше туйдырып ятабыз. Җәй булса — алпавыт эшеннән кайтмыйбыз, кыш булса — авыл байларының юлын таптыйбыз. Үзең уйлап кара. Мирхәйдәр өйләнгән, Нургали бүген килен төшерә, көзгә икесенең берсен башка чыгарырга кирәк. Билгеле, бер имана ашлыгы белән йорт салу түгел, эт оясы да корып булмый. Әнә тагын Гөлчирә җитеп килә, аңа да бирнәсен-мазарын әзерлисе бар.

М и р в ә л и. Әйе, әти, тормыш авыр... Бер сез генә түгел, бөтен хезмәт иясе шулай көн күрә. «Бүген үк тамагым ач, иртәгә нәрсә ашармын», дигән уй белән баш вата.

Б и к т и м е р. Сезнең кала халкының эше ул чаклы түгелдер әле, безнең крестьян хәле бик начар. Чәчим дисәң, җирең юк, эшлим дисәң, акчалы эш таба алмыйсың.

М и р в ә л и. Кала халкының хәле, әти, сезнекеннән авыррак. Эшчегә дә, крестьянга да авыр. Бөтен илгә авыр. Мәрхүм Габдулла Тукай:

«Көзге төн, мин йоклый алмыйм,
Өй түрендә җил елый,
Җил еламый, ач үлемнең
Куркусыннан ил елый», —

дип язган иде.

Б и к т и м е р. Чыннан да, улым, халык елдан-ел бөлгенлеккә төшеп, елдан-ел фәкыйрьләнә бара, шуннан котылырга бер чарасы да күренми.

М и р в ә л и. Чара бар диләр, әти. Әнә шушы көннәрдә генә Петербург, Баку эшчеләре урамнарга чыктылар. Канечкеч патшага, ерткыч палачларга каршы баррикадалар корып сугыштылар.

Б и к т и м е р. Куй, куй, улым, мондый котсыз сүзләр сөйләмә...

Урам яктан А й с ы л у кайтып керә.

А й с ы л у. Мирвәли, синең янга бер хатын килгән. Югары очтан, Бәдерниса, диме шунда.

Б и к т и м е р. Садыйк Галәвиенең хатыны, иманасын алдап алганнар иде, шул турыда киңәш сорап килгәндер.

М и р в ә л и. Шулаймы? *(Китә.)*

Б и к т и м е р. Килен, гаеп итмәсәң, мин синнән бер әйбер турында сорыйм әле... Син кайсы авылныкы буласың, килен?

А й с ы л у. Минем авылым моннан ерак. Казан артында.

Б и к т и м е р. Мин сине, килен, бик ошаттым, акыллы бала булырга охшыйсың... Кара әле, килен, өченче ел Мирвәлине төрмәдә утырган дип ишеткән идек. Шул турыда берничә кат хат белән дә сорап карадык, җавап язмадыгыз. Дөрес булды, ахры?

А й с ы л у. Әйе, әти, дөрес, өч айга якын утырып кайтты. Ул турыда мин үзем дә сезнең белән сөйләшергә йөри идем, башлап әйтеп яхшы иттегез.

Б и к т и м е р. Берәр нәрсә урлаган идеме, әллә кеше кыйнау өченме?

А й с ы л у. Өченче ел Себердә бик күп эшчеләрне аттылар. Шуларны яклап безнең завод халкы да эш ташлады. Шунда безнең Мирвәли дә эшчеләрне оештырып йөргән иде.

Б и к т и м е р. Эш ташлаган өчен генә төрмәгә ябалармы?

А й с ы л у. Бик зур эш бит ул, әти. Эш ташлау белән генә калсалар, бер хәл иде дә, байраклар күтәреп, урамнарга чыктылар. Базар мәйданында собрание ясап, патшаны, түрәләрне сүктеләр.

Б и к т и м е р. Менә ул ничек!

А й с ы л у. Икенче көнне Мирвәлине кулга алдылар, өч ай тулганда гына өйгә кайтты.

Б и к т и м е р. Ах, башсыз, башсыз, ни дип шундый эшкә катнашырга кирәк? Төрмәдә акылга утыртканнардыр, инде хәзер, шаять, йөрми торгандыр?

А й с ы л у. Йөри, әткәй, һаман ташлаганы юк. Кайвакытларда яшерен собраниеләргә китеп, берәр тәүлек югалып йөри. Бу эшең ярамый дип ачулансаң, юләр кеше шикелле, көлә генә. Ичмасам, сез үгетләр идегез. Бик хәтәр эш бит ул. Быел да берничә иптәшен Себергә сөрделәр.

Б и к т и м е р. Солдатта, Япон сугышында да нидер буталып йөргән иде, һаман ташламый икән. Үзе белән яхшылап сөйләшергә туры килер. «Кемнеке — аныкы» дигәндәй, Алла сакласын, йөзгә оят китерүе бар.

З ә м з ә м б а н у *(башын тәрәзәдән сузып).* Җиңги, мичең булып бетте инде, әңгәмәңне соңыннан сатарсың.

А й с ы л у. Хәзер, килендәш. *(Кереп китә.)*

Б и к т и м е р. Гаҗәп, искитәрлек гаҗәп... Патшаны һәм аның түрәләрен?.. Тфү, тфү, әйттем исә кайттым. Мондый сүзләрне сөйләү түгел, уйлавы да куркыныч. *(Тәрәзә төбеннән скрипкасын алып, кылларын тартып карый.)* Кыллар дымланган, җил-давыл булыр, ахры...

Бакча ягыннан, чиләк белән бәрәңге күтәреп, Г ө л н и с а керә.

Г ө л н и с а. Сиңа, картлач, бүген ни булды? Иртәдән бирле шул каз муеның белән булашасың.

Б и к т и м е р. Әллә нишләп, карчык, эч поша.

Г ө л н и с а. Эшсез торгангадыр. Юкса нәрсәгә? Аллага шөкер, үзебез исән-сау, тормышыбыз тигез, балалар да яныбызда.

Б и к т и м е р. Анысы шулай, тик менә, давыл сизгән ат кебек, йөрәк никтер тынычсыз.

Г ө л н и с а. Юк-барларны уйлап шомланма, әнә Шәүлиханнарга барып кайт, йөрәгең басылыр. *(Коедан су ала.)*

Б и к т и м е р. Анда ни калган?

Г ө л н и с а. Яшьләр алдына куярга әйберләребез җитешми.

Б и к т и м е р. Ә акча?

Г ө л н и с а. Көтәргә, бурычка сорарсың.

Б и к т и м е р. Муеннан баттык бит инде, анасы.

Г ө л н и с а. Бушлай сорамыйбыз ла, балалар исән булсалар, эшләп түләрләр. Күрәсең, урак җитте, башлап сезнең ашлыкларга төшәрбез, диең.

Б и к т и м е р. Ай бу Нургалине, вакытсыз өйләнеп бөлдерде бит атасын. Авызың ачсаң, үпкәң күренергә торганда, тот та кыз чыгарып ал, имеш, дурак.

Г ө л н и с а. Солдат акылы төштән соң, диләр, бик дөрес. Я, нишлисең?

Б и к т и м е р. Барырга туры килер, кеше арасында сынатырга ярамас. Малайның да хәтере калмасын. Яшьлек гомере бер генә килә. Их, Гөлниса, безнең дә яшь чаклар бар иде, мин әйтәм. Хәтереңдәме, беренче кат кияү булып кергәндә, билбау очын таба алмый интеккән идең.

Г ө л н и с а. Әллә тагын, хәтерләмим.

Б и к т и м е р. Кара инде, оныттың дамыни?

Г ө л н и с а. Онытырсың да, утыз алты ел бит аңар.

Б и к т и м е р. Ә менә мин онытмыйм, бүгенгедәй исемдә. Икебезне генә аулак өйгә ябып куйдылар... Син, боеккан болан баласы төсле, чаршау эченнән чыктың да, исән килдеңме, дип

кул очыңны гына биреп күрештең. Аннан өстемне, аннан аягымны салдырдың. Аннан кара-каршы утырып чәй эчтек...

Г ө л н и с а. Хи-хи-хи, карт юләр... Олыгайганчы акыл кермәде.

Б и к т и м е р. Шундый матур чаклар, искән җилдәй, үттеләр дә киттеләр. Сизми дә калдык. Ярый әле нужа белән торсак та, әйбәт гомер кичердек. Балалардан да уңдык: берсеннән-берсе чибәрләр, берсеннән-берсе акыллылар. Бигрәк тә Мирвәли белән Нургалине урыс авылында укытып яхшы иттек. Шул чагында кара уйлы кешеләр: «Балаларын урыс итә инде», — дип сөйләгәннәр иде, бер дә алай булмады. Бар да хәзер киңәш сорап Мирвәлигә киләләр. Нургали дә молодис, унтер-әфичәр булып кайтты бит. Ул урамнан үтеп китсә, бөтен авыл белән артыннан карап калалар. Өч малай, өчесе дә солдат.

Г ө л н и с а. Солдат булулары белән мактанасың юк инде.

Б и к т и м е р. Юк, мактанам. Үзем дә солдат, малайларым да солдат. Солдатка егетләрнең каймакларын гына алалар.

Г ө л н и с а. Шул солдат турында сүз чыкса, дөньяңны онытасың, йомышыңа бар инде.

Б и к т и м е р. Әйе шул, нәрсә алырга дидең әле?

Г ө л н и с а. Бер кадак кызыл билле прәннек, бер кадак кәнфит. Бавырсак пешерергә бер биш кадак ак он сорарсың, аннан, чәйшикәр дә беткән. Бер кадак шикәр белән ярты такта чәй дә алырсың.

Б и к т и м е р. Ярый, мин киттем. *(Китә.)*

Өйдән З ә м з ә м б а н у чыга.

З ә м з ә м б а н у. Әнкәй, иртәнгә коймакны нинди оннан изәрбез икән?

Г ө л н и с а. Нинди он дип, ару оныбыз бер генә, солыдан изәрсең.

З ә м з ә м б а н у. Бер-ике коймакка бодай оныбыз да җитәрлек әле.

Г ө л н и с а. Аны урак өстендә токмачка тотарбыз. Кара әле, килен, истә чакта әйтеп куйыйм. Бүген яшь килен төшкәч, урыныгызны бәләкәй якка җәярсез инде.

З ә м з ә м б а н у. Анда бик эссе була бит, әнкәй.

Г ө л н и с а. Эссе булса, тәрәзәләрен ачарсыз.

З ә м з ә м б а н у. Җитмәсә тагын чебене, тараканы күп.

Г ө л н и с а. Анысы үзеңнән, өйне чиста тотмыйсың. Син килгәнче безнең өйдә андый хәшәрәтләрнең булганы юк иде.

З ә м з ә м б а н у. Шулай инде ул, килен салмасы килбәтсез була.

Г ө л н и с а. Бар, буш чагыңда чоланыңны юып куй.

З ә м з ә м б а н у. Юк инде, яшь килен төшә дип, биш ел яткан чоланымны бирер хәлем юк.

Г ө л н и с а. Алай кыланма, яшьләргә кадер-хөрмәт күрсәтү ата-бабадан калган йола бит.

З ә м з ә м б а н у. Кадер-хөрмәт күрсәтәсегез килсә, үз яныгызга — түргә яткырыгыз. Я әнә печәнлеккә менсеннәр, анда тынычрак булыр. Адәм рәтле кешеләр башта йорт салалар, аннан улларын өйләндерәләр.

Г ө л н и с а. Шулай кирәк иде дә, без картларны көтеп тормыйсыз, матур улларымны күрүгә күзегез тона,ябышасыз да чыгасыз. Үч иткәндәй, өч килен өчегез дә ябышып килдегез.

Зәмзәмбану китә. Г а й н а в а л керә.

Г а й н а в а л. Саумы, Гөлнисаттәй.

Г ө л н и с а. Шөкер әле, Гайниҗамал, ни эшләр бетереп йөрисең?

Г а й н а в а л. Әманәт белән кергән идем. Өебезне бикләп, күрше алпавытка уракка барабыз, безнең йортка күз-колак булмассыз микән?

Г ө л н и с а. Озаккамы?

Г а й н а в а л. Сабан урагына кадәр кайтмыйбыз инде.

Г ө л н и с а. Үз урагыгыз бер дә юкмыни соң?

Г а й н а в а л. Бер каттан гына чәчкән ярты бавыбыз бар иде, уңмаган, урак тыгарлык түгел, алабута белән билчән каплаган.

Г ө л н и с а. Эш өстендә авылда да эш күп булыр, йортыгызны ташлап китмәскә иде, уты-күзе бар дигәндәй.

Г а й н а в а л. Аптыраган инде. Авылда эшләсәң, кулга акчасы тими, товар алдырыш теңкәгә тияләр. Алпавытта арзанрак булса да, акчалата бирә. Аннан, аларның дисәтинәләре дә, безнең авыл байларыныкы кебек, торымнан-торымга түгел, сажин белән үлчәп бирәләр. Кышка ашарлык, өс-баш ясарлык акча алып кайтыш булмасмы диюебез иде.

Г ө л н и с а. Ярый, мин уракка йөрмим, караштырырмын.

Г а й н а в а л. Тәрәзә, ишекләрен такта белән кадакладык, искәрә торыгыз. Бала-чага пыяласын ватмасын. Менә ачкычы, ара-тирә кергәләп карарсың. Хуш.

Г ө л н и с а. Хуш, баеп кайтыгыз.

Г а й н а в а л. Шулай булсын, амин. *(Китә.)*

Русча шыңшып, улан киеменнән Н у р г а л и керә.

Н у р г а л и. Анайка, анайка!

Г ө л н и с а. Бәлеш, нигә кайттың, улым Нургали?

Н у р г а л и. Чәкчәк ашына егетләрне чакырып йөрим.

Г ө л н и с а. Соң ничек, бар да киләме?

Н у р г а л и. Киләләр. Бурган Хантимировны гына туры китерә алмадым.

Г ө л н и с а. Нинди Бурган? Безнең авылда андый кеше юк иде ләбаса.

Н у р г а л и. Ну, сезнеңчә — Борһан Хантимер малае.

Г ө л н и с а. Шулай диген, улым, үзебезчә генә сөйлә. Әтиең, Шәүлихан Мирзаханы белән Ходаяр шәкертне дә чакырыйк, дигән иде.

Н у р г а л и. Кирәкми, алар безгә килмәсләр.

Г ө л н и с а. Килмәсәләр, үзләрендә калыр. Чакырмыйча ярамый, берсе мәхдүм, икенчесе старшина малае. Йомышыбыз төшсә, шуларга барабыз. Аннан, андый кешеләрнең чәкчәк төшеме дә мул була.

Н у р г а л и. Яратмыйм шул мулла-байга баруны. Ну, ярый, мин пошел.

Г ө л н и с а. Улым, бу солдат киемнәреңне салсаң да ярар иде. Бердән, үзеңә эссе, икенчедән, унбиш көннән бирле капран солдат булып йөрүеңне яратмыйм.

Н у р г а л и. Ничего, вакыты җиткәч салырбыз әле. Ярый, мин опять пошел. *(Китә.)*

Г ө л ч и р ә кайтып керә.

Г ө л ч и р ә. Әни, иптәш кызларымның һәммәсен дә чакырдым. Бар да килергә булдылар.

Г ө л н и с а. Бик әйбәт булган, кызым.

З ә м з ә м б а н у керә.

З ә м з ә м б а н у. Әнкәй, әллә нишләп маем атланмый.

Г ө л н и с а. Салкын су сибәргә иде.

З ә м з ә м б а н у. Сиптем, төртенгән шикелле, күбекләнеп тик йөри. Яза-яза кулбашларым калмады.

Г ө л н и с а. Әй Алла, шуны да кеше төсле эшли алмыйсың. *(Китә.)*

Г ө л ч и р ә. Җиңги, кил әле. Берәүгә дә әйтмәскә дип сүз бирсәң, үзеңә бер сер сөйлим.

З ә м з ә м б а н у. Юк, юк, Аллам сакласын, миннән сер чыгамы соң?

Г ө л ч и р ә. Кызларны чакырып кайтканда су аша чыга идем, басма өстендә Мирзахан абый очрады. «Нихәл, гүзәл Гөлчирә?» — дигән була. Бик әйбәт әле, Мирзахан абый, дим.

З ә м з ә м б а н у. Ул анда нишләп йөри, әллә балык тотарга төшкәнме?

Г ө л ч и р ә. Белмим. Шуннан, бу кулымнан тотып алды да: «Мин синең шушы кара күзләреңне яратам», — ди.

З ә м з ә м б а н у. Булмас ла!

Г ө л ч и р ә. Ихлас әгәр.

З ә м з ә м б а н у. Шуннан? Шуннан?

Г ө л ч и р ә. Җибәр, Мирзахан абый, дим. Җибәрми. Кит басмадан, дим, юл бирми. Аптырагач, бар көчемә этеп җибәргән идем, аяк-кулларын бутап, суга төште дә китте.

З ә м з ә м б а н у. Ничек, киемнәре беләнме?

Г ө л ч и р ә. Әйе. Шуннан мин басмадан чыгып йөгердем дә яр башына мендем. Әйләнеп карасам, ни күзләрем белән күрим, судан чыккан да, кулларын салындырып карачкыдай басып тик тора. Бөтен җиреннән шыбырдап су ага.

З ә м з ә м б а н у. Әй чырсыз, чырсыз, харап иткәнсең бит.

Г ө л ч и р ә. Итсә, тотынмасын. Нигә юлымны бүлә?

З ә м з ә м б а н у. Димәк, ул сине сөя.

Г ө л ч и р ә. Сөя?

З ә м з ә м б а н у. Әйе, сөя. Мин дә синең шаян күзләреңне ошатам, дияргә иде.

Г ө л ч и р ә. Оялмыйчамы?

З ә м з ә м б а н у. Үзе килеп сүз кушкач, нигә оялырга? Үзе бай, үзе укыган, үзе чибәр. Егетне ычкындыргансың.

Г ө л ч и р ә. Мирхәйдәр абый печәннән кайтты. *(Китә.)*

Чалгы тотып М и р х ә й д ә р керә.

М и р х ә й д ә р. Уф, арыдым.

З ә м з ә м б а н у. Йөрисең шунда, башкалар туй итә, ә син кеше камыты киясең.

М и р х ә й д ә р. Нишләп турсайдың?

З ә м з ә м б а н у. Турсаю гына түгел, бурсаерсың да. Бу йортта синең белән миңа сан бармыни?

М и р х ә й д ә р. Тагын тавыш чыгардың?

З ә м з ә м б а н у. Кунак хөрмәтенә түздем әле, чыдадым. Әмма мин аны барыбер калдырмыйм. Имеш, икегез дә бер чыбыктан сөрелгән, эш рәте белмисез дигән була.

М и р х ә й д ә р. Кем?

З ә м з ә м б а н у. Билгеле инде, анаң! Бүгенге аш-суларны миннән алып Айсылу җиңгигә биргән булды. Әйтерсең мин әзерли белмим, әйеме?

М и р х ә й д ә р. Ансы дөрес инде, аш-су әзерләргә килгәндә, синең осталык чамалы. Сабан туенда пешергән бәлешләрең дә көеп, тишелеп беткән иде. Айсылу җиңги дөнья күргән, кала хатыны, алар аш-суга оста булалар.

З ә м з ә м б а н у. Синең шул булыр инде. Өч тиенлек кадерең булмаса да, анаң җырын җырларсың. Менә шуның өчен дә мине кагалар, кыерсыталар.

М и р х ә й д ә р. Ай-һай, ирек бирерсең микән?

З ә м з ә м б а н у. Кагуның, читләтүнең ар ягына чыктылар, яшь килен төшкәч, тагын да көн булмас. Әнә инде бүгеннән үк бәләкәй якка ятарга куштылар.

М и р х ә й д ә р. Йокларга булгач, барыбер түгелмени?

З ә м з ә м б а н у. Әй Ходаем, кеше ире төсле гарьләнә дә белмисең, ичмасам. Җиләк кебек яшь чакларым шушы мүкләк белән үтә бит.

М и р х ә й д ә р. Ярый, ярый, тиле дигән саен, тигәнәк буе сикермә. Кое суы салып бир, юынып алырга кирәк.

Газета тотып М и р в ә л и керә. Зәмзәмбану китә.

М и р в ә л и. Нихәл, энекәш Мирхәйдәр?

М и р х ә й д ә р. Бик әйбәт, абый. Үзең нихәл соң?

М и р в ә л и. Бер көе генә. Печән чабу арытмадымы?

М и р х ә й д ә р. Бераз булды инде, абый. Быел печән шулкадәр уңган, каерып алгысыз. Бүген кояшы бик эссе иде, шуның өстенә, үч иткәндәй, тозлаган иттән аш пешергәннәр, тамак кибеп аптыратты.

М и р в ә л и. Шәүлихан малайлары тәкә суеп сыйласалар, байлыклары кимер иде микәнни?

М и р х ә й д ә р. Аналары бик саран бит аларның, тәкә сую түгел, шикәрне дә шакмаклап кына бирә. Әйләнеп тә карамас идем, абый, кыш көне бер чана печән алган идек, шуның өчен ике десятинә чабарга туры килде.

М и р в ә л и. Кышын тагын шуларга барасыз инде.

М и р х ә й д ә р. Үз болының булмагач, билгеле, шулай. Бөтен Идел буе шулар кулында бит. *(Як-ягына каранып кесәсеннән бер ярты аракы чыгара. Чашкага салып Мирвәлигә суза.)* Абый, әтиләр күргәнче тот әле.

М и р в ә л и. Кирәкмәс иде, энекәш. Арыган кеше —үзең эч...

М и р х ә й д ә р. Икебезгә дә җитәрлек, әйдә, тот.

Б и к т и м е р керә. Карап тора.

М и р в ә л и. Ярый алайса, синең исәнлеккә, энекәш.

М и р х ә й д ә р. Сау бул, абый.

Б и к т и м е р. Айт, мошенниклар! Аталарыннан яшереп эчәләр. Кая, балалар, миңа да өлеш чыгарыгыз әле. *(Араларына кереп утыра.)*

М и р в ә л и. Әти, синең белән безгә уңайсыз булыр.

Б и к т и м е р. Зарар юк, бик уңайлы булыр.

Биктимергә дә салып бирәләр.

М и р в ә л и. Ярый алайса, исәнлеккә-саулыкка, әти.
М и р х ә й д ә р. Байлык белән муллыкка, әти.
Б и к т и м е р. Шулай булсын, балалар, амин!

Эчәләр. Н у р г а л и керә, аларга карап, мыегын бөтереп тора.

Н у р г а л и. Әти, алпавыт Твардовский: «Крестьяннар белән эчәсең, взятка аласың», — дип, урман каравылчысын чыгарган. Мине үзенә каравылчы итеп алмасмы икән?

Б и к т и м е р. Ник алмасын, улым, бик алыр. Үзең атлы - солдат, бераз укымышың да бар, минемчә, берсүзсез алыр. Кара әле, каян уйлап чыгардың, бик акыллы киңәш бу, каравылчы булып алсаң, утынын да буш ягар идек. Ара-тирә бүрәнәсен дә тарттырырга була. Минем Твардовский белән танышлык та бар, сөйләшеп карыйм әле.

М и р в ә л и. Кирәкми, әти, пычранма. Урман каравылчысы булу бик начар хезмәт ул. Крестьяннарның тиресен тунарга, атлаган саен крестьян өстеннән протокол язарга, авыл саен тентү ясап, алпавыт эте булып йөрергә безнең өчен ярамас.

Н у р г а л и. Әгәр дә мин аларның берсен дә эшләмәсәм?

М и р в ә л и. Ул чагында сине алпавыт өч көн дә тотмый, әнә, теге каравылчысын кугандай, куа да чыгара. Кирәкми, Нургали, «Биктимер малае шулай эшләде», — дип халык еларлык булмасын.

М и р х ә й д ә р. Абый дөрес әйтә, пычранма, Нургали, авыл белән яманатлы гына булып бетәрсең.

Н у р г а л и. Соң бит миңа нәрсә булса да эшләргә кирәк? Җир юк...

М и р в ә л и. Минем белән заводка китәрсең.

Тәрәзәдә Г ө л н и с а күренә.

Г ө л н и с а. Улым, Нургали, кайнешең килгән, ашка сине көтәләр икән.

Н у р г а л и. Шулаймы? Мин киттем, әни. *(Китә.)*

Г ө л н и с а. Карт, өйгә кер әле. *(Биктимер китә.)*

М и р х ә й д ә р. Абый, Нургалине заводка дигәннән, миңа да шунда берәр урын булмасмы? Туйдым мин бу авылдан. Крестьян булып чәчәргә җирең, ашарга ипиең булмасын, имеш. Юньле кием күрмисең.

М и р в ә л и. Заводта да, энем, эшләр шәптән түгел бит. Һәр көнне меңләгән кешеләр авыллардан киләләр дә завод капка төпләрендә тезелеп торалар, узган-барган мастерлардан, начальстволардан ялынып эш сорыйлар. Нургалине урнаштыру җиңелрәк, чөнки ул яңа гына хезмәттән кайткан, солдатларны беренче чиратта алалар. Шулай да мин, белеш-танышлар белән сөйләшеп, көзгә сине дә берәр цехка урнаштырырга карармын.

Артта кыңгырау тавышы.

Болар кемнәр, безгә түгелме?

М и р х ә й д ә р. Безгә шул. Мөршидә белән Хөрмәтулла кияүләр! *(Китә.)*

Өйдән Б и к т и м е р белән Г ө л н и с а чыга да кунак каршыларга китәләр. М ө р ш и д ә керә.

М ө р ш и д ә. Абый...

М и р в ә л и. Саумы, Мөршидә?

М ө р ш и д ә. Абый, абыкаем. *(Елый.)*

М и р в ә л и. Тукта, сиңа ни булды?

М ө р ш и д ә. Күңелем тулды. Синең белән күрешмәгәнгә сигез ел тула бит, абый.

М и р в ә л и. Әйе, Мөршидә, син ул чагында чандыр гына матур кыз идең. Ә хәзер юанаеп киткәнсең. Йә, тормышың ничек?

М ө р ш и д ә. Аллага шөкер, абый, тормышыбыз түгәрәк, күңелебез күбәләк, дөньябыз тигез, бәхетебез игез дигәндәй, дөбердәтеп гомер итәбез. Өченче ел гына, яңа йорт җиткереп, башка чыктык. Ике атыбыз, ике сыерыбыз, уналты баш сарыгыбыз бар. Кияүдән дә бик уңдым. Ашамый-эчми, ормый-сукмый, яман телле, каты сүзле түгел. Үзе эш сөючән, байлык өчен көючән. Быел өч оя тавык, ике оя үрдәк, бер оя каз утырткан идем. Бибиләрем-чебиләрем ишегалды тутырып йөриләр.

М и р в ә л и. Балаларың ничәү?

М ө р ш и д ә. Ике улыбыз, бер кызыбыз бар. Олы улыбыз быел тырмага йөрде.

М и р в ә л и. Ярый, ярый, Мөршидә, тормышың зарланырлык түгел алайса.

М ө р ш и д ә. Юк, биргәненә мең шөкер, абый. Тик менә син генә безне ташладың. Шулай итеп, гомергә кара эшче булып калырсың микәнни?

М и р в ә л и. Шулай, сеңелем.

М ө р ш и д ә. Безне, туган илеңне бер дә сагынмыйсыңмы?

М и р в ә л и. «Туган илгә караганда туйган җир якын», дигән бабайлар.

М ө р ш и д ә. Анысы шулай инде, абый.

Х ө р м ә т у л л а керә.

Менә, киявегез Хөрмәтулла шул була инде, абый.

М и р в ә л и. Саумы, кияү?

Х ө р м ә т у л л а. Бик яхшы, каенагай, бер дә үзгәрмәгәнсең.

М и р в ә л и. Тукта әле, тукта, мин сине таныган кебек булам, кем дияргә белмим.

Х ө р м ә т у л л а. Яхшырак уйлап кара, танырсың.

М и р в ә л и. Бер дә хәтерләмим.

Х ө р м ә т у л л а. Солдатка алынган елыңда безнең күршебез Камал абзыйларга кунакка килгән идең. Мин ул чакта уналты яшьлек малай гына идем. Исеңдәдер, мин сине Камилә түтәй янына кунарга керткән идем. Әти сизеп алды да пыр-р туздырып куып чыгарды.

М и р в ә л и. Ха-ха-ха... Әйе, әйе, картлач башымнан бүрегемне алып калган иде. Икенче көнне китәргә ат җиккәч кергән: «Мә, энем, уңган егет бүрек ташлап йөгерми», — дигән була, үзе көлә. Мәзәк карт иде, исәнме әле?

Х ө р м ә т у л л а. Күптән юк инде, мин солдатта чакта үлде.

М и р в ә л и. Син дә солдатмыни?

Х ө р м ә т у л л а. Так точно, солдат. Аршауда хезмәт иттем. Бер елдан җирәбә белән кайттым.

М ө р ш и д ә. Абый, иртәнге чәйдән безгә кунакка китәбез.

М и р в ә л и. Сезнең авыл уракка төшкән диләр түгелме соң?

Х ө р м ә т у л л а. Юк әле, ярлы-ябагай шунда ашар өчен генә урып маташа. Китәбез, каенагай.

М и р в ә л и. Белмим шул, кеше урак урганда, кунак булып яту килешер микән соң?

М ө р ш и д ә. Юк, юк, абый, кысыр сарык суеп кунак итәрбез.

Г ө л н и с а керә.

Г ө л н и с а. Улым, Мирвәли, Гриша дигән иптәшең килгән.

М и р в ә л и. Нинди Гриша?

Г ө л н и с а. Спас авылыннан, солдатта бергә хезмәт иткән Гришаң.

М и р в ә л и. Артамонов? *(Китә.)*

Г ө л н и с а. Кияү, кызым Мөршидә, әйдәгез чәйгә, аннан килен каршылыйсы бар.

М ө р ш и д ә. Нинди килен?

Г ө л н и с а. Ашыгыч булганга, сезгә хәбәр итә алмадык. Нургали өйләнде.

Х ө р м ә т у л л а. Нургали өйләнде? Кемгә?

Г ө л н и с а. Әхтәри старостаның Нуриясен чыгарып алды.

М ө р ш и д ә. Тукта әле, әни, үзең чыгарып алды дисең, үзең килен каршылыйсы бар дисең.

Г ө л н и с а. Ул бик кызык булды инде, кызым. Әхтәри, кызының Нургали белән шаярганын сизгән дә, тиз генә, итче Муса малаена бирергә булган. Кыз, беләсез, шәһәрдә кызлар мәктәбендә укыган. Аптырап калмаган, өченчекөн, ятарга торганда гына, әйберләрен күтәреп, безгә килеп кермәсенме?

Х ө р м ә т у л л а. Менә сиңа кирәк булса!

М ө р ш и д ә. Я, я, әни?

Г ө л н и с а. Аның артыннан ата-аналары килеп җиттеләр. Кызны алып китәргә телиләр, кыз якын да килми, Нургалигә сыткы сагызы кебек ябышкан.

Х ө р м ә т у л л а. Афәрин, уңган кыз икән.

Г ө л н и с а. Шуннан, усаллык белән булмагач: «Без сезгә бирергә каршы түгел, тик, зинһар, кеше арасында хурлыкка калдырмагыз, туй ясап, үз өебездә никах укытып бирик», — дип, ялынып сорагач, Нургалине көндердек. Кичә туй кисәге ясаган булып, Нургалине кыз куенына озаттык. Бүген килен көтәбез.

М ө р ш и д ә. Әхтәри хатыны кызына тиң таба алмый йөри дигәннәр иде, борыны төшкән икән алайса, хи-хи-хи...

Х ө р м ә т у л л а. Безнең каениш бит ул кызлар күзе төшәрлек егет, үзе улан, үзе унтер-офицер!

Керел китәләр. Өйдән З ә м з ә м б а н у белән Г ө л ч и р ә чыгып, шомырт агачы астына табын әзерлиләр.

З ә м з ә м б а н у. Гөлчирә, Нургали абыең чәкчәк ашына Мирзаханны да чакырган.

Г ө л ч и р ә. Чакырса, бик әйбәт булган.

З ә м з ә м б а н у. Мин дә шулай дим, кош теледәй хат кисәге язып куй, бирермен.

Г ө л ч и р ә. Аллам сакласын, егетләргә хат язаммы соң!

З ә м з ә м б а н у. Нигә язмаска? Үзе сиңа гашыйк булган бит. Кара аны, кулыңа эләккән бәхетне ычкындырма.

Г ө л ч и р ә. Юк, язмыйм, башта үзе язса икән, анда күз күрер иде.

З ә м з ә м б а н у. Йә, ярый алайса, телдән генә әйтермен.

Г ө л ч и р ә. Әйтмә, җиңги, кирәкми.

К ы з л а р керә, бер бала йөгереп уза.

Б а л а. Килен төшә, килен!..

Ишегалдына хатын-кызлар, балалар кереп тулалар, өйдән А й с ы л у , М ө р ш и д ә йөгереп чыгып, урамга узалар. Н у р г а л и керә, капка төбендәге балаларга, хатын-кызларга прәнник, конфет сибеп югала. Н у р и я н е ике ягыннан култыклап, А й с ы л у белән З ә м з ә м б а н у керә. Гөлниса, өйдән чыгып, өйалдына палас җәя, кулындагы ике җамаяктан бал белән май каптыра.

Г ө л н и с а. Әйдә, килен, әйдә, төкле аягың белән.

Кереп китәләр. А р т а м о н о в белән М и р в ә л и керә.

А р т а м о н о в. Америка страховой обществосында, Зингер компаниясендә агент булып хезмәт итәм. Полиция рөхсәтеннән башка өч көнлек юлга да чыга алмыйча, күзәтү астында торам.

М и р в ә л и. Күзәтү астында? Нәрсә өчен?

А р т а м о н о в. Үткән елны Шакир хаҗи белән урман кисүчеләр арасында зур конфликт чыккан иде, мин анда конторщик булып эшли идем. Крестьянны беләсең, үзенчә эшләргә ярата. Башта подрядчикны, соңыннан становой приставны кыйнадылар. Шул эшне миннән күрделәр. Чепуха, конечно. Димәк, син кунакка кайттың?

М и р в ә л и. Безнең завод, хәрби заказларны эшләүгә күчү уңае белән, зур ремонтка туктады. Эшчеләрне унбишәр көнгә прогулкага чыгардылар. Шул уңайдан файдаланып, әти белән әнине, туганнарны күрергә кайттым.

А р т а м о н о в. Хәрби заказлар дигәннән... газеталарда бик күңелсез хәбәрләр язалар.

М и р в ә л и. Әйе, Гриша, сугыш куркынычы көннән-көн үсә, Франция президенты Пуанкареның Петербургта рус гаскәрләренең парадын кабул итүе тикмәгә генә түгел. Бу, әлбәттә, бик күп серләр белән бәйләнгән.

Өйдән, көянтә-чиләк күтәреп, Н у р и я һәм аны чолгап алган к ы з л а р чыга. Шаулашып яшь киленгә су юлы күрсәтергә китәләр. Н у р г а л и белән М и р з а х а н керә.

Н у р г а л и. Пожалыста, Мирзахан әфәнде, рәхим итегез.

М и р з а х а н. Исәнме, Мирвәли абый?

М и р в ә л и. Бик яхшы, Мирзахан.

М и р з а х а н. Нихәл син, ходатай?

А р т а м о н о в. Бик әйбәт әле, барчук...

М и р в ә л и. Я, Мирзахан, бик шәп байыйсызмы?

М и р з а х а н. Эшебез яхшы, быел безгә Мәскәү фирмалары ун мең кредит бирделәр.

М и р в ә л и. Оһо... Димәк, сез эшне эредән йөртә башлагансыз.

А р т а м о н о в. Аларның эше шәп... Аталары старшина, уллары коммерсантлар.

Б е р н и ч ә е г е т белән Х ә й б у л керә.

М и р в ә л и. Кодалар, рәхим итегез.
Х ә й б у л. Карт анабыз кара туфрак,
Байлык бирсен кода йортына,
Безнең аймак сәлам диде
Сезнең якның яше-картына.
М и р в ә л и. Алып куенга биргән сәламнәрен,
Түрдән узсын кода илчесе,
Сый-хөрмәттән тәмләп авыз итсен,
Кардәш-ыруг, туган, димчесе!
Х ә й б у л. Рәхмәт, Мирвәли абый, ничә еллар зимагурда йөрсәң дә, гореф-гадәтләрне онытмагансың.
М и р в ә л и. Яшьлек белән үзләштерелгән йола онытылмый икән ул, кодалар.

Н у р и я белән к ы з л а р судан кайтып керәләр.

Х ә й б у л. Янтык басма, абынма,
Як-ягыңа салынма,
Атла туры кыл кебек,
Эшлә йортка кол кебек!

Кызлар кереп китәләр.

Н у р г а л и. Әйдәгез, егетләр, прошу, менә моннан узыгыз.

Утырышалар.

М и р х ә й д ә р. Кысылыбрак, егетләр, кысылыбрак.

Б а с а р ы й белән Я с ә в и керә.

Б а с а р ы й. Әссәламегаләйкем.
Х ө р м ә т у л л а. Вәгаләйкемәссәлам.
Я с ә в и. Үч иткәндәй, бүген кибеткә кеше тулды, көчкә ябып котылдым.
Б а с а р ы й. Минем янга Илья Петрович килгән иде, төрле исемлекләр сорап башымны катырды.

Г ө л н и с а чәкчәк кертә.

Г ө л н и с а. Улым Мирхәйдәр, син вакларсың инде.

М и р х ә й д ә р. Юк, әни, миннән булмый ул. Без аны Мирзахан әфәндегә бирик.

М и р з а х а н. Гафу итегез, Мирхәйдәр абый, булдыра алмыйм.

Г ө л н и с а. Алай булса, кода, син.

Х ә й б у л. Юк, юк, кодагый, миннән булмый ул.

Х ө р м ә т у л л а. Берегезнең дә йөрәге җитмәде, кая, үзем ваклыйм, булмаса. *(Җиңнәрен сызганып, чәкчәк ваклаага керешә.)*

Г ө л н и с а. Сакланыш, кияү, пычагы бик үткен, кулыңны уймасын.

Х ө р м ә т у л л а. Кайгырма, каенанай, киявең сынатмас алай.

Г ө л н и с а. Ягез, балалар, бисмилла әйтеп алыгыз.

Барысы да берәр шакмак чәкчәк алалар.

Х ә й б у л. Ике яшькә, чәкчәкләре кебек, татлы тормыш телибез.

М и р з а х а н. Байлык белән гомер итсеннәр.

Г ө л н и с а. Шулай булсын, амин.

Урамда җыр тавышы ишетелә, кулларына чәкчәк тоткан килеш аптырап калалар.

Х ә й б у л. Нишләп болай вакытсыз чакта гармун уйныйлар?

М и р х ә й д ә р. Исерекләр, ахры.

Ә х т ә р и йөгереп керә.

Ә х т ә р и. Басарый, әйдә, тизрәк!

Б а с а р ы й. Ни бар, Әхтәретдин абзый?

Ә х т ә р и. Патша хәзрәтләреннән указ бар.

Б а р ы с ы бергә. Нинди указ?

Б и к т и м е р керә.

Ә х т ә р и. Ярман патшасы белән сугыш башланган!..

Б а р ы с ы б е р г ә. Сугыш башланган?!

Ә х т ә р и. Әйе, сугыш башланган. Яңа гына волостьтан чапкын килеп китте. Әйдә, Басарый, кырык яшькә кадәр булган запас солдатларга исемлек төзерсең.

Б и к т и м е р. Кырык яшькә кадәр дисеңме, кода?

Ә х т ә р и. Әйе, кода, синең өч улың да алына. Хәзерләнегез. Көтеп торырлык булмасын, таңнан калага чыгабыз. Патша хәзрәтләренең указы шулай... *(Китә.)*

Аның артыннан кунак егетләре дә китәләр.

Айсылу. Мирвәли...

Зәмзәмбану. Мирхәйдәр...

Нурия. Нургали...

Мөршидә. Хөрмәтулла...

Биктимер. Балалар...

Гөлниса. Бәбкәләрем, Мирвәли, Мирхәйдәр, Нургали... Кияү, син дәме?

Гөлчирә. Дәү абый, туган абый, бәләкәй абый, җизни...

Чыр-чу, елаш. Урамда, берсе икенчесенең тавышын күмәрлек итеп, биш-алты гармунда уйныйлар, җырлыйлар, елыйлар.

Җыр. Кыр капкасын чыккан чакта,
Бер карармын каерылып;
Илем, суым, туганнарым,
Каласыз бит аерылып.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Биктимер карт өе. Ике якта ике ишек. Түрдә зур сәке, сәке өстендә сандыклар, мендәр-ястыклар. Пәрдә ачылганда Гөлчирә хат укый. Аның әйләнә-тирәсендә Биктимер, Гөлниса, Айсылу һәм Зәмзәмбану тыңлап торалар.

Гөлчирә. «Вә янә дә күрше-коланга, кардәш-ыругларга, дус-ишләргә, ил картларына аермаенча күптин-күп, чуктинчук сәламнәремне ирсал вә тәблигъ әйләдем. Сәлам соңында шуны белдерәм: әткәй, әнкәй, без монда азап чигәбез. Өч айдан бирле окопта ятабыз. Иртән яңгыр яуса, кичен кар ява. Кара тана анасына охшаган иде, асрый күрегез. Абый белән Нургалидән хәбәр киләме? Тәүлеккә бер тапкыр ашарга бирәләр, анда да эт капмаслык борчак күмәче белән ясмык шулпасы».

Гөлниса. Әй бала, бала... Барысы да шул хәлдә микән?

Гөлчирә *(укуын дәвам итеп)*. «Эх, әнкәй, син мине тапмаган булсаң, бу газапларны күрмәгән булыр идем. Сүзем күп иде, мөхтәсәр кылдым. Ярманнар туп атарга керештеләр. Хушыгыз, хәер-догадан ташламагыз. Патша кулында грифтар булып торгучы улыгыз Мирхәйдәр». Бер җыры да бар:

«Миннән калган түбәтәем
Төсем итеп тотың кучкарда;

Дөньялыкта кавыша алмасак,
Кавышырбыз мәхшәрдә».

Г ө л н и с а. Бәбкәем, бәбкәем...

Б и к т и м е р. Сабыр ит, карчык, үз-үзеңне бетермә. Тормышлары авыр булса да, безнекеләр исән-сау әле. Әнә башкаларныкы беренче сугышларда ук үлделәр. Хәбәрсез югалдылар.

Г ө л н и с а. Нишлим соң, бик авыр бит, атасы...

З ә м з ә м б а н у. Әткәй, пособиесе турында нигә бер сүз дә язмаган икән?

Башкалар аптырап калалар.

Б и к т и м е р. Анысын мин белмим инде, килен.

З ә м з ә м б а н у. Үткән хатыбызда баштагы өч ае өчен акчасын алганыбыз юк, дип язган идек. Шул турыда тагын колагына киртеп язарга кирәк, җебеп тормасын, юллап җибәрсен.

Б и к т и м е р. Әй килен, аның башында пособие кайгысы түгелдер шул, күрәсең ич нәрсәләр яза. Хәерчегә бер тамчы дигәндәй, казна биргән акча белән яши алмассың, тизрәк бу каһәр суккан сугышны бетерсеннәр, иремне кайтарсыннар иде, диң.

З ә м з ә м б а н у. Әллә инде пособиемне дә сорамаска кушар идеңме?

Б и к т и м е р. Нишләп кушыйм, кушмыйм, сорарга кирәк, үзем дә берничә тапкыр прошение яздым бит, тагын да язарбыз. Тик мин сиңа шуны әйтүем — хәзерге минутта ireңнең хәленә кереп, безнең белән авыр кайгысын уртаклашырга дию-ем.

З ә м з ә м б а н у. Юкка кайгырудан ни файда? Үлгән кеше артыннан үлеп булмый бит.

Б и к т и м е р. Кара, кара, нәрсә сөйли, тирес бит? Димәк, үлүен телисеңң?

З ә м з ә м б а н у. Тукта әле, нигә миңа бәйләнәсең? Үлсен дип кайчан әйттем? Кайчан ишеттең?

Б и к т и м е р. Тагын ябышты инде, телеңә тилчә чыккыры, тфү, ләгыйнь...

З ә м з ә м б а н у. Төкермә! Тел очыңа төер чыкмасын.

Б и к т и м е р. Төкерү генә түгел, каеш чыбыркы кирәк иде сиңа, кешесе юк.

З ә м з ә м б а н у. Көне-төне кагып табалавыгыз аз иде, инде чыбыркы белән кыйнамакчы буласыз икән? Кулыңны гына тидереп кара, хәзер урядникка җәвит итәрмен.

Б и к т и м е р. Ах Алла... Сүзе сүзгә охшамый, авызы сүздән бушамый дигәндәй, нишлим инде бу каһәр белән? Күзгә чебен кебек безелдәп өскә килә дә, зәһәрле теле белән җаныма тия.

З ә м з ә м б а н у. Кем чебен, минме чебен?

Б и к т и м е р. Әйе, син чебен! Чебен генә түгел, шөшлә, кигәвен син!

З ә м з ә м б а н у. Мин шөшлә, кигәвен?

Б и к т и м е р. Ул гына да түгел, нашатыр син.

Г ө л н и с а. Куй, атасы, шул эт белән эт булма.

З ә м з ә м б а н у. Айсылу җиңги, ишетәсеңме, миңа эт диләр.

Г ө л ч и р ә. Җитәр инде, җиңги, күршеләр ишетер.

З ә м з ә м б а н у. Ишетсен! Хәзер староста Әхтәри коданы алып киләм, әйткән сүзләрегезне онытмагыз.

Б и к т и м е р. Бар, бар, алып кил, аны гына түгел, аннан зуррагын алып килсәң дә курыкмыйм, алар алдында да әйтермен. Нашатыр гына түгел, кришки водка диярмен. Сиңа Зәмзәмбану түгел, Кислатабану дип исем кушарга иде.

З ә м з ә м б а н у. Мин Кислатабану? Мулла кушкан исемемне бозасыз!

Б и к т и м е р. Әйдәгез теге якка, бу барыбер безгә тынычлык бирмәс.

Айсылу белән Зәмзәмбанудан башкалар бүлмәгә кереп китәләр.

З ә м з ә м б а н у. Юк, мин моны болай калдырмыйм. Син, җиңги, шаһит булырсың, яме?

А й с ы л у. Кеше көлдермә, килендәш, үзең гаепле, бераз гына телеңне тыярга иде.

З ә м з ә м б а н у. Анысын синнән сорамыйлар. Элек басканнары да җитәрлек булды, хәзер ирек бирмәбез, хәзер безнең көн, солдаткалар заманы, әйеме?

А й с ы л у. Тукта әле, нигә кызасың? Аларның сиңа берниндидә яманлык эшләгәннәре юк.

З ә м з ә м б а н у. Хәзер генә кигәвен, нашатыр, Кислатабану дип мыскыл итүләре?

А й с ы л у. Үзең гаепле, үзең ябыштың.

З ә м з ә м б а н у. Килмешәк башың белән миңа акыл өйрәтмә, яме!

А й с ы л у. Бу кадәр аңсыз, надан булырсың икән.

З ә м з ә м б а н у. Надан? Хи-хи-хи... Бичара, ашагач амин да тота белмисең, җитмәсә тагы надан дигән буласың.

А й с ы л у. Синең белән тел пычратып торганчы... *(Китә.)*

З ә м з ә м б а н у. Авызың томаландымы? Хи-хи-хи... *(Тышка чыгып китә.)*

Б и к т и м е р белән Г ө л ч и р ә чыга.

Б и к т и м е р. Бар, кызым, хатыңны Басарый абыеңа илтеп тапшыр, иртәгә волостька баручы булса, биреп җибәрсен.

Г ө л ч и р ә. Ярый, эти. *(Китә.)*

Г ө л н и с а керә.

Г ө л н и с а. Ни өчен генә бу Мирвәли язмый икән?

Б и к т и м е р. Белмим, карчык, үзем дә тәмам аптырадым инде.

Г ө л н и с а. Әллә, Ходаем, пленга калды микән?

Б и к т и м е р. Ул бит узган хатында «ялга чыктык, шәһәрдә торабыз», дип язган иде.

Г ө л н и с а. Мин аңламыйм, бу кешеләр ни өчен генә сугышалар икән?

Б и к т и м е р. Хәзрәт әйтә: сугыш — пәйгамбәрләрдән калган изге эш, ди.

Г ө л н и с а. Алар әйтер... Алар бит үзләре бармыйлар.

Бүлмәдән А й с ы л у чыга.

А й с ы л у. Әткәй, минем сезгә киңәшем бар иде.

Б и к т и м е р. Нинди киңәш ул, килен? Сөйлә.

А й с ы л у. Үзегез беләсез, алты ай тула инде, Мирвәлидән хат-хәбәр дә юк. Сугышның тукталуы турында уйларга да ярамый, диләр. Мин сездән китәргә уйлыйм.

Б и к т и м е р. Син нәрсә, килен, әллә бездән риза түгелме?

А й с ы л у. Ай, юк, әткәй, үз балагыз кебек күрүегез өчен рәхмәт сезгә.

Г ө л н и с а. Алай булгач, нигә бездән китәсең?

А й с ы л у. Алтмыш яшьлек картның тапканын ашап ятасым килми.

Б и к т и м е р. Эшебез ул кадәр үк начар түгел бит әле, кулымда һөнәрем булгач, ризыклык табып торам. Менә кышка дугалар әзерлим, бәләкәй чаналар ясармын. Шулай итеп торырбыз әле.

А й с ы л у. Юк инде, әткәй, мин китәргә булдым. Әйбәт кенә урын да чыгып тора.

Б и к т и м е р. Нинди урын ул?

А й с ы л у. Шәүлиханнар асрауларын яратмыйлар икән, шуның урынына мине алырга булдылар.

Г ө л н и с а. Ай-һай килен, Ханзафа бикәнең усаллыгы бөтен өязгә җәелгән. Аларга асрау түгел, килен дә ярамый. Әнә Касыймханы тагын хатынын аерган, ди. Ул бит сине каклап кипterer.

А й с ы л у. Зәмзәмбану килендәштән сүз ишетеп торганчы, эше авыр булса да, җаным тыныч булыр.

Артамонов керә.

Б и к т и м е р. Тукта, бу Гриша түгелме?

А р т а м о н о в. Әйе, Биктимер Шамкаевич, мин.

Г ө л н и с а. Гриша улым, син ничек монда?

А р т а м о н о в. Сугышта контужен булдым. Өч айга төзәлергә җибәрделәр.

А й с ы л у. Исәнмесез, Мироныч? *(Күрешә.)*

Г ө л н и с а. Килен, самовар куй. Гришаны кунак итәрбез.

Айсылу китә.

А р т а м о н о в. Рәхмәт, мин хәзер китәм. Өйгә кайтып барышлый, хәл белергә генә кердем.

Г ө л н и с а. Юк, юк, чәй эчертми җибәрмим. *(Китә.)*

А р т а м о н о в. Я, Биктимер Шамкаевич, нишләп торасыз?

Б и к т и м е р. Болай ярыйсы, Гриша, тик Мирвәли югалды бит. Хат та, хәбәр дә юк...

А р т а м о н о в. Гаҗәп, нигә язмый икән?

Б и к т и м е р. Үзебез дә аптырадык, күңелгә әллә нинди шикләр дә килә.

А р т а м о н о в. Әйе, ансы да бик мөмкин...

Б и к т и м е р. Бу немец дигәннәре бик көчлемени?

А р т а м о н о в. Аларда техника, аларда корал. Коры мылтык белән агулы газларга, ике йөз миллиметрлы пушкаларга каршы торып булмый шул.

Б и к т и м е р. Ике йөз миллиметрлы дисеңме?

А р т а м о н о в. Әйе, Биктимер Шамкаевич, ике йөз миллиметрлы пушкалардан атарга керешкәндә, бөтен җир йөзе тетрәп, әйләнә-тирәң утка, төтенгә, осколоклар буранына әйләнә. Менә шул дәһшәттән исән калган рус солдатлары окоп почмакларына посалар да, канечкеч патшаны, сатлык генералларны, куркак офицерларны сүгәләр.

Б и к т и м е р. Японнарга оттырган кебек, болардан да җиңелербез микәнни?

А р т а м о н о в. Әйе, Биктимер Шамкаевич, рус патшасының җиңелүе көн кебек ачык. Ләкин Россия халкы җиңәчәк.

Б и к т и м е р. Ничек инде ул, патшасы җиңеләчәк тә, халкы җиңәчәк?

А р т а м о н о в. Гасырлар буе ач-ялангачлыкта интегеп, туктаусыз көрәшләрдә чыныккан эшчеләр, еллар буе окопларда

тилмергән солдатлар, көннән-көн бөлгенлеккә төшкән крестьяннар озакламый урамнарга чыгарлар да, язгы ташкыннардай булып, сарайларга каршы барырлар.

Айсылу керә.

Айсылу. Әткәй, Мөршидә килде.
Биктимер. Мондый пычракта нишләп йөри икән?
Артамонов. Ярый, хәзергә хуш, сау булыгыз, Мирвәлидән хат килү белән, миңа хәбәр итәрсез.
Биктимер. Тукта, Мироныч, чәй эчәрбез.
Артамонов. Рәхмәт. Үземнекеләрне күрергә ашыгам. Бераздан иркенләп килермен әле.

Биктимер Артамоновны озата. Гөлниса бүлмәдән чыга.

Гөлниса. Ай Алла, кунагым китеп тә барган, аның өчен чәй куйдык.

Мөршидә керә.

Мөршидә. Нихәл, әни, арумы?
Гөлниса. Бик әйбәт, кызым, каян болай?
Мөршидә. Урман сорап волостька барган идем, Хөрмәтулладан хат алдым.
Гөлниса. Соң нәрсә яза?
Мөршидә. Сезнең хәер-догада исән-сау гына йөрим, начальстволарым бик яраталар, һаман да шул офицерымда денщик булып торам, дигән. Шушы хат белән ун кадак күчтәнәч җибәрәм, тиздән алырсыз, дип язган.
Гөлниса. Алланыкын белмәссең, дигәндәй, кызым, бу дөнья кызык кына корылган. Берәүләр ач ята, икенче берәүләр күчтәнәчләр җибәреп тора.
Мөршидә. Шулай инде ул, әни, «майламыйча арбасы, җайламыйча чанасы йөрми», дигән бабайлар. Киявегез барган мәлне бер ат акчасына офицерларын сыйлады.

Биктимер керә.

Гөлниса. Алланың каһәре төшсен иде бу патшасына, безне болай тилмерткәнче муены борылсын, үлгән чагында телен чәйнәп җанын бирсен иде, имансыз!
Биктимер. Куй, куй, юләр, андый сүзләр сөйләмә. Монда гаеп патшада түгел, ярманда, диләр, тоткан да, явыз, безнең җиргә

басып кергән. Билгеле, бугазыңа килеп ябышкач, сугышмыйча хәлең юк.

М ө р ш и д ә. Әти мин сезне алырга дип кергән идем, кайгылы көннәрегездә күңел ачып кайтырсыз.

Б и к т и м е р. Кирәкми, кызым, үзең дә солдатка кеше.

М ө р ш и д ә. Булса ни, минем тормышым зарланырлык түгел әле. Атланмаем капламалап, сарымаем тәпәнләп, туңмайларым табаклап ята. Узган атнаны гына ике капчык борай, өч капчык бодай оны тарттырган идем. Әле бүген пособие акчамны алгач, биш гөрәңкә кәрәзле бал алдым, рәхәтләнеп сыйланып кайтырсыз.

Б и к т и м е р. Юк, кызым. Ялан да ялан сиңа кунакка йөрүе кешедән уңайсыз.

М ө р ш и д ә. Сез ят кеше түгел миңа.

Б и к т и м е р. Ансы шулай, өе барның көе бар дигәндәй, эшсез ятуны яратмыйм.

М ө р ш и д ә. Кайгырма, әти, мин сиңа эш табармын. Ватылган, җимерелгән әйберләремне төзәтеп китәрсең. Сыерлар абзарының өрлеге сыгылган, эчтән берәр терәү кисәге салырсың. Менә кыш җитә, чанамның үрәчәсе юк, аңа үрәчә куярсың. Камытымның бөяте тузган, бөят утыртырсың, мунча ишегенең күгәне купкан, аңа күгән кагарсың. Һәрхәлдә, сиңа өч-дүрт көнгә җитәрлек эш табармын әле.

Б и к т и м е р. Белмим шул, ничек булыр икән? Пешекләргә куйган дугалыкларым бар иде.

Г ө л н и с а. Алар качмас әле, карт, көз озын, әкренләп эшләрсең.

Б и к т и м е р. Барыйк дисеңме?

Г ө л н и с а. Шулай дим, күңел ачып кайтырбыз.

Б и к т и м е р. Ярый алайса, чыгып ат җигим.

М ө р ш и д ә. Бар, бар, әти, караңгы төшкәнче кайтып җитәргә кирәк.

Биктимер чыгып китә.

Нурия килен кайда?

Г ө л н и с а. Аталарында тора.

М ө р ш и д ә. Әллә ташлап киттеме?

Г ө л н и с а. Юк, безнең ризалык белән. Ата-анасының кадерле баласы бит, ялынып сорагач, каршы килмәдек.

А й с ы л у керә.

А й с ы л у. Әнкәй, чәй әзерләдем.

Г ө л н и с а. Әйдә, кызым, әтиең ат җиккәнче бер-ике чынаяк эчеп алыйк.

Айсылудан башкалар бүлмәгә чыгып китәләр. Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Җиңги, бәгырем, сиңа хат!
А й с ы л у. Хат? Кая, бир.
Г ө л ч и р ә. Ә сөенчегә?
А й с ы л у. Ни теләсәң, шуны алырсың. *(Хатны укып.)* Ә?!
Г ө л ч и р ә. Җиңги, сиңа ни булды?
А й с ы л у. Юк, берни дә булмады...
Г ө л ч и р ә. Кемнән ул хат, абыйданмы?
А й с ы л у. Юк, түгел...
Г ө л ч и р ә. Туганнарыңнанмы?
А й с ы л у. Алардан да түгел...
Г ө л ч и р ә. Алай булгач, кемнән соң?
А й с ы л у. Сорама, Гөлчирә, әйтмим.
Г ө л ч и р ә. Әйт инде, җиңги, минем дә беләсем килә.
А й с ы л у. Сиңа аны белү ярамый...
Г ө л ч и р ә. Әйтмисең икән, мин болай да төшендем.
А й с ы л у. Нәрсә төшендең? Әллә ачып укыдыңмы?
Г ө л ч и р ә. Эх, җиңги, димәк, син дә абыйны алдадың?..
А й с ы л у. Син ни сөйлисең, Гөлчирә?..
Г ө л ч и р ә. Алай булгач, кемнән соң ул хат? Нигә миннән яшерәсең?
А й с ы л у. Алай шикләнә торган булгач, әйтәм. Ләкин хатта язылган сүзләрне беркемгә дә чыгармаска сүз бирәсеңме?
Г ө л ч и р ә. Иши белән ант итәм.
А й с ы л у. Тыңла, укыйм. «Айсылу, мин биш айдан бирле төрмәдә утырам. Кайчан чыгасым билгеле түгел. Үз тормышыңны үзең кайгырту ягын кара. Минемчә, заводка китүең яхшырак булыр. Әткәйләргә минем турыда бернәрсә дә белдермә. Хуш. Мирвәли».
Г ө л ч и р ә. Абый төрмәдә?
А й с ы л у. Әйе, Гөлчирә, төрмәдә...
Г ө л ч и р ә. Ни өчен яптылар икән?
А й с ы л у. Күрәсең, ни өчен икәнен язмаган.

Айсылу елый. Г ө л н и с а белән М ө р ш и д ә керә.

Г ө л н и с а. Килен, ни булды сиңа?
А й с ы л у. Юк, әнкәй, берни дә булмады.
Г ө л н и с а. Нигә соң елыйсың?
А й с ы л у. Менә, хат алдым...

Г ө л н и с а. Мирвәлидәнме?
А й с ы л у. Түгел, заводтан...
Г ө л н и с а. Соң?
А й с ы л у. Бертуган абыем үлгән...
Г ө л н и с а. Сугыштамы?
А й с ы л у. Юк, болай, авырып үлгән...

Тыштан Б и к т и м е р керә.

Б и к т и м е р. Килен, ни булды сиңа?
Г ө л ч и р ә. Абый...сы үлгән...

Гөлниса белән Мөршидә утырып дога кылалар.

Б и к т и м е р. Елама, килен, үзеңә исәнлек бирсен.
М ө р ш и д ә. Җиңги, әйдә безгә, кунак булып кайтырсың.
А й с ы л у. Рәхмәт, Мөршидә, синдә болай да бик күп кунак булдым инде.
М ө р ш и д ә. Булсаң ни? Син безгә ят кеше түгел.
Б и к т и м е р. Чынлап та, әйдә, килен, күңел ачып кайтырсың.
Г ө л н и с а. Әйдә, килен, бергә-бергә күңелле булыр.
Г ө л ч и р ә. Бар, җиңги.
М ө р ш и д ә. Эшсез тору күңелсез дисәң, курыкма, җиңги, сиңа да эш табармын. Үземә, балаларыма дип алган күлмәклекләрем ята, мулла абзыйлардан аяк машинасы алып чыгып бирермен дә, келтерәтеп тик утырырсың.
А й с ы л у. Ярый алайса.
Б и к т и м е р. Бар, килен, өстеңә киеп чык, хәзер китәбез.

Айсылу бүлмәгә кереп китә. Тыштан З ә м з ә м б а н у кайтып керә. Мондагылар юлга чыгарга әзерләнәләр.

Б и к т и м е р. Килен, ике-өч көнгә Мөршидәгә барабыз, үзегез генә торырсыз инде.
З ә м з ә м б а н у. Ярый, әткәй, бик әйбәтләп торырбыз.
Б и к т и м е р. Мунчада кибәргә күтәргән дугаларым бар, һәр көнне ягып торыгыз, кипсеннәр.
Г ө л н и с а. Саклап тотсагыз чәй-шикәрегез җитәрлек, аш пешерсәгез, борчак чумарасы салырсыз.
Б и к т и м е р. Кич яткансда малларны, кош-кортларны барлап ябарга онытмагыз.
Г ө л н и с а. Тавыкларга җим сипмәгез, ындыр тирәсендә чүпләнсеннәр.

А й с ы л у киенеп чыга.

Б и к т и м е р. Ягез, бер фатиха.

Утырып дога кылалар.

Б и к т и м е р. Аллаһы әкбәр, әйдәгез.

Г ө л ч и р ә. Әти, без бүген аулак өй ясап алсак, гаеп итмәссез микән?

Б и к т и м е р. Керәчине бик кадерле бит, кызым.

Г ө л ч и р ә. Без сукыр лампаны гына яндырырбыз.

Г ө л н и с а. Утырсыннар инде, карт, эрлисе сүсләре дә бар.

Б и к т и м е р. Ярый, кызым, тик карагыз аны, минем йөземә кызыллык китерерлек булмасын.

Г ө л ч и р ә. Юк, юк, әти, без күрше Сәлимә белән Шәмсенурны гына чакырабыз.

Б и к т и м е р. Ярый. Әйдәгез, Аллага тапшырдык.

Гөлчирә белән Зәмзәмбану озата чыга. Бераздан әйләнеп керәләр.

Г ө л ч и р ә. Бичара, Айсылу җиңги кызганыч...

З ә м з ә м б а н у. Мин кызганыч түгелме?

Г ө л ч и р ә. Син дә кызганыч. Ул бигрәк тә. Аның бит монда беркеме дә юк.

З ә м з ә м б а н у. Ярый, кеше кайгысын кайгырта торган чак түгел, үз турыбызда уйларга кирәк. Кемнәрне чакырабыз?

Г ө л ч и р ә. Кемнәрне дип, Сәлимә белән Шәмсенурны чакырырбыз да шулар җитәр.

З ә м з ә м б а н у. Гомер эчендә бер туры килгән аулакта да рәхәтләнеп утырмагач — ул нигә ярый? Минем иптәшләремнән Айгыр Мәрьям белән Чөгендер Наһарны да чакырырбыз, әйеме?

Г ө л ч и р ә. Юк, юк, җиңги, Айгыр Мәрьям турында авызыңны да ачасы булма.

З ә м з ә м б а н у. Юкка аны яратмыйсың. Ул бик күңелле солдатка, җырга, такмакка аннан да оста хатын өяздә дә юк диләр, әйеме?

Г ө л ч и р ә. Кирәкми, әтиләргә ишетелсә, Алла сакласын.

З ә м з ә м б а н у. Ярый, мин кешеләр чакырырга киттем. *(Чыгып китә.)*

Тыштан тәрәзәгә яңгыр сибеп яуганы ишетелә.

Г ө л ч и р ә. Ходаем... Бу нинди бетмәгән яңгыр булды? Әтиләр чыланыр инде...

Өй эченә әкрен генә караңгы төшә башлый, Гөлчирә чүпрәк белән лампа пыяласын чистарта-чистарта җырлый.

Җ ы р. Айлар буе бертуктамый,
Пыскып яңгырлар ява,

Яуган көзге яңгырлардай,
Ил күзеннән яшь ага.
Шул яшь белән бергә безнең
Йөрәкләргә кан сава...

*(Лампага ут кабыза, тәрәзә пәрдәләрен тарта. Бер чүлмәк гөлне кулына ала.)*

Гөлләр гөле, яранкаем,
Көтәм синнән ал чәчәк,
Ал чәчәктәй матур көннәр
Кайчан безгә киләчәк?..
Киләчәк, тиздән киләчәк,
Ал чәчәкләр бирәчәк.

Г а й н а в а л керә.

Г а й н а в а л. Гөлчирә, Гөлнисаттәй теге яктамы?

Г ө л ч и р ә. Ул, Гайнавал түтәй, өйдә юк. Мөршидә түтәйләргә киттеләр.

Г а й н а в а л. Шулаймыни? Нишлим инде? Ахунҗан хатыныннан эрләргә тула йоны алган идем, көн дә кереп шуны тыкырдата, кич утырып бетерим дисәм, лампамда бер тамчы керәчинем калмаган. Әҗәткә биреп тормассызмы дип кергән идем.

Г ө л ч и р ә. Безнең дә юк шул, түтәй, кичә әти бер гөрәнкә алып кайткан иде, лампаларга салып бетердек.

Г а й н а в а л. Шулайдыр шул, дөньясы корды бит. Инде нишлим? Кибеткә барсам — акчам юк.

Г ө л ч и р ә. Сафиулла абый турында хәбәр бар икән дип ишеттек, шул сүз дөресме?

Г а й н а в а л. Әйе, Гөлчирә, күрше авылның Чимун малае аягын өздереп кайтты, бер полкта хезмәт итә идек, Сафиуллалар немец ягында бүленеп калдылар, ди.

Г ө л ч и р ә. Мескен... Бая балаларыңны кыйный идең, нигә инде, түтәй, аларга тиясең, болай да күлмәк-ыштансыз өйдә боегып утыралар.

Г а й н а в а л. Сөйләмә инде, Гөлчирә, бөтен дөньясының үчен шулардан алам. Бераз чыбык-чабык алып кайтыйм дип, бәләкәй арба тартып әрәмәгә киткән идем, кайтсам, уйнап, лампадагы керәчинемне түккәннәр. Шуннан түзмәдем, ичмасам, берегез дә үлмисез дип, дүртесен дә тотып кыйнадым... Кыйнадым да, соңыннан үзләрен кызганып, күкрәгемә кыса-кыса еладым... Ярый, Гөлчирә, мин чыгыйм әле.

Г ө л ч и р ә. Гайнавал түтәй, без бүген кич утырырга җыенабыз, кер безгә, бетерәсе эшем дә бар, дисең.

Г а й н а в а л. Тарсынмасагыз, бик әйбәт булыр иде дә...

Г ө л ч и р ә. Ник тарсыныйк? Бездә әллә нинди кешеләр булмый, бераз кич утырырбыз шунда.

Г а й н а в а л. Ярый алайса, мин чыгыш балаларымны йоклатыйм да керермен.

Китә. Г ө л ч и р ә озата чыга, Н у р и я белән әйләнеп керә.

Г ө л ч и р ә. Әйдә, апа, өстеңне сал.

Н у р и я. Юк, Гөлчирә, чишенеп тормыйм, әткәйләр анда озак торырлар микән?

Г ө л ч и р ә. Белмим шул. Шулай да берничә кич кунарлар инде. Йомышың бар идемени?

Н у р и я. Мине Шәүлихан абзый Касыймханнары мөгаллимә апа урынына куярга телиләр, шул турыда әткәйләрнең рөхсәтен сорамакчы идем.

Г ө л ч и р ә. Минемчә, апа, каршы килмәсләр, начар эш түгел ич. Ул мөгаллимә апа нигә китә икән соң?

Н у р и я. Ике абыйсын берьюлы сугышка алганнар, карт әнисе янында торырга беркемнәре дә юк икән.

Г ө л ч и р ә. Касыймхан дигәннән, тагын хатынын аерган диме?

Н у р и я. Аларга кеше ярыймыни! Аннан мин сиңа сораган китабыңны, Габдулла Тукай шигырьләрен китердем. *(Китап бирә.)*

Г ө л ч и р ә. Рәхмәт, апа, мин аның шигырьләрен шулкадәр яратам...

Н у р и я. Аларны кем генә яратмый икән.

Г ө л ч и р ә. Яратмаучылар да бар икән. Беркөнне мин мулла абзыйлардан бер китап алып чыккан идем, шунда, шагыйрь түгел ул, дип язганнар.

Н у р и я. Аны күралмаучы дошманнары язганнар.

Алъяпкычына әйберләр салып З ә м з ә м б а н у кайтып керә.

Н у р и я. Исәнме, җиңги?

З ә м з ә м б а н у. Ару әле.

Н у р и я. Ярый, Гөлчирә, мин кайтыйм.

Г ө л ч и р ә. Утыр әле, апа, нигә ашыгасың?

Н у р и я. Өйдә эшләрем күп. Шул турыда Нургали абыеңа да хат язасым бар. *(Китә.)*

З ә м з ә м б а н у. Нишләп йөргән була?

Г ө л ч и р ә. Кызлар мәктәбенә мөгаллимә итеп куялар, ди, шул турыда әтиләрдән ризалык сорарга килгән.

З ә м з ә м б а н у. Әй, кыланышына карап косарсың, әйеме.

Г ө л ч и р ә. Җиңги, итәгеңдә нәрсә ул?

З ә м з ә м б а н у. Шаулама, Гөлчирә, юлым уң булды. *(Итәгендәге әйберләрне бер-бер артлы алып.)* Менә сиңа биш гөрәнкә клиндер, ике гөрәнкә салат прәннеге, бер гөрәнкә кәнфит, бер гөрәнкә айбагар, ярты гөрәнкә әрбет чикләвеге...

Г ө л ч и р ә. Җиңги... бу кадәр әйберләрне кайдан алдың?

З ә м з ә м б а н у. Каян булсын, кибеттән.

Г ө л ч и р ә. Ә акча?

З ә м з ә м б а н у. Бер тиенсез, барысын да буш бирде.

Г ө л ч и р ә. Кем?

З ә м з ә м б а н у. Мирзахан. Бер гөрәнкә айбагар алыйм дип кибетләренә кергән идем, бәхеткә каршы ул анда иде...

Г ө л ч и р ә. Соң?

З ә м з ә м б а н у. Шул, аулак өй хөрмәтенә шушы әйберләрне Ясәвидән үлчәтеп бирдертте. Һәм сиңа бик күп сәлам әйтергә кушты. Гөлчирәне шулкадәр сагындым, шулкадәр сагындым... ди. Соңга таба, Ясәви белән, бәлки, барып та чыгарбыз әле, дигән була. Килегез, дидем, әйеме?

Г ө л ч и р ә. Бу кадәр әйберләрне алмаска иде, җиңги.

З ә м з ә м б а н у. Дурак син, Гөлчирә, башкалар ничек итеп егетләрдән ашарга белми йөргәндә, син биргәнне дә читкә кагарга уйлыйсың.

Г ө л ч и р ә. Шәмсенурларны чакырдыңмы?

З ә м з ә м б а н у. Чакырдым... Тик аналары кертмәгән була.

Г ө л ч и р ә. Юньләп әйтмәгәнсеңдер әле.

З ә м з ә м б а н у. Әйттем, кат-кат сорадым. Кызларымны аулак өйгә йөртер хәлем юк, дигән була.

Г ө л ч и р ә. Син дә инде, җиңги, шуны да эшли алмагач... Менә күр дә тор, икесен дә алып чыгармын. *(Китә башлый.)*

З ә м з ә м б а н у. Гөлчирә, дөресен әйткәндә, мин аларны чакырмадым. Нигә дисәң, Мирзахан башка кешеләрнең булуын теләми. Беләсең, бай малае, ыбыр-чыбыр халык арсында утырасы килми торгандыр, әйеме?

Н а һ а р керә.

Н а һ а р. Әллә беркем дә юк инде?

З ә м з ә м б а н у. Әйдә, әйдә, ахирәт.

Н а һ а р. Нихәл, Гөлчирә җаным.

Г ө л ч и р ә. Бик әйбәт әле, Наһар түтәй.

З ә м з ә м б а н у. Гөлчирә, мә, бу әйберләрне теге якка урнаштыр.

Гөлчирә китә.

Н а һ а р. Кемнәрне чакырдың?

З ә м з ә м б а н у. Хатыннардан икәү генә булабыз.

Н а һ а р. Ирләрдән?

З ә м з ә м б а н у. Билгеле инде, үзебезнекеләрдән писер Басарый белән кибетче Ясәви, Мирзахан була.

Н а һ а р. Юкка Мирзаханны чакыргансың, бер дә безгә иш кеше түгел.

З ә м з ә м б а н у. Кайгырма, без аларны теге якка куарбыз, үзебез монда типтерербез, әйеме?

Каба белән йон тотып Г а й н а в а л керә.

З ә м з ә м б а н у. Нишләп йөри бу сурәбәт?

Г а й н а в а л. Саумы, күрше?

З ә м з ә м б а н у *(салкын гына).* Әйбәт әле.

Г а й н а в а л. Нихәл, Шәмсенаһар?

Н а һ а р. Шөкер әле.

З ә м з ә м б а н у. Сез утыра торыгыз, мин Гөлчирәгә булышыйм. *(Китә.)*

Г а й н а в а л. Иреңнән хәбәр киләме?

Н а һ а р. Килгәли.

Г а й н а в а л. Нәрсәләр яза?

Н а һ а р. Әй, ул мүкләкнең шул инде, сызлана.

Г а й н а в а л. Авырдыр шул, авыр булмаса, сызланмас иде...

Н а һ а р. Авыр дип инде, Гайнавал, бер ул гына түгел, бөтен ил белән. Электән дә елак кешегә җитә калды.

Г а й н а в а л. Хәзер генә Әхтәри старостаны күрдем, иртәгә симез сыерларны илтәбез, ди. Хатын-кызларны да алалар икән, дигән сүз йөри, дөрес була, ахры.

Н а һ а р. Китсәнә, безнең белән анда нишләсеннәр?

Г а й н а в а л. Курыкма, эш табарлар. Әнә яңа салына торган Әгерҗе тимер юлына үзбәк, кыргыз дигән халыкларны китергәннәр, үз илләрендә кыш булмаганга киемсез килгәннәр икән. Бичараларның өсләренә карап еларлык, ди. Шундый салкын яңгырда яланаяк тимер юл салалар икән.

Тәрәзәгә яңгыр сибеп яуганы ишетелә.

Көне дә дөмекте, өй түбәмнән үтмәсә ярар иде...

Тынлык. Җырлыйлар.

Н а һ а р. Телеграм баганасы
Олы юлга маяк ул,
Сагынасыңмы дип сорыйсың,
Сагынмаган кая ул.
Г а й н а в а л. Тышка чыксам, ташка басам,
Ташның салкыннарына,

Кулларымны куеп елыйм,
Бәгырем ялкыннарына.

Б е р г ә. Телеграм баганасын
Саныйсым калган икән.
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән.

Ишек шакыйлар. З ә м з ә м б а н у күрше бүлмәдән чыга.

З ә м з ә м б а н у. Туктагыз, ишек кагалар.

Н а һ а р *(өй ишеген ачып кычкыра)*. Кем бар?

М и р з а х а н *(тыштан)*. Бу мин!

Н а һ а р. Мирзахан бугай, кертәбезме?

З ә м з ә м б а н у. Нигә сорап торасың, ач тизрәк!

Н а һ а р, өйалдына чыгып, бераздан Б а с а р ы й, М и р з а х а н, Я с ә в и л ә р белән әйләнеп керә.

М и р з а х а н. Аулак өйләр котлы булсын!

Н а һ а р. Урыныгыз түрдән булсын!

Б а с а р ы й. Үзегез аулак өйдә утырган буласыз, үзегезнең егетләрегез дә юк.

З ә м з ә м б а н у. Булмаганны каян аласың? Аксак, сукырдан башка кешесе дә калмады ич.

Г ө л ч и р ә бүлмәдән чыга.

Г ө л ч и р ә. Җиңги, самовар өлгерде... Бәрәч, кеше бар икән.

М и р з а х а н. Исәнме, Гөлчирә?

Г ө л ч и р ә. Бик яхшы, Мирзахан абый.

З ә м з ә м б а н у. Әйдәгез, теге якка чәйгә.

Г ө л ч и р ә. Мирзахан абый, әйдәгез.

М и р з а х а н. Рәхмәт, Гөлчирә, минем эчәсем килми.

З ә м з ә м б а н у. Әйдәгез, кунаклар.

Б а с а р ы й. «Ат өстеннән табынга,
Чыдам бирсен карынга», —
дигән кебек булды бу.

З ә м з ә м б а н у белән М и р з а х а н н а н башкалар китәләр.

М и р з а х а н. Зәмзәмбану түтәй... Бер кеше дә чакырмыйм диден, Гайнавал чекерәеп утыра.

З ә м з ә м б а н у. Сөйләмә инде, Мирзахан, бик зур аңлашылмаучылык туды. Мин югында Гөлчирә чакырып куйган.

М и р з а х а н. Нишлибез?

З ә м з ә м б а н у. Әйтеп чыгарырга туры килер.

М и р з а х а н. Алай ярамый, бәлки, бераздан үзе олагыр.

З ә м з ә м б а н у. Уйламый да, кич утырырга эш белән кергән.

М и р з а х а н. Син бар, Басарыйны җибәр әле.

Зәмзәмбану китә. Б а с а р ы й керә.

Б а с а р ы й. Нигә чакырдың?

М и р з а х а н. Эшләр начар бит, Басарый, Гайнавал бар.

Б а с а р ы й. Булса соң?

М и р з а х а н. Миңа бүген тәкәббер Гөлчирәне кулга төшерергә кирәк, шуны аңлыйсыңмы?

Б а с а р ы й. Бик яхшы аңлыйм, менә бу безгә булышыр. *(Аракы шешәсе күрсәтә.)*

М и р з а х а н. Каян алдың?

Б а с а р ы й. Анысы сиңа кирәкми.

М и р з а х а н. Эчәрләрме соң?

Б а с а р ы й. Һи... хәзерге солдаткалар...

М и р з а х а н. Бар алайса, Гайнавалны аяктан егарга кара.

Б а с а р ы й. Өйрәтмә, ул турыда тәҗрибә җитәрлек.

Китә. Мирзахан уйланып йөри. Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Мирзахан абый, сине чәйгә көтәбез.

М и р з а х а н. Әйттем бит инде, эчәсем килми. Эх, Гөлчирә... *(Гөлчирәне тотып ала.)*

Г ө л ч и р ә. Җибәр, Мирзахан абый, кеше күрер.

М и р з а х а н. Күрсә, нигә куркасың?

Г ө л ч и р ә. Курыкмыйм да, яхшы түгел.

М и р з а х а н. Ничек яхшы түгел?

Г ө л ч и р ә. Әллә ничек, уңайсыз дим...

М и р з а х а н. Мин сиңа бик матур бүләк китердем. Яратырсың микән? *(Фабричный перчатка бирә.)*

Г ө л ч и р ә. Кирәкми, Мирзахан абый, мондый затлы бүләккә каршы бирерлек минем бер әйберем дә юк.

М и р з а х а н. Миңа синнән берни дә кирәкми. Син үзең миңа зур бүләк. Эх, Гөлчирә, мин сине шулкадәр сагынып кайткан идем, ләкин...

Г ө л ч и р ә. Нәрсә ләкин?

М и р з а х а н. Өегез әллә нинди солдаткалар белән тулган. Мин бүген киләчәк тормышыбыз турында сөйләшергә дип килгән идем.

Г ө л ч и р ә. Алар безгә уңайсызламыйлар, сөйләшик.

М и р з а х а н. Менә шушы серле кара күзләр
Елан төсле күңелем чактылар,
Чактылар да минем йөрәгемә
Мәңге сүнмәс утлар яктылар.

Г ө л ч и р ә. Кем шигыре бу?

М и р з а х а н. Үземнеке.

Г ө л ч и р ә. Син шулай шагыйрь дәмени?

М и р з а х а н. Түгел идем. Башыңа төшсә, башмакчы буласың, диләр бит. Сиңа гашыйк булганнан бирле мин дә менә шундый мәхәббәт шигырьләре яза башладым.

Урам яктан тәрәзә кагалар.

Г ө л ч и р ә *(бүлмә ишегенә барып кычкыра).* Җиңги, җиңги!

Зәмзәмбану бүлмәдән чыга.

М и р з а х а н. Утны сүндерегез.

Лампаны кысалар.

З ә м з ә м б а н у *(тәрәзәгә барып).* Кем бар?

Х ә й б у л *(урамнан).* Бу без, Зәмзәмбану җиңги, аулак өйгә килгән идек.

М и р з а х а н. Кертмәгез, кертмә.

З ә м з ә м б а н у. Хәйбул, без бит кич утырмыйбыз.

Г ө л ч и р ә. Ач, җиңги, ак билетлы егетләр, бераз утырырлар да чыгарлар.

М и р з а х а н. Кирәкми, ачмагыз.

Х ә й б у л. Ачыгыз инде, күрәсез, яңгыр ява, өегезне ашамабыз.

З ә м з ә м б а н у. Әрсезләнеп йөрмәгез, кертмибез булгач кертмибез, ятарга әзерләндек...

Егетләр гармунда җырлап китәләр.

Е г е т л ә р  җ ы р ы. Быел яңгыр бик вак ява,
Вак яуса да чылата;
Быел көннәр бик ямансу,
Җырлата да елата.

М и р з а х а н. Киттеләр... Утны яндырыгыз.

Утны кабызалар. Эчке бүлмәдә чинап җырлаган тавыш ишетелә.

Г ө л ч и р ә. Җиңги, нишлиләр анда?

З ә м з ә м б а н у. Наһар ахирәтнең эченә шайтан баласы кергән, җырлап шуны тышка чыгара.

Г ө л ч и р ә. Нинди шайтан баласы? *(Китә.)*

М и р з а х а н. Зәмзәмбану җиңги, нишләрбез икән, тышта бик караңгы, җитмәсә тагын чиләкләп яңгыр ява.

З ә м з ә м б а н у. Ярый инде, хәерле булсын, иртәнге коймактан китәрсең, әйеме?

Н а һ а р белән Я с ә в и кочаклашып җырлап чыгалар.

Н а һ а р. Әйттер-типтер, сиптер әйдә,
Дуслар борын салмасын,
Аша да эч, уйна да көл,
Үкенечкә калмасын.

Эх-ма!..
Авыр безгә дөньясы,
Онытылмасмы нужасы;
Биби бикә, би Заһидә,
Бану, Сылу, Шәрифә.

З ә м з ә м б а н у. Бай абзыйлар бакчасы,
Бакчасында мунчасы;
Үлмәсен дә, кайтмасын да,
Килеп торсын акчасы.
Эх-ма!..
Авыр безгә дөньясы,
Онытылмасмы нужасы;
Биби бикә, би Заһидә,
Бану, Сылу, Шәрифә.

Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Җиңги, бу нинди эшегез? Фу, син дә эчкәнсең икән.

З ә м з ә м б а н у. Эчтем шул. Нигә аңа исең китә?

Г ө л ч и р ә. Хатын башыгыз белән ничек оялмыйсыз?

Н а һ а р. Оят? Хи-хи-хи... Кайчандыр бездә бар иде, ә хәзер очты инде ул. Шулай бит, ахирәт?

З ә м з ә м б а н у. Дөрес, ахирәт!

Б е р г ә. Үлмәсен дә, кайтмасын да,
Килеп торсын акчасы.

Эчке бүлмәдән Б а с а р ы й йөгереп чыга. Җилкәсе белән ишекне терәп тора.

М и р з а х а н. Нәрсә бар?

Б а с а р ы й. Гайнавал бәйләнә.

Г а й н а в а л *(эчке яктан).* Ач ишекне!

Г ө л ч и р ә. Кит, Басарый абый, нигә аны чыгармыйсың?

Басарыйны ишек яныннан этеп җибәрә. Г а й н а в а л чыга.

Г а й н а в а л. Син миңа әйт әле, ни дип син миңа кул саласың?

Б а с а р ы й. Кара, кара, тонган күз, кайчан кул салдым?

Г а й н а в а л. Качкан чагында. Ах син, кәлтә елан...

Утын агачы күтәреп Басарыйга килә, Басарый мич башына менеп китә.

Б а с а р ы й. Мирзахан, әйтегез әле шул акайганга, нигә минем арттан йөри ул?

Г а й н а в а л. Сез мине шуның өчен эчердегезмени? Гайнавалны аракы белән сатып алырга булдыгызмы? Безнең ирләребез анда кан түгә, ә сез монда бездән көләргә, безне хурларга уйлыйсыз!

М и р з а х а н. Гайнавал түтәй, юкка тавыш чыгарма, сине беркем дә хурларга уйлаганы юк.

Г а й н а в а л. Беләм мин сине, бурсык баласы! Сыйлап-сыйпап астыртын кисәргә уйлыйсың... Мине алдый алмассың.

М и р з а х а н. Бик кирәгең бар иде! Синең кебекләрнең поты бер тиен.

Г а й н а в а л. Башыгыз исән чакта югалыгыз күземнән!

М и р з а х а н. Нәрсә? Хәерче башың белән безгә әмер бирәсең? Ха-ха-ха...

Г а й н а в а л. Югалыгыз! Юкса мин сезне бәреп үтерәм...

Утын агачы белән һөҗүм итә. Мирзаханнар тышка, Зәмзәмбанулар эчке бүлмәгә качалар.

Г ө л ч и р ә. Тынычлан, түтәй, елама...

Г а й н а в а л. Авыр миңа, Гөлчирә... Гомерем буе шулай газап чигәрмен микәнни? Мин бит үз гомеремдә бер генә тапкыр да көлгәнем юк. Бераз гына онытылмасмы, күңелем күтәрелмәсме дип эчкән идем, юк, тагын да начаррак булды. *(Ыңгырашып сәкегә ава.)*

Г ө л ч и р ә. Елама, түтәй, сиңа авыр икәнен беләм, ләкин нишлим соң? Берничек тә ярдәм итә алмыйм... Тынычлан, елама... Менә шулай, бераз йоклап ал...

Гайнавал йокыга китә. Гөлчирә аның баш астына мендәр сала, өстенә яба. Зәмзәмбану белән Наһар ишектән башларын сузып карыйлар.

З ә м з ә м б а н у. Тончыктымы?

Г ө л ч и р ә. Акрын, йоклады.

З ә м з ә м б а н у. Син гаепле моңар, син!.. Үз башыңа бәла итеп чакырдың.

Г ө л ч и р ә. Йокларга кирәк. *(Тышкы ишекне бикли.)*

З ә м з ә м б а н у. Бу вакыттан нинди йокы ди ул? Рәхәтләнеп утырабыз әле, әйеме?

Г ө л ч и р ә. Күрәсең, лампаның керәчине беткән.

З ә м з ә м б а н у. Бетсен, сукыр лампаны яндырырбыз, әйеме?

Г ө л ч и р ә. Сез теләсәгез нишләгез, мин ятам. *(Китә.)*

З ә м з ә м б а н у. Бар, бар, алдыңнан артың.

Ишек шакыйлар.

Н а һ а р. Кем бар?

М и р з а х а н. Бу без, түтәй, ач.

З ә м з ә м б а н у. Әйдәгез, җанкисәкләрем.

Ишекне ача. Туңган, калтыранган М и р з а х а н, Б а с а р ы й, Я с ә в и керәләр.

М и р з а х а н. Гөлчирә кая?

З ә м з ә м б а н у. Теге якта, бар...

Мирзахан китә.

Б а с а р ы й. Әхмәт Ясәви!
Я с ә в и. Әү, Мөхәммәт Басарый...
Б а с а р ы й. Утны сүндер.
Я с ә в и. Уф...

Караңгыда калалар.

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Аюхановлар өенең залы. Төрле якка китә торган ишекләр. Пәрдә ачылганда янып торган мич алдында А й с ы л у җырлап утыра.

А й с ы л у. Су буена төшкәнем юк,
Үсә микән тал-тирәк;
Яна дисәм, ялкыны юк,
Ялкынсыз яна йөрәк.

Эчке бүлмәләрнең берсеннән кычкырып Х а н з а ф а чыга.

Х а н з а ф а. Айсылу, Айсылу, дим, Касыймхан кайтты, бар, капка ач.

Айсылу чыгып китә. Бераздан К а с ы й м х а н белән әйләнеп керә.

К а с ы й м х а н. Нихәл, әнкәй, исән тордыңмы?
Х а н з а ф а. Бик яхшы, улым, үзең исән-сау кайттыңмы соң? Ни карап торасың, өсләрен салдыр.

А й с ы л у К а с ы й м х а н н ы чишендерә.

Бар, самовар куй.

Айсылу китә.

К а с ы й м х а н. Ссс... көн салкын икән, туңдырган.
Х а н з а ф а. Әйдә, улым, менә монда мич алдына утыр. Хәзер Мирзахан да торыр. Бергәләп чәй эчәрбез.
К а с ы й м х а н. Мирзахан? Ул өйдәмени?
Х а н з а ф а. Өйдә, кичә кунакка кайтты.
К а с ы й м х а н. Гаҗәп бер кеше булды инде ул егет. Авыл белән шәһәр арасында гулять итеп акча туздыра.
Х а н з а ф а. Я, улым, сәүдәләрең ничек, уң булдымы соң?
К а с ы й м х а н. Яхшы, әнкәй. Казна белән йөз меңле контракт языштым. Шәһәр торгменда Воронцовларның Өчтамак пристанендагы икмәк контораларын сатып алдым.
Х а н з а ф а. Воронцовларның? Ә үзләре?
К а с ы й м х а н. Алар бөлделәр. Бөтен вексельләре протестка керәп, үзләре банкротлыкка чыктылар. Хи-хи-хи...

Х а н з а ф а. Нишләп алай? Янәшә-тирәне үз кулларында тоталар иде ич.

К а с ы й м х а н. Алар, әнкәй, иске байлар, яңача сәүдә итә белмиләр. Эх... байлык, дәүләт артыннан чабу шулкадәр күңелле, шулкадәр ләззәтле эш икән... йөргән саен рух күтәрелеп, тәнгә җиңеллек кертә.

Х а н з а ф а. Син яшьтән үк тынычсыз, мал җанлы идең. Малайлар белән кузна уйнаганда да, ашау-эчүеңне онытып, көннәр буе өйгә кайтмый йөри идең.

К а с ы й м х а н. Әтидән алган бер меңлек суманы өч-дүрт ел эчендә җитмеш-сиксән меңгә җиткерү, казнадан йөзәр меңләп авансларалу — кеше акылы җитмәслек могҗиза! Безнең хәзер ике базарда отделениебез бар. Өчтамак пристане да безнең кулда. Җәйгә анда асты таш, өсте агачтан бер йорт салдырып җибәрербез. Аскы катында — зур магазин, өске катында — контора. Контора түбәсендә — Кама пароходларын берничә чакрымнардан котлап алучы «Торговый дом братьев Аюхановых» дип язылган вывеска булыр. Аннан паровой тегермән, аннан кыр казыдай баржалар таккан буксир пароходларыбыз моннан Нижнийга, Нижнийдан Астраханьга йөреп торырлар. Ә аннан чит илләр белән, Берлин, Лондон белән эш итү... шайтан алгыры, хыял гына да нинди тәмле бит...

Х а н з а ф а. Амин, улым, шулай булсын.

А й с ы л у керә.

А й с ы л у. Абыстай, Хәдичә остабикә килгән.

Х а н з а ф а. Аның шул булыр инде, синең кайтуыңны күреп нәфесен сузып йөри торгандыр. *(Чыгып китә.)*

А й с ы л у. Касыймхан, түбән өйдә Нурия мөгаллимә көтә. Керергә ярыймы икән, ди.

К а с ы й м х а н. Ник ярамасын, бик ярый, керсен. Аннан кибеткә төшеп Ясәвине җибәрерсең, шуннан берьюлы каенатаң Биктимер картны чакырып кайтырсың.

Айсылу китә, Н у р и я керә.

Әйдә, Нурия, рәхим итегез.

Н у р и я. Рәхмәт.

К а с ы й м х а н. Я, Нурия, ни хәлләр бар?

Н у р и я. Иң әүвәле сездән алган акчаларның хисабын бирим әле. *(Кәгазьләр бирә.)*

К а с ы й м х а н. Ярый, вакытым тисә, карармын. Йә, тагы нинди хәлләр бар?

Н у р и я. Утын бетте, ягарга юк. Бер атнадан бирле балаларның ата-аналарыннан тумранлап җыеп ягабыз.

К а с ы й м х а н. Күңелсез. Тагын нинди хәлләр бар?

Н у р и я. Аннан, керосиныбыз азайды.

К а с ы й м х а н. Бик тиз, күптән түгел генә алган идегез түгелме?

Н у р и я. Өч лампага бүлә башлагач, озакка бармый шул.

К а с ы й м х а н. Саклап яндырсыннар, керосин мәсьәләсе җитди мәсьәлә икәнен беләсез. Йә, тагын нинди хәлләр бар?

Н у р и я. Аннан, китап, кәгазьләр җитешми. Җиде-сигез балага бер китап. Шуның аркасында балалар дәрескә хәзерлексез киләләр.

К а с ы й м х а н. Юк бит, бу юлы да шәһәр китапчыларына кереп сөйләштем, юк, диләр.

Н у р и я. Ул чагында Казаннан алдырырга кирәк. Мин сезгә нәширләрнең адресын биргән идем шикелле.

К а с ы й м х а н. Минем эшем ул гына түгел шул, Нурия, бөтен волостьны товар белән тәэмин итү миңа йөкләнгән.

Н у р и я. Акчасын бирегез, үзем соратып алырмын. Гомумән, быел уку башланганнан бирле мәктәпкә кергәнегез, дәресләрнең ничек барышы турында сорашканыгыз да юк. Сез бит авыл белән сайлап куелган кеше, халыкның ышанычын акларга иде.

К а с ы й м х а н. Турысын әйткәндә, Нурия, мин сезне кызганам. Кара мужик кызларын укытам дигән булып нигә ул кадәр янып-көеп йөрергә? Бигрәк тә минем белән нигә яманатлы булырга? Мин бит сезнең өчен яхшы теләктәге кеше.

Н у р и я. Анысы өчен рәхмәт. Ләкин кызлар мәктәбенең язмышына кискен үзгәреш кирәк. Юкса өй саен утын сорап йөрү, балаларның ата-аналарын борчу мине туйдырды инде.

Б а с а р ы й керә.

К а с ы й м х а н. Йә, Нурия, тагын нинди хәлләр бар?

Н у р и я. Хәзергә шулар җитеп торыр. Хушыгыз. *(Китә.)*

Б а с а р ы й. Кырыс хатын шул, кырыс.

К а с ы й м х а н. Син дә уңмаган, шул көннән бирле аулый алмыйсың.

Б а с а р ы й. Юк бит, каһәр, бирелми. Төрле юллар белән кылын тартып карадым, җайга килү сизелми. Кичә шулай өйләрендә икәү генә идек, эх, мин әйтәм: әгәр дә мин хатын-кыз булсам, Касыймхан кебек кешегә ия булуны үземә максат итеп куяр идем дим, һәм шунда аның турында нинди караштa булуыңны сөйләдем. Аңламаганга салыша.

К а с ы й м х а н. Куй инде, куй, җанлы талкы булудан башкага ярамыйсың.

Б а с а р ы й. Ярарбыз әле, туры юл белән булмаган икән, башка җаен табарбыз...

К а с ы й м х а н. Нинди җаен?

Б а с а р ы й. Бүген авылга килгән хатларны ачып укыганда, бик кызыклы бер хат юлыкты. Тыңла, укыйм. Хатны Биктимер картка Нургали белән бергә хезмәт итүче бер солдат яза, менә нәрсә ди ул: «Биктимер абзый, сезнең улыгыз Нургали, венгр кавалериясенә каршы атакага барганда аты үлеп, дошман ягында калды».

К а с ы й м х а н. Димәк, Нургали пленда?

Б а с а р ы й. Шулай булып чыга. Ләкин без аны үтерәбез.

К а с ы й м х а н. Ничек?

Б а с а р ы й. Аты дигән сүзне бетерик әле, күрерсең. *(Хатны өстәлгә куеп, сүзне бетерергә керешә.)*

К а с ы й м х а н. Тукта, син нишлисең? Һич аңламыйм.

Б а с а р ы й. Хәзер аңларсың. Тыңла, укыйм: «Сезнең улыгыз Нургали, венгр кавалериясенә каршы атакага барганда үлеп, дошман ягында калды». Инде аңлашыламы?

К а с ы й м х а н. Әйе, бик яхшы аңлашыла, эт кеше икәнсең.

Б а с а р ы й. Менә шуннан соң инде Нурия артыннан ялынып йөрисе дә юк. Атасы Әхтәри абзый белән генә сөйләшергә кирәк.

К а с ы й м х а н. Сугыш бетеп, Нургали кайтып килсә?

Б а с а р ы й. Бердән, бу сугыш тиз генә бетәчәк түгел. Икенчедән, мир булып Нургали кайтканчы берничә балагыз булыр. Мин хәзер бу хатны бик әйбәтләп ябыштырам да берәр малай белән Биктимер картка җибәрәм.

К а с ы й м х а н. Кара аны, соңыннан миңа бәласе булырлык булмасын.

Б а с а р ы й. Кайгырма, майлагандай булыр.

Я с ә в и керә.

Ярый, мин китим, сезгә уңайсызламыйм. *(Китә.)*

К а с ы й м х а н. Сөйлә, Ясәви, сәүдәләр ничек?

Я с ә в и. Үкертәбез генә. Ике базарда да яхшы сәүдә иттек. Отделениеләрнең дә эшләре канәгатьләнерлек. Кичә бер айлык хисапларын һәм кассаларын тапшырдылар. Ләкин, Касыймхан, бу Мирзахан белән нишләргә? Кайта да кассага кул суза. Кичә тагын миннән йөз сум акча алды.

К а с ы й м х а н. Йөз сум акча алды? Соң бит сиңа бер тиен дә акча бирмәскә дип әйтелгән!

Я с ә в и. Анысы шулай, ләкин аның холкын беләсең. «Син кысылма» дип кенә җибәрә.

К а с ы й м х а н. Син доверенный түгел, чүпрәк! Соңгы мәртәбә әйтәм: минем рөхсәтемнән башка бер тиен бурыч һәм кассадан акча бирмәскә.

Я с ә в и. Бетте, бетте, күзенә кырып салырга да бирмим.

К а с ы й м х а н. Бүгеннән керосин, тоз, чәй-шикәр кебек товарларны акчага сатуны туктатып, фәкать икмәккә алыштырыгыз.

Я с ә в и. Гафу итегез, аңлап җиткермим.

К а с ы й м х а н. Сәүдә тәртибен үзгәртеп, бөтен басымны икмәккә ясыйбыз. Мин шәһәр торгиенда Өчтамак пристанен сатып алдым. Иртәгәдән андагы амбарларга ремонт ясатырга кирәшәбез.

Я с ә в и. Алай... Димәк, мондагы кибетләрне ябабыз?

К а с ы й м х а н. Киресенчә, киңәйтәбез. Тагын берничә базарда отделениеләр ачу ягын карарга кирәк булыр.

Я с ә в и. Ләкин товарлар азайды, Касыймхан.

К а с ы й м х а н. Товар мәсьәләсе хәл ителгән. Безгә, хәзер икмәк ташыру шарты белән, бөтен кирәкле товарларны военный ведомство җибәреп торачак. Син бүген калага китәрсең, илле мичкә керосин, йөз капчык шикәр, егерме ящик чәй алып кайтырсың.

Я с ә в и. Уһу... Алай булганда эшләр шәп икән.

К а с ы й м х а н. Эшләр хәзер башка, Ясәви! Тиздән бөтен өяз минем кулда булачак. Син бар, калага бару өчен олаулар әзерлә.

Я с ә в и. Минем, теге, солдат мәсьәләсе нишләде?

К а с ы й м х а н. Әйе, әйтергә онытып торам икән, кереп сөйләштем, тагын алты айга калдырырга булдылар.

Я с ә в и. Ай рәхмәт, Касыймхан, мин сиңа...

К а с ы й м х а н. Ярый, төчеләнмә, бар, эшеңдә бул.

Ясәви китә, Касыймхан уйланып йөри.

Асламчы килгән урамга,
Асыл алыйк юрганга.

Хи-хи-хи, нинди аңгыралык! Димәк, борынгы сәүдәгәрләр урам буенча кызыл мал сатып йөргәннәр.

Б и к т и м е р керә.

Б и к т и м е р. Әссәламегаләйкем.

К а с ы й м х а н. Вәгаләйкемәссәлам. Әйдә, Биктимер абзый, түрдән — кәнәфигә уз.

Б и к т и м е р. Минем аяклар пычрак, моннан да ярар.

К а с ы й м х а н. Йә, Биктимер абзый, ни эшләр бетереп ятасыз?

Б и к т и м е р. Мактанырлык түгел, Касыймхан. Барлы-юклы ашлыгымны сатып алган диләнкедән дугалар ясаган идем, шу-

лар белән базардан базарга йөреп карадым, берсен дә сата алмадым.

К а с ы й м х а н. Малайлардан хәбәр киләме?

Б и к т и м е р. Моннан бер ай элек Нургалидән хат алган идек. Мирвәлидән, сигез ай тула инде, хәбәр юк. Соңгы көннәрдә Мирхәйдәр дә язмый башлады.

К а с ы й м х а н. Әйе, сезнең гаиләгә авыррак килде шул. Хат язганда үзләренә миннән сәлам әйтеп язгыгыз. Менә нәрсә, Биктимер абзый, көзен кибеттән бурычка әйберләр алган идегез. Шуларны бу көнгә кадәр түләгәнегез юк.

Б и к т и м е р. Хәлем бик авыр бит, Касыймхан.

К а с ы й м х а н. Хәлем бик авыр дип булмый, Биктимер абзый. Шәригать тә, закон да алган бурычыңны түләргә куша.

Б и к т и м е р. Ансы шулай, тик юк лабаса, юк... Әнә булмаса, ясап куйган дугаларым бар, шуларны алыгыз.

К а с ы й м х а н. Мин алар белән нишлим?

Б и к т и м е р. Кибетләрегезгә куеп сатарсыз.

К а с ы й м х а н *(үз-үзенә)*. Әйе, синең утыннарыңны гына төяп йөрисе калган иде, ди. Менә нәрсә: мин Воронцовларның Өчтамак пристанендагы икмәк конторaларын сатып алдым. Шундагы амбарларга, сушилкаларга вак-төяк төзәтүләр кирәк булачак. Бирәчәкләрең хисабына, бәлки, син аларны миңа эшләп бирерсең?

Б и к т и м е р. «Бирәчәгең бирми, гүргә кереп булмый» дигәндәй, ярый инде, эшләрмен...

К а с ы й м х а н. Бар, кучер Җамалига чыгып әйт, ат җигеп бирсен, кай җирләрен төзәтергә һәм нинди агач материаллары кирәклеген карап кайтырсың.

Б и к т и м е р. Ярый...

Китә. М и р з а х а н чыга.

М и р з а х а н. Хәерле иртәләр, абый.

К а с ы й м х а н. Син тәмам барин булдың, Мирзахан. Төш җиткән, һаман йоклап ятасың.

М и р з а х а н. Мин төн буе укып утырган идем. Йә, абый, эшләрең ничек?

К а с ы й м х а н. Яхшы, тик син генә минем эшемә уңайсызлыйсың.

М и р з а х а н. Ничек уңайсызлыйм?

К а с ы й м х а н. Ни өчен кассадан акча аласың?

М и р з а х а н. Менә кызык! Кирәк булганга.

К а с ы й м х а н. Шәһәргә барып гулять итәргә? Тәтәйләрдә типтерергәме? Моннан соң минем рөхсәтемнән башка кибеткә төшәргә, кассага кулың сузарга хакың юк... *(Китә.)*

Мирзахан. Абый, син мине хаксыз рәвештә хәкарәт итәсең. *(Артыннан китә.)*

Гөлчирә керә, төрле якка карана. Айсылу чыга.

Гөлчирә. Җиңги, әти кайда?
Айсылу. Касыймхан абый аны хәзер генә каядыр йомыш белән җибәрде. Кирәк идемени?
Гөлчирә. Өйгә хат китерделәр... Нургали абый үлгән...
Айсылу. Нургали үлгән?..
Ханзафа *(эчке бүлмәдән).* Айсылу, Айсылу, дим!
Айсылу. Тамагыңа таш кергере! *(Китә.)*

Мирзахан чыга.

Гөлчирә. Мирзахан... *(Ташлана.)*
Мирзахан. Чү, Гөлчирә, әни күрмәсен.
Гөлчирә. Мирзахан, узган кайтуыңда да мине күрмәдең, кичә кеше җибәреп чакырттым, нигә килмәдең?
Мирзахан. Авырый идем. Юлда суык тидердем.
Гөлчирә. Кайтып яхшы иткәнсең. Мин синең яныңа барырга тора идем.
Мирзахан. Минем яныма? Анда нәрсәгә?
Гөлчирә. Мин сине шулкадәр сагындым...
Мирзахан. Сагындың?
Гөлчирә. Әйе, сагындым... Аннан минем йөгем — көмәнем бар...
Мирзахан. Йөгең — көмәнең бар? Кемнән?
Гөлчирә. Ничек кемнән?
Мирзахан. Менә мин моны көтмәгән идем. Ничек инде ул алай булырга мөмкин?
Гөлчирә. Әллә син миннән шикләнәсеңме?
Мирзахан. Шикләнмим... Шулай да гаҗәпләнәм...
Гөлчирә. Гаҗәпләнерлек урын юк, син аны бик яхшы беләсең.
Мирзахан. Ансы миңа караңгы инде.
Гөлчирә. Эх, Мирзахан... Синең оятың кая? Минем бит шаһитларым бар...
Мирзахан. Елама, юләр кызый. Мин бит сиңа шаярып кына әйттем. Йә, тынычлан, син минеке идең, моннан соң да минеке булырсың. Тик менә бала гына... Тизрәк чара күрергә кирәк.
Гөлчирә. Минемчә, чара бер генә, халыкка беленмәс борын никах укытыйк.
Мирзахан. Булмый ул, Гөлчирә, мин учетта, казна кулында

эшләүче кеше, бүген монда булсам, иртәгә фронтка тотып җибәрүләре дә бик мөмкин.

Г ө л ч и р ә. Җибәрсеннәр, мин сине көтәрмен.

Х а н з а ф а керә, тыңлап тора.

М и р з а х а н. Әгәр дә мин анда үлеп калсам? Синең яшь гомерең әрәм булачак.

Г ө л ч и р ә. Юк, син үлмәссең. Мин сине бер ел, ике ел, хәтта өч ел көтәргә риза. Тик, зинһар өчен, халыкка беленгәнче никах укытыйк.

Х а н з а ф а. Никах?!

Г ө л ч и р ә. Ах!..

Х а н з а ф а. Син ни дип аның муенына сарыласың?

Г ө л ч и р ә. Юк, Ханзафа абыстай, сарылмыйм бит.

Х а н з а ф а. Ялганлама!.. Мин карап тордым. Ах син, себерке!

М и р з а х а н. Әнкәй! Алай дип син аны хурларга хакың юк. Чөнки ул минем сөйгәнем.

Х а н з а ф а. Сөйгәнең? Хи-хи-хи!.. Син, Шәүлихан старшина малае, шушындый бер пычрак мужик кызын сөясең?

М и р з а х а н. Мин сиңа тагын әйтәм, әнкәй, алай дип хурларга синең хакың юк!

Х а н з а ф а. Хурлау гына түгел, очраган бер егеттән үптереп, аулак өйләр саен кочтырып йөргән себеркене типкәләп чыгарырга да хакым бар. Бар моннан! Безнең йортта эзең булмасын! *(Китә.)*

М и р з а х а н. Гөлчирә, син аның сүзенә карама, мин сине сөям, шулай булгач, безнең арага беркем дә керә алмас. Менә сиңа акча.

Г ө л ч и р ә. Акча? Миңа нигә ул?

М и р з а х ан. Balаңны төшерергә кирәк булса дим.

Г ө л ч и р ә. Баламны төшерергә? Их, Мирзахан, мин бит сине чын күңелдән сөйгән идем.

М и р з а х а н. Нишлим соң? Без бит әле һаман да ата-аналар коллыгыннан котылып җиткәнебез юк. Син хәзергә минем сүзләремне генә тыңла, калганы бар да без дигәнчә булыр.

Г ө л ч и р ә. Юк, Мирзахан, икенче кат мине алдый алмассың.

М и р з а х а н. Нишләп мин сине алдыйм? Киресенчә, ярдәм итәргә телим.

Г ө л ч и р ә. Кирәкми миңа синең ярдәмең. Мә акчаларыңны! *(Битенә бәрә.)* Онытма, Мирзахан, кайчан да булса бер моның үчен синнән алырмын! *(Тиз генә чыгып китә.)*

Х а н з а ф а керә.

М и р з а х а н. Тупас син, әнкәй! Сезнең тормышыгыз тупас булган кебек, кешеләр белән булган мөгамәләгез дә шундый ук тупас! Хәзер бит кешеләрне яткырып тал чыбыгы белән кыйный торган чак түгел, кыйналган кешенең үзе сизмәслек итеп акыл камчысы белән кыйный торган заман. Ә сез тотасыз да кешенең маңгаена күсәк белән сугасыз!

Х а н з а ф а. Нишли алыр дип уйлыйсың? Муллага барыр, аннан ары китсә — судка бирер, ләкин нишләсә дә, безнең сүзебез сүз булыр.

Тышта тавыш-кычкырыш. Йөгереп Я с ә в и керә.

Я с ә в и. Касыймхан, Касыймхан кая?

К а с ы й м х а н бүлмәдән чыга.

К а с ы й м х а н. Нәрсә бар?

Я с ә в и. Хатын-кызлар тавыш чыгара, мине кыйнарга телиләр, көчкә кибетне ябып котылдым.

Җитез адымнар белән Г а й н а в а л керә.

Г а й н а в а л. Бу нинди яңа приказ? Тоз белән керәчин алырга дип килгән идем, менә бу ялагаегыз, икмәксез бирмибез дип, төртенә.

К а с ы й м х а н. Шулай сатарга аңа мин куштым. Бүгеннән чәйшикәр, тоз, керосин кебек товарлар бары тик икмәккә генә алыштырылачак.

Г а й н а в а л. Мин сатып алып ашаучы кеше, үземә булмаганны каян алып бирим ди?

К а с ы й м х а н. Синең өчен генә аерым закон чыгарып булмый.

Г а й н а в а л. Нишләп минем өчен генә булсын? Әнә кара, күпме халык җыйналган, бар да сатып алып ашаучы кешеләр.

К а с ы й м х а н. Түрәләрнең приказы шулай. Казнага икмәк кирәк. Солдатларны, сезнең ирләрегезне туйдырырга икмәк кирәк.

Г а й н а в а л. Туйганчы ашарлык икмәкләре дә булмагач, алмасыннар, сугышмасыннар.

К а с ы й м х а н. Синең белән минемчә шулай да, закон икенче төрле уйлый шул.

Г а й н а в а л. Әйтер идем инде, ачуым килмәгәе, закон, имеш! Бәрәңге манып ашарлык тозы да булмагач, ул нинди закон була ди! Кайтарыгыз безнең ирләребезне, бер әйберегез дә кирәкми!

К а с ы й м х а н. Синең иреңне мин алмадым. Алган кешедән сора.

Г а й н а в а л. Сез алдыгыз, синең атаң алды!

К а с ы й м х а н. Ярый, синең белән сөйләшеп торырга минем вакытым юк. Әнә чабатаңның кары эри.

Г а й н а в а л. Эресә, сөртерсез әле. Сугышка бармавыгыз гына җитмәгән, безне тереләй талап ятасыз.

К а с ы й м х а н. Бар, чык моннан.

Г а й н а в а л. Тоз белән керәчин алмый чыкмыйм.

К а с ы й м х а н. Яхшылап әйткәнне тыңламасаң, җилкәләп озатырмын.

Г а й н а в а л. Кулыңны тидереп кара.

К а с ы й м х а н. Әле син карышмакчы буласыңмы?

Г а й н а в а л. Тотынма миңа. Үз өең дип тормам, салып җибәрсәм, салма пешкәнче ятарсың. *(Кулындагы шешә белән кизәнә.)*

К а с ы й м х а н. Чыгасыңмы, юкмы?

Г а й н а в а л. Барыбер мин моны болай калдырмыйм. *(Китә.)*

М и р з а х а н. Абый, болай ярамый, чыннан да ул хаклы. Ашарына булмаганны, кайдан алып сиңа икмәк китерсен.

К а с ы й м х а н. Анда минем эшем юк, икмәк китермәсә — товар алмый, шул гына.

М и р з а х а н. Син бит бу эшең белән аларның безгә булган дошманлыкларын кабындырасың гына.

К а с ы й м х а н. Кабынса, нишли алырлар? Үз күләгәсеннән курыккан куян син...

М и р з а х а н. Ә син — комсыз хайван!..

Х а н з а ф а. Балалар, атагыз кайтты...

Ханзафадан башкалар чыгып китәләр. Бераздан бүре толып кигән мәһабәт гәүдәле Ш ә ү л и х а н керә.

Ш ә ү л и х а н. Картайдың, старушка, картайдың, каршы алырга да чыкмый башладың.

Х а н з а ф а. Әйдә, атасы, өсләреңне теге якта салырсың.

М и р з а х а н белән К а с ы й м х а н керә.

Ш ә ү л и х а н *(Мирзаханның аркасыннан сөеп).* Йә, сынок, эшләрең ничек?

М и р з а х а н. Яхшы, әткәй, үземне тагын бер айга отпускага җибәрделәр.

Ш ә ү л и х а н. Молодец, сынок, молодец... *(Сөйләшә-сөйләшә кереп китәләр.)*

Йөгереп З ә м з ә м б а н у керә.

З ә м з ә м б а н у. Җиңги, җиңги, дим...

А й с ы л у чыга.

А й с ы л у. Нәрсә, килендәш?

З ә м з ә м б а н у. Кара инде, тыным бетте, әйеме?

А й с ы л у. Сөйлә тизрәк, минем эшем бар.

З ә м з ә м б а н у. Мирвәли абый кайтты!..

А й с ы л у *(кулындагы әйберләрен төшереп җибәрә).* Мирвәли кайтты?..

З ә м з ә м б а н у. Әйе, кайтты.

А й с ы л у. Авырумы, әллә яраланганмы?..

З ә м з ә м б а н у. Юк, тап-таза, алты айга төзәлергә җибәргәннәр. Әйдә тизрәк.

А й с ы л у. Нишлим соң, тәмам аптырадым бит.

Эчке бүлмәдән кычкырып Х а н з а ф а керә.

Х а н з а ф а. Айсылу, Айсылу, дим!.. Монда икәнсең, нигә эндәшмисең?

А й с ы л у. Абыстай, минем ирем кайткан, күреп килергә рөхсәт ит инде.

Х а н з а ф а. Юк, юк, минем эшләремне кем эшли ди?

З ә м з ә м б а н у. Әйдә, җиңги, нәрсәгә шул чүмәләдән сорап торасың? *(Айсылуның кулыннан өстерәп китә.)*

Х а н з а ф а. Айсылу, Айсылу, абзаңны мунчага кертәсе бар! Менә сиңа, каһәрне, тыңламыйча китеп тә барды. Нишлим инде? Аш хәзерлисе бар, мунча өлгерде, минем башыма бәла булып каян кайтасы булгандыр. *(Онытылып.)* Айсылу, Айсылу, дим, әй, тфү!..

Ш ә ү л и х а н шигырь укып чыга.

Ш ә ү л и х а н.

Әгәр дә мин түгәрәк күл булып,
Шунда йөзгән аккош син булсаң;
Чылтырап аккан чишмә син булып,
Кырыйда үскән камыш мин булсам;
Бу дөньяның гөлбакчасы мин булып,
Түтәлдә үскән гөле син булсаң;
Гөлдә туйган орлык мин булып,
Чүпләүчесе, былбыл, син булсаң...

Х а н з а ф а. Нинди бәет укыйсың тагын?

Ш ә ү л и х а н. Иран шагыйре Ширазиның шигырьләрен өйрәнәм.

Х а н з а ф а. Тапкансың икән, башка эшең юкмыни?

Ш ә ү л и х а н. О... зур шагыйрь ул. Урта Азиядә тылмач булып йөргән вакытымнан бирле, аның шигырен кулыма төшерә

алмый йөри идем. Байсар хәзрәте вафат булгач, аңгы-миңге улыннан алдап алдым.

Кап-караңгы төн буенча
Мин янамын шәм кебек...
Тик син алда ялтырыйсың,
Бу җиһанга ямь түгеп.
Әйдә, иркәм, балкы шулай,
Балкы шулай нурланып,
Сүнсен анда бар гүзәллек,
Күз нурыңнан хурланып.

Мунчаң булдымы?

Х а н з а ф а. Нигә, батюшка хатыны кертмәдемени?

Ш ә ү л и х а н. Нинди батюшка хатыны?

Х а н з а ф а. Волостьтагы поп хатыны Матрена янына йөрисең, диләр.

Ш ә ү л и х а н. Ифтира, карчык, ифтира, дошманнар сүзе. Батюшка хатыны Матрена белән сине алыштыраммы соң?

К а с ы й м х а н керә. Ханзафа китә.

К а с ы й м х а н. Әткәй, синең белән җитди бер мәсьәлә турында сөйләшәсем бар иде.

Ш ә ү л и х а н. Сөйлә, улым, нинди җитди мәсьәлә ул?

К а с ы й м х а н. Үзең бик яхшы беләсең. Мин төннәремне йокламыйча шәһәрдән шәһәргә, базардан базарга чабам, мал табарга тырышам. Ләкин безнең Мирзахан минем дәүләтемне туздыра, атна саен монда кайтып, сәүдә эшләремә тыкшына.

Ш ә ү л и х а н. То-есть, ничек тыкшына?

К а с ы й м х а н. Минем юклыгымнан файдаланып, кибеттән бурычка товар өләшә. Минем рөхсәтемнән башка кассадан акча ала. Акча ала да, шәһәргә барып, тәтәйләрдә типтерә. Очраган бер җирдә минем белән талашып, кешеләр алдында абруемны төшерә. Ул, гомумән, безнең тормыштан риза булмыйча, әллә нинди сүзләр сөйләнеп йөри башлаган.

Ш ә ү л и х а н. Ну-ка, давай үзен бире...

Касыймхан китә. М и р з а х а н керә.

М и р з а х а н. Нигә чакырдың, әткәй?

Ш ә ү л и х а н. Әй син, малай!.. Нигә агаңны обижать итәсең? Нигә син аның сәүдә эшләренә тыкшынасың?

М и р з а х а н. Эш нәрсәдә, әткәй, мин аңламыйм.

Ш ә ү л и х а н. Молчать!

М и р з а х а н. Кычкырмыйча, яхшылык белән генә сөйләшик әле.

Ш ә ү л и х а н. Каршы сөйләмә син, молокосос!

М и р з а х а н. Әткәй, син мине хурлыйсың.

Ш ә ү л и х а н. Молчать!

М и р з а х а н. Син, әткәй, миңа акырынма. Мин синең ишегеңнән керергә куркып торган крестьяннарың түгел.

Ш ә ү л и х а н. Ох син, эттән туган дуңгыз баласы! Бөтен Россия халкы фронтларда кан түгеп йөргәндә, син тыныч кына учетта ятарга уйламыйсың. Син ишәк баласын биш-алты йөз сум ришвәт биреп солдаттан калдырган булсам, бүген тотып фронтка озатырга да кыйбат алмам.

М и р з а х а н. Фронтка китү минем өчен артыграк булыр иде. Ләкин минем анда булуым белән генә ватан язмышы хәл кылыначак түгел. Чөнки сез ватан белән җитәкчелек итә белмисез.

Ш ә ү л и х а н. Ничек, ничек, җитәкчелек итә белмибез? Мин Урта Азиядә рус генералларына яхшы тылмачлык итүем өчен его величество государь император хәзрәтләреннән рәхмәт алган Шәүлихан Аюханов булам. Ун ел өяздә суд заседателе, унбиш ел старшина булып, берничә медальләр алу дәрәҗәсенә ирешкән атаңа каршы мондый сүзләр әйтергә ничек җөрьәт итәсең?

М и р з а х а н. Минем сүзләрем дөрес. Бөтен аппаратыгызда эшсезлек, ришвәтчелек, талаучылык, шуның өчен дә гаскәр сугышмый, штабларга немец шпионнары кереп урнашкан. Генераллар хыянәт итеп безне саталар. Зур шәһәрләрдә ачлык, бөлгенлек. Транспорт эштән чыккан. Завод-фабрикаларда күмер, нефть юк, крестьян хуҗалыгы көннән-көн җимерелеп, һәлакәткә бара.

Ш ә ү л и х а н. Молчать!.. Каторжаннар сүзен сөйлисең.

М и р з а х а н. Бу сүзләрне мин генә түгел, туып килә торган революция дәһшәтеннән ватаныбызны коткарып калырга теләүче һәрбер укыган кешеләребез әйтәләр. Әгәр дә без тизлек белән чара күрмәсәк, кара халык толпасы һәммәбезне җир йөзеннән себереп түгәчәк.

Ш ә ү л и х а н. Ялганлыйсың, нахально ялганлыйсың!

Х а н з а ф а керә.

Х а н з а ф а. Ни булды сезгә, нигә талашасыз?

М и р з а х а н. Бөтен ил белән канлы яшь түгелә. Ул яшьләр беркөнне...

Ш ә ү л и х а н. Молчать! Вон моннан, вон минем өемнән!

М и р з а х а н. Ярый, мин китәм...

Х а н з а ф а. Юк, юк, улым, мин сине җибәрмим.

Ш ә ү л и х а н. Ялынма шул эттән туган дуңгызга!..

Артта хатын-кызлар тавышы.

Г а й н а в а л. Әйдәгез старшинага, нигә безне талата ул?
Ә х т ә р и. Карагыз әле, җәмәгать, бу ни кылануыгыз?

К а с ы й м х а н чыга.

К а с ы й м х а н. Нинди тавыш ул?
М и р з а х а н. Әнә күрегез, солдаткалар өегезгә басып керәләр.

Ишек ачыла. Ә х т ә р и белән Б а с а р ы й күренә.

Ә х т ә р и. Кермәгез, таяк ашыйсыгыз киләмени?
Г а й н а в а л. Бүлмә безне, җибәр старшинага!

Бәреп җибәрә, аның артыннан хатын-кызлар өйгә кереп тулалар.

*Пәрдә.*

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук Биктимер карт өй эче. Пәрдә ачылганда Б и к т и м е р белән М и р в ә л и сөйләшеп утыра.

Б и к т и м е р. Миңа бернәрсә дә кирәкми. Бүген бар, иртәгә юк дигәндәй, миңа өч аршин җир җитә.

М и р в ә л и. Юк шул, әти, өч аршин җир үле гәүдә, җансыз мәет өчен генә ул. Кешегә дөньяда яшәү өчен матур табигать, җир-сулар, шаулап торган урманнар кирәк. Әйләнә-тирәдәге иксез-чиксез алпавыт җирләренә, очсыз-кырыйсыз казна, удел урманнарына карап торырлык булгач, крестьян булып яшәвеңдә ни файда?

Б и к т и м е р. Файда дип, безгә аңардан файда юк инде, тик ярман патшасын җиңсәләр, яңа манифест чыгар, җирсез крестьяннарга җир бирерләр дип өмет итәсең.

М и р в ә л и. Манифест? Кем чыгара соң ул манифестны?

Б и к т и м е р. Кем булсын, патша хәзрәтләре.

М и р в ә л и. Соң бит ул үзе алпавыт.

Б и к т и м е р. Ничек алпавыт?

М и р в ә л и. Алпавытның да ниндие генә әле. Бер миллион десятина җире бар. Өлкән һәм кече князьләренең — ун миллионнан артыграк. Шушы кешеләр ничек итеп крестьян файдасына манифест чыгарсын. Менә син, әти, әйт әле, безнең өчен сугыш кирәк идеме?

Б и к т и м е р. Безгә кирәкми дә бит, ничә әйтсәң дә, патша хәзрәтләренә кирәк.

М и р в ә л и. Аңа нәрсәгә?

Б и к т и м е р. Ярман солдатлары безнең җиргә басып кергәннәр дип сөйләделәр бит.

М и р в ә л и. Бар да ялган. Рус солдатына сугыш кирәк булмаган кебек, немец солдатына да кирәкми. Менә миңа нәрсәгә сугыш? Торырлык урыным, йортым да юк. Бүген эшләмәсәм, иртәгә ашарлык икмәгем дә юк. Ә шулай да мине көчләп сугышка куалар. Шул ук вакытта, бай балалары, көннән-көн баеп, кесәләрен алтын-көмеш белән тутыралар.

Б и к т и м е р. Бу сүзләрең дөрес, улым. Шәүлихан малайларын гына алып карыйк. Сугышка кадәр бакали белән кыты-мыты итеп маташкан кешеләр шушы бер ел эчендә искитәрлек булып баедылар. Әнә Өчтамак пристанен сатып алганнар. Паровой тегермән салдырам, пароходлар алам дип мактана, ди.

М и р в ә л и. Менә шуның кебекләр нигә сугышка бармыйлар?

Б и к т и м е р. Мондагы рәхәтне ташлап, күрәләтә үлемгә барырга юләр түгел бит алар.

М и р в ә л и. Алар өчен булган сугышта минем дә үләсем килми. Шулай ук Мирхәйдәрнең дә, Иванның да, мәрхүм Нургалинең дә үләсе килмәгәндер. Нигә алар безне көчләп алалар да, суеларга хөкем ителгән хайваннар көтүе шикелле, сугышка куалар? Нигә алар, гомерендә түтәл бакчасы да булмаган, тамагы икмәккә, өсте киемгә туймаган Гайнавал кебек хатыннарны, ирләреннән аерып, миллион аналарны, миллион балаларны елаталар?

Б и к т и м е р. Әйе, улым, уйлап карасаң, чыннан да, шулай. Өйләр ятимнәр, урамнар хәерче, гарипләр белән тулды. Кара әле, улым, әгәр мин әйтәм, бөтен солдатлар, коралларын ташлап, сугышмасалар, берни дә эшли алмаслар иде.

М и р в ә л и. Юк инде, әти, безнең кулга корал эләккән икән, аны ташларга ярамый. Без аны бүгенме, иртәгәме үз патшабызга, капиталист-байларыбызга каршы борырга тиеш.

Б и к т и м е р. Куй, куй, улым. Тәүбә-әстәгъфирулла, диң. Кеше ишетсә, әллә ни уйлавы бар.

Ә х т ә р и керә.

Ә х т ә р и. Сәламегаләйкем.

Б и к т и м е р. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, кода.

Ә х т ә р и. Саумы, Мирвәли кода?

М и р в ә л и. Шөкер әле, Әхтәри абзый, үзеңдә ни хәлләр бар?

Ә х т ә р и. Эш күп, кода, эш. Берсен үтәргә өлгермисең, икенчесен китереп тоттыралар. Кичә ясакны илтеп тапшырдым, бүген яңа указ җибәргәннәр.

Б и к т и м е р. Нинди указ тагын?

Ә х т ә р и. Икенче чираттагы атларны китерергә кушалар.

Б и к т и м е р. Атларны? Соң?

Ә х т ә р и. Шул, сезнең җирән алашаны да таңнан волостька илтергә кирәк булыр, дип керүем иде.

Б и к т и м е р. Тукта әле, минем бердәнбер атым, аны биргәч, үзем нәрсә белән калам ди?

Ә х т ә р и. Анысын мин белмим инде, патша хәзрәтләренең указы шулай.

Б и к т и м е р. Өч улымны бирдем, бозаулы сыерымны алдыгыз, бераз гына оят кирәк иде, кода.

Ә х т ә р и. Үзем өчен түгел бит, патша хәзрәтләренең указы шулай.

Б и к т и м е р. Безнең семьяга гына каныгырга димәгәндер, нигә башкалар бирмиләр?

Ә х т ә р и. Бирәләр, барыбыз да бирәбез. Менә мин йөгән дә кидермәгән биш яшьлек айгырымны илтергә торам.

Б и к т и м е р. Синең аннан башка да җитәрлек, утарың тулы. Минем бердәнбер алашам.

Ә х т ә р и. Ярый, ярый, сүз көрәштерә торган чак түгел, патша хәзрәтләренең указы шулай. Иртәгә тугыз сәгатьтә правлениедә булырга, атыңның башында каеш нуктасы белән җылы җабуты булырга тиеш. Оныта күрмәгез. Патша хәзрәтләренең указы шулай. *(Китә.)*

Биктимер сүзсез аптырап кала. Г ө л н и с а бүлмәдән чыга.

Г ө л н и с а. Улым, Мирвәли, Айсылу килен китәбез дип әйберләрен җыештырып йөри, ул ни дигән сүз?

М и р в ә л и. Әйе, әни, мин сезгә әйтергә кыймый йөри идем, без таңнан китәбез.

Б и к т и м е р. Китәсез? Кая?

М и р в ә л и. Элек эшләгән җиребезгә, заводка.

Б и к т и м е р. Ул ничек була инде? Димәк, безне тагын ташлыйсыз?

М и р в ә л и. Шулайрак, әти.

Г ө л н и с а. Синең кайтуың, балам, безне шатландырып, Нургалинең үлемен оныттырган иде.

Б и к т и м е р. «Ата-ана күңеле балада, бала күңеле далада» дип, белеп әйткәннәр. Мин бит сезне кайгылы чакларымда киңәшчем, аптыраган чакларымда булышчым булырсыз, дип үстергән идем.

М и р в ә л и. Әйе, әти, мин сезне аңлыйм... Ләкин минем сездә бер көн артык торуым үзем өчен, шулай ук сезнең өчен дә бик зур бәхетсезлек китерү куркынычы бар.

Г ө л н и с а. Әллә, улым, качып кайттыңмы?

Б и к т и м е р. Эх, балалар... балалар... Сезне карап үстерүгә биргән көчләремне башка бер әйбергә куйган булсам, яхшырак булыр иде. Мин сине башка балаларым арасында иң акыллысы, иң шәфкатьлесе дип йөри идем, син дә миһербансыз икәнсең.

М и р в ә л и. Әти, алай миңа әрни торган булсаң, мин сиңа эшнең ничек булганын сөйләп күрсәтим.

Б и к т и м е р. Кирәкми, бер сүзеңне дә тыңламыйм. «Үтмәс балта сөяк чабарга ярый ул». Без дә кирәк булырбыз әле. Әйдә, карчык.

Г ө л н и с а. Улым, китмә, кал безнең янда.

Б и к т и м е р. Ялынма, үзем исән чакта алар ярдәменә калмассың, әйдә...

Китәләр. Мирвәли уйланып йөри. А й с ы л у керә.

А й с ы л у. Мирвәли, тагын ни булды? Әткәй белән әнкәй моннан чыктылар да елыйлар.

М и р в ә л и. Китүебез турында әйткән идем, җибәрәселәре килми.

А й с ы л у. Чыннан да, алар хаклы, Нургалинең үлү хәбәре аларны әрнетә. Шуның өстенә ашарларына беткән, актык куәсләрен изделәр. Әгәр дә атларын да алсалар, белмим, нишләрләр инде... минемчә — китмик, калыйк шунда, үзләренә булышырбыз, ярдәм итәрбез.

М и р в ә л и. Минем хәлем аларныкына караганда яманрак һәм куркынычрак икәнен берегез дә белмисез, мин хәрби кыр суды тарафыннан алты елга хөкем ителгән кеше.

А й с ы л у. Алты елга? Ни өчен?

М и р в ә л и. Без тора торган шәһәрдә эшчеләрнең сугышка каршы демонстрацияләре булды. Шунда безнең батальонны демонстрантларга каршы атарга чыгардылар. Без, әлбәттә, атмадык. Менә шул эштә безне гаепләп кулга алдылар. Билгеле, икенче көнне үк безгә кыр суды ясап, икебезне унике елга каторгага, калган дүртебезне алтышар елга хөкем иттеләр.

А й с ы л у. Алай булгач, син ничек монда кайттың?

М и р в ә л и. Бер иптәшем белән төрмәдән качтым. Урал ягына барышлый, сине алып китәргә дип кенә монда туктадым.

А й с ы л у. Ярабби, гомеребез буена шулай кан йотып торырбыз микәнни?..

Мирвәли. Елама, Айсылу. Хәзергә минем хәлем ул кадәр начар түгел, кулымда документым да бар, теләгән җиргә барып эшкә керә алам, ләкин монда гына торырга ярамый. Син, Айсылу, миннән башка торып елакка әйләнгәнсең. *(Кочагына алып иркәли.)* Эх сине... Я, беттеме?

Айсылу *(елмаеп карап тора, берни дә булмаган кебек итеп)*. Бетте...

Мирвәли. Күптән шулай диләр аны. Нык булырга, тормышта көрәшергә кирәк, Айсылу... *(Сөя.)*

Артамонов керә.

Артамонов. Исәнме, Айсылу?

Айсылу. Бик әйбәт, Мироныч. Әйдә, өстеңне сал.

Артамонов. Рәхмәт, Айсылу, вакытым юк. Әйдә, Мирвәли, безне көтәләр.

Айсылу. Сез кая?

Мирвәли. Камали абзый чәйгә чакырган иде...

Айсылу. Ай-һай, Мирвәли, чәйгә микән?

Мирвәли. Ярый инде, ярый, шаулама. Бар, син әтиләрне юат, тынычландырырга тырыш. *(Айсылуны бүлмәгә озата.)* Әйдә, Гриша, киттек.

Китәләр. Ишек янында Гайнавал белән очрашалар.

Әйдүк, Гайнавал җиңги, түрдән уз.

Гайнавал. Узып тормыйм, Мирвәли. Мине нәрсәгә чакырган идең?

Мирвәли. Мин бүген сиңа кергән идем, үзеңне туры китерә алмадым. Салкын өйдә киемсез балаларыңны күреп, йөрәгем әрнеде. Бигрәк тә, өстенә булмагач, өлкән улың сабакка йөрми икән. Менә мә. *(Акча чыгарып бирә.)* Шул балага өс-баш алырсың.

Гайнавал. Кирәкми, Мирвәли, сез үзегез дә юл кешесе.

Мирвәли. Син безнең өчен кайгырма, ничек тә аптырамабыз. Курыкмыйча ал, бу минем генә ярдәмем түгел, эшчеләрнең авызларыннан өзеп җыеп биргән тиеннәре ул.

Гайнавал. Моның өчен мин сиңа ни дияргә дә белмим.

Мирвәли. Аннан, менә бу иптәшне таныйсыңмы?

Гайнавал. Волостьта тегү машинасы сатучы түгелме соң?

Артамонов. Нәкъ шул үзе, абыстай. Мин хәзер почтада эшлим. Син минем янга килгәлә, сөйләшеп утырырбыз, кайгы-хәсрәтләрне уртаклашырбыз.

Мирвәли. Сиңа, Гайнавал җиңги, бу иптәш белән бик нык бәйләнештә булырга кирәк. Ул сиңа булышыр, ярдәм итәр.

Г а й н а в а л. Нәрсә турында сүз бара, төшенмим?

М и р в ә л и. Әйдә, Камали абзыйларга керик, шунда төшендерербез.

Китәләр. Кайгылы хәлдә Г ө л ч и р ә кайтып керә. Үзен кая куярга белмичә, аптырап йөри. Уйланып җырлый.

Г ө л ч и р ә.

Инде нишлим, ал чәчәктәй яшьлегемне
Кара болыт төсле кайгы каплагач,
Саф йөрәктән булган керсез мәхәббәтем
Аяк асларына салып тапталгач?..
Күзләремә тулган кайнар яшем белән,
Ник алардан ярдәм, өмет мин көтәм?
*(Бишмәт кесәсеннән шешә чыгарып.)*
Шул алдакчы, бер әшәке кабахәттән
Шуның белән үч алырга ант итәм!..

А й с ы л у керә.

А й с ы л у. Гөлчирә, нәрсә ул?

Г ө л ч и р ә *(каушап)*. Берни дә түгел, җиңги, кершән шешәсе...

А й с ы л у. Кая, бир әле миңа.

Г ө л ч и р ә. Ярый инде, җиңги, сиңа кирәкми ул...

А й с ы л у. Гөлчирә, дөресен сөйлә, сиңа ни булды?

Г ө л ч и р ә. Җиңги, бәгырем, мин алдандым, минем йөгем бар...

А й с ы л у. Йөгең бар? Кемнән?

Г ө л ч и р ә. Мирзаханнан.

А й с ы л у. Эх, Гөлчирә, син бит акыллы кыз идең, нишләп алдандың?

Г ө л ч и р ә. Сорама, җиңги, тасма телләре белән күңелемне аулады. Нишлим, җиңги, менә шушы кислотаны битенә сибимме, я барып муенына сарылыйммы?

А й с ы л у. Куй, юләр. Икенче кат үзеңне түбәнәйтергә уйлыйсыңмы? Ярый, булган эш беткән, абыең белән киңәшеп, берәр җаен табарбыз.

Г ө л н и с а керә.

Г ө л н и с а. Килен, камырың кабарган.

А й с ы л у. Шулайдыр шул. Әйдә, Гөлчирә, миңа булышырсың.

Китәләр. Б и к т и м е р керә.

Б и к т и м е р. Ай-яй, тышта буран күтәрелде, малларны ябып керим әле.

Г ө л н и с а. Әтисе, тукта әле, мин бая мич казнасыннан бер тимер кисәге таптым. *(Револьвер күрсәтә.)*

Б и к т и м е р. Яхшы тимер кисәге... Мылтык ич бу.

Г ө л н и с а. Кит аннан, мылтык озын көшшәле була түгелме соң?

Б и к т и м е р. Моңа ләвәрвир диләр. Әфичәрләр, үрәдникләр тага торган мылтык.

Г ө л н и с а. Үзем дә шундый нәрсәдер дип уйлаган идем. Каян килде икән безгә?

Б и к т и м е р. Каян булсын, билгеле инде, теге акыллы башныкы, Мирвәлинекедер.

Г ө л н и с а. Бир алайса, үзе кайтып кермәс борын куйган җиренә яшерим.

Б и к т и м е р. Юк, карчык, ләвәрвир миндә калсын. Ул малайның күңеле яхшылыкта түгел, әгәр дә шуның белән берәрсен атып куйса, гомерлек казамат дигән сүз. Шуның өчен без аны башка җиргә яшерик.

Г ө л н и с а. Ә ул сораса?

Б и к т и м е р. Күрмәдек, диярбез.

Г ө л н и с а. Ышанмаса?

Б и к т и м е р. Ышанмаска, безнең кулга биреп куйганы юк ла.

Г ө л н и с а. Ярый, үзең теләсәң нишлә. Мин катышмыйм. Аннан, бу Зәмзәмбану килен белән нишләргә инде? Бүген тагын Чөгендер Наһарына аулакка керәм, ди.

Б и к т и м е р. Ходай орган хатын булды инде ул.

Г ө л н и с а. Кичә волостька пособие алырга баргач та, Басарыйлар белән чәйгә кереп, әш-мәшә килеп беткәннәр.

Б и к т и м е р. Кем әйтә?

Г ө л н и с а. Күрше Гайнавал сөйләде. Бүген үзем дә күрдем. Су юлында шул Басарый белән авызга-авыз куеп сөйләшеп тордылар. Урам тулы халык йөри, аларның исләрендә дә юк, ихахай да михахай киләләр.

Б и к т и м е р. «Атың үшән булса — сатып котылырсың, агай-энең яман булса — качып котылырсың, хатының яман булса — ничек котылырсың?» дип белеп әйткәннәр. Бар, әйт, этиең чакыра, диң.

Г ө л н и с а. Тик, зинһар өчен, иплэп кенә. *(Китә.)*

Б и к т и м е р. Бу ләвәрвирне нишләтергә соң? Бәкегә ташларгамы, әллә тирескә күмәргәме икән? Юк, әрәм итәргә ярамый. Белмәссең, кирәк булып куюы бар. *(Тәрәзә кашагасына яшерә.)* Ятсын шунда, ашарга сорамый бит.

З ә м з ә м б а н у керә.

З ә м з ә м б а н у. Нигә чакырдың, әткәй?

Б и к т и м е р. Утыр әле, килен, сиңа сүзем бар. Бая су юлында Мәрдән Басарые белән авызга-авыз куеп сөйләшеп торганыгызны күрдем.

З ә м з ә м б а н у. Алла! Әллә инде кеше белән сөйләшергә дә ярамыймы?

Б и к т и м е р. Ярамый дип әйтмим, һәрнәрсәнең үлчәве бар, әдәп белән сөйләшергә кирәк. Алла сакласын, яман- атың илгә таралыш, Мирхәйдәргә язсалар...

З ә м з ә м б а н у. Языгыз, хатының кеше белән су юлында сөйләшә, дип языгыз.

Б и к т и м е р. Кичә волостька баргач та, нәрсәгездер булган, ахры. Үзеңнең дә дәрәҗәңне төшермә, безнең дә йөзебезгә кызыллык китермә. Безнең нәсел — Аллага шөкер.

З ә м з ә м б а н у. Безнең нәселгә ни булган? «Капкабыздан эт бакмый, төнлегебездән җил какмый», дигәндәй, әлхәмделилләһи шөкер.

Б и к т и м е р. Дөрес, нәселегез байлык белән терәкле, әмма барыгыз да чуар йөрәкле. Ирдән иргә йөрергә яратасыз. Озын сүзнең кыскасы — андый эшләреңне ишетәсе булмыйм!

З ә м з ә м б а н у. Кеше гаебен күргәнче, үз кызыңны карасаң яхшырак булыр иде, әйеме?

Б и к т и м е р. Минем кызыма ни булган?

З ә м з ә м б а н у. Арыш боламыгы кебек, аркылыга җәелә башлаган.

Б и к т и м е р. Ялганлыйсың, явыз, мин синнән таптырырмын!

З ә м з ә м б а н у. Нигә миннән, вакыты җиткәч, үзе дә табар әле. *(Китә.)*

Б и к т и м е р. Нәрсә сөйли ул, нәрсә сөйли тилчә тел?.. Гөлниса, Гөлниса, дим!

Г ө л н и с а чыга.

Г ө л н и с а. Ни бар, әтисе?

Б и к т и м е р. Син Гөлчирәдә бернәрсә дә сизгәнең юкмы? Аның турында мин яман хәбәр ишеттем, йөге бар, ди...

Г ө л н и с а. Йөге бар ди? Кем әйтә?

Б и к т и м е р. Теге тилчә тел сөйләде.

Г ө л н и с а. Ышанма. Ул имансыз әллә нәрсә дә сөйләр.

Б и к т и м е р. Юк, карчык, ул балада ни булса да бар. Төннәр буе йокламыйча көрсенеп-пошынып чыга, аулак калдымы — еларга тотына.

Г ө л н и с а. Еларга килгәндә бер ул гына түгел, барыбыз да елыйбыз.

Б и к т и м е р. Шулай да, сөйләшеп карыйк әле. Кызым, кызым, Гөлчирә...

Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Син эндәштеңме, әткәй?

Б и к т и м е р. Менә нәрсә, кызым, синең турыда яман хәбәр таралган, шул дөресме?

Г ө л ч и р ә *(нишләргә белмичә)*. Юк, әти, дөрес түгел...

Г ө л н и с а. Яшермә, кызым, оят булса да, әйт.

Г ө л ч и р ә. Ышанмагыз, әни, юк...

Б и к т и м е р. Мин әйтәм, бар, дим. Ни өчен алайса кайгыга чумып, дөньяңны онытып йөрисең?

Г ө л ч и р ә. Болай гына... *(Кычкырып елап җибәрә.)* Мин алдандым!..

Г ө л н и с а. Ярабби...

Б и к т и м е р. Кемнән?

Г ө л ч и р ә. Ансын сорама, әти, әйтмим.

Б и к т и м е р. Әйт, кызым. Кем ул сине алдаучы ата эт?

Г ө л ч и р ә. Юк, әти, әйтмим.

Б и к т и м е р. Яхшылыкта әйт, кызым. Усаллыкка калса, барыбер әйттерермен.

Г ө л ч и р ә. Юк, әйтмим.

Б и к т и м е р. Әйтерсең. Мин сине әйттерермен!.. *(Ишек янына барып, чөйдән чыбыркы ала.)*

Г ө л ч и р ә. Әти... *(Бүлмәгә китә.)*

Б и к т и м е р. Качма, качып котыла алмассың! *(Гөлчирә артыннан китә.)*

Г ө л н и с а. Атасы, сабыр, аяу белән... *(Китә.)*

Шәл бөркәнеп, бүлмәдән А й с ы л у чыга, тышка уза. Артта тавыш-кычкырыш. Куышып бу якка чыгалар.

Г ө л ч и р ә. Әти, тимә, әйтәм!.. Мирзахан...

Б и к т и м е р. Мирзахан?! *(Мич арасыннан балта алып, ишеккә бара.)*

М и р в ә л и белән А й с ы л у кайтып керә.

М и р в ә л и. Әти, син кая?

Б и к т и м е р. Тотма, җибәр. Мин ул бурсык балаларын балта белән тураклыйм!..

М и р в ә л и. Куй, әти, юләрләнмә.

Г ө л н и с а. Син акылыңдамы, дулама.

Б и к т и м е р. Җибәрегез мине, җибәрегез!! *(Бөтен тавышка кычкырып, тышка омтыла.)*

Б а с а р ы й керә.

Б а с а р ы й. Биктимер абзый, публикация китердем.

Б и к т и м е р. Нинди публикация?

Б а с а р ы й. Мирхәйдәр абый үлгән.

Б и к т и м е р. Мирхәйдәр үлгән?..

Б а с а р ы й. Әйе, менә полыгыннан язу җибәргәннәр. *(Биктимергә бирә.)*

Г ө л н и с а. Ай-ай, йөрәгем... *(Хәлсезләнеп егыла.)*

Б и к т и м е р. Карчык, син нишләдең?.. *(Кулындагы кәгазен төшереп җибәрә.)*

Г ө л ч и р ә. Әни, ни булды сиңа?

М и р в ә л и. Тавышланмагыз, су бирегез.

А й с ы л у су кертеп бирә. Мирвәли аны авызына алып анасының йөзенә бөрки, Г ө л н и с а сискәнеп китә.

Б и к т и м е р. Карчык, Гөлниса...

Г ө л н и с а. Туңам, теге якка яткырыгыз...

Гөлнисаны бүлмәгә алып китәләр. Басарый югала. Тышта җил-давыл котыра. Б и к т и м е р бүлмәдән чыга. Идәндә яткан публикация кәгазен кулына ала. Яшькә тыгылып сөйли.

Б и к т и м е р. Балам Мирхәйдәр, мин сине шушы бер кәгазь кисәге өчен карап үстердеммени?..

Бүлмәдән М и р в ә л и чыга.

Әниең тынычландымы?

М и р в ә л и. Йокыга китте. Әти, мич казнасына бер әйбер яшергән идем, алмадыңмы?

Б и к т и м е р. Юк, улым, нинди әйбер иде соң ул?

М и р в ә л и. Револьвер.

Б и к т и м е р. Юк, улым, алмадым, фу... Тышта буран котыра, капканы каерып ташламаса ярар иде. Бикләп керим әле.

Тышка чыгып китә. Бүлмәдән А й с ы л у чыга.

М и р в ә л и. Кем генә алды икән?

А й с ы л у. Ялгышмыйсыңмы, шунда куйдыңмы?

М и р в ә л и. Кая куйганымны белмәскә — бала түгел лә мин. Зәмзәмбану килен алмады микән?

А й с ы л у. Аңа нәрсәгә ул?

М и р в ә л и. Аптыраганга әйтүем. Юкса кая китәргә мөмкин?

А й с ы л у. Минемчә, әнкәй яшергәндер, уянгач аңардан сорарбыз. Бу Гөлчирә белән нишлибез инде?

М и р в ә л и. Үзебез белән алып китәбез.

А й с ы л у. Үз хәлебез дә шәптән түгел, аны да бергә алсак...

М и р в ә л и. Зарар юк, моннан гына тизрәк китәргә, анда барып җитсәк бар да рәтләнер. Бу көенчә аны ничек калдырып китәсең. Әйдә, таң алдыннан ат белән Мироныч килергә булды. Бераз йоклап алыйк.

Бүлмәгә кереп китәләр. Тыштан Б и к т и м е р керә. Нәрсә эшләргә белмичә, аптырап йөри. Стенага эленгән скрипкасын алып, озын, моңлы көй уйный. А й с ы л у чыга.

А й с ы л у. Әткәй, нигә ятмыйсың инде?

Б и к т и м е р. Йоклыйсы килми, килен, үч иткәндәй, бүген тышта шомлы буран котыра...

А й с ы л у. Капкада кеше бар бугай.

Б и к т и м е р. Юктыр, килен, буран тавышыдыр, мондый шомлы төндә кем йөрсен?

А й с ы л у. Бар, әткәй, әнә ишегалдында йөриләр...

Ишек кагалар.

Б и к т и м е р *(өй ишеген ачып).* Кем бар?

Ә х т ә р и *(тыштан).* Бу мин, Биктимер кода, ач әле.

А й с ы л у. Әхтәри кода. Тагын нинди хәбәр китерде икән?

Биктимер чыгып китә. Бераздан ике стражник белән Әхтәриләрне ияртеп, С а м с о н о в керә.

Ә х т ә р и. Мирвәли кода өйдәме?

Б и к т и м е р. Өйдә, бар, килен, монда җибәр.

Айсылу китә. М и р в ә л и, Г ө л ч и р ә белән шунда ук әйләнеп керә.

М и р в ә л и. Нәрсә бар?

Ә х т ә р и. Менә, кода, сине сорап килгәннәр.

С а м с о н о в. Кайчан кайттыгыз?

М и р в ә л и. Бүген.

Ә х т ә р и. Кичә кайттың бит, кода.

М и р в ә л и. Юк, Әхтәри абзый, мин бүген кайттым.

Ә х т ә р и. Нигә инде ялганларга? Кичә кайттың, миңа күпер башында очрадың.

С а м с о н о в. Ни өчен волостька барып күренмәдегез?

М и р в ә л и. Иртәгә барырга тора идем.

С а м с о н о в. Документыгыз бармы?

М и р в ә л и. Әлбәттә, бар. Менә, рәхим итегез.

С а м с о н о в. Исем, фамилиягез ничек?

М и р в ә л и. Вәли Тимерев.

С а м с о н о в. Ни өчен волость правлениесе дәфтәрендә Мирвәли Биктимерев булып күренәсез?

М и р в ә л и. Әйе, дөрес. Бу документны воинский начальникта кыскартып язганнар.

С а м с о н о в. Бу документыгыз ялган.

М и р в ә л и. Яхшылап карагыз. Воинский начальникның кулы һәм печате дә басылган.

С а м с о н о в. Әйе, формаль яктан бар да эшләнгән. Мин сезне кулга алам.

М и р в ә л и. Ни өчен?

С а м с о н о в. Сез социал-демократ большевиклар ярдәме белән төрмәдән качып, монда кайткансыз. Киенегез.

Б и к т и м е р. Балам, бу нинди эш?

Г ө л ч и р ә. Абыем, соңгы өметем син идең...

М и р в ә л и. Еламагыз... Телләрегезне аркылы тешләп булса да, чыдагыз. Күз яшьләре көчсезлек билгесе, ә без көчсезләрдән түгел!.. Айсылу, Гөлчирә белән өязгә кадәр мине озата барырсыз, шуннан заводка китәрсез. Киенегез. Хуш, әти...

Б и к т и м е р. Хуш, улым... әниеңне...

М и р в ә л и. Уятмагыз. Бу вакыйганы да хәзергә аңа әйтмәгез. Син кайгырма, әти, мин югалмам.

С а м с о н о в. Артык сөйләшмәгез, әйдәгез!

Китәләр. Биктимер баскан җирендә катып кала.

Б и к т и м е р. Тукта әле... бу нинди шомлы көн? Бер генә балам да калмады... *(Нидер исенә төшеп, сискәнеп китә. Тиз генә тәрәзәгә бара, кашагадагы револьверны ала, йөгереп килеп ишекне тибеп ача.)*

Ашыгып А р т а м о н о в керә.

А р т а м о н о в. Бу нишләвең, Шамкаеч?

Б и к т и м е р. Мирвәлине коткарам.

А р т а м о н о в. Мирвәлине син түгел, башкалар коткарыр аны.

Б и к т и м е р. Кемнәр?

А р т а м о н о в. Безнең иптәшләр!

*Пәрдә.*

# ДАУЛЫ КӨННӘР

# ИКЕНЧЕ КИСӘК

*Дүрт пәрдәле драма*

Бу кисәктә катнашучылар:

Биктимер.
Гөлниса.
Мирвәли.
Айсылу.
Зәмзәмбану.
Нургали.
Нурия.
Гөлчирә.
Артамонов.
Гайнавал.
Наһар.
Хәйбул.
Мөршидә.
Хөрмәтулла.
Шәүлихан.
Ханзафа.
Касыймхан.
Мирзахан.
Әхтәри.
Самсонов.
Басарый.
Ясәви.
Пастухов — эшче һәм партия җитәкчесе.
Әкрам — элекке учитель, хәзер эшче.
Пелагея — шәһәрдә гади рус карчыгы.
Кригер — земский начальник, эре алпавыт.
Гыйльман — авыл мулласы.
Лашманов — волостной писарь.
Соколов — сугыштан кайткан гарип солдат.
Карчык — солдат анасы.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур гына өйнең аскы каты. Шәһәрчә җыйналган бүлмә. Ике ишек. Пәрдә ачылган да Гөлчирә җырлап бала йоклата.

Гөлчирә. Йокла, балам, җан ямем,
Йокла, чәчәк бәйләмем,
Йокла күлдәй тын гына,
Йокла урмандай моң гына.
Йокла, көлеп ай кебек,
Йокла, эреп май кебек.
Сиңа тиңдәш бар микән?

Булса булыр гөл генә –
Тик ул гөл дә синдәй ялгыз,
Җир йөзендә бер генә.
Йокла көлеп, ай кебек,
Йокла эреп, май кебек.

*(Баланың өстенә яба. Тәрәзәгә бара.)*
Бу Айсылу җиңги нишләп кайтмый соң?..

П е л а г е я керә.

П е л а г е я. Йокладымы?

Г ө л ч и р ә. Көчкә... Кулларым калмады...

П е л а г е я. Авырмаса ярар иде. Син югында елады да елады.

Г ө л ч и р ә. Апыйсы килгән, шуңа елагандыр.

П е л а г е я. Ир бала шул, тиз ачыгучан була.

Г ө л ч и р ә. Ярый әле, әби, син бар, үз анамдай миңа ярдәм итәсең.

П е л а г е я. Шулай инде ул, кызым, бер-береңә ярдәм итми ярамый. Менә мин дә иремнән дүрт бала белән калган идем. Мәрхәмәтле кешеләр миңа да булыштылар. Балаларымны карап үстерергә ярдәм иттеләр.

Урамда ат аяк тавышлары ишетелә.

Кемнәр тагын чабышалар?

Г ө л ч и р ә *(тәрәзәдән карап).* Атлы полицейскийлар...

П е л а г е я. Газраилләр, тагын кая баралар икән?

Г ө л ч и р ә. Кичә кулга алынган кешеләрне чыгаруны сорап безнең заводта җыелыш ясарга йөриләр иде. Мөгаен, шунда бара торганнардыр.

П е л а г е я. Әйе, мондый чуалышны мин икенче кат күрүем. Бишенче елны да шундый ук эш ташлаулар, шундый ук җыелышлар булган иде. Ләкин быелгысы тагын да көчлерәк күренә.

Г ө л ч и р ә. Пелагея Павловна, бу җиңги нигә кайтмый соң?

П е л а г е я. Белмим шул, кызым...

Г ө л ч и р ә. Мин инде курка башладым. Чөнки бүген дә бик күп кешеләрне кулга алганнар... Эшли торган җиренә барып кайтыйм әле. Икенче сменага калмады микән? *(Киенә башлый.)*

П е л а г е я. Син, кызым, йөрмә инде. Аны алып киттеләр.

Г ө л ч и р ә. Кая?

П е л а г е я. Күл буендагы танышларыгызга. Авылдан кардәш тиешле кешегез килгән диме?

Г ө л ч и р ә. Нигә соң аны башта ук шулай димәдең?

П е л а г е я. Ни өчендер ул аны сиңа әйтмәскә кушкан иде.

Г ө л ч и р ә. Шул-шул, сез миннән яшерәсез. Мөгаен, ул заба-

стовкага катнашкандыр. Шуның өчен аны кулга алганнардыр әле.

П е л а г е я. Юк, кызым, әйтәм бит, танышларыгызга алып киттеләр. Озакламый кайтыр. Ярый, тиздән смена алышыныр, мин пирожкиларымны сатарга чыгыйм әле.

Г ө л ч и р ә. Әби, мин синең ул пирожки төреп бирә торган кәгазьләреңне укыган идем, анда баш китәрлек сүзләр язылган.

П е л а г е я. Мин бит, кызым, укый белмим. Ни язганнар соң?

Г ө л ч и р ә. Ярый инде, әби, белмәгәнгә салышма. Мин башка эшләрегезне дә сизеп торам.

П е л а г е я. Нинди эшләребезне?

Г ө л ч и р ә. Беркөнне Әкрам абый китергән кәгазьләрне әйтәм...

П е л а г е я. Димәк, син аларны да укыдың?

Г ө л ч и р ә. Әйе, кат-кат укыдым. Менә шуның өчен дә мин җиңгидән шикләнәм...

П е л а г е я. Шикләнмә, кызым, ул кәгазьләрдә аның катнашы юк.

Г ө л ч и р ә. Сез бит аны төрле йомышлар белән дә йөртәсез. Алла сакласын, аңа бер-бер хәл булып куйса, бала белән мин кая барырмын?

П е л а г е я. Курыкма, кызым, син хәзер беркайчан да урамда калмассың.

Гудок тавышы ишетелә.

Әнә смена алышына, мин пирожки сатарга киттем. *(Корзинка тотып китә.)*

Г ө л ч и р ә *(тегү машинасы алып тегәргә утыра. Җырлый).*

Казан дигән таш каланың
Урамы такыр микән?
Минем газиз башкайларым
Әйләнеп кайтыр микән?
Бу Казанның урамнарын
Таптамам дигән идем.
Туып үскән җирләремне
Ташламам дигән идем.

А й с ы л у кайтып керә.

А й с ы л у. Ташла эшеңне, Гөлчирә.

Г ө л ч и р ә. Нигә, җиңги?

А й с ы л у. Бәйрәм итәбез, шатлык безгә, Гөлчирә!

Г ө л ч и р ә. Нинди шатлык? Пелагея Павловна сине каядыр алып киттеләр дигән иде.

А й с ы л у. Әйе, менә мин шуннан кайттым. Мирвәли абыең иректә.

Г ө л ч и р ә. Иректә?.. Чыгарганнармы?

А й с ы л у. Юк, ул качкан!.. Иркутск дигән шәһәрдән бер кеше кайткан. «Моннан ике айлар элек, бергәләп качкан идек, ул документ көтеп калды», ди. Димәк, ул тиздән биредә булачак, Гөлчирә! Мин, алардан чыктым да, олы урам буйлап кайта башладым. Үз-үземә төрле сораулар бирәм, үзем үк җавабын да кайтарам. Шулай итеп, уйланып кайта торгач, бөтенләй икенче якка китеп барганмын. Кире борылдым да, бер кибеткә кереп, кесәмдәге бар акчама менә шушы тәмле әйберләрне алдым. Самовар куй, сыйланабыз, бәйрәм итәбез!

Аркасына капчык асып Б и к т и м е р килеп керә. Айсылу белән Гөлчирә аптырап кала.

Б и к т и м е р. Саумы, балалар?

Г ө л ч и р ә *(каршы барып)*. Әти!.. Син ничек биредә?

Б и к т и м е р. Менә, сезнең яныгызга килдем, кызым. Исәнме, килен?

А й с ы л у. Әйдә, әти, өсләреңне сал. *(Чишенергә булыша.)*

Б и к т и м е р. Әллә кайда торасыз икән, көчкә эзләп таптым.

Г ө л ч и р ә. Сөйлә, әти, әни ни хәлдә?

Б и к т и м е р. Бер көе генә йөри шунда. Сезне сагына... Һәр чәй янында сезне телгә алабыз.

А й с ы л у. Авылда ниләр бар соң, әти?

Б и к т и м е р. Уңай якка берни дә юк, килен, һаман шул искечә: көннән-көн бөлгенлеккә төшә барабыз. Бик күбесенең быел чәчүлеге дә юк... Ярый, ул турыда сөйләрмен әле. Нургалидән хат алдык бит, балалар.

А й с ы л у *(исе китеп)*. Хат алдыгыз?!

Г ө л ч и р ә. Бәләкәй абыйданмы?

Б и к т и м е р. Әйе, кызым, бәләкәй абыеңнан шул, хат килде. Менә укып карагыз. *(Хат чыгарып бирә.)*

Г ө л ч и р ә *(халыкка карап)*. Әйе, әйе, аның кулы, аның язуы... *(Укый.)* «Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтле улып торгучы әткәй белән әнкәйгә, безки улыгыз Нургалидән күптин-күп, чуктин-чук сәламнәремне ирсал вә тәблигъ әйләдем. Аның бәгъзендә сеңелем Гөлчирә илә Айсылу җиңгигә... *(авыз эченнән укып китә.)* Вә янә дә Мөршидә түтәйгә, Зәмзәмбану җиңгигә... Сәлам соңында сезгә шуны мәгълүм итәем — елга якын хәбәрсез торуым сезне бик борчыгандыр инде. Ул болай булды: без, маҗар дигән дошман солдатларының тылына кереп, зур маҗаралар куптарган идек. Ләкин алар безне алдап керткәннәр икән. Көннәрнең берендә безне бүлеп алдылар да, төрле яклап кыйнарга керештеләр. Безгә бу боҗраны

өзеп чыгудан башка чара юк иде, һәм без шулай эшләдек тә. Арсланнар шикелле, дошман сафларына ташландык... Менә шушы дәһшәтле сугышта атым үлеп, үзем яралы хәлдә әсир калганмын...»

А й с ы л у. Мескен...

Б и к т и м е р. Укы әле, кызым, укы. Анда тагын әллә ниләр язылган.

Г ө л ч и р ә. «Шуннан мине яралы килеш Дунай буендагы лагерьларның берсенә җибәрделәр. Без анда ачлык, ялангачлык җәфаларын татыдык... Помой базларында, чүплек башларында туеныш йөрдек... Анда күргән авыр газапларым бер Аллага гына мәгълүмдер. Алары да берни түгел иде, түзә идем, ләкин туган илемне сагынуыма чыдый алмадым... Көннәрнең берендә, эштән кайтып килгәндә, тоттым да ун сажень биеклектәге күпердән Дунай елгасына сикердем...»

А й с ы л у. Ай!.. Шуннан, шуннан, Гөлчирә...

Г ө л ч и р ә. «...Вакыт кич иде, конвой солдатлары миңа никадәр генә атсалар да, тидерә алмадылар. Шулай итеп, мин Дунай суын кичеп котылдым... Аннан инде, мәрхәмәтле кешеләр ярдәмендә, Карпат тауларында яшәүче малорус халыклары арасына барып чыктым. Алар мине үз араларында яшереп асрадылар. Безнекеләр Карпатка бәреп кергәч, мин үзебезнекеләргә барып кушылдым. Хәзер, Аллага шөкер, яңадан үземнең полкымда отделение командиры булып хезмәт итәм. Тиздән ялга чыгабыз дип торалар. Бәлки әле, кайтып килергә дә рөхсәт бирерләр. Шушы хатым белән Мирвәли абыйга, Мирхәйдәр абыйга һәм Нуриягә дә хат салдым, алганнардыр. Тик мин шуңа бик кайгырам, сезнең хәл-әхвәлегез турында берни дә белмим. Тизрәк хат язып салыгыз. Хуш-сау булыгыз. Улыгыз Нургали».

А й с ы л у. Искиткеч, искиткеч фаҗига... Теге хатны язган солдат нинди кабахәт кеше булды икән?

Б и к т и м е р. Сөйләмә инде, килен, шул хат аркасында күпме яшь түктек...

А й с ы л у. Шулай да Нурия килендәш шатлангандыр инде, бичара...

Б и к т и м е р. Без хат алганны ишеткәч, иреннән качып, төнлә белән килгән иде, бер сүз дә әйтә алмады. Әниеңне кочаклап, елады да елады...

Г ө л ч и р ә. Ничек инде иреннән качып?

Б и к т и м е р. Аны бит кияүгә бирделәр.

А й с ы л у. Кемгә?

Б и к т и м е р. Шәүлихан Касыймханына.

Г ө л ч и р ә. Кайчан?

Б и к т и м е р. Бер-ике айлар бар инде. Шуларның барысын да әйтеп, Нургалигә язып җибәрдек.

А й с ы л у. Мескен, ишетсә нишләр инде?

Б и к т и м е р. Әйе, килен, бу каһәрле сугыш халыкны нинди генә хәлгә төшермәде... Мирвәлидән сезгә хәбәр киләме?

А й с ы л у. Юк, эткәй... Юлдан гына бер хат салган иде, хәзер кайда икәнен дә белмибез...

Б и к т и м е р. Аның каторгага хөкем ителүен ишеткәч, авылның бик күп кешеләре хәл белергә өйгә килделәр. Әле хәзер дә урам чатларына, тегермән, каравыл өйләренә җыелдылармы, гел аның турында гына сөйлиләр. Хәтта Мәрхабҗамал кебек карчыклар «Мирвәли өлеше» дип, мичләренә хәер ипиләре салалар.

А й с ы л у. Сез сөйләшә торыгыз, мин самовар куеп җибәрим.

Чыгып китә. Урамда тагын ат аягы тавышлары ишетелә.

Б и к т и м е р. Сездә нәрсә, кызым, чуалыш барамы дим?

Г ө л ч и р ә. Әйе, әти, кичә бер завод эш ташлаган иде, шунда команда белән жандармнар килделәр дә бер эшчене атып үтерделәр.

Б и к т и м е р. Нәрсә өчен?

Г ө л ч и р ә. Завод ишегалдында, собрание вакытында җыелган халыкка сугышны туктатырга, эш хакын күтәрергә өндәп сөйләгән. Шул чагында аны жандармнар кулга алырга теләгән, ләкин халык ирек бирмәгән. Ә ул, һаман сөйләвендә дәвам итеп, меңләгән халыкка «Долой канечкеч патша» дип кычкырган. Менә шуның өчен аны жандарм начальнигы атып үтергән.

Б и к т и м е р. Әйе, кызым, авылда да хәзер үтерешләр күренә башлады. Становой приставның бер зәһәрле тикшерүчесе бар иде. Көннәрнең берендә шушы кеше юкка чыкты. Бөтен авыллардан, урманнардан эзләделәр, тапмадылар. Үтереп Камага салганнар икән дип сөйлиләр. Поездддан төшүгә солдатлар, паспорт сорап, капчыктагы бөтен әйберләремне актарып, котымны алдылар.

Г ө л ч и р ә. Нишләп, әти?

Б и к т и м е р. Куенымда менә бу әйберем дә бар иде. *(Револьвер чыгарып күрсәтә.)*

Г ө л ч и р ә. Каян алдың син аны?

Б и к т и м е р. Теге вакытны Мирвәли абыеңныкы калган иде.

Г ө л ч и р ә. Нигә соң аны янында йөртәсең?

Б и к т и м е р. Станциягә кадәр җәяү килдем, юлда бүреләр очраса дип алган идем. Ул каһәрләр безнең тирәдә шулкадәр күбәйделәр. Көпә-көндез авылга килеп, сарык бәрәннәрен алып китәләр. Сездә дә тынычлык юк икән... Шуны, кызым, берәр җиргә куеп торыйк әле, киткәндә алырмын...

Г ө л ч и р ә. Бир, әти, менә монда яшерик. *(Идән астына салалар.)*

Б и к т и м е р. Син, кызым, кичер мине... Теге вакытны ачу белән рәнҗеттем...

Г ө л ч и р ә. Күптән онытылганны искә төшермә инде, әти.

Б и к т и м е р. Көйгән икмәк ачысы күңелдән китми, диләр бит, кызым, вакыты шундый булды шул... Бер көн эчендә таудай хәсрәт өстебезгә ауды... Шул турыда һәр көнне әниең белән сөйләшеп үкенәбез... Мин инде, кызым, сине алып китәргә килдем.

Г ө л ч и р ә. Юк, әти, мин авылга кайтмыйм. Шундый хурлыктан соң, ничек итеп мин кеше күзенә күренеп йөрермен? Ярый әле, монда килеп котылдым, авылда калган булсам, бәхетсезлек корбаны булыр идем. Монда мин кешеләр белән аралашам, укырга, һөнәргә өйрәнәм.

А й с ы л у *(бүлмәдән тышка чыгып китешли)*. Гөлчирә, самоварны карарсың, мин казан астына утын яргалыйм.

Г ө л ч и р ә. Ярый, җиңги, бар.

Икесе ике якка китәләр. Биктимер бала бишеге янына килә.

Б и к т и м е р. Нихәл, улым, йокың туйдымы? Бабаңны таныдыңмы? Эсс, эсс... киереләсең киләме? Әйдә алайса, үс, үс, үс... Менә инде, елый да башлады...

Бала тавышына Г ө л ч и р ә чыга.

Г ө л ч и р ә. Уяндымыни?

Б и к т и м е р. Ятсынган була.

Г ө л ч и р ә. Әти, минем кулым күмерле, арбасы белән минем янга керт әле.

Б и к т и м е р. Әйдә, улым, трр... киттек!.. *(Китәләр.)*

А й с ы л у белән Ә к р а м керә.

А й с ы л у. Беләсеңме, Әкрам, бездә бүген шундый шатлык...

Ә к р а м. Мәсәлән?

А й с ы л у. Мирвәли качкан!

Ә к р а м *(белмәгәнгә салынып)*. Булмас ла.

А й с ы л у. Ихлас әгәр. Яныннан кайткан кешене күреп сөйләштем.

Ә к р а м. Ә мин сиңа, Айсылу, аннан да зуррак шатлык китердем.

А й с ы л у. Белмим шул, минем өчен моннан да зур шатлык ни

генә булыр икән? Шулай да әйтеп кара әле, нинди шатлык икән ул?

Әкрам. Иң элек утыр әле.

Айсылу. Нигә?

Әкрам. Егылыш китәрсең.

Айсылу. Юк, мин хәзер шатлыкны да, кайгыны да салкын кан белән каршыларга өйрәнеп киләм. Я, әйт инде, көттермә.

Әкрам. Мирвәлиең хәзер безнең шәһәрдә.

Айсылу. Ә?!

Әкрам. Әйттем мин сиңа, утыр, дидем.

Айсылу. Биредә дисеңме?

Әкрам. Әйе, биредә.

Айсылу. Кайда, кемдә ул?

Әкрам. Җиләк бистәсендә, Пастуховлар квартирасында.

Айсылу. Алай булса, хәзер миңа шунда китәргәме?

Әкрам. Юк, юк, ул үзе монда килергә тиеш. Хәзер аңа киемнәр, документлар әзерләп йөриләр.

Айсылу. Шулай булгач, бигрәк тә яхшы, шунда мин дә булышырмын.

Әкрам. Юк инде, синең анда булмавың яхшырак. Я сиздереп куярсың. Минем сиңа башка йомышым бар. Кичә дошман пулясыннан һәлак булган Федор Петровичның квартирасын беләсеңме?

Айсылу. Әйе, беләм.

Әкрам. Белсәң, хәзер шунда барып, менә шушы акчаларны хатынына бирерсең. Ләкин алдыңны-артыңны карап йөр, күзәтмәсеннәр.

Айсылу. Ярый, беренче кат түгел бит.

Әкрам. Бар, син әйләнеп кайтканчы, Мирвәли дә килеп өлгерер. *(Озата.)*

Бүлмәдән Биктимер чыга.

Нихәл, абзый кеше, исәнме?

Биктимер. Шөкер әле, энекәш.

Әкрам. Шәһәргә азык-төлек белән килдеңме?

Биктимер. Азыгы булса, үзем ашар идем әле, энекәш. Юк шул... Кызым белән киленемне күрергә килдем.

Әкрам. Димәк, син Биктимер абзый буласың?

Биктимер. Ә син мине каян беләсең?

Әкрам. Гөлчирә белән Айсылулар сөйләве буенча.

Биктимер. Синең үзеңне кем дияргә соң?

Әкрам. Мин элек учитель идем.

Биктимер. Хәзер нинди кәсептә?

Әкрам. Заводта эшлим.

Б и к т и м е р. Алай... Сугыштан качып ятасың икән.

Ә к р а м. Дөресен әйткәндә, шулай. Я, Биктимер абзый, авылда соңниләр бар?

Б и к т и м е р. Ни булсын? Һаман шул крестьян күрә инде... Элек булса бар тапканыңны ясак, недоимкаларга түләдек. Хәзер булса бөтен авырлык безнең җилкәдә...

Ә к р а м. Сугышның авырлыгын, Биктимер абзый, бер сез генә түгел, барыбыз да күрәбез.

Б и к т и м е р. Юк шул, күрмисез! Суксагыз тимер өзәрлек егетләр монда йөрисез. Менә син үзең, нигә сугышка бармыйсың?

Ә к р а м. Бу сугыш — юлбасарлар, империалистлар сугышы! Кайчан менә халык интересы өчен булган сугышны башлап җибәрербез, ул чагында мин дә барырмын!

Б и к т и м е р. Ә менә минем улларым хәзер дә сугышалар...

Ә к р а м. Аларга да бармаска иде.

Б и к т и м е р. Соң бит көчләп алалар... Сез кала халкы шулай инде, электән дә пустау бишмәт киеп, калач ашап тордыгыз.

Ә к р а м. Син, Биктимер абзый, эшчеләрнең тормышын белмисең.

Б и к т и м е р. Юк, мин эшчеләр турында әйтмим, менә синең кебек укыган кешеләр дим. Сугыш башлану белән, кайсыгыз заводка, кайсыгыз учетка, кайсыгыз конторларга кердегез дә качып калдыгыз. Әнә безнең авылда Ясәви дигән приказчик бар, казнага чабата җыйган булып, учетта ята. Ә үзе, базардан базарга йөреп, җимерттереп сәүдә итә.

Ә к р а м. Бу турыда син хаклы.

Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Исәнме, Әкрам абый.

Ә к р ам. Бик яхшы, Гөлчирә, үзегез ничек яшисез?

Г ө л ч и р ә. Бер көе генә, яңарак кына эштән кайттым. Менә әти килде. Күңелле булып китте әле.

Ә к р а м. Әйе, Гөлчирә, әтиең синең бик кызу кеше күренә.

Г ө л ч и р ә. Спорлаша торгандыр.

Б и к т и м е р. Юк әле, кызым, спорлашмадым. Бераз кылларын гына тарткалап карадым. Әйбәт егет икән, төтене туры чыга. Син, энем, кич белән минем янга кил әле, киңәшләрем бар.

Ә к р а м. Ярый, Биктимер абзый, килермен.

Б и к т и м е р. Син, кызым, безнең авылның Шакирҗан малаен шушы тирәдә тора дип яза идең.

Г ө л ч и р ә. Әйе, әти, каршыдагы өйнең аскы катында.

Б и к т и м е р. Анасының күчтәнәче белән әйтеп җибәргән сүзләре бар иде.

Г ө л ч и р ә. Әйдә, әти, каян керергә икәнен күрсәтим.

Китәләр. П е л а г е я кайтып керә.

Ә к р а м. Я, Пелагея Павловна, сәүдәләр ничек соң?

П е л а г е я. Аллага шөкер, барысын да сатып бетердем.

Ә к р а м. Димәк, үтемле товар булып чыкты?

П е л а г е я. Әйтмә дә. Кайберләре икешәр тапкыр килеп алалар. Күбрәк кирәк иде, җитмәде. Беләсең, мондый товарга хәзер халык сусаган.

Ә к р а м. Кайгырма, Пелагея Павловна, тагын китердем. *(Куеныннан чыгарып бер пачка кәгазь бирә.)*

П е л а г е я. Болары да шул, эш ташлау турындамы?

Ә к р а м. Түгел. Болары Федор Петровичны үтерүче палачларны хөкемгә тартуны таләп итеп язылган. Иртәгә күмү вакытында зиратта таратырсың.

П е л а г е я. Ярый алайса, мин аларны хәзер тышка чыгарып яшерим. *(Китә.)*

М и р з а х а н керә.

М и р з а х а н. Исәнмесез?

Ә к р а м. Исәнмесез, әфәндем?

М и р з а х а н. Миңа Әкрам Ильясов дигән иптәш кирәк иде.

Ә к р а м. Сезгә нигә ул?

М и р з а х а н. Полиция тарафыннан үтерелгән эшче Федор Петровичны күмүгә без дә катнашырга телибез.

Ә к р а м. Ягъни сез кемнәр буласыз?

М и р з а х а н. Мин социал-революционерлар партиясенең либераль зыялылар оешмасының вәкиле Мирзахан Аюханов булам. Менә безнең оешмаларның Федор Петровичның семьясына җыйган ярдәме. *(Күп кенә акча суза.)* Федор Петровичны күмү кайда һәм кайчан башланачагын миңа белеп кайтырга кушканнар иде.

Ә к р а м. Сез ялгышкансыз, әфәндем. Беренчедән: мин сез эзләгән Ильясов түгел. Икенчедән: кемнедер күмү һәм семьясына ярдәм җыю кебек эшләргә бернинди дә катнашым юк. *(Акчаларын кайтарып бирә.)*

М и р з а х а н. Гаҗәп... Миңа ул Ильясов дигән кешене биредә, күмү эшләре белән шөгыльләнә дип әйткәннәр иде.

Ә к р а м. Сезгә дөрес аңлатмаганнар.

М и р з а х а н. Ул чагында мине гафу итегез.

Ә к р а м. Зарар юк, андый ялгышулар була ул.

М и р з а х а н. Хуш, сау булыгыз.

Ә к р а м. Хушыгыз, әфәндем.

Мирзахан китәргә дип ишеккә бара, Г ө л ч и р ә кайтып керә.

М и р з а х а н. Ярабби, Гөлчирә? Сез биредәме?!

Г ө л ч и р ә. Әйе, биредә...

М и р з а х а н. Хәзергә мине гафу итегез, эшем бик ашыгыч иде. Сөйләшеп утырырга килермен әле. *(Китә.)*

Ә к р а м. Димәк, ул кеше сезнең танышыгыз?

Г ө л ч и р ә. Әйе... ул безнең авылның старшина малае... Сезгә килгән идеме?

Ә к р а м. Федор Петровичны күмүгә катнашу өчен, зыялылар исеменнән вәкил булып килдем, ди.

Г ө л ч и р ә. Зинһар, якын җибәрмәгез, икейөзле хаин ул!

Ә к р а м. Мондагы кайбер эшләре турында ишетә белә идем, шуның өчен дә мин аңа якты чырай күрсәтмәдем.

Г ө л ч и р ә. Ул Федор Петровичны күмү кайчан була соң?

Ә к р а м. Иртәгә, төштән соң.

Г ө л ч и р ә. Мин хәзер генә аның хатынын күрдем. Больницадан иренең гәүдәсен алып кайтып бара иде. Мескенне шулкадәр кызгандым... Иренең баш очына утырган да елый да елый...

Ә к р а м. Еламый нишләсен?.. Аның бит биш баласы, карт анасы бар. Аларны карарга, туйдырырга кирәк... Я, Гөлчирә, мин биргән китапны укыдыңмы?

Г ө л ч и р ә. Әйе, укыдым. Тик бик кызганыч икән. Мескен, ананың бердәнбер улын Себергә сөрәләр... Үзен кыйнап, төрмәгә ябалар... Ләкин мин шунысын аңлый алмыйм: нигә ул китапны укудан тыялар икән?

Ә к р а м. Чөнки ул китап дөреслек турында язылган. Эшчеләр анда ничек итеп көрәшәләр, ә?.. Менә, мин сиңа тагын берне китердем әле. *(Китап бирә.)*

Г ө л ч и р ә. Кызыкмы, кызганычмы?

Ә к р а м. Укыгач белерсең. Дәресләрең ничек соң?

Г ө л ч и р ә. Барысын да өйрәнеп бетердем.

Ә к р а м. Молодец, Гөлчирә! Теге хисап-табышмакны да чиштеңме?

Г ө л ч и р ә. Күптән инде, бик җиңел бит ул.

Ә к р а м. Шулай да, ничек әле ул?

Г ө л ч и р ә. «Несла старушка в корзинке сто яиц, а дно упало. Сколько яиц осталось в корзинке?»

Ә к р а м. Ничә калган соң?

Г ө л ч и р ә. Туксан тугыз.

Ә к р а м. Нигә туксан тугыз?

Г ө л ч и р ә. Чөнки берсе төшеп ватылган.

Ә к р а м. Шулай микән? Тагын бер кат укып кара әле.

Г ө л ч и р ә. «Несла старушка в корзинке сто яиц, а дно упало.

Сколько яиц осталось в корзинке?» Шулай инде, берсе төшеп сытылгач, туксан тугыз кала.

Әкрам. Сүз бит монда «одно» турында түгел, «а дно», ягъни корзинканың төбе турында бара. Димәк, корзинканың төбе төшкәч, бер йомырка да калмаган, бар да җиргә коелып ватылган була.

Гөлчирә. Ә?.. Менә хикмәт кайда икән?!

Әкрам. Юкәдә шул чикләвек...

Сакал-мыеклары җиткән Мирвәли керә.

Гөлчирә. Тукта, бу кем?

Мирвәли. Гөлчирә, әллә танымыйсыңмы?

Гөлчирә. Дәү абый!! *(Ташлана.)*

Мирвәли. Акрын, Гөлчирә...

Гөлчирә. Менә бәхет... Сине күрер көнебез дә бар икән... Әти, әти шатланыр инде!..

Мирвәли. Ул да мондамыни?

Гөлчирә. Монда шул. Ул бүген генә килгән иде.

Мирвәли. Кайда соң ул, бүлмәгездәме?

Гөлчирә. Күршеләргә кергән иде, хәзер чакырып чыгарам. *(Китә.)*

Әкрам. Шулай, Мирвәли, тагын кайттым, диң?

Мирвәли. Әйе, Әкрам, кайттым. Я, синең хәлләр ничек соң?

Әкрам. Болай ярыйсы гына. Өч ай утыртып чыгардылар.

Мирвәли. Нәрсә өчен?

Әкрам. «Школада тыелган фәннәр буенча дәрес бирәсең» дип, кулга алганнар иде, исбат итә алмадылар. Шулай да, учительлек правамнан мәхрүм иттеләр.

Мирвәли. Алай... Хәзер кайда эшлисең?

Әкрам. Заводта. Аннан, аерым кешеләргә рус теленнән дәресләр бирәм. Сезнең Гөлчирә белән Айсылуны да укытам.

Мирвәли. Рәхмәт, Әкрам. Чын күңелдән рәхмәт сиңа. Айсылу кайда соң, әллә эштәме?

Әкрам. Хәзер кайтыр, мин аны йомыш белән җибәргән идем.

Төен тотып Пастухов керә.

Пастухов. Мирвәли, мин сиңа киемнәр китердем. Хәзер үк киенеп ал. Аннан, менә бу сакалны да куеп карарсың.

Мирвәли. Яхшы, иптәш Пастухов. *(Киемнәрне алып, бүлмәгә кереп китә.)*

П а с т у х о в. Әкрам, безнең губерна комитеты Федор Петровичның табутын трибуна итәргә һәм аны күмүне бүген уздырырга карар чыгарды.

Ә к р а м. Ни өчен бүген, иртәгә түгел?

П а с т у х о в. Иртәгә калдырсак, полициянең махсус постлар кую ихтималы бар. Икенчедән, вак буржуа партияләре сырышырга йөриләр.

Ә к р а м. Анысы дөрес. Күптән түгел генә берсе миңа да килгән иде. Ләкин шунысы бар, бүген өлгерә алырбызмы соң?

П а с т у х о в. Бөтен завод-фабрикаларга хәбәр ителде. Син хәзер, музыка мәктәбенә барып, Арон Давидовичны күр, минем исемнән әйт: хәзер, укучылардан оркестр төзеп, Федор Петровичның квартирасына җибәрсен. Ләкин тиз булсын, чөнки бер сәгатьтән күмү башланырга тиеш.

Ә к р а м. Ярый алайса, мин киттем.

П а с т у х о в. Сабыр. Аннан, син реальное училищега, механика, техника мәктәбенә керерсең. Укучыларны хәзер үк оештырсыннар һәм митингта сөйләргә берәр кеше дә билгеләсеннәр.

Ә к р а м. Ярый, иптәш Пастухов.

П а с т у х о в. Тагын бер генә йомыш. Мин Тихомировка кызыл материя табарга кушкан идем, нишләде икән, шуны кереп бел. Демонстрация башлануга Мирвәлине кереп алырсың.

Әкрам китә. Киенеп М и р в ә л и чыга.

Әйбәт, бик әйбәт! Бу кыяфәттә хәзер сиңа йөрергә була. Менә бу күзлекне киеп кара әле.

Мирвәли күзлек кия.

Шәп, бик шәп! Кулыңа бер таяк та булса, профессордан бер дә ким түгел.

М и р в ә л и. Петр Ильич, минем өчен аталарча кайгыртып йөрүегез өчен, сезгә ни диеп кенә әйтергә дә белмим.

П а с т у х о в. Ул турыда соңыннан. Ярый, мин киттем. Демонстрациядән соң монда кайтмассың. Аңарчы беркемгә дә күренмә. Хәзергә хуш. *(Китә.)*

Мирвәли өстендәге киемнәрен салып куя, А й с ы л у кайтып керә.

А й с ы л у. Мирвәли!

М и р в ә л и. Айсылу!.. *(Кочагын җәеп бара. Айсылу килеп ташлана. Озак кына сүзсез торалар.)* Менә шулай, менә шулай... Без тагын бергә...

А й с ы л у. Мирвәли... Беренче мәртәбә мин синең күзләреңдә яшь күрәм...

М и р в ә л и. Син бит минем бәхетем дә, шатлыгым да һәм рәхәтем дә. Шуның өчен дә син минем исемнән бер генә дә чыкмадың. Иң авыр минутлар кичергән чакларымда да минә шушы ачык йөз, якты чырай белән күз алдыма килеп баса идең дә, язгы кояш кебек, елмаеп, миңа көч бирә идең.

А й с ы л у. Ә син мине үзеңдә булган түземлек, чыдамлык үрнәкләре белән сугарып, дөньяга аек акыл белән карарга өйрәттең.

М и р в ә л и. Әйе, Айсылу, синең турында мин бик күңелле сүзләр ишеттем. Син хәзер революционерлык юлына басып барасың икән...

А й с ы л у. Алай ук түгел инде, бераз шунда йомышларына йөргәлим.

М и р в ә л и. Анысы да бик зур эш. Исеңдәме? Ул турыда безнең арада күпме сүз була иде?

А й с ы л у. Мин бит хәзер укыйм, белемгә өйрәнәм.

М и р в ә л и. Яхшы, бик яхшы, Айсылу.

Г ө л ч и р ә белән Б и к т и м е р кайтып керә.

Б и к т и м е р. Улым, бәбкәм минем... *(Мирвәлинең күкрәгенә башын куеп елый.)*

Айсылу белән Гөлчирә китә.

М и р в ә л и. Елама, әти...

Б и к т и м е р. Сүз әйтмә, улым, тулган йөрәгемне бушатыйм... Мин бит сине яңадан күрә алмам дип кайгыра идем... Син соң әле ничек?..

М и р в ә л и. Качтым.

Б и к т и м е р. Әй, бала, бала, Себер китәрлек нинди генә гаепләрең булды соң?

М и р в ә л и. Мин, әти, кеше үтермәдем. Караңгы төннәрдә юл басып та йөрмәдем. Халыкны талауга корылган законнарга каршы баруым өчен мине җәберлиләр.

Б и к т и м е р. Бераз гына сиңа ата-анаңны да кызганырга иде, синең аркаңда безгә дә тормыш бирмиләр. Солдат семьяларына чәчүлек орлык кайта дигән хәбәр бар иде, волостька бардым, «улың каторжан» дип, халык алдында мәсхәрә итеп чыгардылар. Казна урманыннан солдат семьяларына утыннар бирделәр. Анда да безне мәхрүм иттеләр. Балалары сугышта булган кешеләргә ясактан льгот килгән иде, синең аркаңда аннан да безне төшереп калдырдылар. Син бит хәзер яшь түгел, үз тормышыңны үзең кебек ма-

тур итеп төзергә вакыттыр. Синең кебек уңган егетләр алдай-гөлдәй итеп торалар.

Мирвәли. Әгәр дә мин, әти, үз тормышым өчен генә тырышучы кеше булсам, мин мал таба алмас идемме?! Юк, мин аны теләмим. Андый улыгыз булу сезгә дә кирәкми. Чөнки андый байлык, дәүләткә ия булу — ерткычлыкның иң югары баскычы. Аның каршында туганлык та, кардәшлек тә юк. Ул барысын да үзенә кол итә. Мин үземнең дә, сезнең дә, шулай ук башка хезмәт ияләренең дә киләчәк бәхетләре өчен көрәшәм.

Биктимер. Шулайдыр да бит... Без сине төрмәдән төрмәгә сөрелеп йөрү өчен карап үстердекмени... Дөньядагы тигезсезлекләрне син генә бетерә алмассың. Ташла, балам, син ул гадәтеңне...

Мирвәли. Әгәр дә син, әти, мине балаң дип танысаң, аз гына мине ихтирам итсәң, ул сүзләрне сөйләмә.

Биктимер. Ярый, балам, артык бер сүз дә әйтмим, бу минем соңгы соравым иде. Үз акылың үзеңдә, белеп эшли торгансыңдыр.

Мирвәли. Әни нихәлдә соң, саулыгы әйбәтме?

Биктимер. Бик бетәшкән иде, улым, күзләре дә начар күрә иде. Хикмәти хода, Нургалидән хәбәр килү белән, бөтенләй үзгәреп китте.

Мирвәли. Нургалидән? Ул исәнме?

Биктимер. Исән, улым, исән. Менә аңардан хат алдык.

Кесәсеннән чыгарып хат бирә. Мирвәли рухланып хат укый.

Мирвәли. Ай молодец, ай молодец Нургали!.. Нинди геройлыклар эшләгән...

Биктимер. Хатын авылда өйдән өйгә йөртеп туздырып бетерделәр. Кемнәр генә алып укымады аны. Аннан, улым, Мироныч менә шушы адрес белән ниндидер бер кешене күрергә кушкан иде. *(Тагын бер хат күрсәтә.)*

Мирвәли *(хатның адресын укып)*. Федор Петрович Александров...

Биктимер. Вокзал тирәсендә булырга кирәк. Менә шуны ничек күрергә икән?

Мирвәли. Юк, әти, син аны күрә алмассың инде...

Биктимер. Нигә, улым, әллә моннан күчеп киткәнме?

Мирвәли. Кичә аны үтергәннәр.

Биктимер. Кемнәр?

Мирвәли. Жандармнар.

Биктимер. Бая миңа Гөлчирә сөйләгән батыр эшче шул микәнни?

М и р в ә л и. Шул, үзе. Ул шәһәрдә безнең партиянең җитәкчесе булып тора иде. Менә шундый кешене харап иткәннәр.

Б и к т и м е р. Кызганыч, бик кызганыч... Мироныч миңа шул кешедән ниндидер китаплар, кәгазьләр алып кайтырга кушкан иде. Шулай итеп, аның әманәте үтәлмичә калыр микәнни?

М и р в ә л и. Мин синең бу хатыңны, әти, Федор Петрович урынына калган Пастухов дигән иптәшкә бирермен. Миронычның әманәтен ул үтәп җибәрер.

Еракта кайгы маршы уйнала. Мирвәли белән Биктимер тыңлыйлар. Йөгереп Ә к р а м керә. Бүлмәдән А й с ы л у чыга.

Ә к р а м. Мирвәли, Федор Петровичның табутын алып чыктылар. Мин сине алырга кердем.

М и р в ә л и. Әйдә, киттек, Әкрам.

А й с ы л у. Мирвәли, син чыкма, күреп, тотарлар.

М и р в ә л и. Юк, Айсылу, мондый чакта аларның күзләре тона.

Мирвәли Пастухов китергән киемнәрне һәм күзлекне кия. Биктимер бая Г ө л ч и р ә белән идән астына яшергән төргәген ала.

А й с ы л у. Көтегез, мин дә сезнең белән. *(Киенә башлый.)*

Б и к т и м е р *(Мирвәлине бер читкә алып.)* Улым, яныңа запас итеп менә шуны да ал әле.

М и р в ә л и. Нәрсә ул, әти?

Б и к т и м е р. Ләвәрвир.

М и р в ә л и. Каян алдың?

Б и к т и м е р. Теге вакытны бездә югалткан идең, мин аны таптым.

М и р в ә л и. Ха-ха-ха. Синдә торсын ул, әти. *(Кесәсеннән браунинг чыгарып.)* Миндә аның тагын да яхшырагы бар.

Ә к р а м. Әйдәгез, киттек.

Мирвәли, Айсылу, Әкрамнар китәләр. Бала арбасы тартып бүлмәдән Г ө л ч и р ә чыга. Оркестр тавышы якыная.

Г ө л ч и р ә. Әти, син бала янында торырсың инде, мин урамга, халык карарга чыгам.

Б и к т и м е р. Ярый, кызым, ярый, торырмын.

Г ө л ч и р ә. Менә соскасы, еласа каптырырсың. *(Китә.)*

Оркестр якынайганнан-якыная бара. Тыштан П е л а г е я керә.

П е л а г е я. Әй халык, урамга сыймыйлар.

Б и к т и м е р. Музыкасы йөрәккә тия торган музыка икән...

П е л а г е я. Арсландай малай үстерүең өчен рәхмәт сиңа, карт.

Б и к т и м е р. Безнең Шамкаевлар бар да шундый инде, бабушка.

П е л а г е я *(өстенә киенә башлап).* Мин дә чыгып карыйм әле.

Б и к т и м е р. Бабушка, тукта әле. Бала янында син генә калып торсаң ничек булыр икән?

П е л а г е я. Халыкны карыйсым килә иде шул.

Б и к т и м е р. Карарсың әле, син бит шәһәр кешесе. Менә минем бер дә күргән юк. Нишлиләр икән анда?

П е л а г е я. Бар алайса, бар.

Б и к т и м е р. Менә сускасы, еласа каптырырсың. *(Тиз генә киенеп чыгып китә.)*

Урамдагы халык ташкыны, Варшавянка көенә җырлап, тәрәзә артыннан узалар.

Җ ы р. Шомлы җилләр исә өстебездән,
Марш, марш алга, эшче халык.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Әүвәлге пәрдәләрдә күренгән Биктимер карт өй эче. Пәрдә ачылганда Б и к т и м е р белән Г а й н а в а л сөйләшеп утыра. Мич башында З ә м з ә м б а н у н ы ң таралып йоклаганы күренә.

Б и к т и м е р. Дүрт көн буена завод трубалары кычкыртып торды. Беркем эшкә бармады. Кулга алынган иптәшләрен чыгарттылар. Эш хакларын күтәрттеләр, бушлай больниска йөрергә, ниндидер касса ачарга рөхсәт алдылар.

Г а й н а в а л. Менә бит ул кеше нишләтә!

Б и к т и м е р. Алар без түгел, алар закон беләләр. Безнең эш башка, «сиңа яраган миңа ярамый, миңа уң булган, күршегә кул түгел» дигәндәй, төрлебезгә төрлечә кирәк. Петербурда да эшләр чуалган, янарал Сухомлиновны кулга алганнар.

Г а й н а в а л. Янарал кадәр янаралнымы?

Б и к т и м е р. Янарал кадәр янаралны шул. Тик, «карга күзен карга чукымый» дигәндәй, күп тә үтмәгән, патша үз кулы белән указ язып, төрмәдән чыгарткан. Шул турыда кала халкының ачуы бик кабарган. Янаралны хөкем итәргә сорыйлар икән.

Г а й н а в а л. Ул янаралның гаебе нидә икән соң?

Б и к т и м е р. Немецларга сатылган. Сугыш серләрен итәк астыннан ярманнарга җибәреп торган, ди. Шул турыда патша хатыныннан да шикләнәләр икән.

Г а й н а в а л. Кит аннан, Биктимер абзый, патша хатыны андый эшне эшләмәс.

Б и к т и м е р. Нигә эшләмәсен, ул да немец кызы бит. Немец булдымы, шпион була икән. Аннан тагы берничә еллардан бирле патша сараенда бер изге, аллаяр карт торган. Көннәрнең берендә шушы карт кисәктән генә юкка чыккан. Эзләргә керешәләр, һич таба алмыйлар. Ахырында, князь Юсупов дигән бер әфисәр килгән дә «мин үтердем» дип җәвит иткән, ди.

Г а й н а в а л. Менә сиңа кирәк булса?.. Нигә үтерде икән?

Б и к т и м е р. «Патша хатыны белән уйнаш итте. Рәчәйне немецларга сатты, сарайга шпионнар тутырды», дип әйткән ди.

Г а й н а в а л. Әйе, дөньяга чыксаң әллә ниләр ишетәсең шул. Беркөнне, Мироныч безне үз өенә җыеп, сугышның ничек башлануы турында язылган бер китап укыды. Исебез китте инде. Солдатлар кырыла, ә патшалар, халыктан яшеренеп, бер-берләренә кунакка йөрешәләр икән. Аннан, син югында, авылда зур җыен булды, Шәүлихан старшина кайткан иде, шунда бөтен ярлылар чәчүлек орлык сорадык. Өмет итмәгез, фронттан арткан бер гөрәңкә дә икмәк юк, дип куйды.

Б и к т и м е р. Немецларга озатып торгач, булмас шул.

Г а й н а в а л. Ничек немецларга?

Б и к т и м е р. Мирвәли сөйләде: безнең икмәк купецлары Швед дигән патша аркылы немецларга җибәреп торганнар. Менә шуның аркасында илдә икмәк юк икән.

Г а й н а в а л. Димәк, үз ипиебезне ашап, үзебезне кыйныйлар?

Б и к т и м е р. Күрәсең, шулай булып чыга.

Г а й н а в а л. Шулайдыр, Биктимер абзый. Юкса кая китсен ул ипи? Уңыш та булмый түгел, тырышып-тырмашып булса да, булган җирне кысыр калдырмыйча чәчәләр. Әнә Шәүлихан малайлары, боз катканчыга кадәр баржаларга төяп озатканнар иде, кышын да туктаганнары юк, көне-төне станциягә ташыталар.

Б и к т и м е р. Кара әле, Гайнавал, шул турыда минем башта бер уй бар: яз житә, синең дә, минем дә, башкаларның да чәчүлек орлыгы юк. Әгәр дә, мин әйтәм, без дә, эшчеләр кебек, бер сүздә булып тотынсак, ул икмәкләр беркая да китә алмаслар иде.

Г а й н а в а л. Ничек инде ул, Биктимер абзый?

Б и к т и м е р. Менә ничек: Шәүлихан малайларының ул икмәкләрен станциягә ташытмыйк. Алар бит бар да безнең тиребез белән табылган ипекәйләр.

Г а й н а в а л. Ай-һай, Биктимер абзый, бик зур эш бит ул. Безнең көчтән килер микән соң?

Б и к т и м е р. Ник килмәсен? Эшчеләрнеке килә бит. «Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга» дигәннәр. Шул турыда син сүз сыярдай кешеләр белән сөйләшеп чык әле.

Г а й н а в а л. Ярый, Биктимер абзый, кылларын тарткалап карармын.

Күкрәгенә Георгий тәресе таккан өлкән унтер-офицер погонында атлы гаскәр формасында Н у р г а л и керә.

Н у р г а л и. Әти, Хәйбул абыйларга Григорий Мироныч килгән, минем янга килеп чыксын әле, ди.

Б и к т и м е р. Нигә безгә төшмәде икән? Әйдә әле, Гайнавал, бу турыда аның белән дә киңәшеп карарбыз. *(Китәләр.)*

Мич башында йоклап яткан Зәмзәмбану торып утыра.

З ә м з ә м б а н у. Нургали, кичә нигә безнең аулакка кермәдең?

Н у р г а л и. Камали абзый кунакка алып киткән иде. Аннан шәһәрдән әти кайтты, аның белән сөйләшеп утырдык.

З ә м з ә м б а н у. Ә мин сине көттем. Сый да әзерләгән идем. Бүген Айгыр Мәрьямнәргә кер, мин анда булырмын.

Н у р г а л и. Җиңги, телең ни сөйләгәнне колагың ишетәме?

З ә м з ә м б а н у. Ярый инде, назланып маташма.

Н у р г а л и. Оят түгелме сиңа? Мин бит иреңнең туганы.

З ә м з ә м б а н у. Булса соң? Җиңгәләренә өйләнгән җанагалар иң бәхетле ирләрдән санала. Мин сине яратырмын. Мирхәйдәр абыеңа күрсәтмәгән кадер-хөрмәтне күрсәтермен. *(Муеныннан эләктереп ала.)*

Ишектә Гөлниса күренә дә кире югала.

Китсәң озатып, кайтсаң капка ачып каршы алырмын.

Н у р г а л и. Җибәр, җиңги.

З ә м з ә м б а н у. Җибәрмим, Мирхәйдәр абыеңны яратмадым. Электән дә минем күңелем синдә иде.

Н у р г а л и. Әллә син котырдыңмы?!. *(Сәкегә таба этеп җибәрә дә бүлмәгә кереп китә.)*

Г ө л н и с а чыга.

Г ө л н и с а. Нишләп, килен, болай күңелсез?

З ә м з ә м б а н у. Мирхәйдәрне төшемдә күрдем. Бичаракаем

кулына ак күгәрчен тоткан да «Зәмзәмбану, мә, синең өчен тотып китердем», дип каршымда тора. Кулыма алыйм дигәндә генә очты да китте... *(Тышка чыгып китә.)*

Н а һ а р керә.

Н а һ а р. Гөлниса түтәй, Нургали өйдәме?

Г ө л н и с а. Юк, каядыр чыгып киткән иде.

Н а һ а р. Ничек кенә күрергә икән соң үзен?

Г ө л н и с а. Юк, юк, күрмәссең, өйдә тормый ул. Мөршидә түтиләренә кунакка барырга йөри. Аннан Гөлчирәләр янына китәм, ди. Кичә хәзрәтләр синнән чыгып бара иде, тагын үгетләргә килгәнме?

Н а һ а р. Юк, ашка чакырган идем, никах укып киттеләр.

Г ө л н и с а. Нинди никах?

Н а һ а р. Мин бит иргә чыктым.

Г ө л н и с а. Кемгә?

Н а һ а р. Югары очның Җамали абзый малае Җәләлетдинне йортка керттем.

Г ө л н и с а. Иреңнең үлүе дөрес булдымыни соң?

Н а һ а р. Шулай инде, полкыннан язу килде бит. Ярый, Гөлниса түтәй, Нургалигә әйтерсең, мине күрергә тырышсын.

Г ө л н и с а. Нинди сүзең бар иде соң?

Н а һ а р. Нуриядән хат китергән идем.

Г ө л н и с а. Шулаймыни? Кара инде, күрми дә торам, Нургали өйдә икән. Улым, Нургали, Шәмсенаһар түтәй чакыра...

Бүлмәгә кереп китә. Н у р г а л и чыга.

Н у р г а л и. Ни бар, түтәй?

Н а һ а р. Мине Нурия җибәрде. Менә шушы хатны укысын да, җавабын язсын, диде.

Н у р г а л и. Кирәкми миңа аның хаты, башына капласын!

Н а һ а р. Ай Алла, нигә алай дисең, апаем?

Н у р г а л и. Иренә хыянәт итеп бай кияүгә чыгучы хатынга башкача ничек дим?

Н а һ а р. Бу эштә бит аның гаебе юк. Ата-аналары, никах укыту өчен губерна ахуныннан рөхсәт алып, көчләп бирделәр.

Н у р г а л и. Риза булмасын иде!

Н а һ а р. Әйтүе ансат. Ул аңа үзе дә үкенеп бетә алмый. Син кайтканнан бирле елый да елый. Авыруга сабышып бетте инде. Мә, укы әле.

Н у р г а л и *(теләр-теләмәс кенә хатны алып укый).* «Нургали!.. Мин синең алдыңда гаепле... Ата-аналар иркенә, гореф-гадәт, дини йолаларга каршы ачкан көрәшемне ахырына кадәр дәвам

иттерә алмадым. Мәкерле хәйләләренә алданып, җиңелдем... Ышанырсыңмы, юкмы? Анысын мин белмим, ләкин син бер генә минутка да минем йөрәгемнән чыкмадың... Сиңа булган беренче мәхәббәтем хөрмәтенә сорыйм: духовный собрание апа эш йөртеп, коткар мине, ярдәм ит».

Б и к т и м е р белән А р т а м о н о в керә.

Н у р г а л и. Әйдә, түтәй, мин сине озатыйм.

Б и к т и м е р. Улым, Нургали, син кая?

Н у р г а л и. Мин хәзер, әти. *(Наһар белән чыгып китәләр.)*

Б и к т и м е р *(сәке астыннан төргәк алып).* Менә шунда китаплары да, гәзитләре дә бар, диде.

А р т а м о н о в *(төргәкне сүтеп, бер прокламацияне алып укый).* Әйбәт, бик әйбәт... Солых турында, икмәк турында, җир турында язылган икән. Их, менә боларны татарчага тәрҗемә итсәләр, тагын да яхшырак булыр иде.

Б и к т и м е р. Зарар юк. Халык дигәнең үзенә файдалы нәрсәне аңлый ул.

А р т а м о н о в. Юк инде, Биктимер Шамкаевич, һәр халыкның үз телендә булганы яхшырак. Күрәсең, өлгерә алмаганнар. Берничәсен сезнең каравыл өенә ябыштырып куйганда ничек булыр иде икән?

Б и к т и м е р. Бик әйбәт булыр, безнең авылда русча белүчеләр күп.

А р т а м о н о в. Алай булса мә әле, кеше күрмәгән арада гына ябыштырып куй. Ышанычлы кешеләрнең кулларына да бирергә ярый. Тик кара аны, бу турыда бик сак булырга кирәк. Ярый, мин киттем.

Б и к т и м е р. Нигә соң әле ашыгасың? Минем сиңа тагын кала хәбәрләрен сөйлисем бар иде.

А р т а м о н о в. Әйтәм бит, аракы заводына барышым. Илдә барган зур вакыйгалар белән аларны да таныштырасым килә.

Б и к т и м е р. Без шулай итеп тегене башлыйбыз инде?

А р т а м о н о в. Башлагыз, тик карагыз аны, аерым кешеләрнең шәхси интереслары өчен талау гына булып калмасын, беренче чиратта бөтен ярлыларны чәчүлек орлык белән тәэмин итәрлек булсын. Ярый, хушыгыз. *(Китә.)*

Бүлмәдән Г ө л н и с а чыга.

Б и к т и м е р. Нургали Наһар белән нишләп йөри?

Г ө л н и с а. Нуриядән хат китергән.

Б и к т и м е р. Соң, ни язган?

Г ө л н и с а. Сорашмадым әле.

Б и к т и м е р. Өч-дүрт көн өйдә тормасаң, бөтен йортның астыөскә килә. Куйган әйбереңне тапмыйсың. Мунча казанында су калдыргансыз, туңып казан шартлаган.

Г ө л н и с а. Чынлапмы?

Б и к т и м е р. Әнә чыгып кара.

Г ө л н и с а. Син югында мунча яккан идек, Зәмзәмбану киленгә никадәр әйттем, түгеп чык, дидем, тыңламаган, күрәсең.

Б и к т и м е р. Үзе кайда соң әле?

Г ө л н и с а. Йокыдан торды да каядыр чыгып китте. Син югында тагын узынды. Бая монда килеп керсәм, күзләрем шар булды. Нургалинең муенына сарылган.

Б и к т и м е р. Алланың ләгънәте тигән, җир йоткыры, адәм үләте! Юк, ул дуңгызны кондыз итеп булмады, куам да чыгарам. Тора-бара, я миңа да ябышыр.

Н у р г а л и керә. Гөлниса тышка чыгып китә.

Б и к т и м е р. Улым, нигә соң әле син бик күңелсез йөрисең?

Н у р г а л и. Ничек күңелле булыйм соң, әти? Юкка гына кайттым. Мондагы хәлләрне күрмәгән булсам, бәлки, миңа бу кадәр авыр да булмас иде. Кемне генә очратма, аһ-зарын сөйләргә керешә. Хәзер генә Тимерша бабайны күрдем. Арслandай дүрт ул биргән карт, күрше авылдан хәер сорашып кайтып килә.

Б и к т и м е р. Әйе, улым, безнең мондагы тормыш шул инде. Кая гына барма, кемгә генә кермә, күз яшьләре күрәсең. Бу каһәрле сугышның кайчан чиге була инде?

Н у р г а л и. Ул сорауга, әти, берәү дә җавап бирә алмый.

Б и к т и м е р. Әнә эшчеләр бирәләр, улым. Сезнең солдатларга да шулай бер сүздә булырга иде.

Н у р г а л и. Анысын мин әйтә алмыйм, әти. Тик мин шулхәтле туйдым... Хәтта хәзер сугышта күрсәткән батырлыкларымны күз алдыма китереп карыйм да, үз-үземнән оялам. Нәрсә өчен, кем өчен мин кешеләрнең каннарын койдым?

Б и к т и м е р. Болар кемнәр, безгә килеп туктады?

Н у р г а л и. Хөрмәтулла җизни белән Мөршидә түтәйләр.

Б и к т и м е р. Кияү кайтканмы?

Чыгып китәләр. Бераздан М ө р ш и д ә белән Г ө л н и с а керә.

М ө р ш и д ә. Бер айга кунакка җибәргәннәр.

Г ө л н и с а. Балалар куангандыр инде, кызым.

М ө р ш и д ә. Сөйләмә дә инде, әни, кайткан сәгатеннән бирле алдыннан төшмиләр. Кечкенәсенә кадәр өзелеп сагынган. «Әттәм минем, мәм генәм, иң кадерлем, син генәм» дип, так-

маклап үбә. Бигрәк тә үзем инде, ул югында күргәннәрем бар да онытылды.

Г ө л н и с а. Ярый инде, кызым, бик яхшы булган. Без дә Нургалинең кайтуына бик шатландык.

М ө р ш и д ә. Шатланмыйни? Аңа инде без дә куандык. Тик мескеннең хатынсыз калуы гына аяныч. Абыйдан хәбәр юк микән?

Г ө л н и с а *(пышылдап)*. Анда, ди.

М ө р ш и д ә. Ничек анда?

Г ө л н и с а. Качып кайткан... Кеше паспорты белән йөри, ди.

М ө р ш и д ә. Әти күргәнме үзен?

Г ө л н и с а. Өч кич бергә кунганнар...

М ө р ш и д ә. «Яхшыга көн юк, яманга үлем юк» дигәндәй, ичмасам, үлми дә.

Г ө л н и с а. Тукта әле, кызым. Мирвәли абыеңны әйтәсеңме?

М ө р ш и д ә. Аны булмыйча, тагын кемне әйтим соң? Андый юлда кемнең туганы йөри? Беркөнне шулай, Ихсан байларга ашка барган идем, шунда карт остабикә йөземне кызартты. Имеш, «Абыегызны себергә сөргәннәр иде бугай, хәбәр киләме?» — ди. Гарьлегемнән, кайткач утырып еладым.

Г ө л н и с а. Нигә аңа гарьләнергә? Ат урлап китмәгән бит ул.

М ө р ш и д ә. Аннан да яманрак. Патшага каршы баручылар! Безнең Хөрмәтулла әйтә: «Андыйларны асып үтерәләр, безнең каенагай ничек җиңел котылган икән», — ди. Сезгә дә үпкәм зур, шуны тыя алмадыгыз.

Г ө л н и с а. Тыңламагач, нишлисең? Әйдә, йөрсен инде, «җаны теләгән — елан ите ашаган» диләр бит. Теге якка чыгыйк. *(Керәп китәләр.)*

Х ө р м ә т у л л а белән Н у р г а л и керә.

Х ө р м ә т у л л а. Мин шуңа төшенә алмыйм, ул хатны бабайларга кем язган икән?

Н у р г а л и. Бер солдат иптәшем. Ләкин ул хаттагы «атып» дигән сүзне бозганнар. Шуннан инде, «үлеп дошман ягында калды» булып чыккан.

Х ө р м ә т у л л а. Гаҗәп... Цензур шулай эшләгән дисәм...

Н у р г а л и. Юк, хатны авылда ачканнар да усал ният белән бозганнар.

Х ө р м ә т у л л а. Ай-һай, каениш, андый яман эшкә кемнең кулы барыр диш уйлыйсың?

Н у р г а л и. Басарый булырга тиеш. Аның авылга килгән-

киткән хатларны ачып укыганын башкалар да сизгәннәр. Ике көннән бирле саклап йөрим, волостьта качып ята. Бүген кайтмаса, иртәгә волостька барам да, авызын җимерәм... Әйдә, чишен.

Хөрмәтулла шинелен сала.

Җизни... Син дә герой булгансыңмы дим?

Хөрмәтулла. Так точно, әллә сиңа гына дигәнме? Җизнәң дә Георгиевский кавалер!

Нургали. Нинди батырлык күрсәттең?

Хөрмәтулла. Ул бик кызык кына булды инде, каениш. Галицияне ташлап чигенгәндә, безнең полк бер румын авылына кунарга туктады. Ләкин пешкән ашларыбызны да ашарга өлгермәдек, әллә каян гына дошман ярапланнары килеп чыктылар да — дөп тә дөп!.. Бомба ташлый башладылар. Без тагын чигенергә керештек. Шул көннәрне генә безнең полковник янына Петроградтан хатыны кунакка килгән иде, ул да безнең белән. Шулай авылны чыгып бераз гына киткән идек, әлеге полковник хатыны «аһ та вах» килеп еларга ябышмасынмы? Нәрсәгә елый диген? Румын авылында озын колаклы көчеген онытып калдырган икән. Шуннан полковник мине чакырып алды да «Хөрмәтулла Сөнгатуллин, безнең собаканы спасай» ди. «Слушаюсь, ваше высокое благородие, за царя, за собаку душу не пожалею», — дип авылга йөгердем. Ярты сәгать тә үтмәгәндер, этне полковник хатынына китереп тоттырдым. Менә шуның өчен Георгиевский тәресе белән бүләкләделәр һәм бер айга отпуск та бирделәр.

Нургали. Әйе, җизни, син бик ансатлык белән алгансың... Ә менә мин, ике ел буена алдынгы сафта йөреп, нинди генә сугышларда, нинди генә атлы атакаларда булмадым... Ике тапкыр шрапнель белән яраландым. Бер тапкыр кылыч белән җилкәмә чаптылар. Җиде кешем белән бөтен бер взвод немец егерьләрен турап кайтканнан соң гына менә шул тәрене биргәннәр иде...

Биктимер керә.

Әйдә, җизни, чәйгә керик.

Хөрмәтулла. Син бар, керә тор, минем бабай белән сүзем бар әле.

Нургали китә.

Бабай, мин Мирвәли каенагай янына барып сөйләшергә, бик яман гадәтен ташлатырга уйлыйм.

Б и к т и м е р. Белмим шул, кияү, ташлар микән?

Х ө р м ә т у л л а. Ташларга тиеш. Мин аңа дөньяда алай яшәргә ярамавын, кайчан булса да бер ул үз башына үзе җитәчәген аңлатырмын. Кеше бит нинди дә булса бер өмет белән яшәргә тиеш.

Б и к т и м е р. Аның өмете бар, кияү: «Тиздән революция була», — ди.

Х ө р м ә т у л л а. Мин аны акыллы кешегә санап йөри идем, шыр-тиле икән. Нindидер бер төркем кешеләр, патшага, аның армиясенә каршы тора аламыни?

Б и к т и м е р. Синеңчә, тора алмый да, аныңча, тора булып чыга. Бер караганда ышаныш та куясың. Мин зиратка иптәшләрен күмәргә барганда, юлда туктап ясаган собраниеләрендә булдым. Каенагаң шунда, фантан түбәсенә басып, шундый матур итеп сөйләде... Бөтен җыелган халык аның авызыннан чыккан һәр сүзен йотлыгып тыңлады. Шундый матур итеп сөйләүче улым булуына куандым.

Х ө р м ә т у л л а. Патша сүккән өченме?

Б и к т и м е р. Әйе. Әгәр дә ул патша булдыклы кеше булса, безне бу хәлгә калдырмас иде.

Х ө р м ә т у л л а. Дөрес, безнең патшаны йомшак кеше, диләр. Аңа карап эшчеләр артыннан барырга ярамый. Алар бит жалованиеләрен генә арттыруны сорыйлар. Их, менә Николай Николаевич патша булса иде, ул солдат яклы, солдат өчен җанын бирә торган генерал. «Әгәр дә мин патша булсам, һәр солдатка җир кисеп бирер идем», дип әйтә, ди.

Б и к т и м е р. Солдат булмаганнарга нәрсә бирәм дип әйтә икән соң?

Х ө р м ә т у л л а. Мин анысын ишетмәдем. Хәер, үземә булгач, башкаларда минем эшем юк.

Б и к т и м е р. Син шул, кияү, үз төнлегеңнән генә карап сөйлисең. Син әнә халыкка кара, көннән-көн бөлгенлеккә төшеп бара. «Илдә булса үлмәссең, илсез көн күрмәссең» дигән бабайлар.

Г а й н а в а л керә. Хөрмәтулла бүлмәгә кереп китә.

Г а й н а в а л. Биктимер абзый, мин солдаткаларның бик күбесе белән сөйләштем, рәт чыгардай күренә.

Б и к т и м е р. Шулай дисеңме, Гайниҗамал? Касыймхан өйдә микән?

Г а й н а в а л. Юк, станциядә ята, ди.

Б и к т и м е р. Алай булса, авызыңа бал да май. Тәвәккәлләп башлыйбыз. Бар, хатын-кызларны аякка бастыр, мин дә хәзер урамга чыгам. Пожар сарае алдында булырмын. Башта җыйнаулашып старостага барырсыз, казна урманыннан утын, волость мәгәҗиненнән чәчүлек орлык сорарсыз.

Г ө л н и с а керә.

Г ө л н и с а. Без сине тышта дип торабыз, монда тагын нишлисең?

Б и к т и м е р. Менә Гайниҗамал күрше кергән.

Г ө л н и с а. Чәең суына, Гайниҗамал, әйдә, син дә чәйгә кер.

Г а й н а в а л. Рәхмәт, Гөлниса түтәй, вакытым юк әле.

Б и к т и м е р. Бар, Гайниҗамал, Аллага тапшырдык.

Гайнавал китә.

Г ө л н и с а. Тагын нишләп йөри ул?

Б и к т и м е р. Йомыш белән кергән.

Г ө л н и с а. Нинди бетмәгән йомыш инде. Тотасыз да серләшәсез, торасыз да пыш-пыш сөйләшәсез!

Б и к т и м е р. Куй әле, тузга язмаганны сөйләмә.

Г ө л н и с а. Юк. Сезнең арагызда ни дә булса бар. Кайтканнан бирле минем белән сөйләшкәнең, юньләп киңәшкәнең юк. Бар белгәнең Гайнавал да Гайнавал!..

Б и к т и м е р. Әй карчык, карчык... Әйдә, чәй эчик.

Кереп китәләр. Н у р г а л и белән Х ө р м ә т у л л а чыга.

Н у р г а л и. Касыймхан да өйдә юк, Нурияне алам да шәһәргә качам.

Х ө р м ә т у л л а. Ярамый, каениш, бәлагә калырсың. Ни дә булса, башка юлын табарга кирәк.

Н у р г а л и. Нинди юлын табасың? Эшне духовный собраниегә бирергә мөмкин иде. Ләкин Аюхановлар файдасы өчен әллә нинди хәйләи-шәргыяләр уйлап табарлар.

Х ө р м ә т у л л а. Анысы шулай, җавапка тартып куюлары бар.

Н у р г а л и. Мин бу турыда бик күп укыган кешеләр белән киңәштем, хәтта кайтышлый, өяз прокуроры белән дә сөйләштем, барысы да: закон буенча хатын синеке, диләр. Шулай, җизни, мин Аллага тапшырдым. Тик юлга акча гына юк, син миңа, җизни, беразгына биреп тор инде.

Х ө р м ә т у л л а. Юк, каениш, бирә алмам, мин киткәч, тотаң бер атны саткан, ат алырга ният бар. Терлек-дирбия тузган, яңаларны алмыйча булмый. Аннан инде яңадан фронтка барырга исәбем юк, өяздәге түрәләрнең көен күрергә кирәк, анда да акча диярләр.

Н у р г а л и. Син, бәлки, җизни, минем итекне сатып алырсың?

Х ө р м ә т у л л а. Нинди итекне?

Н у р г а л и. Минем өйдә, действительный хезмәттән киеп кайткан итегем калган иде, шуны сатарга уйлыйм.

Х ө р м ә т у л л а. Кая әле, кая, күрсәт әле.

Нургали китә. Итек тотып чыга.

Н у р г а л и. Өр-яңа, иң яхшы хромнан, Ригада тектергән идем.

Х ө р м ә т у л л а. Болай товары яраплык икән. Күпме сорыйсың?

Н у р г а л и. Әйдә, бир унны.

Х ө р м ә т у л л а. Юк, каениш, бик кыйбат.

Н у р г а л и. Нишләп кыйбат булсын? Простой солдат итеге дә хәзер күпме тора!

Х ө р м ә т у л л а. Простой булса, мин дә сүз әйтмәс идем. Офицер итеге шул, безгә нәрсәгә ул? Ярый, тот учыңны, бишне бирим.

Н у р г а л и. Син бигрәк инде, җизни, бушка сорыйсың.

Х ө р м ә т у л л а. Нишләп буш булсын? Хәзер акча бик кыйбат. Я, шул хакка бирдеңме?

Н у р г а л и. Юк, җизни, ул хакка бирмим.

Х ө р м ә т у л л а. Ярый алайса, алты итим.

Н у р г а л и. Булмый, җизни.

Х ө р м ә т у л л а. Күпме соң?

Н у р г а л и. Әнә ал, тугыз сум акча булыр.

Х ө р м ә т у л л а. Булмады, һаман бер балык башын чәйнисең. Син бик саран кеше икәнсең, каениш. Соңгы сүзеңне әйт.

Н у р г а л и. Шул, тугыз сумнан кимгә бирә алмыйм.

Х ө р м ә т у л л а. Ярый, сиңа булсын юан башы, җиде сум итим.

Н у р г а л и. Товарын кара әле син аның, җизни, товарын, борынына төреп тыгарлык.

Х ө р м ә т у л л а. Шуның өчен дә җиде сум бирәм бит. Миңа итекнең кирәге дә юк. Үзем дә киеп кайттым. Тик үз кеше, читкә сатып әрәм итмәсен диеп кенә алуым. Я, бирдеңме?

Н у р г а л и. Менә нәрсә, җизни. Синеңчә дә, минемчә дә булмасын, сигез сум акча.

Х ө р м ә т у л л а. Кара әле, каениш, син бик кансыз кеше икәнсең, үз җизнәңне кычкыртып талыйсың. Бераз гына Алладан курык.

Н у р г а л и. Теләсәң нишлә, шуннан ким бирә алмыйм. *(Итекне алып китә башлый.)*

Х ө р м ә т у л л а. Ярый инде, ярый, миннән булсын яхшылык.

Үземә ярамаса, тутаң киеп җибәрер. Мә, хәерен күр. *(Акча бирә.)* Бар, ишекне яп әле, минем күчтәнәчем бар иде, мәгәрич ясап җибәрербез. *(Аракы чыгара.)*

Н у р г а л и. Менә бу эш булыр, җизни. Тик монда ирек бирмәсләр, әйдә мунчага.

Х ө р м ә т у л л а. Чынлап та бу акыл. Ипи белән тоз алырга онытма.

Китәләр. Б и к т и м е р чыга, өстенә киенә башлый. Г ө л н и с а чыга.

Г ө л н и с а. Тагын кая җыенасың?

Б и к т и м е р. Урамга чыгып кайтыйм әле.

Г ө л н и с а. Өйдәге эшләреңне карарга иде, чәй-шикәр беткән, тозы, кәрәчине юк.

Б и к т и м е р. Никтер эшкә кул бармый, карчык.

Г ө л н и с а. Әнә хәзрәтләр җомгага килә, намазга керер идең.

Б и к т и м е р. Кыстама инде, карчык, минем күңел бүген урынында түгел. Чыгып кайтыйм әле. *(Китә.)*

М ө р ш и д ә чыга.

М ө р ш и д ә. Әни, бая сорарга оныттым, Гөлчирә кайтып китәргә уйламый микән?

Г ө л н и с а. Әтиең бик чакырып караган да якын да килми, ди.

З ә м з ә м б а н у кайтып керә.

З ә м з ә м б а н у. Кунак бар икән. Исәнме, Мөршидә?

М ө р ш и д ә. Шөкер әле.

Г ө л н и с а. Килен, бар, өстәлдә чәй көтә.

Зәмзәмбану китә.

М ө р ш и д ә. Моның белән ничек торасыз?

Г ө л н и с а. Эт белән мәче кебек. Аныгы бер хәл иде әле, Нургалигә күз сала башлаган.

М ө р ш и д ә. Ничек?

Г ө л н и с а. Бая монда килеп керсәм, муенына сарылган.

М ө р ш и д ә. Нигә куып чыгармыйсыз? Алла сакласын, йортыгызга бәла китерүе бар. Сездән булмады инде, үзем башлап җибәрим әле.

Г ө л н и с а. Кирәкми, кызым, аның теленә юлыксаң, Алла сакласын, әллә ниләр ишетерсең.

З ә м з ә м б а н у. Әнкәй, самоварың суынып беткән ич.

Г ө л н и с а. Нишләп суынсын, яңа гына эчтек ләбаса.

З ә м з ә м б а н у. Ышанмасаң, тотып кара, боз кебек.

Г ө л н и с а. Ярый инде, килен, ни булганын ясап эчәрсең.

З ә м з ә м б а н у. Самоварың җырлап утырмагач, чәйнең тәме буламы?

М ө р ш и д ә. Тәмләп эчәсең килсә, биләмдә йөрмиләр аны.

З ә м з ә м б а н у. Йөрсәм, сиңа ни калган? Нигә кысыласың?

М ө р ш и д ә. Нигә кысылмаска? Әллә сиңа алар стерәпкәме? Нигә аларны йөртәсең?

Г ө л н и с а. Кирәкми, кызым, талашма.

М ө р ш и д ә. Тик кенә тор, әни! Җитәр инде, ул кәнтәйнең кубызына бик күп биеп тордыгыз. Хәзер юл куймам.

З ә м з ә м б а н у. Бик куркам инде, өркеттең, чәнчә бармагымны селкеттең.

М ө р ш и д ә. Алар юаш, мин булсам сине күптән инде пумала белән куар идем.

З ә м з ә м б а н у. Бер көн тормыйм, өлешемне генә бирсеннәр.

М ө р ш и д ә. Нинди өлеш? Безнең йортта синең ни хакың бар?

З ә м з ә м б а н у. Сигез ел буе хезмәт иттем. Мирхәйдәр өлеше бар. Җәй, кыш димәдек, кара тиребезне агызып эшләдек. Мәрхүмкәем таңнан торып кара төнне генә өйгә кайта иде. Бичаракаем, сугышка китәсе көнне тышка чакырып чыгарды да, башын күкрәгемә куеп: «Әгәр дә мин үлә-нитә калсам, зинһар өчен, минем өлешемне бу нигездә калдырма», — диде. Мескенкәемнең күкрәк көче белән тапкан малын сезгә азык итәр хәлем юк, ярты байлык минеке!

М ө р ш и д ә. Ничек, ярты байлык синеке? Абый өлеше кая?

З ә м з ә м б а н у. Ул гомеренә зимагурдан кайтмады. Аннан, каторжанга өлеш бирмиләр.

М ө р ш и д ә. Нургалигә ни дисең?

З ә м з ә м б а н у. Аның инде күптән хакы юк. Егет булганчы мәдрәсәдә, рус авылында укыды, аннан инде солдатта.

М ө р ш и д ә. Минем өлешем кая?

З ә м з ә м б а н у. Синең инде үгезең үлгән, уртагың аерылган. Тиешлесен артыңнан төяп илттек. Оялмыйча, тагын өлеш сорар идеңме?

М ө р ш и д ә. Нигә сорамаска? Инәмне дә калдырмыйм, Гөлчирә өлешен дә бераүгә дә бирмим, шәригать буенча, кыз туганының өлеше кыз туганга тия, ди.

Г ө л н и с а. Тукта әле, кызым, без бит үлмәгән. Нигә безнең йортны бүләсез?

М ө р ш и д ә. Менә кызык, өлешемә тигән малны әллә ул кәнтәйгә биримме?

З ә м з ә м б а н у. Ярты байлык минеке! Калганын теләсәгез ничек бүлегез.

М ө р ш и д ә. Бирделәр ди, бирмини, сиңа ярты байлыкны, менә мә!

З ә м з ә м б а н у. Яхшылыкта бирмәсәгез, суд аркылы даулап алырмын.

М ө р ш и д ә. Кит, ичмасам, каршымнан, эчеңне тибеп агызырмын.

З ә м з ә м б а н у. Тырнагыңны тидереп кара, нәселегез белән Себер китәрсез.

М ө р ш и д ә. Тукта дим, килмешәк! Билләһи дип әйтәм, җиргә салып кисәрмен.

З ә м з ә м б а н у. Кулың кыскарак.

М ө р ш и д ә. Шулаймы, кыскаракмы? *(Тотып ала да түргә сузып сала. Кизәнеп, ирләрчә кыйный.)*

З ә м з ә м б а н у. Караул, үтерәләр!.. *(Яланбаш чыгып йөгерә.)*

Г ө л н и с а. Әй ходаем, бөтен авылны җыяр инде. *(Тәрәзәдән карап.)* Әнә мәчет алдында хәзрәтләргә такмаклый...

М ө р ш и д ә. Үзегез гаепле, үзегез ирек бирдегез.

Б и к т и м е р керә.

Б и к т и м е р. Нәрсә булды, нинди тавыш бу?

Г ө л н и с а. Өлеш даулап тавыш чыгарган иде, шуның өчен Мөршидә кыйнады.

Ә х т ә р и, Г ы й л ь м а н, З ә м з ә м б а н у л а р керә.

Г ы й л ь м а н. Әссәламәгаләйкем.

Б и к т и м е р. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, хәзрәт.

З ә м з ә м б а н у. Ай билем, ай эчем!..

Г ы й л ь м а н. Тукта, килен, чинама! Биктимер агай, бу нинди гауга?

Б и к т и м е р. Мин бернәрсә дә белмим, хәзрәт, урамда идем.

З ә м з ә м б а н у. Белә, белә, хәзрәт, кызына әйтеп шул карт шайтан кыйнатты.

М ө р ш и д ә. Хәзрәт, әтинең гаебе юк. Ачуымны китергән иде, тоттым да кыйнадым.

Г ы й л ь м а н. Мулла Әхтәретдин, ни дисең?

Ә х т ә р и. Закон буенча, кеше кыйнарга ярамый, хәзрәт. Зәмзәмбану кодачаны кагулары дөрес булса кирәк, нигә дисәң — миңа берничә тапкыр килгәне бар. Закон буенча, судка бирергә

кирәк. Шәригатьчә ничек була торгандыр, ансын инде сез әйтегез, хәзрәт.

Г ы й л ь м а н. Хатын кешенең икенче бер хатынны кыйнау вакыйгасы пәйгамбәребез заманында булмаган. Шулай ук мондый хәлләр хәдис китапларында да күренми. Бәс, шулай булгач, гаилә эчендәге гауганы үзара бетерү мәслихәт булыр. Мөгъюбә гафу үтенсен, мазлума бәхилләсен.

З ә м з ә м б а н у. Юк, юк, хәзрәт, үлсәм дә бәхиллисем юк. Бүгеннән алар белән тора алмыйм, өлешемә тигән малларымны бүлеп бирегез.

Г ы й л ь м а н. Сабыр, килен. Үгет-нәсихәтне тыңларга, олугларны санларга кирәк.

З ә м з ә м б а н у. Тыңламыйм да, хәзрәт, санламыйм да үзләрен. Бүген кычкыртып кыйнаганнар икән, иртәгә таракан даруы биреп үтерүләре дә бар.

Г ы й л ь м а н. Тәүбә-әстәгъфирулла диең, нишләп алар сине үтерсеннәр? Турысын әйткәндә, синең үзеңдә дә гаеп бар.

З ә м з ә м б а н у. Нәрсә?.. Әллә син дә аларны якларга уйлыйсыңмы? Кара аны, мулла абзый, баштан ук әйтеп куям: аларны яклый торган булсаң, указың очканны сизми дә калырсың.

Г ы й л ь м а н. Ах Алла, нишләп мин аларны яклыйм ди. Минем өчен барыгыз да бер. Тик дин вәкиле буларак, мин сезне килештермәкче идем, андый теләгегез юк икән, ихтыяр үзегездә. Хәер, Биктимер агай ни әйтер тагын?

Б и к т и м е р. Ана сөте белән кермәгәнгә, хәзрәт, тана сөте белән кермәс, дигән бабайлар. Мин риза.

Г ы й л ь м а н. Ягъни мәсәлән, ничек риза?

Б и к т и м е р. Ул йогышлы авырудан котылу өчен, өлешенә тигәнне генә түгел, артыгын да бирергә риза. Әнә ак мунчамны бирәм, алсын! Тик, зинһар өчен, бу зәһәрле елан безнең янда гына тормасын!

Артта хатын-кыз тавышы ишетелә.

Г ы й л ь м а н. Анда тагын нәрсә даулыйлар?

М ө р ш и д ә *(тәрәзәдән карап).* Әти, хатын-кызлар безгә керәләр.

Хатын-кызлар ияртеп Г а й н а в а л керә.

Г а й н а в а л. Әхтәри абзый, әйдә, җыен җый.

Ә х т ә р и. Нәрсә, берәр түрә бармы әллә?

Г а й н а в а л. Казна урманыннан безгә утын, волость мәгәҗиненнән чәчүлек орлык бирсеннәр!

Ә х т ә р и *(таягын күрсәтеп).* Бирермен мин сезгә чәчүлек! Яхшы чакта, барыгыз, өйләрегезгә кайтыгыз!

Г а й н а в а л. Кайтмыйбыз! Әйдә каравыл өенә.

Ә х т ә р и. Хәзрәт, бу котырганнарга син әйтер идең, ичмасам.

Г ы й л ь м а н. Мөслимәләр! Пәйгамбәребез Мөхәммәт салаллаһи галәйһисәллам...

Г а й н а в а л. Хәзрәт, намазыңны укып, мәчетеңне кара, мондый дөнья эшләренә тыгылма!

Г ы й л ь м а н. Юк, юк, Гайниҗамал киленчәк, мин болай гына...

Г а й н а в а л. Көмәйләр, хәзрәткә юл бирегез!

Гыйльман китә.

Я, үз аягың белән барамсың? Әллә чана белән тартып илтикме?!

Ә х т ә р и. Үрядник чакыртам, һәммәгезне казаматка яптырам!..

Г а й н а в а л. Яптырсаң яптырырсың, әйдә, җыеныңны җый әле.

Әхтәрине култыклап, өстерәп алып китәләр.

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шәүлиханнар өе. Пәрдә ачылганда беркем дә юк. Бераздан Н у р и я чыга. Тәрәзәгә барып карап тора.

Н у р и я. Ни өчен бу Наһар түтәй юк икән? Әллә, ходаем, җибәргән хатымны кире кактымы? Тизрәк бу газаплы көннәремнең чигенә чыгасы иде дә, шушы йортка бәйләп токан хәйләләрнең төеннәрен чишәсе иде.

Н а һ а р керә.

Сөйлә, түтәй, күрдеңме?

Н а һ а р. Әйе, Нурия, күрдем, менә җавабы.

Н у р и я *(хатны укып).* «Нурия! Әзерләнеп тор, бүген шәһәргә качабыз». Ничек? Миңа качарга диме?

Н а һ а р. Әйе, Нурия. Хәзер ат әзерләргә булып калды. Кичкә авылдан качабыз, ди.

Н у р и я. Юк, юк, бу мөмкин түгел! Мин бит аңардан духовный собрание аша аертып алуны гына сорадым. Нигә мине андый эшкә өнди ул?

Н а һ а р. Күрәсең, шулай эшләү уңайрактыр.

Н у р и я. Юк, мин риза түгел, хат язам, илтеп кайтырсың. Бүген этиләрдә күрешергә теләвемне әйтерсең. *(Язарга утыра.)*

Х а н з а ф а керә.

Х а н з а ф а. Килен, нишлисең монда?

Н у р и я. Минме?.. Менә, Касыймханга хат язам...

Х а н з а ф а. Юк, юк, килен, сиңа андый эшләр белән шөгыльләнергә ярамый, син сырхыйсың.

Н у р и я. Юк, әнкәй, сырхамыйм. Мин үземне бүген яхшы хис итәм.

Х а н з а ф а *(Һаһарга)*. Ә син монда нишләп торасың?

Н а һ а р. Керләр алырга килгән идем.

Х а н з а ф а. Бая гына алып киттең бит.

Н у р и я. Ак керләремне бирмәгән идем. Әйдә, түтәй, җыйнап алырсың.

Китәләр. Ә х т ә р и керә.

Ә х т ә р и. Саумы, кодагый?

Х а н з а ф а. Син дә, кода, әллә кайда йөрисең.

Ә х т ә р и. Сөйләмә инде, кодагый, үләм бит. Җыен яса дип артымнан йөриләр.

Х а н з а ф а. Нинди җыен?

Ә х т ә р и. Хатын-кызлар чәчүлек орлык даулыйлар. Казна урманыннан утын сорыйлар. Бу кияү нигә кайтмый соң?

Х а н з а ф а. Белмим, кода, бүген инде ат та җибәрдек, юк! Нишләп кайтмый торгандыр.

Ә х т ә р и. Хатын-кызларга кода чыгып бер-ике сүз әйтсә, бәлки, тыңларлар иде.

Х а н з а ф а. Кодаң башын да күтәргәне юк. Чүмерә дә чүмерә генә...

Ә х т ә р и. Бик озакка сузган.

Х а н з а ф а. Бер яктан ул борчый, икенче яктан кызың... Авыру булып ятулары бар да хәйлә, бар да алдау булып чыкты. Теге Биктимер качкыны белән яшерен эш йөртәләр, ахры.

Ә х т ә р и. Ничек белдең, кодагый?

Х а н з а ф а. Араларында Һаһар солдатка бутала. Әле менә хәзер дә сөйләшеп торалар иде. Мин бу якка чыгу белән килен бүлмәсенә кереп киттеләр.

Артта Шәүлихан тавышы.

Тагын уянды. *(Китә.)*

Н а һ а р бүлмәдән чыга.

Ә х т ә р и. Шәмсенаһар килен! Сиңа үпкәм зур.

Н а һ а р. Нигә, Әхтәри абзый?

Ә х т ә р и. Яшь кияүгә чыккансың, никах мәҗлесе уздыргансың, мине читтә калдырдың, ашап бетерер диденңме?

Н а һ а р. Үем бәләкәй булганга, чакыра алмадым шул, Әхтәри абзый, гаеп итмә инде. Берәр араны җиңги белән парлап килерсез әле.

Ә х т ә р и. Учыңда нәрсә ул?

Н а һ а р. Ул ни... Идәндә аунап йөри иде... Бер кәгазь кисәге.

Ә х т ә р и. Кая әле, кая, Шәүлихан коданың кирәкле язуы булмасын.

Н а һ а р. Юк, ул андый кәгазь түгел. *(Китә башлый.)*

Ә х т ә р и *(аркылы төшеп)*. Качма! Бир монда... *(Кулыннан талап ала.)* Бар, себерке, эзең булмасын бу йортта! *(Куып чыгара.)*

Х а н з а ф а керә.

Булды, кодагый, мә, укы әле, мин танымыйм. Җәдитчә язылган.

Х а н з а ф а *(укый)*.

«Нургали!.. Минем монда һәр адымымны күзәтәләр. Кичкә әтиләргә кунарга барам, ындыр артлатып мунча алдына килерсең. Шунда сөйләшербез». Каян моны кулга төшердең?

Ә х т ә р и. Наһар кулыннан талап алдым. Димәк, ул аны Биктимер ристанына илтә торган булган.

Х а н з а ф а. Әлбәттә, шуңа. Я, нишлибез?

Ә х т ә р и. Шаулама, кодагый, мин ул азгын баланы кызык итәм. Хәзер алдап өйгә алып китәм дә, ак өйгә бикләп куям. Касыймхан кияү кайтмаса, төнлә белән шәһәргә озатам.

Х а н з а ф а. Шулай ит, кода, мин аларны саклап тора алмыйм.

Ә х т ә р и. Кызым, кызым, Бибинурия!

Н у р и я чыга.

Н у р и я. Ә... Әти килгән икән, исәнме?

Ә х т ә р и. Хәлең ничек, бәбкәем?

Н у р и я. Бүген Аллага шөкер, әти, кәефем бик әйбәт.

Ә х т ә р и. Әйбәттер шул, кызым... Әйбәттер... *(Халыкка.)* Күзләрең дә май ашаган песинеке кебек янып торалар. *(Нуриягә.)* Менә нәрсә, кызым, әниең сине алырга җибәргән иде. Бик

тәмле угыз тәбәсе пешергән. Әйдә безгә, сыйланып кайтырсың.

Н у р и я. Ярый, әти, үзем дә сезгә барырга җыенып тора идем әле.

Ә х т ә р и. Шулаймыни? Бар, алайса киенеп чык.

Нурия китә.

Х а н з а ф а. Карт төлке, нинди оста сөйлисең...

Ә х т ә р и. Май кап, кодагый, бер атуда куш куян.

Х а н з а ф а. Пожар сарае алдында нинди халык ул?

Ә х т ә р и. Шулар инде, минем чыкканымны көтәләр.

Н у р и я киенеп чыга.

Н у р и я. Әйдә, әти, киттекме?

Ә х т ә р и. Ашыкма, кызым, абынып егылырсың.

Китәләр. Ап-ак күлмәк-ыштаннан Ш ә ү л и х а н чыга.

Ш ә ү л и х а н. Карчык, хәзер генә минем янга губернатор килде. Мужиклар өстеннән жалоба бирде. Шунда судья Пантелей Пантелеевич, дьякон хатынына кул салып, недоимка түләүдән баш тартты.

Х а н з а ф а. Ничек, ничек дидең?

Ш ә ү л и х а н. Мин аларны арестовать иттерәм.

Х а н з а ф а. Кемне, губернаторнымы?

Ш ә ү л и х а н. Түгел, мужикларны, төрмәгә, каталажкага яптырам. Себергә каторгага кудырам. *(Күз алдына китереп.)* Староста, капкорсак, кайда синең десятнигың, сотнигың? Нигә килми чучка танау, стражник, ришвәтче, сукин урәдник?!.

Х а н з а ф а. Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетәме? Сүзеңнең бит һич тә ата-анасы юк.

Ш ә ү л и х а н. Мин монда нигә кердем соң әле? Син чакырдыңмы?

Х а н з а ф а. Юк. Үзең кердең.

Ш ә ү л и х а н. Фу, шайтан алгыры... Баш авырта, кая, тагын бераз гына салып бир әле.

Х а н з а ф а. Каян алыйм? Бая актыгысын эчтең ич.

Ш ә ү л и х а н. Калгандыр әле, мин бит үзем белән әллә нихәтле спирт алып кайттым.

Х а н з а ф а. Үгез бозау кебек, бертуктаусыз чүмергәч, каян калсын ди. Мичкәсе белән булса да тетмәс иде.

Ш ә ү л и х а н. Җанкисәгем, Ханзафа, табып бир инде.

Х а н з а ф а. Син шуны аңла, иртәгә сиңа волостьта булырга кирәк.

Ш ә ү л и х а н. Әйе, әйе, булырга кирәк. Шуның өчен дә мин баш төзәтергә сорыйм.

Х а н з а ф а. Телеңне әрәм итеп сорама, бер тамчы да юк.

Ш ә ү л и х а н. Ул чагында хуш, рус авылына самагун эзләргә киттем.

Х а н з а ф а. Бар, бар, старшина башың белән аракы эзләп йөр.

Ш ә ү л и х а н. Йөрим, туйганчы эчәм дә буранда адашып үләм. Барыбер минем беркемгә дә кирәгем юк. Халык яратмый. Улларым санга санамый... Хәтта син дә мине читкә кага башладың. Бер тустаган аракыңны да кызганасың.

Х а н з а ф а. Ярый, бераз калдырган идем, әйдә, эчәрсең. Тик кара аны, ахыргысы булыр.

Ш ә ү л и х а н. Ахыргысы, карчык, ахыргысы.

Китәләр. К а с ы й м х а н белән Я с ә в и керә.

К а с ы й м х а н. Мин станциядә ашлык көтәм, грузчиклар яллadым, эшелон буш тора. Станция начальнигы һәр сәгате саен акча ала.

Я с ә в и. Нишлим соң, Касыймхан? Бүген йөз олау килгән иде, Кригер потына биш тиен бирә башлагач, «Шуннан ким булса, бармыйбыз» диделәр дә борылып киттеләр. Аптырагач, күрше авыллардан да эзләтеп карадым, юк, берсе дә килмиләр.

К а с ы й м х а н. Шулай да бит, икмәкне ташырга кирәк.

Я с ә в и. Нишлим соң, халык риза булмагач.

К а с ы й м х а н. Менә нәрсә. Сез сораган бәягә — Кригер куйган хакка без дә риза булабыз, дип игълан ит. Соңыннан өч тиен белән расчет ясарбыз.

Я с ә в и. Алай эшләп, мин уңайсыз хәлгә калмаммы?

К а с ы й м х а н. Расчетны үзем ясармын. Ничек кенә булса да, олаулар бүген станциядә булырга тиеш!

Ясәви китә. Х а н з а ф а керә.

Х а н з а ф а. Исән кайттыңмы, улым.

К а с ы й м х а н. Әти өйдәмени?

Х а н з а ф а. Өйдә, өченче көн инде.

К а с ы й м х а н. Тагын эчәме?

Х а н з а ф а. Аның шул инде, өзгәне дә юк. Эчә дә чалган үгез кебек гырылдап йоклый. Уяна да тагын аракы даулый.

К а с ы й м х а н. Нурия өйдә юкмыни?

Х а н з а ф а. Аталарында.

К а с ы й м х а н. Нишләп анда ул?

Х а н з а ф а. Сорама инде, улым, монда әллә ниләр бар... Теге ир кисәге кайтты бит.

К а с ы й м х а н. Ишеттем, кичә Басарый түндәк телеграмма җибәргән иде. Нәрсә булды соң?

Х а н з а ф а. Нәрсә булсын? Кадерле хатыныңның зур гаебе ачылды.

К а с ы й м х а н. Нинди гаебе?

Х а н з а ф а. Менә, укы... *(Хат бирә.)* Мин ашарга әзерләтим әле. Миңлекамал, Миңлекамал, дим!

Касыймхан хатны укып кесәсенә сала. Шашкан кыяфәттә Ш ә ү л и х а н чабып керә.

Ш ә ү л и х а н. Килмә, килмә, кит каршымнан!

К а с ы й м х а н. Әти, сиңа ни булды?

Ш ә ү л и х а н. Балта тотып чабарга киләләр. Әнә алар тәрәзәдән керделәр. Дуңгызга әверелделәр...

К а с ы й м х а н. Әти, бернинди дә дуңгыз юк. Болай кара әле, мине таныйсыңмы?

Ш ә ү л и х а н. Таныйм, Илья Петрович.

К а с ы й м х а н. Түгел, бу мин, Касыймхан.

Ш ә ү л и х а н. Касыймхан?.. Улым, алар миңа йокларга бирмиләр. Төшемә керәләр, күз алдыма киләләр. *(Елый.)*

К а с ы й м х а н. Кыяфәтеңә кара, кемгә охшыйсың?

Ш ә ү л и х а н. Беләм, сынок, беләм...

К а с ы й м х а н. Белгәч, үзеңне тыярга, кулга алырга мөмкиндер.

Ш ә ү л и х а н. Аңламыйсың, сынок, алкоголикның хәлен аңламыйсың. Шул агудан кешеләрне коткару өчен берәр дару да уйлап тапмыйлар.

К а с ы й м х а н. Аның даруы бар, әти, беренче рюмкасын гына эчмәскә кирәк.

Ш ә ү л и х а н. Дөрес, сынок, моннан соң эчмим, бөтенләйгә ташлыйм, ни дисең?

К а с ы й м х а н. Бик яхшы булыр. Ләкин тукран тәүбәсе булып калмаса ярый.

Ш ә ү л и х а н. Юк, юк, сынок, валлаһи, эчмим, хәтта якын да китермим.

К а с ы й м х а н. Юкса үзең уйлап кара, әти, илдә барган ризасызлыкларны бетерүгә без дә катнашмагач, кемнәр җиңәр соң аны? Без бит Романовлар нәселенә сигез буыннан бирле хезмәт итеп килгән данлы Аюхановлар!.. Ә алар, пычрак халыклар, Биктимер

малайлары кебек кара сарыклар, безне үз кубызларына биетергә уйлыйлар. Юк, алар белән чәйнәшергә безнең көчебез дә, тешебез дә җитәрлек әле.

Ш ә ү л и х а н. Дөрес, сынок! Син бераз гына табыш бир инде.

К а с ы й м х а н. Нәрсәне?

Ш ә ү л и х а н. Аракы.

К а с ы й м х а н. Соң бит хәзер генә эчмим дип Алла белән ант иттең.

Ш ә ү л и х а н. Мин сиңа бүгеннән соң, дидем.

К а с ы й м х а н. Рәтең беткән икән, әти.

Ш ә ү л и х а н. Юк әле, сынок, бетмәгән! Мин хәзер волостька барып, теләгән бер мужикны ябып куя алам, теләгән бер авылны Себергә куа алам. Тик менә баш кына авырта... Әйтерсең тимер кыршау белән кысып куйганнар. Я, сынок, тыңла инде.

К а с ы й м х а н. Мә, тыгын!.. Тик ахыргысы булсын...

Ш ә ү л и х а н. Ахыргысы, сынок, ахыргысы. *(Китә.)*

С а м с о н о в керә.

С а м с о н о в. Исәнмесез, Касыймхан Шәүлиханович?

К а с ы й м х а н. Әйдәгез, Савелий Назарич, өстегезне салыгыз.

С а м с о н о в. Юк, юк, мин үтеп барышлый гына. Шәүлихан Алимхановичны күрергә генә кердем.

К а с ы й м х а н. Аның хәле шәптән түгел шул.

С а м с о н о в. Һаман айнымадымы?

К а с ы й м х а н. Юк әле. Сез нәрсәгәдер борчылган.

С а м с о н о в. Бөтен волостьта кошмар. Өченче көн фронттан кайткан солдатлар Твардовскийның урманын кисәргә керешкәннәр иде, объезщик барып туктатырга теләгәч, мылтыгын алып, кыйнап киткәннәр. Кичә Амирхановларның кибетләрен бастылар. Бүген шуларны тикшереп эзләренә төшеп тора идек, Стахиевларның аракы заводы управляющие килеп төште. Мастеровойлары жалованиe арттыруны сорап эш ташлаганнар. Завод хәзер эшләми. Анда бит миллион литр спирт саклана. Кул астымдагы бөтен стражникларны алып шунда барышым. Авылларда старосталарны сүгү, тотып кыйнау, байлар белән халык арасындагы конфликтларны әйткән дә юк, кошмар, кошмар!..

К а с ы й м х а н. Димәк, алар белән кемдер җитәкчелек итә?

С а м с о н о в. Кешесен дә беләбез: Артамонов линия тикшерү хәйләсе белән кичә генә авыллардан кайткан иде, бүген тагы аракы заводына чыгып киткән, ди.

К а с ы й м х а н. Алайса нигә аны кулга алмыйсыз?

С а м с о н о в. Бер мәртәбә инде эшеннән алдыру теләгемә ирешкән идем, өяздә яхшы эшче дип яклыйлар. Яңадан урынына

кайтардылар. Әгәр дә чыннан да аның бүген аракы заводына бару факты дөрес булса, мин аны кулга алып өязгә озатам.

К а с ы й м х а н. Әле мин дә яңа гына станциядән кайтып кердем.

С а м с о н о в. Соң, анданиләр бар?

К а с ы й м х а н. Алай артык берни дә күренми. Шулай да станция начальнигы үзәктән килә торган поездлар йөрешенең тукталуына аптырый. Сәбәбен сорасаң, әйтмиләр, ди.

С а м с о н о в. Неужели бишенче ел вакыйгасы кабатлана инде? Кошмар, кошмар!

К а с ы й м х а н. Алай дип уйламыйм, берәр җирдә зур крушение булгандыр.

С а м с о н о в. Ярый, мин китим, кешеләрем туңа торгандыр. Сез, зинһар өчен, Шәүлихан Алимхановичны җибәрергә тырышыгыз. Чөнки анда Илья Петровичтан башка беркем дә юк. Авыллардан килгән кешеләрнең саны кошмар, кошмар. Алла сакласын, берәр нәрсә эшләп ташлаулары бар. Кошмар, кошмар!.. *(Китә.)*

Н у р и я керә.

Н у р и я. Кайткансың икән.

К а с ы й м х а н. Әллә көтмәгән идеңме?

Н у р и я. Нишләп көтмәскә ди, бик көттем...

К а с ы й м х а н. Шулай микән? Ирен көткән хатын биләмдә йөрми ул.

Н у р и я. Нинди биләм? Әти килеп чакырган иде, аларда булдым.

К а с ы й м х а н. Теге купшың кайткан икән.

Н у р и я. Шулай, диләр.

К а с ы й м х а н. Фронтта сугышмыйча, нишләп йөри ул монда?

Н у р и я. Мин каян белим?

К а с ы й м х а н. Миңа кара әле.

Н у р и я. Менә инде, кызык...

К а с ы й м х а н. Ояласың?

Н у р и я. Нишләп оялыйм?

К а с ы й м х а н. Ах, синең бу күзләрең, нинди серле, нинди хәйләкәр... Нигә калтырыйсың?

Н у р и я. Саулыгым юк.

К а с ы й м х а н. Шулаймыни? Ни булды?

Н у р и я. Салкын тидердем, ахры.

К а с ы й м х а н. Кая, хатыңны бир әле.

Н у р и я. Нинди хатымны?

К а с ы й м х а н. Бүген миңа язган хатыңны.

Н у р и я. Сиңа нигә ул?

К а с ы й м х а н. Укыйсым килә. Ялгышмасам, синең миңа беренче хат язуың бугай. Кая, күрсәт әле.

Н у р и я. Мин аны язып бетерә алмадым.

К а с ы й м х а н. Язган кадәресен бир.

Н у р и я. Килешсез чыкканга мин аны ертып ташладым.

К а с ы й м х а н. Ялганлыйсың! Син аны Биктимер кушшысына язгансың.

Нурия китә башлый.

Тукта, кая барасың?

Н у р и я. Минем кәефем юк...

К а с ы й м х а н. Җавап бирүдән качасың?!.

Н у р и я. Тотма, җибәр, мин синнән куркам!

К а с ы й м х а н. Әйт, яздыңмы?

Н у р и я. Нигә син мине газаплыйсың?

К а с ы й м х а н. Юк, син миңа җавап бир, яздыңмы?

Н у р и я. Әйтәм бит инде, язмадым.

К а с ы й м х а н. Ә мин әйтәм, язгансың.

Н у р и я. Ышан миңа, язмадым.

К а с ы й м х а н. Әйе, әйе, ышанырга ярый, чөнки син хыянәтче хатын!

Н у р и я. Ялган! Син аны берни белән дә исбат итә алмассың.

К а с ы й м х а н. Менә бу нәрсә?.. *(Битенә бәрә.)* Синең һәрбер сүзең мине алдауга корылган. Һәрбер елмаюларың хәйләле мәкер белән сугарылган. Ела, ела!.. Бәлки, мине ышандырырсың? Бәлки, хыянәтле яшең белән керле күңелеңне арындырырсың. Я Ходай, минем өчен нинди зур хурлык!..

Икесе ике җирдә сүзсез торалар.

Бар, әйберләреңне җыештыр, китәбез.

Н у р и я. Кая?

К а с ы й м х а н. Шәһәргә.

Н у р и я. Анда нигә?

К а с ы й м х а н. Анысы синең эш түгел.

Н у р и я. Ни өчен китүемне мин белергә тиештер дип саныйм.

К а с ы й м х а н. Син авыру... Мин сине докторларга күрсәтәм.

Н у р и я. Минем бер җирем дә авыртмый. Һәм мин беркая да бармыйм.

К а с ы й м х а н. Мин әйткәч, барырсың.

Н у р и я. Бармам! Мин синең колың түгел.

К а с ы й м х а н. Югал күземнән! *(Әйбер белән кизәнеп кычкыра.)*

Нурия китә. Кинәт ишектән Б а с а р ы й килеп керә.

Б а с а р ы й. Касыймхан, беттек, тотылдык!

К а с ы й м х а н. Ничек тотылдык?!.

Б а с а р ы й. Биктимер Нургалие мине эт урынына тотып кыйнады. Менә, өч тешемне сугып төшерде.

К а с ы й м х а н. Ни өчен?

Б а с а р ы й. Мин волостьта качып ята идем, кичә ике тапкыр мине сорап безнең өйгә килгән. Икесендә дә, «Минем янга барсын әле», — дип әйтеп калдырган. Кайтып керүгә атымны да туарырга өлгермәдем, тагы бер малайны җибәргән. Барсам, җизнәсе белән мунчада утыралар, икесе дә кызмачалар. Кесәсеннән хат чыгарды да: «Әтиләргә килгән менә бу хатка син, кабахәт, кулың салдыңмы? Аты дигән сүзне син, корчаңгы, боздыңмы?» — ди. Икмәк белән ант итеп карадым, ышанмады. Шуннан бугазымнан тотып алып, мунча идәненә сузып салды да гыр-гырымнан буа башлады...

К а с ы й м х а н. Я, я, шуннан?

Б а с а р ы й. Шуннан инде эшнең ничек булуын әйтми чарам калмады.

К а с ы й м х а н. Сатлык җан!.. *(Яңагына суга.)* Нигә әйттең?

Б а с а р ы й. Түзәрлегем калмады. Бугазымнан буып үтерә иде.

К а с ы й м х а н. Моның өчен, беләсеңме, ул сине нишләтер? Ялган документ ясавың өчен, алты елга төрмәгә яптырыр. Хәзер үк прошение яз.

Б а с а р ы й. Нинди прошение?

К а с ы й м х а н. Сине кыйнавы өчен судка бирәбез.

Б а с а р ы й. Ә соң минем хатны бозуым?

К а с ы й м х а н. Берни дә түгел, буып үтерә башлагач, җанымны саклап калу өчен, юк гаепне өстемә алырга мәҗбүр булдым диярсең.

Б а с а р ы й. Ярый ла ышансалар?

К а с ы й м х а н. Ышанырлыр. Ул якларын үзем карармын.

Басарый китә. Х а н з а ф а керә.

Х а н з а ф а. Улым, ашарга әзерләткән идем.

К а с ы й м х а н. Рәхмәт, әни, минем берни дә ашыйсым килми.

Х а н з а ф а. Әйттем мин сиңа, кара мужик кызына өйләнмә, дидем, тыңламадың. Ул килгәннән бирле йортта бәрәкәт бетте, тыныч тормышыбызның рәхәте китте. Инде нишлисез? Бер хатынга ике ир булдыгыз.

К а с ы й м х а н. Аның бернинди дә дәхле юк. Шәригать белән талак ителгән.

Х а н з а ф а. Ул анда «хөкемгә бирәм, барысын җавапка тарттырам» дип әйтә, ди. Урыс законының аны яклавы бар. Күкрәгенә тәре дә тагып кайткан, ди.

К а с ы й м х а н. Калдыр әле! Бар, әнә Җамали абзыйга чыгып әйт, миңа ат җиксен.

Х а н з а ф а. Тагы кая барасың?

К а с ы й м х а н. Теге өстерәлчекне шәһәргә алып китәм.

Х а н з а ф а. Юкка гына үз сүзеңне итәсең, аерып җибәрергә иде.

К а с ы й м х а н. Җитәр инде, икене аердым.

Х а н з а ф а. Үз дигәнең булмагач, бер дә гаеп түгел ул. Әллә илдә кызлар беткәнме? Менә дигән, морза кызын алыр идең.

К а с ы й м х а н. Минем абруемны, ирлек намусымны кая куясың? Ниндидер бер хәерче малаеннан куркып, хатын аерды дип, бөтен янәшә-тирә көләр иде бугай. Бар инде, бар, ат җиксеннәр.

Х а н з а ф а. Җамали, Җамали дим! *(Китә.)*

Ә х т ә р и керә.

Ә х т ә р и. Сау кайттыңмы, кияү балакай?

К а с ы й м х а н. Чакыртып та килмисең, кая йөрисеңдер дөмегеп?

Ә х т ә р и. Юлда хәзрәт очрап җибәрми торды. Бичара, күз яше белән зарланып елый. «Теге Биктимер малае килгән иде, нигә минем хатынга никах укыдың, мин сине, чалмалы каракны, судка бирәм, төрмәгә яптырам» дип әйтә, ди. Аннан, бүген хатын-кыз котырды. Казна урманыннан утын сорыйлар. Язгы чәчүгә орлык даулыйлар. Өйгә кайтсам, артымнан киләләр. Урамга чыксам, ияреп йөриләр.

К а с ы й м х а н. Нигә волостька хәбәр итмисең, нигә стражниклар чакырмыйсың?

Ә х т ә р и. Чакырдым, килмиләр. Әле менә хәзер дә урядниклар каядыр командалары белән баралар иде, туктатып әйттем, кул гына селтәде. Беренче итеп Биктимер солдатны тотып бирер идем. Хатын-кызларны шул карт шайтан котырта. Бүген иртәдән бирле урамда йөри. Очраган бер кешегә Петербур хәлләре турында сөйли. Әнә хәзер дә пожар сарае алдында утыра. Җыелган халыкка нәрсәдер сөйли.

К а с ы й м х а н. Белергә иде, ул аларга нәрсә лыгырдый икән?

Ә х т ә р и. Ахирәт гамәле турында түгелдер инде. Шуннан ук билгеле, аның бит үз гомерендә пожар сарае алдына чыкканы

юк иде. Ә бүген күкәй баскан күркә кебек шунда утыра. Бара башласаң, сүзне икенчегә бора да, әкият сөйләргә керешә.

К а с ы й м х а н. Я, бабай, кызыңның бу гаебе өчен миңа нинди киңәш бирәсең?

Ә х т ә р и. Үтерсәң дә сүзем юк инде, кияү, тик шул кадәресе бар, кайчагында дүрт аяклы ат та абынып куйгалый. Минемчә, бик әйбәтләп, мөселманчалап пешерергә дә, кичерергә кирәк.

К а с ы й м х а н. Юк, кичермим. Һәм мин аңа ормыйм, сукмыйм да, аерып кына җибәрәм.

Ә х т ә р и. Аерасың?

К а с ы й м х а н. Башкача мөмкин түгел. Үзең уйлап кара, шундый хәлләрдән соң, ничек мин аның белән торыйм?

Ә х т ә р и. Анысы дөрес инде, кияү. Тик аны беркем дә белми, эчтән тынарбыз.

К а с ы й м х а н. Юк, намусым күтәрми, аерам!

Ә х т ә р и *(алдына тезләнеп)*. Кияү, ике күзем, ил каршында безне кимсетмә. Сезнең кебек абруйлы кешеләргә кардәш булу бәхетеннән мәхрүм итмә. Без, анасы белән ул азгын баланы үгетләрбез. Колың булып хезмәт итәргә димләрбез. Зинһар, безне Биктимерләр нәселенә яңадан иш итмә...

К а с ы й м х а н. Ярый, тор. Синдәй өлкән картның үтенечен кире кага алмыйм. Мин аны үзем белән шәһәргә алып китәм. Бәлки, төзәлер әле.

Ә х т ә р и. Төзәлер, кияү, төзәлер.

К а с ы й м х а н. Безнең йортка күз-колак булырсың. Зыян сала күрмәсеннәр. Төнлә белән берничә кешене яшерен каравылга куйсаң да ярар.

Ә х т ә р и. Була, кияү, була, куярбыз.

Артта х а т ы н - к ы з тавышы.

У... Ходай орган хатыннар! Урядниклар килгәч, таралганнар иде, тагын җыелганнар. Корык белән кудырыйм әле. *(Китә.)*

Тыштан Х а н з а ф а керә.

Х а н з а ф а. Улым, атың җигелгән.

К а с ы й м х а н. Хәзер, әни, теге булдымы икән?

Х а н з а ф а *(бүлмәгә барып карый)*. Булган, ахры. Ичмасам, бүген генә китмәсәң иде, эштән чыккан атаң белән калам бит.

К а с ы й м х а н. Бабай белән сөйләштем, ул сиңа булышыр. Әнә эти уянды.

Ханзафа китә. Я с ә в и керә.

Я с ә в и. Олаучылар бар да риза булдылар, кичкә таба юлга чыгалар.

К а с ы й м х а н. Менә нәрсә: бүгеннән бөтен товарларны сатуны туктатып, подвалларга яшер. Кассадагы акчаларыңны алтын-көмешкә әйләндерү ягын кара.

Я с ә в и. Алай... димәк, Биктимер карт юкны сөйләми?

К а с ы й м х а н. Ярый, күпне белсәң тиз картаерсың. Бар, эшеңдә бул.

Ясәви китә. Әйберләрен күтәреп, бүлмәдән Н у р и я чыга.

К а с ы й м х а н. Җыенып беттеңме?

Н у р и я. Әйе, беттем...

К а с ы й м х а н. Кирәкле әйберләреңнең барысын да алдыңмы?

Н у р и я. Инәмне дә калдырмадым...

К а с ы й м х а н. Бик әйбәт булган. Әйдә алайса, киттек.

Н у р и я. Бар, чыга тор...

К а с ы й м х а н. Ә син?

Н у р и я. Мин... көтәм әле...

К а с ы й м х а н. Кемне?

Н у р и я. Әйберләремне төяргә ат көтәм...

К а с ы й м х а н. Соң бит ат җигелгән.

Н у р и я. Минем әйберләрем күп, бер чанага сыймабыз...

К а с ы й м х а н. Син нәрсә, минем белән шаярасыңмы?

Н у р и я. Шаярмыйм, дөресен әйтәм...

К а с ы й м х а н. Шулай булгач, нинди ат турында сөйлисең?

Н у р и я. Мин синең белән артык тора алмыйм, мин синнән китәм.

К а с ы й м х а н. Ах син, уйнашчы!

Н у р и я. Нәрсә?

К а с ы й м х а н. Әйе, әйе, уйнашчы!!.

Н у р и я. Ах син, кабахәт! Пычрак җанлы, фахиш кеше! Аз гына намусың булса, андый сүзне телгә алырга тартыныр идең. Хәер, синең бит бер генә дә саф сүзең булмаган кебек, чиркана белгән йөзең дә юк. Бөтен тормышың ялган, фахишлеккә корылган. Халык алдаучы, казна талаучы жулик!..

К а с ы й м х а н. Җитәр, дим!.. *(Һөҗүм итә.)*

Н у р и я. Әй, халык, ярдәм итегез!!!

Куышып йөриләр, Касыймхан Нурияне тотып буа башлый, Н у р г а л и белән Х ө р м ә т у л л а керә.

Н у р г а л и. Җибәр, бүре баласы!

К а с ы й м х а н. Сез монда нигә кердегез?

Н у р г а л и. Менә, бу хат буенча, исәп-хисапларны өзәргә килдем. Я, ни белән түлисең? Каның беләнме, әллә пычрак җаның беләнме?!

К а с ы й м х а н. Чыгыгыз минем өемнән!.. *(Үзе куркып бүлмәгә таба кача башлый.)*

Н у р г а л и. Юк, качмый тор әле.

Х ө р м ә т у л л а. Каениш, чырсыз кыланма.

Нургали, кулына камчысын алып, Касыймхан артыннан китә.
Артта чаж-чож иткән камчы тавышы ишетелә.

К а с ы й м х а н. Караул, үтерәләр!

Х а н з а ф а чыга.

Х а н з а ф а. Нинди тавыш ул, кемне кыйныйлар?

Х ө р м ә т у л л а. Юк, кыйнамыйлар, болай гына биргәлиләр.

Ханзафа тавыш килгән якка кереп китә.

Ай, бу каенишне, бәлагә калмаса ярар иде.

Бүлмәдән Н у р г а л и чыга.

Н у р г а л и. Әйдә, Нурия, киттек!

Н у р и я. Кая киттек?

Н у р г а л и. Шәһәргә, Гөлчирәләр янына!

Н у р и я. Ә соң ат?

Х ө р м ә т у л л а. Үзем илтә барам, кайгырма, килен.

Н у р и я. Әйдә алайса, алыгыз әйберләрне.

Китәләр. Х а н з а ф а белән К а с ы й м х а н чыга.

Х а н з а ф а. Тукта, улым, баш-күзеңне юарга кирәк, бу көенчә кая барасың?

К а с ы й м х а н. Артларыннан куа барам. Бүре чабагачы кайда икән?

Х а н з а ф а. Йөрмә, улым, үз башыңа бәла алырсың.

Ишекне ачык калдырып, тышка чыгып китәләр. Калтыранып, бүлмәдән Ш ә ү л и х а н чыга.

Ш ә ү л и х а н. Болар кая киткәннәр? Ишекләре ачык калган. Ух, башым авырта...

Х а н з а ф а керә.

Кайда йөрисең?

Х а н з а ф а. Син бернәрсә дә ишетмәдеңме?

Ш ә ү л и х а н. Йокыга киткән идем, туңып уяндым, ни булды?

Х а н з а ф а. Биктимер качкыны Касыймханны кыйнады.

Ш ә ү л и х а н. Ныграк бирергә иде.

Х а н з а ф а. Кемгә?

Ш ә ү л и х а н. Биктимер малаена!

Х а н з а ф а. Мин сиңа, Касыймханны кыйнады, дим.

Ш ә ү л и х а н. Шулаймыни? Баш эшләми, карчык, баш, төзәтеп аласы иде.

Х а н з а ф а. Куй әле шул исерек башыңны. Әнә өйнең асты өскә килгән. Миңлекамал, Миңлекамал!.. *(Кычкыра-кычкыра китә.)*

Бик ашыгып Л а ш м а н о в килеп керә.

Л а ш м а н о в. Шәүлихан Алимханович, сезне алырга килдем, безнең өчен яман хәбәр бар!

Ш ә ү л и х а н. Нинди хәбәр?

Л а ш м а н о в. Безнең волостька земский начальник килә!

Ш ә ү л и х а н. Каян белдегез?

Л а ш м а н о в. Каргалыдан язу җибәргән. «Иртәгә сезнең волостьта булам, беркая да китми торыгыз», — дигән.

Ш ә ү л и х а н. Мондый даулы көннәрдә нишләп йөри икән?

Л а ш м а н о в. Әлбәттә, яхшылыкка түгелдер. Гриша Артамонов кебекләр жалоба биргәндер.

Ш ә ү л и х а н. Шулай дисезме?

Л а ш м а н о в. Башкача ничек булсын? Кыш уртасында йөрмәс иде. Чыннан да, Шәүлихан Алимханович, ясаклар җыелмаган, недоимкалар түләнмәгән, сугыш яралылары файдасына җыелган акчаларның исәп-хисаплары чуалган.

Ш ә ү л и х а н. Ничек чуалган? Аңлатып сөйләгез.

Л а ш м а н о в. Биш меңләбе Касыймхан кулында. Исмәгыйль хаҗи, Панкратовлар сугыш башланганнан бирле отчет биргәннәре юк. Шулай ук, шактый гына сумма сезнең кулыгызда да йөри...

Ш ә ү л и х а н. Ярый, ярый, аңлашылды! Сез үзегез дә базарлар фондыннан кергән акчаларга нәсел сыеры алган идегез бугай, аларны да түләргә кирәк, земскийдан сүз ишетерлек булмасын! Әйдә, киттек. Ул килгәнче бөтен эшне җайлап куярбыз. Карчык, карчык, дим.

Х а н з а ф а керә.

Х а н з а ф а. Нәрсә бар тагын?

Ш ә ү л и х а н. Минем киемнәрне бир.

Х а н з а ф а. Кая барасың?

Ш ә ү л и х а н. Волостька.

Х а н з а ф а. Син бит бүген ашамаган, мунча керәсең дә бар.

Ш ә ү л и х а н. Куй әле син мунчаларыңны. Әнә земский килә, ди. Кая, киемнәрне бир!

Ханзафа китә.

Илья Петрович, үзегез белән алып килмәдегезме?

Л а ш м а н о в. Отчетларны дисезме?

Ш ә ү л и х а н. Түгел, аракы, дим.

Л а ш м а н о в. Юк шул. Мин сезнең мондый хәлдә икәнегезне белмәдем. Ярый, мин чыга торыйм. *(Китә.)*

Х а н з а ф а киемнәр тотып керә.

Х а н з а ф а. Бу нинди шау-шулы көн булды соң?

Ш ә ү л и х а н. Сөйләмә, карчык, минем дә баш шаулый.

Х а н з а ф а. Син анда, зинһар өчен, үзеңне тый инде.

Ш ә ү л и х а н. Ярый, карчык, хуш.

Х а н з а ф а. Аллага тапшырдык.

Китәләр. Ханзафа озата чыга, бераздан әйләнеп керә.

Аллага шөкер, тынычланып калдым бит. Бераз ял итим инде. Миңлекамал, Миңлекамал! Ишекләрне бикләп ал. Казага калган намазларымны укыйм. *(Китә башлый, артта талаш-кычкырыш ишетелә.)* Миңлекамал, урамга чыгып кара әле, тагын анда нәрсә даулыйлар?

Б а с а р ы й йөгереп керә.

Б а с а р ы й. Ханзафа абыстай, амбарларыгызны таларга телиләр, урамда Әхтәри абзыйны кыйныйлар!

Х а н з а ф а. Кемнәр?

Б а с а р ы й. Хатын-кызлар, гарип солдатлар.

Х а н з а ф а. Алай булгач, нигә монда кердең, нигә ирек бирәсез?

Б а с а р ы й. Алар белән нишлисең? Әнә амбарны ваталар!..

Х а н з а ф а. Утны сүндер!

Ясәви лампаны кыса. Караңгыда калалар. Тышта авыр әйбер белән амбар ишеген каерганнары ишетелә.

Г а й н а в а л *(тыштан)*. Ват, җимер! Ишеген!

К ү м ә к т а в ы ш. Үрә!..

Б а с а р ы й. Ваттылар!!!

*Пәрдә.*

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Волость правлениесе. Бер якта барьер белән бүленгән өлкән писарь өстәле. Икенче якта старшина урыны. Биек-биек тәрәзәләр. Берничә шкаф, янмый торган акча сандыгы. Артта ике якка китә торган коридор. Пәрдә ачылганда коридорда, йомыш белән килүче кешеләргә Хөрмәтулла нидер сөйли. Башкалар аны йотлыгып тыңлыйлар.

Хөрмәтулла. Шулай, егетләр, засадада торам, төн шулкадәр караңгы — күзеңә төртсәләр дә берни күрмәссең. Җитмәсә тагын, пыскаклап яңгыр да ява. Менә бервакытны әллә кайда гырылдаган тавыш ишетелә. Тыңлыйм, дошман ягыннан килә. Бераздан тагын берничә тавыш кушылды. Тора-бара, таң бүреләре шикелле, хор белән гырылдарга керештеләр. Мин өйдә хатын гырылдаса да яратмый торган гадәтем бар иде, хәзер бөеренә төртеп ята идем. Әмма монда берни дә эшләп булмый, эч пошырып гырылдыйлар да гырылдыйлар. Тукта, мин әйтәм, боларны кызык итим әле, дим. Әкрен генә тегеләр ягына шуыша башладым... Барып җиттем... Бер солдат — землянка ишеге төбендә, мылтыгын кочаклаган да, утырган килеш йоклаган. Нишләргә? Пленга алыргамы? Юк, мин әйтәм, моның белән генә пычранырга ярамый, бер җыеныш килгәч, зуррак маҗара куптарырга кирәк, дим. Шуннан, мин бу солдатны тычкан тоткан песи кебек кенә буып үтердем.

Карчык. Тәүбә-әстәгъфирулла, кансыз кеше икәнсең.

Хөрмәтулла. Шуннан, әкрен генә землянка ишеген ачып кердем. Бер почмакта тонык кына ут яна... Егермеләп солдат, берничә офицер сәке өстенә тезелеп ятканнар да, рәхәтләнеп, гырылдап йоклыйлар. Шуннан, ишләп кенә һәммәсенең дә коралларын алдым, каешларыннан тотып аркама салдым... Бербер артлы ике гранатаны җибәрдем дә чыгып йөгердем... Берничә атна узгач, без ялга чыктык. Беркөнне шулай, патша килә дигән хәбәр таралды. Полкны урман эчендәге бер яланда сафка тезделәр. Без — солдатлар инде, тын да алмый көтеп торабыз. Менә бервакытны, янаралларын ияртеп, тимеркүк атта патша килеп чыкты да, ялан уртасына туктады. «Хөрмәтулла Сөнгатуллин, безнең янга» дип, полк командиры миңа кычкыра! Мин инде шәм шикелле каткан килеш кенә барып алларына туктадым. Шуннан, патша атыннан төште дә, яныма басып аркамнан сөйде. Аннан солдатларга карап: «Менә, Мамай токымыннан үрнәк алыгыз», — дип күкрәгемә, үз кулы белән, менә шушы тәрене кадады.

Соколов. Ышанмагыз, алдый ул!

Хөрмәтулла. Менә юләр, сезне алдаудан миңа ни файда?

Соколов. Файдасы шул — офицерда халуй булып ятуыңны

батырлык итеп күрсәтергә уйлыйсың. Берүзе немецларны кырган имеш, әллә сиңа немец дуракмы?

Х ө р м ә т у л л а. Тукта әле, Соколов, нигә син миңа ачуланасың?

С о к о л о в. Җыен шкурниклар өчен, аягыңны калдырып кайт та, бер атнадан бирле старшина көтеп ят. Ачулану түгел, әллә ни дә эшләрсең.

Х ө р м ә т у л л а. Аның өчен мин гаеплеме? Синең кебек мин дә көтәм бит.

К а р ч ы к. Кара әле, улым, төрле җирләрдә йөргәнсең, күп кешеләрне дә күргәнсең. Шунда минем улымны очратмадыңмы?

Х ө р м ә т у л л а. Әй, әби, фронт бит ул Яуширмә базары түгел, анда күрсәң дә бер-береңне танымыйсың, күз тона.

К а р ч ы к. Минем улым танырлык иде, кечкенә буйлы, камыт аяклы, маңгаенда тай типкән тояк эзе дә бар иде. Шуңар күрә үзен авылда «ярык Габдулла» дип йөртәләр иде.

Х ө р м ә т у л л а. Юк, әби, мин андый ярык Габдуллаларны күрмәдем. Синең улың ак билетлы булгандыр, безнең Румын фронтында бар да кадровый солдатлар иде.

Бер кулсыз Х ә й б у л керә.

Х ә й б у л. Кара, кара, тагын монда кереп тулганнар.

С о к о л о в. Анда ягылмаган коридорың ашалмас әле.

Х ә й б у л. Закон тәртип булганны ярата.

С о к о л о в. Син бигрәк инде, Хәйбул, начальникларга яраргa тырышасың, ахры.

Х ә й б у л. «Служба не дружба» диләр бит, солдат кеше, үзең беләсең. Бүген безгә земский начальник килә. Шуның өчен чиста тотарга куштылар.

Х ө р м ә т у л л а. Бу старшина нигә килми соң?

Х ә й б у л. Әйтә алмыйм.

Х ө р м ә т у л л а. Ә писаре кайда, өендә ятамы?

Х ә й б у л. Базарда, кибетләрне яптырып йөри. Бөтен җиргә бит, сугышка каршы өндәп язылган кәгазьләр ябыштырганнар.

Х ө р м ә т у л л а. Алай... Ул демократ дигән кешеләр монда да килгәннәрмени? Фронтта да алар бик күп иде.

Х ә й б у л. Барыгыз, түрәләр килгәнче кәмит карагыз, Камай кәмитчеләре балаган коралар.

Х ө р м ә т у л л а. Кайда алар, чиркәү янындамы?

Х ә й б у л. Түгел, күршедә генә, Архиповлар лапасында. Аю белән маймыллары да бар икән.

Еракта шылдырлы гармунда уйнап, клоунның халык җыйганы ишетелә.

Х ә й б у л. Әнә башладылар!

Х ө р м ә т у л л а. Әйдәгез әле.

Хәйбулдан башкалар бар да китәләр. Хәйбул, як-ягына каранып, кесәсеннән кәгазь чыгара да патша портреты астына ябыштырып куя. Җырлый-җырлый идән себерергә керешә. Л а ш м а н о в керә.

Л а ш м а н о в. Посыльный! Бу нинди тәмәке төтене?

Х ә й б у л. Мин каталажка мичен яккан арада кереп тарткannар, көчкә куып чыгардым.

Л а ш м а н о в. Бар, син миңа судья Пантелей Пантелеевичны чакырып кил.

Хәйбул китә. Арыган кыяфәттә әкрен генә атлап К а с ы й м х а н керә.

Л а ш м а н о в. Касыймхан Шәүлиханович, сез авылданмы?

К а с ы й м х а н. Юк, хатынымны урлап качкан Биктимер малае артыннан станциягә куа барган идем.

Л а ш м а н о в. Соң ничек, тоттыгызмы?

К а с ы й м х а н. Юк. Әллә берәр авылга кереп калдылар, әллә башка юл белән киттеләр...

Л а ш м а н о в. Кызганыч.

К а с ы й м х а н. Әйе, Илья Петрович, мондый хурлыкны күрермен дип уйламаган идем. Акчаңны талау, малыңны урлау бер хәл иде, ләкин өеңә кереп хатыныңны алып китү ир кешегә нинди зур гарьлек!..

Л а ш м а н о в. Хатыныгызны бик ярата идегезмени?

К а с ы й м х а н. Күрәсем дә килми иде.

Л а ш м а н о в. Шулай булгач, нигә кайгырырга?

К а с ы й м х а н. Мин-минлегем җирдә таптала!

Л а ш м а н о в. Сез бик арыгансыз, минем квартирама кереп ял итеп алыгыз.

К а с ы й м х а н. Зарар юк. Безнең әти бүген дә килмәдемени?

Л а ш м а н о в. Кичә, үзем барып алган идем, кайтып керергә дә өлгермәдек, сезнең авылдан бик начар хәбәр белән килделәр.

К а с ы й м х а н. Нинди хәбәр белән?

Л а ш м а н о в. Амбарларыгызны талаганнар.

К а с ы й м х а н. Кемнәр?

Л а ш м а н о в. Башта хатын-кызлар, соңыннан бөтен авыл катнашкан. Кичә, Шәүлихан Алимханович белән урядник, Самсоновлар мондагы стражникларны алып, шунда киткәннәр иде, әле кайтканнары юк.

К а с ы й м х а н. Юк, минем чыдар хәлем калмады. Авылга кайтам да берничәсен бәреп үтерәм!

Л а ш м а н о в. Касыймхан Шаулиханович, сез бүгенгә анда кайтмый торыгыз, чыннан да сез кызулык белән берәр нәрсә эшләп ташлавыгыз бар. Мин сезне җибәрмим.

К а с ы й м х а н. Башкача минем түзәрлегем калмады!.. *(Ильяны бәреп җибәрә дә чыгып китә.)*

Х ә й б у л керә.

Х ә й б у л. Пантелей Пантелеевичның хатыны балага авырган, бара алмыйм, ди.

Л а ш м а н о в. Ташкан икән бала табар чак.

Б а с а р ы й керә.

Мәрдәнев, син ничек монда?

Б а с а р ы й. Әхтәри абзыйны больниска китердем.

Л а ш м а н о в. Ни булган аңа?

Б а с а р ы й. Кичә канга батырганчы хатын-кызлар кыйнады.

Л а ш м а н о в. Менә ничек? Димәк, анда эшләр шулкадәрлегә барып җитте?

Б а с а р ы й. У... Нинди генә әле. Тотсалар, мине дә үтерәләр иде, ярый әле, качып котылдым.

Л а ш м а н о в. Ә соң старостаның хәле ничек?

Б а с а р ы й. Доктор әйтә: «Куркынычлы түгел, тышкы күгәрүләр, тырналулар гына», — ди.

Л а ш м а н о в. Алай гына булса, зарар юк.

Х ә й б у л. Авылда эшләр ничек соң?

Б а с а р ы й. Төн буенча тентүләр барды. Бүген гаепле кешеләрне кулга алу башланды. Синең хатынны да, малай, ябып куйдылар.

Х ә й б у л. Ни өчен?

Б а с а р ы й. Икмәк ташыган. Өйалдыннан җиде капчык арыш алдылар. Гәүдәгә бәләкәй генә булса да кырмыска кебек ташыган.

Х ә й б у л. Ә балалар кем белән калды?

Б а с а р ы й. Ансын мин белмим инде.

Л а ш м а н о в. Посыльный, син бар әле, земскийны карап тор, тау башында тройка атлар күренсә, кереп әйтерсең.

Хайбул китә.

Синең килүең яхшы булды. Бунт вакыйгасы белән земскийның

сезнең авылга барып чыгуы бар. Шуның өчен хәзер үк авылга кайтып кит, быелгы ясак-недоимка түләмәүчеләрнең әйберләрен җый.

Б а с а р ы й. Ай-һай, өлгереп булыр микән?

Л а ш м а н о в. Өлгерергә кирәк! Һичбер крестьян зарларына карамыйча, кычкыртып алыгыз! Мир болынын саткан акчаны үзләштерүегез турында берничә тапкыр жалоба белән килгәннәр иде, бу турыда да авыз ачып тормагыз, эшегезне җайлагыз.

Б а с а р ы й. Сез бик кызык кына, Илья Петрович, әйтерсең лә ул акчаны без үзебез генә ашап бетердек. Шәүлихан абзыйга, сезгә дә бит өлеш чыгардык.

Л а ш м а н о в. Ансы шулай... Ләкин бит авыл халкы сезнең өстән жалоба бирәчәк. Земскийга, бергәләп ашадык, дип әйтә алмассың.

Б а с а р ы й. Миңа гына авырлык килә башласа, әйтми дә булмас.

Л а ш м а н о в. Бер генә сүз ычкындырып кара!.. Әллә синең ул гынамы? Сазлык киптерү, күпер салдыруга җыйган акчаларны да тыгынып бетердең. Синең комсызлыгың алардан башка да җитәрлек, адрес язган өчен дә взятка алып ятасың. Кара аны, Басарика!.. Себердә дә сиңа урын тар булыр. Старшина кайтты, бар!

Басарый чыгып китә. Ш ә ү л и х а н кайтып керә.

Ш ә ү л и х а н. Илья Петрович, анда җыелган халыкка чыгып әйтегез, бүген бирәүне дә кабул итмим.

Л а ш м а н о в. Яхшы. *(Чыгып китә, бераздан әйләнеп керә.)*

Шул арада Шәүлихан өсләрен сала.

Ш ә ү л и х а н. Илья Петрович, өяздә нинди хәбәрләр бар?

Л а ш м а н о в. Бернинди дә. Кичәдән бирле почта да кайтканы юк.

Ш ә ү л и х а н. Телеграмма биреп карарга иде.

Л а ш м а н о в. Телеграф эшләми.

Ш ә ү л и х а н. Нишләп алай?

Л а ш м а н о в. Артамонов «линия бозык, төзәтеп ятабыз», ди.

Ш ә ү л и х а н. Бу нинди позор? Земскийга нәрсә дип җавап бирербез?

Л а ш м а н о в. Анысы әле бер хәл иде, Шәүлихан Алимханович, безнең монда башка куркыныч хәбәрләр дә бар.

Ш ә ү л и х а н. Нинди хәбәрләр?

Л а ш м а н о в. Менә укыгыз. *(Портфеленнән бөтәрләнгән кәгазьләр чыгарып бирә.)*

Ш ә ү л и х а н. Әлеге шул, аракы заводындагы прокламацияләр? Каян алдыгыз?

Л а ш м а н о в. Бүген төнлә, базар мәйданындагы бөтен баганаларга, кибет ишекләренә шушы кәгазьләрне ябыштырганнар.

Ш ә ү л и х а н. Бу кем эше булырга мөмкин, кем эше?

Л а ш м а н о в. Минемчә, Артамонов кулы уйный. Миңа бүген килеп әйттеләр: өченчекөн аның өендә аракы заводының мастерлары, сугыштан кайткан гарип солдатлар һәм солдаткалар булганнар. Ул аларга социал-демократларның «Правда» газетасын һәм ниндидер брошюралар укыган.

Ш ә ү л и х а н. Брошюралар укыган?

Л а ш м а н о в. Ә инде ул брошюраларны Биктимер карт шәһәрдән алып кайткан булырга тиеш.

Ш ә ү л и х а н. Әйе, әйе, сез хаклы. Алар бит элек-электән үк дуслар, әшнәләр. Хәзер үк Артамоновны чакыртыгыз. Мин аны эшеннән куам, төнлә белән кулга алдырам!

Л а ш м а н о в. Ләкин ул Никольскида иде, кайтты микән соң әле? Посыльный!

Х ә й б у л керә.

Хәзер үк Артамоновны чакырып кил!

Хәйбул китә.

Ш ә ү л и х а н. Илья Петрович, минем башым бик чатный...

Л а ш м а н о в. Аңлыйм. Туңып кайтырсыз дип, больницадан алдырган идем. Ләкин земский янында исе килмәсме?

Ш ә ү л и х а н. Чепуха, суган кабарбыз. *(Кесәсеннән суган чыгарып күрсәтә.)*

Л а ш м а н о в *(шешә биреп)*. Барыгыз, суд залына кереп эчегез. Миңа да калдырыгыз.

Шәүлихан бүлмәгә кереп китә. Х ә й б у л керә.

Х ә й б у л. Артамонов кайтып бара иде, хәзер керә. Аннан, Илья Петрович, сәүдәгәрләр килгәннәр, старшина янына керергә рөхсәт сорыйлар.

Л а ш м а н о в. Старшина беркемне дә кабул итә алмый. Ул бүген дәүләт эшләре белән мәшгуль.

Хәйбул китә. А р т а м о н о в керә.

А р т а м о н о в. Илья Петрович, мине нигә чакырттыгыз?

Л а ш м а н о в. Мин түгел, старшина әфәнде.

А р т а м о н о в. Кайда соң ул, бүлмәсендәме?

Л а ш м а н о в. Бераз гына сабыр итегез, ул хәзер чыгар. Я, Григорий Мироныч, газеталарда ниләр язалар?

А р т а м о н о в. Үзегез укымыйсызмы?

Л а ш м а н о в. Вакыт тигәне юк. Аннан, мин газета укуны яратмыйм да. Кулыма алу белән йокым килә башлый. Шуның өчен дә игълан һәм көндәлек вакыйгаларын гына караштырырга яратам.

А р т а м о н о в. Нинди гаҗәп кеше сез. Газета бит ул дөньяда булган политик ситуацияләрне яктыртып, кешеләрнең аңнарын үстерә.

Л а ш м а н о в. Нишлисең, кем нәрсәгә яшьтән өйрәнә!.. Берәүләр эш сөя, икенче берәүләр политика белән шөгыльләнә.

А р т а м о н о в. Сезгә дә зыян итмәс иде... Хәер, сез бит кызганыч бәндәләр...

Залдан Ш ә ү л и х а н чыга.

Ш ә ү л и х а н. Сез миңа шуны әйтегез: ни өчен почта кайтмый?

А р т а м о н о в. Үзәктән килә торган поездларның йөреше туктаган.

Ш ә ү л и х а н. Нигә телеграф эшләми?

А р т а м о н о в. Линия бозык, Янбакты авылы белән Никольский арасында ун телеграмма баганасын кисеп алганнар иде, ике көннән бирле шуны төзәттек. Хәзер телеграф эшли башлады.

Ш ә ү л и х а н. Нигә ул багана кисүче мерзавецларны җавапка тартмыйсыз?

А р т а м о н о в. Анысын сез эшләргә тиеш идегез. Мин Илья Петровичка шунда ук язып бирдем. Үзегез атна буена волостьта булмадыгыз. Савелий Назарыч солдаткалар артыннан чаба, авылдан авылга самогон эчеп йөри. Илья Петрович булса...

Ш ә ү л и х а н. Җитте! Артык мин сине биредә тота алмыйм, почтадагы бөтен эшләреңне ярдәмчең Курипановка тапшыр.

А р т а м о н о в. Шулай да, мин үз гаебемне беләсем килә!

Ш ә ү л и х а н. Ансы синең эш түгел, вон моннан!

Артамонов китә. Артта Хөрмәтулла тавышы ишетелә.

Ш ә ү л и х а н. Тагын шул карлыккан тавыш, нәрсә даулый ул?

Л а ш м а н о в. Сугыштан кайткан солдат, сезнең янга керергә сорый.

Атылып Х ө р м ә т у л л а керә.

Х ө р м ә т у л л а. Без анда өч елдан бирле газап чигәбез, тездән кан эчендә йөзәбез, ә сез монда ишек төпләрегезгә сакчылар куеп, безнең кебекләрне бусагадан да кертмисез.

Ш ә ү л и х а н. Туктагыз әле, сез кем соң?

Х ө р м ә т у л л а. Мин Георгиевский кавалер! *(Күкрәген ачып җибәрә.)* Его величество государь император дивизиясенең солдаты — Хөрмәтулла Сөнгатуллин булам!

Ш ә ү л и х а н. Нигә соң аны, башта ук шулай димәдегез?

Х ө р м ә т у л л а. Мин инсафлы кеше! Һәрбер очраган кешегә «Мин алай да мин болай» дип йөримме?

Ш ә ү л и х а н. Рәхим итегез, утырыгыз, нинди хезмәт күрсәтик?

Х ө р м ә т у л л а. Георгиевский кавалер булу сыйфатым белән өстәмә урман сорарга килдем.

Х ә й б у л керә.

Х ә й б у л. Земский начальник килде!

Ш ә ү л и х а н. Солдат әфәнде, хәзергә гафу итегез, бераздан керерсез.

Ашыгып чыгып китәләр. Бераздан К р и г е р, Ш ә ү л и х а н, Л а ш м а н о в керәләр.

Л а ш м а н о в. Рәхим итегез, ваше сиятельство.

К р и г е р. Господа!.. Үзегез бик яхшы беләсез, ватаныбызның намусын саклау өчен, рус халкының кан дошманы булган немецлар белән сугышабыз. Солдатлар ачыга, шәһәрләрдә азык кытлыгыннан — забастовкалар. Ә сез шул вакытта ясак, недоимкалар җыюда җансызлык күрсәтәсез.

Ш ә ү л и х а н. Ваше сиятельство...

К р и г е р. Читкәрәк китегез, сулышыгыздан самогон исе килә! Авылларыгызда төрле җир конфликтлары, урлап урман кисүләр — сезнең волостьта.

Ш ә ү л и х а н. Без бит бу турыда...

К р и г е р. Сабыр! Юлларыгыз төзәтелмәгән, пожар сарайларыгыз каралмаган, сугыш яралылары өчен җыелган акчаларның исәп-хисаплары җибәрелми. Сез миңа әйтегез, бу нинди җавапсызлык?!.

Ш ә ү л и х а н. Әгәр дә...

К р и г е р. Сабыр! Гафу итегез, Аюханов әфәнде, өязгә кайту

белән мин сезне бу вазифагыздан азат иттерү мәсьәләсен куячакмын!

Шәүлихан. Кичерегез, ваше сиятельство, ун көн эчендә һәммәсе дә эшләнгән булыр.

Кригер *(патша портреты астындагы кәгазьгә күзе төшеп).* Бу ни бу?

*(Шәүлихан белән Илья барып карыйлар да, бер сүз дә әйтә алмыйча калтыранып торалар.)* Мин сездән сорыйм, бу нинди алласызлык?.. Патша рәсеме астына кәгазь ябыштырасыз? *(Кубарып ала да укый).* Ә? Я Ходай... патшабызга каршы язылган!..

Лашманов. Кичерегез, ваше сиятельство, бүген безнең бөтен җиребезгә менә шушындый прокламацияләр ябыштырдылар.

Башы ак марля белән бәйләнгән Әхтәри йөгереп керә.

Әхтәри. Киләләр, киләләр!..

Кригер. Бу нинди кеше?

Лашманов. Таштугай авылының старостасы.

Кригер. Староста? Нишләп аның башы бәйләнгән?

Лашманов. Пожарда... Әй юк, буранда өшеткән.

Кригер. Эчәсең, мерзавец?!

Әхтәри. Юк, түрә әпәнде, гомеремдә авызыма да алганым юк.

Кригер. Алай булгач, башыңны нишләп өшеттең?

Әхтәри. Өшетмәдем, солдаткалар кыйнады...

Кригер. Ничек солдаткалар кыйнады? Нигә эндәшмисең?!

Лашманов. Гафу итегез, ваше сиятельство, сезгә әйтергә кыймый тора идек... Кичә Таштугай авылында бунт булды.

Шәүлихан. Әйе, ваше сиятельство, солдаткалар бунты. Менә, старостаны кыйнап, безнең икмәк амбарыбызны таладылар.

Тыштан Самсонов керә.

Самсонов. Әфәнделәр! Доложить итәргә рөхсәт итегез, бунтовщикларның һәммәсен дә тотып китердек. Хәзер сорау алабыз.

Лашманов. Ваше сиятельство, әйдәгез минем квартирама, чәй янына волостьта булган бөтен хәлләр турында ачык итеп сөйләрбез.

Кригер. Яхшы...

Әхтәри белән Самсоновтан башкалар чыгып китәләр.

С а м с о н о в. Староста!

Ә х т ә р и. Әү, гаспадин үрәдник.

С а м с о н о в. Безгә җепнең очын табарга кирәк, кемнән башлыйбыз?

Ә х т ә р и. Минемчә, Зәмзәмбанудан сорарга кирәк.

С а м с о н о в. Чакырыгыз.

Ә х т ә р и *(ишекне ачып кычкыра)*. Зәмзәмбану кодача, үрәдник абыең чакыра.

Курка-курка гына тышкы ишектән З ә м з ә м б а н у керә.

С а м с о н о в. Зәмзәмбану Биктимирова?

Ә х т ә р и. Әйе, әйе, ул була.

С а м с о н о в. Сөйлә, амбар таларга чыктыңмы?

З ә м з ә м б а н у. Гөнаһ шомлыгына каршы, чыккан идем шул.

С а м с о н о в. Иң әүвәле, кем инде сезне котыртты?

З ә м з ә м б а н у. Беркем дә котыртмады, үз-үзебездән котырдык.

С а м с о н о в. Шулай да, башлап кем дә булса берәү чыккандыр инде?

З ә м з ә м б а н у. Кем дип инде, барыбыз да берьюлы, уптым илаһи тоттык та чыктык.

С а м с о н о в. Амбар йозагын кем ватты?

З ә м з ә м б а н у. Һәммәбез дә.

С а м с о н о в. Ничек инде ул һәммәгез дә?

З ә м з ә м б а н у. Шулай, бөтен авыл белән җыйналып килдек тә әүвәл йозакка лом тыктык. Аннан инде лом башына озын бау бәйләп, үрә!.. кычкырып тарттык.

С а м с о н о в. Ә ни өчен алай лом башына бау бәйләдегез?

З ә м з ә м б а н у. Җавап бирергә булса һәммәбезгә дә бергә бирергә булсын, диделәр.

С а м с о н о в. Кемнәр шулай дип әйтте инде?

З ә м з ә м б а н у. Кемнәр дип, сүзне иясе белән йөртмиләр.

С а м с о н о в. Аһа, шулаймыни?.. *(Каты итеп өстәл сугып кычкыра.)* Мин сине казаматта черетермен. Староста! Олау әзерлә, биш минут срок эчендә дөресен сөйләмәсә, өяз төрмәсенә озатам! *(Чыгып китә.)*

З ә м з ә м б а н у. Әхтәри кода, чынлап сөйли микән бу, әллә юри куркыта гынамы?

Ә х т ә р и. Казамат белән генә калдырсалар бер хәл иде, кодача, хәзер бит сугыш вакыты, күп сорап тормаслар, Алла сакласын, Себергә, каторгага озатып куюлары да бар.

З ә м з ә м б а н у. Ходаем, шулай ук җәзасы каты булыр микәнни?

Ә х т ә р и. Сугышка озата торган казна икмәге бит, кодача, тәүбә-әстәгъфирулла, атып куюлары да бар. Кафернең законы үзе белән.

З ә м з ә м б а н у. Болай икәнен белсәм, ике аягымның берсен дә атламаган булыр идем, үз башыма гына азганмын икән.

Ә х т ә р и. Еландай телемне чыгарып әйттем, тыңламадыгыз, галанский әтәч кебек өскә очып кундыгыз. Менә хәзер җәзасын күрегез. Әле дөньядагы белән генә калмассыз, ахирәттә тагын да катырагын татырсыз.

З ә м з ә м б а н у. Әхтәри кода, мин бит сиңа тырнагым белән дә чиртмәдем.

Ә х т ә р и. Күрмәгәнне алдар хәлем юк, кодача, мине кыйнаганда син юк идең шикелле.

З ә м з ә м б а н у. Зинһар, кода, бу бәладән мине йол инде!

Ә х т ә р и. Һи... Анысы булмый инде, кодача, талаганны таламады дип, иманлы авызымны пычратыр хәлем юк.

З ә м з ә м б а н у. Кеше сүзенә, кеше коткысына гына ияреп йөрде диярсең.

Ә х т ә р и. Кеше коткысына иярдеңме, үзең башкаларны котырттыңмы — анысы миңа караңгы. Әмма талавың дөрес.

З ә м з ә м б а н у. Дөрес, таладым, мин аны үзем дә таныйм. Сер итеп кенә әйтим сиңа, кода, билләһи менә Гайнавал сүзенә генә иярдем.

Ә х т ә р и. Нигә соң урәдниккә шулай димәдең? Ничек булганын сөйләп бирсәң, бәлкем, үзеңне коткарып та куярлар.

З ә м з ә м б а н у. Коткарырлармы?

Ә х т ә р и. Алдан вәгъдә бирә алмыйм, ни булганын, ни белгәнең яшермичә сөйләп бирсәң, түрәләрдән сорап карармын.

З ә м з ә м б а н у. Сөйлим, кода, барысын да сөйлим, тик мине коткарсыннар гына.

С а м с о н о в керә.

С а м с о н о в. Я, староста, олавың булдымы?

Ә х т ә р и. Урәдник әпәнде, Зәмзәмбану кодача, кеше коткысына гына иярдем, ди.

С а м с о н о в. Сөйләп бирсен, ничек иярде икән.

З ә м з ә м б а н у. Баштан ук сөйлим микән, әллә амбар талаганнанмы?

С а м с о н о в. Билгеле, баштан ук сөйлә.

З ә м з ә м б а н у. Кичә, иртә белән безгә Гайнавал кергән иде...

Ә х т ә р и. Иплап кенә, ашыкмый гына сөйлә, кодача.

С а м с о н о в. Аһа! Гайнавал синең янга кергән идеме?

З ә м з ә м б а н у. Нишләп минем янга булсын, әткәй янына. Мин мич башында йоклап ята идем, уянып китсәм, әткәй аңа каладагы хәлләр турында сөйли. Шуннан, мин аларны тиенче эт шикелле тыңлый башладым.

С а м с о н о в. Шуннан, шуннан, интересно.

З ә м з ә м б а н у. Шуннан, әткәй әйтә: каладагы эшчеләр күтәрелде, үз хакларын даулыйлар, без дә Касыймхан амбарын талыйк, ди.

С а м с о н о в. Кызык, бик кызык... Шуннан, тагын ни дигән була?

З ә м з ә м б а н у. Шуннан, яннарына әнкәй кергәч, Гайнавал чыгып китте. Бераздан тагын керде, тагын нидер сөйләштеләр. Көн буена алар шулай ыгы-зыгы килеп йөрделәр. Кичкә таба инде Гайнавал өйдән өйгә кереп, хатын-кызларны старостага барырга өндәп йөрде.

Ә х т ә р и. Миннән икмәк белән утын сорарга мы?

З ә м з ә м б а н у. Сиңа бару ул хәйлә генә иде. Чыны Касыймхан амбарларын таларга чыктык һәм шулай эшләдек тә.

С а м с о н о в. Ярый, бар, хәзергә чыгып тор.

З ә м з ә м б а н у. Әхтәри кода, вәгъдәң кая?

Ә х т ә р и. Син кайгырма, кодача, үзем җайлармын. Тик кара аны, монда сөйләгәнне беркемгә дә белдермә.

З ә м з ә м б а н у. Мин белдермәм, үзең нишләрсең икән?

Ә х т ә р и. Кабер инде, кабер, кодача. *(Озатып чыга.)*

С а м с о н о в. Димәк, Биктимер оештырган?

Ә х т ә р и. Ул, ул! Мин сезгә башта ук әйттем бит. Талау вакытында хатын-кызлар кайда булса, ул шунда йөрде.

С а м с о н о в. Хәзер Гайнавалыннан сорап карыйк, ни әйтер икән? Син үзең генә каласың, тарткалап кара. *(Чыгып китә.)*

Әхтәри ишеккә барып кычкыра.

Ә х т ә р и. Гайнавал килен, урәдник әпәнде чакыра.

Г а й н а в а л керә.

Г а й н а в а л. У... Кара мүкәй, син мондамыни?

Ә х т ә р и. Усал син, килен, өстемә атланып кыйнавың гына җитмәгән, каты телең белән дә рәнҗетәсең.

Г а й н а в а л. Сине кыйнау гына аз, күзләреңне төртеп тишәсе калган. Икенче кат җаныбызны борчымаган булыр идең.

Ә х т ә р и. Нигә инде миңа ачуланырга, нигә кешегә начарлык теләргә? Минем сиңа ни зыяным тигәне бар?

Г а й н а в а л. Ә бу нәрсә? Бөтен авылны ристан ясадың!..

Ә х т ә р и. Казна икмәген талавыгыз, сакал-мыекларымны йолкып кыйнавыгыз өчен, аркагыздан сыйпап, рәхмәт әйтерләр дип уйлаган идегезме? Хи-хи-хи...

С а м с о н о в керә.

С а м с о н о в. Ни өчен таладың?

Г а й н а в а л. Тамагым ачка.

С а м с о н о в. Тамагың ач булса, кеше амбарын таларга ярыймы?

Г а й н а в а л. Кешенеке түгел, үзебезнеке! Бар да бездән буш бәягә алынган.

С а м с о н о в. Андый зур җинаятьне эшләргә кем сезне өйрәтте?

Г а й н а в а л. Беркем дә өйрәтмәде. Ач хатыннар җыйналып бардык та йозагын ватып, таладык. Староста каршы төшкән иде, бик яхшылап үзен тотып кыйнадык. Шулай бит, Әхтәри абзый, кыйнадык бит?

Ә х т ә р и. Юк, Гайнавал килен, аңламадың, урәдник әпәнде, кем сезне...

Г а й н а в а л. Татарга тылмач кирәкми! Үрәдник үзе дә бик яхшы сукалый.

С а м с о н о в. Мин синнән соңгы тапкыр сорыйм: йозак ватарга, амбар таларга кем сезне өйрәтте?

Г а й н а в а л. Юкка төпченеп маташма. Менә мин амбар таладым. Иремне кайтармасагыз, балаларымны туйдырмасагыз, иртәгә дә, берсекөнгә дә талармын. Авылда бетсә, монда килеп, волостегызны талармын.

С а м с о н о в. Талый алмассың! Без сиңа закон табарбыз.

Г а й н а в а л. Бик исем китә инде... Закон, имеш! Үзләре монда җылы өйләрдә тыгынып яталар, безнең кебек ярлыларны сугышларга куып, ачтан тилмертәләр. Шул да закон була, имеш!

С а м с о н о в. Алыгыз!.. Биктимер Шамкаевны кертегез.

Гайнавалны алып китәләр. Биктимерне кертәләр. Икенче ишектән К р и г е р, Ш ә у л и х а н, И л ь я керә.

К р и г е р. Аһа... ул карт шушы кешеме?

С а м с о н о в. Шул, үзе, ваше сиятельство.

К р и г е р. Бу карт миңа таныш кеше. Ул минем имениемдә күп вакытлар балта остасы булып эшләгән иде. Ләкин ул вөҗданлы, туры кеше иде.

С а м с о н о в. Аның бер улы революционер, ваше сиятельство. Ватанга хыянәт итүдә гаепләнеп, каторгага сөрелде.

Ш ә ү л и х а н. Икенче бер башкисәре, кичә безнең өйгә кереп улымны камчы белән кыйнады, киленемне урлап качты.

К р и г е р. Аһа... менә ул ничек?.. Хатын-кызларны син оештырдыңмы?

Б и к т и м е р. Әйе, мин!..

Б а р ы с ы  д а. Син?..

К р и г е р. Шундый зур җинаятьне эшләргә кем сине мәҗбүр итте?

Б и к т и м е р. Сез!..

Б а р ы с ы  д а. Без?

Б и к т и м е р. Әйе, сез!! Җирсез-сусыз килеш, нужа белән карап үстергән балаларымны сугышка кудыгыз — түздем. Актык атымны, бердәнбер сыерымны алып, тормышымны җимердегез — түздем. Алма чәчәгедәй кызымны алдап, намусыннан көлделәр — аңа да түздем. Улларымның берсен каторга, икенчесен кара кабергә тыктылар, Мирвәли бәбкәм әйтмешли — телемне аркылы тешләп булса да, аңа да түздем. Ләкин авыл халкының еллар буенча түккән күз яшьләрен, ятим балаларның, карт-корыларның газап чигүләрен күреп чыдамадым, хатын-кызларны амбар йозагын ватып, андагы икмәкләрне халыкка өләшергә мин өйрәттем!!.

К р и г е р. Алып китегез!..

Биктимерне алып китәләр.

Ш ә ү л и х а н. Әфәнделәр! Бу этләргә нинди җәза бирәбез?

С а м с о н о в. Закон кагыйдәләрендә күрсәтелгән җәзаларның иң катысын кулланыйк.

Л а ш м а н о в. Өяздән хәбәр килгәнче, һәркайсына иллешәр камчы сугыйк.

К р и г е р. Юк, әфәнделәр! Мондый хәлләрнең бер сезнең волостьта гына булмавын, бөтен шәһәрләрдә, Россия туфрагының һәр җирендә шундый ук брожениеләр баруын мин сезгә сөйләгән идем. Таштугай авылының бу талау чыгышларына карата, изге монархыбызның законнары ачык булса да, ләкин шушындый буталчык көннәрдә аларны тулысы белән кулланырга ярамавын белдерәм. Хәзергә, котыртучы, башлап йөрүчеләрен кулга алырга да, калганнарын кайтарып җибәрегез.

Артта шау-шу, талаш-кычкырыш. Ә х т ә р и йөгереп керә.

Ә х т ә р и. Әпәнделәр, эшләр харап! Тышта стражникларны кыйныйлар!

Коралланган Биктимер, Хәйбул, Хөрмәтулла, Соколовларны ияртеп, Артамонов керә.

Артамонов. Әфәнделәр! Петроградта революция!

Башкалар. Революция?...

Артамонов. Өченчекөн, канечкеч патша Николай Икенче патшалыгыннан ваз кичкән. Россия белән идарә итәргә Вакытлы хөкүмәт төзелгән.

Лашманов. Вакытлы хөкүмәт?

Шәүлихан. Без моңар ышанмыйбыз.

Артамонов. Менә телеграмма, укыгыз.

Кригер *(укый)*. Әйе, әфәнделәр, революция...

Артамонов. Өяздән җибәрелгән вәкилләр килгәнче, без сезне кулга алабыз.

Кригер. Кулга аласыз?

Шәүлихан. Без сезгә буйсынмыйбыз.

Лашманов. Без ул Вакытлы хөкүмәтне танымыйбыз.

Артамонов. Революция исеменнән боерам: яныгызда булган коралларыгызны өстәлгә куегыз!

Самсонов. Мин сезнең үзегезне кулга алырга боерам. *(Китә башлый.)*

Артамонов. Мәшәкатьләнмәгез! Волостьтагы бөтен стражникларыгыз инде ябып куелган. Коралларыгызны дим, живо!..

Теләр-теләмәс кенә дошман вәкилләре коралларын өстәлгә куялар.

Артамонов. Инде хәзер әйдәгез, безнең белән.

Кригер. Кая?

Биктимер. Каталажкага!..

Алып китә башлыйлар, пенснеле кеше ияртеп Мирзахан керә.

Мирзахан. Боларны кая?

Артамонов. Кулга алдык, каталажкага ябабыз.

Мирзахан. Җибәрегез.

Артамонов. Ничек?

Мирзахан. Мин сезгә беркемне дә кулга алмаска боерам.

Артамонов. Сез кем буласыз?

Мирзахан. Без — өяз вакытлы комитетыннан җибәрелгән вәкилләр.

Артамонов. Таныклыгыгыз бармы?

Мирзахан. Рәхим итегез.

Кәгазь чыгарып бирә. Артамонов алып укый. Гайнавал, Зәмзәмбану һәм башка кулга алынган хатын-кызлар, гарип солдатлар кереп тулалар.

М и р з а х а н. Өяз вакытлы комитетының кушуы буенча, бүгеннән волость аппаратыгыз безнең кулга күчә!

Б и к т и м е р. Миронович, ничек инде алар кулына күчә? «Иске мунча, иске таш, һаман безгә алар баш» дигәндәй, күнәбезме бу эшкә?

А р т а м о н о в. Юк, Биктимер Шамкаевич, мин хәзер телеграфка барып өяз белән сөйләшәм. Аңарчы боларның берсен дә җибәрми торыгыз! *(Чыгып китә.)*

Кораллы крестьяннар дошман вәкилләрен сак астына алалар.

*Пәрдә.*

## ДАНЛЫ КӨННӘР

### ӨЧЕНЧЕ КИСӘК

*Драма дүрт пәрдәдә, тугыз күренештә*

Б у к и с ә к т ә к а т н а ш у ч ы л а р:

Б и к т и м е р.
Г ө л н и с а.
М и р в ә л и.
А й с ы л у.
Г ө л ч и р ә.
Ә к р а м.
М ө р ш и д ә.
Х ө р м ә т у л л а.
Н у р г а л и.
Н у р и я.
З ә м з ә м б а н у.
Г а й н а в а л.
Х ә й б у л.
А р т а м о н о в.
С о к о л о в.
Л а ш м а н о в.
Ә х т ә р и.
Ш ә ү л и х а н.
К а с ы й м х а н.
М и р з а х а н.
К р и г е р.
А н т о н и н а — Кригерның хатыны.
А к и м о в н а — аларда йорт эшләре караучы хатын.
М а р к С е м е н ы ч — Кригерның управляющие.
С а м с о н о в.
Б а с а р ы й.
Я с ә в и.
Г ы й л ь м а н.
Х о д а я р.

# БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәһәрдә Мирвәли квартирасы. Зур-зур тәрәзәләр. Биек-биек ишекләр. Артта киң коридор. Вакыт кичкә таба. Тәрәзәләр аша җәйге шәфәкъ батып, әкренләп караңгылана барганы күренә. Пәрдә ачылганда Г ө л ч и р ә авыз эченнән көйләп өй җыештырып йөри. Г ө л н и с а керә.

Г ө л н и с а. Кызым, кияү кайда эшли диден әле?

Г ө л ч и р ә. Редакциядә.

Г ө л н и с а. Ул нинди эш инде, берәр заводмы дим?

Г ө л ч и р ә. Түгел, әни, газета чыгара.

Г ө л н и с а. Үз башыннанмы?

Г ө л ч и р ә. Алар аны җыйнаулап язалар. Әкрам аларның редакторы, ягъни башлыклары.

Г ө л н и с а. Ярый инде, кызым, әйбәт кешегә туры килгәнсең, кияүне мин бик яраттым. Аннан соң, кызым, яз көне, укырга кердем дип язган идең. Олыгайгач нинди уку була инде ул?

Г ө л ч и р ә. Мин, әни, акушеркалар әзерләү курсында укыйм.

Г ө л н и с а. Аны бетергәч кем буласың инде?

Г ө л ч и р ә. Фельдшер.

Г ө л н и с а. Фельдшер? Чын фельдшермы?

Г ө л ч и р ә. Әйе, әни, чын фельдшер. Я, әни, авылда ниләр бар соң?

Г ө л н и с а. Артык берни дә юк, кызым. Җыен дигән сүзне — мәтәнгәгә, әфәндене гражданга алыштырдылар. Һәр көнне шул мәтәнгәне җыялар да оратор сөйлиләр.

Г ө л ч и р ә. Хи-хи-хи... Зәмзәмбану җиңги нишләп ята?

Г ө л н и с а. Нишләсен? Дөньяда кыланмаганы калмады инде... Хәзер кыстыбый белән сәүдә итә.

Г ө л ч и р ә. Нинди кыстыбый белән?

Г ө л н и с а. Өендә кыстыбый, шәнгәләр пешерә дә пристаньга илтеп сата. Үзебез күргәнебез юк, самогон белән дә кайнаша дип сөйлиләр.

Г ө л ч и р ә. Берәрсенә димләр идегез, ичмасам.

Г ө л н и с а. Аны кем алсын? Фәрештәдәй кызларга да хәзер кияү юк.

Г ө л ч и р ә. Әни, Мидхәт уянды, ишегалдындагы бакчага алып чык әле.

Г ө л н и с а. Ярый, кызым, ярый, алып чыгармын. *(Китә).*

М и р в ә л и кайтып керә.

М и р в ә л и. Әтиләр кайда, теге яктамы?

Г ө л ч и р ә. Әни Мидхәт белән бакчада. Әти вак-төяк әйберләр алам дип соручига киткән иде.

М и р в ә л и. Айсылу нишли?

Г ө л ч и р ә. Мөслимәләр җыелышыннан кайтканы юк әле.

Еракта тревогалы итеп кычкырткан завод гудогы ишетелә.

Г ө л ч и р ә. Абый, бу ни бу?

М и р в ә л и. Алафузов заводы забастовка башлады.

Г ө л ч и р ә. Алар да?

М и р в ә л и. Әйе, бусы дүртенче завод. Бөтен шәһәр эшчеләре Вакытлы хөкүмәткә каршы күтәрелә.

Гудок туктый. Урамда солдатлар җырлаганы ишетелә. М и р в ә л и белән Г ө л ч и р ә тәрәзәгә баралар.

С о л д а т л а р җ ы р ы.

Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам.
Күзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргәй.

Г ө л ч и р ә. Көйләре бик матур...

М и р в ә л и. Минемчә, сүзләре тагын да матуррак. Туып-үскән җирләрен сагыналар... Сугыштан туйганлыкларын белдерәләр... Ә татар буржуазиясе алардан аерым татар полклары төзеп, мөселман шулпасы, мөселман боткасы белән кызыктырып тотарга маташа.

Г ө л ч и р ә. Абый, бу безнең бәләкәй абый түгелме?

М и р в ә л и. Кая?

Г ө л ч и р ә. Әнә алдагы тимеркүк атта килә.

М и р в ә л и. Әйе, ул. Взводы белән уеннан кайтып килә, кыланчык, атын ничек уйната? Безне күрсеннәр дия торгандыр инде.

Г ө л ч и р ә *(тәрәзәдән сузылып).* Бәләкәй абый!

Н у р г а л и т а в ы ш ы. Нихәл, сеңелем, исәнме?

Г ө л ч и р ә. Бәләкәй абый, безгә этиләр килде!

Н у р г а л и. Кайчан?

Г ө л ч и р ә. Бүген иртән, кояш чыкканда. Безгә тиз киләсезме?

Н у р г а л и. Хәзер, сеңелем, взводымны илтеп куям да киләм. Вз-вод, рысь-ю ма-рш!

Юыртып киткән атларның аяк тавышлары ишетелә. А й с ы л у кайтып керә.

Г ө л ч и р ә. Әнә җиңги дә кайтты. *(Китә.)*

А й с ы л у. Мирвәли, мин сиңа бүген ничә тапкыр шалтыраттым, туры китерә алмадым, кайда идең?

М и р в ә л и. Елга аръягында митинглар уздырдым. Йә, сезнең мөслимәләр җыелышында ниләр булды соң?

А й с ы л у (*иронияле көлү белән).* Мөселман солдатларына иганә җыюны карадык. Милли шура съездына делегатлар сайладык.

М и р в ә л и *(көлеп).* Нинди абыстайлар уздылар?

А й с ы л у. Биш кеше. Шулар арасында мин дә бар.

М и р в ә л и. Тәбрик итәм, Айсылу, тәбрик итәм.

А й с ы л у. Күрсәң иде, Мирвәли, президиумда хезмәт иясе хатын-кызлардан берәү дә юк. Бар да юан-юан абыстайлар, энҗе калфаклы туташлар. Бүләк багарга баргандагы кебек, бөтен асыл киемнәрен, алтын-бриллиантларын тагып килгәннәр. Өстәл артында ата күркә шикелле кукраеп утыралар. Ләкин мин мөселман социалистлары исеменнән, татар байларында ялланып эшләүче читекче, кәләпүшче кызларның союзларын төзергә, эш сәгатьләрен, хезмәт хакларын билгеләргә дип чыгыш ясаган идем, бөтен залдагы халык ура кычкырып кул чапты. Соңыннан Мулланур абый килеп кулымны кысты.

М и р в ә л и. Ул миңа шалтыратты. «Синең хатының шундый итеп сөйләде, бөтен татар байларының тетмәсен тетте», ди. Рәхмәт, Айсылу, димәк, син дә үсәсең. Безнең губерна комитеты өч айлык сәяси курслар ача, сиңа шунда кереп укырга кирәк булыр.

А й с ы л у. Белмим шул... Мин әле кайтышлый, теге мәсьәлә буенча врачка кергән идем...

М и р в ә л и. Соң, нәрсә диде?

А й с ы л у. Әйтергә оялам...

М и р в ә л и. Йөгең бармы?

А й с ы л у. Өч айлык, ди...

М и р в ә л и. Рәхмәт, Айсылу... Димәк, ярты елдан безнең томырап торган улыбыз булыр?

А й с ы л у. Каян беләсең, бәлки, кыз туар...

М и р в ә л и. Юк, малай булсын, мин малайларны яратам.

Әйберләр күтәреп, Б и к т и м е р кайтып керә.

Б и к т и м е р. Килен дә кайткан икән.

А й с ы л у. Әйе, әти, кайттым. Үзең кайда идең?

Б и к т и м е р. Менә толчокка чыгып тимер-томырлар, эш кораллары алдым. Сезнең монда дөнья икән, безнең анда кадак та сатмыйлар.

М и р в ә л и *(диваннан урын күрсәтеп).* Әйдә, әти, моннан уз.

Биктимер Мирвәли янына утыра. Айсылу китә.

Иртә белән сораша алмадым, әти, авылда нинди яңалыклар бар?

Б и к т и м е р. Телгә алып сөйләрлек, улым, бернинди дә яңалыклар юк. Бер яңалык бар: ул да булса — җыеннан баш чыкмый. Я милли шурага, я хәрби шурага, я мөселман комитетларына иганә сорап теңкәгә тияләр. Ә җир дисәң? Һаман юк.

М и р в ә л и. Эш башында һаман да шул Шәүлихан малайларымы?

Б и к т и м е р. Башка кем булсын? Шулар инде, берсе волостной комитет рәисе. Икенчесе — өяздә продком вәкиле. Минем сезгә килүемнең төп сәбәбе дә, улым, шулар чутында. Шул мәлгуньнәрнең йөзләрен ачып булма микән дип Мироныч мине җибәргән иде, менә сиңа аның язган хаты да бар. *(Хат бирә. Мирвәли укый.)* Гомеребез буена аталарыннан җәфа күрүебез аз булды, күрәсең, инде хәзер болары безне талыйлар. Алпавыт Твардовскийның аракы заводында мең чиләкләп спирт сакланган икән. Революция булу белән моны сизеп алганнар да, башта үзләре өчен алып торганнар. Аннан инде өяздәге түрәләргә мичкәләп җибәрә башлаганнар. Өсләреннән тикшерүче булмагач, хәзер инде управляющий белән бергәләп каладагы шинкарлар аша сатып яталар. Мироныч берничә тапкыр өязгә дә язып карады, басып калдылар. Бөтен җирдә аларның дуслары, аларның кешеләре утыра. Аннан, алпавыт Кригерның паровой тегермәнендә, төнлә белән каравылчысын үтереп, илле капчык онын урлаганнар иде. Аны да Мироныч Шәүлихан малайлары компаниясенең эше, ди.

М и р в ә л и. Ярый, әти, Миронычның бу хаты турында мин иртәгә үк тиешле кешеләр белән сөйләшермен. Бу фактларны тикшерү өчен комиссия җибәрүне куярбыз.

Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Әти, абый, әйдәгез, чәй өлгерттек, эчеп алыйк.

Н у р г а л и белән Н у р и я керә.

Әнә бәләкәй абыйлар да килделәр.

Н у р г а л и *(җитез адымнар белән килеп Биктимерне кочаклый).* Исәнме, әти!..

Б и к т и м е р. Бик әйбәт, улым.

Н у р и я. Исән генә килдегезме, әткәй?

Б и к т и м е р. Сезнең хәер-догада, килен.

Н у р г а л и. Әни кая соң?

Г ө л ч и р ә. Теге якта. Әйдәгез, анда узыйк.

Гөлчирәдән башкалар сөйләшә-сөйләшә бүлмәгә узалар. Ә к р а м кайтып керә.

Әкрам, нигә бик озак?

Ә к р а м. Шәһәр мәгариф бүлегенең утырышында идем. Бабайлар өйдәме?

Г ө л ч и р ә. Барысы да өйдә. Мирвәли абый да кайтты. Бәләкәй абыйлар да килделәр. Чәй өлгерттек. Әйдә, ашап-эчеп ал.

Ә к р а м. Бар, син кунакларны сыйлый тор. Мин бер җиргә шалтыратып алам.

Гөлчирә китә.

Ә к р а м *(телефон трубкасын алып)*. «Кызыл Байрак» редакциясен бирегез. Бу кем? Галәви абыйммы? Телеграф хәбәрләре булдымы? Берни дә юк?.. Гаҗәп икән... Бераздан тагын белешегез. Минем баш мәкаләм ничек, җыелып беттеме? Яхшы, укып чык әле. *(Тыңлый.)* Шулай, шулай... Сабыр, болай дип үзгәртегез. «Өченче, дүртенче июльләрдә, Петроград шәһәрендә, Вакытлы хөкүмәткә каршы башланган халык хәрәкәтеннән безнең шәһәр эшчеләре дә калышмыйлар», яздыңмы? Ахырына менә болай дип өстәп куй: «Эшче иптәшләр! Бернинди дә килешүгә бармаска, капиталист хуҗалар белән башланган көрәшне ахырына кадәр дәвам иттерергә». Булдымы? Аннан соң теге «Иделдә сәяхәт» дигән очеркны төшереп калдырыгыз. Нигә дисеңме? Илдә шушындый җитди көрәш барганда табигать матурлыклары белән төчеләнүнең кирәге юк. Аның урынына Тымытык мулласы — провокатор Шаһимурат Гаделев турындагы материалны бирегез. Хәзергә хуш.

Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Син нигәдер бүген күңелсез. Әллә инде шәһәрдәге вакыйгалар...

Ә к р а м. Юк, аннан түгел. Бездә болай барысы да бик әйбәт бара. Иртәгә демонстрация булырга тиеш. Тик менә Петроградтан бернинди дә хәбәр бирмиләр. Димәк, анда ни дә булса бар... Әйдә. *(Китә башлыйлар. Тәрәзәдән күреп.)* Болар кемнәр тагын безгә килеп туктады?

Г ө л ч и р ә. Мөршидә апа белән Хөрмәтулла җизниләр бугай. Әйе, әйе, алар. *(Ишеккә барып кычкыра.)* Мирвәли абый, Айсылу җиңги, Хөрмәтулла җизниләр килделәр!..

М и р в ә л и, Н у р г а л и, А й с ы л у, Н у р и я, Б и к т и м е р, Г ө л н и с а л а р чыга.

М и р в ә л и. Мөршидәләр килде, дисеңме?

Г ө л ч и р ә. Әйе, әнә извозчиктан төшәләр.

Биктимер белән Гөлнисадан башкалар тышка чыгып китәләр.

Г ө л н и с а. Нишләп йөриләр икән?

Б и к т и м е р. Белмим шул.

М ө р ш и д ә, Г ө л ч и р ә, А й с ы л у, Н у р и я л ә р керәләр. Мөршидә утырып дога кылганнан соң, авызын мелт-мелт итеп тора да кинәт кычкырып елап җибәрә.

А й с ы л у. Мөршидә, ни булды сиңа?

Г ө л ч и р ә. Апа, тукта әле, нигә елыйсың?

М ө р ш и д ә *(такмаклап)*. Кеше арасында рисвай галәм ясагач, каршыңда көлеп торырга кушар идеңме әллә, оятсыз, тиресбит!.. Апаң ашап бетерер дип уйлагансыңдыр шул. Курыкма, ашар өчен килмәдем. Әнә үзем белән ике капчык азык китердем. Әлхәмделиллаһи шөкер, итем дә, маем да, балым да җитәрлек.

Г ө л ч и р ә. Апа, син ни сөйлисең?

М ө р ш и д ә. Кеше арасына кергәч, апаң артык булгандыр шул. Мин бит сине үз баламнан да болайрак карап үстердем. Төннәр буе син елакның бишеге янында каравыллап чыга идем. Син бит өч яшеңә кадәр минем аркамнан төшмәдең, оятсыз!..

М и р в ә л и, Ә к р а м, Н у р г а л и, Х ө р м ә т у л л а л а р керә.

Х ө р м ә т у л л а. Әссәламәгәләйкүм!

Б и к т и м е р. Вәгаләйкемәссәлам.

Х ө р м ә т у л л а. Мөршидә, бу нинди балавыз сыгу тагын?

Г ө л ч и р ә. Гафу ит, апа, мин сине аңламыйм.

М ө р ш и д ә. Аңламассың шул. Аңласаң, бердәнбер апаңны санга сугар идең.

Х ө р м ә т у л л а. Кирәкми, Мөршидә, үпкәләп сөйләмә.

М ө р ш и д ә. Тик кенә тор, кысылма! *(Биктимер белән Гөлнисага.)* Боларын да әйтер идем инде... Безгә сиздерми генә, безгә белдерми генә чыгып сызганнар.

Г ө л н и с а. Кая сызганнар?

М ө р ш и д ә. Монда, туйга.

Г ө л н и с а. Нинди туйга?

М ө р ш и д ә. Менә, Гөлчирәләр туена.

Г ө л ч и р ә. Кем әйтә?

М ө р ш и д ә. Бөтен авыл гөж килеп сөйли. Өч көн буена өйдән чыкмадым. Суга да бармадым. Очраганы берсе: «Гөлчирәгез кияүгә чыккан икән, Биктимер абзыйлар туйга киткән икән. Сез кайчан барасыз», — дип аптыратып бетерделәр.

Б и к т и м е р. Ә... Менә ни өчен икән?! Бу турыда, кызым,

Гөлчирәгә түгел, миңа үпкәлә. Дөрес, авылдан без туйга барабыз дип киттек. Ләкин мин бөтенләй башка йомышлар белән килдем.

Айсылу. Кунаклар, әйдәгез, чәйгә рәхим итегез.

Нургали белән Биктимердән башкалар кереп китәләр.

Нургали. Пароходта бик тыгыз булмадымы, әти?

Биктимер. Юк, улым, алай кысан булмады, әниең белән балык мичкәләре өстенә менеп утырдык та рәхәтләнеп килдек. Кипяток та ерак түгел иде. Кайнаган саен төшәбез дә алабыз. Төннәрен бик рәхәт икән, нәкъ безнең янда гына машиналар әйләнә. Бутый-бутый пар казанына утын ягалар. Тик Казанга җитәрәк кенә тәгәрмәче бозылып тәүлеккә якын су өстендә утырдык.

Мирвәли керә.

Мирвәли. Шулай, диң, Нургали, авылга икмәк җыярга барам, диң.

Нургали. Әйе, абый, бик күп гаскәри частьларны җибәрәләр.

Мирвәли. Димәк, фронттагы репрессияне тылда да кулланырга уйлыйлар.

Нургали. Ил ачлык алдында, фронт өчен икмәк кирәк бит.

Мирвәли. Безнең илдә андый ачлык булмаска тиеш. Крестьян, икмәге булмаудан түгел, Вакытлы хөкүмәткә ышанмаудан шәһәргә икмәк китерми. Март, апрель айларында алар фронт өчен дә, шәһәр өчен дә җитәрлек икмәк саттылар. Алар хәзер ниндидер яхшы вакытның киләчәген көтеп, шәһәргә икмәк кертмиләр. Чөнки без аларга берни дә бирә алмыйбыз. Мануфактура юк. Чәйшикәр юк, тоз, керосин юк. Тимер-томыр кебек товарларны оныттылар да инде. Көннән-көн чүпрәккә әйләнеп барган кәгазь акчага нигә алар икмәк сатсыннар?

Биктимер. Дөрес, улым, бездә хәзер әйбернең хакын акча белән түгел, иши белән бәяләп йөртәләр. Аннан без шуңар аптырыйбыз, авылга киләләр дә, «ирек», «хөррият» диләр. Җире булмагач, аның коры иреге белән нишлик? Безнең авылда күзгә чәчүгә кадәр түзәбез дә, бирмәсәләр — Кригер җирен бүлеп чәчәбез, диләр.

Мирвәли. Иң дөресе, әти, шул булыр.

Нургали. Дәүләт законының кушуыннан тыш, андый башбаштаклыкны эшләргә ярамый. Чөнки һәрбер башбаштаклык илне бәхетсезлеккә өстери. Хөрриятебезне куркыныч астына куя. Җир мәсьәләсен хәл кылу ул — учредительное собрание эше. Волостьларда хәзер җир биләүчеләр белән җирне эшләүчеләр арасындагы

чыккан конфликтларны чишәр өчен, «килештерү комитетлары» төзелә. Бу демократик оешмалар крестьян белән алпавыт арасындагы бик күп низагларны чишәчәк.

М и р в ә л и. Владимир Ильич әйткәнчә, — ике мең десятина җир биләүче алпавыт белән ике мең десятина җирне эшкәртүче крестьян семьялары арасында нинди килешү булырга мөмкин? Икенче төрле итеп әйткәндә, өч йөз хуҗалыклы бер авыл, ике мең десятина җир биләүче алпавыт ризалыгын көтеп торырга тиеш, имеш. Менә, без, большевиклар, революцион комитетлар каршында берләшеп, оешкан хәлдә крестьяннарны алпавыт җирләрен бүлеп чәчәргә чакырабыз. Шул чагында гына безнең икмәгебез дә, җиребез дә, ирегебез дә булачак.

Н у р г а л и. Аңа мин дә каршы түгел. Ләкин әле вакыт җитмәгән. Бүгеннән алпавыт җирләренә конфискация ясау — илдә тәртипсезлек тудыру булыр иде. Икенчедән, абый, син әйткәнчә эшләү — революция дошманнарының тегермәненә су кою булып чыгар иде.

М и р в ә л и. Син, энем, реакцион министр Шингарев приказындагы җырны җырлап, крестьяннарны авызлыкларга чакырасың.

Н у р г а л и. Минем өчен Шингарев та, башкасы да бер. Мин партиясез кеше. Мин Ватанның туры солдаты! Илдә тынычлык, тәртип булуын гына телим.

Б и к т и м е р. Әйдә әле, улым Нургали, минем сиңа үзеңә генә сөйли торган сүзем бар.

Кереп китәләр. Мирвәли телефонга барып трубканы ала.

М и р в ә л и. Крестовниковны бирегез. Завком белән тоташтырыгыз. Бу кем? Иманколовмы? Исәнме? Мирвәли Биктимиров сөйли. Менә нәрсә. Сезнең заводта иртәгә татар эшчеләренең аерым җыелышларын җыярга йөриләр икән. Белмисең? Өеңдә ни булганны күршеңнән сора, диләр бит. Гомумән, бөтен шәһәр күләмендә хезмәт хакын арттыру, эш сәгатен киметү кебек мөһим мәсьәләләр буенча капиталистлар белән көрәш бара, ә шул вакытта аерым татар эшчеләренең җыелышын уздырып, җомга көнне ял итү, дини бәйрәмнәрдә эшләмәү кебек пустяк мәсьәләләр белән шөгыльләнү — татар милләтчеләренең тегермәненә су кою булып чыга түгелме?.. Билгеләнгән җыелышны кичектерергә ярамый, алар аны уздырсыннар. Ләкин ул кара ниятне масса алдында җимерергә кирәк. Син шуны бел әле! Дөрес булса, миңа хәбәр итәрсең. Үзем барырмын. Ярый, хәзергә хуш!

Тирләрен сөртә-сөртә Х ө р м ә т у л л а чыга.

Х ө р м ә т у л л а *(кикереп).* Әлхәмделиллаһи шөкер, карын бик ачкан иде.

М и р в ә л и. Я, кияү, ни эшләр бетереп ятасыз?

Х ө р м ә т у л л а. Эшләр беткән, көлтә җыясы гына бар дигәндәй, хөррият булу белән мине волость кооперациясенең председателе итеп сайлаганнар иде. Яңа эш, зур эш, һәр авылда бүлекләр ачабыз. Әле бире килүем дә шул кооперациягә мулрак итеп товарлар алып булмасмы диюем иде. Синең монда белеш-танышларың күп инде, каенагай, миңа булышсаң икән.

М и р в ә л и. Ләкин бит, кияү, анда кайткан товарларыгызны дөрес бүлмисез икән.

Х ө р м ә т у л л а. Ифтира, каенагай, ифтира. Каенатай җиткергәндер инде.

М и р в ә л и. Юк, безнең «Кызыл Байрак» газетасына язганнар иде. Укымадыңмы?

Х ө р м ә т у л л а. Юк. Без ул гәҗитне алмыйбыз. «Җондыз» дигәнен — мөселман гәҗитен яздырабыз. Нәрсә дигәннәр иде?

М и р в ә л и *(газета биреп).* Менә әгъзалар өлешенә кайткан товарларны тирегә алыштырасыз икән дә Сарапул шәһәрендәге фабрикантларга илтеп сатасыз икән.

Х ө р м ә т у л л а. Коммерция! Сәүдә эшендә ансыз булмый ул.

М и р в ә л и. Ләкин бит товарлар җәмәгать милке, халык байлыгы. Сине сайлап куйган ул халыкка хыянәт итәргә ярамый. Хыянәт итәсең икән, ул инде җинаять санала. Җинаять итүчеләрне революцион закон белән хөкем итәләр. Без комиссия җибәрергә булдык.

Х ө р м ә т у л л а. Кем инде ул сез?

М и р в ә л и. Губерна Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советы!

М ө р ш и д ә керә.

М ө р ш и д ә. Абый, сине сорап бер кеше килгән.

М и р в ә л и. Шулаймы? *(Китә.)*

М ө р ш и д ә. Нишләп синең борының салынган?

Х ө р м ә т у л л а. Каенагай белән сүзгә килештек.

М ө р ш и д ә. Хөрриятләре турындадыр инде.

Х ө р м ә т у л л а. Түгел шул. Минем кооперация турында. Теге Сарапул купецларына илтеп саткан тиреләр турында гәҗитләренә язганнар.

М ө р ш и д ә. Нәрсә дип?

Х ө р м ә т у л л а. Янәсе, без анда халык хакын ашап ятабыз. Комиссия җибәрәбез, ди.

М ө р ш и д ә. Нигә, абый да кооперациядә эшлимени?

Х ө р м ә т у л л а. Юк та.

М ө р ш и д ә. Шулай булгач, синең кооперацияңдә аның ни катнашы бар?

Х ө р м ә т у л л а. Большевик булгач шулай була инде ул — бөтен җиргә борынын тыгарга тиеш. Син аның белән җайлап кына сөйләшеп кара әле. Ялгышлык белән генә, моннан соң алай эшләмәс диең. Комиссия җибәрсәләр, Алла сакласын, әллә ниләр ачылыр.

Телефон шалтырый. Хөрмәтулла трубканы ала.

Әйе, Биктимировлар фатиры. Ярый, хәзер әйтермен. *(Бүлмәгә кереп китә. Мирвәли белән чыга.)*

М и р в ә л и *(трубканы алып).* Мирвәли Биктимиров телефонда. Бу кайдан, губкомнан? Дмитрий Харитонович, исәнмесез? Ничек, хәзер үк килеп җитәргә? Яхшы, без хәзер чыгабыз. *(Тиз генә бүлмәгә кереп китә.)*

М ө р ш и д ә. Нәрсә ди ул, сиңа әйтәм?

Х ө р м ә т у л л а. Каядыр чакыралар. Зур эш белән булырга кирәк.

Карабин мылтыклар тотыш, киенә-киенә М и р в ә л и белән Ә к р а м һәм аларны озатучы Б и к т и м е р, Г ө л н и с а, Г ө л ч и р ә, А й с ы л у, Н у р г а л и, Н у р и я л ә р чыгалар.

Б и к т и м е р. Нәрсә бар соң, улым?

М и р в ә л и. Артык берни дә юк, әти.

Г ө л н и с а. Нигә соң мылтык белән барасыз?

М и р в ә л и. Кайгырма, әни, без хәзер кайтырбыз.

Ә к р а м. Гөлчирә, безне көтмәгез, кунакларны яхшылап сыйлагыз. Әйдә, Мирвәли, киттек.

Чыгыш китәләр. Айсылу белән Гөлчирә озата чыга. Монда калучылар бер-берләренә карашып торалар.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук — Мирвәли квартирасында, берничә сәгатьтән соң бара. Сөйләшә-сөйләшә Х ө р м ә т у л л а белән Н у р г а л и чыга.

Х ө р м ә т у л л а. Әйдә, каениш, сиңа дип алып килгән күчтәнәчем бар иде. *(Кесәсеннән аракы белән чашка чыгарып, салып бирә.)* Мә, кабып җибәр.

Н у р г а л и. Спирт түгелме?

Х ө р м ә т у л л а. Булса соң?

Н у р г а л и. Каян алдың, дим?

Х ө р м ә т у л л а *(көйләп)*. Сорама кайдан алганны, эчеп җибәр салганны. *(Эчәләр.)* Каенагай белән баҗай озаклады мин әйтәм.

Н у р г а л и. Әйе, сәгать бер тула, алар һаман юк.

Х ө р м ә т у л л а. Син белмәдеңме, аларны нигә чакырдылар икән?

Н у р г а л и. Үзләренең партия эшләре буенча булса кирәк.

Х ө р м ә т у л л а. Баҗай да большевикмыни?

Н у р г а л и. Ниндие генә әле!..

Х ө р м ә т у л л а. Син дә берәр партиягә керергә уйламыйсыңмы?

Н у р г а л и. Юк, җизни, мин беркайчан да бернинди дә партиягә кермәм, ахры.

Х ө р м ә т у л л а. Нишләп алай?

Н у р г а л и. Партиягә керү — үз-үзеңә зур җаваплылык алу дигән сүз.

Х ө р м ә т у л л а. Анысы шулай да, кермичә дә булмый бит. Менә мине әле ансына, әле монсына кыстыйлар. Кайсына керергә дә аптыраган.

Н у р г а л и. Мин синең урынында булсам, тотар идем дә социалист-революционерлар партиясенә керер идем.

Х ө р м ә т у л л а. Юк, мин аларны яратмыйм. Артык төче телләр.

Н у р г а л и. Ул чагында большевикларга язып, аларның җир программалары бик киң.

Х ө р м ә т у л л а. Алар динне, Алланы танымыйлар, мин үзем ни өчендер октябристларны якын күрәм.

Н у р г а л и. Кит аннан, ул бит алпавыт-фабрикантлар партиясе.

Х ө р м ә т у л л а. Эш аларның алпавыт-фабрикант булуларында түгел, каеним. Күңелгә, йөрәккә якын торуларында. Әйдә тот әле. *(Эчәләр.)* Их, каеним, син менә безгә якын шул. Синең турыңда тутаң белән дә еш кына сөйләп алабыз. Бөтен туганнар арасында нигәдер синең сөягең сөйкемле, сүзләрең дә ягымлы. Мин аның нигә икәнен дә белмим, әмма син якын.

Н у р г а л и. Туган туганга якын була инде ул, җизни.

Х ө р м ә т у л л а. Юк шул, каеним, барысы да түгел. Мирвәли каенагай да туган, ләкин һәрбер сүзе керпе кебек чәнечкеле. Аның белән бит, менә синең белән утырган кебек утырып та, сөйләшеп тә булмый, хикмәти хода, аның белән сөйләргә керештемме сүз табалмыйм. Хәтта белгәнемне дә онытам. Ә менә синең белән бөтенләй башкача, сине күрүгә шатлыгым эчемә сыймый.

Бүген дә үзе белән сөйләшергә дип, сүз башлаган идем, күңелне кайтарды.

Н у р г а л и. Нәрсә турында?

Х ө р м ә т у л л а. Булды инде...

Н у р г а л и. Шулай да?

Х ө р м ә т у л л а. Кооперациядә товарлар юк, табыш бирергә булыш әле дигән идем, нигә әйткәнемә үкендем. Ярый, калдырыйк. Миндә, каениш, үтемле товарлар бар. Шуларны берәр җиргә тумырыш булмасмы?

Н у р г а л и. Нәрсә ул, җизни, чәй-шикәрме әллә?

Х ө р м ә т у л л а. Түгел. Икмәк.

Н у р г а л и. Икмәк? Ничә потлап?

Х ө р м ә т у л л а. Нинди потлап? Йөкләп, вагонлап, диң.

Н у р г а л и. Ул кадәре игенне каян кулга төшердең?

Х ө р м ә т у л л а. Твардовский управляющиеныкы. Авылда да аңа кытлык зур. Ләкин, ваклап сатмыйм, ди. Менә шуны берәр җиргә тондырасы иде. Сиңа да, миңа да эшләп алырга була.

Н у р г а л и. Белмим шул, җизни, андый эшкә минем бер дә сәләт юк.

Х ө р м ә т у л л а. Ул чагында берәр кеше табыш бир.

Н у р г а л и. Бездә бер сәүдәгәр малае каптенармус булып хезмәт итә, шуңа әйтеп карасак.

Х ө р м ә т у л л а. Бик әйбәт булыр. Менә бит ул, каениш, синең белән утырганда уртак теле дә, җае да табыла. Әйдә, яхшы аш калганчы, яман корсак ярылсын, кабып бетерик. *(Эчәләр.)*

М ө р ш и д ә белән Н у р и я керә.

М ө р ш и д ә. Нишләп монда утырасыз?

Х ө р м ә т у л л а. Каениш белән сүзебез бар иде.

М ө р ш и д ә. Әйдә, ятыйк инде.

Х ө р м ә т у л л а. Иртә бит әле.

М ө р ш и д ә. Нишләп иртә булсын? Әнә тышта таң ата. Әйдә, әйдә, тор!

Х ө р м ә т у л л а. Әй, шушы хатыннарны, гүрендә дә тынгылык бирмәсләр... (*Китәләр.)*

Н у р и я. Нургали, син тагын эчкәнсең?

Н у р г а л и. Бераз гына җизни сыйлады.

Н у р и я. Бераз гына микән? Беләсең, сиңа эчәргә ярамый.

Н у р г а л и. Кызык кына кеше син. Өйдә ярамый, кешедә дә ярамый, кайда гына ярый соң?

Н у р и я. Сиңа беркайда да, бер җирдә дә ярамый. Һәрбер җирдә җәнҗал белән очлыйсың.

Н у р г а л и. Калдыр әле, пожалуйста, син дә миңа акыл өйрәтмә!

Н у р и я. Файдалы акыл икән, нигә аннан качарга? Бигрәк тә бу турыда, син бит миңа беркайчан да эчмим дип сүз бирдең.

Н у р г а л и. Тагын әйтәм: миңа акыл өйрәтмә! Нәрсә эшләргә икәнен мин үзем дә бик яхшы беләм!.. *(Китә.)*

Нурия нәүмиз булып кала. Г ө л н и с а керә.

Г ө л н и с а. Килен, нишләп берүзең генә?

Н у р и я. Нигәдер, әнкәй, кәефем юк...

Г ө л н и с а. Төне бүген бик бөркү, шуңадыр. Минем дә башым авырта башлады.

Н у р и я. Дөресен әйткәндә, әнкәй, Нургали белән арабыз төзек түгел.

Г ө л н и с а. Нишләп алай? Бер-берегезне яратышып бардыгыз.

Б и к т и м е р керә.

Б и к т и м е р. Карчык, бу Мирвәлиләр кайтмады инде, безгә ятсак та ярый торгандыр.

Г ө л н и с а. Бире кил әле. Менә килен арабыз төзек түгел, ди.

Б и к т и м е р. Нишләп ул алай, килен?

Н у р и я. Барын да сөйләсәң күп инде ул, әткәй.

Б и к т и м е р. Барысын да сөйлә, килен, берсен дә калдырма.

Н у р и я. Соңгы вакытта холкы бик бозылды. Бер сүз әйтер хәлем юк, кабына да китә. Аңа әйтмичә дә мөмкин түгел. Чөнки еш кына безгә үзе белән бергә хезмәт иткән иптәшләре килә. Алар килдеме эчәргә, карта уйнарга керешәләр.

Б и к т и м е р. Андый бозык иптәшләрне кайдан тапкан ул?

Н у р и я. Болай алар бар да укыган кешеләр — кайсы офицер, кайсы милли шурада, кайсы хәрби шурада хезмәт итүче бай, мулла малайлары. Ләкин җыелдылармы, беренче сүзне аракыдан башлыйлар. Аннан инде, бәхәсләшергә, сүз көрәштерергә керешәләр.

Б и к т и м е р. Әйдә әле, анасы, үзе белән сөйләшик.

Китәләр. Тышта яктыра башлый. Г ө л ч и р ә белән А й с ы л у чыга. Гөлчирә тәрәзәләрне ачып җибәрә. Тышта — бакчада кошлар сайраганы ишетелә.

Г ө л ч и р ә. Нинди матур таң ата...

А й с ы л у. Урамда үлем тынлыгы... Бер генә җан иясе дә күренми...

Г ө л ч и р ә. Шулай да алар нигә кайтмыйлар икән?

А й с ы л у. Белмим, Гөлчирә, белмим... Үзем дә шул турыда борчылам...

Г ө л ч и р ә. Әллә барып кайтыйкмы? Нәрсәгә чакыруларын белер идек.

А й с ы л у. Абыең миңа, Петроградта зур вакыйгалар баруын сөйләгән иде, мөгаен, шул турыдадыр.

Г ө л ч и р ә. Чү, аяк тавышы!.. Кемдер болай таба килә...

А й с ы л у. Бу бер генә кеше... Ләкин Мирвәли йөрүе... Әйе, ул! Әнә капкадан керде...

Г ө л ч и р ә. Әкрам кайда калды икән?...

М и р в ә л и керә.

Абый, Әкрам нигә кайтмады?

М и р в ә л и. Аны дежурда калдырдылар.

Г ө л ч и р ә. Нинди дежурда?

М и р в ә л и. Саклык өчен, илле кешене Губком бинасын сакларга калдырдылар.

А й с ы л у. Нәрсә бар соң, Мирвәли?

Б и к т и м е р, Г ө л н и с а, Н у р г а л и, Н у р и я, Х ө р м ә т у л л а, М ө р ш и д ә керә.

Б и к т и м е р. Нигә чакырганнар соң, улым?

М и р в ә л и. Петроградта, әткәй, кешелек тарихында күренмәгән кабахәтлек эшләнгән. Владимир Ильич Ленинны Ватанга хыянәт итүче дип игълан иткәннәр. Һәм аны кулга алырга, суд ясарга приказ биргәннәр.

Б и к т и м е р. Кара син аны, каһәрләрне! Кемнәр инде алар?

М и р в ә л и. Вакытлы хөкүмәтнең сатлык министрлары.

Б и к т и м е р. Ленин хәзер кулдамы?

М и р в ә л и. Хәзергә анысы билгеле түгел... Менә Нургали, синең социалист министрларың кая барып җиттеләр? Гомере буена эшче-крестьян интересы өчен көрәшеп, салкын Себерләрдә, чит илләрдә җәфа күргән кешебезне кулга алырга приказ биргәннәр... Вакытлы хөкүмәткә каршы күтәрелгән революция дулкынын басар өчен, коралсыз эшчеләрнең каннарын койдыралар. «Правда», «Солдат Правдасы» газеталарының редакцияләрен талаталар. Демонстрациягә катнашкан меңләгән кешеләрне кулга алалар.

Н у р г а л и. Анда минем ни катнашым бар?

М и р в ә л и. Син бит аларның туры солдаты.

Н у р г а л и. Абый, әйдә бу мәсьәләне калдырыйк. Чөнки ул бик зур мәсьәлә. Без аны монда чишә алмабыз.

М и р в ә л и. Шулай да син бу кабахәт фактка ничек карыйсың?

Н у р г а л и. Тукта әле, ни өчен син миңа мондый сорау бирәсең?

М и р в ә л и. Синең фикереңне беләсем килә.

Н у р г а л и. Минем фикерем сиңа бик билгеле — мин революция солдаты!

М и р в ә л и. Юк, мин сиңа, Вакытлы хөкүмәтнең бу кабахәт фактына ничек карыйсың, дим.

Б и к т и м е р. Улым, Нургали, нигә алай киреләнәсең? Абыең сорагач, җавап бир.

Н у р г а л и. Әти, катышма... Бу мәсьәләдә син берни дә аңламыйсың.

Б и к т и м е р. Ничек инде ул аңламыйм?

Н у р г а л и. Шулай, син сәясәтне белмисең.

М и р в ә л и. Син бик күп беләсең инде.

Н у р г а л и. Һәрхәлдә, синнән ким түгел.

М и р в ә л и. Үз корсагың турында. Ләкин халык интересын, Ватан интересын аңлауга килгәндә, буржуазия җырын җырлыйсың.

Н у р г а л и. Абый!.. Син минем авырткан җиремә кагылма! Мин Ватан өчен өч ел буе күкрәгемне куеп сугыштым.

М и р в ә л и. Тукта әле, син нинди Ватан турында сөйлисең?! Алпавытлар, капиталистлар Ватанын үз Ватаным димәкче буласыңмы? Синең белән минем Ватаным властьны үз кулыбызга — пролетариат кулына алгач кына булачак!

Н у р г а л и. Чикләнмәгән монархияне яклаучы, революция дошманы булган Казан губернаторы генерал Сандецкийның өенә кереп, кулга алучы солдатларның да берсе мин булдым!

М и р в ә л и *(ирония белән)*. Бик зур батырлык күрсәткәнсең икән!

Н у р г а л и. Кайчан инде халкыбыз ирек алып, илебезнең дошманы булган немецларны тар-мар итәргә торганда, син сугышка каршы чыгып, солых сорыйсың.

Б и к т и м е р. Улым, Нургали...

Н у р г а л и. Без анда, фронтта, егерме дүрт сәгать буена кан эчендә йөзеп йөргәндә, син монда сигез сәгатьлек эш вакыты даулыйсың. Безгә анда, тәүлегенә бер тапкыр ашарга туры килмәгәндә, син монда хезмәт хакын арттыруны таләп итәсең.

Б и к т и м е р. Улым, Нургали, минем сүземне дә тыңла әле...

Н у р г а л и. Эшчеләрне революциягә каршы котыртасың.
Б и к т и м е р. Җитәр, дим мин сиңа!..
Н у р г а л и. Крестьяннарны таларга өндисең.
Б и к т и м е р. Яхшылап әйткәнне белмәдең, менә сиңа, мә!!.

Кизәнеп Нургалинең яңагына суга, ул барып диванга ава. Тыңлап торучылар урыннарыннан сикереп торалар. Нургали иплән кенә диваннан кузгала.

Н у р г а л и. Әйдә, Нурия, болар безгә туганнар түгел!..
Н у р и я. Тукта, Нургали, син кая?
Н у р г а л и. Әйдә, минем белән!.. *(Чыгып китә.)*

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таштугай авылы урамы. Бер якта — Биктимер карт өе һәм каралтылары. Икенче якта — Гайнавал өе күренә. Вакыт кичкә таба, эңгер-меңгер чак. Пәрдә ачылганда артта җыр тавышы ишетелә. Г а й н а в а л өеннән чыгып җыр ишетелгән якка карап тора. Кочаклашып исерекләр керәләр.

Җ ы р. Окопларда яткан чакта,
Килер мылтык тавышы.
Бик озакка китте инде
Бу Германның сугышы. *(Китәләр.)*

Бәләкәй арба тартып, З ә м з ә м б а н у кайтып керә.

З ә м з ә м б а н у. Бу нинди исерекләр, күрше?
Г а й н а в а л. Тагын хәбәр килде бит.
З ә м з ә м б а н у. Нинди хәбәр?
Г а й н а в а л. Ак билет белән калучыларны яңадан наборга чакыралар.
З ә м з ә м б а н у. Кемнәр китә икән?
Г а й н а в а л. Әхтәринең ике малае, Ясәви. Безнең авылдан егермеләп кеше, ди.
З ә м з ә м б а н у. Бик әйбәт булган. Безнең ирләребез күптән инде башларын салдылар. Ә алар һаман монда корсакларын киереп йөриләр. Шәүлихан малайлары тагын каламы?
Г а й н а в а л. Алар җаен табалар, бу юлы да бармыйлар, ди. Син әле кайда идең?
З ә м з ә м б а н у. Пристаньга кыстыбый сатарга бардым.
Г а й н а в а л. Соң ничек, үттеме?
З ә м з ә м б а н у. Аллага шөкер, кырылып алдылар. Тик бер-

ничә ристаны гына пароход кычкырткач, акча бирми йөгерде. Әтиләр һаман юкмы әле?

Г а й н а в а л. Юк, күрше, бүген дә кайтмаулары булды инде.

З ә м з ә м б а н у. Су белән кайтырлармы әллә диш, мин дә Казан пароходыннан көткән идем, күренмәделәр.

Култык астына зур портфель кыстырып, түшенә баш кадәр кызыл бант куеп, милиция начальнигы формасында Б а с а р ы й керә.

Б а с а р ы й. Әйтергә кирәк, бу нинди митингә?

Г а й н а в а л. Бернинди дә мәтәнгә түгел, болай гына сөйләшеп торабыз.

Б а с а р ы й. Бу вакытта нинди сүз булырга мөмкин? Әйтергә кирәк, авылга революцион власть вәкилләре килгән, урамнарыгыз себерелмәгән. Ишегалларыгыз тәртипкә китерелмәгән. Ни өчен без революция ясадык, ни өчен канечкеч патшаны бәреп төшердек? «Җир» дисез, «мир» дисез, ә үзегез шуны да белмисез.

Г а й н а в а л. «Татар түрә булса, чабатасын түргә элә», диләр иде, дөрес икән.

Б а с а р ы й. Беренчедән, мин түрә түгел, гражданка Мөрсәлимова, икенчедән, Вакытлы хөкүмәт вәкиленә тел тидерүең өчен революцион закон исеменнән өч сум штраф салам. Илтеп түләрсең. *(Квитанция бирә.)*

Г а й н а в а л. Алла... Синең бер дә серкәң су күтәрми башлаган...

Б а с а р ы й. Сүз көрәштереп торуны мин революцион закон исеменнән тыям! Гражданка Зәмзәмбану Биктимирова! Нигә синең кисмәгеңдә суың юк?

З ә м з ә м б а н у. Көннәр бик эссе бит, Басарый... Кичә генә тутырып куйган идем, кипкәндер.

Б а с а р ы й. Кипкәнме, кипмәгәнме — анда минем эшем юк. Әйтергә кирәк, хәзергесе минутта кисмәгең сусыз тора. Пумалаңның мунчаласы юк!

З ә м з ә м б а н у. Бар иде, чәчрәп китим, бар иде, бозау чәйнәп бетергән.

Б а с а р ы й. Чәйнәгәнме, чәйнәмәгәнме — анда минем эшем юк. Революцион закон исеменнән биш сум штраф салам, илтеп түләрсең. *(Квитанция биреп китә.)*

З ә м з ә м б а н у. Ай-ай, ничек коры тота бу!

Г а й н а в а л. Әйдә, кылансыннар инде, муеннарын сындырырлар әле. Мироныч әйтә: зур шәһәрләрдә тагын буталышлар бара, ди.

З ә м з ә м б а н у. Мин бу кисмәккә су ташыйм әле, я тагын штраф дияр. *(Китә.)*

Тагын җыр тавышы ишетелә. К а с ы й м х а н керә.

К а с ы й м х а н. Әйттерәләрме, Гайнавал җиңги, ә?
Г а й н а в а л. Әйе, әйттерәләр, тик аракысын каян алалар?
К а с ы й м х а н. Каян дип, хәзер бит һәрбер авыл үзе кайната.
Г а й н а в а л. Шулай микән? Мин икенче төрлерәк ишеткән идем... *(Китә башлый.)*
К а с ы й м х а н. Тукта әле, минем сиңа йомышым бар.
Г а й н а в а л. Без дә кирәк булдыкмыни?
К а с ы й м х а н. Кем сезне кирәкми дигәне бар?
Г а й н а в а л. Ә соң теге вакытны, судка тарттырып йөрүең?
К а с ы й м х а н. Ярый инде, узган эшкә салават диләр түгелме? Мин ишеттем, син быел да уракка читкә китәсең икән?
Г а й н а в а л. Әйе, исәбем шулай.
К а с ы й м х а н. Әйдә, үземә кил. Тарантаска гына утырып йөрерсең.
Г а й н а в а л. Ничә пот бирәсең?
К а с ы й м х а н. Ничек, ничә пот?
Г а й н а в а л. Урган өчен десятина башына ничә пот иген бирәсең, дим.
К а с ы й м х а н. Нигә иген? Акчалата алырсың.
Г а й н а в а л. Юк, мин синең ул керенкаңа эшләмим. *(Биктимерләр ишегалдына кереп китә.)*

Ашыгып М и р з а х а н керә.

М и р з а х а н. Абый, син нишләп биредә?
К а с ы й м х а н. Күрәсең, иген өлгерә. Урырга кеше юк. Бөтен авылны йөреп чыктым, сүз куешкандай, барысы да иген белән түләүне сорыйлар. Менә революциягез кая китереп җиткерде!
М и р з а х а н. Ул кечкенә мәсьәлә, кеше юк икән, өмә җыеп та урдырырсың. Монда икенче бер мәсьәлә килеп туды әле.
К а с ы й м х а н. Нинди мәсьәлә?
М и р з а х а н. Безгә комиссия килә.
К а с ы й м х а н. Нинди комиссия?
М и р з а х а н. Аракы заводындагы чатаклыкларны тикшерергә губерна эшче-крестьян депутатлары советы кеше җибәрә.
К а с ы й м х а н. Каян ишеттең?
М и р з а х а н. Өяздән Ишниязов шалтыратты. Итәк-җиңнәрегезне тизрәк җыегыз, ди.
К а с ы й м х а н. Алай... Каян сизделәр икән?
М и р з а х а н. Авылда торып белмим диң, ә? Биктимер кайда?
К а с ы й м х а н. Шәһәргә, кызының туена киткән, диләр.
М и р з а х а н. Әйе, киткән кызының туена... Муенчак

әзерләргә, синең белән минем муеныма... Мирвәли анда безнең өстән язып биргән, ди.

К а с ы й м х а н. Әйттем мин сиңа, пычранмыйк, дидем. Ә син мичкә-мичкә төяп, өяз комитетындагы начальникларга җибәрдең.

М и р з а х а н. Мин җибәрсәм, гомуми интересыбыз өчен җибәрдем. Ә менә син... Управляющий белән бергәләп бөтен миргә сатып ятасыз. Әнә бүген дә ярты волость исергән. Я, нишлибез?

К а с ы й м х а н. Нишлисең... Хәзер анда егерме мичкәләп спирт җитешми.

М и р з а х а н. Егерме мичкәләп? Нишләп алай бик күп ул?

К а с ы й м х а н. Шулай, ашаган белми, тураган белә. Миндә бар да язылган.

М и р з а х а н. Ул чагында бердәнбер юл — погром ясатудан башка чара юк.

К а с ы й м х а н. Ләкин кемнән?

М и р з а х а н *(кулы белән исерекләр тавышы килгән якка күрсәтеп).* Әнә шул наборга китүчеләрдән. Без хәзер генә Басарый белән аракы заводыннан килдек. Эшнең ничек булуын управляющийга да сөйләдек. Ул каршы түгел. Син хәзер Әхтәри абзый малайларын күр. «Күрше авыллар аракы заводын таларга баралар икән» дип исерекләрнең колакларына салсыннар. Талау башлануга без моннан барырбыз да халыкны тынычландырырга тырышкан булырбыз. Алар, әлбәттә, безне тыңламаслар. Шуннан инде, краннарны ачып агызырбыз яки ут төртеп яндырырбыз.

К а с ы й м х а н. Баш, мин әйтәм, үзеңдә...

М и р з а х а н. Ярый, бар, эшеңдә бул.

Касыймхан китә. Икенче яктан Я с ә в и керә.

Я с ә в и. Мирзахан, мине нигә сорадың?

М и р з а х а н. Синең эшләр шәптән түгел, Ясәви.

Я с ә в и. Наборга чакыруны әйтәсеңме?

М и р з а х а н. Юк. Кригер тегермәнен талавыгызны ачалар.

Я с ә в и. Кемнәр?

М и р з а х а н. Артамонов белән Биктимерләр Мирвәлигә җиткергәннәр. Ул бу эшне губерна эшче-крестьян депутатлары советында күтәргән. Хәзер безгә комиссия килү куркынычы бар. Шуның өчен сиңа ул талауны Биктимернең үзенә аударырлык бер күчтәнәч әзерләргә кирәк.

Я с ә в и. Нинди күчтәнәч, аңламыйм.

М и р з а х а н. Әйдә, сөйләрмен. *(Китәләр.)*

Көянтә-чиләк күтәреп Зәмзәмбану суга китә. Биктимерләр өеннән Г а й н а в а л чыга. Котомка асып А р т а м о н о в керә.

А р т а м о н о в. Исәнме, Гайнавал түтәй?

Г а й н а в а л. Бик әйбәт, Мироныч. Кая болай?

А р т а м а н о в. Өязгә, каралырга барышым.

Г а й н а в а л. Каралырга? Урындагы кешеләрне алмыйлар иде түгелме?

А р т а м о н о в. Шулай иде дә, менә мине җибәрәләр.

Г а й н а в а л. Шәүлихан малайларының эшедер инде.

А р т а м о н о в. Башка кемнеке булсын? Билгеле, шуларныкы, үзләренчә, миңа яманлык теләүләредер инде, ләкин алар ялгышалар. Мин фронтта, солдат арасында күбрәк файда китерермен, дип уйлыйм. Тик менә волостьтагы организация генә зәгыйфьләнә. Җиде кеше китәбез. Нишлисең, чакыргач, бармыйча булмый. Биктимер Шамкаевичлар юкмы әле?

Г а й н а в а л. Юк шул, Мироныч, үзем дә шуңа кайгырам. Мин аларның өйләрендә калган идем, иртәгә уракка төшәләр. Ташлап китсәм, уты-күзе бар дигәндәй.

А р т а м о н о в. Миңа да ул бик кирәк иде. Менә нәрсә, Гайнавал түтәй, минем урынга волостьта карт учитель Степан Фадеич кала, йомышыгыз төшсә, аңа барыгыз. Аннан, Биктимер Шамкаевичка әйтерсең, кайту белән Степан Фадеичка барып, губернадагы хәлләрне сөйләсен.

Г а й н а в а л. Ярый, ярый, Мироныч, әйтермен. Тик нигә соң әле ашыгасыз, безнең авыллар иртәгә генә юлга чыгалар.

А р т а м о н о в. Минем өяз большевиклар комитетында эшләрем бар. Шуның өчен бер көн алдан барырга булдым. Ярый, Гайнавал түтәй, хуш, сау бул.

Г а й н а в а л. Исән йөреп кайт, Мироныч.

Китәләр. З ә м з ә м б а н у судан кайтып килә. Я с ә в и керә.

Я с ә в и. Зәмзәмбану җиңги, сиңа бер-ике пот арыш оны кирәкмиме?

З ә м з ә м б а н у. Артык онын бармыни?

Я с ә в и. Артык түгел дә, иртәгә калага наборга китәм, расходка бер тиен акчам юк.

З ә м з ә м б а н у. Кит аннан, нишләп синдә акча булмасын? Көне-төне искепулян булып йөрисең.

Я с ә в и. Товарга бәйләп куйган идем шул.

З ә м з ә м б а н у. Күпмедән?

Я с ә в и. Үз кеше белән килешербез.

Сөйләшә-сөйләшә Биктимерләр ишегалдына кереп китәләр. Ясту намазыннан кайтышлый Ә х т ә р и белән Г ы й л ь м а н мулла үтеп бара.

Ә х т ә р и. Шулай, хәзрәт, хәер-догагыздан ташламагыз, иртәнге намаздан, без калага чыгабыз.

Г ы й л ь м а н. Хәерле булсын, мулла Әхтәретдин. Синең улларың дөнья күрмәгән егетләр түгел, ншпалла, җаен табарлар әле.

Ә х т ә р и. Белмим шул, хәзрәт, заманалар үзгәреп китте бит. Фронттагы солдатларның соравы буенча чакыралар.

Г ы й л ь м а н. Кайгырмагыз, мулла Әхтәретдин, тәкъдирдә язылмаган булса, берни дә эшли алмаслар. Сугыш инде ул — пәйгамбәрләр заманыннан калган изге эш. Һәр ирнең башыннан уза торган дәүләт йоласы.

Ә х т ә р и. Син кызык кына, хәзрәт, мин сиңа зарымны сөйлим, ә син мине үгет-нәсихәт белән сыйлыйсың. Ярый ла синең үз улың шәһәрдә дин бозып ята, минекеләр дөрләп янган ут эченә баралар.

Г ы й л ь м а н. Тукта әле, мулла Әхтәретдин, нишләп минем улым дин бозсын?

Ә х т ә р и. Намаз догаларын кара халык телендә укырга кирәк дип, гәҗиткә язган.

Г ы й л ь м а н. Аңламагансыз, минем углым Ходаяр дингә ислах кертеп, исламиятне үз җиребездә ныгытырга тырыша.

Ә х т ә р и. Белмим тагы, шимбә базарында миңа Гатаулла мулла сөйләгән иде.

Г ы й л ь м а н. Алар кадимчелек колы, наданнар. Күрәсең, илебездә инкыйлаб булды, бөтен тәдбирләр халыкка якынлаштырылырга тиеш. Ярый, улларыңның котылып кайтуларын теләп истихара намазыннан соң дога кылырмын.

Китәләр. Биктимер ишегалдыннан Зәмзәмбану белән Ясәви чыга.

Я с ә в и. Тик моны, җиңги, минем хатын күрмәсен иде, беләсең, ул бик көнче хатын, теге вакытны синең белән шаярганны сизеп тә сафура бураннары куптарды бит, моны да белеп алса, Алла сакласын, чәбәйкә эт шикелле үзеңә ябышыр.

З ә м з ә м б а н у. Әйе, ул минем су юлымда чәчләремне йолкып бетергән иде. Тик капчык кемнән сорап торыйм соң? Күршеләргә керсәм, бар да йоклыйлар.

Я с ә в и. Биктимер абзыйларныкы юкмыни?

З ә м з ә м б а н у. Бар да, аларның келәтләре бикле бит.

Я с ә в и. Тукта әле, минем кесәдә ачкычлар бар бугай, бәлки, берәрсе ярый торгандыр.

З ә м з ә м б а н у. Чыннан да маташтырып кара әле, ача алмассыңмы? *(Келәт янына китәләр, ачкыч яратып йозакны ачалар.)*

З ә м з ә м б а н у. Кара, синең мондыйга да осталык бар икән?

Я с ә в и. Шәүлихан малайларында юкка гына өч ел дәверенный булыш тормадым. *(Келәткә кереп китәләр, капчык тотып чыгалар.)*

Я с ә в и. Булды бу. Онын бушаткач, менә бу песи йөри торган тишектән эчкә ташларсың.

З ә м з ә м б а н у. Ярый, Ясәви, тапкырлыгың өчен маладис! *(Китәләр.)*

Икенче ишектән Ш ә ү л и х а н белән С а м с о н о в керә.

Ш ә ү л и х а н. Патша бер кеше иде, шулай да ул Россия белән идарә итәргә өлгерде. Ә хәзер нәрсә? Һәр җирдә собрание дә митинга. Күркәләрне җил белән симерткән кебек, халыкны речь белән туйдырырга уйлыйлар.

С а м с о н о в. Алар менә миңа сөйләргә ирек бирсеннәр иде, сөйләр идем аларга речьне!..

Ш ә ү л и х а н. Ул хатын әнә шул эчтәге өйдә тора. Бар, син кер.

С а м с о н о в. Миңа сатар микән соң?

Ш ә ү л и х а н. Сатар. Мин һәрвакытта аңардан алам.

С а м с о н о в. Бәлки хәзер дә сезнең үзегезгә керергә кирәктер?

Ш ә ү л и х а н. Миңа ярамый, бирәчәгем бар. Кара аны, тәмен татып ал. Беркөнне миңа бер каторжаны су сатып җибәрде.

Самсонов Биктимерләр ишегалдына кереп китә дә кире әйләнеп чыга.

С а м с о н о в. Өйдә юк, ишегендә зур йозак.

Ш ә ү л и х а н. Күршеләренә кергәндер, бераз көтик.

Капка төбендәге скамьяга утыралар.

Россия менә нинди хәлгә калды бит, Савелий Назарич, самогончы хатыннарга ялынып йөр, имеш.

С а м с о н о в. Безгә, Шәүлихан Алимханович, немецлар белән сугышырга кирәк булмаган. Ул чагында илдә мондый кытлык та, революция дә булмый иде. Синең эшләр әле ничего, бер улың волость комитеты председателе, икенчесе өяздә продком вәкиле. Менә минем хәлем хәл. Әүвәлге урядник диш, беркая да алмыйлар. Читкә китәр идем, документ бирмиләр.

Ярты капчык он күтәреп З ә м з ә м б а н у кайтып керә.

Ш ә ү л и х а н. Киленчәк, без сине көтә идек.

З ә м з ә м б а н у. Тагын агач акчагамы?

Ш ә ү л и х а н. Юк, менә акчабыз учыбызда.

З ә м з ә м б а н у *(акчаларын алып)*. Әйдәгез.

Ш ә ү л и х а н. Бар, Савелий Назарич.

Зәмзәмбану белән Самсонов кереп китә. Урам яктан М и р з а х а н килеп чыга.

М и р з а х а н. Әти, син монда нишләп утырасың?

Ш ә ү л и х а н. Кичке һавада йөрергә чыктым да ял итәргә утырдым.

М и р з а х а н. Әни сине анда борчылып көтә. Бар, өйгә кайт.

Ш ә ү л и х а н. Кайтмыйм мин ул өегезгә. Абыең мине бүген паразит дип хурлады.

М и р з а х а н. Болай ярамый, әткәй, син безнең белән уртак тел табарга тиеш.

С а м с о н о в әйләнеп чыга.

С а м с о н о в *(Мирзаханны күрмичә)*. Шәүлихан Алимханович, ул синең бирәчәгеңне алып калды. Яртыны гына бирде.

М и р з а х а н. Нәрсә ул яртыны гына?

С а м с о н о в. Исәнмесез, Мирзахан Шәүлиханович.

М и р з а х а н. Кулыңда нәрсә ул?

С а м с о н о в. Юк, Мирзахан Шәүлиханович, берни дә түгел...

М и р з а х а н. Кая, шешәңне бир әле.

С а м с о н о в. Ул минеке түгел, менә, Шәүлихан Алимханович...

М и р з а х а н. Бир, диләр сиңа!.. *(Кулыннан тартып шешәсен ала, иснәп карый.)* Самогон?.. *(Бөкесен алып җиргә агыза да шешәсен читкә ыргыта.)*

Ш ә ү л и х а н. Сынок, син нишләдең?

М и р з а х а н *(Самсоновка)*. Моннан соң әти белән йөргәнеңне күрәсе булмыйм. Вон моннан!..

Самсонов китә.

Аның кебек кешеләр белән дус булырга сиңа, әти, ярамый. Бер улың волость комитетының председателе, икенчесе өяз продком вәкиле. Ә син самодержавие палачы — урядник белән эчеп йөрисең.

Ш ә ү л и х а н. Башка кем белән йөрергә соң? Сасы мужикларың беләнме? Һичбер вакытта! Хәлемнән килсә, мин аларның берсен дә калдырмыйча, кырып бетерер идем.

М и р з а х а н. Ул чагында безгә кем хезмәт итәр иде, дип уйлыйсың. Алай ярамый ул, әти. Әйдә, өйгә илтеп яткырыйм. *(Китәләр.)*

Капчык тотып З ә м з ә м б а н у чыга.

З ә м з ә м б а н у. Кара инде, караңгыда шәйләмичә, безнең ямаулы капчык урынына, өр-яңа капчыгын биреп җибәргән. Ятмаган булсалар, алыштырып кайтыйм әле. *(Китә. Бераз баргач, туктап кала.)* Һи... Нәрсәгә барып йөрим? Аларныкы безгә хәләлдер әле. *(Капчыкны келәт тишегеннән эчкә ыргыта.)*

Аргы урамнарда шау-шу күтәрелә. Сәхнә аша чиләк тоткан кешеләр йөгереп китәләр. Зәмзәмбану шуларның берсен туктата.

З ә м з ә м б а н у. Хәмидулла, кая болай йөгерәсез?

Х ә м и д у л л а. Күрше авыллар аракы заводын талыйлар! *(Китә.)*

Зәмзәмбану тиз генә ишегалдына кереп югала. Көянтә-чиләк күтәреп чыга. Гайнавал тәрәзәсенә барып кага.

З ә м з ә м б а н у. Тор, күрше, тор, мәхрүм каласың!

Г а й н а в а л *(тәрәзәдән башын сузып)*. Нәрсә бар, әллә пожармы?

З ә м з ә м б а н у. Әйдә, киттек!

Г а й н а в а л. Кая?

З ә м з ә м б а н у. Спирт алырга!!

Г а й н а в а л. Нинди спирт?

З ә м з ә м б а н у. Аракы заводын талыйлар. Бөтен авыл шунда йөгерә. Әйдә, киттек.

Г а й н а в а л. Бик, шуның белән генә пычранып йөрисем калган.

З ә м з ә м б а н у. Син теләсәң нишлә, мин киттем! *(Көянтәчиләкләрен кулына тотып, итәкләрен кыстырып китә.)*

М и р з а х а н, К а с ы й м х а н, Б а с а р ы й л а р йөгереп керәләр.

М и р з а х а н. Туктагыз, ашыкмагыз, талый төшсеннәр...

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Биктимер картның ишегалды. Ап-аяз җәйге көн. Пәрдә ачылганда сәхнәдә беркем дә юк. Бераздан көянтә-чиләк күтәреп бакча ягыннан
Г а й н а в а л кайтып керә.

Г а й н а в а л. Ай Алла, Биктимер абзыйлар кайта түгелме? Әйе, шулар шул *(Көянтә-чиләкләрен өйгә кертеп куя да ишегалдына чыга.)*

Аркаларына төеннәр асып, Б и к т и м е р белән Г ө л н и с а кайтып керә.

Г а й н а в а л. Әйдәгез, кунаклар, әйдәгез, бик озакладыгыз.

Г ө л н и с а. Озакладык шул, Гайниҗамал.

Г а й н а в а л. Исән генә йөреп кайттыгызмы?

Б и к т и м е р. Аллага шөкер, Гайнавал. Үзегез нихәл соң, имин генә тордыгызмы?

Г а й н а в а л. Бер көе генә. Мал-туарларыгыз, кош-кортларыгыз да исәннәр. Мирвәлиләр, Гөлчирәләр таза гына калдылармы?

Г ө л н и с а. Әлхәмделиллаһи шөкер, сораганнарга сәлам, диделәр.

Б и к т и м е р. Уракка да төшкәнсез икән.

Г а й н а в а л. Әйе, өч көннән бирле урабыз. Бүген күлем алдыннан, ямщик атында, Хөрмәтулла кияүләрегез үтеп киттеләр. Бер пароходта кайттык, озакламый авылда булырлар, дигәч, төштән соң уракка бармадым, өегезне җыештырып чыгардым.

Г ө л н и с а. Бик рәхмәт инде, Гайниҗамал, сиңа мәшәкать ясадык.

Б и к т и м е р. Авылда ниләр бар?

Г а й н а в а л. Ак билет белән калучылар наборга киткәннәр иде, әле кайтканнары юк.

Г ө л н и с а. Кемнәрне чакырдылар?

Г а й н а в а л. Шәүлихан малайларыннан башкалары берсе дә калмады. Аксак-туксагын да, сукыр-чулагын да төяп озаттылар.

Артта бер тавык әтәч булып кычкыра.

Г ө л н и с а. Нинди ямьсез тавыш ул?

Г а й н а в а л. Сөйләмә инде, Гөлнисәттәй, Зәмзәмбану киленегезнең чуар тавыгы әтәч булып кычкыра. Көш, каһәр суккан, көш!.. *(Җирдән әйбер алып ыргыта.)*

Г ө л н и с а. Нинди бәхетсезлек теләп кычкыра икән, тамагына таш кергере.

Б и к т и м е р. Әй, куйсана, күңеле көр аның, шуңар кычкыра ул.

Г ө л н и с а. Бер дә алай түгел, мин яшь чакта, җизниләрнең бер тавыгы шулай азган иде, яхшылыкка булмады, төнлә белән янгын чыгып, каккан казыклары да калмады. Зәмзәмбану киленгә әйтеп, бүген үк суйдырырга кирәк.

Г а й н а в а л. Үзе өйдә юк шул.

Г ө л н и с а. Кайда, урактамыни?

Г а й н а в а л. Моннан өч көн элек милиция алып киткән иде.

Б и к т и м е р. Ни өчен?

Г а й н а в а л. Наборга китүчеләр аракы заводын таладылар, шунда Зәмзәмбану киленегез дә катнашты.

Б и к т и м е р. Алай... Эшләр булган икән алайса?

Г а й н а в а л. Нинди генә әле... Бер-берсен таптау, авыл белән авыл сугышу дисеңме, берсе дә калмады. Өч кеше аракы чанына төшеп үлде.

Г ө л н и с а. Әнкәем лә...

Б и к т и м е р. Шуннан, Гайнавал, шуннан?

Г а й н а в а л. Шуннан, милицияләр ияртеп Мирзаханнар барганнар. Талаучыларны үгетләп туктатырга теләгәннәр, кая ул, колакларына да элмиләр икән. Шуннан инде, Мирзахан тоткан да үз кулы белән аракы чанына ут төрткән. Икенче көнне төшкә кадәр үкереп янды.

Г ө л н и с а. Менә анысы бик әйбәт булган. Кайчан карама, шунда барып эчәләр иде. Ярый, сез сөйләшә торыгыз, мин самовар куеп җибәрим. Гайниҗамалны кала күчтәнәче белән сыйларбыз. *(Өйгә кереп китә.)*

Б и к т и м е р. Кара әле, Гайнавал, син минем башка күсәк белән суккандай иттең бит. Шул заводны талап ятучы Шәүлихан малайларын тоттырырга дип мин калага бардым. Мирвәли белән кияүнең вакытын әрәм итеп, учреждениедән учреждениегә йөрдек, анда комиссия җибәрергә булып калдылар. Ә син, шул заводны хәзер юк, дисең.

Г а й н а в а л. Заводы бар аның, исән. Тик чаны гына юк.

Б и к т и м е р. Барыбер, чаны булмагач, аларның урлау-урламауларын каян белерләр? Оста эшләгәннәр, оста... Хәзер инде ак эт бәласе кара эткә, дигәндәй, башкаларга сылтый торганнардыр.

Г а й н а в а л. Билгеле, безнең авылдан гына утызлап кешене алып киттеләр.

Б и к т и м е р. Мироныч ничек ирек бирде соң?

Г а й н а в а л. Ул өйдә юк иде шул. Талау буласы көнне генә аны наборга озатканнар иде.

Б и к т и м е р. Димәк, алар моны алдан уйлап, план белән эшләгәннәр. Тагын нинди яңалыклар бар?

Г а й н а в а л. Авыл комитеты председателе Хәйдәр печәтен югалтты.

Б и к т и м е р. Нишләп?

Г а й н а в а л. Минзәлә базарында жуликлар кесәмнән акчам белән бергә алдылар, дип әйтә ди. Дөресе — тәтәйләрдә калдырган, диләр.

Б и к т и м е р. Печать кадәр печатьне дә саклый алмагач, ул кешедән күпме өмет итәсең инде.

Г а й н а в а л. Аңардан өмет юк инде ул, Биктимер абзый. Атнасына бер көн авылда булмый, Ясәвиләр белән итәк асты сәүдәсендә йөри. Без монда сине сайлыйбыз дип торабыз әле.

Б и к т и м е р. Мине, рәис итепме?

Г а й н а в а л. Әйе. Беркөнне җыенда Мирзахан алдында күтәргән идек. Сайлатасы килми. «Биктимер абзый бик әйбәт кеше, тик аның укымышы юк», дигән була.

Х ә й б у л керә.

Х ә й б у л. Исән кайттыңмы, Биктимер абзый?

Б и к т и м е р. Шөкер, энем Хәйбулла. Үзең нихәл соң?

Г а й н а в а л. Кемнәрне алдылар?

Х ә й б у л. Кемнәрне калдырдылар, диң, Гайнавал җиңги. Хәтта мескен Җәләйне дә алдылар.

Г а й н а в а л. Сыңар күзе беләнме?

Х ә й б у л. Әйе, бер күзе белән. Сукса тимер өзәрлек Әхтәри малайларын, Ясәви кебекләрне тагын кайтарып җибәрделәр.

Г а й н а в а л. Нинди генә авырулары бар икән шуларның? Барган саен тишекле бер тиен кебек әйләнәләр дә кайталар.

Х ә й б у л. Шайтаннары да юк. Көне-төне докторлар, комиссия членнары артыннан йөрделәр.

Б и к т и м е р. Алай булгач, Миронычны да алганнардыр инде.

Х ә й б у л. Аны өяз большевиклар комитеты бирмәде. Губерна аша эш йөртеп калдыртты.

Б и к т и м е р. Анысы әйбәт булган. Ул да китсә, муенга менеп атланырлар иде.

Х ә й б у л. Әле дә кимен куймыйлар. Ишеткәнсеңдер, аракы заводын нишләттеләр?

Б и к т и м е р. Әйе, Гайнавал сөйләде.

Г а й н а в а л. Әнә Мироныч та кайтып өлгерде.

А р т а м о н о в керә.

А р т а м о н о в. Исәнмесез, иптәшләр!

Б и к т и м е р. Әйдә, Мироныч, түрдән уз.

Г а й н а в а л. Котылдыңмы, Мироныч?

А р т а м о н о в. Алты айга калдырдылар. Я, Шамкаевич, Мирвәли, Айсылулар нишләп яталар?

Б и к т и м е р. Болай исән-саулар. Тик бик борчулы чакка очрадык. Мирвәли юньләп өйгә кайтып кермәде. Көне-төне заводта красный гвардия отрядлары оештырып йөрде. Туйганчы сөйләшә дә алмадык. Озатырга да пристаньга гына төште. Шунда сиңа менә бу хатны язып бирде. *(Хат бирә.)*

Г а й н а в а л. Биктимер абзый, Гөлчирәнең ире нинди кеше инде?

Б и к т и м е р. Укыган, булдыклы егет. Гәзит чыгару эшендә баш булып тора.

Х ә й б у л. Анысы да монысы, Биктимер абзый, бу бурсык балалары белән нишлибез инде?

Б и к т и м е р. Хәзер аларның койрыкларына басарлар. Озакламый комиссия килергә тиеш.

Х ә й б у л. Нинди комиссия?

Б и к т и м е р. Мирвәли белән кияү, Эшче-Солдат Депутатлары Советына барып, комиссия җибәрүне куйдылар.

Х ә й б у л *(хат укып торган Артамонов янына килеп).* Алай булса, әйләндереп салабыз икән үзләрен, Мироныч, ә?

А р т а м о н о в. Белмим шул, Хәйбул.

Х ә й б у л. Мирвәли абый комиссия билгеләткән, ди.

А р т а м о н о в. Әйе, билгеләткән. Ләкин бөтен эшебезне дә шул комиссия эшләп бирер әле дип көтәргә ярамый. Бу турыда өяз большевиклары комитетында минем докладымны тыңладылар. Шунда безнең волость крестьяннары арасында тиешле дәрәҗәдә оешканлык булмау аркасында, буржуа вәкилләренең башбаштаклык итүләре килеп чыккан дип таптылар. Бу турыда безгә Мирвәли дә шулай дип яза.

Г ө л н и с а *(башын тәрәзәдән сузып).* Карт, самоварым өстәлдә. Кунакларны чәйгә алып кер.

Б и к т и м е р. Әйдәгез, кунаклар, кала күчтәнәчләре белән чәй эчик.

Кереп китәләр. Урам яктан З ә м з ә м б а н у кайтып керә. Өйгә кереп китә. Бераздан Гөлниса белән әйләнеп чыгалар.

Г ө л н и с а. Ай Алла, килен, нигә өйгә кермисең, чит кешеләр түгел ич.

З ә м з ә м б а н у. Вакытым юк, әнкәй, мин хәзер китәм.

Г ө л н и с а. Кая тагын?

З ә м з ә м б а н у. Кригер утарына.

Г ө л н и с а. Анда инде нәрсәгә?

З ә м з ә м б а н у. Эшләргә җибәрәләр.

Г ө л н и с а. Тукта әле, килен, безгә сине милиция алып китте, дип сөйләгәннәр иде.

З ә м з ә м б а н у. Әйе, әнкәй, аракы заводын талауда гаепләп мине алып киткәннәр иде, волостьта өч тәүлек буена ач тотып, бүген суд ясадылар, бер ел алпавыт утарында эшләргә хөкем иттеләр. Башкаларга берни дә булмады, бер мине генә җәзаладылар, имансызлар... *(Елый.)*

Г ө л н и с а. Нишләп алай?

З ә м з ә м б а н у. Ничә әйтсәң дә шул, Шәүлихан малайлары, самогончы, бозык хатын ул, дип өстемнән тордылар.

Г ө л н и с а. Катнашмаган булсаң, ак сакаллы карт булыр идең

дә, килен, күрәсең, язмышың шулай булгандыр инде. Ярый, килен, бер караганда китүеңә кайгырма, эшләсәң тамагың тук, өстең бөтен булыр, дигәндәй, анда торучылар да күп бугай, бәлкем, шунда берәр ир дә табып куярсың.

З ә м з ә м б а н у. Ярый, әнкәй, мин китим инде, урамда илтә баручы милициям көтеп тора. Сезгә әйтеп чыгарга диеп кенә җибәргән иде. Әйберләремне келәткә кертеп куярсыз да, ишек, тәрәзәләремне кадакларсыз. Вакыт табалсам, бер араны кайтып алырмын. Тавык-чебешләремне үзең карарсың.

Г ө л н и с а. Тавык-чебешләре дигәннән, теге чуар тавыгың әтәч булып кычкыра икән. Ул ләгыйнь белән нишләргә инде?

З ә м з ә м б а н у. Бер атнадан бирле кычкырып, шул башыма җитте, ристан! Күкәй салмый ул. Әткәй тотсын да суйсын. Ярый, әнкәй, хушыгыз, төрле чагым булгандыр, гаеп итмәгез. Бигрәк тә әткәй миңа ачу тотмасын. Бичараны бик күп рәнҗеттем. Зинһар, бәхилләсен.

Г ө л н и с а. Бәхилләр, килен, бәхилләр, үзем җайлап әйтермен.

Зәмзәмбану китә. Өйдән А р т а м о н о в, Х ә й б у л, Г а й н а в а л, Б и к т и м е р чыгалар.

А р т а м о н о в. Шулай, Шамкаевич, әзерләнеп торыгыз. Берничә көннән синең кандидатураңны авыл комитетына куябыз. Ә сез, иптәшләр, бүгеннән сайлау хәзерлеген алып барыгыз. Тиешле кешеләр белән сөйләшә торыгыз.

Х ә й б у л. Безнең кешеләр әзер. Җыен булганны гына көтәләр.

А р т а м о н о в. Ярый, Гөлниса түтәй, сау булыгыз. Сыйхөрмәтегез өчен рәхмәт.

Г ө л н и с а. Нигә соң әле бик тиз китәсез?

А р т а м о н о в. Мин бит өяздән кайтышлый гына, өйдәгеләр көтә торгандыр.

Х ә й б у л. Рәхмәт, Гөлнисәттәй.

Г а й н а в а л. Хәзергә хуш, Гөлнисәттәй.

Китәләр.

Г ө л н и с а. Гриша сиңа нәрсә турында хәзерләнергә кушты?

Б и к т и м е р. Чәй янында утырмадың ич, ишетер идең.

Г ө л н и с а. Зәмзәмбану килен чакырып чыгарды.

Б и к т и м е р. Ул кайттымыни?

Г ө л н и с а. Кайтты да, китте дә.

Б и к т и м е р. Кая?

Г ө л н и с а. Аракы заводын талауда катнашуы өчен, бер елга алпавыт эшенә хөкем иткәннәр.

Б и к т и м е р. Ак эт бәласе кара эткә — менә шул инде ул.

Г ө л н и с а. Сөйлә инде, нәрсә булды соң?

Б и к т и м е р. Алар мине, карчык, авыл комитетына рәис итеп сайларга уйлыйлар.

Г ө л н и с а. Рәис итеп? Кит,кит, риза була күрмә, кеше белән яманатлы булып бетәрсең.

Б и к т и м е р. Бетсәм бетәрмен, әмма Шәүлихан малайларының башына җитәрмен!

Г ө л н и с а. Белмим шул. Үзеңнекенә җитеп куйсалар, нишләрсең?

Б и к т и м е р. Юк, хәзер ирек бирмәбез. Шәһәрдә күрдең бит, Мирвәлиләр ничек эшлиләр.

Г ө л н и с а. Алар эшчеләр, укыган кешеләр.

Б и к т и м е р. Теге вакытны, син минем ләвәрвирне кая яшергән идең?

Г ө л н и с а. Чормадагы туфракка күмгән идем.

Б и к т и м е р. Син аны хәзер миңа алып бир әле.

Г ө л н и с а. Аның белән нишләмәкче буласың?

Б и к т и м е р. Анда ятып тутыгып беткәндер. Эш югында майлап, чистартып куйыйм. Бар, төшереп бир әле.

Г ө л н и с а. Әй... Аның өчен генә менеп йөрер хәлем юк, морҗа ачканда алып төшәрмен әле. Тик син менә шуны әйт: ул авыл комитетына сайланып ни генә кырырсың икән?

Б и к т и м е р. Бик күп нәрсә эшләргә була! Беренчедән, бернигә карамыйча, алпавыт Кригерның кысыр басуын өләшеп чәчтерер идем. Аннан, Шәүлихан малайларының бөтен начарлыкларын ачар идем. Мәчет каршына ике катлы школа салдырып, өске катында кызлар, аскы катында ир балаларны русча укытыр идем. Аннан, Акташ чишмәсен җир астыннан улак белән китертеп, нәкъ авылның уртасына, каладагыча фонтан куйдырыр идем.

Понятойлар ияртеп, Б а с а р ы й керә.

Б а с а р ы й. Нихәл, Биктимер абзый, исәнме?

Б и к т и м е р. Бик әйбәт, энем Басарый.

Б а с а р ы й. Сез әле шәһәрдә идегез бугай?

Б и к т и м е р. Әйе, кунакта булып кайттык.

Б а с а р ы й. Мирвәли абыйлар нишләп яталар?

Б и к т и м е р. Бер көе генә. Сораганга сәлам, диделәр.

Б а с а р ы й. Вәгаләйкемәссәлам. Кичә газетада губерна Эшче-Крестьян Депутатлары Советы каршында сайланган ниндидер бер комиссия членнары арасында аның да исеме бар. Безнең авылдан да губерна шәһәрендә эшләрлек кеше чыкты бит дип шатландык. Менә нәрсә, Биктимер абзый: теге каһәр суккан алпавыт Кригер таланган тегермәне турында жалуба биргән икән. Шул уңай белән миңа бүген өяздән приказ килде. Авылдагы бөтен өйләрдә тентү

үткәрергә кушалар. Гаеп итмәссез инде, сезнең келәтегезгә дә кереп чыгарга туры килә.

Б и к т и м е р. Керегез, энем, керегез. Безнең анда тычкан ашарлык та азыгыбыз юк. Карчык, келәт ачкычы кайда икән?

Г ө л н и с а. Шкафта иде. *(Өйдән ачкыч алып чыга.)*

Б и к т и м е р. Мә, Басарый, үзең ачып карарсың.

Басарый ачкычны алып понятойлар белән келәткә кереп китә.

Г ө л н и с а. Әллә бездән шикләнә микән?

Б и к т и м е р. Шикләнмәсә дә, начальство бөтен авылны тентергә кушкач, нишләсен, тенти инде.

Капчык тотып келәттән Басарый һәм понятойлар чыгалар.

Б а с а р ы й. Биктимер абзый, нәрсә бу?

Б и к т и м е р. Нәрсә булсын, капчык.

Б а с а р ы й. Капчыгын капчык, каян килгән сезгә ул капчык.

Б и к т и м е р. Каян дип, кем инде аларны хәтерли. Алар минем күптәнге капчыклар.

Б а с а р ы й. Юк, бу өр-яңа капчык. Кригер клэймәсе дә басылган.

Б и к т и м е р. Кригер клэймәсе дә басылган?.. Бездә андый капчык булырга тиеш түгел.

Б а с а р ы й. Түгелдер дә бит, менә бар. Пүнәтәйләр алдында келәт идәнегездән алдым.

Б и к т и м е р. Карчык, син белмисеңме, каян килгән безгә ул капчык?

Г ө л н и с а. Белмим, атасы. Бездә мондый шикәр капчыгы булганы юк.

Б а с а р ы й. Я, Биктимер абзый, нишлибез?

Б и к т и м е р. Мин ни дип әйтергә дә белмим.

Б а с а р ы й. Өстеңнән протокол язарга туры килә.

Б и к т и м е р. Димәк, мин кеше үтереп, тегермән талаучы булып чыгам? Үз гомеремдә кешенең инәсенә дә тигәнем юк. Аны син дә, авыл халкы да белә.

Б а с а р ы й. Анысы шулай, ләкин менә бу капчык бурлыкны, караклыкны раслый түгелме?

Г ө л н и с а. Ярабби!.. Тагын ни күрәсебез бар икән? Ай!.. *(Баскан җирендә чайкалып тора да, кискән агач кебек җиргә ава.)*

Б и к т и м е р. Карчык, карчык, сиңа ни булды? *(Гөлниса янына килеп, торгызырга тели, ләкин ул инде хәрәкәтсез.)* Син нишләдең, син нишләдең, явыз, кеше үтердең ич, беләмсең?!. *(Басарыйга таба йодрыкларын төйнәп бара, ул югала. Биктимер яңадан

*Гөлниса янына килеп тезләнә, аның гәүдәсен алдына алып сала.)* Гөлниса, Гөлниса... Синсез мин хәзер нишләрмен?.. *(Башын Гөлнисаның күкрәгенә куя, йөрәк өзгеч тавыш белән үксеп елый. Торып баса, күзләрен бер ноктага юнәлтеп әкрен генә үз-үзенә сөйләнә.)* Әйе... Әйе... Мин синең үчеңне алырмын, алырмын, Гөлниса, тыныч бул!..

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Алгы планда ишеге белән тамашачыларга карап торган иске каравыл өе. Аның белән янәшә янгын сүндерү машиналарының лапасы. Лапас эчендә арбалы мичкә һәм бер машина. Өй әйләнәсенә чиләк, пумала, балта, көрәк, багор кебек кораллар эленеп куелган. Артта төрле буяулар белән бизәкләп салынган Шәүлиханнар капкасы. Аның белән янәшә ике катлы өйнең парадный ишеге күренә. Бер читтә күпернең башлангыч өлеше тора. Пәрдә ачылганда Артамонов каравыл өе алдындагы халыкка сөйли.

Артамонов. Англия, Франция империалистлары дипломатлары Вакытлы хөкүмәтнең бусагасын таптап, һөҗүмгә күчүне таләп иттеләр. Америка финанс магнатлары, һөҗүмгә күчүне шарт итеп, Вакытлы хөкүмәткә зур сумада заемнар бирделәр. Менә шулай итеп, йөз меңләгән эшчеләр Петроград урамнарында сугышка каршы демонстрацияләр ясап йөргәндә, безнең рус гаскәрләре 19 нчы июньдә һөҗүмгә күчтеләр. Миллионлаган солдатлар, бу җинаятьчел сугышны туктатуны сорап окопларда, казармаларда митинглар ясап торганда, Вакытлы хөкүмәтнең сатлык генераллары солдатларны һөҗүмгә алып киттеләр. Йөз меңләгән крестьян вәкилләре волостной комитетларга җыйналып һич кичекмәстән солых ясауны таләп иткәндә, күпчелеге шул ук крестьян балаларыннан торган солдатларны күрәләтә үлемгә алып киттеләр. Шулай итеп, Америка, Англия, Франция империалистларының интереслары өчен, алтмыш меңнән артык рус солдатлары башларын салдылар.

Биктимер керә.

Биктимер. Киңәшләр бирексен.
Хәйбул. Уртасында бул, Биктимер абзый.
Артамонов. Әйдә, Шамкаевич.
Биктимер. Мироныч, нигә безгә төшмәдең?
Артамонов. Менә сугыш турында сөйләшеп киттек тә...

Б и к т и м е р. Сугыш дигәннән, яңа гына Миргарифҗан малаеннан хат килгән...

Х ә й б у л. Нәрсә яза икән?

Б и к т и м е р. Ике аягымны да кистеләр, дигән...

А р т а м о н о в. Димәк, «революцион» Вакытлы хөкүмәтнең соңгы сугышларында?

Б и к т и м е р. Күрәсең, шулай... хәлләрен белергә кергән идем, бөтен өй эчләре белән елыйлар... Карап тора алмадым, чыгып киттем...

Х ә й б у л. Еламыйни... Бусы өченче малайлары бит... Өй тулы балалар... Җитмәсә тагын, Миргарифҗан абзый үзе дә саулыксыз...

А р т а м о н о в. Менә, шул инде, агайлар, безнең социалист министрларның халыкка биргән ирегенең җимеше!

Б и к т и м е р *(ерактӑн кемнәрнедер күреп)*. Болар кемнәр, аргы урамнан чаптырып киләләр?

Х ә й б у л. Алдагысы Мирзахан, арттагысы Ходаяр бугай. Димәк, Мироныч, халыкны җыенга кусак та ярый, Мирзахан авылга килде. Халык та кырдан кайтып бетте диярлек.

А р т а м о н о в. Әйе, бик вакыт. *(Хәйбул кулына таяк алып кычкырып китә.)*

Артамонов белән Биктимердән башкалар таралалар.

Б и к т и м е р. Аннан, ишеттеңме әле, Мироныч, боларда бүген зур мәҗлес була икән.

А р т а м о н о в. Шундый кызу эш өстендәме?

Б и к т и м е р. Үзем дә шуны әйтәм, тикмәгә түгелдер. Янәшәтирәдәге сәүдәгәрләр, ишан-муллалар, шәкерт-хәлфәләр чакырылган.

А р т а м о н о в. Кайгырма, Биктимер Шамкаевич, синең губерна шәһәренә кадәр барып йөрүең нәтиҗәсез калмады. Безнең волостьтагы җинаятьләрне тикшерергә губерна Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советыннан аерым полномочие белән бер кеше килә.

Б и к т и м е р. Кем икән?

А р т а м о н о в. Фамилиясен язмаганнар. Записканы миңа Уком секретаре иптәш Вавилов җибәргән.

Б и к т и м е р. Анысы бик әйбәт булган. Аннан, Мироныч, авылга безнең Нургали кайтып төште бит әле.

А р т а м о н о в. Нәрсә, кунаккамы?

Б и к т и м е р. Күрше волостька икмәк җыярга барам дип әйтә ди.

А р т а м о н о в. Ничек инде ул «әйтә» ди.

Б и к т и м е р. Шулай, безгә кермәде. Бабасы Әхтәригә тукта-

ган. Менә, Мироныч, үз балам үземә дошманлык итә... Шуннан инде башкаларга ни кала?..

А р т а м о н о в. Мин аңламыйм, ничек соң ул алай?

Б и к т и м е р. Калага баргач, абыйсы Мирвәли белән сүз көрәштергәне өчен яңагына суккан идем, шуның ачуын тота, күрәсең.

Парадный ишегендә К а с ы й м х а н күренә. Артамонов белән Биктимер китә.

К а с ы й м х а н *(артларыннан карап калып)*. Бу ходатай нишләп йөри икән безнең авылда?

Ә х т ә р и керә.

Бик озакладың, Әхтәри абзый.

Ә х т ә р и. Кияү кисәгем кайтып төште, аның белән юандым. Тиздән учредительный собраниегә сайлаулар була, ди. Дөрес сөйли микән?

К а с ы й м х а н. Әйе, дөрес. Сине чакыртуым да шул турыда иде. Ястү намазыннан соң, безгә килеп чык әле.

Ә х т ә р и. Берәр сүзең бармыни?

К а с ы й м х а н. Мин әтигә бүген җиде азан кычкыртам. Шул уңай белән янәшә-тирәдәге муллаларны, хәлфә, шәкертләрне хәтемгә чакырдым.

Ә х т ә р и. Ай-һай, Касыймхан, Шәүлихан абыйга аның гына файдасы тияр микән?

К а с ы й м х а н. Синнән яшерен-батырыны юк, ул мәҗлес сылтау гына. Без анда учредительный собраниегә депутатлыкка кандидатлар күрсәтүне карарга тиешбез. Шунда син, беренче булып, минем кандидатурамны күтәреп чыгарсың.

Ә х т ә р и. Губерна мөселман крестьяннары исеменнән Мирзаханны күрсәткәннәр түгелме соң?

К а с ы й м х а н. Аны эсерлар партиясе күрсәткән. Ә без, партиясезләр, үз кешебезне куярга тиеш. Киявең килә, әйдә әле, өйгә керик.

Кереп китәләр. Х ө р м ә т у л л а белән Н у р г а л и керә.

Х ө р м ә т у л л а. Юк, каениш, бу турыда син хаклы түгел, мин сиңа шуны әйтим...

Н у р г а л и. Юк, җизни, ничек инде старшина малаен учредительный собраниегә депутат итеп сайларга кирәк.

Х ө р м ә т у л л а. Нишлисең, безнең өяздә Мирзаханнан да кулай кеше юк.

Н у р г а л и. Син шуны аңлыйсыңмы, ул бит буржуй малае.

Х ө р м ә т у л л а. Андый җиргә чабаталы мужикны да җибә-

реп булмый. Петербург кадәр Петербургка барып, крестьян зарын сөйләрлек кеше булырга тиеш.

Н у р г а л и. Шәүлихан старшина малае беркайчан да крестьян файдасына сөйләмәс. Буржуй буржуй инде ул.

Х ө р м ә т у л л а. Сынап-сынап торам да, каениш, сиңа әллә ни булган. Торасың да байлар, буржуйлар, дисең. Әллә син дә большевик булдыңмы? Элек бер дә болай түгел идең, сиңа ни булды?

Н у р г а л и. Авылларда йөрү мине күп нәрсәгә өйрәтте... Чыннан да без шәһәрдә революция булды дип шатланабыз, собраниеләрдә матур-матур сүзләр сөйлибез. Уйлап карасаң, ул революция крестьянга ни бирде? Берни дә! Без ватан өчен «икмәк әзерлибез» дип йөрибез, ә монда вагонлап аны спекулянтларга саталар. Һаман да шул, авылда фәкыйрьлек, бөлгенлек, хәерчелек. Һаман да байлар крестьянны талыйлар.

Х ө р м ә т у л л а. Дөнья шулай инде, бөтен кеше дә бай булмаган кебек, барысы да бертигез дә була алмый. Куллардагы бармаклар да бертигез түгел бит. Әйдә, киттек. Апаң анда көтә торгандыр. *(Китәләр.)*

Бер яктан З ә м з ә м б а н у, икенче яктан Г а й н а в а л керен очраша.

Г а й н а в а л. Ана үрдәк шикелле бу кем юргалап килә икән дисәм, үзебезнең күрше икән.

З ә м з ә м б а н у. Саумы, күрше?

Г а й н а в а л. Шөкер әле, үзең нишләп йөрисең?

З ә м з ә м б а н у. Менә әйберләремне алып китәргә кайттым.

Г а й н а в а л. Син инде бөтенләй шунда калырсың микәнни?

З ә м з ә м б а н у. Шулай инде, урыным бик әйбәт, сыер савып торам.

Г а й н а в а л. Авылны сагынмыйсыңмы?

З ә м з ә м б а н у. Исемә дә кергәне юк. Анда пленга төшкән астри солдатлары бар. Шулар белән шау-гөр килеп ятабыз. Һәр көнне эштән кайткач, үзләре ясаган музыка коралларын алып чыгалар да, казармалары янында уен корып җибәрәләр. Шунда биеләр, җырлыйлар... Әй, күңелле була инде. Кайвакытта таң атканны да сизми калабыз. Анда җибәрүләренә куанам гына. Әти нишләп ята соң?

Г а й н а в а л. Нишләсен мескен, Гөлниса түтәйне бик сагына. Өлкән кешегә ялгыз тору бик кыен иде, ярый әле, күрше авылдагы сеңелесе Сәрбиҗамал түтәй үзен карарга килде. Бергәләп әйбәт кенә торалар. Үзен бүген авылга рәис итеп сайлыйбыз әле.

З ә м з ә м б а н у. Әткәйнеме?

Г а й н а в а л. Әйе, Биктимер абзыйны. Җыенга кил, беренче тапкыр хатын-кызлар да сайлауга катнаша.

З ә м з ә м б а н у. Кызык икән. Чыннан да килим әле.

Г а й н а в а л. Ярый, мин әле хатын-кызларны өндәргә югары очка бара идем.

Икесе ике якка китәләр. Шәүлиханнар өеннән Ә х т ә р и чыга. М и р з а х а н керә.

М и р з а х а н. Сәлам, Әхтәри абзыйга.

Ә х т ә р и. Мәҗлескә килдеңме?

М и р з а х а н. Нинди мәҗлескә?

Ә х т ә р и. Сезнекеләр Шәүлихан абзыйга җиде азан кычкырталар бит.

М и р з а х а н. Шулаймыни? Мин халыкка хөкүмәтебезнең учредительное собраниегә депутатлар сайлау көнен билгеләп чыгарган карарын аңлатырга һәм синең олы улыңны авыл комитетына рәис итеп куярга килдем.

Ә х т ә р и. Минем улымны?.. Соң бит монда Биктимер коданы сайларга йөриләр.

М и р з а х а н. Алар йөрерләр... Ләкин бит әле биредә революцион Вакытлы хөкүмәтнең органнары бар. Биктимер карт тиздән тимер читлек эченә утырыр.

Ә х т ә р и. Гаебе бармыни?

М и р з а х а н. Җыенда ишетерсең. Хәзергә үзең генә бел...

Ә х т ә р и. Кабер инде, кабер. Ул карт шайтанга күптән шул кирәк иде.

М и р з а х а н. Бар, малаеңа әйт, әзерләнеп торсын.

Ә х т ә р и. Рәхмәт инде, Мирзахан, патша старостасы дип күзебезне ачырмыйлар иде, бәлкем, инде хәзер тынарлар?

М и р з а х а н. Тынарлар, Әхтәри абзый, тынмасалар авызларын томаларбыз.

Ә х т ә р и. Бәйрәм ашы кара-каршы, дигәндәй, мин сиңа шуны әйтим әле алайса, син, энем, абыеңнан бик саклан.

М и р з а х а н. Нәрсә, минем турыда начар уйдамы?

Ә х т ә р и. Бүген янәшә-тирәдәге мулла, ишан, хәлфә, шәкертләрне җыеп, атаңа җиде азан кычкыртуы тегермән генә.

М и р з а х а н. Ничек, тегермән генә?

Ә х т ә р и. Учредительный собраниегә депутат итеп сине түгел, үзен сайлатырга хәйлә корып маташа.

А р т а м о н о в, Х ә й б у л, Б и к т и м е р, икенче яктан Х о д а я р, Я с ә в и һәм б а ш к а л а р керәләр.

М и р з а х а н. Я, Хәйбул абый, җыелыш кайчан була инде?

Х ә й б у л. Хәзер, Мирзахан, башлыйбыз. Әнә халык та килә башлады.

Төркем-төркем булып сәхнәгә халык кереп тула. Г а й н а в а л , З ә м з ә м б а н у һәм б а ш к а х а т ы н н а р кереп бер читкә генә басалар.

Ә х т ә р и. Сезгә монда ни калган, оятсызлар? Барыгыз, балаларыгызны карагыз!.. *(Таяк тотып бара башлый.)*

М и р з а х а н. Кума, Әхтәри абзый! Хәзер, яңа закон буенча, сайларга һәм сайланырга хатын-кызларның да хакы бар. Авылдашлар! Җыенибызны башлап җибәрергә рөхсәт итегез. Безнең көн тәртибендә бүген ике мәсьәлә: беренче — авыл комитетына рәис сайлау. Икенче — Вакытлы хөкүмәтнең учредительное собраниегә депутатлар сайлау көнен билгеләп чыгарган карарлары белән танышып китәрбез. Башта без, әлбәттә, рәис сайлауны үткәрербез. Без инде иске председатель турында бүген сөйләп тормабыз, чөнки ул безнең ышанычыбызны аклый алмады, шуның өчен без аны судка бирдек. Сүзне озайтып тормыйча, мин волость комитеты тарафыннан һәм исеменнән авыл комитеты рәислегенә Биктимер абзый Шамкаевны тәкъдим итәм. Шул турыда нинди фикерләр булыр?

Х ә й б у л. Миңа сүз бирегез әле.

М и р з а х а н. Рәхим итегез, Хәйбул абый.

Х ә й б у л. Биктимер абзыйны без бөтен авыл белән беләбез. Безгә ул һәрвакытта акыллы киңәшләр бирә. Очраганда һәркем белән исәнләшә, кайгыбыз булса уртаклаша. Шуңа күрә дә без аны, авыл җыеннарының берсендә, рәислеккә күрсәтеп волость комитетына биргән идек. Шулай булгач, бүген инде без аны шатлана-шатлана сайлыйбыз.

М и р з а х а н. Тагын кем сөйли?

А р т а м о н о в. Миңа да рөхсәт итегез.

М и р з а х а н. Пожалуйста, Григорий Мироныч.

А р т а м о н о в. Биктимер Шамкаевич безгә — большевиклар партиясенә шул ягы белән билгеле: беренчедән, ул — үз кул көче белән көн күрүче ярлы крестьян. Икенчедән, яхшы уллар тәрбияләп үстергән кеше. Үзегезгә мәгълүм, бер улы сугышта һәлак булды. Икенче улы солдат комитетында эшли. Барыннан да бигрәк, аның олы улы Мирвәли Биктимиров, самодержавиегә каршы аяусыз рәвештә көрәшеп, берничә мәртәбә патша төрмәсендә утырды. Бүгенге көндә губерна шәһәрендә Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советында җаваплы постта эшли. Менә шундый кеше хезмәт иясе крестьяннарның интересларын яклар. Аларның ышанычларын гадел хезмәте белән дә аклар дип ышанам.

М и р з а х а н. Тагын да нинди фикерләр булыр?

Г а й н а в а л. Сүз озайтып торуның кирәге юк, тавышка куй инде.

Берничә милиционер ияртеп, ашыгыч рәвештә Б а с а р ы й керә.

М и р з а х а н. Ул чагында тавышка куям. Кем дә кем Биктимер абзыйны Таштугай авыл комитетына рәис итеп сайларга да, шул кешеләр...

Б а с а р ы й. Миңа да сүз бирегез әле.

М и р з а х а н. Биктимер абзыйның кандидатурасы турындамы?

Б а с а р ы й. Юк, аның үзе турында. Кызганычка каршы, без аны сайлый алмыйбыз.

А р т а м о н о в. Ни өчен?

Б а с а р ы й. Яңа гына өяздән алынган приказ буенча ул җавапка тартыла.

Б и к т и м е р. Нинди җавапка?

М и р з а х а н. Бәлки, сез аны халыкка аңлатып бирерсез.

Б а с а р ы й. Исегездәдер, моннан берәр айлар элек алпавыт Кригерның паровой тегерменендә сакчысын үтереп, илле капчык онын урлаганнар иде. Шул уңай белән авылларда үткәрелгән тентүләр вакытында Биктимер абзыйның келәтеннән Кригер клэймәсе сугылган капчык табылып, өязгә җибәрелгән иде. Менә шул эш буенча миңа бүген өяз прокурорыннан приказ килде. Ягъни ул, Биктимер абзыйны кулга алып, өязгә озатырга куша.

Х ә й б у л. Ничек инде ул алай?

А р т а м о н о в. Сез шуңа ышанасызмы?

Б а с а р ы й. Ышанмасак нишли алабыз? Югары революцион оешмаларның приказын мин үтәргә тиеш. Чөнки капчык мәсьәләсе...

З ә м з ә м б а н у. Капчык, капчык, дисезме? *(Атылып алга чыга.)*

Б а с а р ы й. Әйе, аңардан табылган капчык...

З ә м з ә м б а н у. Җәмәгать, яла ягу бу!

М и р з а х а н. Ничек яла ягу?

З ә м з ә м б а н у. Ул капчык Ясәвинеке.

Х ә й б у л. Ясәвинеке?

А р т а м о н о в. Ну-ка, ну-ка, ничек Ясәвинеке?

З ә м з ә м б а н у. Менә ничек аныкы: иртәгә наборга китәсе көннәрендә, кич белән «расходка акчам юк, он алмыйсыңмы, җиңги», дип миңа Ясәви килгән иде. Бәясе юнь булгач мин алырга булдым. Бәлагә каршы булган икән, үз капчыгым ул көнне буш түгел иде, күршеләргә кереп сорасам соң инде, бар да йоклаганнардыр, дип аптырап торганда, бу миңа «Нигә, Биктимер абзыйларның юкмыни», ди. Бар, мин әйтәм, ләкин бит аларның

келәтләре бикләнгән, дим. Шуннан ул: «Минем кесәмдә ачкычлар бар бугай, бәлкем, берәрсе ярый торгандыр әле», — диде дә, бер көлтә ачкычлар чыгарып, ачып та бирде. Шуннан мин, келәт колгасыннан бер капчык алдым, моның белән он алырга киттем. Капка төпләренә җиткәч: «Җиңги, син ишегалдына кереп йөрмә инде, хатын сизүе бар, мин хәзер үлчәп чыгарырмын», — дип кереп югалды. Чыннан да, ул миңа он чыгарды, өйгә кайткач бизмәндә тартып карадым, болай гадел үлчәгән иде, тик онны кисмәккә бушатыйм дисәм, әтиләр капчыгы түгел, илтеп ташлыйм әле, дип капкадан да чыккан идем, ләкин «сезнең иске, ямаулы капчыгыгыз урынына, өр-яңа шикәр капчыгы биргән икән, әйдә, эчеңнән тын инде», дигән бер уй кылт итеп башыма килде бит. Шайтан вәсвәсәсе булгандыр инде, шулай итеп, мин аны Ясәвигә илтеп бирмәдем, әткәйләр келәтенең песи йөри торган тишегеннән эчкә ыргыттым.

Хәйбул. Әһә!.. Менә ул нишләгән?!

Гайнавал. Менә алар ничек хәйлә корганнар?!

Ясәви. Ялганлый ул, җәмәгать, валлаһи, ялганлый, барганым да, күргәнем дә юк.

Зәмзәмбану. Имансыз икән... Күзгә карап тана бит.

Әхтәри. Шаһитләрең бармы, шиһатләрең?

Ясәви. Әйе, шаһитләрең кая, бармы соң?

Җыен халкы икегә бүленеп талаша башлый. Һәрбер кеше нинди дә булса бер сүз әйтеп икенче берәүгә кычкыра.

Артамонов. Иптәшләр! Тавышланмагыз...

Халык тына.

Мирзахан Шәүлиханович, җыелышны бака туена әйләндерүегез өчен, мин сезгә волость большевиклары исеменнән протест белдерәм!

Басарый. Сез теләсәгез ни әйтегез, мин аны кулга алып хәзер үк өязгә озатам.

Хәйбул. Без аны сезгә бирмибез!

Гайнавал. Бөтен авыл белән шаһит булып барабыз! Җитәр инде, Гөлниса түтәйне үтердегез.

Халык яңадан кутәрелеп китә.

Артамонов. Иптәшләр! Мин сезне тәртипкә чакырам. Кригер тегермәне вакыйгасын, гомумән, безнең волостьтагы эшләрне тикшерү өчен безгә, бүгенме, иртәгәме губерна Эшче-Крестьян

һәм Солдат Депутатлары Советыннан җибәрелгән кеше килеп җитәчәк. Шуңа хәтле мин бу җыелышны икенче бер вакытка кичектереп торуны тәкъдим итәм.

Мирзахан. Григорий Миронычның тәкъдиме белән мин берничек тә килешә алмыйм. Чөнки бүгенге җыелышны икенче бер вакытка кичектерү ул учредительное собраниегә сайлау көннәрендә авылны тагын да рәиссез калдыру булыр иде. Без бүген вакытлы гына булса да бер кешене сайлап куярга тиешбез. Ә инде Биктимер абзыйны кулга алуны калдырып торырга мөмкин.

Басарый. Ә прокурор приказын кая куясыз?

Мирзахан. Эше тикшерелеп ачыкланганчы, без аны Григорий Мироныч белән порукага алып торырбыз. Шулай бит, Мироныч?

Артамонов. Порукага алырлык Биктимер Шамкаевичның берничди дә гаебе юк.

Биктимер. Авылдашлар! Мин дә бер-ике сүз әйтим әле.

Гайнавал. Бер-икене генә түгел, Биктимер абзый, күп итеп сөйлә.

Басарый. Юк, сөйләмәс! Мин аны хәзер кулга алам.

Хәйбул. Кулың кыскарак түгелме? Сөйлә, Биктимер абзый.

Халык. Сөйлә, сөйлә, Биктимер абзый.

Биктимер. Басарый түндәкнең әтәчләнүе турында мин хәзер берни дә әйтмим. «Эт этлеген итмәсә, эче күгәрә» дигән бабайлар. Шуның шикелле, әйдә, айга карап өргән маэмай төсле өрә бирсен. «Оясында ни булса — очканында шул булыр» дигәндәй, алар өйрәнгән инде. Аталары, мәрхүм, судтан судка ялган шаһитлеккә йөреп гомерен уздырган булса, болары да шул табак ялап көн итәргә тырышалар. Минем гаепсез икәнемне барыгыз да беләсез. Шулай булгач, нигә миңа алар алдында акланып торырга? Тик мин сезгә шуны гына әйтәсем килә: мондый хәлләр, җәмәгать, безнең арабызда оешканлык җитмәүдән килеп чыга. Мироныч бервакыт җыенда безгә болай дигән иде: революциянең үсеп барышына сүлпән катнашасыз, большевиклар партиясенә, шәһәр эшчеләре тирәсенә тупланмыйсыз, дәүләт аппаратларын үз кулыгызга алырга омтылмыйсыз дигән иде.

Артамонов. Мин анда сезгә, Биктимер Шамкаевич, Владимир Ильич Ленинның сүзләрен мисал итеп китергән идем.

Биктимер. Шулаймы? Әйтәм, ул минем йөрәгемә бик тирән кереп урнашкан. Алтын белән язып куярлык сүзләр икән шул. Әгәр дә без бу хикмәтле сүзләр буенча эш иткән булсак, күптән инде җирле дә, мирле дә булыр идек. Мин дә нахакка бәла ягуларны күрмәгән булыр идем. Карчыгым Гөлниса да вакытсыз гүргә кермәс иде...

Б а с а р ы й. Ярый, ярый, Гришага яхшатланып маташма, ул барыбер сине коткарып кала алмас. Милиционерлар, алыгыз.

М и р з а х а н. Гражданин Мәрдәнов, мин сиңа арестовать итмәскә боерам.

Б а с а р ы й. Гафу итегез, гражданин председатель, бу мәсьәләдә мин сезгә буйсынмыйм. Хәзергесе минутта минем өчен прокурор приказы гына приказ. Каравыл өенә кертеп ябыгыз!

Ике милиционер Биктимерне җитәкләп караул өенә таба алып китә башлый. Халык аларга каршы төшә.

Х ә й б у л. Туктагыз әле, почта атында кемдер килеп туктады.

Барысы да тынып калалар. Юл киеменнән М и р в ә л и керә.

М и р в ә л и. Сездә нәрсә, иптәшләр, җыелыш барамы, дим?

Б и к т и м е р. Юк, улым, атаңны хөкем итәләр!

М и р в ә л и. Ничек, әти, хөкем итәләр?

Б а с а р ы й *(ялагайланып)*. Юк, Мирвәли абый, хөкем итмибез, өяз прокурорының приказы буенча, кулга гына алабыз.

М и р в ә л и. Ни өчен?

Б а с а р ы й. Сезнең келәтегездән Кригер кләймәсе сугылган капчык табылган иде.

З ә м з ә м б а н у. Ялганлыйлар, дәү абый, ул капчык минеке!

Г а й н а в а л. Юри тегермән коралар, Мирвәли.

Х ә й б у л. Нахакка бәла ягалар.

М и р в ә л и. Сабыр, иптәшләр! Эш нәрсәдә соң?

М и р з а х а н. Эш менә болай, Мирвәли абый: моннан берәр айлар элек алпавыт Кригер тегермәненең сакчысын үтереп, оннарын урладылар. Шул уңай белән, авылларда үткәрелгән тентүләр вакытында Биктимер абзыйларның келәтеннән Кригер кләймәсе басылган капчык табылып, өязгә җибәрелгән иде.

Б а с а р ы й *(бүлдереп)*. Шул турыда бүген миңа өяз прокурорыннан приказ килде. Үзегез беләсез, мин революцион законнарны үтәүче генә, алар миңа юкка ачуланалар. Менә укып карагыз, ничек каты язылган.

А р т а м о н о в. Монда, Мирвәли, ачыктан-ачык итеп оештырылган политик шантаж бара.

М и р з а х а н. Без хәзер, Мирвәли абый, бу приказны кире алуларын сорап өяз прокурорына телеграмма бирәбез.

М и р в ә л и. Мәшәкатьләнмәгез. Мин аны бөтенләйгә аннулировать итәм! *(Ертып ташлый.)*

Дошман лагере аптырап кала. Халык шатлана.

М и р з а х а н. Гафу итегез, Мирвәли абый, сезне кем дип таныйк?

М и р в ә л и. Губерна Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советыннан сезнең волостька аерым вәкаләт белән җибәрелгән вәкил итеп танысагыз ялгышмассыз.

*Пәрдә*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ.

Вакыйга шул ук пожар сарае алдында бара. Вакыт кич инде. Каравыл өе эчендә тоныкы кына ут яна. Пәрдә ачылганда муллалар, хәлфәләр, шәкертләр Шәүлиханнар өенә кереп китәләр. Каравыл өеннән М и р в ә л и белән А р т а м о н о в чыга.

М и р в ә л и. Безнең партия, Гриша, иптәш Сталинның, Революциянең тынычлык юлы белән үсү чоры бетте, тыныч булмаган чоры, алышу һәм шартлау чоры җитте, дигән күрсәтмәсе нигезендә, эшчеләр сыйныфының җитәкчелеге белән, тиздән социалистик революцияне тормышка ашырырга хәзерләнә. Үзең беләсең, аны булдыру безнең илдә хәлиткеч көч булып торган крестьяннар катнашыннан башка мөмкин түгел. Менә шуның өчен дә безнең партия, минем кебек крестьян арасыннан чыккан членнарга мобилизация үткәреп, авылларга чыгарды. Шул ук вакытта учредительное собраниегә сайлау кампаниясен уңышлы үткәрүне дә безнең өскә йөкләде.

А р т а м о н о в. Бик яхшы булган, Мирвәли. Биредә миңа эшләве бик авыр иде. Чөнки безнең бу тирәдә милләтчеләр, эсерлар күп һәм көчлеләр, атлаган саен «изелгән милләт» маскасы астында революциянең үсешенә аяк чалалар. Кайбер татар авылларында җыелыш уздыра башласаң, «нигә безнең мәчетләргә дәүләт хисабыннан акча җибәрелми? Нигә безнең муллаларга рус поплары шикелле жалованье бирелми?» дип куялар.

М и р в ә л и. Әйе, Гриша, татар буржуазиясе бөтен җирдә хәзер колачын киң җәеп җибәрде. Шул «изелгән милләт» маскасы астында контрреволюцион панисламизм, пантюркизм хәрәкәтен бөтенләе белән үз кулына алырга җыена. Әнә Казанда, бер үк вакытта бөтен Россия мөселманнарының икенче съездын, «Үзәк хәрби шура», «Милли шура» съездларын уздырып, бөтен җитәкче аппа-

ратларга татар буржуа балаларын сайлап куйдылар. Инде хәзер «Милли Мәдәни Мохтарият» вывескасы астында Идел-Урал штатын игълан итәргә маташа. Ләкин рус капиталистларыннан төзелгән Вакытлы хөкүмәт аларга ул «мохтарият» дигән үрмәкүч тозагын да бирәчәк түгел. Чөнки милли мәсьәләдә рус монархиясе белән буржуаз революция арасында бернинди дә аерма юк. Татар хезмәт ияләре фәкать безнең большевиклар партиясенең җитәкчелеге астында гына, башка изелгән милләтләр белән берлектә, үзенең Милли Автономияле Республикасын төзиячәк. Бу — безнең программабыз. Бу — безнең бөтен милләтләр өчен күтәргән азатлык байрагыбыз.

А р т а м о н о в. Кичәге газетада бер кызыклы хәбәр басылган. Лотфи Исхаков дигән бер бәндә, Петроградка барып, князь Львов белән Черновларны күреп, «Вакытлы хөкүмәт составына безнең мөселманнардан да бер министр тәгаен итәргә мөмкин түгелме», дип сорау бирә. Ул мөселман министрының, әлбәттә, татардан булуы күз алдында тотыла торгандыр инде. Тегеләр, билгеле, андый мөселман министрның тәгаен ителәчәген вәгъдә иткән булалар.

М и р в ә л и. Димәк, татар буржуазиясе сатлык. Вакытлы хөкүмәткә контрреволюцион көчен үзе тәкъдим итеп йөри. Шулай булгач, алар ничек итеп татар хезмәт ияләренең милли азатлык хокукларын яклый алсыннар?

А р т а м о н о в. Ничего, Мирвәли, безнең рус халкы әйтмешли: перемелится — мука будет. Туып килә торган социалистик революция ул чүп-чарларны тиздән себереп ташлаячак. Ярый, миңа китәргә вакыт. Син волостьта кайчан булырсың икән?

М и р в ә л и. Бүген мондагы кешеләр белән сөйләшәм, иртәгә таланган аракы заводы буенча Твардовский имениесендә булам.

А р т а м о н о в. Ул чагында мин волость большевикларының җыелышын берсекөнгә үткәрәм, син шунда июль вакыйгалары, шәһәр хәлләре турында сөйләсәң яхшы булыр иде.

М и р в ә л и. Ярый, хәзерләнермен. Син дә аңарчы тиешле кешеләрне күреп, кирәкле материалларны хәзерли тор. Учредительное собраниегә депутатлыкка кандидат итеп куелырга уйланган Аюханов кандидатурасын без егарга тиеш.

А р т а м о н о в. Әлбәттә, без аны егарбыз. Ярый, хәзергә хуш.

М и р в ә л и. Хуш, Гриша. Ольга Дмитриевнага сәлам әйт.

Артамонов китә. Каравыл өеннән Х ә й б у л чыга.

Х ә й б у л. Менә бит ул, Мирвәли абый, безнең монда ниләр эшләнә!

М и р в ә л и. Монда гына түгел, Хәйбулла. Бөтен Россия хәзер шундый кискен сыйнфый көрәш чорын кичерә. Изелгән сыйныфларның күтәрелешенә каршы эксплуататорлар сыйныфы ерткычларча чәйнәшә.

Х ә й б у л. Менә шул турыда ярлыларның сиңа сүзе бар, вакытың булса, сөйләр идек, диләр.

М и р в ә л и. Вакытны табарбыз, Хәйбулла. Нинди сүзләр икән ул?

Х ә й б у л. Кригерның паровой тегермәнен, Твардовскийның аракы заводын үзләре талап та башкаларга ягуларын белүчеләр бар.

М и р в ә л и. Син аларны хәзер минем янга чакыра алмыйсыңмы?

Х ә й б у л. Монда килмәсләр шул, аулак җирдә булса, сөйләрләр иде.

М и р в ә л и. Алай да була. Мин аларны кайда күрә алам?

Х ә й б у л. Минем өйгә чакырыйк.

М и р в ә л и. Бик әйбәт. Бар алайса, син аларны җый. Бар да килеп беткәч, миңа әйтерсең.

Х ә й б у л. Ярый алайса, мин киттем. *(Китә.)*

М и р з а х а н керә. Мирвәли чыга башлый.

М и р з а х а н. Мирвәли абый, минем сиңа сүзем бар иде.

М и р в ә л и. Мин сезнең белән волость комитетында сөйләшермен.

М и р з а х а н. Минем бүген сөйләшәсем килә. Сезне эзләп әле өегезгә дә барган идем.

М и р в ә л и. Ул кадәре ашыгыч нигә кирәк булдым соң?

М и р з а х а н. Биктимер абзый белән булган бүгенге күңелсез вакыйга турында безгә аңлашмыйча ярамый.

М и р в ә л и. Ул турыда хәзер сөйләүдә мәгънә булыр микән соң?

М и р з а х а н. Булыр, Мирвәли абый! Дөрес, мондый үкенечле вакыйганы мин булдырмаска тиеш идем. Бу, әлбәттә, минем зур гаеп. Ләкин кайвакытларда синең ихтыярыңнан тыш эшләнгән фактлар да булгалый икән. Менә миңа бүген шундый бер хәлнең шаһите булырга туры килде. Басарый сволочь! Өяздән килгән акылсыз приказны алу белән миңа әйтмичә, минем белән киңәшмичә үзлегеннән эшләгән. Бу адымы өчен мин аны җәзасыз калдырмам, әлбәттә.

М и р в ә л и. Белмим шул, хәлеңнән килер микән?

Мирзахан. Ни өчен алай дип уйлыйсыз?

Мирвәли. Чөнки ул өяз прокурорының приказын үтәргә тырышкан. Ә прокурор инде нинди дә булса бер авторитет биргән материалга таянып эш иткән. Шулай булгач, сез аның белән берни дә эшли алмыйсыз. Халык әйткәнчә «эт эткә, эт койрыкка» килеп чыга.

Мирзахан. Шулай инде ул, мин сезгә нинди генә дәлилләр китерсәм дә ышанмассыз, чөнки сез миңа Гөлчирә мәсьәләсе белән дошманлык саклыйсыз.

Мирвәли. Дөрес, мин сиңа дошманлык саклыйм. Ләкин ул дошманлыгым сеңелемне мәсхәрә итү өчен генә түгел, бәлки, безне изеп килгән бер сыйныфның вәкиле һәм хәзер дә шул сыйныфның интересларын яклауны дәвам иттерүче кеше булуың өчен.

Мирзахан. Дөрес түгел! Ул сыйныф белән минем бернинди дә алыш-бирешем юк хәзер. Халыкка, революциягә ни дәрәҗәдә бирелгән кеше булуымны эшем белән исбат итә алам.

Мирвәли. Белмим шул, син аны нинди генә эшең белән исбат итә алырсың икән?

Мирзахан. Менә бу йортта мине тудырган ата-аналарым, туганнарым торалар. Минем өчен болардан да якын, болардан да газиз беркем дә булмаска тиеш. Ләкин мин аларга карата бернинди дә кардәшлек хисләре саклый алмыйм. Чөнки алар анда бөтен янәшә-тирәдәге соры кортларны җыеп учредительное собраниегә үз вәкилләрен уздырырга заговор корып яталар. Әгәр дә сез хәзер яныгызга понятойлар алып керсәгез, минем сүзләремнең дөреслеген күрерсез. Һәм аларны кулга алырга мәҗбүр булырсыз дип ышанам.

Мирвәли. Аларны нигә миңа кулга алырга? Сез шушы волостьның сайланып куелган кешесе. Кулыгызда чикләнмәгән власть бар. Керегез дә үзегез кулга алыгыз, революцион закон исеменнән үзләрен хөкем итегез.

Мирзахан. Сезнең властегыз зуррак, сез губерна Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советыннан җибәрелгән кеше.

Мирвәли. Юк, Мирзахан, минем кулларым белән утлы күмер көри алмассың.

Хәйбул керә.

Хәйбул. Мирвәли абый, мин сине алырга килдем.

Мирвәли. Әйдә, Хәйбул, киттек.

Мирзахан. Мирвәли абый, иртәгә мин Биктимер абзыйны авылга рәис итеп сайлауны үткәрергә уйлыйм.

М и р в ә л и. Әгәр да аны халык тели икән, синең белән минем тыкшынудан башка да үткәрерләр.

М и р з а х а н. Анысы шулай, әлбәттә... Без сезнең белән кайчан очрашырбыз икән соң?

М и р в ә л и. Берсекөнгә, волостьта.

Хәйбул белән китәләр.

М и р з а х а н *(артларыннан карап калып, үз-үзенә).* Юк! Без синең белән бүген дә очрашырбыз әле...

Я с ә в и керә.

Я, күрдеңме?

Я с ә в и. Күрдем. Басу капкасы төбенә кадәр үзен тарантасыма утыртып та алып килдем. Озакламый монда булыр. Аннан, мин яңа гына Әхтәри абзый малаен күрдем, бөтен ярлы-ябагай Хәйбул чулак өенә җыела, ди.

М и р з а х а н. Әһә... Димәк, Мирвәли хәзер шунда китте.

Я с ә в и. Нәрсәгә икән?

М и р з а х а н. Һәрхәлдә, синең белән минем файдага түгелдер...

Я с ә в и. Әнә Самсонов килә.

М и р з а х а н. Бар, син үз юлыңда бул.

Ясәви китә. С а м с о н о в керә.

С а м с о н о в. Исәнмесез, Мирзахан Шаулиханович.

М и р з а х а н. Саумысез, Савелий Назарич.

С а м с о н о в. Мине нигә чакырттыгыз?

М и р з а х а н. Бүген безгә, әти белән сине һәм охранка агенты Шаһмурат мулла Гаделевне кулга алырга Губерна Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советыннан аерым уполномочие белән бер кеше килде.

С а м с о н о в. Нинди кеше?..

М и р з а х а н. Мирвәли Биктимиров.

С а м с о н о в. Биктимиров?..

М и р з а х а н. Сез аны беләсез бугай...

С а м с о н о в. Бик яхшы беләм. Моннан ике ел элек, мин аны кулга алып, унике елга хөкем иттергән идем.

М и р з а х а н. Менә шул кеше иртәгә сезнең өчегезне дә, Николай патшаның явыз палачлары итеп, губерна шәһәренә алып китәчәк.

С а м с о н о в. Димәк, безгә крышка?

М и р з а х а н. Кара язмышыгызга риза булып калсагыз, билгеле, шулай.

С а м с о н о в. Риза булмый, мин ни эшли алам? Тик миңа Шаулихан Алимханович кына кызганыч, карт кеше, неужели инде аны коткарырга бертөрле дә әмәл юк?

М и р з а х а н. Аны гына түгел, сезне дә коткарырга әмәл бар. Тик аңа зур тәвәккәллек кирәк.

С а м с о н о в. Например?

М и р з а х а н. Сезнең тормышыгызга кул сузучы кешене юк итегез.

С а м с о н о в. Биктимировны?

М и р з а х а н. Әйе, Биктимировны... Менә шул чагында син дә, әткәй дә иртәгә булачак аресттан котылырсыз. Шул ук минутта миннән сорап йөргән документыгызны алырсыз. Ул документ белән теләгән җирегезгә барып, хезмәт иясе крестьян булып, күкрәк киереп йөрерсез. Ризамы?

С а м с о н о в. Миңа хәзер барыбер, тик кайда һәм ничек?

М и р з а х а н. Ул хәзер югары очта, Хәйбул чулакта. Озакламый бередән үтеп китәргә тиеш. Бәхеткә каршы бүген төн дә караңгы.

С а м с о н о в. Ләкин бит хәзер минем бирегә килүемне күрделәр.

М и р з а х а н. Андый шиккә урын калдырмас өчен, син хәзер авыл башындагы Хафиз карттан сорап су эчәрсең дә, Никольский юлы белән авылдан чыгып киткән булырсың. Бераз баргач кире борылып, басу белән безнең ындыр артына килерсең. Аннан инде чокыр буйлатып төшәрсең дә менә шушы күпер астында яшеренеп торырсың. Эшеңне бетергәч, шул ук юл белән авылдан чыгып сызарсың.

С а м с о н о в. Кая, бир револьверыңны.

М и р з а х а н. Тупас кеше син, Савелий Назарич. Мондый эшне тавыш-тынсыз гына башкарырга кирәк. Сиңа пычак, үземә кендек әзерләп куелган булыр.

С а м с о н о в. Ничек, сез дәме?

М и р з а х а н. Әйе, икәүләп. Үз атамны үзем ничек тотып бирим?.. Син һөҗүм иткәндә, мин шушы тирәдә булырмын. Бар, эшеңдә бул.

Самсонов китә. Шәүлиханнар өендә тавыш күтәрелә. Ап-ак күлмәк-ыштаннан Ш ә ү л и х а н, аның артыннан Ә х т ә р и белән б е р н и ч ә ш ә к е р т йөгереп чыга. Мирзахан янгын сүндерү машиналары арасына яшеренә.

Ш ә ү л и х а н. К чорту муллаларың, ишаннарың миңа!

Ә х т ә р и. Чү, Шәүлихан абзый, хәзрәтләр ишетер.

Ш ә ү л и х а н. Ишетсеннәр, курыкмыйм мин ул живодерлардан, әрәмтамак, паразитлардан!

Ә х т ә р и. Соң бит алар сезне терелтергә, сезне дәваларга килгәннәр.

Ш ә ү л и х а н. Кирәкми миңа аларның төкерек чәчеп лыгырдаулары!

Ә х т ә р и. Әйдә, Шәүлихан абзый, керик.

Ш ә ү л и х а н. Кермим мин ул бәлеш козгыннары янына!

М и р з а х а н *(яшеренгән җиреннән чыгып)*. Туктагыз, нигә тавышланасыз?

Ә х т ә р и. Менә Шәүлихан абзыйны хәзрәтләр, түр идәненә салып, өшкерә генә башлаганнар иде, сикереп торды да, төрлесен төрле якка бәргәләп чыгып йөгерде.

Ш ә ү л и х а н. Сынок, алар мине авыру дип төрле чепухалар белән дәвалыйлар.

М и р з а х а н. Тавышланма, әти, кешедән яхшы түгел. Әйдә, мин сине мәзин җизниләргә илтеп яткырыйм.

Ш ә ү л и х а н. Ә соң рәтең булырмы?

М и р з а х а н. Тавышланмасаң, табарбыз.

Ш ә ү л и х а н. Ул чагында эш башка.

М и р з а х а н. Әхтәри абзый, барыгыз, мин әтине илтеп яткырам.

Китәләр. Бәхәсләшеп Н у р г а л и белән Х ө р м ә т у л л а керә.

Х ө р м ә т у л л а. Юк, каениш, монда Мирзахан гаепле түгел, прокурор приказ биргәч, үтәмичә аның хәле юк. Үзеңнән мисал ал. Авылларга чыгып икмәк җыярга сиңа приказ биргәннәр икән, килгәнсең. Иртәгә сугышка китәсең дип кушалар икән, берни дә эшли алмыйсың, китәсең. Приказ — приказ инде ул, аны үтәмичә ярамый.

Н у р г а л и. Приказ белән приказ арасында аерма бар. Хәзер иске режим түгел. Алар юри әтине халык алдында мәсхәрә итәргә булганнар. Шуның нәтиҗәсендә әнкәй мәрхүмәне вакытсыз үләргә мәҗбүр иткәннәр. Бәхетләре, җыен вакытында авылда булмадым. Мин аларны шунда ук чапкалап бетерер идем. Ничего, әле дә вакыт узмаган... Безнең семьяга күрсәткән явызлыкларының үчен мин бүген алардан кайтарам!.. *(Янгын сүндерү машиналары янына китә.)*

Х ө р м ә т у л л а. Кирәкми, каениш, сугышып йөри күрмә. Түбәнлек бит ул. Мирвәли каенагай аларның эшләрен тикшерергә килгән ди. Гаепләре бар икән, җавапка тартырлар. Ләкин, тагын әйтәм: кул белән уйный күрмә. Тукта әле, нигә син ул гайкаларны борасың?

Н у р г а л и. Тегермән артына җәен тотарга төшәм.

Х ө р м ә т у л л а. Төшсәң, андый гайкалар башка җирдә дә бетмәгән. Нигә янгын сүндерү машинасының гайкаларын борып аласың. Давай, давай куй! Син бала түгел лә. Җәй көне, Алла сакласын. Ут-күз чыгып куюы бар. Әйдә, киттек.

Н у р г а л и. Бар, син кайта тор.

Х ө р м ә т у л л а. Ә син?

Н у р г а л и. Әйтәм бит, тегермән артына балык тотарга төшәм.

Х ө р м ә т у л л а. Ә соң кармакларың кая?

Н у р г а л и. Тегермәнче Федордан алып торырмын. Мә, минем кылычны да үзең белән ал.

Х ө р м ә т у л л а. Тукта әле, каениш, син нидер эшләргә уйлыйсың, ахры?

Н у р г а л и. Юк, җизни, берни дә эшләмим.

Х ө р м ә т у л л а. Ә нигә соң кылычыңны миңа бирәсең?

Н у р г а л и. Балык тоткан җирдә нигә ул миңа? Ярый, мин киттем. *(Китә.)*

Х ө р м ә т у л л а. Мөгаен, бу каһәр берәр кыз янына бара торгандыр. Ну усал да, хәйләкәр дә минем бу каениш. *(Китә.)*

Бераздан М и р з а х а н керә. Күпер янына килә.

М и р з а х а н *(әкрен генә)*. Савелий Назарич, син андамы?

С а м с о н о в *(күпер астыннан башын сузып)*. Биредә...

М и р з а х а н. Мә, сиңа пычак. Әнә ул килә... Бар, урыныңда бул!..

Самсонов күпер астына төшеп китә. Мирзахан янгын сүндерү машиналары арасына яшеренә. М и р в ә л и кереп сәхнә аша үтеп барганда, күпер астыннан С а м с о н о в чыгып һөҗүм итә.

М и р в ә л и. Кем ул? Якын килмә! Ташла пычагыңны!.. *(Самсоновны сугып ега.)*

М и р з а х а н. Әй, халык, ярдәмгә килегез!..

Самсонов яңадан һөҗүм итә башлый. Мирзахан килеп аңа арт ягыннан ата.

М и р в ә л и. Мирзахан, син нишләдең?

М и р з а х а н. Беләсеңме, Мирвәли абый, ул кем? Элекке урядник Самсонов.

С а м с о н о в *(нидер әйтергә теләп)*. Биктимиров, ул мине...

М и р з а х а н. Әле син тончыкмадыңмыни, сволочь! Менә сиңа, мә!.. *(Тагын ата.)*

М и р в ә л и. Нигә син аны аттың, нигә үтердең?

М и р з а х а н. Мин синең җаныңны саклап калырга теләдем. Мирвәли абый.

М и р в ә л и. Юк. Ул нидер әйтергә теләгән иде, син аңа ирек бирмәдең.

Төрле яклап кешеләр кереп тула.

Х ә й б у л. Нәрсә бар, бу нинди мылтык тавышы?

М и р з а х а н. Менә Самсонов, пычак белән, Мирвәли абыйга һөҗүм иткән иде, мин ул этне атып үтердем.

Х ә й б у л. Туктагыз әле, һавада бу нинди яктылык?..

М и р в ә л и. Кайдадыр пожар.

М и р з а х а н. Безнең каралтылар яна!..

Х ә й б у л. Ут бар, ут бар!! *(Йөгереп китә.)*

Калганнар кычкырышып таралалар. Шашкан кыяфәттә күпер астыннан Н у р г а л и чыга. Өс-башларын каккалый, маңгай тирләрен сөртә. Х ө р м ә т у л л а килеп чыга. Нургалигә карап тора.

Н у р г а л и. Барысы өчен, барысы өчен дә, бу минем изге үчем!..

Х ө р м ә т у л л а. Их, каениш, шушымыни синең балык тотуың?

Н у р г а л и. Май кап, җизни... Әйдә машинаны чыгарыйк, башкаларга капмасын.

Янгын сүндерү машинасын чыгара башлыйлар. Янгын көчәйгәннән-көчәя бара. Төрле яклап сәхнәгә халык кереп тула. Парадный ишегеннән йөгерешеп м у л л а л а р, х ә л ф ә л ә р, ш ә к е р т л ә р чыгалар.

*Пәрдә.*

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Икенче кисәкнең соңгы пәрдәсендә күренгән волость правлениесенең эче. Тышта таң атып килә. Авыл вәкилләре белән үткәрелә торган волость крестьян җир комитетының утырышы бара. Президиумда А р т а м о н о в, М и р в ә л и, М и р з а х а н, С о к о л о в. Трибунада Ходаяр нотык сөйли. Артамонов председательлек итә.

Х о д а я р. Беренче булып без, социал-революционерлар, сезгә программа төзедек, без үк башлап алпавыт җирләрен керәстиәннәргә бүлеп бирергә дип кычкырдык.

Х ә й б у л. Кычкыргансыздыр, анысына ышанабыз. Тик менә бүген шуны нигә соң тормышка ашырмыйсыз?

Х о д а я р. Һәрнәрсәнең җае-вакыты бар, көтегез, сабыр итегез, «сабыр иткән морадына җиткән» дигән бабайлар. Гражданнар! Безгә мөстәбит патша заманында бүгенге шатлыклы көнне, ирекле тормышны, бер тәүлеккә сузылган менә шундый җыелышлар ясауны күрергә мөмкин идеме? Юк! Мең мәртәбә, миллион мәртәбә юк! Карасагызчы бу саф һавага, карасагызчы очсыз-кырыйсыз далага, карасагызчы мәңге яшел булып торган нарат, чыршы урманнарына...

А р т а м о н о в. Иптәш оратор! Куелган регламент өстенә ике тапкыр яртышар сәгать вакыт сорап алдыгыз, ә шулай да сүзегезнең очы-кырые күренми. Шуның өчен мин сезне туктатам.

Г а й н а в а л. Дөрес, Мироныч! Без монда аның төче сүзләрен тыңларга килмәдек. Ул безгә җир бирү-бирмәү турында сөйләсен. Сөйләми икән, юкка төкерек чәчмәсен!

Х о д а я р. Азат ителгән илдә, шәхес иреклеген, демократия хокукларын чикләвегезгә каршы мин өяз социалист-революционерлар комитеты һәм өяз милли шура исеменнән протест белдерәм!

Г а й н а в а л. Белдер, белдер әйдә, тик, зинһар, сөйләмә генә.

А р т а м о н о в. Сүз Таштугай авыл комитеты председателе Биктимер Шамкаевичка бирелә.

Б и к т и м е р. Җәмәгать! Мин бүген тыңлап утырдым, утырдым да шундый бер уйга килдем, ялгышсам төзәтерсез, Вакытлы хөкүмәт алдар таздан да болайрак булып чыкты түгелме? Учредительное собраниене 17 нче сентябрьдә була дип бер алдады. Октябрьда була дип икенче алдады. Инде хәзер билгеле булмаган вакытка кичектереп, тагын безне алдарга тели. Минем сезгә бер соравым бар: кайчан инде бу алдау-алданууларның бер чиге була? Алар безгә бүген дә түзәргә, булмаган учредительное собраниене көтәргә кушалар. Сигез айдан бирле көтә-көтә өтеккә калып беттек инде, җәмәгать! Өскә кияргә кием калмады, иске капчыкларны сүтеп күлмәк-ыштан тегәбез. Шул да булдымы хөкүмәт?

А р т а м о н о в. Шуның белән сөйләүләрне бетерәбез. Тәкъдим өчен сүз губерна Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советы һәм волость большевиклары исеменнән Мирвәли Биктимировка бирелә.

М и р з а х а н. Ни өчен аңа? Башта безнең тәкъдим, социалист-революционерлар тәкъдиме булырга тиеш.

Х ө р м ә т у л л а. Шулай шул. Нигә чират бозасыз?

Х ә й б у л. Кем соң ул «сез»?

Х ө р м ә т у л л а. Кем булсын? Билгеле инде, игенчеләр.

Х ә й б у л. «Игенчеләр» бик төрле шул, җизнәкәй. Менә мин дә игенче, син дә игенче... Тик синең белән минем арада таудай аерма бар, дисәңче.

С о к о л о в. Правильно, Хәйбулка! Вакытны бушка уздырмагыз, сүзне Биктимировка бирегез.

М и р в ә л и. Иптәшләр! Бөтен шәһәрләрдә, барлык завод-фабрикаларда большевиклар партиясе җитәкчелеге астында «Долой сатлык социалист министрлар, бетсен сугыш, бөтен власть Советларга!» дигән лозунглар белән эшче-солдат массалары урамнарга чыктылар. Без-крестьяннар да эшче-солдат иптәшләрнең ташкынына кушылып, «Долой волость аппаратларына кереп урнашкан буржуа балалары!» дибез.

М и р з а х а н. Долой немец шпионнары!

М и р в ә л и. Долой контрреволюционерлар!

М и р з а х а н. Долой Ватан хыянәтчеләре!

М и р в ә л и. Долой империализм ялчылары!

А р т а м о н о в. Гражданнар, тәртипкә чакырам! Иптәш Биктимиров, дәвам итегез.

М и р в ә л и. Вакытлы хөкүмәтнең арендага җир сату, җир алу турында чыгарган закон проектына каршы протест белдереп, волостьтагы алпавыт, чиркәү, монастырь җирләрен бүгеннән бөтен халыкныкы дип игълан итәбез. Икенче: махсус кулллардан алынган җирләр белән идарә итүне халыкның үзе сайлап куйган демократик оешмаларына тапшырабыз. Өченче: илдә икмәккә кытлык бар чакта, алпавыт Кригер урган ашлыкларын җыйдырмыйча, басуында черетә. Тизлек белән шуларны җыеп алуны авыл комитетларына тапшырабыз.

С о к о л о в. Дөрес, Биктимиров.

Х ә й б у л. Күптән шулай кирәк иде.

А р т а м о н о в. Икенче тәкъдим өчен сүз волость крестьян комитетының председателе Аюхановка бирелә.

М и р з а х а н. Мин тәкъдим ясаудан баш тартам.

А р т а м о н о в. Ул чагында, димәк, беренче тәкъдимгә кушылып тормышка ашыруны өстегезгә аласыз?

М и р з а х а н. Без үз фикеребезне төштән соң ачылачак волость крестьян съездында әйтербез. Хәзергә минем андый вәкаләтем юк.

Л а ш м а н о в керә.

Л а ш м а н о в. Мирзахан Шаулиханович, сезне телеграфка чакыралар.

Лашманов белән Мирзахан китә.

А р т а м о н о в. Тавышка куям, кем дә кем Мирвәли Биктимиров керткән тәкъдимнәргә риза, шул кешеләр кулларын күтәрсеннәр. *(Күпчелек кул күтәреп тавыш бирә.)* Төшерегез. Кемнәр каршы? Дүрт кеше. Ә сез, Ходаяр әфәнде?

Х о д а я р. Мин воздержаться итәм.

А р т а м о н о в. Димәк, Мирвәли Биктимиров тәкъдиме үтте. Шуның белән волость җир комитетының авыл вәкилләре белән үткәрелгән җыелышын ябык дип белдерәм.

М и р в ә л и. Иптәшләр! Авылларга кайту белән җыен җыеп, волость җир комитетының карарларын халыкка аңлатыгыз һәм шуны тормышка ашыру өчен тиешле чараларны күрегез. Гайнавал җиңги, әти, тышта мине көтегез, бер-ике сүзем бар.

Халык тарала. Артамоновка телеграмма кертеп бирәләр.

А р т а м о н о в. Мирвәли, иптәш Вавиловтан телеграмма.

М и р в ә л и. Нәрсә яза?

А р т а м о н о в. Тыңла, укыйм: «Петроградта урам сугышлары бара, матрослар «Аврора»дан Кышкы сарайга аталар, дип губерна шәһәреннән хәбәр итәләр. Безнең өяздә дә Кызыл Гвардия отряды төзелде. Шәһәрне саклау эше аларга тапшырылды. Кыю хәрәкәт итегез».

М и р в ә л и. Димәк, Гриша, без бүгенге көн тәртибен дөрес һәм вакытлы куйганбыз.

А р т а м о н о в.Әйе, Мирвәли, тик аны безгә тормышка ашырасы гына бар. Мин хәзер мондагы хәлләр турында иптәш Вавиловка телеграф белән белдерәм дә, Петроградта барган вакыйгалар турында аракы заводы эшчеләренә хәбәр итәргә китәм.

М и р в ә л и. Яхшы, Гриша, мин лесопильный завод эшчеләрен күтәрергә барам!

Чыгып китәләр.

К р и г е р керә. Кулына кәгазьләр тотып бүлмәдән Л а ш м а н о в чыга.

К р и г е р. Илья Петрович, мин сезгә килгән идем.

Л а ш м а н о в. Сөйләгез, Василий Робертович.

К р и г е р. Миңа киңәш бирегез, нишлим? Имениедәге эшчеләрем сигез сәгатьлек эш вакыты таләп итәләр. Хәтта пленный солдатларыма кадәр, собрание ясап, үз араларыннан комитет сайлап куйдылар.

Л а ш м а н о в. Ул хәл сездә генә түгел, Василий Робертович, бөтен илдә хәзер шундый анархия хөкем сөрә.

К р и г е р. Шулай да соң миңа нишләргә, әйтегез?

Л а ш м а н о в. Берни дә әйтә алмыйм, чөнки хәзер илдә закон да, власть та юк. Һәркем үз белгәненчә эш итә.

К р и г е р. Председателегез кайда, үз бүлмәсендәме?

Л а ш м а н о в. Юк, ул телеграфта утыра. Минемчә, ул да сезгә төпле бер киңәш бирә алмас. Гафу итегез, мине анда көтәләр.

К р и г е р. Бер генә минутка.

Л а ш м а н о в. Кичерегез, вакытым юк. Озакламый безнең съезд башлана. *(Китә.)*

Кәгазьләр тотып Х ө р м ә т у л л а керә.

Х ө р м ә т у л л а. Исәнме, барин?

К р и г е р. Мин нинди «барин» булыйм? Кайчан минем белән сөйләшергә дә теләмиләр!

Х ө р м ә т у л л а. Менә сиңа, мә! Ничек эндәшергә соң?

К р и г е р. Теләсәң ничек. Тик «барин» сүзе белән генә хурлама. Син миңа килеп чык әле. Миндә сиңа коммерция бар.

Х ө р м ә т у л л а. Бүген вакытым юк, иртәгә, бәлки, барып чыгармын.

К р и г е р. Иртәгә соң була. Мин бүген китәм.

Х ө р м ә т у л л а. Кая?

К р и г е р. Кая икәнен үзем дә белмим, ләкин бу хаостан башымны алып качмый чарам юк.

Х ө р м ә т у л л а. Минем үземнең дә эшләр бик шәптән түгел шул, барин-гражданин.

К р и г е р. Нишләп алай?

Х ө р м ә т у л л а. Губернадан комиссия килде, тикшерәләр.

К р и г е р. Хәзергә кооперациядә председатель синдер бит?

Х ө р м ә т у л л а. Мин дә. Очырырлар, ахры...

К р и г е р. Шулай да килеп чык әле. Мин сиңа әйберләремне сатарга уйлыйм.

Х ө р м ә т у л л а. Нинди әйберләреңне?

К р и г е р. Баргач әйтермен.

Х ө р м ә т у л л а. Ярый, ярый, барин-гражданин, ул чагында әбәзәтельне барырмын.

Кригер эчкә кереп китә. Мадьяр солдатын җитәкләп тышкы ишектән З ә м з ә м б а н у керә.

З ә м з ә м б а н у. Нихәл, кияү, исәнме?

Х ө р м ә т у л л а. Исән, исән, җиңгәчәй... үзең нихәл соң?

З ә м з ә м б а н у. Ал да гөл кебек.

Х ө р м ә т у л л а. Нишләп монда йөрисең?

З ә м з ә м б а н у. Мирвәли абый янына киңәшкә килгән идем. Такта яручылар янына киткән. Мироныч та өйдә юк. Айсылу җиңги дә Твардовский утарыннан кайтмаган. Киңәшергә кеше табалмый йөрим.

Х ө р м ә т у л л а. Нинди киңәш иде соң?

З ә м з ә м б а н у. Бүген иртән утарда эшләүчеләр исеменнән сигез сәгатьлек эш вакыты, хезмәт хакыбызны арттыруны сорап баринга кергән идек, куып чыгарды.

Х ө р м ә т у л л а. Тукта әле, тукта, син кем соң?

З ә м з ә м б а н у. Ишетмәдеңме? Мин бит хәзер зур нәчәл.

Х ө р м ә т у л л а. Нинди нәчәл?

З ә м з ә м б а н у. Беркөнне Айсылу җиңги безнең утарга килеп, конторщик Дарафийны председатель, ат караучы Аркашаны секлетарь, мине челән итеп сайлатты. Менә шул җыен белән сайлап куйган комитетның законнарын танымаска маташа.

Х ө р м ә т у л л а. Алай... Син дә комитет булдым диң, җиңгәчәй, ә?

З ә м з ә м б а н у. Әйе, кияү, Аллага шөкер, булдым. Мирвәли абый белән Айсылу җиңгигә рәхмәт инде, алар мине бу дәрәҗәгә мендерде.

Х ө р м ә т у л л а. Егылып төшмәсәң ярый инде.

З ә м з ә м б а н у. Юк, кияү, төшмәм, бай белән буржуйга хәзер чытырман кебек ябышам. Җитәр инде, бик күп каныбызны эчтеләр.

Х ө р м ә т у л л а. Бу пленный нишләп йөредә?

З ә м з ә м б а н у. Минем белән язылырга килде.

Х ө р м ә т у л л а. Кайсы партиягә?

З ә м з ә м б а н у. Ничек кайсы партиягә?

Х ө р м ә т у л л а. Кемнәр партиясенә языласыз дим?

З ә м з ә м б а н у. Һи... Миңа тагы партиягә язылу. Менә шул астри-мажар солдатына кияүгә чыктым.

Х ө р м ә т у л л а. Кияүгә чыктың?

З ә м з ә м б а н у. Әйе. Гыйльман мулла, никах укырга, башта волостьтан язу китер, ди.

Х ө р м ә т у л л а. Соң бит алар безнең диндәге халык түгел, аның белән нинди никах укытасың?

З ә м з ә м б а н у. Ул үзе диннәрнең берсенә дә ышанмый, минем өчен барыбер, ди.

Х ө р м ә т у л л а. Еллар иминләнгәч кайтып китсә?

З ә м з ә м б а н у. Юк, китми, монда кала. Үз илендә аның беркеме дә булмаган, мондагы кебек алпавытта эшләп торган.

Х ө р м ә т у л л а. Чиләгенә күрә капкачы да табылган. *(Китә.)*

Л а ш м а н о в үтеп бара.

З ә м з ә м б а н у. Илья Петрович, мин менә бу кешегә кияүгә чыктым, никах укытырга язу сорыйлар.

Л а ш м а н о в. Тапкансыз икән өйләнешеп йөрер чак. Мондый мажара көннәрендә нинди никах ди ул?

З ә м з ә м б а н у. Кемгә ничек бит? Берәүләргә мажара, икенче берәүләргә дөнья яңара. Язып бир инде.

Л а ш м а н о в. Барыгыз, коридорда көтегез. Әнә председатель килә.

Зәмзәмбану белән мадьяр солдаты китә. М и р з а х а н керә.

М и р з а х а н. Ходаяр кайда?

Л а ш м а н о в. Минем бүлмәдә. Басарый белән шашка уйнап утыралар.

М и р з а х а н. Чакыр әле үзләрен.

Лашманов китә. Ходаяр белән Басарыйны ияртеп керә.

М и р з а х а н. Дусларым! Безнең өчен зур шатлык. Хәзер генә өяз белән сөйләштем, икмәк хәзерләү сылтавы астында безнең волостька бер взвод кавалерия җибәргәннәр.

Б а с а р ы й. Бер взвод кавалерия?

М и р з а х а н. Озакламый алар монда килеп җитәчәк.

Х о д а я р. Яхшы хәбәр, Илья Петрович, ә?

Л а ш м а н о в. Әйтәсе дә юк. Димәк, Касыймхан Шаулихановичның өязгә баруы нәтиҗәсез калмады. Тик ул солдатларны кая урнаштырырбыз икән?

М и р з а х а н. Бүгенгә школада кундырырбыз. Иртәгәдән Твардовский имениесенә күчерербез. Илья Петрович, ашау-эчү, урын-җир әзерләүне сиңа тапшырам. Ә сез, Ходаяр әфәнде, комиссар булып, алар арасында тәрбия эшләрен алып барырсыз. Аннан, мин сезгә шуны әйтергә тиеш, Касыймхан абый анда Мирвәли белән Артамонов мәсьәләсен дә хәл кылган, бүген үк үзләрен кулга алып, өязгә җибәрергә кушалар.

Л а ш м а н о в *(кулларын уып)*. Менә бу эш булыр, ичмасам…

М и р з а х а н. Басарый, хәзер үк белешеп кил, Мирвәли белән Артамонов кайда икән? Өйләрендә булсалар, кешеләреңне, олауларыңны хәзерләп куй. Кулга алырбыз да өязгә озатырбыз... Аңлашыламы?..

Б а с а р ы й. Бик аңлашыла...
М и р з а х а н. Аңлашылса барыгыз, эшегездә булыгыз.

Мирзахан белән Лашмановтан башкалар китәләр.

Илья Петрович, делегатлар, руханилар ничек, киләме?
Л а ш м а н о в. Әкренләп җыелалар. Тик шул кадәресе бар, собраниеләр ясап түгел, элекке Тамбов губернаторы Богданович әйтмешли, «ут белән хәрәкәт итәргә» иде.
М и р з а х а н. Ул бик искергән, тупас метод, Илья Петрович.
Л а ш м а н о в. Крестьян белән башкача мөмкин түгел. Хәзер генә Спасово авылының приговорын китерделәр. Бөтен авыллары белән Твардовский җирләрен бүлеп бирүне таләп итәләр. Минемчә, әнә шул өяздән килә торган кавалерия көче белән...
М и р з а х а н. Без бит монархистлар түгел, коалицион социалистлар. Ул кара халык аңсызлык аркасында гына большевиклар артыннан бара. Без аларга аңлатырга тиешбез.
Л а ш м а н о в. Әгәр дә алар аңларга теләмәсәләр?
М и р з а х а н. Ул чагында күз күрер. Шулай, иртәгәдән мәчет, чиркәү мөнбәрләрен файдаланабыз.

Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Керергә мөмкинме?
М и р з а х а н. Гөлчирә?..
Г ө л ч и р ә. Шулай да таныдың?
М и р з а х а н. Сине танымаска мөмкинме соң, күз нурым... Рәхим итегез, утырыгыз. Шулай диң, Гөлчирә... Кунакка кайттыңмы?
Г ө л ч и р ә. Юк, Каргалы волостена, балаларга чәчәк салырга барышым.
М и р з а х а н. Син кем соң?
Г ө л ч и р ә. Медицина сестрасы.
М и р з а х а н. Син сестра?
Г ө л ч и р ә. Әйе, Каргалы волостенда чәчәк эпидемиясе башланган. Губерна Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатларының карары буенча барам. Менә минем документларым. Каргалыга чаклы олау бирегез.
М и р з а х а н. Илья Петрович, хәзер үк минем пар атымны җиксеннәр. Менә бу иптәшне Каргалыга илтеп куярлар.
Л а ш м а н о в. Яхшы, мин хәзер әйтәм. *(Китә.)*
Г ө л ч и р ә. Бу патша этен нигә монда тотасыз?
М и р з а х а н. Алыштырырга кеше таба алмыйбыз. Я, Гөлчирә, безнең балабыз ничек, үсәме?

Г ө л ч и р ә. Сиңа нигә ул?

М и р з а х а н. Ничек инде ул «нигә»? Мин бит аның атасы.

Г ө л ч и р ә. Әйе, үкенечкә каршы, атасы... Ләкин бит чын аталар балаларының муеннарына муенчак салмыйлар.

М и р з а х а н. Аның белән мине әрнетмә син, Гөлчирә. Искән җил белән аккан суны кире кайтарып булмаган кебек, үткән кара көннәр шәүләсен искә төшерүдән дә файда юк. Чөнки алар юләр яшьлек булып күптән инде еракларга актылар.

Г ө л ч и р ә. Әйе, актылар... Ләкин бит алар, синең үз шигырең белән әйткәндә, «безнең йөрәкләргә мәңге сүнмәс нәфрәт утлары яктылар...»

М и р з а х а н. Анда минем гаебем юк. Мин ул чакларда, бөтен кабахәтлекне эченә җыючы, кешеләр бәясен бакыр тиеннәр белән үлчәп йөртүче иске тормыш корбаны, ата-анамның кызганыч колы идем.

Г ө л ч и р ә. Бичара... Шулай да, мин әйтәм, атаңның креслосында озак утырасың. Варислыкны бик ныклап алгансың, ахры.

М и р з а х а н. Гафу итегез, алмадым. Аны миңа революция, халык тапшырды.

Г ө л ч и р ә. Ышанам, халык тапшыргандыр. Ләкин сигез айлык гомереңдә шул халык өчен, революция өчен нәрсә эшләдең?

М и р з а х а н. Кызык сорау. Шулай ук соң, безнең эшебездә бер дә үзгәреш юкмыни?

Г ө л ч и р ә. Юк димим, бар, әлбәттә. Революция бик күпләрнең күзен ачып, алдагы бөек көрәшкә халыкны туплады. Әмма сезнең эшегездә бернинди дә үзгәреш күренми. Атаң заманында менә монда Николай патша портреты торса, хәзер инде аның урынына Керенскийны асып куйгансыз. Ясаган үзгәрешегез бары шул гына.

Л а ш м а н о в керә.

Л а ш м а н о в. Атлар җигелде, чыгып утырыгыз.

Г ө л ч и р ә. Мин хәзер. *(Чыгарга җыена.)*

Лашманов китә.

М и р з а х а н. Гөлчирә, без бүген тәмам аңлашырга тиешбез.

Г ө л ч и р ә. Минем сүзләремдә аңлашылмаслык берни дә юк шикелле.

М и р з а х а н. Мин ул турыда түгел. Шәхси тормышыбыз турында әйтәм. Чөнки мин үземне, синең каршыңда, алдакчы кеше

итеп калдырасым килми. Сиңа булган мәхәббәтемнең сафлыгын исбат итәргә телим. Аерыл син ул иреңнән, бала ятим үсә бит.

Г ө л ч и р ә. Синең кебек ата этнең ярдәменә мохтаҗ түгел ул!.. *(Китә.)*

Б а с а р ы й керә.

Б а с а р ы й. Бу нишләп тагын синең янында йөри.

М и р з а х а н. Шаярма, ул хәзер зур кеше. Медицина сестрасы булган. Биктимер балалары менә кая үрмәли. Я, ничек, белдеңме?

Б а с а р ы й. Белдем. Икесе дә каядыр чыгып киткәннәр.

Артта солдатлар җырлаганы ишетелә.

Әнә солдатлар килеп тә җиттеләр!

М и р з а х а н. Бар, яхшылап каршы алыгыз. Ходаяр ялкынлы нотык сөйләсен.

Басарый китә. Солдатлар җыры якыная. М и р з а х а н тәрәзәгә бара.

Шәһәрдән безгә кораллы көч килә, көч кенә түгел, авылдагы большевизм чиренә каршы үч килә!..

Йөгереп Х о д а я р керә.

Х о д а я р. Мирзахан, ярдәмгә җибәрелгән атлы взводның командиры безнең авылның Нургали булып чыкты!

М и р з а х а н. Биктимер Нургалиеме?

Х о д а я р. Шул — үзе, эшләр начар бит!

М и р з а х а н. Кайгырма. Абыйсына каршы фикердәге кеше ул.

Кавалеристларча киенгән Н у р г а л и керә.

Чыннан да, үзебезнең Нургали абый икән...

Н у р г а л и. Исәнме, Мирзахан.

М и р з а х а н. Бик яхшы, Нургали абый, әйдә, рәхим ит, утырыгыз.

Н у р г а л и. Рәхмәт. Безнең Мирвәли абый, Айсылу җиңгиләр әле һаман сездәме?

М и р з а х а н. Әйе, бередә, бергә эшлибез. Мирвәли абый бездә губерна Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советының вәкиле булып эшли. Айсылу апа авыл хуҗалыгы эшчеләренең союзын

оештырып йөри. Әле сезнең Гөлчирә дә бирεдә иде. Яңа гына үзен Каргалыга озаттым.

Н у р г а л и. Шулаймыни? Ул нигә килгән?

М и р з а х а н. Балаларга чәчәк салырга җибәргәннәр. Я, Нургали абый, шәһәрдә ниләр бар?

Н у р г а л и. Подробно әйтә алмыйм, чөнки мин Суык-Суда идем, бүген иртән аннан кайтып төшү белән монда чыгарга приказ бирделәр. Шулай да кичәдән бирле шәһәр Советында бик җәнҗаллы собрание бара, дип сөйләделәр.

М и р з а х а н. Сез инде, Нургали абый, үз бурычыгызны аңлый торгансыздыр, авылларда икмәк хәзерләү белән бергә крестьян арасындагы тәртипсезлекләрне бетерү вазифасы да сезнең өскә йөкләнгән.

Н у р г а л и. Конечно. Без бит революциягә, Вакытлы хөкүмәткә ант иткән революцион солдатлар.

Ә х т ә р и йөгереп керә.

Ә х т ә р и. Мирзахан!.. *(Нургалине күреп сүзеннән туктап кала.)* Кияү кайткан икән, исәнме, сау кайттыңмы, кияү балакай?

М и р з а х а н. Әхтәри абзый, син нидер әйтергә теләгән идең.

Ә х т ә р и. Ә... Әйе, Кригерны талыйлар.

М и р з а х а н. Кемнәр?

Ә х т ә р и. Башлап безнең авыллар чыктылар. Алардан күреп Каенсар, Спасово авыллары килеп җиттеләр. Ахырзаман анда, кыямәт, үзара талаш, кычкырыш бара!..

М и р з а х а н. Нургали абый, Ходаяр! Хәзер үк атлы взводны алып анда китегез. Ай-вайларына карамыйча атыгыз, башлап йөрүчеләрен тотып монда китерегез!..

Н у р г а л и. Яхшы... Әмерегез җиренә җиткерелгән булыр...

М и р з а х а н. Пуляларны кызганмагыз!..

Нургали белән Ходаяр китә. Артта команда тавышы.

Н у р г а л и. По коням... рысью марш!..

Ат аяк тавышлары ишетелә.

Ә х т ә р и. Әмма кызык булалар хәзер, аталы-уллы очрашалар.

М и р з а х а н. Ничек аталы-уллы?

Ә х т ә р и. Соң бит, Кригер көлтәләрен Биктимер карт ташыта.

М и р з а х а н. Биктимер?

Ә х т ә р и. Әйе, Нургали кияү алдында әйтмәдем. Моннан кайту белән җыен җыйды да халыкны басуга алып чыгып китте.

М и р в ә л и керә.

М и р в ә л и. Бу нинди кабахәтлек?
М и р з а х а н. Нәрсә булган?
М и р в ә л и. Халыкка каршы нигә кавалерия җибәрдең?
М и р з а х а н. Алар анда Кригерны талыйлар.
М и р в ә л и. Халыкка хыянәт итүең өчен, революция алдында җавап бирерсең!
М и р з а х а н. Син аларны котырттың, син аларга талау юлларын өйрәттең.
М и р в ә л и. Юк! Алар хәзер мин өйрәтмичә дә нәрсә эшләргә икәнен яхшы беләләр. Синең кебек икейөзле хаиннәрнең кая таба алып баруын да күрәләр. Әгәр дә синдә шул халыкка карата аз гына яхшы ният бар икән, солдатлар белән ике арадагы бәрелешне булдырмаска тиешсең. Әйдә, имениегә киттек.
М и р з а х а н. Мин үз тарафымнан тиешле булган чараны күрдем, калганы сезнең эшегез.

Әхтәри белән бүлмәгә кереп китәләр. Тышкы ишектән А р т а м о н о в керә.

А р т а м о н о в. Мирвәли, өяздән гаскәр килгән диме?
М и р в ә л и. Әйе, Гриша, килгән. Ләкин, Мирзахан аларны Кригер ашлыкларын ташучы крестьяннарга каршы җибәргән.
А р т а м о н о в. Ах, кара елан!
М и р в ә л и. Безгә хәзер ул солдатларны үз ягыбызга аударырга кирәк. Каян гына булса да син атлар тап, икәү хәзер шунда китәбез.
А р т а м о н о в. Почта атлары өйдә, мин хәзер килеп җитәрмен. *(Китә.)*

Бүлмәдән коралланып М и р з а х а н, Л а ш м а н о в, Б а с а р ы й һәм Ә х т ә р и л ә р чыга.

Б а с а р ы й. Урыныңнан кузгалма!
М и р в ә л и. Ни өчен?
М и р з а х а н. Революциягә хыянәт итүең өчен без сине кулга алабыз.
М и р в ә л и. Ах син, кабахәт!..
Б а с а р ы й. Күп сөйләнмә!..

Әхтәри Мирвәлинең арт ягыннан килеп тотып ала.

М и р з а х а н. Кул-аягын бәйләп подвалга ташлагыз!

Мирвәлине алып китәләр.

Л а ш м а н о в. Менә бу эш, ичмасам, күптән шулай кирәк иде аларга. Хәзер авыллардагы иярченнәрен дә утарга кирәк.

Ә х т ә р и керә.

Ә х т ә р и. Мирзахан, юкка гына син Басарыйны уңмаган дисең, молодец икән. Тегенең касыгына берне генә бирде, кискән агач кебек «дөп!» итеп егылды. Хи-хи-хи...

Б а с а р ы й керә.

Б а с а р ы й. Артамонов килә, нишлибез?
М и р з а х а н. Нәрсә сорап торасың, агач авыз? Нишләргә икәне әйтелгән бит сиңа!

А р т а м о н о в керә.

А р т а м о н о в. Мирвәли, атлар булды, әйдә, киттек!..
Л а ш м а н о в. Кая шулкадәр акырасың, горлапан?
М и р з а х а н. Мирвәлие янына монысын да төшереп ябыгыз!..
А р т а м о н о в. Якын килмәгез, еланнар!..

Төрлесен төрле якка сугып ега да тәрәзәдән сикерә.

М и р з а х а н. Тотыгыз, тот, качырмагыз!!

Мирзаханнан башкалар Артамонов артыннан китәләр.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Алпавыт Кригерның залы. Берничә ишек, идәндә паласлар, стенада трюмо, ау мылтыгы һәм портретлар. Тәрәзәләрдә пәрдәләр. Бер читтә пианино. Пәрдә ачылганда А н т о н и н а тәрәзәдән карап тора. Акимовна диванда ниндидер кул эше эшләп утыра.

А н т о н и н а. Нишләп кенә тора икән?..
А к и м о в н а. Кайгырма, Антонина, кайтыр әле.
А н т о н и н а. Ябып куймагайлары дип куркам.
А к и м о в н а. Курыкма, гаепсезгә япмаслар.
А н т о н и н а. Соңгы айларда аның нервлары бик какшады, бер

сүз әйтер хәлем юк, хәзер кабынып китә. Кичә күрдең ич, мельник Серафим белән нишләде? Минем белән сүз көрәштермә дип яңагына кундырды. Анда да, товарищлар белән сүзгә килеп, берәр нәрсә эшләп куюы бар.

Акимовна. Товарищлар белән алай кылана алмас. Серафимга суккан икән, барин түгеллеген онытып җибәргәндер. *(Пауза.)*

Антонина. Берәр нәрсә сөйлә, ичмасам.

Акимовна. Нәрсә сөйлим икән соң?

Антонина. Нәрсә булса да, миңа күңелсез...

Акимовна. И... Онытып торам икән, безнең Бобсик ашамаган бит. *(Китә.)*

Антонина пианинода күңелсез генә көй уйный, Кригер керә.

Кригер. Кемне көмәсең?

Антонина. Эчем пошып утыра идем. Я, ничек, сөйләштеңме?

Кригер. Әйе. Урамда гына председательләрен күрдем. Өяздән гаскәр чакыртканнар, килеп җитү белән сезнең имениене сакларга җибәрәбез, ди. Ләкин, мин аларга ышанмыйм. Чөнки волостной җир комитетларында безнең җир-суларыбызны бүләргә карар чыгарганнар.

Антонина. Революция булу белән китик дидем мин сиңа, Вася, тыңламадың.

Кригер. Дүрт буыннан бирле җыеп килгән дәүләт кызганыч иде шул. Инде хәзер китәргә мин дә риза.

Марк керә.

Марк Семеныч, кайда йөрисез?

Марк. Мине каравылчы Мирон чакырырга килгән иде, бардым, төрле авыллардан килгән крестьяннар егермеләп олауда җәен кискән әрдәнәләрне төяп урманнан чыгып киләләр. Алдагы атларының башыннан тотып, йөкләрен бушатырга кушкан идек, кая ул, балталарын күтәреп килә башладылар, көчкә качып котылдык. Каравылчы Мироны да хәзер «башка кеше алыгыз, барин өчен үләр хәлем юк» ди. Нишлибез, барин?

Кригер. Ут төртеп яндырырга, аларга да, безгә дә булмасын!

Антонина. Вася, син алай кызма, тагын мигренең кузгалыр.

Кригер. Марк Семеныч, бүген безгә берничә җигүле ат хәзерлә, китәбез.

Марк. Ә имение?

Кригер. Затлы әйберләрне үзебез белән алабыз, мал-туарларны сатабыз.

М а р к. Белмим шул, барин, кем генә алыр икән?

К р и г е р. Волость кооперациясе ала. Барыгыз, яхшы атларны хәзерләгез.

Марк китә.

Әйдә, Антонина, әйберләрне җыйнап хәзерләник.

Китәләр. М ө р ш и д ә белән Х ө р м ә т у л л а керәләр.

М ө р ш и д ә. Нигә беркем дә күренми?

Х ө р м ә т у л л а. Теге якта, җыена торганнардыр.

М ө р ш и д ә *(әйләнә-тирәне караныл).* Әй, байлык, әй, байлык. Каян килгән бу байлык?

Х ө р м ә т у л л а. Каян булсын? Бар да безнең крестьян көченнән.

М ө р ш и д ә. Кая соң алар китәләр икән?

Х ө р м ә т у л л а. Германиягә.

М ө р ш и д ә. Нигә, алар немечләрмени?

Х ө р м ә т у л л а. Нинди генә әле... Дүртенче бабалары Пугачев явын бастыруда эш күрсәткән икән, шуннан Әби патша боларның бабаларын дворян ясап, безнең бабайларның җирләренә утырткан.

М ө р ш и д ә. Хөрмәтулла, менә бу күкеле сәгате белән зур көзгесен сатмас микән?

Х ө р м ә т у л л а. Әй, калдыр әле, андый ялтыравыклы әйберләргә кызыкма! Син менә теге нәсел сыерларын, яхшы атларын, әйбәт иген коралларын очсызрак бирсә иде, диң.

М ө р ш и д ә. Бирми кая барыр? Барыбер бит аларны талыйлар. Әнә кичә Танай баярының бер әйберен калдырмыйча ташыганнар. Их, мин әйтәм, бу әйберләрне ак өйгә куеп җибәрсәң, бөтен дошманнарның йөрәге янар иде. Син сорап кара әле, Хөрмәтулла, яме?

Х ө р м ә т у л л а. Бәяләрен бик кыйбат куймаса, сорармын.

М ө р ш и д ә. Кара әле, сиңа әйтәм. Менә бу идәндәге паласны да сатмасмы? Карт хәзрәтләрнеке кебек бөтен түрне иңләтеп җәеп җибәрер идек, ә?

Х ө р м ә т у л л а. Син бигрәк инде, берьюлы баерга уйлыйсың.

М ө р ш и д ә. Туры килгәндә файдаланып калырга кирәк. Ялан да ялан революция булмас бит.

Х ө р м ә т у л л а *(пианино янына утырып).* Менә бу малны мин алыр идем.

Клавишларын баскалап карый.

М ө р ш и д ә. Мирвәли абыйлардагы әргән икән.

Хөрмәтулла бер бармак белән «Әпипә» көен уйный. К р и г е р керә.

К р и г е р. А... Килдеңме?

Х ө р м ә т у л л а. Әйе, барин-гражданин, килдем.

К р и г е р. Мин сиңа, имениедәге бөтен мал-туарларны, иген коралларын сатарга булдым.

Х ө р м ә т у л л а. Ул кадәр акча миндә юк бит, барин-гражданин.

К р и г е р. Миңа акча кирәкми. Син миңа волость кооперациясе исеменнән язу гына бир. Печатең үзең беләнме?

Х ө р м ә т у л л а. Конешно, үзем белән, менә ул!

К р и г е р. Ул чагында мин договорны язам.

Х ө р м ә т у л л а. Яз, яз, барин-гражданин. *(Кригер китә башлый.)* Әй, барин, тукта әле. Син миңа, менә бу бүлмәдәге әйберләреңне дә сат инде, мин алар белән кабинетымны бизәп җибәрер идем.

К р и г е р. Ярый, аларны да алырсың. *(Китә.)*

М ө р ш и д ә. Нәрсә ди ул, сиңа әйтәм?

Х ө р м ә т у л л а. Шаулама, хатын, булды бу. Өй җиһазларын да бушлай бирәм, ди.

М ө р ш и д ә. Ничек инде ул бушлай?

Х ө р м ә т у л л а. Акча сорамый. Кул куйган кәгазь генә бирерсең ди.

М ө р ш и д ә. Син кул куйган кәгазь белән нишләмәкче була икән?

Х ө р м ә т у л л а. Немец бит ул, хәйлә корып маташа. Үзенчә иске режимның кайтуын өмет итә. Соңыннан бездән түләтергә чамалый. Ялгышасың, барин! Николай патшаның кире кайтуы утють инде ул хәзер.

М ө р ш и д ә. Бүген төшемдә ак җәймә белән зур-зур балыклар тотканыңны күргән идем, дәүләт, байлык килергә булган икән.

Кәгазь тотып К р и г е р чыга.

К р и г е р. Булды бу. Әйдә, укып чык та кулыңны куй.

Х ө р м ә т у л л а. Укымыйча да куям. *(Кулын куеп, печатен баса. Берсен үзенә ала.)* Әйдә, Мөршидә, тизрәк олаулар алып килик.

Китәләр. Сакал-мыеклары җиткән, өстенә начар киемнәр кигән Ш ә ү л и х а н керә.

К р и г е р. Боже мой! Шәүлихан Алимханович, мин сезне бу кыяфәттә күрермен дип уйламаган идем.

Ш ә ү л и х а н. Кардәш-ыругларыннан аерылган, уллары тарафыннан кагылган кеше башкача ничек булсын соң? Мин хәзер Янбакты авылындагы сеңелемә барган идем, капкаларыннан да кертмәделәр. «Өйдә юклар» дип хезмәтчеләреннән әйттерделәр. Василий Робертович, мине сыйлагыз әле.

К р и г е р. Сез бит эчкәнсез инде.

Ш ә ү л и х а н. Сеңелемә ачу итеп кайтышлый чуаш авылында пальтомны самогонга алыштым. Беләм, минем килүемне сез дә яратмыйсыз. Нишлисең, иске дус итеп кердем. Тизрәк җибәрәсегез килсә, сыйлагыз мине.

К р и г е р. Каян алыйм? Янәшә-тирәдәге спирт заводларын таладылар.

Ш ә ү л и х а н. Заводларны гына түгел, мине дә алар менә нинди хәлгә калдырдылар... Ярый, синдә булмаса, миндә бераз бар әле. *(Кесәсеннән калган аракылы шешәсен чыгара.)* Әйдә, утыр, эчәбез.

К р и г е р. Беләсез бит, мин эчмим.

Ш ә ү л и х а н. Мин дә хәзер эчә алмыйм, бер-ике рюмка җибәрүгә исерәм... *(Салып эчә.)* Йөрәк начарланды, Василий Робертович, кайвакытта тибүеннән туктап куйгалый... Әйе, дәрәҗәң беткәч, беркемнән дә ярдәм көтмә икән. Балалар гына түгел, хәтта кырык ел бергә гомер иткән карчыгым да хәзер үз янына яткырмый. Беләсеңме, мин хәзер кайда йоклыйм? Түбән өйдә, хезмәтчеләр янында... *(Калган аракысын салып эчә.)* Василий Робертович, сез акыллы кеше, миңа әйтегез әле, бу ыгы-зыгылар нидән килеп туды соң?

К р и г е р. Безнең патша булдыксыз кеше иде.

Ш ә ү л и х а н. Юк, мин сезнең ул сүзегез белән килешә алмыйм. Безнең Николай Александрович егерме елдан артык идарә итте. Беркем дә аны алай димәде, хәтта аның портретына карап табындылар. Кинәттән генә шул кеше яраксыз булып чыкты. Юк, болар бар да бозыклык... Эчеп бетерерләр алар Россияне...

К р и г е р. Кем белә, бәлки, эчмәсләр!

Ш ә ү л и х а н. Эчәрләр. Аптырагач кеше эчәргә сабыша. Ничек алар байларсыз, патшасыз, укыган кешеләрсез торырлар? Менә шуннан инде, җыйнаулашып эчәргә ябышырлар.

К р и г е р. Шәүлихан Алимханович, мин сезне...

Ш ә ү л и х а н. Китегез дисезме?

К р и г е р. Юк, мин сезне ат белән өегезгә илттереп куймакчы булам.

Ш ә ү л и х а н. Кирәкми, мин өйгә кайтмыйм. Волостька китәм, юлда очраган авыллардан кешеләр җыям да комитетларына һөҗүм итәм, таш өстендә таш калдырмый ватам, җимерәм, үзләрен асам, кисәм! Әйдә бергә китәбез.

К р и г е р. Хәзер түгел, бераздан. Утырыгыз әле, ял итеп алыгыз, аннан карарбыз.

Ш ә ү л и х а н. Сез мәшһүр пирсиян шагыйре Хафизны беләсезме?

К р и г е р. Әйе, яшь чагымда укыганым бар.

Ш ә ү л и х а н. Урта Азияне Россиягә кушканда, мин генерал Кауфманның тылмачы идем. Ул миңа һәрвакыт менә бу шигырьне укырга куша иде:

Ая сакый! Кадәхеңне мул тутырыш,
Күбекләнгән ялкын ширбәтең китер.
Тереклектән бизгән җаным өчен,
Көч бирерлек дәрманың китер.
Мин эчәрмен ул кәүсәрең,
Бар дөньяның шатлыгын кочыш.
Дәрт кабызсын арган йөрәгемә,
Кадәхеңнән сучаңлар очыш.

*(Гырылдап йокыга китә.)*

А н т о н и н а керә.

А н т о н и н а. Вася, әйдә инде, ул исерек белән юанма.

К р и г е р. Чү, йоклады...

А н т о н и н а. Йоклады?..

М а р к керә.

М а р к. Барин, басудагы ашлыкларны ташыйлар!

К р и г е р. Кемнәр?

М а р к. Таштугай крестьяннары.

К р и г е р. Куыш җибәрегез!

М а р к. Алар бик күп, бөтен авыллары белән килгәннәр.

К р и г е р. Әйдә алайса, икәүләп!.. *(Стенага эленгән ау мылтыгын ала.)*

А н т о н и н а. Йөрмә, Вася, без бит барыбер китәбез.

К р и г е р. Үз күз алымда гына булса да минем мөкатдәс милегемә кагылмасыннар! Бу башбаштаклыкның бер чиге булырга тиеш. Әйдә, Марк Семеныч!

Китәләр. Төен тотып А к и м о в н а чыга.

А н т о н и н а. Акимовна, син болай кая?

А к и м о в н а. Күчәм.

А н т о н и н а. Икенче бүлмәгәме?

А к и м о в н а. Юк, Спасово авылындагы сеңелемә күчәм.

А н т о н и н а. Димәк, безнең белән китмисең?

А к и м о в н а. Мин анда нишлим? Сезгә артык йөк булып йөримме?

А н т о н и н а. Юк, юк, мин сиңа рөхсәт итмим, синнән башка мин ничек яшәрмен?

А к и м о в н а. Өйрәнерсең, барыня, тормыш ул — рәхимсез судья, барысына да өйрәтә... Менә мин дә җитмеш еллык гоме-

ремнең илле елын сездә уздырган идем, ул тормыш бүген миңа сезгә ияреп йөрмәскә куша... Хушыгыз! *(Китә.)*

Шашкан кыяфәттә йөгереп К р и г е р керә.

К р и г е р. Боже мой, боже мой!.. *(Килеп диванга ава.)*

А н т о н и н а. Нәрсә булды, Вася, кыйнадылармы?

К р и г е р. Марк Семеныгны сәнәк белән чәнчеп үтерделәр!

А н т о н и н а. Сәнәк белән?..

К р и г е р. Миңа да ташланганнар иде, көчкә качып котылдым. Әйдә, Антонина, тизрәк тайыйк моннан.

Китә башлыйлар. Икенче ишектән сәнәкләр белән коралланган крестьяннар ияртеп Б и к т и м е р керә.

Б и к т и м е р. Туктагыз! Сабыр итегез, барин.

К р и г е р. Тагын сезгә ни кирәк?

Б и к т и м е р. Сез анда безнең бер иптәшебезне яраладыгыз, ул хәзер үләргә ята.

К р и г е р. Ә сез минем управляющиемны, иң якын кешемне...

Б и к т и м е р. Ул кеше түгел, гомере буена безнең каныбызны эчүче этегез иде. Алай да без аңа тимәдек, башлап ул безгә мылтыктан ут ачты. Шулай булгач, үз җәзасын гына татыды. Бу эшегез өчен сезгә дә җавап бирергә туры килер. Шуның өчен мин сине кулга алам.

К р и г е р. Соң бит мин ул кешегезгә тимәдем.

Б и к т и м е р. Безгә мылтыктан ут ачарга син куштың аңа. Әйдә волостька!

А н т о н и н а *(тәрәзәдән күреп)*. Вася, кавалерия килә, кавалерия!

К р и г е р. Әһә! Шәһәрдән безгә ярдәм килә! Сез, талаучыларга, хәзер чик куела. Мин хәзер сезнең барыгызны да тотып яптырам. Башлап йөрүче син карт иблисне аттырам!

Берничә солдат һәм Ходаярны ияртеп Н у р г а л и керә. Озак кына Биктимер белән карашып торалар.

Н у р г а л и. Әти?.. Син ничек биредә?

Б и к т и м е р. Синеңчә миңа кайда булырга иде соң?

Н у р г а л и. Һәрхәлдә, син баринны сакларга тиеш түгел идең.

Б и к т и м е р. Юк, улым, мин аны сакламыйм. Без аның басуыннан яңгыр астында череп яткан көлтәләрен ташый идек, югары очның Хәйбул абыеңны атып яраладылар. Шуның өчен мин аны кулга алырга кердем.

Н у р г а л и. Бик дөрес эшләгәнсең, әти!

К р и г е р. Командир әфәнде, алар минем управляющиемны үтерделәр, алар минем имениемне талыйлар.

Н у р г а л и *(солдатларына)*. Алыгыз да ябып куегыз!..

Солдатлар Антонина белән Кригерны алып китәләр. Башкаларга сиздерми генә Ходаяр чыгып тая.

Әти, Хәйбул абый кайда соң?

Б и к т и м е р. Җир өстендә калган иде, әйдә, улым, больниска озатыйк.

Н у р г а л и. Абзыйлар! Нәрсә карап торасыз, алыгыз әйберләрен!

Биктимер белән Нургали китә. Крестьяннар бер-берләрен төрткәләп әйберләрне ала башлыйлар. Х ө р м ә т у л л а белән М ө р ш и д ә керә.

Х ө р м ә т у л л а. Әй, әй, нишлисез монда?

М ө р ш и д ә. Нигә безнең әйберләрне аласыз? Кара инде бу исерекне, безнең кәнәфидә йоклап утыра. Тор, тор, бирән!.. Әнкәем лә, үлгән!!

Х ө р м ә т у л л а. Үлгән?..

А р т а м о н о в керә.

А р т а м о н о в. Бу нинди башбаштаклык, бу нинди анархия?

Х ө р м ә т у л л а. Дөрес, Гриша, монархия шул, көпә-көндез кеше талыйлар.

А р т а м о н о в. Ә син үзең нигә ул әйберләрне күтәрдең?

Х ө р м ә т у л л а. Күтәрсәм, болар минем үз әйберләрем.

А р т а м о н о в. Ничек үз әйберләрең?

Х ө р м ә т у л л а. Шулай, мин договор белән баринның үзеннән бөтен өй җиһазларын, иген кoралларын сатып алдым, менә минем кәгазем.

А р т а м о н о в *(кәгазьне кулына алып карый).* Без синең бу договорыңны танымыйбыз.

Х ө р м ә т у л л а. Ничек инде ул танымыйсыз? Ике якның да кулы куелган, бик әйбәтләп печать сугылган.

А р т а м о н о в. Безнең законга сыя торган договор түгел бу. Куегыз әйберләрне, куегыз!

Х ө р м ә т у л л а. Менә сиңа күчтәнәч...

Н у р г а л и белән Б и к т и м е р һәм берничә кеше ияртеп З ә м з ә м б а н у керә.

А р т а м о н о в. Иптәшләр! Алган әйберләрегезне урыннарына куегыз. Инәсенә дә тиясе булмагыз! Тиздән бу имениедә ярлыбатраклар өчен коммуна төзеләчәк. Хәзер әйдәгез минем белән, Мирвәлине коткарырга, волостька!

Б и к т и м е р. Мирвәлине? Мироныч, аңа ни булган?

А р т а м о н о в. Аюхановлар аны кулга алдылар.

Б и к т и м е р. Кулга алдылар?.. *(Тиз генә чыгып китә.)*

А р т а м о н о в *(Нургалигә).* Иптәш командир! Монда тәртип

сакларга, әйберләргә опись ясарга берничә солдатыгызны калдырырга кирәк булыр.

З ә м з ә м б а н у. Юк, Мироныч, солдатлар анда барсыннар, мондагы тәртипне без үзебез дә карарбыз.

А р т а м о н о в. Сез кем соң?

З ә м з ә м б а н у. Мин кичә сайланган рабочком председателенең урынбасары. Менә бу егет, Аркаша, безнең секлетарь була инде. *(Мадьяр солдатына күрсәтеп.)* Бусы пленныйлар комитетының вәкиле.

А р т а м о н о в. Алай булганда эш башка. Хәзер үк имениедә тәртип урнаштырыгыз. Мал-туарларны, барлык җиһазларны исәпкә алыгыз, бер генә шырпысын да әрәм-шәрәм итәргә ирек бирмәгез.

З ә м з ә м б а н у. Була, була, Мироныч!

А р т а м о н о в. Ә сез, иптәшләр, әйдәгез минем белән.

Н у р г а л и. Солдатлар! По ко-ням!!

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шул ук волость комитетында бара. Пәрдә ачылганда М и р з а х а н, үзен кая куярга белмичә, ишекле-түрле йөренә. Бертуктамый папирос пыскыта. Л а ш м а н о в керә.

Л а ш м а н о в. Мирзахан Шаулиханович, делегатлар залга кереп тулдылар. Съездны башларга вакыт.

М и р з а х а н. Хәзер башлыйбыз, Илья Петрович, хәзер. Белмәдегезме, өяздән нинди хәбәрләр бар икән?

Л а ш м а н о в. Хәзергә берниндн хәбәр юк. Ләкин мин шуңа аптырыйм, иртәгә буласы базар өчен халык нигәдер бүгеннән үк җыела. Бөтен базар мәйданы тулган.

М и р з а х а н. Халык шулай инде ул, кызык күрәсе килә торгандыр.

Б а с а р ы й керә.

Я, ничек, Артамоновны тоттыгызмы?

Б а с а р ы й. Почта атларына утырып качты.

М и р з а х а н. Нигә куа бармадың?

Б а с а р ы й. Револьверы бар. Якын да җибәрми, атыша.

М и р з а х а н. Милиция начальнигы түгел син, утын агачы!.. *(Яңагына суга.)*

Б а с а р ы й *(елап)*. Тукта әле, нигә син миңа сугасың, нигә сугасың, ә? Туры хезмәтемнең әҗере шушы булдымы, ә? *(Мирзаханга һөҗүм итә. Мирзахан чигенә.)*

Л а ш м а н о в *(араларына кереп)*. Куегыз, кеше көлдермәгез.

А й с ы л у керә.

А й с ы л у. Мирзахан, Мирвәли кайда?

М и р з а х а н. Белмим, Айсылу апа, өегездә юкмыни?

А й с ы л у. Юк шул. Ул бүген бөтенләй өйгә кайтмаган.

М и р з а х а н. Сез үзегез кайда идегез соң әле?

А й с ы л у. Твардовский имениесендә ялланып эшләүчеләрнең профсоюзын оештырырга барган идем. Егерме биш кеше язылды. Өч кешелек рабочком сайлатып кайттым.

М и р з а х а н. Анысы бик әйбәт булган.

А й с ы л у. Бу Мирвәли кайда соң?

М и р з а х а н. Собраниедән соң ул Лесопильный заводка китмәде микән?

А й с ы л у. Ул аннан кайткан, күптән түгел монда кереп киткәнен күргәннәр.

М и р з а х а н. Ул чагында бүлмәсендә утыра торгандыр.

А й с ы л у. Карадым, анда да юк

Ә х т ә р и керә.

Әхтәри кода, Мирвәлине күрмәдеңме?

Ә х т ә р и. Юк, кодача, күрмәдем. Нигә ул кадәр кирәк иде соң?

А й с ы л у. Твардовский имениесеннән кайттым, өйгә керә алмый йөрим, ачкыч аңарда.

Ә х т ә р и. И... Онытып торам икән... Бая гына потребитель кибетенә кереп бара иде, шунда утыра торгандыр.

А й с ы л у. Шулаймыни? *(Китә.)*

Л а ш м а н о в. Мирзахан Шаулиханович, безне делегатлар көтәләр.

М и р з а х а н. Әйдә, Илья Петрович, башлыйбыз.

Артта хатыннар тавышы.

Ул нинди тавыш тагын?

Ә х т ә р и. Бая әйткән солдаткалар, сугышны туктатуны сорап килгәннәр.

М и р з а х а н. Демонстрация?

Л а ш м а н о в. Нindie генә әле, кулларында язылган флаглары да бар.

Х а т ы н н а р т а в ы ш ы. Кая үзләре, нигә чыкмыйлар?

Б а с а р ы й. Сезне сорыйлар.

М и р з а х а н. Куып таратыгыз үзләрен.

Б а с а р ы й. Алар бик күп, өч йөзләп бар.

М и р з а х а н. Өч йөзләп?

Ә х т ә р и. Бөтен авыллардан җыйналып килгәннәр.

Берничә солдатка ияртеп Г а й н а в а л керә.

Г а й н а в а л. Тәмам барин булдыгыз, чакырып та чыкмыйсыз!

М и р з а х а н. Нәрсә бар?

Г а й н а в а л. Менә без бүгеннән сугышны туктатуны, ирләребезне кайтаруны сорап волость крестьян съездына килдек.

М и р з а х а н. Ләкин бит, түтәйләр, ул алай гына эшләнә торган эш түгел.

Г а й н а в а л. Нигә эшләнмәсен? Хәзер халык иреге дисез түгелме соң? Безнең волость солдаткалары ирләрен кайтаруны сорыйлар дип съезд исеменнән Петербургка телеграмма бирегез.

М и р з а х а н. Без андый телеграмманы бирә алмыйбыз. Чөнки ул кыргыйлык. Бернинди дә закон кагыйдәләренә сыймый торган башбаштаклык. Андый зур мәсьәләләрне собрание җыеп хәл итмиләр. Бу эштә мин сезне гаепләмим, сезне алдаганнар, кемнәрдер өйрәтеп җибәргәннәр.

Г а й н а в а л. Безне беркем дә өйрәткәне юк. Башта үзебезнең авыл солдаткалары җыйналып сөйләштек тә монда килергә чыктык. Юлда инде рус, чуаш авылларының да солдаткалары кушылдылар. Озын сүзнең кыскасы, без әйткән телеграмманы бирегез.

М и р з а х а н. Тагын әйтәм, без андый телеграмманы бирә алмыйбыз.

Г а й н а в а л. Ул чагында, көмәйләр, әйдәгез, съездларына керәбез.

М и р з а х а н. Басарый, куып чыгар үзләрен.

Б а с а р ы й. Барыгыз, бар, өйләрегезгә таралыгыз, юкса хәзер ябып куйдырам.

Г а й н а в а л. Урыныгыз җитәр микән? Көмәйләр, үрә!

Х а т ы н н а р *(кыска гына кырт кисеп кычкыралар).* Үрә!

М и р з а х а н. Бу ни бу?

Х а т ы н н а р. Үрә, үрә!!

М и р з а х а н. Бу нишләвегез, әллә котырдыгызмы?

Х а т ы н н а р. Үрә! үрә!! үрә!!!

Басарыйны егып, суд залына кереп китәләр. Тыштан А й с ы л у керә.

А й с ы л у. Әхтәри кода, нигә ялганлыйсың, потребитель кибете бүген бөтенләй ачылмаган.

Ә х т ә р и. Мин анысын белмим инде, синең иреңә каравыл тормадым.

А й с ы л у. Мирзахан, кайда Мирвәли?!

Бик нык ачуланган кыяфәттә атылып Б и к т и м е р керә.

Б и к т и м е р. Кайда Мирвәли?

А й с ы л у. Әткәй, мин дә аны эзләп йөрим, әйтмиләр.

Б и к т и м е р. Сездән сорыйм, кайда Мирвәли?..

М и р з а х а н. Икесен дә тотып бәйләгез!

Б и к т и м е р *(револьвер чыгарып).* Якын килмәгез! Җаныгызны җәһәннәмгә җибәрмәс борын әйтегез, Мирвәлине кая куйдыгыз? *(Һавага ата. Әхтәридән башкалар куркып бүлмәгә качалар.)* Ә, син, кода, нишләп монда йөрисең? *(Якасыннан тотып ала.)*

Ә х т ә р и. Тәүбә-әстәгъфирулла диген, кода, бу нишләвең бу?

Б и к т и м е р. Мирвәли кайда?

Ә х т ә р и. Белмим, кода.

А й с ы л у. Белә, әткәй, белә, юри әйтми ул.

Б и к т и м е р. Яхшылыкта әйт, кайда Мирвәли?

Ә х т ә р и. Җибәр әле, кода, якаңы ертасың.

Б и к т и м е р. Әйт тизрәк, маңгаеңа менә шуның белән җибәрәм.

Ә х т ә р и. Бетте, бетте, кода, аны подвалга яптылар.

А й с ы л у. Подвалга?

Б и к т и м е р. Әйдә, килен!.. *(Китәләр.)*

Х о д а я р керә.

Х о д а я р. Мирзахан, Мирзахан!

Мирзаханнар чыгалар.

М и р з а х а н. Нәрсә бар тагын?

Х о д а я р. Хыянәт, хыянәт!

М и р з а х а н. Нинди хыянәт?

Х о д а я р. Нургали крестьяннар ягына авышты. Артамонов хәзер аларны монда алып килә.

М и р з а х а н. Илья Петрович, акчаларны, кыйммәтле кәгазьләрне ал, хәзер качабыз.

Сәхнә артында тавышлар ишетелә. Залдан съезд делегатлары бу якка йөгерешеп чыгалар.

Х о д а я р. Әнә алар килеп тә җиттеләр!

М и р з а х а н. Ишек, тәрәзәләрне бикләгез! Коралларыгызны алыгыз, актык патроннарга кадәр сугышабыз.

Ишек, тәрәзәләрне биклиләр, сәхнә артында тавыш-кычкырыш көчәя. Ишекләрне дөбердәтәләр. Тәрәзә пыялалары чылтырап ватыла. Ишекләр кубарылып эчкә ава. Язгы ташкыннардай булып, бердәм халык төркеме һәм с о л д а т л а р кереп тулалар.

А р т а м о н о в. Урыннарыгыздан кузгалмагыз!..

Мирвәли, Биктимер, Айсылукерә.

Н у р г а л и *(каршы барып).* Дәү абый!..
М и р в ә л и. Рәхмәт сиңа, энекәш. *(Кочаклашалар.)*

Телеграфист керә.

Т е л е г р а ф и с т. Мироныч, Мироныч, Петроградтан телеграмма!

А р т а м о н о в. Китер бире! Укы, Мирвәли.

М и р в ә л и *(укый).* «Россия гражданнарына! Вакытлы хөкүмәт төшерелде. Дәүләт власте Эшче һәм Солдат Депутатларының Петроград Советы органы һәм Петроград пролетариаты гарнизонының башында торучы Хәрби Революцион Комитет кулына күчте. Халыкларның көрәшеп килгән эше: һич кичекмәстән демократик солых тәкъдим итү, җиргә алпавытчылык милкен бетерү, производство өстеннән контроль кую, Советлар хөкүмәтен төзү эше тәэмин ителде. Яшәсен Солдат Эшче-Крестьяннар Революциясе! Ульянов-Ленин».

Б ө т е н х а л ы к *(шатлык белән).* Ленин...

*Пәрдә.*

*1937—1952*

# БИШБҮЛӘК

*Пьеса биш пәрдәдә, сигез күренештә*

Катнашучылар:

Тимеркәй — Кызыл Армиядә атлы взвод командиры.
Мәрфуга — аның анасы.
Маһинур — Мәрфуганың кызы, Тимеркәйнең сеңлесе.
Башкатов — волость ревком председателе.
Махиан — маякчы карт.
Корбан — Тимеркәйнең иптәше, кызыл армеец, черкес егете.
Егор Калашников — матрос.
Самат — Бишбүләк авыл советы председателе.
Сәләхи — аның улы.
Әхтәм — урта хәлле крестьян.
Саҗидә — аның хатыны.
Гөлсем — аларның кызы.
Фәүзия — укытучы.
Һайдель — чехословак мятежниклары һәм аклар бригадасы командиры.
Джонсон — инглиз полковнигы.
Чингизов — аклар штабының начальнигы, Һайдельнең урынбасары, соңрак бригада командиры.
Варламов — авылда качып йөрүче офицер, соңыннан адъютант.
Ислам — авылның эре сәүдәгәре.
Зөләйха — аның хатыны.
Зифа — аларның кызы.
Юргатаев — аклар коменданты.
Бәйрәм — бакалея сәүдәгәренең улы.
Идрис — укытучы.
Иван — бай тегермәнче.
Камәр — хәлле кеше кызы.
Мингулов — аклар солдаты.
Курбатов — аклар солдаты.
Шаһбаз — мәзин малае.

Вакыйга 1918—1919 елларда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ислам байның ишегалды. Артта төрле төстәге буяуларга буялган койма һәм кечкенә капка. Уң якта асты кирпеч, өске катлары агачтан салынган йортның берничә тәрәзәсе һәм террасасы күренә. Сул якта таш кладовой. Пәрдә күтәрелгәндә Идрис белән Зифа сөйләшеп утыралар. Артта машина белән ашлык суккан тавыш ишетелә.

И д р и с. Шәһәрдә властьны үз кулларына алып, башка партияләрне читкә кага башлагач, мин авылга — Бишбүләккә килгән идем. Ләкин алар хәзер авылларда да бедноталар, ревкомнар төзеп, милли әмәлләрне җимерә баралар. Безнең татар милләте...

З и ф а. Гафу итегез, Идрис әфәнде, сез һаман «милләт», «милләт» дисез. Шушындый киеренке көннәрдә конкретрак проблемалар юкмыни?

И д р и с. Зифа туташ... Милли мәсьәлә, милли мәнфәгать һәрвакытта беренче нәүбәттә торырга тиеш. Әйтик, менә сезнең әтиегезгә күпме контрибуцияләр салдылар. Алар гына аз иде, инде хәзер ындырындагы ашлыгын суктырып алалар. Бу бит безнең милләтебезне икътисади яктан көчсезләндерү дигән сүз.

З и ф а. Соң бит алар икмәкне башка милләт байларыннан да алалар.

И д р и с. Анысында минем эшем юк. Миңа үз милләтем кадерле.

З и ф а. Шулайдыр, Идрис әфәнде, ләкин мондагы ревком эшләре турында сөйләсәгез, яхшырак булыр иде.

И д р и с. Мин аңламыйм, нәрсәгә ул ревком сезгә? Нигә аның эшләре? Әллә чыннан да сез коммунистлар яклы инде?

З и ф а. Мин культура кешесе, авылны ничек итеп үзгәртергә теләүләрен һәм хәзерге җаваплы моментта нинди планнар белән шөгыльләнүләрен беләсем килә. Сез мине ревком җитәкчеләре белән таныштырыгыз.

И д р и с. Бик рәхәтләнеп. Тик председателе өйдә юк, авылларда митинглар уздырып йөри. Секретаре һәм кайбер членнары белән таныштырырга мөмкин. Әйдәгез. *(Китәләр.)*

Шәлен ябына-ябына З ө л ә й х а белән М ә р ф у г а чыга.

З ө л ә й х а. Тегермәнче Иван агай әйтә: күркә чебиләренә җим биргәндә каты җиргә сибәргә ярамый, чүпләгәндә мие селкенеп, шуннан үлүчән булалар, ди. Иске чүпрәктәнме, чыпта кисәгеннәнме мендәр кебек нәрсә тегәрсең дә, җим биргәндә шунда гына сибәрсең.

М ә р ф у г а. Ярый, иркәм, тегәрмен. Моннан ары җимнәрен дә шунда гына сибәрмен.

З ө л ә й х а. Кар базына күз салган идем, әчегән сөтләрең күбәйгән, бозылмас борын эремчек кайнатырга иде.

М ә р ф у г а. Ярый, ярый, иркәм, кайнатырмын.

З ө л ә й х а. Исламгәрәй әйтә: кара айгырга солы биргәндә, түгеп-чәчеп йөрмәсеннәр, ди.

М ә р ф у г а. Хатын-кызны санга санамый башлады. Кичә Ма-

һинурны чак-чак кына тешләп алмаган. Аны берәр ир-аттан караткмасаң, белмим шул...

З ө л ә й х а. Ялчы тотарга кушмыйлар бит. Сезнең өчен дә контрибут түләтеп җаныбызга тиделәр. Аннан ашлык сугучы кызларыңа әйт: бәрәңгеләрен тыгынсыннар да ихахайлап-михахайлап утырмасыннар, өйләренә китсеннәр.

М ә р ф у г а. Ярый, ярый, иркәм, әйтермен.

Икесе ике якка китәләр. Урманнан гармун белән җырлап килгән тавыш ишетелә. Йөгерешеп ындыр ягыннан кызлар керәләр.

Е г е т л ә р. Капка төбендә торасың,
Нечкә билең борасың,
Нечкә билләреңне борып,
Кемне көтеп торасың.

Г ө л с е м *(коймага менеп).* Сәләхи, нишләп болай әргән уйнап йөрисез?

С ә л ә х и *(коймадан үрелеп).* Шатланыгыз, кызлар, тагын дөнья сезгә кала бит.

М а һ и н у р. Сәләхи абый, чәнечкәләп-төрткәләп әйтмәсәң, күңелең булмый, ахры.

С ә л ә х и. Ярый инде, кызлар, без китүче кешеләр бит, гаепкә алмагыз.

Г ө л с е м. Китәсез? Кая?!

М а һ и н у р. Зимагурга, бурлаккадыр.

С ә л ә х и. Юк шул, кызлар, дошманнарга каршы сугышка.

К ы з л а р. Сугышка?!

С ә л ә х и. Әйе, кызлар, сугышка.

Г ө л с е м. Нишләп алай? Кыш көне үк сугыш бетеп, мир ясалды түгелме?

С ә л ә х и. Шулай иде дә, гражданнар сугышына барырга дип ревкомнан бүген хәбәр алынды.

Г ө л с е м. Герман дигән каһәр тагын безнең җиргә кергәнме?

С ә л ә х и. Түгел шул, кызлар. Аклар дигәне иске режимны кайтарырга къләләр.

Г ө л с е м. И Ходаем... Тагын да әлләниләр күрәсебез бар икән...

С ә л ә х и. Кызлар, кичкә берәр җирдә аулак ясап, күңел ачу кичәсе маташтыра алмассызмы?

М а һ и н у р. Ярый, ярый, Сәләхи абый, уйлап карарбыз.

Е г е т л ә р. Хуш, исән бул, Бишбүләккәй,
Урман, суларың белән,
Дошманнарны җиңгәннән соң
Без кайтырбыз дан белән.

*(Егетләр җырлап китәләр.)*

Икенче яктан К а м ә р йөгереп керә.

К а м ә р. Кызлар, кызлар!..

Г ө л с е м. Нәрсә бар?

К а м ә р. Харап булдык, киләләр...

М а һ и н у р. Кемнәр, аклармы?

К а м ә р. Түгел, авылны таларга армияләр килделәр.

К ы з л а р. Армияләр?!

К а м ә р. Әнә исполком алдында ак күбеккә төшкән ике ат бәйләп куйганнармы? Шулар инде. Үзләре исполкомга кереп киттеләр. Авылны инәсеннән җебенә кадәр талыйлар ди.

Г ө л с е м. Шул ике атлы кешеме?

К а м ә р. Алар икәү генә булсалар да, яэҗүҗ-мәэҗүҗ кавеменнән яралган, дип әйтә ди хәзрәт. Болай җанга тигәннәре аз иде, инде армияләрен җибәреп талатмакчы булганнар.

Г ө л с е м. Камәрбану, нигә инде коммуннарга яла ягасың?

К а м ә р . Бер дә яла түгел, ни өчен әтидән иксән потлап икмәк саттырдылар?

Г ө л с е м. Саттырсалар, учыгызны тутырып акчасын алдыгыз. Шул талау буламы?

К а м ә р. Ә нигә соң хәзрәткә, Сәгыйть хаҗиларга, Ислам абзыйларга кантригутлар салдылар?

Г ө л с е м. Тиешле булгандыр.

М а һ и н у р. Чыктылар! Чыктылар!

Г ө л с е м. Әнкәем лә, берсе кызыл чалбар кигән түгелме соң?

М а һ и н у р. Киләләр, киләләр! Болай таба киләләр!

Г ө л с е м. Маһинур, тукта инде, әллә нинди кешеләргә кулың болгама.

М а һ и н у р. Алар монда таба киләләр бугай.

К а м ә р. Качыгыз, кызлар, качыгыз!

М а һ и н у р. Әбәү, Камәрбану! Таш сыбызгы кебек чиныйсың.

К а м ә р. Әйдәгез!

Маһинурдан башкалар өйгә кереп китәләр. Кавказча киенгән Т и м е р к ә й белән К о р б а н чыга.

М а һ и н у р. Тукта, бу соң безнең абый түгелме?

Т и м е р к ә й. Сеңелем, Маһинур?! Кара син, нинди зур кыз булгансың.

М а һ и н у р. Ә син ничек картайгансың, сакал баскан.

Т и м е р к ә й. Әни кайда соң, нигә күренми?

М а һ и н у р. Мал өендә, су кайната иде. Хәзер чакырып киләм *(Китә.)*

К о р б а н. Иптәш Тимеркәй, бу кыз бала синең кыз кардәшеңме?

Т и м е р к ә й. Әйе, Корбан, минем туган сеңелем шушы инде.

К о р б а н. Гүзәл кыз, гүзәл! Исеме ничек?

Т и м е р к ә й. Маһинур.

К о р б а н. Махай, Махай, тфү...

Т и м е р к ә й. Маһинур...

К о р б а н. Әһә, белдем, Махимур. Бик гүзәл кыз балаң... әй, сеңелең бар икән. Махимур...

Г ө л с е м өйдән чыга.

Г ө л с е м. Тимеркәй?

Т и м е р к ә й. Гөлсем!

Г ө л с е м. Кайттыңмыни? Ай-кояшым, Тимеркәй...

Т и м е р к ә й. Тукта, Гөлсем, мондый чакта күз яшьләре түкмиләр.

Г ө л с е м. Нишлим соң, шатлыкларым эчемә сыймый, яшем белән басмасам.

К о р б а н. Һи, яман... Дәртләремә дәрманым юк, битем каплап качмасам. *(Өйгә кереп китә.)*

М ә р ф у г а, М а һ и н у р чыга.

М ә р ф у г а. Бәбкәм, бәбкәм, Тимеркәй...

Т и м е р к ә й. Әнкәй!..

М ә р ф у г а. Насыйп икән... карт көнемдә... бәбкәмне күрергә...

Т и м е р к ә й. Тукта, әни, елама инде.

М ә р ф у г а *(Тимеркәйнең аркасыннан кагып елый)*. Сөйлә, бәбкәм, сугыш беткәч нигә өйгә кайтмадың?

Т и м е р к ә й. Шулай туры килде инде, әни. Башта патша яклы Корнилов дигән генерал белән сугыштык, аннан Украинадан немец оккупантларын куып чыгаруда катнаштым. Аннан инде, бу якларда аклар баш күтәргәч, бирегә җибәрделәр.

М ә р ф у г а. Үз теләгең беләнме?

Т и м е р к ә й. Әйе, әни, башта Кызыл Гвардиягә, соңыннан Кызыл Армиягә үз теләгем белән язылдым. Нигә, әни, улыңның кызыл сугышчы булуын әллә ошатмыйсыңмы?

М ә р ф у г а. Ошатуын ошатам да... Дүрт ел йөреп сугыштан туймавыңны гына әйтәм.

Ә х т ә м *(койма башыннан карап)*. Тимеркәй кайткан диләрме?

М ә р ф у г а. Кайтты, кайтты, Әхтәм абый, әйдә, монда кер.

Ә х т ә м керә.

Ә х т ә м. Һи... Кура җиләге, кайттыңмыни, әкият?

Т и м е р к ә й. Исәнме, Әхтәмҗан абзый?

М ә р ф у г а. Ярый, балам, сез сөйләшә торыгыз. Мин сезгә самовар куеп җибәрим. Кызлар, барыгыз, эшләрегездә булыгыз.

Әхтәм белән Тимеркәйдән башкалар китәләр.

Т и м е р к ә й. Я, Әхтәм абзый, сөйләп җибәр, ни эшләр бетереп ятасыз?

Ә х т ә м. Син безне куй әле. Үзең сөйлә. Сине бит танырлык та түгел. Әллә нинди чикмәннәр киеп җибәргәнсең.

Т и м е р к ә й. Чикмән түгел, Кавказ буркасы, диләр. Мин бит кызыл кавалерия отрядында взвод командиры.

Ә х т ә м. Командир гынамыни? Мин бит сине грнадир булгансың дип торам. Нәрсә, отпускага кайттыңмы?

Т и м е р к ә й. Юк, ревкомга эш белән килдем. Үзләре өйдә юк икән, авылларга чыгып киткәннәр.

Ә х т ә м. Әйе, аларның кызу эш өсте, ут капкандай чабалар. Бу Башкатов дигәннәре бик гаярь кеше булды бит, әкият.

Т и м е р к ә й. Чингизовларның аракы заводында машинист булып эшләгән Башкатов түгелдер ич?

Ә х т ә м. Шул үзе инде. Ул бит безнең ревком председателе. Шул, мин сиңа әйтсәм, бик күп кешеләрне өндәп коммунга язу дисеңме, ач губерналарга икмәк җыйнау дисеңме, кантрибут салып байларны кысу дисеңме, прәме галәмәт кеше икән.

Артта гармунда русча уйнап, җырлап узалар.

Т и м е р к ә й. Бу ни бу, көпә-көндез җырлап йөриләр?

Ә х т ә м. Шул инде, Башкатовның эше. Авыллардан мобилизациягә киләләр. Нәрсә соң, энем, куркыныч бармыни?

Т и м е р к ә й. Әйе, Әхтәм абзый, чит ил капиталистлары белән аклар безнең илгә канлы кулларын сузалар.

Ә х т ә м. Шулай дип сөйлиләр иде, дөрес икән алайса.

Т и м е р к ә й. Бу мәсьәләгә крестьяннар ничек карый соң?

Ә х т ә м. Төрлесе бар инде, энем. *(Исламның өенә күрсәтеп.)* Менә моның кебекләр шатлана торгандыр. Безнең кебекләргә күңелле түгел. Нигә дисәң, Советның безгә файдасы күп тиде. Үзең беләсең, минем җирем юк иде, җан башыннан җир алдык. Болыныбыз юк иде, болын бирделәр. Урман дисәң, җырлый-җырлый алпавыт урманын кисәбез. Аннан, энем, акыллы атын мактаганда, юләр хатынын мактый дигәндәй, ишеткәнсеңдер, сабан туенда минем чаптаркаем тирә-як байларының борынына сукты бит.

Т и м е р к ә й. Синең шулай чабыш атларың да бармыни?

Ә х т ә м. Син барындагы кара алашаны сугышка алгач, колыннан алып үстергән идем.

Т и м е р к ә й. Син алайса баегансың.

Ә х т ә м. Йорт-каралтыларымның артканы юк. Шулай да атка тиендем. Башы гына сау булсын. Тик менә чирләп тора, ике-өч көннән бирле ашамый. Ат духторына әйтием диеп исполкомга килгән идем дә, өйдә юк икән. Синең кайтуыңны да анда гына ишеттем.

Т и м е р к ә й. Алай булса, мин сиңа менә дигән ат остасы бирермен. Корбан! Бире чык әле.

К о р б а н кызлар яныннан чыга.

К о р б а н. Ни боерасың, иптәш командир?

Т и м е р к ә й. Менә бу агайның аты чирләгән, барып кара әле.

Ә х т ә м. Бу кеше ат остасымы? Кит аннан, сакал-мыек та чыкмаган.

К о р б а н. Оста гына түгел, мин атның докторы!

Ә х т ә м. Әйдә алайса, товарищ духтор. *(Китәләр.)*

М ә р ф у г а керә.

М ә р ф у г а *(Тимеркәйнең аркасыннан сөеп).* Бәбкәем, бәбкәем...

Т и м е р к ә й. Менә инде. Тагы нигә елыйсың?

М ә р ф у г а. Авыр, балам, көчең беткәч, кешедә гомер итү бик авыр икән... Өйләнеп бирәр өй кисәге оештыра алсаң, безне моннан коткарыр идең.

Т и м е р к ә й. Коткарырбыз, әни, бераз гына сабыр итегез. Әни, Махиан абый исәнме?

М ә р ф у г а. Исән, улым, тик былтыр Сафура җиңгәң генә үлде... Абыең шул эшендә инде, әле кичә дә безгә балык китергән иде.

Т и м е р к ә й. Болар тагын да баеганнар, ахры?

М ә р ф у г а. Котырдылар инде, балам, котырдылар.

Т и м е р к ә й. Үзләре кая соң, берсе дә күренми?

М ә р ф у г а. Исламгәрәй әвендә, ашлык суктыра иде, Зөләйхасы Сәгыйть хаҗиларда, Зифабанулары Идрис хәлфә белән йөрергә китте.

Т и м е р к ә й. Зифабану һаман укыймы?

М ә р ф у г а. Өяз мәктәбен бетергән иде дә, яңадан ниндидер курс дигәннәренә кереп духтор булырга маташа. Ул да бүген Өфедән кайтты әле.

Т и м е р к ә й. Өфедән кайтты? Үзе генәме?

М ә р ф у г а. Ниндидер ямщик белән.

Т и м е р к ә й. Ямщик белән?..

М ә р ф у г а. Әйе, балам, нигә сорыйсың?

Т и м е р к ә й. Юк, болай гына.

М ә р ф у г а. Әйдә, балам, чәйгә керик, кызлар туйгандыр инде.

Т и м е р к ә й. Тукта инде, әни, иптәшем Әхтәм абзыйларда, аның кайтканын көтик. Аннан минем ревкомга кереп чыгасым да бар.

М ә р ф у г а. Ярый, балам, ярый алайса, шул арада мин мунча ягып җибәрермен. Анда озак йөрмәссеңдер бит?

Т и м е р к ә й. Хәзер кайтырмын, әни. *(Китәләр.)*

Өйдән М а һ и н у р, Г ө л с е м, к ы з л а р чыга.

М а һ и н у р. Үләм инде, түтәй, теге егеткә күңелем төште бит. Үзе дә мине ошатты бугай.

Г ө л с е м. Анысы да монысы, Маһинур, берәр аулак өйдә кунак итәсе иде үзләрен. Алынган яшьләрне дә шунда чакырыр идек.

М а һ и н у р. Аулак өйнең кирәге юк, синең сугыш куйган тулаларың бар иде кебек, шуңар өмә ясыйк.

Г ө л с е м. Дөрес шул. Уйлап табуың өчен рәхмәт. Әйдә безгә, әтиләрдән барып сорыйбыз да кичкә шаулатып өмә ясыйбыз. *(Китәләр.)*

И с л а м белән В а р л а м о в керә.

И с л а м. Николай Петрович, тизрәк сөйләгез, нинди хәбәрләр алып килдегез?

Гади ямщиклар киеменнән Ю р г а т а е в керә.

В а р л а м о в. Хәбәрләрме?..

И с л а м. Шикләнмәгез, кызым белән ямщик булып килүче кеше шушы инде.

В а р л а м о в. Алай булса яхшы, исәнмесез, — Варламов. *(Күрешәләр.)*

И с л а м. Йә, Николай Петрович?

В а р л а м о в. Бөек максатыбыз өчен сугышка керергә әзер торучы егетләрем авылларда качып, яшеренеп яталар. Аларның кайберләре корал белән дә тәэмин ителгән.

И в а н белән Б ә й р ә м керә.

И в а н. Уф, асылам, суелам!..

И с л а м. Ни булды, Иван Иванович?

И в а н. Ат мобилизациясенә ике атымны язып, кулымнан подписка алып киттеләр.

Б ә й р ә м г а л и. Миннән бер ат, үземне армиягә...

И с л а м. Кайгырмагыз, дусларым, шуның өчен дә мин сезне чакырткан идем. Тиздән үзебезнекеләр килеп җитәләр.

И в а н. Үзебезнекеләр?

Б ә й р ә м. Кемнәр алар?

И с л а м. Аклар.

Б ә й р ә м.<br>И в а н. } Аклар?

И с л а м. Әйе, аклар. Чит ил гаскәрләре белән бергәләп...

И в а н. Юк, Исламгәрәй, ышанмыйм. Ул хәбәрне син бер айдан бирле сөйләп киләсең.

И с л а м. Миңа ышанмасагыз, менә сезгә җанлы шаһит. *(Юргатаевны күрсәтә.)*

И в а н. Бу өтек — акмы? Кара-чутыр бит.

И с л а м. Котлымөхәммәт, сөйләп бир үзләренә.

Ю р г а т а е в. Тыныч булыгыз, әфәнделәр...

М ә р ф у г а керә.

М ә р ф у г а. Ишеттеңме, Исламгәрәй? Бик зур шатлыгыбыз бар.

И с л а м. Нинди шатлыгыбыз инде ул?

М ә р ф у г а. Тимеркәем кайтты!

И с л а м. Тимеркәй кайтты?! Кайда соң ул?

М ә р ф у г а. Әнә минем бәбкәм, кайтып килә.

Т и м е р к ә й керә. Башкалар аптырап кала.

Т и м е р к ә й. Саулармы сез!

И с л а м. Бик яхшы, энем Тимеркәй, исән кайттыңмы?

Б ә й р ә м. Ислам абзый, син бара алмыйм дисең алайса?

И с л а м. Кая?

Б ә й р ә м *(ымлап).* Иртәгә шәһәр базарына дим...

И с л а м. Ә... Юк, Бәйрәмгали, күрәсең бит, кызым кунакта. Менә Тимеркәй дә кайткан. Аларны ташлап базарларга йөрер хәлем юк.

Б ә й р ә м. Ярый, Тимеркәй, безгә дә кер, малай, сөйләшеп утырырбыз.

И в а н. Тукта, Бәйрәмгали, бергә китәрбез. Сау бул, товарищ. Тегермәнгә барсаң, рәхим ит. Ачы балның шәбен куеп, кәбестә белән сыйлармын. Ярый, сау булыгыз. *(Китәләр.)*

И с л а м. Тимеркәй энем, гаеп итмә инде, менә бу ач губернадан килгән кешегә *(Варламовка күрсәтеп.)* ашлык саткан идем,

үлчәп кенә җибәрим. Мәрфугаттәй, югары өйгә табын әзерлә, Тимеркәйне кунак итәрбез.

М ә р ф у г а. Ярый, ярый, Исламгәрәй, безне зурлавыгыз өчен рәхмәт. *(Китә.)*

И с л а м. Әйдә, товарищ!.. *(Варламов белән китәләр.)*

К о р б а н керә.

К о р б а н. Иптәш командир, мин теге агайның атын барып карадым, аты хаста түгел, коры печән ашаганга теле генә бозылган. Их, аты да аты...

Т и м е р к ә й. Бик шәпмени?

К о р б а н. Сөлек инде, сөлек... Их, мин әйтәм, ул атны үзебезгә каратсак...

Т и м е р к ә й. Ничек инде үзебезгә?

К о р б а н. Беләсең, минем ат начар. Ул агайның атын сиңа алсак, синеке миңа булыр иде.

Т и м е р к ә й. Ай-һай, ул аны сатармы икән?

К о р б а н. Шулай да сөйләшеп кара әле, иптәш командир.

Т и м е р к ә й. Корбан, бар әле, исполком алдына ниндидер бер ат менгән кеше килеп туктады. Ревком председателе түгелме?

К о р б а н. Тыңлыйм, иптәш командир. *(Китә.)*

И д р и с белән З и ф а керә.

З и ф а. Ләкин аларның өйдә булмаулары кызганыч... *(Тимеркәйне күреп.)* Гафу итегез, кеше бар икән. Боже мой, Тимеркәй абый түгелме соң бу?..

Т и м е р к ә й. Әйе, мин, нихәл, Зифабану?

З и ф а. Бик яхшы әле, Тимеркәй абый. Сине монда хәбәрсез югалды дип торалар иде.

Т и м е р к ә й. Мин сезне курсларда укыйсыз дип ишеткән идем, нишләп болай вакытсыз кайтасы булдыгыз?

З и ф а. Өс-башларымны алыштырып чыгарга рөхсәт итегез. Аннан иркенләп сөйләшербез... *(Китә.)*

Т и м е р к ә й. Сез кем буласыз?

И д р и с. Шушы авылның укытучысы һәм волисполком члены — Идрис Салихов.

Т и м е р к ә й. Волисполком члены? Исәнмесез! Йә, иптәш Салихов, волостьта мобилизация эшләрегез ничек бара?

И д р и с. Мин ул кадәрен әйтә алмыйм.

Т и м е р к ә й. Ничек әйтә алмыйсыз? Волисполком члены дисез бит.

И д р и с. Мин үзем гаскәргә мобилизация ясауга каршы.

Б а ш к а т о в керә.

Б а ш к а т о в. Ревком председателен сорап килүче сез буласызмы?

Т и м е р к ә й. Әйе, Кузьмич, мин булам.

Б а ш к а т о в. Сез мине беләсез?

Т и м е р к ә й. Нигә белмәскә? Мин бит шушы авылныкы, менә боларда ялчы идем. Сезнең заводка бәрәңге илтә идем, атлар симертү өчен заводыгыздан барда алып китә идем.

Б а ш к а т о в. Әйе, хәзер бераз хәтерлим. Гафу итегез. Ә сез, Салихов, ни өчен билгеләнгән авылыгызга барып митинг үткәрмәдегез?

И д р и с. Авырыйм, иптәш Башкатов. Су коенган идем, тамагымда ангина.

Б а ш к а т о в. Авыргач, нигә монда йөрисез?

И д р и с. Зифа туташта тамак даруы юк микән дип кергән идем.

Б а ш к а т о в. Безне калдырыгыз. Мин сезне тыңлыйм.

Идрис китә.

Т и м е р к ә й. Мин сезгә приказ китердем. *(Пакет бирә.)*

Б а ш к а т о в *(ертып укый)*. «...Сезнең волостьтан мобилизовать ителгән яшьләрне... отряд вәкиле Тимеркәй Миңлекәевкә тапшыруыгызны боерам. Бондюг һәм Глушерма заводларының оборудованиеләрен күчереп бетергәнче, шушы участокта фронт линиясен тотып тору вазифасы сезгә йөкләнә. Өяз хәрби комиссары Гольянов». Хәзер бездә комиссия бара. Авыллардан килә торалар. Иртә беләнгә кадәр мин сезгә өч йөз кеше бирә алам.

Т и м е р к ә й. Яхшы, иптәш Башкатов.

Б а ш к а т о в. Сезнең килүегез бик әйбәт булды әле. Без бүген кичкә волость большевикларының чираттан тыш җыелышларын чакырган идек. Сез шунда фронт хәлләре турында информация ясарсыз.

Ф ә ү з и я керә.

Ф ә ү з и я. Иптәш Башкатов, мин сезнең чакыруыгыз буенча.

Б а ш к а т о в. Миңлекәев, таныш булыгыз, яңа гына курс бетереп кайткан укытучыбыз.

Т и м е р к ә й. Тимеркәй Миңлекәев.

Ф ә ү з и я. Нарат Башыннан — Фәүзия Мозаффарова. Мин сезне таныйм, герман сугышына безнең абый белән бергә киткән идегез.

Т и м е р к ә й. Харисның сеңлесе? Ул кайда хәзер?

Ф ә ү з и я. Сугыштан кайтмады, үлгән хәбәре килде...

Б а ш к а т о в. Менә нәрсә, иптәш Мозаффарова: Мазар асты авылында митинг үткәрүне Салиховка тапшырган идек, саботажлык итеп, бармаган. Хәзер үк шунда китеп митинг үткәрегез. Мәсьәлә бер генә — социалистик Ватаныбыз куркыныч астында. Чит ил интервентларына, җирле реакцион көчләргә каршы халыкны күтәрергә кирәк. Кызыл Армиягә доброволь булып язылырга өндәгез. Москва, Петроград шәһәрләре өчен әзерләнгән икмәк запасларын төятеп, бүген үк монда җибәртегез. Барыгыз ревкомга. Анда сезгә подвода бирерләр.

Ф ә ү з и я. Яхшы, иптәш Башкатов. Хәзергә хушыгыз. *(Китә.)*

Б а ш к а т о в. Авыр көннәр кичерәбез, Миңлекәев.

Т и м е р к ә й. Безнекеләр кичә Бирскины калдырдылар.

Б а ш к а т о в. Кызганычка каршы, шулай. Кичәдән бирле Иж, Воткинск тирәсендә эсерлар восстаниесе бара. Иртәгәдән дә соңга калмыйча чигенергә иде, ләкин безнең пристаньда үзәк шәһәрләр өчен җыйган утыз мең пот икмәгебез бар. Шуларны озатырга Сарапулдан буксир көтәбез, ә ул, нишләптер, килми.

Т и м е р к ә й. Әйе, Кузьмич, хәлегезне аңлыйм...

Б а ш к а т о в. Хәзерге вакытта яшьләргә мобилизация үткәрәбез. Яңа гына ике авылда митинг үткәреп кайттым, ә хәзер Кама буендагы кичүне, аванпостларны тикшереп кайтырга кирәк. Чөнки ул безнең өчен иң әһәмиятле мәсьәлә. Мин сездән ревкомга барып мобилизация һәм эвакуация мәсьәләләре белән шөгыльләнүегезне сорар идем.

Т и м е р к ә й. Яхшы, иптәш Башкатов. Аннан бу йортта шигем бар. Хуҗаның кызы Уфадан кайткан, ә безнең Уфаны калдырганга инде бер атна. Бая мин бире килгәндә ниндидер билгесез кешеләр бар иде.

Б а ш к а т о в. Алар турында миңа хәбәр иттеләр.

Йөгереп Е г о р килеп керә. Матрос киеменнән.

Е г о р. Иптәш Башкатов, Сарапул эшләми.

Б а ш к а т о в. Ничек эшләми?

Е г о р. Көч-хәл белән Камбарканы бирделәр. Ләкин анда ниндидер бер сволочь кыз көлә, шаяра. Буксир кирәк идемени, сез инде аны көтмәгез, тәпи-тәпи китү ягын карагыз, ди. Әгәр дә ул, курва... минем янымда шул сүзне әйткән булса, мин аны шунда ук бахнуть итәр идем.

Б а ш к а т о в. Кызма, кызма, иптәш Калашников.

Е г о р. Кызмый нишлим, иптәш Башкатов? Агыйдел буенча да сорап карадым, юньләп сөйләшмиләр, я бөтенләй җавап бирмиләр. Аннан минем баржам тулды, ә икмәк һаман килә, куярга урын юк. Пристань начальнигы дебаркадерына алмый, нишләргә миңа?

Б а ш к а т о в. Урын табарбыз. Тик менә буксир мәсьәләсе генә. Таныш булыгыз, безнең үзәктән килгән вәкилебез, иптәш Калашников.

Т и м е р к ә й. Миңлекәев. *(Күрешәләр.)*

Б а ш к а т о в. Иптәш Калашников, хәзер безгә бер генә юл — Бондюг белән бәйләнергә, нинди дә булса берәр катер табып җибәрә алмаслармы. Булмый икән, баржаны батырудан башка чара юк.

Е г о р. Утыз мең пот икмәкне батырыргамы? Һичбер вакытта! Буксир килми икән, без аны лямка тартып булса да алып төшәрбез.

Б а ш к а т о в. Әйдәгез телеграфка, мин Казанны, Москваны сорыйм. *(Китә башлыйлар.)*

Ю р г а т а е в керә. Зифа террасадан күзәтә.

Ю р г а т а е в. Иптәш комиссар, синдә йомышым бар иде.

Б а ш к а т о в. Йомышың бар иде? Син кем буласың?

Ю р г а т а е в. Ислам абзый кызын ямщик булып китергән идем.

Б а ш к а т о в. Ә... Ул ямщик син икәнсең алайса?..

Ю р г а т а е в. Әйе, мин идем. Идел аръягына чыгар өчен перевозга пропуск кирәк иде.

Б а ш к а т о в. Идел аръягына?

Ю р г а т а е в. Әйе, нигә иптәш комиссар?

Б а ш к а т о в. Болай гына... Минем дә Идел аръягына чыгасым бар иде, утыртып барырсыңмы?

Ю р г а т а е в. Җырлый-җырлый алып барыр идем, иптәш комиссар, атым начар шул.

Б а ш к а т о в. Документың бармы?

Ю р г а т а е в. Бар, менә рәхим итегез.

Б а ш к а т о в. Рәхим итегез...

Ю р г а т а е в. Нәрсә дидегез?

Б а ш к а т о в. Минем белән ревкомга барырсыз.

Ю р г а т а е в. Ревкомга? Анда нәрсәгә?..

Б а ш к а т о в. Пропуск алырсыз.

Зифа югала.

Ю р г а т а е в. Ярый алайса, мин атымны гына карап керим.

Б а ш к а т о в. Урыныңнан кузгалма! Син арестован!

Ю р г а т а е в. Арестован? Ни өчен?..

Б а ш к а т о в. Анысын тикшергәч белерсең, тәти егет! Миңлекәев, әйдәгез миңа ярдәмгә.

Ю р г а т а е в. Карагыз әле, иптәш комиссар...

Б а ш к а т о в. Күп сөйләнмә. Марш алдан!!! *(Китәләр.)*

Икенче яктан К о р б а н кереп каранып йөри.

К о р б а н. Бу Махимур кая югалды соң? *(Маһинур киеменнән киенеп сәхнә аша үтеп китүче Зифа белән Идрисне күреп.)* Махимур! Тукта әле, Махимур, Махимур дим!!!

Капкадан М а һ и н у р керә.

М а һ и н у р. Нигә шулкадәр кычкырасың?

К о р б а н *(аптырап.)* Бу нә бу? Бер Махимур китте качып, икенчесе тора басып...

М а һ и н у р. Төш күрә башладыңмы әллә? Миңа абый кирәк иде. Кайда ул?

К о р б а н. Менә монда, папахам астында.

М а һ и н у р. Әй, шаяртмый гына әйт әле. Миңа аны күрергә кирәк.

К о р б а н. Әй, гүзәл кыз Махимур. Аны күрергә телисең, мин угланны теләмисеңме?

М а һ и н у р. Хи-хи-хи! Теләмим шул.

К о р б а н. Ай-ай-ай! Минем иптәшемнең туганы мине күрергә дә теләми. Ай, гүзәлем, вай, гүзәлем, гүзәлем, ай!.. *(Кыланып каршысына бара.)*

М а һ и н у р. Җитәр инде, май ашаган песи кебек күзләреңне уйнатма. *(Әкрен генә яңагына суга.)*

К о р б а н. Монысына да сук. *(Икенчесен куя.)* Кызлар суккан җир тамугта янмый ди безнең черкес халкы.

Т и м е р к ә й керә.

Т и м е р к ә й. Маһинур...

М а һ и н у р. Ай алла, оятлы булдык бит.

Т и м е р к ә й. Куй әле оятыңны, Зифабану өйдәме?

Г ө л с е м керә.

Г ө л с е м. Тимеркәй, бездә бүген тула өмәсе була, сине чакырырга килдем.

М а һ и н у р. Мин белмим, абый, нигә миннән сорыйсың?

Т и м е р к ә й. Зифабану, Зифабану!!

И с л а м керә.

И с л а м. Нигә кычкырасың, энем Тимеркәй?

Т и м е р к ә й. Зифабану өйдәме?

И с л а м. Зифабану, Зифабану, кызым Зифабану... Өйдә юк, ахры.

Т и м е р к ә й. Корбан, бар син ишегалдыннан кара. Мин югарыга менәм. *(Тиз генә югарыга менеп китә.)*

Корбан ишегалдыннан эзләнә.

М а һ и н у р. Ислам абзый, Зифабануны нигә эзлиләр?

И с л а м. Белмим, кызым, белмим. Синең бу абыең аждаһага әйләнеп кайткан. Кеше өстенә акыра-бакыра.

Тимеркәй югарыдан төшә.

Т и м е р к ә й. Кайда Зифабану?

И с л а м. Әйтәм бит, белмим. Син кайтканнан бирле күргәнем юк.

Т и м е р к ә й. Ялганлама. Әйт тизрәк, кая яшердегез?

М ә р ф у г а керә.

М ә р ф у г а. Бәбкәм, нигә тавышланасыз?

Т и м е р к ә й. Әни, Зифабану кайда?

К о р б а н керә.

М ә р ф у г а. Әле яңа гына миннән Маһинур күлмәген алып…

И с л а м. Әйе, әйе... Маһинур күлмәген киеп репетициягә барам диеп йөри иде бугай.

К о р б а н. Күлмәк?! Таптым!..

Т и м е р к ә й. Таптың, кайда?

К о р б а н. Махимур киемнәрен киеп качты.

З ө л ә й х а керә.

З ө л ә й х а. Тимеркәй кайткан икән, кил, күрешик.

Т и м е р к ә й. Мин сездән соңгы тапкыр сорыйм: Зифабанунының кайда икәнен әйтәсезме, юкмы?!

И с л а м. Кайда икәнен белмәгәч, ничек әйтәбез ди.

Т и м е р к ә й. Өегездә контрреволюция оештырып, шпионнар саклавыгыз өчен кулга алынасыз.

И с л а м. Кулга алынабыз?!

М ә р ф у г а. Бәбкәм, бу нишләвең?

З ө л ә й х а. Аштаткан апларымның әҗере шушымыни, оятсыз!

Атаң үлеп, урамда калган чакларыгызда җылы почмак биреп карап үстерүчеләрне хәзер оныттыңмыни?

Т и м е р к ә й. Юк, онытмадым. Бары да исемдә. Унике яшьлек малай чакларымда базардан базарга, прилавкадан прилавкага кызыл мал төргәкләрегезне ташып арыганнан соң, төннәр буе тәмле йокыларыгызны, акча сандыкларыгызны саклаганнарым бүгенгедәй исемдә. Шулай ук кышкы салкын бураннарда төлке тамакларга төрелгән исерек гәүдәләрегезне ярминкәдән ярминкәгә йөртеп, кулаякларымны өшеткәннәрем дә исемдә. Сезнең файдагыз өчен ачылган сугышта дүрт ел буе газап чигүләрем дә исемдә. Корбан, ал үзен...

К о р б а н. Әйдә, марш! *(Исламны алып китәләр.)*

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әхтәм агайның өе. Урта хәлле крестьянга хас җиһазланган. Кызлар җыелган, тула басарга әзерләнәләр. Стан коралар, Мәһинур тәрәзәдән карап җырлый.

М а һ и н у р. Ак тулалар тиз керешә,
Аркау буе тигез эрләнгәч;
Бик күңелсез кыз балага
Көткән яры килмәгәч.
Ай-һай, дусларым,
Дусларым, дус-ишләрем,
Аңламыйсыз йөрәгемнең
Ник ашкынып типкәнен,
Аңламыйсыз күңелем тәрәзәсен
Кемнең килеп чирткәнен.

Х о р. Җырлый-җырлый, гөрли-гөрли,
Өмәләрдә күңел ачабыз.
Ак оекка, ак чикмәнгә
Җырлап тула басабыз;
Яшьлек дәрте шатлыкларын
Колач җәеп кочабыз.

М а һ и н у р. Басам тула ак оекка,
Җырлыйм күңел боекка,
Хәлем сөйләп бирсәгезче
Җем-җем кара мыекка.
Ай-һай, дусларым,
Дусларым, дус-ишләрем,
Аңламыйсыз йөрәгемнең
Ник ашкынып типкәнен,
Аңламыйсыз күңелем тәрәзәсен
Кемнең килеп чирткәнен.

Х о р. Сырлы сәке өсләрендә
Безнең баскан ак тула
Үзе ап-ак, үзе йомшак,
Үзе бик спай була.
Ак чикмәнле егет күрсәм,
Эчкә шатлыгым тула.

С а җ и д ә керә.

С а җ и д ә. Кызлар, туланы мунча казанында пешекләдем, барыш алыгыз.

Г ө л с е м. Ярый, әни. Тимеркәй абыйлар кайтмадымы әле?

С а җ и д ә. Юк шул, кызым. Көтеп-көтеп кайтмагач, әтиең алырга үзе китте.

Г ө л с е м. Нишләп кенә яталар икән анда?

С а җ и д ә. Волостьтагы бөтен коммуннар исполкомга җыелганнар ди. Тимеркәй үзләренә нәрсәдер сөйли икән.

К а м ә р. Саҗидәттәй, Ислам абзыйларны чыгармаганнармы?

С а җ и д ә. Нишләп чыгарсыннар. Аларның гаепләре бик зур ди.

К а м ә р. Зур диеп инде, кеше үтергәннәре юктыр бит.

С а җ и д ә. Әхтәмҗан абзаң әйтә: кеше үтерүдән дә яманрак, ди. Зифабанулары аклар ягыннан шымчы булып кайткан бит. Ярый качып котылган. Кызлар, барыгыз инде, бар, тула суынмасын. Керен яхшылап сыга күрегез.

Кызлар китәләр. М ә р ф у г а керә.

М ә р ф у г а. Кеше кулына калмасыннар, ике яклап үксез йөрмәсеннәр дип, җиләк кебек яшь гомеремне кешедә ялчылыкта үткәрдем. Ә алар...

С а җ и д ә. Мәрфугаттәй, әйдә теге якка узыйк.

М ә р ф у г а. Юк, Саҗидә, узып тормыйм. Тимеркәем китәм дигәч, ризалык бирмәгән идем. Ни әйтсәң дә бала бит, җан тартмаса да, кан тарта, диләр, бик дөрес. Үзе кая соң, теге яктамы?

С а җ и д ә. Юк, Мәрфугаттәй, правление йортында. Коммуннарга нидер сөйли ди.

М ә р ф у г а. Әй, ходай орган бала...

С а җ и д ә. Мәрфуга түтәй, нигә инде алай борчыласың?

М ә р ф у г а. Борчылмый нишлим, Саҗидә. Кемнең баласы аның кебек йөри?

С а җ и д ә. Хәзерге яшьләр шулай инде. Безнең теләк белән генә йөрмиләр. Әнә Нарат Башының Мозаффар мулла кызы Фәүзия дә коммун булган ди.

М ә р ф у г а. Монда, үз янымда торса, бер генә түгел, биш катлы коммун булса да, сүз әйтмәс идем. Китәм диеп йөрәгемне өзә бит. Кара әле, Сәҗидә, солдатка киткәнче үк сезнең кызыгыз белән даннары чыккан иде, үзләрен, мин әйтәм, башлы-күзле итсәк ничек булыр икән?

С а җ и д ә. Белмим шул, Мәрфугаттәй, атасы ни әйтер бит.

М ә р ф у г а. Малайны бер дә җибәрәсе килми, шул сылтау белән без аны тотып калмасак, сез әйбәт кияүсез, мин малайсыз калам бит.

С а җ и д ә. Әнә кайталар. Бар, син теге якка уз, атасы белән сөйләшеп алырбыз.

Мәрфуга алгы бүлмәгә уза, Сәҗидә чыгып китә. Т и м е р к ә й белән Ә х т ә м җ а н кайтып керә.

Ә х т ә м. Шулай да, энем, бу дөньялар кайчанрак тынычланыр икән?

Т и м е р к ә й. Болай булса, Әхтәм абзый, чаптарыңа атланып, билгә кылыч, кулыңа мылтык алмыйча, тынычланмас, ахры.

Ә х т ә м. Юк инде, энем, мин үзем баш-аягым белән сугышка каршы кеше. Кытайны килештерергә бардым, япон сугышында йөрдем, үз өлешемә тигәнне үтәдем.

Т и м е р к ә й. Әгәр дә аклар килеп, алпавытларны үз имениеләренә кайтарып, җир-суларны кире алсалар да, сугышка каршы булыр идеңме?

Ә х т ә м. Нишләп алсыннар, хәзер бит хөррият, без теләмәгәч, ул ничек ала ди?

Т и м е р к ә й. Сорап торырлар! Бер мәртәбә түбәсенә сугып җиргә егылган дошманга ирек бир әле, җирләреңне алу гына түгел, әллә ниләр дә күрерсең.

Еракта буксир тавышы.

Ә х т ә м. Бу ни бу? Ике көннән бирле пароход юк иде.

Т и м е р к ә й. Димәк, Әхтәм абзый, икмәк баржасын алырга буксир килде.

Ә х т ә м. Бик әйбәт булган, матрос бик борчыла иде, ул бит фатирда бездә тора. Шул әйтә: Мәскәү халкы бер әчмүхә икмәк белән тора, ди. Унган кеше икән, төн димәде, көн димәде — ике-өч көндә бер баржалык икмәк җыйнады.

Тыштан әйбер күтәреп С а җ и д ә керә.

С а җ и д ә. Әхтәмҗан, теге егет тагын ат янында кайнаша. *(Бүлмәгә кереп китә.)*

Ә х т ә м. Тәмам язгы бизгәк булды бит, әкият. Сат та сат дип колагымны тондырып бетерде. Турысын әйтергә кирәк, энем, ул егеттән мин шикләнә башладым. Чаптарымны урлап китмәсә ярар иде.

Т и м е р к ә й. Курыкма, ул андый егет түгел. Атыгызны яратканга сөеп кенә йөри ул.

К о р б а н керә.

Ә х т ә м. Шулай да күзләре бик майлы. Ат бурыныкы төсле, янып торалар...

Б а ш к а т о в керә.

Ә х т ә м. Әйдә, Кузьмич, әйдә, рәхим ит. Хатын, хатын, кунак килде дим!

Корбан белән Әхтәм кереп китәләр.

Т и м е р к ә й. Йә, Кузьмич, әйләнә-тирәдә ничек, тынычлыкмы?

Б а ш к а т о в. Әйе, бөтен җирдә тынычлык. Әллә ничек, бүген кич тә бик матур... Ай яктысы... Кама өсте шулкадәр тын, шулкадәр гүзәл... Көзгедәй ялтырап ята... Тагын бер кат постларны тикшереп чыктым да су читендәге чуерташлыкка ятып тәмәке тарттым. Ничектер яшь чакларым исемә төшеп китте... Беләсеңме, Миңлекәев, һәр кешенең гомерендә нинди дә булса хатирә булырлык кадерле минутлары була... Менә бу кич тә миңа хатыным белән беренче мәртәбә танышкан кичемне хәтерләтте. Мин ул чагында Стахиевларның «Глушерма» заводында слесарь булып эшли идем. Ә Марияның Алабугада курста укыган чаклары. Без аның белән шундый айлы кичтә, көймә алдык та, суда йөрергә чыктык. Иж суын беләсең... «Глушерма» тирәсендә ул шундый матур итеп бормаланып-бормаланып җәелеп ага. Әйтерсең лә әкияттәге серле елга кебек... Бер ягында туйра, таллыклар, икенче ягында биек-биек тезмә таулар... Мин ишкәктә, ә ул, күбәләк шикелле, ак күлмәктән койрыкта... Йөри торгач, таң атканны сизми калганбыз. Кызык бит, ә?

Т и м е р к ә й. Әйе, Кузьмич, яшьлек, мәхәббәт кешеләрнең гомерендә бер генә була диләр бит. Шуңар күрә дә ул онытылмый. Менә без дә, шушы йортның кызы белән, мин солдатка киткәндә вәгъдәләр куешкан идек. Дөрес, бездә алай сездәге кебек су өстендә кыз белән егеткә көймәдә йөрергә ярамый. Без абзар артында, лапас астында очраша торган идек. Мин ул хатирәне фронтларда, постта торганда, окопларда искә төшерә идем...

Буксир пароходының китү тавышы ишетелә.

Б а ш к а т о в. Әһә, пароход кузгалды... Димәк, утыз мең пот икмәк тиешле кешеләренә озатылды.

Ә х т ә м керә.

Ә х т ә м. Әйдәгез, кунаклар, рәхим итегез.

Тимеркәй, Башкатов кереп китәләр. Сәхнә артында Самат тавышына Әхтәм тукталып кала.

Самат. Әхтәм өйдәме?!
Әхтәм. Әйдә, әйдә, кем ул?

Ашыгып Самат керә.

Әхтәм. Ә, председатель икән. Әйдә, Самат, эчкә узыйк.
Самат. Юк, узып тормыйм. Сиңа шуны әйтергә килдем, иртәгә подводага барырсың.
Әхтәм. Подводага? Кара әле, Самат, узыйк әле. Сөйләшә-сөйләшә утырырбыз.
Самат. Рәхмәт, вакытым юк. Атың белән үзеңә өч тәүлеккә җитәрлек азык алырга онытма.
Әхтәм. Әйдә әле, Самат. Кузьмич белән Тимеркәйләр дә бездә кунакта. Бергә-бергә сыйланып алырбыз. Башка вакытта чакырып та булмады үзеңне.
Самат. Син мин әйткәнне тыңла әле.
Әхтәм. Тыңлыйм, бик яхшы тыңлыйм. Теге якка узыйк әле.
Самат. Әйтәм бит, вакытым юк.
Әхтәм. Анлык кына табарсың. Әйдә инде, әйдә.
Самат. Юк, син ул кыставыңны куй әле, мин әйткәнне тыңла дим.
Әхтәм. Тыңлыйм ич инде, кая барырга соң?
Самат. Кайда икәнен анда әйтерләр.
Әхтәм. Тукта әле, Самат, мин бит узган атнаны гына Әгерҗегә бардым, аннан ат та сырхап тора. Башка берәүгә әйтергә иде.
Самат. Башкаларга да әйтелде. Бишбүләктән сиксән подвода кирәк.
Әхтәм. Кара әле, Самат...
Самат. Сүз көрәштерә торган чак түгел, таң ата башлауга ревкомда булырга!.. *(Китә.)*
Әхтәм. Алай... Күрәсең, эшләр бик шәптән түгел. Чаптаркайга солыны күбрәк салырга туры килер.

Егор кайтып керә.

Әхтәм. Егор дус, баягы пароход сиңа булмадымыни?
Егор. Миңа иде. Ашлык белән командамны озаттым.
Әхтәм. Ә үзең?
Егор. Үзем Вятская Полянага чыгам. Анда безнең тагын бер командабыз бар. Аларның да эшләрен миңа рәтләргә кушалар.
Әхтәм. Бик әйбәт булган, әйдә алайса, теге якка, табынга.
Егор. Рәхмәт, хозяин. Мин әйберләремне генә алырга кердем. Подвода алам да юлга чыгам.

Ә х т ә м. Юк, юк, кунак итми җибәрмим. Көне-төне өйдә тормагач, сыйлап та булмады.

Е г о р. Рәхмәт, хозяин. Болай да бик күп сыйладыгыз. Миңа иптәш Башкатовны чакырып чыгарсагыз иде.

Әхтәм китә. Башкатов белән әйләнеп чыга.

Б а ш к а т о в. Нәрсә, Егор?

Е г о р. Сезне срочно Алабугадан телеграфка сорыйлар.

Б а ш к а т о в. Әйдә алайса, киттек.

Ә х т ә м. Кузьмич, ә аш?

Б а ш к а т о в. Ашны инде, Хәкимҗанов, икенче вакытны ашарбыз. Хәзергә хушыгыз.

Е г о р. Хуш, хозяин, рәхмәт! *(Китәләр.)*

Ә х т ә м. Их, бу нинди кешеләр соң?.. Ашарга да вакыт таба алмыйлар. Чабалар, йөгерәләр... *(Кереп китә.)*

Тула күтәреп к ы з л а р кайтып керә. Станга сузып салалар.

Г ө л с е м. Әйдәгез, кызлар, тула суына башлаган.

М а һ и н у р. Кич салкында аваз биреп,
Күкрәк киереп җырласаң,
Җанга рәхәт булып китә,
Бер озын көй моңласаң.

Х о р. Әй, күңелле өмәсе!
Шунда яшьләр җыела,
Шунда уйнау, шунда көлү,
Шунда ярлар сөелә.

М а һ и н у р. Ач тәрәзәң өлгесен,
Ал чәчәкле гөллесен,
Ал чәчәкле гөлләрегез
Бар дөньяга күренсен.

Х о р. Әй, күңелле өмәсе!
Шунда яшьләр җыела,
Шунда уйнау, шунда көлү,
Шунда ярлар сөелә.

М а һ и н у р. Егетләр килә!

Гармунга җырлап, е г е т л ә р керә.

Е г е т л ә р. Сандугачлар усакта,
Китми алар кусак та,
Дошманнарга сер бирмәбез,
Дуслар исән-сау чакта.

С ә л ә х и. Нихәл, кызлар, бик сагынмадыгызмы?

М а һ и н у р. Саргаеп үләбез инде, Сәләхи абый.

С ә л ә х и. Барыгыздан да бигрәк Камәрбану сагынгандыр инде.

К а м ә р. Илаһи, гомеремдә дә күрмәсәм риза.

С ә л ә х и. Сагынырсыз әле, әй шул Сәләхи абыйны тагын бер кат күреп, уймак кебек авызыннан чут-чут итеп үбәсе иде, дип зар-интизар булып еларсыз әле.

К а м ә р. Сине сагынырга, өебезгә янгыр үтми бит әле.

С ә л ә х и. Ай-һай, Камәрбану, яучы җибәрергә йөри идем, болай булгач, җибәрмим инде. Бик ачы телле икәнсең.

К а м ә р. Җибәр, ник җибәрмисең! Кәнтәй бикәбез кичә генә бәбәйләде.

С ә л ә х и. Әй, җан кисәгем, багалмам, бик сагындым, күз алмам. Кич кунарга чакырсаң да, үпкәләмә — бара алмам.

К ы з л а р. Ха-ха-ха...

К а м ә р. Әнигә әйтим әле... *(Иркәләнеп елый.)*

Г ө л с е м. Камәрбану, бу ни кылануың?

К а м ә р. Нигә соң адәм актыгыннан мыскыл иттерәсез?

Г ө л с е м. Сәләхинең уйнап кылануын аңламаска тиле түгелсеңдер бит.

К а м ә р. Үз хәерчеләре, үз ишләре янына барып маймыллансын.

С ә л ә х и. Белмәдем бит, атаңа кантрибут салганда, сине дә кантрибутлыйсы калган икән.

Тышта исерекләр тавышы.

М а һ и н у р. Кызлар, тагы егетләр килә.

Г ө л с е м. Әллә исерекләр инде?

М а һ и н у р. Бәйрәмгалиләр.

К а м ә р. Бәйрәмгалиләр... *(Тәрәзәгә йөгереп менә.)*

С ә л ә х и. Кара, кара, күрдегезме?.. Иш ише белән, дуңгыз түше белән диләр, дөрес икән. Бәйрәмгали килә дигәч, тәрәзәдән төшеп йөгерә дип торам.

Җырлап Б ә й р ә м г а л и л ә р керә.

Б ә й р ә м. Уйсу җирнең солысын,
Җил коядыр корысын,
Гомерең булса онытмассың
Минем куйным җылысын.

Кызлар, нигә безне каршы алмыйсыз?

Г ө л с е м. Каршы алырга өйрәнмәгән, килгәннәргә ишек тишелгән.

Б ә й р ә м. Кызлар, нигә эндәшмисез? *(Маһинурга кагыла.)*

М а һ и н у р. Җибәр әле, Бәйрәм абый, сулышыңнан кәҗә тәкәсе исе килә.

Б ә й р ә м. Синең ишеләргә Бәйрәм абыеңның кул салуын дәрәҗә санарга кирәк.

Г ө л с е м. Бәйрәмгали, юньләп кенә кылан әле. Бездә кунаклар бар.

Б ә й р ә м. Нинди кунаклар?

Г ө л с е м. Мәрфугаттәйнең Тимеркәе белән кафтау арты егете.

Б ә й р ә м. Ә?!. Бик зур кешеләр икән! Бетмәс монда аның ише алаканатлар.

С ә л ә х и. Бәйрәм, эчкән булсаң, буеңа сеңдереп утыр.

Б ә й р ә м. Сеңдермәсәм нишләрсең?

С ә л ә х и. Сирәк җирең ешлармын.

Б ә й р ә м. Нәрсә дидең, нәрсә?

С ә л ә х и. Хатын-кыз янында гайрәт чәчеп йөрсәң, баскычтан тотып атарга да кыйбат алмам.

Б ә й р ә м. Әкрен, әкрен, хәерчеләр комитеты. Андый чакларыгыз үтте инде.

С ә л ә х и. Без әле яңа башларга торабыз.

Б ә й р ә м. Соңгарак калдыгыз. Идел аръягында чыбыркы шартлатып куян куганны ишетмисез, ахры.

С ә л ә х и. Шуңа күрә авыз ача башладык диген.

Б ә й р ә м. Ачарбыз әле, алла боерса, шундый итеп ачарбыз, бер кабуда йотарбыз. Атаңның салган кәнтрибуцияләрен костырырбыз.

С ә л ә х и. Нәрсә дидең? Тагын бер кат әйт әле.

Б ә й р ә м. Кит каршымнан! *(Төртә.)*

С ә л ә х и. Әле сез шулай кул да озайта башладыгызмыни? Менә сиңа, елан! *(Суга.)*

Бәйрәм тәгәрәп китә. Бәйрәм иптәшләре Сәләхигә ташлана. Сәләхи яклары тегеләргә каршы төшәләр. Т и м е р к ә й, Ә х т ә м, К о р б а н чыга.

Т и м е р к ә й. Егетләр, бу ни эшләвегез?

С ә л ә х и. Мин сине этне буган кебек буармын!

Т и м е р к ә й. Сәләхи, бу ни кылануың? *(Аера.)*

С ә л ә х и. Синең йөрәгең янган чакта пычак белән ярып тоз сибә. Эчеп кергәннәр дә салган кәнтрибутларыгызны дип яныйлар... у-у!.. Канат чыгара башладыгызмыни?

Т и м е р к ә й. Җитәр, Сәләхи! Ә сез таегыз моннан.

К о р б а н. Шагом марш! *(Куып чыгара.)*

Әхтәм озата китә.

С ә л ә х и *(үзен-үзе өзгәләп)*. Дурак булдык шул, аның ише еланнарның муенын өзеп ташлыйсы калган. Аклар килә дигән хәбәрне ишеткәч, нишлиләр...

Т и м е р к ә й. Их, егетләр!.. Сез аларның фронтта ниләр эшләгәнен белсәгез иде. Уфа янында сугышта безнең берничә кызылармеецыбыз, урманда адашып, акларга эләккәннәр. Бәйрәм кебек кулак балалары мескеннәрнең колак-борыннарын кисеп тереләй җиргә күмгәннәр.

С ә л ә х и. Бүген таң атыш, иртәгә көн тусын әле, мин ул бүреләрне өч аяктан сикертмәсәм, исемем Сәләхи булмасын.

Г ө л с е м. Кызлар, егетләр, әйдәгез, уйнап-көлеп алыйк.

М а һ и н у р. Әйдәгез, йөзек салыш уйныйбыз.

С ә л ә х и. Юк, кызлар, сукыр тәкәле.

Г ө л с е м. Юк, Сәләхи, табышмаклы уйныйбыз.

С ә л ә х и. Минем өчен бары да бер. Тик миңа каршы чыгарга хәлеңнән киләме?

Г ө л с е м. Әллә курка дисеңме? *(Сәләхи каршысына чыгып баса.)* Әйдә.

М а һ и н у р. Шауламагыз, башлыйлар.

Г ө л с е м. Еллар буе канат кагыш
Талпынса да, оча алмыйдыр,
Ач аюдай көн дә улап,
Азык ашап туя алмыйдыр.
Булса да ул туймас карын,
Бар халыкны тук кыла.
Әйтеп бирче, җор егетем,
Шул нәрсәкәй ни була?

С ә л ә х и. Булса да ул туймас карын, бар халыкны тук кыла. *(Уйлана.)* Тегермән.

Е г е т л ә р. Молодец, Сәләхи, тегермән шул.

Г ө л с е м. Егетләр, мин Сәләхигә юри генә җиңел табышмак биргән идем.

Е г е т л ә р. Юк инде, шыртма.

С ә л ә х и. Курыкмагыз, егетләр, Сәләхидә анлык кына тапкырлык табылыр әле. Әйдә, Гөлсем.

Г ө л с е м. Өермәләр өеп, утлар атып,
Җир, күкләрне тотып селкетә,
Селкетә дә йомшак җилләр белән
Илгә байлык чәчеп беркетә.
Киң яланнар, буш далалар
Иркен сулап тын ала,
Барлык кошлар, хайванәтләр,
Бар табигать шатлана.
Илдән-илгә һич тә армый йөрсә ул,
Бар халыкка шатлык биргән нәрсә ул.

С ә л ә х и. Бар халыкка шатлык биргән нәрсә ул... *(Уйлана.)* Таптым! Күк күкрәп, яңгыр яву.

Е г е т л ә р. Дөрес, Сәләхи, яңгыр.

С ә л ә х и. Йә, егетләр, җиңелүчеләргә нинди җәза бирәбез?

Е г е т. Яраткан егетен өч тапкыр үбәргә.

С ә л ә х и. Әйдә, Гөлсем, малай, чәпелдәт... *(Авызын очлайтып көйләп тора.)*

Гөлсем Тимеркәйне кочаклап үбә. Тәрәзәдә С а м а т күренә.

С а м а т. Тимеркәй, Тимеркәй, дим. Иптәш Башкатов хәзер үк ревкомга килергә кушты. Кызлар, егетләр, таралыгыз!

Т и м е р к ә й. Әйдә, Корбан. *(Китә.)*

К о р б а н. Хушыгыз.

М а һ и н у р. Кунак егете, кая барасың?

К о р б а н. Мине ревкомга чакырганнар.

М а һ и н у р. Җибәрмибез, җибәрмибез. Бераз уйнап алабыз.

С ә л ә х и. Туктагыз әле, бу әти нигә таралырга кушты икән?

М а һ и н у р. И, аңа карамыйбыз ла. Кунак егетенә үзем бер табышмак бирәм. «Башы бар, мие юк, биле бар, корсагы юк, койрыгы бар, йоны юк». Шул ни була, егет асылы, нәкъ өстенә бас әле.

К о р б а н. Башы бар, мыегы юк, койрыгы бар, йоны юк! *(Уйлана.)* Таптым! Белмим.

М а һ и н у р. И, җебегән, шуны да белмәдең, бик җиңел нәрсә иде. Чабата.

К о р б а н. Бездә чабата кимиләр.

М а һ и н у р. Кызлар, нинди җәза бирәбез?

К ы з л а р. Җырласын, җырласын.

М а һ и н у р. Юк, кызлар, аны бик шәп биюче диләр. Биетәбез.

Кавказча бию көе уйнала. Корбан бии башлый. Тышта атышлар ишетелә. К о р б а н туктап кала. Ә х т ә м керә.

Ә х т ә м. Яшьләр, таралыгыз! Бишбүләк читендә сугышлар бара!

К о р б а н. Сау бул, гүзәл Махимур. *(Сәләхи белән китәләр.)*

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге Ислам байның ишегалды. Пәрдә ачылганда К у р б а т о в белән М и н г у л о в кладовойдан талашып чыгалар.

К у р б а т о в. Яхшылыкта бирәсеңме, юкмы, дим?

М и н г у л о в. Бирмим!

Тартышалар. Ю р г а т а е в керә.

Ю р г а т а е в. Встать! Смирно! Нигә сугышасыз?

К у р б а т о в. Кавказ егетенең киемнәрен салдырган идек. Вот Мингулов черкескасы белән чалбарын үзенә алмакчы була.

Ю р г а т а е в. Кая, китерегез әле.

М и н г у л о в. Прапорщик әфәнде...

Ю р г а т а е в. Молчать! Итеге белән бүреге кайда?

М и н г у л о в. Алары әнә Курбатовта.

Ю р г а т а е в. Бир монда! *(Корбанның киемнәрен алып китә.)*

К у р б а т о в. Миннән җәлләгән идең, барыбер үзеңә дә булмады.

М и н г у л о в. Сиңа да бит тәтемәде.

Урамнан М ә р ф у г а белән М а һ и н у р керә.

М и н г у л о в. Соң, ничек, таптыгызмы?

М а һ и н у р. Юк, абый, бер җирдә дә юк... Волостной правление йортында да, караул өендә дә булдык, юк, диләр.

М ә р ф у г а. Улым, тагын бер кат язуыңны кара әле, сездә түгелме?

К у р б а т о в. Әйттем бит инде, бабушка, Тимеркәй Миңлекәев дигән кеше бездә күренми.

М ә р ф у г а. Кайда гына булыр икән ул бала?

Урамда М а х и а н тавышы.

М а х и а н. Балык сатам, балык, кем ала?

М а һ и н у р. Әни, Махиан абый.

Җепкә тезгән балыклар тотып М а х и а н керә.

М а х и а н. Нихәл, Мәрфуга?

М ә р ф у г а. Шөкер әле, абый.

М а х и а н. Господаларыңа балык кирәкмиме икән?

М ә р ф у г а. Әй, абый, миндә алар кайгысы юк әле. Тимеркәем өчен ут йотам. Әле генә эзләп кайттык. Үлеләр арасында да, ябылганнар арасында да юк.

М а х и а н. Кайгырма, Мәрфуга, ул исән... Таң алдыннан Кузьмич белән миндә булдылар. «Чилчә» урманнарына киттеләр. Аннан, кызым Маһинур, абыеңның иптәше Кавказ егете кайда икән, миндә аңа абыеңнан әманәт бар иде.

М а һ и н у р. Аны бит, абый, тоттылар.

М а х и а н. Тоттылар, ничек алай?

М а һ и н у р. Сәләхи абый белән өмәдән чыгып барганда Бәйрәмгалиләр искәртмәстән башына кендек белән сукканнар да тотып япканнар.

М а х и а н. Абыең менә шушы хат кисәген аңа тапшырырга кушкан иде.

М а һ и н у р. Ничек тапшырыйм? Ул бит кладовойда утыра.

М а х и а н. Үзең җаен табарсың инде. Мә... Балык сатам, балык, кем ала? *(Кычкырып югала.)*

Маһинур белән Мәрфуга китә. И с л а м , Б ә й р ә м г а л и , п о п , м у л л а һәм б а ш к а л а р керә.

И в а н. Эх... Башкатов дигән ата большевикны ычкындырганнар. Бугазын чәйнәрмен дигән идем.

И с л а м. Кайгырмагыз, дусларым, беркая да китә алмаслар. Пермь ягыннан килгән гаскәрләр белән бу яктан үтүчеләр кушылганнар. Алар хәзер камалып калдылар. Командирның помощнигы да таныш кеше булып чыкты. Күрше боярыбызның улы — Чингизов.

И в а н. Владимир Асланович?.. Ну, алайса тиреләрен үтмәс пычак белән туныйбыз икән.

И с л а м. Бәйрәмгали, тагын да язасы кешеләр калмагандыр бит?

Б ә й р ә м. Тегеләр арасына Сәхәбине кыстырмыйбызмы?

И с л а м. Кыстыр, кыстыр, җыен булса: байлар, байлар, дип ул кычкыра торган булган.

И в а н. Коры кыстыруда мәгънә юк, боярларның имениеләрен, аракы заводын талаучыларның башлыгы дип куярга кирәк.

Ю р г а т а е в. Смирно! Ударный бригада командиры полковник Һайдель җәнаплары килде!

Һ а й д е л ь, Ч и н г и з о в, В а р л а м о в керәләр.

Һ а й д е л ь. Исәнмесез, Бишбүләкнең могтәбәр картлары!

Б а ш к а л а р. Хуш килдегез, сәламәтлек телибез!

И с л а м. Большевиклар кулыннан коткаручы армиягә Бишбүләк крестьяннарыннан икмәк белән тоз, рәхим итеп алыгыз.

Һ а й д е л ь. Рәхмәт, сезнең белән танышырга рөхсәт итегез.

Ю р г а т а е в. Бу әфәнде иң атаклы сәүдәгәрләребездән Исламгәрәй Асылгәрәевич Дулатов.

Һ а й д е л ь. Исәнмесез, Дулатов әфәнде!

И с л а м. Бусы берничә тегермәннәре белән мәшһүр булган Иван Иваныч Толстопузов.

И в а н. Бу әфәнде бакалея сәүдәгәренең улы — Бәйрәмгали Сәфәргалиев.

Б ә й р ә м. Герман сугышында старший унтер-офицер идем.

И с л а м. Бусы авылыбызның учитель кисәге — Идрис әфәнде Салихов.

И д р и с. Гафу итегез, гади учитель генә түгел, эсерлар партиясенең әгъзасы.

Һ а й д е л ь. Әһә... Социалист?.. Әфәнделәр, безгә киңәшкә керергә рөхсәт итегез.

Б а ш к а л а р. Рәхим итегез.

Һайдель белән офицерлар өйгә кереп китәләр.

И с л а м. Әй, дусларым, яхшы кешеләрнең авызыннан чыккан сүзләренә майдай эреп китәсең. «Әфәнделәр, безгә киңәшкә керергә рөхсәт итегез», — ди бит.

И в а н. Образованный кешеләр большевиклар кебек түгел шул. Минем белән күрешкәндә шундый ачык чырай белән кулымны кысты, мин андый кул кысуны икмәк купецы Стахиевлардан да күргәнем булмады.

И д р и с. Культурный кешеләр эсерларны ярата шул. Минем социалист дигән сүземне ишеткәч, шәм кебек катып калды. Честь бирергә теләгән иде дә, сездән тартынды бугай.

Һ а й д е л ь һәм б а ш к а л а р чыга.

Һ а й д е л ь. Әфәнделәр, халык армиясенең командованиесе тарафыннан Бишбүләк волость аппаратына түбәндәге кешеләр күрсәтелә:

В а р л а м о в *(приказ укый).* Армия уполномоченные һәм волостной старшиналыкка — Исламгәрәй Дулатов. Волость судьялыгына — Иван Иванович Толстопузов. Волость полиция начальнигы итеп Бәйрәмгали Сәфәргалиевләр билгеләнделәр.

И д р и с. Командир әфәнде, андый урыннарга сайланып...

Һ а й д е л ь. Сезнең белән соңыннан сөйләшербез. Калган назначениеләр Дулатов әфәнде тарафыннан билгеләнәләр. Башка мәсьәләләр турында минем урынбасарым господин Чингизов, адъютантым Варламов белән сөйләшерсез.

Ч и н г и з о в. Әфәнделәр, әйдәгез минем белән.

Һайдель белән Идристән башкалар өйгә кереп китәләр.

Һ а й д е л ь. Социалист әфәнде, япон сигаретасы белән сыйларга рөхсәт итегез.

И д р и с. Рәхмәт. Без мондый папиросларны күптән күргәнебез юк инде.

Һ а й д е л ь. Алай булса коробкасы белән алыгыз.

И д р и с. Юк, командир әфәнде, яхшы түгел...

Һ а й д е л ь. Алыгыз, ал. Кирәк нәрсәгез булса сорагыз... Без сезгә барын да биреп торырбыз. Кием-салым, ашау-эчү һәм башкалар.

И д р и с. Сез бигрәк тә инде, командир әфәнде... Зурлавыгыз өчен рәхмәт.

Һ а й д е л ь. Социалист әфәнде, без сезгә бик зур дәрәҗәле бер урын бирергә уйлый идек.

И д р и с. Нинди урын ул, командир әфәнде?

Һ а й д е л ь. Безнең бригадада мобилизовать ителгән татар-башкортларның саны шактый гына бар. Без сезне бригаданың мулласы итеп куярга телибез.

И д р и с. Мулла?.. Мин бит социалист кеше.

Һ а й д е л ь. Зарар юк. Мин үзем дә социалист кеше, ләкин большевиклар белән рәхимсез көрәш вакытында сөйләнеп тору зарарлы. Безнең һәркайсыбызның да теләге бер: большевикларны җиңү, аларның халык арасына чәчеп калдырган большевизм идеясен төбе-тамыры белән йолкып ташлау...

И д р и с. Анысы дөрес. Ләкин мулла булу — минем идеалыма каршы эш.

Һ а й д е л ь. Зарар юк. Мулла дигәч тә сез мәчеткә йөреп намаз укымассыз. Сез фәкать гаскәр арасында, дин-милләт исеменнән беседалар үткәреп, большевизмга дошманлык тудырырга тырышырсыз.

И д р и с. Белмим шул, ничек булыр икән?

Һ а й д е л ь. Бик яхшы булыр, социалист әфәнде. Менә шушы язу белән хуҗалык начальнигына барырсыз, ул сезгә кирәк әйберләрегезне бирер.

И д р и с. Рәхмәт сезгә. *(Китә.)*

Д ж о н с о н керә.

Д ж о н с о н. Рөхсәт сорыйм.

Һ а й д е л ь. Рәхим итегез.

Д ж о н с о н. Цивилизацияле илләрнең корреспонденты Джонсон.

Һ а й д е л ь. Сезне күрүемә мин бик шат. Килүегез турында хәбәр иткәннәр иде, ни өчендер озакладыгыз.

Д ж о н с о н. Бу варварлар илендә транспорт төрләренең примитив хәлдә булуы миңа тоткарлык ясады. Сез мине гафу итегез, чехословак корпусы офицеры булуыгызны искә алып, турыдан-туры сөйләргә уйлыйм.

Һ а й д е л ь. Әлбәттә. Без европалыларның көнчыгыш кыргыйларына карата булган карашлары теләсә нинди шартларда да яшәргә тиеш.

Д ж о н с о н. Сез хәзер миңа фронт хәлләре турында сөйләгез.

Һ а й д е л ь. Фронтта моңа кадәр бөтен инициатива безнең кулда иде, ләкин кичә Казан белән Әгерҗе арасындагы тимер юл сызыгы буйлап Азин дивизиясен куйдылар. Кайбер участокларда

контрһөҗүмгә күчтеләр. Бүген безнең бер авылны алдылар. Казан аша бертуктаусыз яңа частьлар ташыйлар.

Д ж о н с о н. Хәзер ташый алмаслар инде. Казан безнең кулда.

Һ а й д е л ь. Безнең кулда? Кайчан?

Д ж о н с о н. Моннан берничә сәгать элек Самара группировкасы тарафыннан төшерелгән десант белән алынды. *(Карта чыгарып.)* Хәзер Казандагы Самара группировкасы юнәлешне Москвага борачак. Сезнең частьларыгыз Пермь частьлары белән берлектә Казан — Екатеринбург тимер юл сызыгын большевиклардан бушатып, Ярославль шәһәренә барып чыгачак. Аннан инде, полковник әфәнде, безгә Архангельск, Мурманскидагы дусларыбыз кулларын сузачак. Шулай итеп, Россиянең язмышы хәл ителәчәк.

Һ а й д е л ь. Гафу итегез, сэр, сезне кем дип аңларга?

Д ж о н с о н. Рәхим итегез. *(Документ чыгарып бирә.)*

Һ а й д е л ь *(укып)*. Бөекбритания армиясенең полковнигы?

Д ж о н с о н. Бик дөрес.

Һ а й д е л ь. Гафу итегез, полковник әфәнде, сезгә булган ихтирамлы хезмәтемнең беренчесе нидән торырга тиеш?

Д ж о н с о н. Беренчедән, Париж, Лондон һәм Нью-Йорк газеталарыннан корреспондент булып килүемне һәм миңа теләгән чагымда армия арасында йөрергә рөхсәт бирүегезне бригадагыз буенча игълан итәрсез. Икенчедән, төп вазифам — сезнең хәрби консультантыгыз булуымны сер итеп сакларсыз.

В а р л а м о в керә.

В а р л а м о в. Полковник әфәнде, армия штабыннан сезне аппаратка сорыйлар.

Һ а й д е л ь. Әйдәгез, полковник әфәнде...

Д ж о н с о н *(бүлдереп)*. Тссс... Корреспондент.

Һ а й д е л ь. Әйе... сэр, корреспондент. *(Өйгә кереп китәләр.)*

Җирле кара көчләрне ияртеп Ч и н г и з о в чыга.

Ч и н г и з о в. Ярый, әфәнделәр,эшкә башлагыз.

Китәләр. Өйдән З и ф а чыга.

Ч и н г и з о в. Йә, Зиночка, тыныч йокладыгызмы?

З и ф а. Революция булганнан бирле мондый тыныч йокы күргәнем юк иде. Ләкин арестованныйлар шаулашып уяттылар.

Ч и н г и з о в. Ул этләрне моннан алырга кирәк булыр.

З и ф а. Мин мәсьәләне этиләргә чиштем.

Ч и н г и з о в. Чиштең? Нәрсә диделәр?

З и ф а. Шундый кеше киявебез булу иң зур бәхетләрнең берсе, дип шатландылар. Ярый, Володя, мин лазаретка киттем, обедны бездә ашарбыз. Аннан соң бераз ял итеп алырбыз, яме?

Ч и н г и з о в. Ярый, Зиночка.

Зифа китә. Ә х т ә м һәм к р е с т ь я н н а р тавышы.

Ә х т ә м. Җибәрегез мине, җибәрегез.

К у р б а т о в керә.

Ч и н г и з о в. Ни бар анда?

К у р б а т о в. Сезнең приказыгыз буенча безнең солдатлар Әхтәм исемле кешенең атын алырга барганнар иде, ат иясе каршылык күрсәткән. Көчләп ала башлагач, атының муенына ябышып монда килгән.

Ч и н г и з о в. Бар, әйт, монда кертсеннәр.

Курбатов китә. Ә х т ә м н е кертәләр.

Ч и н г и з о в. Нигә алай тавыш чыгарасың?

Ә х т ә м. Ваша благороди, сезнең солдатларыгыз минем атымны талап алдылар.

Ч и н г и з о в. Атыңны алырга мин куштым.

Ә х т ә м. Син куштың? Минем бердәнбер атымны алырга хакыгыз юк!

Ч и н г и з о в. Бар, кайтып кит! Атың халык армиясенә алына!

Ә х т ә м. Көпә-көндез кеше талагач, ул нинди халык армиясе булсын?

Ч и н г и з о в. Егерме биш шомпол бирегез дә кладовойга кертеп ябыгыз.

Алып китә башлыйлар.

Ә х т ә м. Тәмам имансыз икәнсең. Ат карагы, жулик!

Ч и н г и з о в. Алып китегез.

Әхтәмне алып китәләр. Һ а й д е л ь керә.

Һ а й д е л ь. Бу нинди экзекуция?

Ч и н г и з о в. Атын алган өчен буза күтәрергә килгән иде. Акылга утыртырга туры килде.

Һ а й д е л ь. Господин Чингизов, мондый эштә тактика кирәк.

Дуңгыз суйгандай кеше кыйныйсыз. Ә урамда толпа җыелганны күрмисез.

Ч и н г и з о в. Ул мужик большевизм белән агуланган кеше. Андыйлар белән башкача көрәшергә мөмкин түгел.

Һ а й д е л ь. Большевизм белән ничек көрәшергә мине өйрәтмәгез! Моннан соң андый тактикасыз җәзалар минем әмеремнән башка эшләнмәсен. Ударный бригада командирының гына приказлары закон булырга тиеш. *(Кереп китә.)*

Ч и н г и з о в. Ярый, килмешәкләр! Вакыт җитәр, большевиклар ашаган йодрыкны сез дә ашарсыз әле.

Кладовойдагы арестованныйлар шаулашалар.

Ч и н г и з о в. Юргатаев!

Ю р г а т а е в кереп баса.

Ю р г а т а е в. Ни боерасыз, штабс-капитан әфәнде?

Ч и н г и з о в. Хәзер үк шулардан допрос алыгыз да волость каталажкасына илтеп ябыгыз.

Ю р г а т а е в. Тыңлыйм, штабс-капитан әфәнде.

Чингизов кереп китә. Юргатаев исемлектән карап кычкыра.

Ю р г а т а е в. Мозаффарованы бирегә!

Фәүзияне кладовойдан чыгаралар.

Ю р г а т а е в. Шундый матур кыз бала. Ха-ха-ха... Нинди гаеп эшләдең соң, туганкай?

Ф ә ү з и я. Бернинди дә.

Ю р г а т а е в. Ә ни өчен яптылар?

Ф ә ү з и я. Белмим.

Ю р г а т а е в. Ничек инде белмисең?

Ф ә ү з и я. Халыкка хезмәт итүдән башка бернинди дә гаебем юк иде.

Ю р г а т а е в. Ә соң Мазар Асты авылында митинг үткәрүегез, байлардан унике подвода икмәк алдыруыгыз гаеп түгелме?

Ф ә ү з и я. Һич! Москва, Петроград кебек ачка интеккән шәһәрләргә икмәк җибәртүдә азмы-күпме ярдәмем тигән икән, ул минем кешелек намусым белән вөҗдан фидакарьлегем.

Ю р г а т а е в. Курбатов! Конвой командасына чыгарып тапшырыгыз, минем квартир хуҗамның келәтенә япсыннар.

Ф ә ү з и я. Юк, юк, мин анда бармыйм.

Ю р г а т а е в.Алай холыксызланмагыз. Сез бит кыз кеше, сезне ирләр янында тотарга закон белән дә, шәригать белән дә ярамый.

Ф ә ү з и я. Алар миңа уңайсызламыйлар, мине алардан аермагыз. Ә инде келәт турында уйлап та карама, бугазыңны чәйнәп өзәрмен.

Ю р г а т а е в. Алыгыз!

Фәүзияне алып китәләр.

Ю р г а т а е в. Корбангали Айвазов!

Корбанны чыгарып бастыралар.

Ю р г а т а е в. Син кем?

К о р б а н. Менә, рәхим итегез.

Ю р г а т а е в. Бу ни бу?

К о р б а н. Гариза.

Ю р г а т а е в. Нинди гариза?

К о р б а н. Армиягезгә доброволь итеп алуыгызны сорап язган гаризам.

Ю р г а т а е в. Доброволь итеп? Син бит Кызыл Армиядә дә доброволь булгансың.

К о р б а н. Минем бөтен гомерем доброволь. Николай патшаның Кавказ дикий дивизиясендә доброволь, Кызыл Армиядә доброволь, телисез икән, сезнең армиягездә дә доброволь булып хезмәт итә алам.

Ю р г а т а е в. Ә ни өчен кулга алганда ике кешене чәнечтең?

К о р б а н. Үзегез уйлап карагыз, комендант әфәнде, төн, караңгы, биш-алты кеше искәртмәстән һөҗүм иткәч, мин аларны бандитлар дип уйладым. Мин дә бит кеше, үләсем килмәде. Бәхетләре, тимер белән башыма сугып аяктан екмасалар, мин аларның барысын да тураклап ташлый идем. Сез мине үзегезгә алыгыз, минем нинди кеше икәнемне киләчәктә таныхсыз. Валлаһи дип әйтәм, таныхсыз!..

Ю р г а т а е в. Карап карарбыз. Кире кертеп ябыгыз.

Корбанны кире кертеп ябалар.

Ю р г а т а е в. Сәләхи Саматов!

Сәләхине чыгаралар.

Ю р г а т а е в. Атаң кем?

С ә л ә х и. Тимерче.

Ю р г а т а е в. Нигә ялганлыйсың? Ярлылар комитеты председателе бит.

С ә л ә х и. Шулай икәнен белгәч, нигә сорыйсың?

Ю р г а т а е в. Контрибуцияләр салдыңмы?

С ә л ә х и. Салдым.

Ю р г а т а е в. Большевикларга ялчы булып Кызыл Армиягә китәргә йөрдеңме?

С ә л ә х и. Йөрдем.

Ю р г а т а е в. Тула өмәсендә кешеләр кыйнадың, утын агачы! *(Суга.)*

Сәләхинең борыныннан кан китә.

Ю р г а т а е в. Сөрт борыныңны, гадость...

С ә л ә х и. Суга белмисең икән, менә шулай сугалар аны!! *(Алагаемга суга.)*

Юргатаев тәгәрәп китә, Сәләхи ындырга таба йөгерә.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Ислам байның ишегалды. Вакыт иртә белән. М а һ и н у р терраса өстәлендәге чынаяк һәм бушаган шешәләрне җыештырып йөри. Пассажир пароходының кычкыртып туктаганы ишетелә. Сакалмыеклары җитүле, гади крестьян киеменнән Т и м е р к ә й керә.

М а һ и н у р. Абзый, әле беркем дә йокыдан тормаган. Әнкәем лә... Бу бит, абый, син?

Т и м е р к ә й. Чү, Маһинур, шаулама, әни йоклыймы?

М а һ и н у р. Ул бит өйдә юк. Саклау Баш авылына карлыган җыярга җибәргәннәр иде.

Т и м е р к ә й. Йә, монданиләр бар?

М а һ и н у р. Нәрсә булсын, көне-төне эчәләр. Бик күп кешеләрне кулга алдылар.

Т и м е р к ә й. Менә нәрсә, Маһинур. Безгә синең ярдәмең кирәк.

М а һ и н у р. Нинди ярдәмем?

Т и м е р к ә й. Менә бу өндәмәләрне сиңа калдырам. Солдатлар, крестьяннар арасына ничектер таратасы иде.

М а һ и н у р. Нинди өндәмәләр ул?

Т и м е р к ә й. Акларга каршы өндәп басылган кәгазьләр.

М а һ и н у р. Юк, юк инде, абый, монысын мин алмыйм. Әй, ходаем, капкада кеше бар.

Т и м е р к ә й. Качыр мине.

Маһинур Тимеркәйне ишек артына яшерә. Б ә й р ә м г а л и керә.

Б ә й р ә м. Маһинур, Исламгәрәй абзыйны уята алмассыңмы? Бик ашыгыч йомышым бар иде.

М а һ и н у р. Әйтеп карармын. *(Өйгә кереп китә.)*

Бераздан И с л а м белән М а һ и н у р өйдән чыга.

Б ә й р ә м. Исламгәрәй абзый, тәмле йокыгыздан уятуым өчен гафу итегез.

И с л а м. Нәрсә бар?

Б ә й р ә м. Бүген төнлә Щербаково авылындагы унике мобилизованный егетебез халык армиясенә барудан баш тартып партизаннар янына киткәннәр.

И с л а м. Партизаннар янына?

Б ә й р ә м. Исламгәрәй абзый, йә, нишләргә кушасыз?

И с л а м. Кул астындагы полиция частьларын алырга да, баш тартучыларның мал-милекләренә конфискация ясарга, ата-аналарын, семьяларын кулга алып монда китерергә!

Б ә й р ә м. Тыңлыйм, господин старшина. *(Китә.)*

Зур чемодан тотып И д р и с керә.

И д р и с. Хәерле иртәләр, Исламгәрәй әфәнде.

И с л а м. Һу!.. Идрис әфәнде, кайчан кайттыгыз?

И д р и с. Яңа гына, иртәнге пароходта, бригада командиры Һайдель җәнаплары белән бер каютада.

И с л а м. Сөйләгез, нинди хәбәрләр алып кайттыгыз?

И д р и с. Хәзер сөйләрмен. Иң элек, Һайдель җәнапларының приказы буенча, менә бу әманәтләрне тиешле кешеләренә тапшырырга кирәк.

И с л а м. Нинди әманәтләр соң алар?

И д р и с. Милләт мәҗлесе белән халык армиясе баш командованиесенең бөтен Россия мөселманнарын большевикларга каршы өндәп чыгарган хитапнамәләре.

И с л а м. Хитапнамәләре?.. *(Бер кәгазь алып укый.)* Россия мөселманнарына! *(Авыз эченнән.)* Эм... *(Кычкырып.)* «Халык армиясенең гали командованиесе, милләт мәҗлесе илә берлектә, Мөхәммәт сәлаллаһи галәйһиссәлам полклары төзергә кереште. Үзенең милләтен ихтирам иткән, аның һәлакәткә төшүен теләмәгән саф калебле мөселманнар, халык армиясенең мобилизацияләрен көтеп тормыйча, Мөхәммәт полкларына доброволь булып язылсыннар». Әйбәт, бик әйбәт һәм бик вакытлы булган.

И д р и с. Шуның өчен дә Һайдель җәнаплары бүген үк авылларга җибәрергә кушкан иде.

И с л а м. Бүген үк түгел, Идрис әфәнде, хәзер үк таратырбыз. Маһинур! Эшеңне ташла, менә бу кәгазьләрне егерме кисәккә бүлеп бик яхшылап төреп бирерсең.

М а һ и н у р. Абзый, минем эшләрем күп иде, башка берәрсенә куша алмассыңмы?

И с л а м. Нинди эшләр ул кадәр?

М а һ и н у р. Өйләрне җыештырып бетерәсем бар. Офицерларның керләрен юарга куштылар. Аннан тагы...

И с л а м. Ярый, ярый, акыл сатып каршы сөйләмә. Көн җитмәсә, башланмаган төнең бар. Шулай егерме кисәккә бүләрсең дә, өсләреннән җепләр белән бәйләрсең. Әйдә, Идрис әфәнде, чәй янында миңа Уфа хәбәрләрен сөйләрсең.

Китәләр.

Т и м е р к ә й чыга.

М а һ и н у р. Абый, зинһар өчен кит инде, харап булабыз.

Т и м е р к ә й. Шаулама, Маһинур, бик шәп булды бу. *(Төенне чишеп өндәмәләрне өстәлгә куя.)* Бир кәгазьләреңне. *(Идрис китергән хитапнамәләрнең күп өлешен алып ашъяулыкка төрә.)*

М а һ и н у р. Тукта әле, абый, син нишләргә телисең?

Т и м е р к ә й. Соңыннан белерсең, сеңелем, соңыннан. Ә хәзергә минем өндәмәләрне урталарына салыш, алар әйткәнчә төрә башла.

Ашыга-ашыга төрәләр. М и н г у л о в керә.

Т и м е р к ә й. Әй, кызый, мин килгәнне старшинага әйтерсең, мин полковник Һайдель янында булырмын.

М а һ и н у р. Ярый, абый, әйтермен.

Тимеркәй төенен тотып чыгып китә.

М и н г у л о в. Нишлисең, акыллым?

М а һ и н у р. Менә, кәгазь төрергә куштылар. Әйдә, булыш әле миңа.

М и н г у л о в. Нинди кәгазьләр соң алар?

М а һ и н у р. Укып кара, белерсең.

М и н г у л о в. Укый белсәм, синнән дә сорап тормас идем, белмим шул.

М а һ и н у р. Мөфти хәзрәт дигәннәренең мөселманнарны кызылларга каршы өндәп чыгарган фәрманы.

М и н г у л о в. Алар өндәргә беләләр, тик менә монда, сугышка гына килмиләр. Кара әле, акыллым, синең яныңа килеп йөрүче кем ул?

М а һ и н у р. Кайсы? Әле чыгып киткән кешеме?

М и н г у л о в. Юк, кичә килгән иде бит, таза гына бер нәрсә, кызмы, киленчәкме дим.

М а һ и н у р. Ә, Гөлсем түтәйне әйтәсең икән. Әллә күзең төштеме?

М и н г у л о в. Күз төшәр дә бит, безнең кебек ак солдатка кемнәр карасын?..

М а һ и н у р. Нигә алай дисең, ул да сине ошаткан.

М и н г у л о в. Ялганлыйсың ла...

М а һ и н у р. Җир йотсын әгәр.

М и н г у л о в. Нәрсә дигән була?

М а һ и н у р. Аклар арасында да әйбәт егетләр булыр икән, ди.

М и н г у л о в. Авылыбызда күз өстендә каш идек тә, мобилизовать итеп башны ашадылар. Бай булмасак та, атыбыз да, сыерыбыз да бар иде. Син аңар әйтеп кара әле, келәтенә кертмәсме икән?

Урам яктан Ю р г а т а е в керә.

Ю р г а т а е в. Встать смирно! Чабата авыз... Атларыңны карамый нишләп монда йөрисең?

М и н г у л о в. Виноват, господин комендант.

Ю р г а т а е в. Встань как следует! Руки по швам! Кругом, марш!

Мингулов борылып солдатларча атлап китә.

Ю р г а т а е в. Я, Мәһинур, мин әйткәнне уйладыңмы?

М а һ и н у р. Уйладым.

Ю р г а т а е в. Соң, ничек?

М а һ и н у р. Куркам.

Ю р г а т а е в. Нәрсәдән?

М а һ и н у р. Мыегың бик зур.

Ю р г а т а е в. Зарар юк. Телисең икән кыскартырга да мөмкин. Я, әйт инде, ризамы?

М а һ и н у р. Тукта инде, кабындырма. Берничә көн уйларга бир. *(Китә.)*

Өйдән Д ж о н с о н чыга.

Д ж о н с о н. Комендант әфәнде, начар аучы икәнсез. Үрдәгегез очты бит.

Ю р г а т а е в. Беркая да китә алмас, сэр Джонсон. Чөнки ул хәзер минем кулга ияләнгән.

Д ж о н с о н. Алай дисәң, сүзем юк.

Урам яктан Ч и н г и з о в керә.

Ч и н г и з о в. Хәерле иртәләр, сэр.

Д ж о н с о н. Сезгә дә шуны телим, штабс-капитан.

Ч и н г и з о в. Сез ни өчендер бүген бик иртәләгәнсез.

Д ж о н с о н. Дәүләт киңәшмәсеннән полковник Һайдель кайткан. Аның янына барышым.

Ч и н г и з о в. Әйе, мин дә аның янында идем.

Д ж о н с о н. Соң ничек, нинди яңалыклар китергән?

Ч и н г и з о в. Бернинди дә. Һаман әле демагогия дәвам итә.

Д ж о н с о н. Сез нәрсәне күздә тотасыз?

Ч и н г и з о в. Большевизм заразасы белән көрәштә либерализмга урын булырга тиеш түгел.

Д ж о н с о н. Ягез, господин Чингизов, я?

Ч и н г и з о в. Сез минем белән килешмисезме?!

Д ж о н с о н. Киресенчә, дәвам итегез.

Ч и н г и з о в. Минемчә, сэр Джонсон, сез Россия хәлләрен безгә караганда яхшырак беләсез.

Д ж о н с о н. Алай ук түгел. Ләкин шунысы ачык: Россия белән идарә итәргә диктатор кирәк.

Ч и н г и з о в. Тулысынча килешәм, сэр Джонсон. Шулай да, мин сезне кем дип таныйм соң?

Д ж о н с о н. Рус җиренең гади бер патриоты, цивилизация сөюче итеп танысагыз, ялгышмассыз. Мин сезнең белән күптәннән бирле сөйләшергә йөри идем. Чөнки хәзерге иң җаваплы чорда большевизм белән көрәшергә учредилкачылар сәләтсез булган кебек, хәрби командованиедә Һайдель кебек либераль чехословак офицеры да яраксыз.

Ч и н г и з о в. Бу турыда сез хаклы, сэр. Мин кичәдән бирле частьларда йөрдем. Һәр җирдә тәртипсезлек, иске офицерларга буйсынмаучылык таралган.Ниндидер «халык армиясе», «халык азатлыгы» турында сөйлиләр. Төрле партияләрнең вәкилләре кыргый крестьяннарны большевикларга каршы сугышырга өндиләр. Аларга өндәү түгел, камчы кирәк, шомпол кирәк, полевой суд, үлем җәзасы белән хөкем итүне тормышка ашырырга кирәк!

Д ж о н с о н. Мин сезне шулай итеп күрә идем, димәк, ялгышмадым. *(Документ күрсәтә.)*

Чингизов, укып, честь бирә.

Д ж о н с о н. Анысы артык, кирәкми. Без бергәләп эшләрбез. Әйдәгез бакчага. *(Сөйләшә-сөйләшә китәләр.)*

Өйдән З ө л ә й х а чыга.

З ө л ә й х а. Маһинур, Маһинур, дим.

М а һ и н у р керә.

М а һ и н у р. Ни бар, абыстай?

З ө л ә й х а. Кая дөмегеп йөрисең?

М а һ и н у р. Малларны көтүгә кудым.

З ө л ә й х а. Зифабану җылы сөт көтә.

М а һ и н у р. Хәзер, абыстай, кертермен. Аннан, абыстай, Саклау Баштан бер хатын килгән иде, сине уятырга кыймадым. Әнинең баш өянәге ябышып, карлыган җыя алмый ята икән.

З ө л ә й х а. Әй, ул үләтнең шул булыр инде.

М а һ и н у р. Әни, Зөләйхага кереп әйтегез, миңа булышырга Маһинурны җибәрмәс микән, дигән. Әй, карлыган ди, абыстай, чиләкләп җыялар икән...

З ө л ә й х а. Шулай диләр шул. Туйга вареньe кайнатырбыз дип җибәргән идем. Ярый, төштән соң китәрсең. *(Кереп китә.)*

И с л а м белән И д р и с чыга.

И с л а м. Маһинур, теге кәгазьләрне төреп бетердеңме?

М а һ и н у р. Күптән инде. *(Чемодан тоттыра.)*

И с л а м. Менә рәхмәт. Хәзер бер төргәген ал да староста Гайфулла абзаңа илтеп бир, берәр данәсен һәр өй саен кертеп таратсын. Калганнарын урам чатларына, капка баганаларына ябыштырсын.

М а һ и н у р. Ярый, абзый. *(Китә.)*

И с л а м. Ә без, Идрис әфәнде, волостной правлениегә барыйк та, өсләренә адресларын язып, үз кулларыбыз белән башка авылларга да таратыйк.

И д р и с. Әйе, Исламгәрәй әфәнде, мотлакан, шулай итик.

Төргәкләрне күтәреп китәләр.

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урман, тау, чокырлар арасы. Пәрдә ачылганда бер төркем партизаннар күренә. Кайсы корал чистарта, кайсы аяк киемнәре төзәтә. Бер читтә С ә л ә х и ияр рәтләп утыра. Урта җирдә баскан килеш бер партизан җырлый, калганнары аңа кушылалар.

П а р т и з а н. Мин үскәндә урман, басуларың,
Болыннарың безгә ят иде.
Алпавытлар сиңа, байгуралар —
Алар хуҗа, алар баш иде.
Х о р. Бишбүләгем, кайтсам, тарсынмассың,
Тиздән кайтам — кунак итәрсең.
Бездәй батыр егетләрең биреп
Армиягә бүләк итәрсең.
П а р т и з а н. Туган иде безгә әйбәт көннәр,
Йөрдек кояш кебек елмаеп,
Һәр кешегә җирен-суын биреп,
Киткән иде тормыш уңаеп.
Х о р. Бишбүләгем, кайтсам, тарсынмассың,
Тиздән кайтам — кунак итәрсең.
Бездәй батыр егетләрең биреп
Армиягә бүләк итәрсең.
П а р т и з а н. Һөҗүм иткәч безгә явыз дошман,
Судан, кырдан һәм дә даладан.
Таш стена булып күтәрелдек
Бар авылдан, завод, каладан.
Х о р. Бишбүләгем, кайтсам, тарсынмассың,
Тиздән кайтам — кунак итәрсең.
Бездәй батыр егетләрең биреп
Армиягә бүләк итәрсең.

Ш а һ б а з керә.

Ш а һ б а з. Фу, билләһи, йокларга да бирмисез!..

С ә л ә х и. Тукта әле, Шаһбаз, син нигә эштә түгел?

Ш а һ б а з. Авырыйм, малай, Сәләхи, бизгәк тота.

С ә л ә х и. Әллә ни булды сиңа, килгәннән бирле көзге чебеш кебек чирлисең.

Ш а һ б а з. Мондый эт тормышында чирләү генә түгел, үләрсең дә. Җылы аш, тәмле йокы күргән юк.

С ә л ә х и. Син, Шаһбаз, атаңның азан тавышын сагына башладың, ахры.

Ш а һ б а з. Юк, сагынмадым.

С ә л ә х и. Алай булгач, нигә соң корт ашаган теш кебек сыкрыйсың?

Ш а һ б а з. Бу сыкрау түгел, Сәләхи дус. Чын дөреслекне әйтү генә. Мин үзебезне буранда адашкан юлчыларга охшатам.

С ә л ә х и. Дөрес түгел! Без юл адашмаган. Киләчәк матур көнебез, якты тормышыбыз өчен юл салучылар, ди безне комиссар.

Ш а һ б а з. Ул әйтер, тел сөяксез бит ул... Тик менә үзе китте дә югалды.

С ә л ә х и. Китсә, кайтыр әле.

Ш а һ б а з. Белмим шул... Бер Казанга барып урнашкач, ни дип кенә монда кайтыр икән.

С ә л ә х и. Син алай сөйләнмә, яме!.. Безнең Кузьмич революция өчен күпме татыган. Ике-өч тапкыр төрмәдә утырган кеше, ул безне ташламас.

Ш а һ б а з. Ташламаса бик ярар иде дә, никтер, минем күңелем шикләнә. Тимеркәй белән теге матрос та китеп югалды. Соңгы көндә Самат абый да, балтасын суга төшергән мужик кебек, уйланып йөри. Син менә үзең уйлап кара, безнең монда икәнебезне белеп һөҗүм итсәләр, нишли алабыз?

С ә л ә х и. Сугышырбыз! Корал белән көчебез җитми икән, йодрык сугышына чыгарбыз. Алай да булмый икән, тешләребез белән чәйнәшербез, әмма аларга бирешмәбез. Ягез әле, егетләр, үзебезнең теге көйне җырлап алыгыз.

П а р т и з а н. Ач бүредәй чит ил гаскәрләре
Басып кергән илнең чикләрен.
Октябрьда тар-мар иткән кебек,
Юк итәрбез дошман көчләрен.

Х о р. Чут-чут итеп,
Чут-чут итеп,
Талга кунып,
Канат кагып
Сайрый алмый моңлы сары сандугачлар,
Җәйге төннең саф чыкларын эчмичә,

Зур җиңүгә
Ирешүләр,
Кочакланыш
Күрешүләр
Булмас безгә авырлыкны татыш кичмичә,
Чит илләрнең сатлык явын җиңмичә.

П а р т и з а н. Бишбүләгем, изге туган җирем,
Туфрагыңны кайтыш үбәрбез.
Шул туфракка баскан кара көчне
Тиздән барыш себереп түгәрбез.

Х о р. Кулга тоткан
Мылтыклардан,
Билгә таккан
Кылычлардан,
Без чыгарбыз, давыллардай, тын урманнан.
Үч алырбыз барлык явыз дошманнан.
Уйнап торган
Көр атлардан,
Һич бозылмас
Төз сафлардан
Ташкын булыш без агарбыз киң юллардан,
Тау, чокырлар, урман, басу, кырлардан.

Б а ш к а т о в керә.

С ә л ә х и. Кузьмич кайтты! *(Гомуми җанлану.)*

Б а ш к а т о в. Исән тордыгызмы, иптәшләр?

С а м а т. Үзең сау кайттыңмы, иптәш комиссар? Бик озакладыгыз. Без монда куркыш тора идек.

С ә л ә х и. Казанда ниләр бар, иптәш комиссар?

Б а ш к а т о в. Казанда эшләр яхшы, Сәләхи. Сезнең биредә ничек соң?

С а м а т. Биредә хәзергә тынычлык. Бары тик моннан ике көн элек унбиш чакрымдагы кордонга килеп безне сорашыш киткәннәр. Каравылчы үз кеше, бер сүз дә ычкындырмаган. Аннан, Кузьмич, бездә шатлык. Кичә аклар мобилизациясеннән баш тарткан унике егет килеп безгә кушылды.

Б а ш к а т о в. Унике егет? Молодцы, рәхмәт аларга.

С ә л ә х и. Егетләре бик шәп, Кузьмич, бишесе герман сугышында булган, берсе пулеметчы, икесе артиллерист. Үзләре белән ике винтовка да алыш килгәннәр. Тик менә патроннары гына юк.

Б а ш к а т о в. Патрон булыр, Сәләхи. Бүген төнлә безгә унбиш ящик патрон китерәчәкләр.

С а м а т. Кемнәр, иптәш Башкатов?

Б а ш к а т о в. Елгачылар. Берникадәр винтовка да булачак.

С ә л ә х и. Алай булгач, безнең эшләр яхшы, иптәш комиссар.
Б а ш к а т о в. Халыкны җыегыз, минем сүзем бар.
С а м а т. Иптәшләр, бирегә, барыгыз да бирегә!

Партизаннар кереп тулалар.

Б а ш к а т о в. Утырышыгыз.

Барысы да утыралар.

Б а ш к а т о в. Иптәшләр! Безнең Кызыл Армиябез көннән-көн зур уңышларга ирешеп дошман гаскәрләрен кысрыклавын дәвам итә. Богородскидан Казанга кадәр дошман пароходлары йөри алмыйлар. Сугыш өчен уңайлы булган уңъяк Волга ярлары безнекеләр кулында. Бөек Ленинның приказы буенча китерелгән диңгез флотилиясе һәр көнне Казан пристанена килеп төрле могҗизалар күрсәтә. Казан тирәсендәге икенче һәм бишенче армия гаскәрләре бертуктамый акларга ташлана. Шуның белән бергә, мин сезгә әйтергә тиеш: утызынчы августта, митингтан кайткан чагында, даһи остазыбыз Владимир Ильичка ике тапкыр револьвердан атканнар.

Бөтенесе дә урыннарыннан сикереп торалар.

Б а ш к а т о в. Ул хәзер яралы хәлдә больницада ята...
С ә л ә х и. Ленинга һөҗүм иткәннәр. Их, ерткычлар икән!..
Б а ш к а т о в. Казанда кешелек тарихында күрелмәгән ак террор бара. Бер Алафузов заводыннан гына биш йөз кешене кулга алдылар. Һәр көнне крепость астында, чапкаланып-кискәләнеп ташланган кешеләрнең гәүдәләре аунап ята. Шейнкман, Мулланур Вахитов, Комлев, Гассар иптәшләрне ерткычларча үтергәннәр... Менә шул террорга каршы Казанда подпольеда эшләүче большевиклар партиясенең җитәкчелегендә, Казан фронтовикларының җыелышы дигән сылтау астында өченче сентябрьдә биш меңнән артык халык катнашы белән, елга аръягындагы площадьта зур митинг үткәрелде. Ул митингта Алафузов һәм башка завод эшчеләре, артиллерия склады хезмәткәрләре булдылар. Митингны ачып җибәрү белән берсе артыннан икенчесе менеп сөйләгән ялкынлы ораторлар, Казанда дәвам иткән ак террорга каршы протест белдереп, халыкны восстаниегә өндәделәр. Партия оешмасы һәм Казан эшчеләренең вәкилләре мине бирегә озатканда, сезне — крестьяннарны да эшчеләр белән бергә хәрәкәт итәргә сорадылар. Шул сорауны кабул итү йөзеннән сез һәркайсыгыз, аерым-аерым булып, хәзер үк авылларга китәрсез. Казандагы хәлләрне сөйләп халыкны восстаниегә өндәрсез!

Т и м е р к ә й һәм Егор керәләр. К о ч а к л а ш ы п күрешәләр.

Т и м е р к ә й. Кузьмич!..

Б а ш к а т о в. Миңлекәев! Егор!

Т и м е р к ә й. Кузьмич, булган хәлләр турында соңыннан сөйләрмен. Хәзер безгә һичкичекмәстән Щербаково авылына бара торган юлга чыгарга кирәк.

Б а ш к а т о в. Щербаково юлына? Анда нигә?

Т и м е р к ә й. Щербаково авылы егетләре, аклар мобилизациясенә барудан баш тартып, безнең янга килгәннәр булса кирәк.

С ә л ә х и. Әйе, әйе, килделәр. Бая әйткән унике егет.

Т и м е р к ә й. Кичә шуларның имуществоларына конфискация ясарга, ата-аналарын арестовать итәргә бер взвод солдат һәм полиция частьларыннан төзелгән отряд җибәрелгән иде. Хәзер алар анда, барып басарга кирәк.

Б а ш к а т о в. Бер взвод дисеңме?

Т и м е р к ә й. Әйе, Бәйрәмгали командасы астында бер взвод солдат һәм полиция частьлары.

Б а ш к а т о в. Дөрес, Тимеркәй, басарга!.. Еланнарны изеп сыткан төсле, һәммәсен дә юк итәргә. Яхшы атларны, үткен егетләрне сайлап алыгыз.

Тимеркәй китә.

С ә л ә х и. Менә бу эш, ичмасам!

Б а ш к а т о в. Сәләхи! Минем атымны иярлә. *(Куышка кереп китә.)*

С ә л ә х и. Була ул, иптәш комиссар!

Ш а һ б а з. Нишләргә? Китәргәме, монда калыргамы? Әйе, әйе, китәргә! Орынтын юллар белән барып анда хәбәр итәргә... *(Китә.)*

Куыштан коралланып Б а ш к а т о в чыга.

Б а ш к а т о в. Самат!.. Син биредә калырсың. Операциягә китүебез турында заставаларга хәбәр итегез. Атышлар булса, курыкмыйча белеп торсыннар.

С а м а т. Яхшы, иптәш комиссар.

Т и м е р к ә й керә.

Т и м е р к ә й. Иптәш комиссар, илле кешелек отряд әзер.

Б а ш к а т о в. Әйдәгез, иптәшләр! Революция өчен!!.

Китәләр. Самат, Махиан китүчеләрне озата чыгалар.

*Пәрдә.*

# ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Европача җиһазландырылган Ислам байның кунак бүлмәсе. Төрле якка китә торган ишекләр. Пәрдә ачылганда бүлмәдә Һайдель, Юргатаев, Джонсон.
Иван йөгереп керә.

Иван. Полковник әфәнде, эшләр харап!

Һайдель. Нәрсә бар?

Иван. Авылга большевиклар кергән.

Джонсон *(урыныннан сикереп тора)*. Большевиклар кергән?..

Һайдель. Кайда алар?

Иван *(кулында йомарланган кәгазьне сузып)*. Менә алар!

Һайдель. Бернәрсә дә аңламыйм, бу нинди кәгазьләр?

Иван. Урамнарга большевиклар өндәмәсен ябыштырганнар. Пожар сарае яныннан үтеп бара идем, бер төркем солдатлар, крестьяннар җыелганнар да көлешә-көлешә шушы өндәмәләрне укыйлар. Ул мошенниклар нәрсә язганнар диген, мин сезгә укып күрсәтим әле...

Һайдель. Кирәкми. Мин аларның нәрсә язганнарын болай да бик яхшы беләм. Староста, старшиналар ни караган?

Иван. Ул гололобыйларга ышанырга ярыймы? Аларның һәркайсында большевик каны бар.

Һайдель. Барыгыз, миңа староста белән старшинаны чакырыгыз!

Иван. Хәзер, була ул. *(Китә.)*

Һайдель. Я, комендант әфәнде, моңа ни дисез?

Юргатаев. Полковник әфәнде, мин сезгә әйтергә кыймый тора идем, Идрис Салихов алып кайткан өндәмәләрнең өчтән ике өлеше большевиклар өндәмәсе булып чыктылар.

Һайдель. Аның булуы мөмкин түгел. Чөнки Салихов әфәнде минем күз алдымда ул өндәмәләрне армия штабыннан алды да минем денщигыма тапшырды.

Юргатаев. Анысы шулай, ләкин Идрис Салиховның тикшереп алмавыннан файдаланып, типография эшчеләренең салып җибәрүе бик мөмкин. Инде алай түгел икән, подпольедагы большевикларның мондагы бер кеше аркылы тарату ихтималы да юк түгел.

Һайдель. Нинди кеше ул?

Юргатаев *(Джонсонга карап)*. Хәзергә сер итеп сакларга рөхсәт итсәгез иде.

Шаһбаз керә.

Шаһбаз. Полковник әфәнде, кичерегез мине. *(Алдына барып тезләнә.)*

Һайдель. Син кем?

Шаһбаз. Партизан.

Д ж о н с о н *(тагын урыныннан сикереп торып)*. Партизан?!

Һ а й д е л ь. Кем сине тотыш китерде?

Ш а һ б а з. Беркем дә. Үз ихтыярым белән килдем. Мин күрше авылның мәзин малае.

Һ а й д е л ь. Ничек инде ул, үзең мәзин малае, үзең партизан?

Ш а һ б а з. Ялгышлык белән алар арасына эләккән идем. Полковник әфәнде, тизлек белән чара күрегез. Партизаннар Щербаково авылына җибәрелгән отрядыгызны басарга киттеләр.

Һ а й д е л ь. Син нәрсә, шантаж оештырырга килдеңме?

Ш а һ б а з. Полковник әфәнде, валлаһи дип әйтәм, минем сүзләрем дөрес.

Һ а й д е л ь. Хәзер үк тикшерергә, миңа доложить итәргә!

Ю р г а т а е в. Тыңлыйм, полковник әфәнде. Әйдә, марш! *(Китәләр.)*

Һ а й д е л ь. Дәвам итик, сэр Джонсон. Шулай итеп, без зур тарихи чорда...

Д ж о н с о н. Әйе, сез анда тарихи чорда Уфада собраниеләр ясап яттыгыз. Ә биредә урманнарыгызда партизаннар, авылларыгызда большевиклар. Фронтларда һөҗүм итү сәләтегезне югалттыгыз. Хәтта кайбер участокларда инициативаны кызылларга бирдегез. Цивилизованный Антантаның төньяк-көнбатыш шәһәрләргә төшергән десантларына кушылу планыбызны җимердегез. Миллион сумлык алтыннар хисабына кайтарып алган Урал промышленность учакларыбызны яңадан куркыныч астына куйдыгыз...

Һ а й д е л ь. Хәзерге көнне безнең оборонада торуыбыз большевикларның миллионлаган армия туплавына бәйләнгән.

Д ж о н с о н. Ә сез нигә шундый армияне тупламыйсыз?

Һ а й д е л ь. Игълан ителгән мобилизацияләрнең нәтиҗәсе сезгә билгеле. Россия халкы дүрт ел буена тартылган сугыштан туйган. Шуның өчен алар солдат хезмәтеннән качалар.

Д ж о н с о н. Шулай да бит алар большевикларга баралар.

Һ а й д е л ь. Бөтен промышленность өлкәләре алар кулында, алар төп көчләрен эшчеләрдән туплыйлар.

Д ж о н с о н. Абсурд! Тиздәнме сез һөҗүм итәргә уйлыйсыз?

Һ а й д е л ь. Һөҗүм итәр өчен реаль көч булырга тиеш, хәзергә минем андый көчем юк.

Д ж о н с о н. Андый көчегез кайчан соң булачак?

Һ а й д е л ь. Кайчан миңа коалицион директория штабы бирер...

Д ж о н с о н. Әгәр дә алар бирмәсәләр?

Һ а й д е л ь. Сэр Джонсон, сез кирәгеннән артыграк кайгыртучанлык күрсәтә башладыгыз.

Д ж о н с о н. Бүген генә түгел, без һәрвакытта да Россия турында кайгыртып килдек. Чөнки аның завод-фабрикалары, тимер юл, шахталары — барысы да бит безнең акчабызга салынган.

Шуның өстенә хәзер дә армиягезне ашатабыз, киендерәбез, сугыш кораллары белән тәэмин итәбез һәм сезгә түлибез.

Һ а й д е л ь. Сэр Джонсон...

Д ж о н с о н. Йә, җитәр. Россия турында ни дәрәҗәдә кайгыртуымны тиз арада күрерсез!

Һайдель кайдадыр китәргә җыена. Ч и н г и з о в , В а р л а м о в керәләр.

Ч и н г и з о в. Полковник әфәнде, Верховный Правительнең приказын тыңлап китегез.

Һ а й д е л ь. Нинди Верховный Правитель?

Ч и н г и з о в *(укый)*. «Учредительное собрание әгъзаларыннан төзелгән Себер вакытлы хөкүмәт директориясе бетерелеп, үземне Верховный Правитель һәм Себер гаскәренең баш командующие итеп игълан итәм. Верховный Правитель адмирал Колчак».

Һ а й д е л ь. Колчак — Верховный Правитель?

Ч и н г и з о в. Хәзер инде армия штабының приказын тыңлагыз!

В а р л а м о в *(укый)*. «Икенче бригада командиры полковник Һайдельне урыныннан алып, бригада командирлыгына штабс-капитан Чингизовны билгелим. Полковник Һайдельне аерым чехословак батальонының командиры итеп калдырырга боерам. Армия командующие генерал Сахаров».

Һ а й д е л ь. Мин моңа риза түгел, мин армия штабы белән сөйләшергә барам!

Һайдель ачуланып чыгып китә.

Д ж о н с о н. Тәбрик итәм, сэр Чингизов.

Ч и н г и з о в. Рәхмәт сезгә. Поручик Варламов, армия штабының приказын полкларга, аерым частьларга җиткерегез. Үзегез бүгеннән бригада штабы начальнигының хезмәтен алырсыз. Адъютантлыкка поручик Марковны билгеләрсез.

В а р л а м о в. Тыңлыйм, господин штабс-капитан! *(Китә.)*

З и ф а керә.

З и ф а. Володя, юлда полковник Һайдельне очратып, исәнмесез, дип дәшкән идем, немецча сүгенеп китте. Әллә фронттан начар хәбәр килдеме?

Ч и н г и з о в. Безнең өчен шатлыктан башка берни дә юк. Учредилкачылар муенын сындырды. Бригада белән командовать итүне миңа тапшырдылар.

З и ф а. Син бригада командиры?! Бәгърем, Володя, без нинди бәхетле, никахыбыз көннәрендә безгә нинди зур шатлык. *(Каткат үбә.)*

В а р л а м о в керә.

В а р л а м о в. Телефонограмма... Ачылган прорывтан обход ясап, кызылларның Земгальский латыш полкы тимер юл станциясен алган. Полк командиры тизлек белән ярдәм сорый.

И с л а м керә.

И с л а м. Әфәнделәр, коточкыч хәбәрләр!.. Бәйрәмгали кул астында җибәрелгән полиция отряды Щербаково крестьяннарын камап килгән чакта, урманнан чыкканнар да, коралларын алып, үзләрен тураклаганнар.

Ч и н г и з о в. Кемнәр?

И с л а м. Башкатов белән Миңлекәевләрнең партизан отряды.

Ч и н г и з о в. Җитте! Җитте! Артык түзә алмыйм. Мин андый бандитлар белән ничек көрәшергә белермен! Варламов! Үз кул астыгызда запас батальоннан карательный отряд оештырып, бандитларны тоту өчен облавага чыгарга!

В а р л а м о в. Тыңлыйм, капитан әфәнде.

Ч и н г и з о в. Старшина! Бөтен старосталарга приказ бирергә: унбиш яшьтән алтмыш яшькә кадәр авыл халкын мобилизовать итеп бандитларга облава ясарга. Яшереп асраучыларны авыллары белән яндырырга! Күреп әйтмәүчеләрне, ашарга бирүчеләрне атарга!

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Ислам бай залы. Пәрдә ачылганда Ислам кунаклар каршылап йөри.

И с л а м. Әйдәгез, кунаклар, рәхим итегез.

И в а н, п о п һәм башка к у н а к л а р керәләр.

И в а н. Туйлар котлы булсын.

И с л а м. Шулай булсын. Әйдә, Иван Иванович.

И в а н. Уйламаган җирдән командир бабасы булдың да куйдың бит.

И с л а м. Аллага шөкер, Иван Иванович. Сер итеп кенә әйтәм, тиздән Бишбүләктән китәбез. Зур урынга назначение алдым.

И в а н. Нинди урынга? Әллә өязгә, шәһәр головалыгынамы?

И с л а м. Түгел, армия штабы каршындагы азык-төлек хәзерләү интендантствосына инспектор итеп билгеләделәр.

И в а н. Алай... Ә йортларыңны нишләтәсең?

И с л а м. Волостной правлениегә саттым. Больница ясыйлар.

И в а н. Син киткәч, волостной кем булыр икән?

И с л а м. Чукмарлыдан Сәйфулла байны куярга телибез.

И в а н. Китегез, кит. Аның ише неграмотный кешене старшина итеп куярга ярыймы соң? Ул бит үзенең тире-ярысыннан башка бернәрсә дә белми.

И с л а м. Тагын кунаклар килде, сез сөйләшә торыгыз. *(Чыгып китә.)*

И в а н *(попның колагына).* Ишеттегезме? Гололобый башы белән инспектор булам дигән була. Ана көчеге аркасында кая үрмәли.

Күзлекле солдат белән ярым татарча, ярым европача киенгән К а м ә р керә.

К а м ә р. Хәерле иртәләр, әфәнделәр!

И в а н. Нинди иртә булсын, кояш баеп килә бит.

К а м ә р. Нихәл, Иван агай, арумы?

И в а н. Ару, ару. Синең дә эшләр ару күренә...

И с л а м, И д р и с, о ф и ц е р л а р, ш ә ф к а т ь т у т а ш л а р ы, к у н а к л а р керәләр.

И с л а м. Әфәнделәр, рәхим итегез.

И д р и с. Туй мәҗлесегез котлы булсын.

И с л а м. Шулай булсын, амин.

Д ж о н с о н керә.

Д ж о н с о н. Сәлам сезгә, әфәнделәр!

И с л а м. Әйдәгез, сэр, рәхим итегез.

Д ж о н с о н. Рәхмәт сезгә.

И д р и с. Встать смирно! Кияү белән кыз килә!

Бар да торып басалар. Ч и н г и з о в белән З и ф а чыгып баш ия.

Ч и н г и з о в. Әфәнделәр, гомерлек юлдашым итеп сайлаган Зинаида Исламовнаны тәкъдим итәргә рөхсәт итегез.

И д р и с. Бәхетле тормыш белән озын гомерләр телибез.

Подноска тезелгән эчемлек өләшәләр.

З и ф а. Әфәнделәр! Тормыш җепләребезне бергә бәйләү шәрәфенә багышлап бокал күтәрүегезне сорыйм.

Б а ш к а л а р. Ура, ура!

И д р и с. Горько, горько!

Зифа белән Чингизов үбешәләр.

Ч и н г и з о в. Әфәнделәр! Бүген, беренчедән, ике яшь көчнең бергә кушылу бәйрәме көне булса, икенчедән, Себер вакытлы хөкүмәт директориясе бетерелеп, Колчак хәзрәтләренең үзен Верховный Правитель итеп игълан иткән тарихи көн. Шулар хөрмәтенә ура!

Б а ш к а л а р. Ура! Ура!

И с л а м. Әфәнделәр! Бик күп илләр аша, бик күп диңгезләр аша, безгә теләктәшлек күрсәтеп килгән кадерле англичан кунагыбыз Джонсон әфәнде саулыгына эчәргә чакырам.

Д ж о н с о н. Юк, юк, әфәнделәр! Мин дөньяда иң кунакчыл, иң ихтирамчыл Россия халкының саулыгына, сезнең саулыкка эчәргә чакырам. Ура!

З ө л ә й х а. Әфәнделәр, өстәлләргә тәгам куелды, ашап-эчеп алыгыз!

Зөләйхадан башкалар кунак бүлмәсенә кереп китәләр.
М ә р ф у г а керә.

З ө л ә й х а. Мәрфугаттәй, Исламгәрәй сиңа бернәрсә дә әйтмәдеме әле?

М ә р ф у г а. Миңа сүзе бар идемени?

З ө л ә й х а. Бар иде шул. Үзегезгә башка урын карарга кушам дигән иде.

М ә р ф у г а. Башка урын? Ә соң сездә?

З ө л ә й х а. Коммун анасын өегездә асрыйсыз икән, бер минут тотмыйча чыгарыгыз дип губернатордан приказ алдык. Шулай, Мәрфугаттәй, башка җирдән урын карагыз.

М ә р ф у г а. Иркәм, егерме ел бергә тордык, егерме ел бергә гомер иттек. Шулар хөрмәтенә...

З ө л ә й х а. Юк, юк. Сезнең өчен губернатордан шелтә алып төрмәләрдә черер хәлебез юк! *(Китә.)*

М а һ и н у р керә.

М а һ и н у р. Әни, ни булды сиңа? Нигә елыйсың?

М ә р ф у г а. Безне бит, кызым, куалар. Коммун анасын өебездә тотмыйбыз, чыгып китегез, диләр.

М а һ и н у р. Кайгырма, әни, ачка үлмәбез. Озакламый абыйлар кайтыр.

М ә р ф у г а. Кайтырлармы икән?

М а һ и н у р. Кайтырлар, боларның хәзер көймәсе комга терәлгән. Бар, әйберләрне җыештыр, хәзер үк китәбез.

Мәрфуга китә. Ю р г а т а е в керә.

Ю р г а т а е в. Маһинур, мин әйткәнгә ни дисең?

М а һ и н у р. Этем шикелле артымнан йөрмә әле.

Ю р г а т а е в. Этем шикелле?.. Ярый! Мин сине яшь кыз бала дип кызгана идем. Болай булгач, үзеңә үпкәлә.

М а һ и н у р. Нигә мине кызганырга? Мин бит гарип-гораба түгел.

Ю р г а т а е в. Тимер читлек тәртипләрен татый башлагач белерсең әле.

М а һ и н у р. Инде хәзер үзегезгә кияүгә чыгарга теләмәгән кызларны да ябарга керештегезмени?

Ю р г а т а е в. Ябу гына түгел, синең кебекләргә муенчак салырга да кыйбат алмыйбыз. Большевиклар өндәмәсен тарату уен эш түгел ул.

М а һ и н у р. Нинди өндәмә?

Ю р г а т а е в. Кичә авылда большевиклар өндәмәсен таратуда синең кулың уйнаганы миңа билгеле. Йә бүген минем квартирама барасың, йә каргаларга азык буласың!

Аргы бүлмәдән к у н а к л а р исереп чыга.

И д р и с. Әфәнделәр!.. Мин штабс-капитан әфәндедән төрмәдә утыручы Кавказ егетен китереп биетүен сорар идем.

Б а ш к а л а р. Браво, браво, сорыйбыз!

Ч и н г и з о в. Сез нәрсә, әфәнделәр! Сыналмаган шәхесне, бигрәк тә арестантны монда китереп биетергә ярыймы соң?

З и ф а. Володя, нигә аңардан шикләнергә? Ул бит аңсызлыгы аркасында гына Кызыл Армиядә йөргән. Аны бик матур биюче диләр. Биетик инде.

Ч и н г и з о в. Һич мөмкин түгел.

З и ф а. Сүземне тыңламасаң, үпкәлим.

Ч и н г и з о в. Ярый, мин синең соравыңны үтим. Ләкин комендант әфәнденең фикере ничектер бит.

Ю р г а т а е в. Тыныч булыгыз, капитан әфәнде, куелган сынауларның нәтиҗәсе яхшы. Монда китереп биетү генә түгел, хәтта ышаныш корал бирергә дә мөмкин дип саныйм.

Ч и н г и з о в. Ярый, китерегез.

Юргатаев китә.

З и ф а. Әфәнделәр... Ха-ха-ха... Мин сезгә... ха-ха-ха... Үземнең шатлыклы бәйрәмем көнендә... ха-ха-ха... Исердем бугай...

В а р л а м о в керә.

В а р л а м о в. Штабс-капитан әфәнде, партизаннар отряды тармар ителде, туй мәҗлесегез хөрмәтенә башлыклары тотып китерелде! *(Ишеккә барып кычкыра.)* Бире кертегез!

Бәйләнгән хәлдә Т и м е р к ә й н е кертәләр.

М а һ и н у р. Абыем Тимеркәй!

Ч и н г и з о в. Тимеркәй?! Синмени ул бандитлар башлыгы?

Т и м е р к ә й. Мин бандит түгел, эшче-крестьян Кызыл Армиясенең командиры.

Ч и н г и з о в. Молчать! Ничек болай бире киләсе булдың? Сез бит налет ясарга җыена идегез.

Т и м е р к ә й. Мине тотуга шатланмагыз, меңләгән, миллион-

лаган Тимеркәйләр, Башкатовлар анда калдылар. Бүгенме, иртәгәме алар...

Ч и н г и з о в. Җитәр!.. Ишегалдына алып чыгыгыз да йөз шомпол бирегез!

М а һ и н у р... Абыем... Тимәгез аңар...

Маһинурны алып ташлыйлар. Тимеркәйне алып китәләр.

М а һ и н у р. Әни, абыйны тотканнар!.. *(Эчке бүлмәгә кереп китә.)*

Ч и н г и з о в *(тәрәзәгә барып).* Яткырыгыз, сугыгыз! Менә шулай, менә шулай!

Барысы да тәрәзәдән тышка карап торалар. М ә р ф у г а белән М а һ и н у р чыга.

М ә р ф у г а. Балам, балам, бәбкәм кая?

М а һ и н у р. Әнә тышта сугтыралар.

М ә р ф у г а. Балам, бәбкәм минем... *(Китә.)*

К о р б а н керә. Анасы артыннан китеп бара торган Маһинурны туктата.

К о р б а н. Маһинур, бар, тиз, чаптарның тезгенен чиш, чаптар әзер булсын, арткы капка ачык булсын!

М а һ и н у р. Нишләмәкче буласың?

К о р б а н. Соңыннан белерсең, соңыннан.

Маһинур китә.

Ч и н г и з о в. Алып ташлагыз анасын! Һушыннан яздымы? Шулай да ыңгырашмады, молодец икән. Илтеп ябыгыз. Әфәнделәр! Поручик Варламовның партизаннар башлыгын тоту шәрәфенә салган бокаллар көтә.

З и ф а. Володя, теге егетне биетик инде...

Ч и н г и з о в. Әйе, ул безнең истән чыккан. Я әле, һөнәреңне күрик. Ничек биисең икән?

Музыка лезгинка уйный. К о р б а н төрле фигуралар ясап бии.

Ч и н г и з о в. Ах, молодец, ах, молодец, ах, подлец... Ярый, мин сине солдат итеп алам.

З и ф а. Әфәнделәр! Поручик Варламовның батырлыгын котлау өчен өстәлгә!

Кереп китәләр. Корбан җитди карарга килү хәрәкәте ясап сәхнәдән югала. И с л а м белән М ә р ф у г а талашып керә.

М ә р ф у г а. Исламгәрәй, ни дип син аны яклап бер генә сүз дә әйтмәдең? Ни дип син бәбкәемнең күкрәгенә менеп таптадың?!

И с л а м. Бар, бар, югал күземнән!

М ә р ф у г а. Илаһи, минем кебек карт көнемдә хәсрәт татып...

И с л а м. Тап төшермә минем туема!!

М ә р ф у г а. Ләгънәт төшсен сиңа, ләгънәт этләр туеңа!.. *(Өстәлдәге шешәне алып Исламга җибәрә. Шешә барып тәрәзәгә тия. Пыяла ватылган тавыш ишетеп барысы да бу якка йөгерешеп чыгалар.)*

З и ф а. Әткәй, монда ни булды?

И с л а м. Әнә теге ана эт... Чык өемнән, үләксә!

К у р б а т о в йөгереп керә.

К у р б а т о в. Штабс-капитан әфәнде, Кавказ егете сезнең чаптарыгызга атланып качты!..

Б а ш к а л а р. Качты?..

Ч и н г и з о в. Тревога күтәрергә, артыннан куарга!..

*Пәрдә.*

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ.

Беренче пәрдәдәге Ислам байның ишегалды. Ачык тәрәзә аша өй эчендә Чингизовның телефонда сөйләшкәне күренә. Капка төбендә таш кладовой ишеге янында К у р б а т о в белән М и н г у л о в сакта тора. Пәрдә ачылганда ыгы-зыгы; солдатлар, офицерлар чабышып йөриләр. Еракта туп тавышлары ишетелеп тора.

М и н г у л о в. Ишетәсеңме, Курбатов, гөбедә май язалармыни. Кыздыралар, ахры.

К у р б а т о в. Кыздырмасалар, безнең кебек нестроевойларны постка куймаслар иде.

М и н г у л о в. Әйдә, тартып алыйк булмаса.

К у р б а т о в. Без янганчы, тәмәке янсын дисеңме?

М и н г у л о в. Безнеке түгел бит, әйдә, яна бирсен. Табак японский, мундир английский...

К у р б а т о в. Аны киюче дурак российский, диген. *(Мингуловка күрсәтә.)*

М и н г у л о в. Ә син үзең кем?

К у р б а т о в. Мин дә синең шикелле дурак.

Чиләк тотып өйдән З ө л ә й х а чыга. Урам яктан Г ө л с е м керә.

Г ө л с е м. Зөләйха абыстай, мине нигә чакырган идең?

З ө л ә й х а. Без бит кичә теге үләтләрне куып чыгардык, сыерлар саумаган, маллар каралмаган, кеше табып алганчы безгә булышмассыңмы?

Г ө л с е м. Ярый, Зөләйха абыстай, булышырмын.

З ө л ә й х а. Өйдә бер чүмеч су калмаган. Мә, тиз генә суга бар әле. Аннан сыерларны саварсың. Аннан өйләрне җыештырырсың. Аннан савыт-сабаларны юарсың. Аннан... Ярый, бар, бит юарга су кирәк.

Г ө л с е м. Зөләйха абыстай, Исламгәрәй абзый безнең әти турында сөйләшеп карамасмы икән, һаман чыгармыйлар бит.

З ө л ә й х а. Бар, бар, эшеңдә бул әле. Башта хезмәтеңне ит, аннан әҗерен көт диләр.

Икесе ике якка китәләр. Ю р г а т а е в керә.

Ю р г а т а е в. Ах, агач авызлар, каравылда шулай торалармыни? Басыгыз урыннарыгызга! *(Мингуловка суга да өйгә кереп китә.)*

К у р б а т о в. Кай җиреңә сукты?

М и н г у л о в. Авызга утыртты.

К у р б а т о в. Дурак син! Миңа сугып карасын иде, мин аның теш казнасын кулына тоттырып җибәрер идем.

М и н г у л о в. Әй, мактанчык, җибәреп кара.

Ю р г а т а е в ачык тәрәзә янына утырган Ч и н г и з о в каршына килеп баса.

Ю р г а т а е в. Штабс-капитан әфәнде, Петр-Павел авылында салынган налогларны түләмәүчеләрне җавапка тарту өчен барган Иван Ивановичны үтереп арбасына салып җибәргәннәр иде. Моннан полицияләр барып гаепләләрне кулга ала башлагач, авыллары белән каршы торганнар, нишлибез?

Ч и н г и з о в. Хәзер үк командагызны алып китегез. Үтерүчеләрне авыллары белән юк итегез!

Ю р г а т а е в. Тыңлыйм, штабс-капитан әфәнде! *(Ишегалдына чыга. Аннан урамга уза.)*

Г ө л с е м судан кайтып өйгә кереп китә. Ч и н г и з о в каршысына В а р л а м о в килеп баса.

В а р л а м о в. Штабс-капитан әфәнде, иртәдән бирле кызылларның ике канониркалары кичүдәге ротабызны борчыйлар иде. Рота командиры Корниловның хәбәр итүенә караганда, моннан бер сәгать элек фәкать матрослардан торган тагын йөз кешелек десант төшергәннәр. Яр буйлап кичүгә таба хәрәкәт итәләр.

Ч и н г и з о в. Ничек кенә булса да кичүгә җибәрмәскә!

В а р л а м о в. Штабс-капитан әфәнде, әгәр дә резервтагы ротаны ярдәмгә җибәрсәк?

Ч и н г и з о в. Резервтагы рота штабка прикрытие булып сакланырга тиеш. Күрәсез бит, бөтен яклап безне кысалар.

В а р л а м о в. Алай булса, Корниловка нинди җавап бирергә?

Ч и н г и з о в. Теләсә нинди шартларда да кичүгә җибәрмәскә.

Варламов югала. Өйдән З и ф а чыга.

З и ф а. Володя, мин госпитальгә киттем.

Ч и н г и з о в. Әйе, әйе, яралы офицерларны Кама аръягына озатыгыз.

З и ф а. Димәк, безнең хәлләр куркыныч астында?

Ч и н г и з о в. Казанны безнекеләр биргәннәр, моннан егерме биш чакрымдагы пристаньга десант төшергәннәр. Кичүгә һөҗүм итәләр.

Зифа ишегалды аша урамга чыгып китә. Казачий киемнән Е г о р килеп Ч и н г и з о в каршына баса.

Е г о р. Штабс-капитан әфәнде, мин сезгә элемтәгә җибәрелдем.

Ч и н г и з о в. Каян?

Е г о р. Уң флангтан, казачий дивизионнан.

Ч и н г и з о в. Ишегалдында көтеп торыгыз, кирәк булгач чакырырбыз.

Е г о р. Тыңлыйм, штабс-капитан әфәнде. *(Ишегалдына чыга. Чиләк тотып сыер саварга баручы Гөлсемне туктатып.)* Әй, кызый!

Г ө л с е м. Сез кем? Я, ходай, матрос абый?

Е г о р. Әкрен... Әйдә әле минем белән.

Китәләр. Өйдән И с л а м белән З ө л ә й х а чыга.

З ө л ә й х а. Син тиз кайтырсыңмы икән?

И с л а м. Әйтә алмыйм.

З ө л ә й х а. Китәргә булсак, әйберләрне карарга иде.

И с л а м. Әйберләреңә берни дә булмас, баш турында уйларга кирәк.

З ө л ә й х а. Әйберләрең булмаса, башың белән нишлисең?

И с л а м. Анысы дөрес. Ярый, мин киттем, кыйммәтле әйберләрне җыйный тор. *(Китә.)*

Е г о р керә.

Е г о р. Нихәл, якташлар? *(Яннарына барып утыра.)*

М и н г у л о в. Әйбәт әле.

К у р б а т о в. Кайсы частьтан буласың?

Е г о р. Казачий дивизионнан.

М и н г у л о в. Каймакчымыни?

Е г о р. Ничек каймакчы?

М и н г у л о в. Безнең пехотачылар сезнең кавалеристларга шундый исем кушканнар.

Е г о р. Каймак ашап йөрергә вакыт тигәне юк әле. Бер атнадан бирле передовойда.

К у р б а т о в. Эшләр ничек соң?

Е г о р. Шәптән түгел. Азинчылар тынгы бирмиләр. Сез дә элемтәчеме?

К у р б а т о в. Юк, менә бу кладовойны саклыйбыз.

Е г о р. Анда нәрсә соң? Сугыш припасларымы?

К у р б а т о в. Түгел. Аристованныйлар. Кичә тотылган партизаннар башлыгы.

Шешә тотып Г ө л с е м керә.

Г ө л с е м. Абыйлар, мин сөт белән ипи китергән идем.

М и н г у л о в. Безгәме?

Г ө л с е м. Әйе, сезгә. Бик тәмле яңа сауган сөт. Эчәсегез киләме?

М и н г у л о в. Әй, сеңелем. Без монда эчкәннәрне кире чыгарырга торабыз, ә син эчәргә дисең.

Г ө л с е м. Дөресен әйткәндә, мин аны сезгә түгел, әнә андагы бичараларга китергән идем. Алар бит кичәдән бирле берни дә ашаганнары юк. Бирегез аларга, бераз тамак ялгап алсыннар.

М и н г у л о в. Юк, юк, булмый ул. Сизеп алсалар, баскан җиребездә атарлар.

К у р б а т о в. Әйдә, Мингулов, бир, парин. Аристант булсалар да, кызганыч бит.

Е г о р. Конечно, барыбер аларны аталар, әйдә ашап калсыннар.

М и н г у л о в. Күрсәләр?

Е г о р. Күрмәсләр. Сез искәреп торыгыз, үзем бирермен.

М и н г у л о в белән К у р б а т о в караштыралар.

Е г о р *(Кладовой ишегенә барып).* Әй, сез, большевиклар! Сөт белән ипи китергәннәр, мәгез, алыгыз! *(Солдатларга ишеттермичә.)* Бөкесен сүтеп укыгыз.

М и н г у л о в. Син, кызый, тай инде моннан, тай. Әнә офицер килә.

Гөлсем китә. Урамнан ашыгып Д ж о н с о н керә дә өйгә уза.

Е г о р. Бу нинди кеше?

К у р б а т о в. Бу ерактан, Париж-Лондон дигән шәһәрдән.

Е г о р. Нишләп йөри икән?

К у р б а т о в. Газета язучы диме шунда.

Е г о р. Шпион икән.

К у р б а т о в. Ничек инде шпион?

Е г о р. Шулай, аларның кайсысы корреспондент, кайсысы спортсмен булып киләләр дә шпионлык итеп йөриләр. Әйдәгез, якташлар, тартып җибәрик.

М и н г у л о в. Яңа гына ташладык.

К у р б а т о в. Әйдә, Мингулов, сыйлап биргәннең суын эч диләр.

Е г о р. Тәмәкесе бик әйбәт.

Төрергә керешәләр. Джонсон Чингизов янына килә.

Д ж о н с он. Коточкыч, коточкыч! Андый көчне алар каян алалар?.. Турысын әйткәндә, нахалларча һөҗүм итәләр. Ярый, хушыгыз, сэр Чингизов.

Ч и н г и з о в. Сез кая?

Д ж о н с о н. Армия штабына, консультация алырга барам.

Ч и н г и з о в. Димәк, качасыз?

Д ж о н с о н. Юк, качмыйм. Яңадан зуррак хәзерлек белән килер өчен китәм. Хушыгыз. *(Бер кулына рюкзак, икенчесенә чемодан тотып ишегалдына чыга.)* Солдатлар, мә, алыгыз, сезгә бүләгем.

Е г о р. Нәрсә соң ул?

Д ж о н с о н. Артык әйберләрем, туалетлар.

Е г о р. Юкка, әфәндем, бу мазьларны безгә бирәсез. Юлда үзегезгә кирәк булыр бит. Бигрәк тә менә сабын кисәге дә бар икән.

Д ж о н с о н. Сүзегезне аңламыйм.

Е г о р. Сабын җәяү йөргән чакта үкчә майлар өчен бик шәп дару санала.

Д ж о н с о н. Беренче кат ишетүем, киңәшегез өчен рәхмәт. Хушыгыз, солдатлар.

Е г о р. Алдыңнан артың яхшырак.

Д ж о н с о н. Нәрсә дидегез?

Е г о р. Соңга каласыз, дим.

Д ж о н с о н. Киңәшегез өчен тагын бер кат рәхмәт. *(Китә.)*

М и н г у л о в белән К у р б а т о в рәхәтләнеп көлә.

М и н г у л о в. Син бик мәзәк егет икәнсең. Үзең каян соң?

Е г о р. Әйттем бит инде, казачий дивизионнан.

М и н г у л о в. Юк, кай җирдә туган дим?

Е г о р. Чиләбе казагы.

М и н г у л о в. Һи... Чынлап та якташ икәнсең...

Е г о р. Ә син үзең?

М и н г у л о в. Аргаяштан.

Е г о р. Башкортмыни?

К у р б а т о в. Мин дә шул тирәдән. Троицкидан.

Е г о р. Кара син аны, якташлар икәнбез...

М и н г у л о в. Синең бу тәмәке чынлап та бик шәп, ахры. Бер-ике суыруга башка китте бит.

К у р б а т о в. Конфет тәме киләме дим үзеннән.

Е г о р. Аны безнең офицерларга биргәннәр иде, каптенармус минем үз кеше. Бу тәмәке Яваның үзеннән килгән, ди.

М и н г у л о в. Шулайдыр, бу гади тәмәкегә охшамый.

Е г о р. Армиядә күптәнме?

К у р б а т о в. Дүрт ел тула инде. Германнан кайтып бер генә ел тордым. Мобилизовать иттеләр.

Е г о р. Ә син доброволецмы?

Курбатов йокыга китә.

М и н г у л о в. Аллам сакласын, дегет лагоны.

Е г о р. Ничек инде ул, дегет лагоны?

М и н г у л о в. Көчләп алдылар да арба артына таккан дегет лагоны кебек йөртәләр. *(Иснәп.)* Минем эчтә кату бар, походка ярамыйм. Ике тапкыр комиссиядә торып каралдым, җибәрмиләр... *(Исни.)*

Е г о р. Җибәрмәсләр шул, кеше кирәк бит.

М и н г у л о в. Кирәк дип инде... Безнең кебек солдаттан ни файда... *(Утырган җирендә йокыга китә.)*

Егор як-ягына каранып кесәсеннән ачкыч чыгара. Барып кладовой ишеген ача. Кладовойдан Т и м е р к ә й белән б е р н и ч ә  к е ш е чыга.

Е г о р. Әйдәгез, иптәшләр, биредән, кырга!..

Китәләр. В а р л а м о в керә.

В а р л а м о в. Штабс-капитан әфәнде, кызылларның көчле кавалериясе атакага ташлана!

И с л а м йөгереп керә.

И с л а м. Әфәнделәр, кызылларның аэропланы!..

Йөгерешеп өйләрдән чыгалар. Төрлесе төрле урынга посалар. Берничә бомба шартлаган тавышлар, пулемет авазлары ишетелә. Самолет әкрен генә югала.

И с л а м. Аллага шөкер, китте бугай...

Ю р г а т а е в йөгереп керә.

Ю р г а т а е в. Әфәнделәр, без барган авылда көчле восстание!

Ч и н г и з о в. Восстание?

Ю р г а т а е в. Авылга якынлашу белән, безне ут ачып каршы алдылар. Цепькә таралып һөҗүм итеп карасак та, кара болыт төсле ябырылган толпага каршы бара алмадык.

Ч и н г и з о в *(ачу белән)*. Чигенә башларга! Варламов! Бөтен частьларга тәртип белән Кама аръягына чигенергә приказ бирегез. Резервтагы рота белән бригада штабына прикрытие булып чигенерсез. Кама аръягына чыккач, арьергард булырсыз.

В а р л а м о в. Тыңлыйм, штабс-капитан әфәнде. *(Китә.)*

Ч и н г и з о в. Прапорщик Юргатаев, кладовойдагыларны үзегез белән алып йөрмәгез, яннарына керегез дә эшләрен бетерегез.

Ю р г а т а е в. Тыңлыйм, штабс-капитан әфәнде. *(Ишегалдына чыга.)*

Ш а һ б а з керә.

Ш а һ б а з. Комендант әфәнде, Маһинурны күргәннәр.

Ю р г а т а е в. Кайда?

Ш а һ б а з. Зөбәир мунчасында, качып ята ди.

Ю р г а т а е в. Әйдә, киттек.

Китәләр. Әйберләр күтәреп өйдән З ө л ә й х а белән И с л а м чыга. Багажлар өстерәп И д р и с керә.

И д р и с. Исламгәрәй әфәнде, бу нинди вөҗдансызлык? Сәгыйть хаҗи белән ат җиктереп тора идек, солдатлар килеп керделәр дә, арбабыздан төшереп, атыбызны алып киттеләр.

И с л а м. Бернәрсә дә эшләп булмый, Идрис әфәнде, яралы офицерларны озатырга авылдагы бөтен атлар приказ белән алынды.

И д р и с. Алай булган тәкъдирдә мин ничек китим ди.

И с л а м. Ансын мин белмим инде, үзегез берәр җаен табыгыз.

И д р и с. Ничек табарга? Авылда бер ат калмаган.

И с л а м. Ул чагында тәпи-тәпи китү ягын карагыз.

И д р и с. Тәпи-тәпи?! Юк, юк, анысы миннән булмый ул. Миндә ревматизм, җәяү бер адым да атлый алмыйм.

И с л а м. Большевикларга каласыгыз килмәсә, атларсыз.

И д р и с. Аерым ат булмый икән, үз яныгызга алыгыз.

З ө л ә й х а. Юк, юк. Кеше төяп йөри торган чак түгел. Күрәсең, үз әйберләребез дә сыймыйлар.

И д р и с. Алай булса, әйберләремне генә салыгыз, үзем арба артыннан ияреп булса да барырмын.

З ө л ә й х а. Әйберләреңне дә салмыйбыз, үзеңне дә алмыйбыз. Әйдә, Исламгәрәй.

Елап К а м ә р керә.

К а м ә р. Ислам абый, сиңа килгән идем...

И с л а м. Әй, бетмәс монда сезнең эшләр.

Кереп китәләр.

И д р и с. Тукта әле, туташ, нигә болай өзгәләнеп елыйсың?

К а м ә р. Теге, писарь киявем, басу капкасыннан чыгу белән, үземне төртеп төшерде дә әйберләремне алып чапты.

И д р и с. Елама, туташ, мин аны, татар кызын, татар милләтен мыскыл итүче жуликны, болай гына калдырмам. Мин аны куып җитәрмен дә җиде бабасын танытырмын.

К а м ә р. Хәлфә абзыкаем, син моны чынлап әйтәсеңме?

И д р и с. Мин анымы, мин аны!.. Җиде кат җир астына керсә дә, эзләп табармын.

К а м ә р. Рәхмәт, хәлфә абзыкаем, рәхмәт. Ичмасам, син шул ристанны акылга утыртсаң иде.

И д р и с. Утыртырбыз, туташ, утыртырбыз. Ал менә шушы әйберләрне.

К а м ә р. Нигә?

И д р и с. Теге ристанны куа барабыз.

К а м ә р *(әйберләрне күтәреп)*. Уһу! Бик авыр икән... Бу кем әйберләре соң?

И д р и с. Минекеләр.

К а м ә р. Синекеләр? Ә нигә соң атка салмыйсың?

И д р и с. Әй, туташ, туташ, мине дә бит синең кебек кәкре каенга терәттеләр.

К а м ә р. Шулаймыни?

И д р и с. Шулай шул. Әйдә, киттек.

К а м ә р *(әйберләрне ыргыта)*. Төче телләнеп миннән күтәртеп бармакчы булган идеңме? Төкерәм башыңа. *(Итәкләрен кыстырып йөгерә.)*

И д р и с. Туташ, туташ, дим!.. Нишләргә инде? Тукта, берәрсендә бәләкәй арба юк микән? *(Китә.)*

Юргатаев Маһинурны алып керә.

Ю р г а т а е в. Иткән җинаятең менә кая китереп җиткерде. Ничек һәм кемнәр белән эшләвеңне әйтмәсәң, берничә минуттан соң каргаларга азык булырсың.

М а һ и н у р. Булсам булырмын, әмма син ерткычка азык булмам...

Ю р г а т а е в. Курбатов, Мингулов! *(Яннарына бара, аптырап кала, типкәләп уята.)* Сез нәрсә, чучка борыннар! Көпәкөндез сакта йокладыгыз? Кая болар? Кая качырдыгыз?! *(Курбатовка суга.)*

Курбатов стенага бәрелеп ава. Мингуловка кизәнгәндә Курбатов арт яктан мылтык түтәсе белән җибәрә. Юргатаев кискән агач кебек егыла.

К у р б а т о в. Бет, тончык, кабахәт!..

М и н г у л о в. Курбатов, син ни эшләдең?!.

М а һ и н у р. Абыйлар, әйдәгез минем белән.

К у р б а т о в. Әйдә, Мингулов, безгә хәзер барыбер. Беткән баш беткән. Себергәме, каторгагамы, киткән баш киткән!

Китәләр. Бәләкәй арба тартып И д р и с керә. Юргатаевның гәүдәсен күрә.

И д р и с. Йә, Ходай!.. *(Тәрәзәгә барып.)* Әфәнделәр, эшләр харап. Юргатаевны үтергәннәр!..

Йөгерешеп ишегалдына чыгалар.

В а р л а м о в. Штабс-капитан әфәнде, мондагы арестованныйларны да качырганнар!

Ч и н г и з о в. А?.. Тизлек белән телефоннарны алырга!.. Миңа ат бирегез!

З и ф а йөгереп керә.

З и ф а. Володя, әткәй!

Б а р ы с ы. Нәрсә бар?

З и ф а. Партизаннар килеп, волостьтагы арестованныйларны коткардылар. Әнә алар, урам буйлап монда таба киләләр.

Урамнан атыша-атыша партизаннар йөгерәләр. Т и м е р к ә й, Е г о р һәм б а ш к а л а р күренә.

И с л а м. Әйдәгез, арткы капкадан.

Йөгерәләр.

Т и м е р к ә й. Качмагыз, барыбер котыла алмассыз. *(Ата.)*

Чингизов егыла, башкаларының артларыннан китәләр. Шашкан кыяфәттә мылтык тотып Ә х т ә м керә. Сәхнә уртасына басып берничә тапкыр ура кычкыра, өйгә кереп югала. М ә р ф у г а керә. Сәхнә буйлап кычкырып йөри.

М ә р ф у г а. Кайда ул ристаннар, кайда ул буржуйлар? *(Авыр яралы Чингизовны күреп.)* Ә, эләктеңме, ристан... *(Чеметә.)*

Офицерлардан калган киемнәрне киеп өйдән Ә х т ә м чыга.

Ә х т ә м. Мәрфугаттәй, нишлисең?

М ә р ф у г а. Әхтәмҗан икән. Менә монда берсе дөмекми калган, үчемне алам.

Ә х т ә м. Кит әле аннан читкәрәк, дошманыңнан үчне шулай алалармы, әкият! *(Мылтык затворын ача.)*

Качкан җиреннән И д р и с чыга. Әхтәм аның каршысына төшә.

И д р и с. Син нишлисең, мужик?

Ә х т ә м. Нәрсә дидең? Нәрсә дидең? Тагын бер кат әйт әле?

И д р и с. Бетте, бетте, Әхтәмҗан абзый...

Ә х т ә м. Юк, бетмәсен әле. Бас әле менә шунда.

И д р и с. Әхтәмҗан абзый, син нишләргә уйлыйсың?

Ә х т ә м. Менә Мәрфугаттәй белән суд ясыйбыз да атабыз.

И д р и с. Атасыз? Абзыкаем, әбекәем, харап итмәгез!

Ә х т ә м. Абзыкаеммы, сукин собака! Бик күп йөрдең алар янында. Тезлән, ялагай!

М ә р ф у г а. Әхтәмҗан, бердән, мөселман, икенчедән, хәлфә кеше, калсын әйдә, бәлкем, файдасы тияр.

Ә х т ә м. Шулай дисеңме... Алай да әнә шунда ябып куйыйк әле.

И д р и с. Әхтәмҗан абзый...

Ә х т ә м. Төче телләнмә, барыбер ышандыра алмассың.

Кладовойга илтеп ябалар. М а һ и н у р керә.

М а һ и н у р. Әхтәм абзый, кара әле, басу иңләп гаскәр килә.

Ә х т ә м. Кавалерия, авылга кавалерия керде!

К о р б а н йөгереп керә.

К о р б а н. Нихәл син, гүзәл Махи... тфү... Маһинур?

Ә х т ә м. Үзең нихәл, әкият, минем чаптаркаем исәнме?

К о р б а н. Һу!.. Яхшы ат икән чаптаркай. Кичә моннан кач-кач, куып карасалар да, җитә алмадылар. Әнә капка төбендә ул.

Б а ш к а т о в керә. Ислам байның өй түбәсенә эленгән монархистлар флагын алып ташлый, аның урынына кызыл флаг элеп куя. Ачык капка аша урамнан ура кычкырып узган кызылармеецлар күренә. Т и м е р к ә й, С а м а т, Е г о р, С ә л ә х и л ә р керә.

Т и м е р к ә й. Иптәш Башкатов, акларның штабы кулга алынды. Әнә аларны китерәләр.

В а р л а м о в, И с л а м, З и ф а, Ш а һ б а з л а р ны кертәләр.

Б а ш к а т о в. Әнә шул кладовойга ябыгыз!

Хатын-кызларны ияртеп Г ө л с е м керә.

Г ө л с е м. Бишбүләк халкыннан икмәк белән тоз, рәхим итеп алыгыз!

Б а ш к а т о в. Рәхмәт, иптәшләр! Үз язмышын үз кулына алган халык беркайчан да җиңелмәс!

*Пәрдә.*

# ЭЧТӘЛЕК

Наемщик . . . . . 5
Чаткылар . . . . . 62
Ташкыннар . . . . . 126
Шомлы көннәр . . . . . 126
Даулы көннәр . . . . . 186
Данлы көннәр . . . . . 248
Бишбүләк . . . . . 323

Литературно-художественное издание

*Тази Гиззат*
*(Гиззатуллин Тази Калимуллович)*

ИЗБРАННОЕ

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Л.К.Җәләлетдинова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *М.Ш.Хәйруллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән

Оригинал макеттан басарга кул куелды 8.04.2002. Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе.
«Таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 20,16.
Шартлы буяу-оттиск 20,58. Нәшер-хисап табагы 21,40. Тиражы 3000. Заказ Б-189.

Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.